ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Ф.Г. Гарипова**

# ТАТАР ТОПОНИМИЯСЕ халкыбызның географик атамаларында – терминнар

Казан
2017

**УДК 811.512.145'373**
**ББК 81.2Тат-3**
**Г 22**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни редакторы**
филология фәннәре кандидаты **О.Р. Хисамов**

**Гарипова Ф.Г.**
**Г 22** Татар топонимиясе: халкыбызның географик атамаларында – терминнар / Ф.Г. Гарипова. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 456 б.
ISBN 978-5-93091-244-9

Монографиядә татар топонимик терминнары тикшерелә. Географик атамалар ясауда кулланылган терминнар тарихи-чагыштырма планда, таралу ареаллары ягыннан анализлана. Топонимик терминнарның вакытлар үтү белән топонимнарга әверелү юллары күрсәтелә.

Тел белгечләренә, аспирантларга, студентларга һәм татар топонимиясе белән кызыксынган киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

**УДК 811.512.145'373**
**ББК 81.2Тат-3**

**ISBN 978-5-93091-244-9**

© Гарипова Ф.Г., 2017;
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2017

## РУХИ ТЕЛ БАКЧАБЫЗ САКЧЫСЫ

Фән дөньясында үз юлын, кыйбласын табуга, үз мәктәбен булдыруга санаулы галимнәр генә ирешә. Моның өчен гомереңне эзлекле, максатчан рәвештә фәнни эшчәнлек алып баруга багышлау, шушы юнәлештә ихластан, хәтта фанатикларча хезмәт кую таләп ителә. Бакыйлыкка күчкәнче, соңгы сулышына кадәр кыйбласына тугры калып, татар ономастикасын өйрәнүгә үзеннән саллы өлеш керткән Фирдәвес Гариф кызы Гарипова әнә шундый шәхесләребезнең берсе иде.

Ул 1941 елның 7 декабрендә ТАССРның Биектау районы Кодаш авылында гаиләдә сигезенче бала булып туа. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын 1965 елда тәмамлаганнан соң, Биектау районы Ямаширмә урта мәктәбендә укыта. 1966–1970 елларда Республика фәнни китапханәсендә китапханәче булып эшләп ала. 1974 елдан 2014 елга кадәр –ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында (1996 елга кадәр − СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты дип йөртелә) лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре булып хезмәт куя. 1976 елдан Казан дәүләт педагогия институтында студентларга хәзерге заман татар әдәби теле (лексикология), татар әдәби теле тарихы, татар теленең тарихи грамматикасы буенча белем бирә, югары уку йортлары өчен дәреслекләр, методик ярдәмлекләр яза. Филология фәннәре докторы (1992), профессор (1993). Татарстанның һәм Русиянең атказанган фән эшлеклесе (1995, 2003).

Галимә татар топонимиясен өйрәнүдә төп белгечләрнең берсе исәпләнә. Аның «Духовный родник: Знаменитые татар-

ские деревни». ( Казань: Магариф, 2005), «История в названиях» (Казань, 1995), «Авыллар һәм калалар тарихыннан» (Казан, 2 томда, 2001, 2003), «Авыл – милләтебезнең җаны» (Казан, 2011), «Исемнәрдә – ил тарихы» (Казан, 1994), «Рухи башкалабыз: мәшһүр татар авыллары» (Казан, 2005), «Татар топонимиясе: халкыбызның тарихи һәм рухи мирасы» (Казан, 2011) һ.б. бик күп хезмәтләре басылып чыкты һәм фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде. Фирдәвес Гарипова татар топонимнары сүзлекләрен эшләгән бердәнбер галимә. Аның «Татарстан гидронимнары сүзлеге» (Казан, ике китапта, 1984, 1990), «Татарстан микротопонимнары сүзлеге» (Казан, ике китапта, 1992, 1993), «Татар топонимнары сүзлеге» (Казан, 2010) сүзлекләрен татар топонимиясенең казанышы дип атарга мөмкин.

Галимәнең гидронимик берәмлекләрне өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлеге аерым урын тота, гидронимия аның төп фәнни юнәлеше булып тора. Ул 1975 елда «Гидронимия Заказанья Татарской АССР (на материале бассейнов рек Ашит, Казанки, Меши и Шошмы)» дигән темага кандидатлык диссертациясен, 1991 елда «Исследования по гидронимии Татарстана» дигән темага докторлык диссертациясен яклый. Аның «Татарстан гидронимнары сүзлеге»ндә генә түгел (Казан, ике китапта, 1984, 1990), «Татарстан микротопонимнары сүзлеге» (Казан, ике китапта, 1992, 1993), «Татар топонимнары сүзлеге» (Казан, 2010) хезмәтләрендә дә гидронимнар төп урынны алып торалар.

Ул 2014 елның 4 ноябрендә Казанда вафат булып, Биектау районының Олы Битаман авылы зиратында җирләнде.

Сезнең игътибарга тәкъдим ителгән китап − Фирдәвес Гарипованың соңгы хезмәте. Ни кызганыч, авторның үзенә әлеге хезмәтнең басылып чыгуын күрү насыйп булмады. Безнең тарафтан әзерләнгән әлеге китап рухи тел бакчабызның сакчысы Фирдәвес апабыз рухына бер дога булып ирешсен иде.

***Олег Хисамов,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының*
*фән эшләре буенча урынбасары*

## ТАТАР ГЕОГРАФИК АТАМАЛАРЫНДА – ТЕРМИННАР

*Туган җиреӊ чүл булса да,*
*Күңелдә ул гөл генә!*
*Ватан катлы-катлы булмый,*
*Ватан була бер генә!*
Равил Фәйзуллин

Татар теле төрле типтагы ялгызлык исем-атамаларына, ягъни ономастика берәмлекләренә бик бай. Аларны өйрәнү үтә дә зарури, моның шулай икәнен аңлау өчен XIX гасырда яшәгән рус галиме Н.И. Надеждин сүзләрен искә төшерү дә җитә. «Җир – шундый китап ул, кешелек тарихы анда география терминнары белән язылган» (Надеждин, 1837). Татар географик берәмлекләре һәм аларның атамалары ясалуына катнашкан терминнарның күп булуы – халкыбызның югары дәрәҗәдәге мәдәни үсешкә ирешүенең бер чагылышы ул. Мәгълүм ки,Урта Идел буйларында һәм башка төбәкләрдә су-елгалар һәм башка географик берәмлекләр халык тормышында алыштыргысыз кыйммәткә ия булганнар.

Александр Гумбольдт «Үзәк Азия» («Центральная Азия») дип исемләнгән хезмәтендә «Татар телләре рельеф, җир өстенең төрләрен чагылдыра торган берәмлекләргә бик бай», – дип язып калдыра. «XIX гасырның данлыклы географы һәм энциклопедисты Александр Гумбольдт мондый нәтиҗәгә 1829 елда

Идел–Каспий һәм Алтай аралыгындагы җирләрдә үзе булып, үзе күреп кайтканнан соң килә. „Татар телләре“ дигәннән, галим Азия һәм, өлешчә, Россиянең Европа өлешендәге дала һәм ярымдала зонасында яшәгән барлык төрки һәм монгол халыкларын күз алдында тота» (Мурзаев, 1966: 40).

Җирле тарихны өйрәнү өчен географик атамаларның һәм аларны барлыкка китерүдә канашкан терминнарның әһәмияте хакында Л.С. Берг, А.П. Дульзон, Д.П. Европеус, М.А. Кастрен, В.В. Радлов, В.П. Семенов Тянь-Шаньский, Э.М. Мурзаев, С.А. Суперанская, А.К. Матвеев, В.А. Никонов, К.К. Целуйко, О.Т. Молчанова, Е.И. Чернышов, М.Ф. Розен, А.М. Малолетко, В.Н. Барашков, Э.Л. Дубман, Ю.Н. Смирнов һ. б. зур хезмәт куйганнар.

Бу өлкәгә зур өлеш керткән татар галимнәре дә шактый: Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Һ. Атласи, Һ.В. Йосыпов, Г.Х. Ахунҗанов, Г.Ф. Саттаров, Ф.С. Фәсиев, Р.Г. Әхмәтьянов, Ф.Г. Гарипова, Х.Ч. Алишина һ. б. галимнәр язганнар һәм язалар.

Э.М. Мурзаев фикеренчә, топонимик тикшеренүләр җирле географик терминнарны җыеп системага салудан башланырга тиеш. Чөнки мондый төр терминнар: а) атамалар барлыкка килүдә зур роль уйныйлар; б) этимология ачкычы хезмәтен үтиләр; в) географик берәмлекне ачыклап, аерып, икенче төрле әйткәндә, классларга, төрләргә үк бүлеп тә күрсәтәләр (Мурзаев, 1966: 3).

Борынгы заманнарда төрле су чыганакларын һәм гомумән топонимнарны атау өчен кулланылган *буа, күл, инеш, елга, урман, дала, ышна, алан, ялан, үзән, кыр, каш, кичү, чишмә* һ. б. кебек күмәклек сүзләр соңыннан ялгызлык исемнәренә әверелеп киткәннәр. Бу төр, ягъни физик-географик терминнарга нигезләнгән атамалар, бигрәк тә су чыганакларына мөнәсәбәтлеләре, топонимик әдәбиятта иң борынгы атамалар буларак карала. Моны төрки халыклар топонимиясе мәгълүматлары да раслый. Славян (Воробьева, 1973: 215), төрки, фин-угор, монгол, тунгус-маньчжур (Мурзаев, 1966: 4) һ. б. халыклардагы

гидронимнарның һәм топонимнарның күпчелеге җирле география терминнарыннан тора.

*Дон, Днепр, Дунай* атамаларының тамыры *дон* борынгы скиф телендә «елга» мәгънәсен белдергә (Абаев, 1958: 366–367). Чуваш телендә бу сүз хәзерге көнгә кадәр *тан* (боз өстенә чыккан су) формасында (Ашмарин, 1937: 177), татар диалектларында *дан*, табар әдәби телендә *тан, тын* (Танширмә, Данурай дигән елга атамалары), мордва халкында *Сарадан* (Смирнов, 1895: 7), осетиннарда кайбер зур һәм кечкенә елгаларның (Ардон, Гизельдон, Фипкачдон һ. б.) исемнәре составында сакланган (Абаев, 1949: 235). Бу тамыр элементны үз эченә алган атамалар көньяк Себердә, көньяк-көнчыгыш Саха-Якутиядә, Чита, Амур өлкәләрендә, Бурятиянең төньягында (Дар-Дан-Гол: Мельхеев, 1969: 42), Иркутск өлкәсенең көньяк-көнчыгыш өлкәләрендә очрый (Дульзон, 1970: 96).

Африкадагы Нил елгасының исеме дә симет-хәмит телендә «елга» төшенчәсен белдерә торган *начал* сүзенә барып тоташа (Никонов, 1959: 293). Ханты телендә Мую-Юган, Мат-Юган, Рытьеган, Кава-Еган, Кул-Еган һ. б. гидронимнарның икенче компонентлары да *елга* дигән мәгънәне аңлата (Мурзаевы, 1959: 263).

*Дэльгер-Мурэн, Селенг-Мурэн* һ. б. елга атамалары составында кулланыла торган *мурэн* берәмлеге бурят һәм монгол халыкларында «күп сулы зур елга» дигәнне белдерә. Монголлар Иделне *Итиль-Мурэн* дип атыйлар.

Географик объект-берәмлекләрне атау-тасвирлау өчен кулланыла торган география терминнарының аерым географик берәмлекләр атамасына әверелү күренеше бик борынгы чорлардан ук килә. Моның субъектив сәбәбе – халыкның географик берәмлекләрне бер-берсеннән начар аеруы, ә объектив сәбәбе – аларны төгәл аеру мөмкинлеген тудыручы тарихи шартларның аерым чорларда өлгереп җитмәве, су чыганакларын һәм гомумән географик объект-берәмлекләрне аеру зарурлыгының көн таләбе дәрәҗәсенә күтәрелмәве. Бу вакытта әле кешеләр үзләренең

торагы тирәсеннән башка урынны белмәгәннәр. Тирә-юньдәге географик атамаларның саны бер яки берничә генә булып, халык аларны *су, елга, алан ялан, сазлык, күтер, калкулык, кирмән, авыл, дәрья, сырт, уйсулык, урмае, кизләү, борын* һ. б. рәвешле генә кабул иткән. Борынгы халык җир өслеген иң гомуми ике өлешкә генә аерып, коры җир һәм су дип кенә караган.

Тормышның алга таба үсүе нәтиҗәсендә, ыруглар һәм кабиләләр бер-берсе белән тыгыз аралаша башлагач, физик-географик объект берәмлекләрнең һәрберсен аерым-аерым атау, аларны бер-берсеннән аеру зарурлыгы көн тәртибенә куелган. Тирә-юньне ныклап үзләштерү барышында, элемтә, юнәлеш (ориентир) билгеләү, балык тоту, сугару чыганагы булу һәм башка практик максатлар таләбе нигезендә, су чыганаклары, иң элек, бик гомумиләштерелгән төрләргә (мәсәлән, коры *җир* һәм *суга*, ә соңыннанрак ага һәм акмый торган суларга) бүленгән. Тора-бара бу гомуми төрләрнең генә халык ихтыяҗларын канәгатьләндереп бетермәве ачыкланган. Җир һәм су чыганаклары күбрәк үзләштерелә барган саен, терминнарның гомуми төрләр сафына керә торган һәм детальләнеп аерылган җирле төрдәшләре барлыкка килгән (мәсәлән, *күл* сүзенең хәзерге диалекталь формалары: *тоба, чүгәт, күлләвек* һ. б.). Мондый күмәклек сүзләрдән торган атамалар тирәлекнең физик-географик үзенчәлекләрен, ягъни үз билгеләрен шактый нечкәләп ачыклыйлар. Гидронимик әдәбиятта төр (родовые) терминнары дип аталган *күл, буа, су, чишмә, болак* кебек гомумтөрки гидронимик атамалар төрле киңлекләрдә таралыш алганнар. Төр терминнары сыйфатында, гадәттә, әдәби лексика файдаланыла. Бер үк типтагы су чыганакларының (мәсәлән, күлләрнең) төрле рәвешләрен күрсәтә торган *җан, чүгәт, тоба, күлләвек* кебек диалекталь атамалары *төрчә* (видовые) *терминнар* хасил итәләр. Соңгыларының таралу ареалы чикле.

Тирә-юньдә дөрес юнәлеш алу өчен борынгы бабаларыбыз үзләренең гәүдә әгъзаларыннан уңышлы файдаланганнар. Моңа беренчеләрдән булып Каюм Насыйри игътибар итә. Галим

Э.М. Мурзаев исә бу күренешнең башка милләт халыкларына да хас икәнлеген күрсәтә. Мондый атамалар бик борынгы булып, чал тарих белән бәйләнәләр. Кешеләрнең элек үз-үзен, гәүдәсен һәм аның өлешләрен танып-белү нигезендә кушылган *Акбит, Акбаш, Аккүз, Карабаш, Карачәч, Каракаш* һ. б. антропонимнары да борынгы төрки исемнәргә керәләр.

Галимнәр фикеренә караганда, терминология мәсьәләсе фән-техниканың саф эчке эше генә түгел. Ул гомуми әдәби тел төзү, мәктәп-мәгариф, мәдәният һ. б. иҗтимагый эшчәнлекләр белән турыдан-туры тыгыз бәйләнгән. Шуңа күрә бүгенге көндә дә терминнар киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә, республикабызның хуҗалык-идарә һәм мәдәни төзелешендә актуаль функция үти (Фасеев, 1969: 3).

Җәмгыять үсеше алга барган саен, топонимнарны аерып карауга ихтыяҗ арта бара. Атама биргәндә барлык төр географик берәмлекләрнең күзгә ташланып торган физик-географик үзенчәлекләре, яисә тормыш-көнкүреш өчен әһәмиятле ягы исәпкә алына. Шул рәвешле, *Кәкре күл, Ышна басуы, Урман күле, Озын күл, Ялан күпере, Балыклы елга, Кыр күле, Сай елга* кебек атамалар барлыкка килә. Аерым бер атаманың үзен генә топонимия системасыннан аерып, ялгызын гына карарга, тикшерергә ярамый. Чөнки һәр атаманың урыны билгеле бер топонимик системада була, ә һәр оя үзе бу системаны төзүче нигез вазифасын башкара.

Географик атамалар ясауда кулланылган терминнарның кайберләре гомумтөрки бергәлек, бәлки әле аннан да элгәрерәк антик чорларда барлыкка килгәннәрдер. Чөнки татар географик атамаларын ясау, барлыкка китерүдә катнашкан терминнарны тикшерү-анализлау барышында аларның бик тирәнгә китүен, бабаларыбызның якын һәм ерак җирләрдә яшәгән кавем-кабиләләр, халыклар белән тыгыз аралашуларын тоемларга һәм күрергә мөмкин. Мәсәлән, әрмән чыганакларында кыпчак бабаларыбызга нисбәтле кадерле мәгълүматлар галим Искәндәр Абдуллин архивында саклана. Кызганыч, хәзер безнең

институтыбызда бу хезмәтне редакцияләп бастырып чыгара ала торган галим юк. Шулай ук тунгус-маньчжур, фин-угор, грузин һәм гомумән Төньяк Кавказ, Россиянең һәр төбәгендә, Молдовада (гагаузлар), Балтыйк буе республикаларында, Польшада (караимнар), Европаның Германия, Франция, Англия, Италия, Австрия, Болгария, Испания кебек илләрендә яшәгән халыкларга нисбәтле география атамалары составында һәм аерым атама буларак безнең җирлектә очрый торган географик берәмлекләргә туры килә торган лексик төрдәшләр, формантлар очрыйлар. Менә шуның өчен дә «...терминология эшчәнлеге антик заманда ук башланып, ул чакта бары берничә тел һәм кайбер фәннәр белән чикләнгән булса, хәзер төрле илләрдә йөзләрчә телдә фәнни-техник, укыту-педагогик, иҗтимагый-сәяси, сәнгать-спорт һ. б. тармаклар буенча меңнәрчә атамалар эшләнеп практикага кертелә. Термин теориясе, предметның гаять киң, объектларның төрле ишле булуы сәбәпле, термин төзү практикасын иңләп, гомумиләштереп өлгерә алмый (муллык аркасында фәкыйрьлек!), хәзергә теория урынына аерым (еш кына капма-каршы) принциплар, киңәш-рецепт төсендәге таләп-норма һәм кагыйдәләр хөкем сөрә» (Фасиев, 1969: 7).

Басмада топонимиягә караган йөздән артык термин тикшерелде. Алар барысы да тарихи-чагыштырма планда, төрки халыклар, шул исәптән татарларда хәзер яшәүче яисә кайчандыр яшәп киткән төбәкләрдәге материаллар файдаланылып, ягъни таралыш ареаллары күрсәтеп анализланды. Шул ук вакытта аерым топонимия терминнарының вакытлар үтү белән атама буларак куланыла башлаулары да күрсәтелде.

Борынгы заманнарда ук татар халкы су-инешләрне, һәр башка географик берәмлекләрне хөрмәтләгән, озынлыкларына һәм башка физик-географик үзенчәлекләренә карап исемнәрен атаган. Хәзерге татар телендә топонимия терминнары булып түбәндәге лексик берәмлекләр хезмәт итәләр.

***Авыз***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *авыз* лексик берәмлеге исем дип ныгытылган һәм аның *өченче мәгънәсе* бо-

лай аңлатылган: «Мич, шалаш, оя һ. б. ш. кебек эче куыш нәрсәләрнең алгы өлешендәге тишек. *Хәлим керергә дип шалаш авызына килде һәм анда сөйләшкән тавышларны ишетеп туктап калды*. Г. Гобәй. *Нургали тартып бетермәгән тәмәкесен сүндермичә мич авызына ыргытты*. Ә. Еники. *Шул стенада тау куышыдай булып шахта авызы күренә*. А. Расих».

*Дүртенче мәгънәсе*: «Янар тау түбәсендә лава агып яки атылып чыга торган тар һәм тирән тишек. *Без янар тау авызыннан атылган утлы туфрак һәм көл булып һавага ыргылдык*. Ә. Еники. // Бомба яки снаряд шартлаудан барлыкка килгән чокырның өсте».

*Сигезенче мәгънәсе*: Урман, әрәмәлек кебек нәрсәләрнең чите, кырые, башланган яки беткән урыны. *Урман авызы. Захаров аларны, ашыктырып, әрәмәлек авызына алып чыгып китте.* А. Шамов. *Каенлык авызында аларны ...чандыр немец офицеры каршы алды*. Ә. Еники.

*Тугызынчы мәгънәсе*. «Елга, инеш коя торган урын, тамак». Елга авызы. *Без пароход йөртеп уйнаган ермак авызында пристань була*. Г. Гобәй. (ТТАС, 1: 7).

Шушы ук сүзлектә *урман авызы* гыйбарәсе «урманның юл ачыклыгы башланган урын, урманга кереп китә торган урын», – дип бирелгән. Мисаллар да китерелгән. *Сәлим шунда ук нечкә генә кыңгырау тавышын ишетте, һәм урман авызында җигүле ат күренде*. Г. Гобәй. (ТТАС, III: 313).

Ләйлә Мәхмүтова мәгълүматларына караганда, *awыз/авыз* лексик берәмлеге *авыз* мәгънәсендә «Codex Cumanicus» (1303 ел) хезмәтендә очрый.

Ләкин бу чыганакта әле аның «елга авызы, ягъни бер елганың икенче елгага койган өлеше *авыз* дип аталуы бирелмәгән. Күрәсең, бу чорда ул әле кулланылмаган.

*Авыз* термины географик атамалар ясауда шактый катнаша: *Урман авызы* – Тәтеш районының Олы Тархан авылы янындагы урын атамасы; *Урман авызы болыны* – Тәтеш районының Олы Тархан авылы янындагы болын атамасы; *Тыкрык авызы* – Кама

Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында, Ылгыма елгасы бассейнында. *Аргы тыкрык авызы* – Олы Мәрәтхуҗа авылы, Кама Тамагы районы. Каенлы елгасы бассейнында. *Бирге тыкрык авызы* – Олы Мәрәтхуҗа авылы янында, Кама Тамагы районы. Шомыртлык авызы – Буа районы Карлы авылы янындагы урын атамасы.

Нурулла Гариф сүзлегендә Балавыз елгасы атамасы урын алган: Балаусовка (Балавыз елгасы) – Казан елгасының сулъяк, түбән агымында, Янчура, Клетни авылы янында, Арча юлы өстендә.

*Балавыз* – Чистай районында Чирмешән елгасы кушылдыгы, *Уравыз елгасы* – Аксубай районында, Олы Сөлчә елгасы, *Су авызы* – Бөгелмә районында Димескәй елгасы. *Сыза авызы* – Яшел Үзән районында Зөя суы кушылдыклары. Казандагы хәзерге Калинин бистәсе элек *Балавыз* дип йөртелгән. Шушы соңгы атамадан *Балавыз урманы* дип йөртелгән атама барлыкка килгән. *Балавыз урманы аланы*, *Авыз урманы*. *Авыз* компоненты белән Адай авылында (Актаныш районы) *Дүмгәк авызы* – түмгәкле бер болынга керү урыны билгеләнгән. Күршедәге Бикбау авылында (Минзәлә районы) *Япма авызы* – атауның күл әйләндереп алмаган коры җире. Шул ук районның *Найдаш авызы* – шул исемдәге урынның башланган җире. Минзәлә районының Бикбау авылы янында *Читтән авызы* Юалык болынындагы бер сыза. *Шомыртлык авызы* – Буа районы Карлы авылы янындагы урын атамасы.

*Урман авызы* гыйбарәсе һәм гомумән *авыз* термины югарыда күрсәтелгән мәгънәдә әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында кулланыла.

Гомәр ага Бәшировның «Намус» романында *урман авызы* гыйбарәсе кулланылган: *Нәфисәләр урман авызыннан кереп, тар сукмактан бераз барганнан соң, иренчәк агымлы кечкенә генә инешне узып, бер ачыклыкка килеп чыктылар.* Г. Бәширов.

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» дип исемләнгән повестенда мондый җөмлә бар: *«Үлчисең, көрәк оны*

*бирәсең, капчыгыңны чишеп мөшкә авызына шудырып куясың да аска төшәсең».*

Мөхәммәт абыйның бу мисалындагы *мөшкә* сүзен хәзер яшьләр аңламаска да мөмкин. Хәзер елгалар, буалар яннарында тегермәннәр юк.

Вахит Имамовның «Сәет батыр» дип аталган тарихи повестенда *урман авызы* еш очрый: *«Сәет кул астында тупланган йөзләгән ир һаман да шул Баландышны тирәләп, урман авызында ята иде...»*

Айдар Хәлимнең «Кыйбла: хикәяләр, новеллалар» (Казан: Татар кит. нәшр., 2005. 382 б.) китабында да урман авызы гыйбарәсе күңелләрне әллә нишләтеп, шомландырып, «бу ни бу», «ни беләр бетәр бу халәт»! – дип, эчке бер дерелдәү белән абзац беткәнне күтәсең. *«Гүя үзәннәрне басып килгән язгы ташкын тар, ясалма буа авызына килеп тыгылды, күзле бозлар, берсе өстенә берсе менеп, җан ачулы тавышлар чыгарып һәм шытырдап уалды, кинәттән алар барысы да астан, тирәннән этәрелгән көч белән күккә аткарылды, аннан, хәлләре бетеп, җиргә тартылды, яр буенда бөреләнеп килгән таллыкларны имгәтте».*

*Авыз* апеллятивы белән ясалган атамалар Россия буйлап сибелгән татарлар телендә дә еш очрый. *Ауз, авуз, авузь, авус, агиз, агызь, ахиз* лексик компонетлары Кырым татарларында, Ульяновск өлкәсендә (*Кулаткы авызы* Иске Кулаткы районы Усть-Кулаткы авылы микротопонимы, Иске Кулаткы районы Яңа Кулаткы авылында *Башсыз елгасы авызы* һ. б.), Самара өлкәсендә (*Карамалы елга авызы, Торна елга авызы, Соргыт елга авызы* – Камышлы районындагы Иске Ярмәк һәм Татар Байтуганы авылларындагы елгачыклар һ. б.), Башкортстанда (*Булат елга авызы* – Яңаул районында, *Утар елга авызы* – Тәтешле районында, Күмертау районында Куергаз елгасының уң кушылдыгы *Казакавыз* елгасы бар һ. б.) очрый.

Борынгы төрки телдә *aγiz* – «рот», «отверстие», «устье реки» (ДТС, 1969: 21). М. Кашгари сүзлегендә *aғis* – «устье

арыка», «устье колодца» (МК, 1: 88). В. Радлов сүзлегендә күрсәтелгәнчә, чыгтай телендәге *aғis* – «рот», «отверстие», «ущелье реки» (Радлов, I, Ч. 1: 171) функциясен үтәгән. Төрки телләрдә бу сүзнең төрле фонетик төрдәшләре (вариантлары) бар, мәсәлән, балкар телендә – *авуз,* үзбәк телендә – *огиз,* төрекмән – *агыз,* башкорт, казак телләрендә – *ауыз,* азәрбайҗан – *агыз,* кыргыз телендә *ооз* «бер елганың икенчесенә кушылган урыны», «елга тамагы» мәгънәсендә кулланыла. Балкар гидронимиясендә аузның «тарлавык» мәгънәсе дә актив кулланыла. Мәсәлән, *суу аузу* – «су тарлавыгы» (Коков, Шахмурзаев, 1970: 113). Бу апеллятив, ягъни *ауз* – «елга юлы» мәгънәсендә дә йөргән (Мусукаев, 1981: 91). Казакстанда – *Аузорпа (орпа* – «сай кое»), *Аузу* – «басу уртасында калган күл яки урман» (Койчубаев, 1974). Төркмәнстанда *Ташауз* өлкәсе һәм *Ташауз* шәһәре, *Агзыгара* чишмәсе һәм *Агзыдашт* тигезлеге бар (Атаниязов, 1980: 22). Алтайда – *Каоозы, Он-Оос,* Иртыш елгасы бассейнында *Агыз аул* атамасы алган аул бар. Төньяк Кавказда *Тырны-Ауз* һ. б. Коми гидронимиясендә *ауз* – «елга авызы», мәсәлән: *Важадыз.* Кырымдагы Ураус-Дереси атамасы үзенең килеп чыгышы белән борынгы төрки телдә «елга» төшенчәсендә йөргән *ураус~урауз* сүзләренә барып тоташа (Сл., 1979: 5801). Бу апеллятивның таралыш ареалы Э.М. Мурзаев тарафыннан тикшерелә (1984: 38). Кыскасы, төрки телләрдәге *аас/агыз/агыс/авыз/авус/ауз/огис/оос* – «авыз» топонимиядә «тамак», «елга», «елга тамагы», «чыганак, су башы, елга башы, чишмә башы»н аңлата. Бу лексик берәмлек белән ясалган географик атамалар күп җирләрдә очрыйлар (мәсәлән, Төньяк Кавказда *Тырны-Ауз* һ. б.).

***Авыл (аул)***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек исем дип бирелгән һәм аның түбәндәге мәгънәләре күрсәтелгән: «1. Авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче халык яши торган урын, торак пункт. *Авылны чыккач, Хәлим малайларга пилоткаларын салып бүрек кияргә кушты*». Г. Гобәй.

2. Авылда яшәүчеләр, авыл халкы. *Бөтен авылның диярлек бу спектакльне кызыксынып көтүе безнең болай да канат-*

*ланган йөрәкләребезне җилкендерә.* М. Әмир. *Авыл уянды. Өй түреннән, урам тутырып, көтү үтеп китте.* (ТТАС, Т. 1).

Күренекле диалектолог Ләйлә Таһир кызы Мәхмүтова мәгълүматларына караганда, *awыл/авыл* лексик берәмлеге татар телендәге *авыл* мәгънәсендә «Codex Cumanicus» (1303 ел) хезмәтендә очрый.

Төзүче-автор буларак А.К. Тимергалин җыеп дөньяга чыгарган «Миллият сүзлеге»ндә (Казан, 2007: 12) *авыл* турында мондый сүзләр язылган: «Авыл – татар-кыпчак сүзе. Борынгы төркичәдә *агыла* «киртәләп алынган урын, кура, табыр сүзеннән» (Р. Әхмәтьянов). Рус телендә шул рәвешендә языла. Зуррак авылларны элегрәк гарәпчә сүз белән *карья* дип тә атаганнар, ә башкорт якларында авылны, *җәйләүдән* аерып, *ызма* дип тә йөрткәннәр.

*Авыл* термины бигрәк тә үзбәк һәм таҗик телләренә хас «кышлак» мәгънәсендәге сүзгә туры килә (мәсәлән, үзбәктә авыл хуҗалыгы – *кышлак хуҗалыгы*).

Украинада авыллар *хутор* һәм *станица* дип атала (*хутор* төркичә *утар* сүзеннән булырга тиеш, ә *станица* – *стан* тамырыннан ясалган, шул ук торлак). Рус телендәге *село* термины чиркәүле зур авылны белдерә. Татар сөйләмендәге *сала* рус теленнән кергән (аеруча мишәр теленә хас сүз, караим телендә дә бар). Мәгънәсе ягыннан *сала* сүзе карьяга тарта шикелле.

Олы авылдан бүленеп чыккан торак пунктлар бездә «Яңавыл» дип йөртелә. Рәсми чыганакларда русча «выселки», «починок» (татар «пучинкә» ди) терминнары очрый. Хәзерге вакытта мондый торак пунктлар саны кимегәннән-кими, кайберләрендә ике-өч хуҗалык кына утырып калган.

Татар авылларының исемнәре гадәттән тыш чуар, әмма аһәңле һәм, кагыйдә буларак, күңелгә ятышлы. Татар шагыйре Гәрәй Рәхимнең «Безнең авыллар» дигән шигырендә бу – гүзәл чагылыш тапкан:

*Матур минем туган авыл –*
*«Аланлык» дигән авыл.*

*Күрше авыл да бик матур –*
*«Баланлык» дигән авыл.*
*Урман кебек гөрләп үсә*
*«Имәнлек» дигән авыл,*
*«Юкәлек» дигән авыл,*
*«Каенлык» дигән авыл,*
*«Наратлы» дигән авыл.*
*«Усаклы» да бик матур,*
*«Зирекле» дә бик матур,*
*«Карагай» авылы да,*
*«Җиләкле» авылы да –*
*Бик матурлар бары да.*
*Хыялларга канат куя*
*«Җиһан» исемле авыл,*
*«Болгар» исемле авыл,*
*Һәм «Кондыз» дигән авыл,*
*Һәм «Йолдыз» дигән авыл.*
*«Сәфәр» дигән авыл да,*
*«Яшәр» дигән авыл да,*
*Һәм «Кызыл Көрәш»е дә*
*Һәм «Кызыл Керәшен» дә.*
*Булсын әйдә, булсын җирдә*
*«Ташлы» дигән авыл да,*
*«Кашлы» дигән авыл да,*
*«Тигәнәкле» дә булсын,*
*«Тигәнәле» дә булсын,*
*«Кәкре Елга» да булсын,*
*«Бөкре Елга» да булсын,*
*«Тайгаклы» дигән авыл,*
*«Сайгаклы» дигән авыл.*
*Му авылы да булсын,*
*«Су» авылы да булсын,*
*«Ала Елан» авылы,*
*«Кара Елан» авылы.*

*«Түбән авыл» да булсын,*
*«Кече авыл»да булсын.*
*Булсын «Әби авылы»,*
*Булсын «Бабай авылы»,*
*Булсын «Малай» авылы,*
*«Көек» дигән авыл да,*
*«Кыек» дигән авыл да,*
*Өч өйле дә булсыннар.*
*Өч йөз өй дә булсыннар,*
*«Мөрәле» дигән авыл,*
*«Шүрәле» дигән авыл,*
*«Кече Таң» дигән авыл,*
*«Кычыткан» дигән авыл,*
*«Базарлы Матагы» да,*
*Базарсыз «Матагы» да.*

Хәзерге урбанизация (шәһәрләшү) дәверендә татар милләтенең һәм мәдәниятенең яшәеше, хәтта сакланып калуы өчен, авылларның әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Менә монда милли сәясәт белән гомуми икътисадны үзара гармонияле үстерү мәсьәләсе хәл итә.

«***Авыл көе***» – Гадәттә, авыл җирендә җырлана торган кыска лирик җыр, дүртьюллык.

***Авыллык*** – Археологиядә борынгы авыл калдыкларын (хәрабәләрен, урынын ~ ныгытылмаган торак калдыкларын) белдерә торган термин. «Шәһәрлек» термины белән бер өлге буенча ясалган сүз, русчадан (селище) калька. Татарстанда болгар чорына нисбәтле 1000 нән артык авыллык билгеле».

Шушы ук рәткә тагын Адлер Тимергалин сүзлегендә бирелгән *аймак* лексик берәмлеген дә кертеп карыйбыз. «*Аймак* – монголча *ай – «җыю, туплау»* сүзеннән. Мәгънәсе – зур төркем, ырулар берләшмәсе әммәт, җәмәга (русча – община). Хәзерге татар телендә: 1. Җир, урын, төбәк. 2. Нәсел, ыру, кабилә. //*Ак каймак татарлары. Кара аймаклар*. 3. Төркем, даирә. // *Аймакташлар җыелышы*».

А.К. Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә «*Багавыл* тарихи термин – караучы, химаяче, опекун. Н. Исәнбәттә *багавыл* – авыл башы, бәк авыл. Р. Әхмәтьянов «багавыл – тикшерүче-инспектор» дип аңлата. //Яман илгә ясавыл булма, бөлгән илгә бүкавыл булма. Мәкаль».

*Авыл* лексик берәмлеге топонимнар ясауда актив кулланыла: Касыйм авылы – Кече Чынлы (Чүпрәле районы) авылын элек шулай Касыйм авылы дип атап йөрткәннәр.

*Авыл тавы* – 1. Теләче районының Иске Җөри авылы; 2. Саба районының Югары Утар авыллары янындагы тау атамалары. *Авыл ышнасы* – Кама Тамагы районының Иске Казиле авылы басуы. Ышна – урман кисеп, җирне агачлардан чистартып ачылган урын. *Авыл очы болыны* Семистрау (Өшәр) авылы Актаныш районында. *Авыл читендәге чишмә* – Аксубай районының Яңа Ибрай авылы янында. *Авыл ермагы* – Апас районындагы Шуширмә авылында (Гөбенә елгасы бассейны). *Авыл урманы* – Апас районының Аххуҗа авылы янында. *Авылдан югары елга* – Арча районының Корайван авылы янында, Кесмәс елгасы бассейнында. *Авыл кизләве* – Яшел үзән районының Карашәм авылы янында, Мөсәл елгасы бассейнында. *Авыл елгасы* – Чүпрәле районы Алешкин Саплык авылы янында. *Авыл күле* – Апас районының Мөрәле, Бортас, Әлмәндәр, Кече Бакырчы; Нурлат районының Кычытканлы; Тәтеш районының Үтәмеш; Буа районының Адав-Толымбай; Иске Суыксу; Кама Тамагы районының Кече Карамалы һәм Салтыган авылы яннарындагы күлләр. *Авыл елгасы кизләве* – Чүпрәле районы Алешкин Саплык авылы янындагы *Авыл елгасы* ярында. *Авыл күле чыганагы* – Апас районы Мөрәле авылы янындагы *Авыл күле* бассейнында. *Авыл суы* – Саба районы Олы Шыңар; Арча районы Югары Мәтәскә авылы; Биектау районы Кече Солабаш авыллары янындагы тау чыганаклары. *Авыл эчендәге елга* – Саба районы Тимершык авылында. *Югары авыл зираты чишмәсе* – Чирмешән суы бассейнындагы, Апас районы Дәүләки авылы янындагы чишмә. *Югары авыл юлы* – Кама

Тамагы районы Олы Кариле авылы янындагы юл атамасы. *Югары авыл елгасы* – Чирмешән суы кушылдыгы, Апас районы Багыш авылы янында. *Югары авыл кизләве* – Бия елгасы бассейнында, Апас районы Югары Ындырчы авылы янында. *Югары авыл чишмәсе* – Куак елгасы бассейнында. *Иске авыл* – Яшел Үзән районы Бишнә авылы. Бу авыл кешеләре үзәннән күчеп килгәннәр. Үзәндә авыл эзе әле дә бар. *Иске авыл болыны* – Мамадыш районы Еники-Чишмә авылы янындагы болын атамасы. *Иске авыл зираты* – Сарман районы Баш авылында. *Иске авыл идәне* – Нурлат районы Киекле авылында урын атамасы. *Иске авыл юлы* – Мамадыш районы Кече Сон авылы янындагы юл атамасы. *Иске авыл күле* – Нурлат районы Би күле авылында. *Иске авыл суы* Питрәч районы Чыты авылында. *Иске авыл сырты* – Мортыш-Баш авылы Сарман районы. Калкулык атамасы. *Иске авыл урыны* – 1. Алабуга районы Бәзәкә авылы; 2. Лениногорск районы Бәкер авылы; 3. Мамадыш районы Еники-Чишмә авылы; 4. Нурлат районы Кәкре атауда; 5. Сарман районы Мортыш-Баш авылында; 6. Яшел Үзән районы Юынчы авылында.

*Авыл* лексик берәмлеге авыл атамалары ясауда да катнаша: Биектау районында *Яңавыл* атамасы алган авыл бар. Кама Тамагы районында Минглич авылы халык телендә *Абызавыл* дип йөртелә. Мамадыш районының Олыяз авылы җирлегендә *Кыравыл* атамалы торак җирлек урнашкан.

Авыл атамаларының күбесе тарихи чыганакларда очрыйлар. Нурулла Гарифның «Тарихи чыганакларда төрки-татар исемнәре һәм географик атамалар» дип аталган сүзлегендә хәзерге Спас районы җирлегендә элек булган *Озын авыл* турында мондый сыйфатлама укыйбыз: «Долгая (*Озын авыл*), чюв (ясаклылар), Нугай юлы өстендә, Яңа Салман авылы янындагы юл буена урнашкан». Бу авыл хәзер картадан юкка чыккан.

*Авыл* лексик берәмлеге әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында бик еш һәм тирән мәхәббәт белән кулланыла.

Туган авыл ул – туган нигез, туган җир, туган як һәм туган туфрак. *Авыл* дигәндә менә шул төшенчәләр дә күз алдында тотыла.

*Аул* лексик компоненты башка төрки телләрдә дә кулланыла: төрк диалектларында аулны, кырым татарларында авыл җирлеген (төрек диалектларында да авыл җирлеген) аңлата (Севортян, 1974), команнарда *аул* – «авыл җирлеге» (Радлов I: 74, 75).

Аулны Э.М. Мурзаев болай сурәтли. *Аул* атамасы – Көнчыгыш һәм Кавказ регионнарында кулланыла. Аул, бистә, лагерь, күчмә халыкларның юрталардан торган туктап тору урыны, торак, йорт, гаилә һәм хуҗалык. *Авул, авыл, ауыл, айыл, аил, агыл* компонентлары рус теленә төрки телләрдән кабул ителгән. Бу лексик берәмлек башка төбәкләрдә яши торган төрки булмаган халыклар телендә дә очрый. Монгол телендә *аил* – «авыл, сала, поселок (бистә)», «юрталар төркеме», «утар», «усадьба». Кайбер тунгус-маньчжур телләрендә *айил* – «авыл», «бистә», «күрше». Бу терминның таралыш ареалы Кече Азиядән алып Тын океанга кадәр. Башкортстанда *Яңаул/Янаул* атамасы күп тапкырлар кабатлана. Авыл атамаларының бу модель белән ясалуы Казакстанда да күзәтелә. Анда да, Павлодар һәм Көнчыгыш Казакстан өлкәләрендәге кебек, *Жанааул* (ягъни Яңавыл) дип аталган торак пункт атамалары бар. Зур Барсук исеме алган ком чүлендә *13* саны алган аул бар. Карталарда ул «Унөченче аул» («Аул 13-й») дип бирелә. Кемерово өлкәсе җирләреннән ага торган Кондома елгасы ярындагы авыл *Аил* дип йөртелә. Чечен Республикасында *Чеченаул* бар. Дагстанда *Байрамаул, Темираул, Ленинаул* исеме алган торак пунктлар очрый.

Көнбатыш Себердә, Иртыш елгасы бассейнында *аул* лексик берәмлеге белән ясалган авыллар шактый күп: *Кубяк авыл, Коллар авылы, Утрау авыл, Сала аул, Ука аул, Ускат аул, Вагай аул, Ишим аул, Тау аул, Агыс аул, Утыз аул, Ташаткан аул, Артыш аул, Карагай аул, Кашкара аул, Тар-Тамак аул* (Тара елгасы бассейны), *Толбазы аул* һ. б.

Нәтиҗә итеп шуны әйтергә кирәк: Татарстанда да, аннан читтә дә татарлар яшәгән авыллар (башка милләтләр авыллары да) бетүгә йөз тота. Авыллар бетү сәбәбе юл һәм мәктәп булмау. Шагыйрә Илсөяр Иксанованың «Авылдан китү» шигырендәге юллар күзгә яшь сарыштыра һәм йөрәкне авырттыра.

*Каерылып карыйм артка...*
*Туган нигез,*
*Зәңгәр капка.*
*Әти-әни озатып кала...*
*Балаларны кала ала.*
*Каерылып карыйм артка:*
*Өй дә шул ук,*
*Шул ук капка.*
*Тик озатмый беркем,*
*Беркем...*
*Килә икән шулай бер көн.*

***Агачлык.*** Терминның нигезендә *агач* сүзе ята. *Агачлык* «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә исем дип бирелгән һәм: «Агачлар үскән урын, кечкенә урман дип ныгытылган». *Ул алдан бераз читтәрәк каралып күренгән агачлык төркемен күрсәтте.* Г. Бәширов. *[Елга кырыенда] агачлык тагын да куерак, – агач күләгәләре тагын да тыгызрак һәм зәңгәрсу төстә күренәләр*. Ш. Камал (ТТАС, I: 15).

Ләйлә Мәхмүтова мәгълүматларына караганда, *агач* лексик берәмлеге «агач», «бүрәнә» мәгънәсе белән Codex Cumanicus (1303 ел) хезмәтендә очрый.

***Агач, агачлык*** лексик берәмлекләре географик берәмлек атамалары ясауда байтак кулланыла: *Агач күпер* – Питрәч районының Кун авылында күпер атамасы; *Агачлар рәте* – Апас районының Әлмәндәр авылы янындагы җир атамасы; *Агачныкылар күле* – Җире елгасы бассейнында, Актаныш районының Ахун авылы янында; *Агач Таулары* – Кама Тамагы районының Олы Салтык авылы янында. *Түбән печәнлек агачлыгы* – Биектау

районы Зур Кавал авылында. *Олы агач* – Чистай районы Иске Роман авылы янындагы урман атамасы.

***Арша*** лексик берәмлегенең дә агачка мөнәсәбәте бар. *Арша* – казак телендә «артыш агачы» мәгънәсендә кулланыла. *Арча* – борынгылыкның өченче чорыннан ук Кырым татарлары телендә сакланып калган реликт – борынгылык формасы. Авазлар күчешен искә алсак, *Арча* атамасының килеп чыгышы *артыш* агачын белдерә торган *арча ~ арша* лексик берәмлегенә нисбәтле.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *Арча* – исем, ботаника белән бәйләнешле дип ныгытылган: «Артыш. *Тянь-Шань таулыгыннан искән ачы салкын җил тау сыртларындагы корчаксыган үләннәрне, арча, кыргый алма, чикләвек агачларыннан коелган яфракларны уйсулыкларга илтеп тутыра*. А. Айдар» (ТТАС, I: 74).

Шушы ук сүзлектә *Артыш* – исем дип ныгытылган һәм аңа аңлатма бирелгән: «Җимеше медицинада кулланыла торган, һәрвакыт яшел ылыслы куак яки агач. // Сыйфат мәгънәсе. Артышка бәйләнешле. *Камил белән Фоат күл яры буйлап узып, артыш әрәмәлегенә керделәр*. М. Әмир. // Сыйфат мәгънәсе. Артыштан ясалган яки артыштан киселгән. *Әтинең башында чалма, өстендә яшел сыман чапан, кулында артыш таяк*. Ш. Әхмәдиев» (ТТАС, I: 73).

***Артышлык*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә исем дип ныгытылган һәм артыш үсә торган урын дип аңлатылган, мисал китерелгән: *Тау артышлыгыннан [балалар] үз куллары белән [җиләк] җыеп кайттылар*. Э. Касыймов» (ТТАС, I: 73).

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә артыш болай сурәтләнә: «Артыш – Җимешле (сусыл) күркәләре медицинада кулланыла торган мәңге яшел агач яки куак. Татарстанда сирәгәеп бара торган үсемлек булып исәпләнә. Яфрак-ылыслары һәм бөреләре һаваны микроблардан чистарта торган эфир майлары бүлеп чыгара. Артыш ылысларын төнәтеп, елның теләсә кайсы фасылында куллану өчен, шифалы эчемлек әзерләп була.

Электә артышны яндырып төтәсләү-котлау йоласы башкарганнар (Р. Әхмәтьянов). // *Артыш исеннән шайтан кача, ди. Артыш агачы им булыр. Картлар сүзе*».

Урта Азиядә артышны *арча* дип йөртәләр. Атама күп кенә төрки телләргә хас, чуваш һәм мари телләрендә дә йөри.

***Артыш, арча*** лексик берәмлекләре географик атамалар ясауда актив катнашалар: *Артыш тавы* – Балтач районы Пүскән авылы янындагы тау атамасы. *Артышлы күл* – Питрәч районы Күн авылы янындагы күл. Алтай географик атамаларын тәфсилле өйрәнгән галим О.Т. Молчанова Артыш Кол атамасын ныгытып куйган. *Артышлы елга* – 1. Балтач районы Түбән Кенә; 2. Питрәч районы Шәле авыллары янындагы инеш-елгалар. О.Т. Молчанова мәгълүматларына караганда, Таулы Алтайда да Артыш атамасы алган елга бар. *Артышлы юлы* – Питрәч районы Шәле авылы янындагы юл һәм басу атамалары һ. б.

***Артыш*** лексик берәмлеге Вахит Имамовның «Утлы дала» романында болай кулланылган: *«Ясугәй үзе яшеренеп торган артыш ботакларын кабаланып этәрде дә, түгәрәктә утырган мәркетләргә текәлде»*.

***Арча*** лексик берәмлеге шулай ук атамалар ясауда кулланыла. Хәзер Арча шәһәр статусы алды. Борынгы чорларда Арча шәһәр булган. Арчага багышлап халкыбыз үзе «Арча» дигән җыр чыгарган:

*Арча якларына карыйм,*
*Дустым Арча ягында.*
*Арча ягы бигрәк матур*
*Кош сайраган чагында.*

Шул ук «Миллият сүзлеге»ндә «Арча – Артышның бер төре, нарат» дип ныгытылган. // Арчылау – арча яндырып төтәсләү ырымы.

Бу сүзлектә тагын *арчан* сүзенә дә игътибар бирелгән: «Арчан – тармакланып үсә торган мәңге яшел үсемлек, куакчык.

Дару үләне булып хисаплана. Нарат урманнарында, торфлы сазлыкларда үсә, Татарстанда сирәгәеп бара.

Русча – вереск».

*Агач* лексик берәмлеге Нурулла Гарифның «Тарихи чыганакларда төрки-татар исемнәре һәм географик атамалары» дип аталган китабында болай күрсәтелгән: «*Агач (Агач)*, пом. Пуст. Н. дар., на п. Каме, близ д. Аган – Агач и г. Лаишева; За татарская озерная грива (Татарлар ягындагы күл һәм агачлык җирләр)».

Агачларыбызның мохитны бизәкләве, күңелебезне әллә нишләтеп хушландыруы, халәтебезгә чиксез бәхет алып килүе безгә таныш. Шул гамь, шул бәхет безгә яшәү өчен көч бирә, тормышны аңларга, кешеләрне яратырга өйрәтә. Менә шуның өчен *агач* – халык авыз иҗатында һәм әдипләребез иҗатында да еш кулланыла.

*«Бәла агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри»; «Агач күрке – яфрак, адәм күрке – чүпрәк»* кебек мәкальләр бар.

Э.М. Мурзаев тикшеренүләренә караганда, *агач* лексик берәмлеге төрки телле халыклар топонимиясендә күп очрый. Аның төрдәш-вариантлары: *агаж, агаш, агас, агыч, йагач*. *Агачдере* – Копетдагдагы тарлавык (ике тау арасындагы тар аралык, бик тирән чокыр). Махачкала янында *Агачаул*. Кабарда-Балкар республикасында *Агач-Башы* (Урман башы) атамасы өч җирдә кабатлана. *Агачлы-Кол* – озын чокыр, сыза, коры үзән исеме. *Агач-Кийири* урманлы ил, өлкә дигәнне аңлата. *Агачлар* – Төркиянең Европа өлешендә. Төркия топонимиясендә *агач* сүзе хәзер киселеп беткән, ләкин кайчандыр бу урында агачлар үскән җирләрне аңлата.

***Агым. Агымсу. Акма.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *агым*ның су, агым белән бәйләнешле ике мәгънәсе бирелгән.

*Беренче мәгънәсе*: «Елга үзәне буенча су агышы хәрәкәте». *Агыйдел дә безгә табан кысылып* тарая һәм агымын тизләтә. М. Әмир. Суның агымы *мине бер минуттан соң үзе белән алып китте*. М Гафури. // Сыйфат мәгънәсе: Ага торган. *Агымсу*

*ялтыравыклы күксел бозга уралып ята.* Ш. Камал. *Киң басулар, шаян агым сулар Язгы җилгә дулкынлансыннар.* М. Җәлил.//Көчле ага торган, ташкын. *Агым сулы Иртыш буенда Тубылгылар өзә Сабира.* Ә. Ерикәй (ТТАС, 1977: 18).

*Икенче мәгънәсе*: «Диңгезләрдә, океаннарда су массасының, ташкынының хәрәкәте». *Салкын агым. Гольфстрим агымы. Агымнар башлыча һәрвакыт бер үк юнәлештә исә торган җилләр тәэсирендә барлыкка киләләр.* Физик география (ТТАС, 1977: 18).

*Акма* сүзенең *елга, агым* белән бәйләнешле мәгънәсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бирелмәгән. Ләкин акма, агым, агымсу лексик берәмлекләре белән географик атамалар байтак очрый: *Акма елга* – Мамадыш районының Тулбай авылы яныннан агып үтә торган Шийә елгасы кушылдыгы. *Акма кугы күле* – Спас районындагы Яңа Рәҗәп тирәсеннән агып үтә торган Үтәк (Утка) елгасы бассейнындагы күл. Хәзерге Спас районындагы Иске Рәҗәп авылын элек *Акма Елга* дип атаганнар. *Агым Зөя* – Яшел Үзән. *Агымсу чишмәләре* – 1. Яшел Үзән районының Юынчы авылы янында, Эрә елгасы бассейнында; 2. Биектау районының Коркачык авылы янында, Казан суы бассейнында.*Агымтамак* – Минзәлә районының Бикбау авылы тирәсендә, Баҗана елгасын Ык белән тоташтыра торган тамак һәм шул тирәләр. *Олы агым* – Мазар күле белән Баҗана елгасы арасында язгы чорда хасыйл була торган көчле агым. Минзәлә районының Бикбау авылы (ул Актанышның Күҗәкә авылы белән күршедә урнашкан) яныннан агып уза торган Ык елгасына *Бакай акмасы, Бәдәй киреакмасы, Гыймай акмасы* теркәлгән.

Күренекле диалектолог Л.Т. Мәхмүтова мәгълүматларына караганда, *агым, агыш* терминнарының агым (течение) мәгънәсе «Codex Cumanicus» (1303 ел) хезмәтендә очрый. Бу хезмәттә *агыш* лексик берәмлеге дә бар.

*Агым* лексик берәмлеге төрки телләрдә дә очрый:

***Акар*** – төрек телендә «ага торган», «елга», «елгачык», «инеш» мәгънәсендә кулланыла.

Р.Г. Әхмәтьянов бастырып чыгарган «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә *ак-у (акты, агым)* сүзе ныклап тикшерелгән (Әхмәтьянов, ТТЭС, 2005: 52).

*Агым, агымсу, акма* лексик берәмлекләре татар халык иҗатында шактый урын алган.

*Агымсулар ничек ага,*
*Яшь гомерләр дә шулай.*

(Татар халык җыры).

*Дунай суы агым су, бик шәп икән агуы,*
*Кәрим, Алла, мөшкел хәл төреккә каршы баруы.*

(Рус-төрек сугышы бәетеннән).

*Агым, агымсу, акма* – әдипләребез һәм шагыйрьләребез иҗатында еш очрый.

Классик әдип Гомәр ага Бәшировның роман һәм повестьларын укыганда һәрвакыт нинди дә булса яңалык белән танышабыз, халкыбызга хас йола-кануннар һ. б. үзечәлекләрне яңадан исебезгә төшерәбез. Әдипнең «Туган ягым – яшел бишек» китабына урнаштырылган «Чәңки, чәңки, чәңки җылан» дип аталган повестенда балачакта ишетеп калган такмаклар хәтеребездә яңара:

*Чәңки, чәңки, чәңки җылан,*
*Чәңки башлы кара җылан,*
*Агым суда раван җылан;*
*Атам-анам хакы өчен*
*Кузгалмый гына ят җылан!*

Картлар әйтә, шушыны әйтсәгез, җылан тимәс, ди. Шулай да очрамаса яхшырак инде...

Безнең өлкәннәребез белми әйтмәс. Аларның тәҗрибәләре зур, тамырлары чал тарих төпкелләрендә, белем һәм уңышлары тәҗрибәләреннән, табигать, җир-анабыз белән дус булудан килә...

Гомәр ага Бәширов «Намус» романында *агым* терминын күчерелмә мәгънәдә куллана: *«Әнә берничә урында чүп үләннәренә ут төртеп җибәрделәр: саргылт төтен әйләнмәле дулкыннары белән җир өстенә орына-орына, киң агым булып, урман буена таба сузыла».*

***Агым*** лексик берәмлеге язучы, җәмәгать эшлеклесе, Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» романында очрый: *«Көймә, агым уңаена тибрәлеп, Агыйдел буйлап аска төшеп китте».*

Дәрдемәнд үзенә генә хас шигъри осталык белән *агымсуны* үзенчәлекле итеп файдалана:

*Таулы матур илләрендә*
*Гөрли агым сулары;*
*Тонык ялтыр күлләрендә*
*Каңгылдый аккулары.*

*Ага гөрләп, ага зурлап агымсу*
*Китә йомгакланып-йомгакланып бу.*

Ленар Шәех *агымсуны* менә ничек сыйфатлый.

*Сулар гел агар инде дә,*
*Үз юлын табар инде.*
*Күңелләргә ялкын түгел,*
*Агымсу кабар инде...*

Татар теле сөйләшләрендә бу сүзнең төрле төрдәш вариантлары бар. Чистай сөйләшендә *акма* «ага торган», типтәрләрдә *алкын* «агым», Тау ягында *акма* «ага торган инеш», Әтнә яклрында *агынты* «агым су», себер татарларында *ыгу* «агым, агу», тобол, төмән сөйләшләрендә *ык, агым, койган* «агым су» мәгънәләрендә кулланыла.

Төрки халыкларда да *агымсу* мәгънәсен аңлата торган терминнар бар. Казакларда *агын*, кыргызларда *агыс*, төрекләрдә *акын*, төркмәннәрдә *ак-кың,* ойрот телендә *агыт* сүзләре *агымсу* төшенчәсен аңлата. *Агым, агын* терминнарын эченә алган гидронимнар төрки халыклар яши торган барлык урыннар-

да да очрый. Мәсәлән:Джунгар Алатавында – *Агынакатты;* Алтайда, Калбин сыртында – *Агынакты;* Азәрбайҗанда *Ахынджа* (бу елгасы Шамхорчай суына кушыла). Көнчыгыш Тянь-Шаньның көньяк тау битендә урнашкан Кучы районында елга һәм сайларның мондый исемнәре теркәлгән: *Каракыракын, Каракумышакын, Суакынсай* һ. б.

***Акан, акын*** терминнарының төп мәгънәләре – «ага торган», «агым», «агым су»; *агынты* – «елга һәм диңгезләрнең агымы». В. Радлов Кырым татарлары һәм төрек телендәге *акан* терминының *ак + ан* компонентларыннан ясалуын күрсәтә. Э.В. Севортян *ак* сүзенең *ын* суффиксы белән ясалган *ахын, акин, агын* терминнарының «агым су, тиз агым, дулкын»ны аңлаткан географик мәгънәләре белән төрки телләрнең бөтен төркемнәрендә да очравын ассызыклый. Составында *акин* термины булган географик атамалар бик күп җирлекләрдә, аерым алганда Балкан ярымутравында, Кавказда, Анатолиядә, Урта һәм Үзәк Азиядә, Казакстан, Себердә һ. б. территорияләрдә урнашкан. *Терсаккан* елгасы – Копетдагта; *Акан* елгасы – Ишем елгасы кушылдыгы; *Убаган* – Казакстанда; Синьцзянда, Кучи янындарак *Каракумышакын* атамасы бар.

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *Агар, акар* терминнары төркмән һәм Азәрбайҗан телләрендә «шарлама; ташкын; агым, агыш; агылыш» мәгънәсендә кулланылалар. Төркмәнстанның Чәләкән ярымутравында ул минераль су ташкыны урнашкан урын. Бадхыз төбәгендә *Акар-Чишмә* исеме алган үзенә бер табигый урын бар. Бу төбәктә өченче чор борынгылык флорасының бай файдалы казылмалар калдыгы очрый. Ташауз өлкәсендә *Агар* атамасы ныгып калган.

***Айырча.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *айырча* – «аерылып торган өлеш, ябь». *Чәчәк аерчасы. Койрык аерчасы.*

***Айырчалы.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек сыйфат дип билгеләнгән һәм «Аерылып торган, аеры, ябьле» дип аңлатылган. Мисаллар да бирелгән: *Аерчалы яфрак. Аерчалы йөзгеч.*

***Айыры (аеры)*** термины югарыда аталган сүзлектә сыйфат дип бирелгән һәм аның ике мәгънәсе күрсәтелгән.

Беренче мәгънәсе: аерылып торган, бүленеп торган, аерым-аерым торган. *Аеры яфраклы чәчәк*. Аеры тояклылар.//рәвеш мәгънәсе. *Аерым-аерым. Ана сөтен аеры имә Бала игез булмаса*. Дәрдемәнд.

Икенче мәгънәсе: чатлы, япьле. *Учакта – аеры башлы ике казык башындагы аркылы агачка асып куелган зур гына казанның астында – коры чыбык-чабык яна*. Ш. Камал (ТТАС, I: 23).

Бу терминнар татар географик атамалары ясауда шактый актив файдаланылалар, ә гидронимиядә – «елга кушылдыгы, елга култыгы, кече елга» мәгънәсен белдерәләр. Аларның бу мәгънәләре «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бирелмәгән. Терминнар гидронимик атамаларының состав өлеше буларак кулланыла: *Айырча сыза* – Табар елг. кушылдыгы (Апас районында), *Айырчалы йылга* – Димскәй елгасы кушылдыгы (Баулы районы), Мичән суы кушылдыгы (Саба районы); *Айыры елга* – Уратма елгасы кушылдыгы (Зәй районы); *Мөхәммәт айырчасы* – Иганә елгасы кушылдыгы (Сарман районы); *Айырчалы елга* – 1. Мичән елгасы бассейны (Яңа Мичән авылы Саба районы). *Аерча* – «аерылып торган, аеры, япьле» (ТТАС, I: 23). 2. Симет елгасы кушылды, Саба районы Түбән Симет авылы янында; *Аеры тоба аланы* – Баулы районы Исергәп авылы янындагы алан атамасы һ. б. Әлеге терминнар микротопонимнар составында да кулланыла*: Айыры тоба аланы* (Баулы районы), *Айры күл кыры* (Саба районы) һ. б.

В.В. Радлов сүзлегендә *аірык* – «кечкенә елга», *аіры* – «кечкенә елгачык». Татар теле диалектларында бу терминның *әйре* варианты теркәлгән.

Бу апеллятив төрле фонетик вариантларда, нигездә, «елга култыгы, елга кушылдыгы, су белән юылып ясалган канау», «елгачык» мәгънәләре белән барлык төрки телләрдә очрый. Татарстаннан читтә ул Ульяновск өлкәсендә яши торган татарлар телендә кулланыла: *Айырча елгасы* – Тирешкә суы бассейны

(Иске Кулаткы районы); *Айырча күле* – Тирешкә суы бассейны һ. б. Микротопонимнар: *Айырча түбә кыры* – кыр (Иске Кулаткы авылы, Иске Кулаткы районы) һ. б. Самара өлкәсендә: *Айырча инеше аланы* – алан (Камышлы районы Чуваш. Байтуганы авылы) һ. б. Башкортстан топонимиясендә *айыр* – «елга култыгы, тау тармагы». *Айыр* компоненты алган атамалар бу республиканың көньягында урнашкан. *Чулым* татарлары телендә *айры* – «елга». Себер татарлары телендә *айры* – «елга тармагы». Таулы Алтай гидронимиясендә *айры* – елга ермагы. Мәсәлән: *Кара айры* – «Кара ермак», *Куру айры* – «Кипкән ермак», *Акайры, Мешту-Айры, Коннаайры, Йолдо-Айры, Алгаир* (Майма авылы янындагы Катунь елгасының уң кушылдыгы), *Аир* (Ремезов картасында – Ишем елгасы тамагыннан өстәрәк Катунь елгасының сул кушылдыгы). Күрәсең, ул хәзерге Айа елгасы (Малолетко, 1992: 49).

*Аир, ай* терминнары төрек, Кырым татарлары, караим, кумык, нугай телләрендә «аеру, бүлү» мәгънәләрен аңлата.

Таулы Алтайда *айры* – елга, тау, киң һәм озын чокырларның атамалары булып кулланыла ала. Елгаларның, тау сыртлары һәм тарлавыкларның исем-атамалары бер яки берничә сүздән ясалганда *айры* аларның составында компонент булып кулланыла. Тау, тарлавык, киң һәм озын чокыр атамалары составында *айры* – «тармакланган урын, аерма, чат» кебек үзенең төп мәгънәсен саклый (мәсәлән, тау атамалары: *Ас-Айры, Кайа-Айры* һ. б.). Гидронимик апеллятив буларак *айры* топонимнарда «елга култыгы», «субүләр», «кечерәк елга», гомумән, «елга» мәгънәләрендә кулланыла. Мәсәлән; елга, кече елга атамалары: *Ак-Айры, Јайлу-Айры инеше, Joldy-Айры чишмәсе, Кызыл-Айры инеше* (Молчанова, 1979:18). А.М. Малолетко мәгълүматларына караганда, Тоболның түбән агымында ага торган елгалар: *Уцкармаир, Янтаир, Еланаир, Албагаир;* Шориядә: *Тогурайры, Кошайры* елгалары; Хакасиядә *Алтынадыр* «Алтын инеш», *Адыр* елгасы – Пыжа елгасы кушылдыгы, Прителецк районында (1992: 49). *Тыва* телендә *адыр* – «елга ермагы», «тау аерча-

сы». Бу телдә *адыр* термины елга атамалары ясауда актив һәм шулай ук тау исем-атамаларында да кулланыла. *Ол-Адыр* – «Юеш кушылдык», *Кургат-Адыр* – «Коры кушылдык» (Овюр районы), *Адыр* (Тоджин районы), Тандин районында *Адыр-Тей* тавы (*тей* – калкулык) (Розен, Малолетко, 1986: 22). Казак телендә *айрык* «ике калкулык арасындагы су ерган тар урын, тау ярыгы», хәзерге казак телендә *айрык* «субүләр» мәгънәсендә йөри, елга атамасы составында кулланылып, аның үзенчәлеген күрсәтә: *Тесайрык, Терсайрык* һ. б. (Конкашпаев, 1961: 6). *Павлодар* өлкәсе гидронимиясендә *айрык* – «тармакланып киткән кечкенә елга һәм елга култыгы». Кыргыз топонимиясендә *айры* компоненты белән 7 атама теркәлгән. Аларның 2 се су чыганагы атамасы: *Айры-Таш* – Ош өлкәсе Ноокат районы җирләреннән ага торган Каракол елгасының югары агымындагы инеш; *Айры-Төр* – Кайчы елгасының сул кушылдыгы (Нарын өлкәсе, Атбашы районы), калган 5 *Айры-Таш* атамалары тау сырты һәм тау үткелләре (Умурзаков, 1988: 13). Орел шәһәре Орел елгасы ярына урнашкан (елга хәзер Орлик дип йөртелә). Ипатьев елъязмасында елга Ерель дип теркәлеп калган «Его же русь зовет Угол» по месту впадения реки в Оку». Г.П. Смолицкая бу фактны нигез итеп алып, Орел топонимын һәм Ерель гидронимын төрки *айыр, айры* термины белән бәйләп аңлата.

***Алан***. «Татар теленең аңлматмалы сүзлеге»ндә *алан* – «Урман эчендәге агачсыз, ачыграк урын», – дип бирелгән (ТТАС, I: 44). *Аргы якның аланы – ачы була баланы*. Җыр. *Ял иттек без палаткалар корып, Җиләк җыйдык яшел аланда.* З. Мансур (ТТАС, I: 44).

***Аланлык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек болай ныгытылган: «Урман эчендәге ачыклык, алан». *Бөтен аланлык ак, сары, кызыл, зәңгәр төстәге төрле чәчәкләр белән бизләгән*. М. Гали (ТТАС, I: 44).

Фикерле диалектолог, һәр язган хезмәтен тәфсилле анализ нәтиҗәсендә генә басмага чыгарган галимә Нажия Борһанова инде онытылып бетеп барган, халык элек-электән яратып

бәйрәм иткән җыеннарның халык-гавәм хәтерендә сакланып калган бер өлешен тырышып җыеп, өйрәнеп, «энә күзеннән үткәреп» тикшерү нәтиҗәсендә бастырып чыгара һәм шушы гамәле белән ул безгә зур бүләк калдыра.

Галимә мәгълүматларын караганда, «Алан җыенын июнь башында (рус халык календаре Троица вакытында) Мишә һәм Нырсы елгалары бассейннарына (Мишәнең сул кушылдыгы) утырган Алан, Сауш, Янцевар һәм Нырсы елгасы үзәненә урнашкан татар авыллары халкы һәм керәшен татарлары да матур бәйрәм итеп үткәргәннәр».

А.К. Тимергалин төзеп чыгарган «Миллият сүзлеге»ндә *алан* термины болай аңлатылган: «*Алан* – Урманда ачык җир, аклан, аяз. Гомумкыпчак сүзе» дип карала. Мәхмүд Кашгари сүзлегендә (XI) *алан* – яссы, тигез. *Алан, Сучалан* – Суык + алан, *Саралан* – сары + алан.

Кайбер профессорлар *алан* сүзен «поле» (числовое поле) урынына тәкъдим иткәннәр иде. Мөгаен, уңышсыз тәкъдим, чөнки *алан* – принципта кечерәк һәм әйләнә-тирәсе чикләнгән ачык мәйдан, «өлкә» мәгънәсенә ия. Безнең аң төпкелендә алан – урман эчендә агачлар булмаган урын, ә рус терминологиясендәге «поле» (немец телендә – шул ук мәгънәдәге *feld,* инглизчә – *field*) төшенчәсе, киресенчә, үз мәйданында нәрсәнеңдер булуына басым ясый (тензорлар кыры, Җир магнетизмы кыры, яки гравитация көчләре кыры, информация кыры, сугыш кыры һ. б.). Кыскасы, фәннең байтак өлкәләрендә дә тамыр җибәргән *кыр* (борынгы төркичәдә – *кыра, тарлау*) сүзенә кагылмаска кирәк, *алан* сүзенең югарыда күрсәтелгән мәгънәләрне колачлый алуы шикле һәм гомум кабул ителүе юк чамасында. Дөрес, алан сүзе төрекчәдә «кыр» мәгънәсендә очрый, ләкин ул бу телдә системага – терминология кырына – кереп өлгергән шикелле. Ә татарча фәнни терминологиядә *алан* сүзе системага кермәгән, шуңа күрә телне тагы ирексезләп, бездә калыплашып һәм тармакланып өлгергән сүзләрне алмаштыруның хаҗәте юк. Тотрыклы терминологиянең урнашуында, карарлашуында эзле-

клелек белән дәвамчылык принцибы ифрат зур әһәмияткә ия. Шулай да гавам арасында гадәттән тыш популяр «Поле чудес» телетапшыруының атамасын «Могҗизалар аланы» дип алу килешлерәк тә, төгәлрәк тә булыр иде.

***Аклан.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *Аклан* – иске, диалекталь дип беркетелгән һәм аңа түбәндәге аңлатма бирелгән: урман тирәсендәге яки урман эчендәге зур булмаган ачыклык, алан. *Алар көннәрнең берендә урманнан чыктылар да... бер акланга, яшел чирәм өстенә утырдылар.* Г. Ибраһимов (ТТАС, I: 34).

Адлер Тимергалин җыеп чыгарган «Миллият сүзлеге»ндә *Аклан* түбәндәгечә аңлатылган: урманда ачык җир, кечерәк алан. Бу сүз топонимнарда да катнаша. Эвен һәм эвенк телләрендә дә *аклан/аглан* сүзе бар икән. Мәсәлән, *Мәндәй акланы, Наратлы акланы*.

*Алан, Аклан, Аланлык* терминнары белән географик атамалар шактый күп ясалган. *Алан башы* – Аксубай районының Иске Ибрай авылы янындагы алан атамасы, Тормы елгасы бассейнында; *Алан арты* – Апас районының Иске Йомралы авылы янында алан атамасы. *Алан башы урамы* – Буа районының Каенлык авылындагы урам атамасы; *Алан юлы* – Мамадыш районының Кече Кирмән авылыннан аланга бара торган юл; *Алан елгасы* – Апас районының Кече Болгаер авылы янында, Олы Шаһиян елгасының уң кушылдыгы; *Алан тау* – Саба районының Алан-Елга авылы янындагы тау атамасы. *Бүре аланы* – 1. Аксубай районы Иске Татар Әдәмсуы; 2. Чүпрәле районы Иске Чокалы; 3. Мамадыш районы Кече Бүрсет; 4. Балтач районы Яңгул авыллары яннарындагы аланлык атамалары. *Бүре аланы елгасы* – Аксубай районы Иске Татар Әдәмсуы авылы янындагы елга. *Бүре аланы тавы* – Мамадыш районы Югары Бүрсет авылы янындагы тау атамасы. *Азанча аланы* – Әлки районы Иске Алпар авылы янында. *Кәсәми аланы* – Әлки районы Иске Алпар авылы янындагы алан атамасы. *Ялан аланы* – Аксубай районы Шәрбән авылы янындагы алан атамасы.

*Каенсар аланы* – Яшел Үзән районы Күгәй авылы янындагы алан атамасы. *Аланлык* – Аксубай районы Такталачык авылы янындагы аланлык. *Аланлык* – Югары Ослан районында, Идел ярында. *Каенсар аланы калкулыгы* – Яшел Үзән районы Күгәй авылы янындагы калкулык атамасы. *Кара куак аланы* – Биектау районы Ташлы Кавал авылы янындагы алан. *Чум аланы* – Балтач районы Пүскән авылы янындагы алан атамасы. *Аклан күле* – Апас районы Зур Күккүз авылы янындагы күл. *Аклан юлы* – Зур Күккүз авылыннан чыгып бу Акланга бара торган юл. *Аклан юлы* – Алексеев районы Сахаровка авылы янындагы сукмак атамасы.

Нурулла Гарифның «Тарихи чыганакларда төрки-татар исемнәре һәм географик атамалар» дигән китабында *алан* термины болай ныгытылган: Заковаллевская поляна (Кавал авылыннан соң башланган ачыклык урыннар, аланнар. Зерекли – Зератлы (Зирекле – Зиратлы *алан*), нугай (даругасы) өстендәге алпавыт авылы Столма ~ Толманың аланлыгы.

Алан термины белән авыл атамалары шактый күп ясалган: *Алан* – Арча, Балтач, Мамадыш, Теләче, Түбән Кама районнарындагы, *Йосыф Аланы, Алан-Елга* – Саба, *Алан-Җөри* – Теләче, *Алан-Бәксәр* – Биектау, *Алан-Полян* – Балык Бистәсе районнарындагы авыллар.

*Алан* – әдипләребез иҗатында еш кулланыла: Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында алан сүзе очрый: *«Әмма Камил абыйсы нигәдер Гайнанны тынычландырырга ашыкмады. Бер түгәрәк алан уртасына яккан учакка, бер Гайнанга карап, тирән уйланып беравык сүзсез утырды».*

*Алан* – Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» романында шактый файдаланыла: *«Карт адымнарын шактый тизләтә төште һәм урман эчендәге аланлыкка килеп чыкты. Аланны урталай ярып киң елга агып ята иде, мөгаен, Агыйдел үзедер, чөнки картның юлында әле мондый зур елга очрамады».*

*Алан* – төрки телләрдә дә еш кулланышта: *Алан* төрек телендә «урмандагы ачык урын», «алан» мәгънәсендә фәнни әй-

ләнештә йөри (Радлов, I: 359), төрек теле диалектларында *алаң* «кыр», «басу», «үзәнлек», кырым татарлары телендә *алан* «урман арасындагы аланлык».

*Алан* термины төрки телләрдә – «ачык тигез урын» төшенчәсен аңлата. Мәхмүд Кашгари хезмәтендә *аланг* – «тигез, яссы һәм ялпак урын».

Э.В. Севортян мәгълүматлары игътибарга лаек: башкорт телендә *аклан;* якут телендә *алы, йаланг;* үзбәкләрдә диалекталь термин *алак;* тыва телендә *аланды, алак* һ. б. Башка мәгънәләре дә бар: «урман аланы; алан; ике урман арасындагы ачыклык; кыр; тигезлек, үзән». Хорезмда *алан* – «чирәм җир; кыргый дала, сахра, кеше аяк басмаган урыннар; ташланган сугару челтәрләре, иске канал» һ. б. Төркиядә «болын», Алтайда – «кыр; үзәнлек; тигезлек». Төрекмән топонимиясендә *алан* термины актив кулланыла: 1) Төрекмән Каракомлыгының ялангачландырылган комнары, ягъни өстен үсемлекләр каплаган тау тезмәләре арасында ак таплар булып ялтырап ята торган урыннар; 2) үсемлекләр белән капланмаган, балчыклы туфрактан гыйбарәт киң, биек булмаган яссы калкулык; 3) *ала* – берни үсми торган, күппочмаклык рәвешендәге тигез такыр яссылыклар; 4) *алаязы* – «иркен үзән, күз күреме җитмәгән тигезлек».

Ф.К. Комаров якут телендәге *алы, алыы* терминын тәфсилләп тикшергән. Аның мәгълүматларына караганда, *алы, алыы* – түбәнлектәге болын; куаклыклар белән капланган үзән. Куаклыклар арасында тал, каен һәм чыршы төрләре еш урнашкан. Төньяк-көнчыгыш районнарда көн иткән якутлар телендә бу термин куаклыклар яисә түмгәкләрдә дә үсә ала торган үсемлекләр белән капланган урман аланы (Абый һәм Мом районнарында), таулар арасындагы урманлыклар белән капланган киң үзән (Алланхов районы), урманның бары куаклыклардан гына торган төбәге (Верхоян районы)». Г.К. Конкашпаев мәгълүматларына караганда, хакас телендә *чалан* – «тигезлек», «дала»; татар телендә *ялан* «үзән», «ачык урын»; башкорт телендә *ялан* «олы алан», «басу», «ачык урын»; казак телендә

*алан* «ачык урын», «урман аланы», «алан, болынчык, чирәмлек» (Конкашпаев, 1951). Э.В. Севортян *алан* термины турында мондый мәгълүматлар бирә: шор телендә чалан – «тигезлек». Төрки булмаган халыклар телендә дә мондый параллельләр бар. Эвенклар телендә *авлан, аблан, аглан, агла* – «алан», «болын», «тигезлек», «урмансыз чиста урын» (Севортян, 1974). Ф.К. Комаров мәгълүматларына караганда, эвенк телендә *авлан* – «урмандагы алан», «сирәк урман», «тигезлек», «алан»; эвен телендә *авлан* – «урмансыз урын», «алан», «тундра», «тигез урын», «тундралы урыннар».

*Алан* термины белән географик берәмлекләр бик күп ясалган: Төрекмәнстанда *Датлы-Алан,* Якутиядә *Авлан* атамасы алган елга бар. Мондый атама тагын Амур өлкәсендә һәм Хабаровск краенда очрый. *Яланкул* күле Омск өлкәсендә бар. *Авлан* күле Төркиянең төньягында урнашкан. Болгар топонимиясендә *Алан-Бунар* – аландагы кое.

*Алан* сүзе – мари һәм удмурт телләрендә дә бар, алардагы мәгънәсе ~ тугай, әрәмәлек, болын. *Алань* һәм *елань* сүзләре В. Дальнең «Словарь живого великорусского языка» сүзлегенә дә теркәлгән. Кыскасы, безнең якларда бу сүзнең таралышы милли чикләрне белми шикелле. Хәер, «Башкортча-русча сүзлек»кә (М., 1958) *алан* сүзе кермәгән. Аларда русча поляна – *аклан*, диалектларында *аяз* (*айаз* сүзе дә бар). Бу факт *алан* сүзенең этимологиясе турында уйланырга мәҗбүр итә.

***Алачык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек исем дип бирелгән һәм «Төрле эшләр өчен кабык, такта һ. б. материаллардан оештырылган кечкенә каралты», – дип аңлатылган. *Тегермән янына ук алар тагын тәгәрмәч тугымы һәм чана табаны бөгә торган алачык ясаганнар*. М. Гали. *Көпчәкләр аунап яткан тимерче алачыгы яныннан үтеп, Якуп икенче урамга килеп чыкты*. И. Гази (ТТАС, I: 44).

Бу лексик берәмлекнең икенче мәгънәсе «искергән» дип ныгытылган һәм түбәндәгечә аңлатылган: «Җәй айларында вакытлыча яшәү өчен куыш, шалаш». *Мостафа... өянке агачлар*

*артында, читәннән үреп, алачык эшли иде.* Ш. Камал. *Ул матур кыз Сакчы кыз иде, Алачыкта үскән, урманда.* Ә. Ерикәй. // Начар, җимерек кечкенә өй яки бүлмә турында. *Син беләсең безнең алачыкны, Кәҗәсез дә гомер иткәнне* Ш. Маннур (ТТАС, I: 44).

Л.Т. Мәхмүтова мәгълүматларына караганда, *алачык* лексик берәмлеге татар телендәге *алачык* «хижина, хата» мәгънәсендә «Codex Cumanicus» хезмәтендә очрый.

Адлер Тимергалин китабындагы мәгълүмат мондый: «*Алачык* – гомумтөрки сүз, алачык, аланчык – кечкенә мәйданчык, өйалды, ишегалды»; кайбер төрки телләрдә – «тирмә, куыш, чатыр, ышык җир». Казак телендә *лашык* – «ертык, тишек өй», татар диалектында *алан* сүзенең йорт алды «йорт алды, лапас, япма» мәгънәсе дә барлыгын искәртеп китик // *Казарма дигәннәре тәбәнәк түшәмле, кечкенә тәрәзәле, озын караңгы алан иде.* К. Тинчурин.

Димәк, рус телендәге *лачуга* сүзе төркичәдән (атап әйткәндә, кыпчак теленнән үк) алынма булып чыга, аның борынгы рус телендәге формасы оригинальгә якынрак та әле – *олачуга, алачуга.* // «Хижина дяди Тома» – «Томагай алачыгы» (Бичер Стоу китабының исеме татарчага шулай тәрҗемә ителгән). Русча *кузнецкая лачуга* – «тимерче алачыгы».

Сүзләр дә хәрәкәттә һәм күчештә...

*Алачык* лексик берәмлеге топонимнар ясауда кулланыла. *Алачык* – Саба районындагы Тимершык авылы янындагы урын атамасы. *Алачык елгасы* – 1. Бөрсет/Бүрсет елгасы бассейнында, Мамадыш районының Түбән Сон авылы янында; 2. Арча районының Наласа авылы яныннан ага торган Наласа елгасы бассейнында. *Карама алачык* – Балык Бистәсе районы Бикчурай авылы янындагы тимерче алачыгы атамасы. *Карама алачык болыны* – Балык Бистәсе районы Котлы Бөкәш авылы янындагы болын атамасы. *Хәйбулла алачыгы* – Кама Тамагы Бишалаб авылы янындагы кыр атамасы. *Карама алачык* – Балык Бистәсе районы Бикчурай авылы янында булган тимерче

алачыгы атамасы. *Ислам алачыгы* – Балтач районы Ор авылы янындагы алачык атамасы. *Карама алачык болыны* – Балык Бистәсе районы Котлы Бөкәш авылы янындагы болын атамасы. *Чура алачыгы күле* – Арча районы Наласа авылы янындагы күл.

*Алачык* читтә яши торган татарлар телендә дә кулланыла. Ульяновск өлкәсенең Вязгай авылы янында *Алачук елга* инеше бар. Шул ук өлкәнең Усть-Кулаткы авылы янында *Алачык* исеме алган урынны өлкәннәр әле дә хәтерли. Самара өлкәсенең Денис авылы янында *Алачык* урыны сакланып калган. Ул да өлкәннәр хәтерендә генә. Оренбург өлкәсендәге *Саракташка* елгасына *Алачык* елгасы кушыла. Самара өлкәсендә *Алачык* атамасы алган урын бар.

*Алачык* термины төрки халыкларда да очрый.

«Кырым топонимиясе» дип аталган хезмәттә алачык термины искә алынган: *алачык, алачук, алачух, ала* – чагатай телендә *алачук,* караим теленең тракай диалектында һәм төрек телендә «ботаклардан ясалган шалаш, авылдагы җәйге кухня» (Радлов, I: 362), диалектларында *алаҗык, алаҗук* «киездән ясалган палатка», «басудагы, бакчадагы яки яшелчә бакчасындагы шалаш, көтүчеләрнең ботаклардан эшләнгән йортлары».

***Алмагач***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *алмагач* – исем дип ныгытылган һәм мәгънәсе: «Розачалар семьялыгыннан алма бирә торган җимеш агачы», – дип аңлатылган. *Бакчаның алмагачларыннан куәтле бер ис аңкый.* Г. Ибраһимов (ТТАС, I: 44).

*Алмагач* лексик берәмлеге топонимнар ясауда да актив катнаша: *Алмагач күле* – Яшел үзән районы Мулла иле авылы халкы куллана, Әрә елгасы бассейнында; *Алмагач инеше* – Нурлат районының Иске Әмзә авылы янындагы Гәрәй елгасына кушыла; Балык Бистәсенең Зур Мәшләк авылы яныннан ага торган Шомбыт елгасына кушыла. *Алмагач юлы* – Яшел Үзән районының Кече Өтәк авылы янындагы юл атамасы; *Алмагач үзәне* – Саба районы Явлаштау авылындагы үзән атамасы. *Алмагач кырачы* – Спас районы Әҗмәр авылында алмагач һ. б. агачлар үсә торган урын. *Алмагачлы тирәк* – Кырый Йорткүл авылы,

Спас районы. Җиләк җыя торган урын. *Алмагачлы юл* – Бидәңге авылы янында, Тәтеш районы; *Алмагач чишмәсе* – Ушмы суы бассейны, Югары Ушмы авылы Мамадыш районы; *Алмагач тугайы* – Саба районы Җәнәй авылы янындагы тугай.

*Алмагач, алмагачы* лексик берәмлеге татар халык авыз иҗатында әдипләр һәм шагыйрьләр әсәрләрендә кулланыла:

> *Алма агачыннан ерак төшми.* (Әйтем)
>
> *Их, алмагачлары,*
> *Сайрый сандугачлары.* (Җыр)

Халык уен уйдырып сала белә...

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *алмагач* лексик берәмлеге кулланыла: *«Минһаҗ абзыйның күз карасыдай күреп алты-җиде ел буе тәрбияләп үстергән, берсеннән-берсе затлы ике төрле алма бирә торган тәҗрибә алмагачы булган. Алмалары пешеп җиткән көннәрдә генә шул алмагачның ботагын каерып төшергәннәр дә алмаларын талап киткәннәр».*

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *алма, алмагач* лексик берәмлеге төрки топонимиядә тирән эз калдырган. Бу очракта тиз генә Казакстандагы *Алматы* шәһәре искә төшә. Бу географик атама аны сугаручы Кече һәм Зур Алматы (Алматинка) елга-сулары белән бәйләнешле. Урта гасырлар уртасында Кавказдан алып Казакстанга кадәр киң территориядә *Алмалы, Алмалык, Алмалу, Алмало, Алмали, Алмачи* атамалары бик еш очрый. *Алмалы* географик берәмлеге атамасы башкорт галимнәре тарафыннан этноним дип ныгытылган.

***Ара***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ара* лексик берәмлеге исем дип бирелгән һәм мәгънәсе болай аңлатылган: «Ике нәрсә арасындагы бушлык, буш урын, ачыклык». *Мич арасы. Тәрәзә арасы. Садый ике лабаз арасын сынамаган күз сизмәслек итеп кенә бүлеп алган дая, игенен шунда яшергән.* Г. Гобәй. *Кечкенәләргә килгәндә, эш җиңел, башын ике аяк арасына кыстыра да: – Икенче усал булма!.. дип бирепме бирә.*

К. Нәҗми. // Ике предмет яки ике кешене аерган урталык. – *Ике арага минем чаршауны корып куй әле, – диде Җәмилә.* М. Гафури (ТТАС, I: 637).

Л.Т. Мәхмүтова мәгълүматларына караганда, *ара* лексик берәмлеге «ике предмет арасындагы урын» дип «Codex Cumanicus» (1303 елда басылып чыккан) чыганагында ныгып калган.

***Аралык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек исем дип бирелгән һәм *беренче мәгънәсе* болай аңлатылган: ике нәрсә арасындагы урын, ачыклык. *Фанерадан бүлеп эшләнгән, бер үк вакытта кухня булып та саналган бу тар гына аралык, ут янмаганга, караңгы иде*. Г. Минский. *МТМга җитмәс борын бер буш аралык бар*. Ә. Еники. //Авыл өйләрендә мич белән стена арасында калдырылган ачыклык. *Абзардан өйгә әйләнеп керү белән, ул җәелгән урынга ятмыйча, әле аралыкка барып нидер актарды, әле тула оегын эзләде.* С. Рафиков.

*Икенче мәгънәсе* диалекталь дип бирелгән һәм болай аңлатылган: «Ике каралты арасына салынган сарай». *Әнвәр тиз генә тәрәзәдән чыгып аралыкка кача.* Г. Камал (ТТАС, I: 67).

*Ара, аралык* лексик берәмлегенең топонимиягә нисбәтле мәгънәләре «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бирелмәгән. Ләкин югарыдагы мәгънәләре географик атамаларда куллануга юл ача.

*Ара, аралык* лексик берәмлекләре географик атамалар ясауда очрыйлар: *Ара кизләү* – 1. Кама Тамагы районы Олы Яңасала авылы янындагы кизләү. Коры Үләмә елгасы бассейны. 2. Әтнә районы Ябынчы авылы янындагы кизләү. *Атау арасы* – Биектау районы Ямәширмә авылы янындагы урын атамасы. 3. *Чат арасы* – Тәтеш районы Бакырчы авылы янындагы урман атамасы. *Аралык кизләwе* – Ышланды суы бассейны (Салтыган авылы, Кайбыч районы), *Аралык чокыры* – Ышланды суы кушылдыгы Салтыган авылы янында (Кайбыч районы). *Йылга арас*ы – Кама Тамагы районы Иске Кариле авылы янындагы җир атамасы. *Йылга арасы кизләве* – Кама Тамагы районы Иске Кариле авылы янындагы җир атамасы. *Йылга арасы кизләве* – елга

арасы суы бассейны. Кама Тамагы районы Иске Казиле авылы янында. *Йылга арасы суы* – Кама Тамагы районы Иске Казиле авылы янында. *Орым арасы* – Кайбыч районы Мәлки авылы янындагы урын атамасы. *Су аралыгы* – Арча районы Кушлавыч авылы янындагы урын. *Су арасык елгасы* – Олы Бәрәзә авылы янында, Арча районында. Ашыт елгасы бассейны.

*Ара* термины Татарстаннан читтә яшәгән татарлар һәм кардәш төркиләр телендә дә еш очрый. *Ара* – коман, төрек һ. б. төрки телләрдә «ике предмет арасы» дигән мәгънә аңлата. Татар телендә дә ул нәкъ шундый ук мәгънәне белдерә (Радлов, I: 245). Э.М. Мурзаев мәгълүматлары да *ара*ның «урталык», «ике географик берәмлек арасындагы урын, җир» мәгънәсен аңлатуын күрсәтә.

***Арка***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу термин диалекталь дип ныгытылган һәм «биеклек, калкулык», дип аңлатылган. *Елгадан үтеп, арыш басуы аша аркага менгәч, кояш та чыкты*. М. Гафури (ТТАС, I: 67).

*Арка* термины топонимнар ясалышында кулланыла: *Арка бүләк басуы* – Баулы районы Бәйрәкә авылы янындагы басу атамасы. *Капкыш аркасы басуы* – Азнакай районы Әлкәй авылы янындагы басу атамасы. *Аркалык сукмагы* – Кама бассейнында, Балык бистәсе районының Саескан Тавы авылы тирәсендә.

*Арка* термины күбрәк халык телендә кулланыла. *Җәй көне җиләк аркалыкта, калкурак урында үлән арасында күбрәк табыла. Кырдагы калку, аркалык урыннарда, печән, үлән арасында, кояш кыздырган урыннарда җиләк күп була.*

А.К. Тимергалин төзеп чыгарган «Миллият сүзлеге»ндә (Казан, 2007) «*Арка суы*» дигән гыйбарә бирелгән һәм мәгънәсе дә ныгытылган: *«Һәрбер бала атасының арка суыннан барлыкка киләдер».*

*Арка* термины шактый күп төрки телләрдә очрый. Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *арка* термины төрки телләрдә «арка» «арка сөяге, умыртка тезмәсе» мәгънәсен аңлата. Географик атамалар терминологиясендә мәгънәләре шактый

күп: «тар кабырга рәвешле озынча калкулык», «субүләр (елгаларны һәм елгаларга караган уйсулыкларны бер-берсеннән аера торган калкулык)», «тау кабыргасы», «кашлак», «тауның арткы сөзәклеге», «тауның күләгәле сөзәклеге», «төньяк»; тыва һәм хакас телләрендә *арка* – «тау урманы», «тайга», «сузылган тау тезмәсе»; алтайлыларда *арка* – «тау итәге», «тау бите»; якут (саха) телендә *арга* – «арка», «көнбатыш»; нугай һәм кумык телләрендә *арка* – «курган», «түбә», «таулар тезмәсе», «тау»; башкортларда *арка* – «тау сырты», «калкулык», «калку җир», «сөзәклек». О.Т. Молчанова Таулы Алтайдагы а*рка* терминын тәфсилләп анализлый.

*Арка* термины белән ясалган географик атамалар күп урыннарда очрыйлар: Көньяк Уралда *Такты-Арка* һәм *Кудрат-Арка* калкулыклары; Тывада *Арга-Хем* елгасы, *Аргалыг-Кыр* һәм *Улуг-Арга* исеме алган тау атамалары; Саратов өлкәсендә *Аргадак* районы; Хакасиядә *Арга-Тау* кабыргасы, *Арка* исеме алган тау кабыргасы; Караганда өлкәсендә *Яңа Арка* – тимер юл станциясе. Алтайда *Аркатура* тавы бар. *Аркалык* – Тургай өлкәсенең үзәге. *Арка-Юрм* атамасы турында Б.Х. һәм Дж.Х. Карамышевларның 1980 елда басылып чыккан «Ономастика Востока» җыентыгында урнаштырылган мәкаләләрендә тәфсилләп тикшерелгән. Фирганә кыргызлары Семиречьеда яшәүче туганнарын *аркалык* дип атыйлар, ягъни арткы яктагылар дип йөртәләр. Ә *Алай арты* кабыргасы – *Арка-Алай,* ягъни *Арткы Алай* Алай үзәненең һәм Алай кабыргасының көньяк ягында урнашканнар. Бу күренеш соңыннан барлыкка килгән тәрҗемә дип уйланыла.

Идел–Урал җирлегендә нигездә ул тау сыртын аңлата. Күренекле топонимист Э.М. Мурзаев арка термины турында түбәндәге мәгълүматларны җыйган. Көньяк Уралда *Такты-Арка* һәм *Кудрат-Арка;* Тывада: *Аргалыг-Кыр, Улуг-Арга* сыртлары һәм *Арга-Хем* елгасы; Саратов өлкәсендә *Аркадак* районы бар; Хакасиядә – *Арга сырты* барлыгы теркәлгән. Дагстанда *Арка* шәһәре бар. Казакстанның Караганда өлкәсендә *Яңа Арка* тимер юл станциясе теркәлгән; казаклар Казак вак сыртларын

*Сары арка – Сары кабырга* дип атыйлар. Алтайда – бер шәһәр *Аркатура* исеме алган.

Төрки телләрнең кайберләрендә: «арка, арка сөяге, умыртка тезмәсе», топонимиядә «озынча калкулык», «калкулык, кечкенә тау, кашлак», «тауның арткы сөзәклеге»; якут телендә «көнбатыш», чагыштыр. Монгол телендә *ап* – «арка, арткы як», «төньяк, арткы як», эвенк телендә *аркан* – «арка, иңбаш»: *Улуг-Арга сырты*». Тывада *Арга-Хем* елгасы, Дагстанда – *Арка тавы*, Алтайда – *Аркатур тавы*, Казакстанда – *Аркалык*. *Арка*ның төп мәгънәсе алтай телендә «кабырга һәм җилкә, тау сөзәклеге», гадәттә ул төньяк юнәлешендә, урман белән капланган була, хакасча *арга*. Алтайда *Карагайлы арка тавы* бар. Ул тауда чыршылар күп үсә. Обь елгасы кушылдыгы Чулымның унъяк ярында *Арга кабыргасы* бар.

Гомумән, *арка* терминының төрки телләрдә төп мәгънәләре «калкулык», «сузылган тау сырты», тыва һәм хакас телләрендә *арга* – «тау урманы», «тайга», «сузылган сырт», «тау сырты», «сөзәклек, тау бите», «төньяк»; алтайлыларда *арка* – «тау итәге», «тау бите»; якут (саха) телендә *арга* – «көнбатыш», «арка»; нугай һәм кумык телләрендә *арка* – «курган», «түбә», «таулар тезмәсе», «тау»; башкортларда *арка* – «тау сырты», «калкулык», «калку җир», «төньяк сөзәклектәге урман».

***Атау***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *атау* сүзенең ике мәгънәсе күрсәтелгән.

***Атау*** I фигыль дип ныгытылган һәм «Кемгә яки нәрсәгә дә булса исем бирү, исем кушу, атама бирү», – дип аңлатылган. *Ул тыкрыкны аның исеме белән атап, тешсез Ибрай тыкрыгы дип йөртәләр*. М. Әмир.

***Атау*** II исем, искергән сүз, кара: *утрау* дип күрсәтелгән һәм мондый мисаллар китерелгән: *Ә бу җирдә менә атаулар. Зур диңгезләр. Күлләр*... Һ. Такташ. *Пароход үз җае белән бара, без атауга якынлашканнан-якынлашабыз*. Ф. Әмирхан.

*Утрау* исем дип бирелгән һәм болай аңлатылган: «Һәр ягыннан да су уратып алган коры җир». *Олы Шырдан үрен менгәч*

*тә, диңгез уртасындагы биек утрауга салынган Зөя шәһәре күренде.* М. Гали. *Диңгез эчендә утрау бар, аның өстендә кала.* Дәрдемәнд. //күчерелмә мәгънәдә: Тирә-юньдәгеләрдән читтә аерылып торган нәрсә турында. *Казан вокзалында Мәскәүгә китүче «Татарстан» поездын озатырга төшкән йөзләгән халык арасында алар аерым утрау булып басып торалар иде.* А. Гыйләҗев (ТТАС, I: 82).

Л.Т. Мәхмүтова мәгълүматларына караганда, *атау* лексик берәмлеге «Codex Cumanicus» (1303 ел) чыганагында «утрау» мәгънәсендә дә күрсәтелгән.

«Татар теленең диалектологик сүзлеге»ндә (2009) *атау*ның *икенче мәгънәсен* аңлатканда *каш* 1.1 гә җибәрелгән. Түбән Кама керәшеннәре һәм Казан арты сөйләшләрендә *атау* һәм *каш* мордва-каратай, хвалын, сергач сөйләшләрендә югарырак, калкулык урын мәгънәсендә кулланыла. Лаеш сөйләшендә *атау* – «калку җирдәге куаклык». *Өченче мәгънәсе*: мамадыш сөйләшендә «авылның елга белән аерылып торган урамы». *Дүртенче мәгънәсе*: төмән сөйләшендә (Төмән өлкәсе) – «үзәнлек». *Бишенче мәгънәсе*: рус алынмасы дип күрсәтелгән. Касыйм, сергач, Ульяновск өлкәсендә таралган карсун сөйләшендә, Оренбург өлкәсендә таралган каргалы сөйләшендә *атау*ның мәгънәсен аңлатканда *алсын* 1 лексик берәмлегенә җибәрелгән һәм ул калкулыкны аңлата.

Адлер Тимергалин төзеп чыгарган «Миллият сүзлеге»ндә *атау* 1 (татар) – *Утрау* дип бирелгән. Адлер атауны аңлату өчен Р. Әхмәтьяновның «атау ул – елга утравы яисә елга тамагындагы, дельтадагы утрау» – дигән фикерен китерә.

*Атау* лексик берәмлеге белән шактый гына атамалар ясалган: *Атау* – Балтач районы Алан, Кама Тамагы районы Даныш, Чирмешән районы Иске Кади, Баулы районы Татар Кандызы, Яңа Чишмә районы Чоллы Башы авылы, Кукмара районы Югары Өскебаш авылларындагы урам атамалары. *Бу урамдагы йортлар* калкулыкка салынган. Аксубай районы Иске Татар Кармәте, Арча районы Казанбаш, Балтач районы Кили авыл-

лары янындагы басу атамалары. Арча районы Олы Бәрәзә, Биектау районы Өмбе авыллары янындагы калку урыннар да *атау* дип йөртелә. Яшел Үзән районының Мулла иле авылында *Атау чалуы* – болын атамасы. *Атау ышнасы* – Балык Бистәче районының Янтык авылы янындагы басу атамасы. *Атау эче* – Питрәч районы Шәле авылы янындагы урын атамасы. *Атау урамы* – Чирмешән районының Иске Кади, Мамадыш районының Катмыш, Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе, Арча районының Орнаш авылларындагы урамнар атамалары. Алар күп санда. *Атау кыр* – Балтач районы Пүскән авылындагы кыр атамасы. *Атау арасы* – Биектау районы Ямаширмә авылындагы урын атамасы. *Атау басуы* – Балтач районы Кили, Апас районы Әлмәндәр авылындагы басу атамалары, *Атау йорт*ы – Буа районы Адав-Толымбай авылы янындагы матур бер урын шулай атала. *Дуңгыз атавы* – 1. Буа районы Адав-Толымбай. 2. Спас районы Иске Рәҗәп авыллары янындагы атау исемнәре. *Дуңгыз атавы урамы* – Аксубай районы Яңа Ибрай авылындагы урам атамасы. *Букрый атавы* – Кайбыч районы Мәлки янында, Орым суы бассейнында.

*Атау* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында кулланыла.

Бу лексик берәмлек төрки халык телендә дә шактый очрый: *Ада* – төрек һәм Кырым татарлары телендә «утрау» һәм «ярымутрау» (Радлов, I: 476).

***Аяк***. Аяк сүзе белән җирле халык агымсуларның түбән агымын, елга тамагын атый. Кызганыч, *аяк* сүзенең бу мәгънәсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә кермәгән.

Борынгы төрки телдә *adaq* «елга тамагы» мәгънәсендә йөргән (ДТС, 1969: 8). Мәхмүт Кашгари сүзлегендә *азак* «зур елга тамагы» (МК, 1). Азов диңгезе исеме дә шуннан алынган. Дон елгасы тамагында кайчандыр Азау (Азак) кальгасы торган. В. Радлов сүзлегендә азәрбайҗан, чыгтай һәм кыргыз телләрендә *daj*ның «елга тамагы»н белдерүе теркәлгән (Радлов, т. I, ч. 1: 205).

Татар гидронимиясендә *аяк* сүзе белән җирле халык агымсуларның түбән агымын, елга тамагын атый, мәсәлән: *Елга аягы,*

*Су аягы, Инеш аягы.* Минзәлә районының Бикбау авылы янындагы *Комаяк* – Ык ярындагы комлы, сөзәк урын атамасы.

«Аяк» апеллятивы югарыда күрсәтелгән мәгънәдә Татарстаннан читкә сибелгән татарлар телендә дә еш кулланыла.

Башкортстанда көн иткән татарлар телендә: Мәчетле районы җирләреннән аккан Ай елгасының сул кушылдыгы *Куш аяк* елгасы, Бөрҗән районыннан аккан Зур Нөгеш елгасының сул кушылдыгы *Саплайак,* Җалаер районы җиреннән агып узган Сакмар елгасының уң кушылдыгы шулай ук *Саплайак* исемен йөртә. «Айак» компонентын үз составына алган елгалар татарлар көн иткән һәр төбәктә, аерым алганда Ульяновск, Самара, Әстерхан, Оренбург һ. б. өлкәләрдә очрый.

Рифкать Әхмәтьянов сүзлегендә *аяк* II «нога» < гомумтөрки *айак* < *бо*рынгы төрки *adaq* id. Төрки телләрдә бу сүзнең вариантлары һәм икенчел мәгънәләре күп: алтай, хакас *азак* – «аяк» < борынгы *azaq* > борынгы кыпчак *азау* – «аяк», «елганың түбәндәге агымы» > *Азов* (кара: шулай ук *Азак диңгезе* «Азов диңгезе»); татар, башкорт *азак, адак* – «соңыннан, ахырда, ахыр» көнчыгыш төрки диалектлардан (борынгы хакас компонентыннан) соңрак кергән; якут һ. б. телләрдә *атах* – «аяк, түбәнге; ахыргы; елганың түбәнге агымы» <**атаг* > кыпчакларда *атау* – «елга утравы, дельта, аерым көтүлек» һ. б. Чагыштыр: шулай ук чуваш *ура* < *ора* < **рак* «аяк»; борынгы төрки *adaq* – «бәбиләрне атларга өйрәтер өчен ясалган җайланма» (Әхмәтьянов, ТТЭС, 2005: 77). Кардәш төрки (мәсәлән: каракалпак, карачай-балкар, азәрбайҗан, төркмән, үзбәк, төрек, казак, тыва, алтай, хакас) телләрдә бу сүз төрле фонетик вариантларда «елга авызы» мәгънәсендә йөри.

Төрки телләрдә *адак/азак/айак/аях* – «нога», топонимиядә: «тау асты, елганың түбән агымы, тамак, елга тамагы, коя торган урын». Азәрбайҗанда: *Аяг-Кырвенд,* Кыргызстанда, Монголиядә: Күлләр үзәнендә – *Адагин-Цаган-Нур* атамасы теркәлгән. Бурят телендә *адаг* – «конец, устье реки». *Эгэтын адаг* (Усть-Эгита), *Ородой адаг* (Усть Орот), *Хэжэнгын адаг* (Усть-

Кижинга) (Мельхеев, 1969: 90). *Аяк-Кырвенд* – Азәрбайҗан, *Кызыл Аяк* – Кыргызстан топонимнары. Хәрәзм һәм Төркмәнстанда *Адак* топонимы очрый (Караев, 1986: 7). Осетия топонимиясендә Дигор тарлавыгыннан агып үтә торган Урух елгасы атамасыннан *Урухадага*, *Суадаг* (Кара чокыр), *Дзуары адаг* (Изге чокыр) атамалары ясалган. Монголиядә, Байдараг елгасының сул кушылдыгы бетә торган күлләр үзәнендә *Адагин-Цаган-Нур* исемендәге күл бар. Эчке Монголия һәм Кытайда *Адаганур* исемендә бистә һәм күл бар. Азов диңгезен төрекләр *Azaq denizi* дип йөртәләр (Мурзаев, 1984: 39). «Аяк» терминының антоним пары *баш.*

***Әләшә*** термины – «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә юк, ул сүзлеккә кертелмәгән.

1969 елда басылып чыккан «Татар теленең диалектологик сүзлеге»ндә *әләшә* – Казан артының этнә сөйләшендә «яшьләр уены (гулянье, игры молодежи)». *Ашыт җыенында Кала тауга әләшәгә чыгалар ыйы җәшләр* (ТТДС, 69: 543). 2009 елда басылып чыккан «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә *әләшә* дөбъяз сөйләшендә дә «яшьләр уены (гулянье, игры молодежи)».

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *әләшә/әләсә* тарихи лексик берәмлек дип ныгытылган һәм аңлатмасы да бирелгән: «Әләшә/Әләсә Казан татарларында язын ут ягу һәм шуның аркылы сикерү йоласы, башта пакьләнү ритуалы булып, соңыннан яшьләр уенына әйләнгән».

Ут аша сикереп чыкканда, «Алач!» дип кычкырганнар. Бу аваз – татар, кыргыз, казак һ. б. халыкларда пароль сүз – *оран*. Ә Себер татарларына *алас* әйтелеше хас. Мондый йола Урта Азиядә аеруча күп таралган була. Казан һәм Себер татарларына ул шуннан килгән дип уйлыйлар. Р. Әхмәтьянов *алас* сүзенең этимологиясен гарәпчә *халас* – «азат, йөксез, гөнаһтан хали» сүзе белән бәйли.

*Әләшә* лексик берәмлеге татар географик атамалары арасында очрый. *Әләшә бәйрәме* – июньнең беренче яртысында

уздырыла. Ул табигатькә табыну бәйрәме. Табигатькә чыгып, учак ягып авыллар халкы ашарга пешереп ашый. Ул билгеле бер урында үткәрелә (Әтнә районы). *Әләтә җире* – Әтнә районы Күәм авылы янындагы җир атамасы. *Әләшкә басуы* – Яшел Үзән районы Мулла иле авылы янындагы басу атамасы.

Әтнә районында *Әләшә* бәйрәме Әүлияләр каберлеге янында Күәм белән Әйшияз авыллары арасындагы Калатауда элек-электән үткәрелә торган бәйрәм. Бу бәйрәм сабан туе алдыннан уздырылган.

Әләшә белән мөнәсәбәтле географик атамалар да очрый. Гадәттә татар телендә *т – с* авазлары бер-берсенә күчешә. Шуңа *Әләшә* белән *Әләтә*не һәм *Әләсә*не бер үк тамыр дип карыйбыз.

***Әрәмә***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *әрәмә* лексик берәмлеге исем дип ныгытылган һәм мәгънәсе: «Яланда, күбесенчә су буйларында, уйсу җирләрдә үскән вак куаклык», дип аңлатылган. *Бары Үрге әрәмәнең инеше буйларында үлән яхшы үсте*. Ш. Камал. *Әрәмәләр арасында Сайрый тургай баласы*. Ә. Ерикәй.

***Әрәмәле***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *әрәмәле* сүзе: «Әрәмәсе булган, әрәмә үскән», – дип аңлатылган. Авылның тагын бер ягында әрәмәле болынлык, сазлык (Г. Толымбай).

***Әрәмәлек***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *әрәмәлек* исем дип ныгытылган һәм «Әрәмә күп үскән урын», – дип аңлатылган. *Юллар бозылып өлгергәнче, иптәшләр безгә бу сазлыклардан чыгарга кирәк*. Г. Әпсәләмов. *Текә тауга күтәрелүнең авырлыгы бик нык сизелмәде сизелүен. Агыйдел тугаендагы әрәмәлекне уйнап кына үттек*. М. Әмир (ТТАС, III: 686).

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә куаклык, әрәмәлек мәгънәсен *чаукалык* лексик берәмлеге белән аңлатуы болай ныгытылган: «Чаукалык диалекталь – куаклык, әрәмәлек». Бу сүзне «(лесо)посадка» мәгънәсендә тәкъдим итүчеләр булды (мәс., Р. Батулла). Чыннан да, *чаукалык* сүзенең мәгънәви функцияләре әдәби телебездә файдаланылмый ята шикелле.

*Әрәмә, әрәмәле, әрәмәлек* лексик берәмлекләре географик атамалар ясауда шактый актив кулланылалар. Алар үзләре генә дә һәм атамалар составында да килә алалар. *Әрәмә* – 1. Чирмешән районының Кара Чишмә авылы янында; 2. Тәтеш районының Кече Әтрәч авылы янында. Бу әрәмәдә элек ак үрдәк сую гадәте булган. Урын атамасы; 3. Питрәч районының Татар Казысы авылы янында. Әрәмәлек урын; *Әрәмә арасы* – Мамадыш районы Арташ авылы янындагы урын атамасы; *Әрәмә инеше* – Алексеев районы Олы Тигәнәле авылы янында, Тигәнәле елгасына кушыла; *Әрәмә болыны* – Аксубай районының Иске Кармәт авылы янында; *Караңгы әрәмә* – Питрәч районы Тау Иле авылы янындагы әрәмә. *Пуп әрәмәсе* – Яңа Чишмә районы Зирекле авылы янындагы болын атамасы. *Чат әрәмәсе* – Актаныш районы Иске Кормаш авылы янындагы әрәмә атамасы. *Югары оч әрәмәсе* – Мамадыш районы Күк Чишмә авылы янындагы әрәмә. *Югары чыршылы ягы әрәмәсе* – Лениногорск районы Түбән Чыршылы авылы янындагы әрәмә атамасы. Рәкыйпов. *Чишмә әрәмәсе* – Лениногорск районы Түбән Чыршылы авылы янындагы әрәмә атамасы. *Бәләкәй әрәмә* – 1. Актаныш районы Иске Кормаш; 2. Мамадыш районы Усали авыллары янындагы әрәмә атамалары.*Чуккаен әрәмәсе* – Актаныш районы Кәзкәй авылы янындагы әрәмә атамасы. *Олы әрәмә* – 1. Актаныш районы Иске Кормаш авылы; 2. Лениногорск районы Сарабиккол авылы; 3. Мамадыш районы Усали авылы яннарындагы әрәмәләр атамасы. *Олы сад әрәмәсе* – Лениногорск районы Түбән Чыршылы авылы янындагы әрәмә атамасы. *Әрәмәлек* – Чистай районының Ишәле авылында урын, Кама Тамагы районының Зур Салтык авылы янындагы әрәмә атамасы. *Әрәмәлек җире* – Мөслим районының Симәк авылы янындагы, *Әрәмәлек күле* – Сөн суы бассейнында, Актаныш районының Кәзкәй авылы янындагы, *Әрәмә чишмәләре* – Кирәмәт елгасы ярында Аксубай районының Иске Кармәт авылы янындагы атамалар; *Әрәмәлек елгасы* – Балык Бистәсе районының Зур Мәшләк авылы янында Шомбыт

елгасына кушыла. *Әрәмәле елгасы* – Ашыт елгасы бассейнында, Симет авылы тирәсендә. *Шырлык* – Актаныш районы Кәзкәй авылы янындагы вак әрәмәлек атамасы.

*Әрәмә* лексик компонентын күренекле тюрколог Н.К. Дмитриев болай сыйфатлый: «Әрәмә – дым, юешлек ярата торган үсемлекләр бергәлеге, берләшмәсе. Гадәттә ул елгалар тугаенда, су баса торган болыннарда һәм түбәндә урнашкан тау киртләчләрендә була. *Әрәмә* – яфраклы агачлар, куак, камышлар үсә торган юеш болынлык, киң үзәннәрдән ага торган елга яннарына елышкан була. Идел буйларында (Поволжье), Идел аръягында (Заволжье), Дон бассейны яры буйларында куе булып үскән тал, өянке, буйга нык үрләгән төрле үләннәр җыелмасы. Алар юеш болын-тугайлыклар юеш куаклыклардан торган тирәлекнең уйсулык, уйсу җир, су баса торган җирлеккә күчүен күрсәтәләр. Татарстанда, Урал елгасы бассейнында *әрәмә* – урманлы тугай, куаклык, су баса торган болын, елга буендагы үзәнлек. Оренбург өлкәсендә һәм Төньяк Казакстанда *рема* – югарыда күрсәтелгән мәгънәләрдән тыш, «куаклары үскән юеш тәбәнәк озын чокыр, сыза, коры үзән». Көнбатыш Себердә – мүкнең бер төре һәм шуннан барлыкка килгән торфлыкта нарат һәм кедр агачлары үсә торган тирәлек. М.К. Мельхеев мәгълүматларына караганда, Тывада *урем* – тар, батынкы тугайда урнашкан елга буйларындагы тау үзәннәре, су баса торган болын. Камчаткада үзенчәлекле, ягъни биек кәүсәле, куәтле әрәмәләр тезмәсе күзәтелә. Татар һәм башкорт телләрендә «сирәк урман», «кечкенә урман», «вак һәм еш куаклык» мәгънәләрен белдергән *äрäмä* (әрәмә) сүзе рус теленә *урема* формасында кабул ителгән (Дмитриев, 1962).

***Әрчү***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *әрчү* лексик берәмлеге: «Агач-куакларны тамырлары белән куптарып, берәр нинди урынны чистарту, – дип аңлатылган. *Җир әрчү. Чәчүлек әрчү. Иң элек урман арасыннан юл әрчиләр*. Исем мәгънәсе: «Урманда агач һәм куаклардан чистартылган ачыклык». *Әнә агачлар арасыннан яктысы күренгән алан – Моратай әрчүе инде ул*. Г. Бәширов (ТТАС, III: 685).

*Әрчү* термины географик берәмлек атамалары ясауда кулланыла: *Ишемяр әрчүе* – Питрәч районы Шәле авылы янындагы басу атамасы. *Таракан әрчүе* – Әгерҗе районы Иж-Бубый авылы янында урын атамасы. *Гали әрчүе* – Мамадыш районы Тулбай авылы янындагы бу җирне Гали исемле кеше ачкан. Моның өчен ул бу җирне урманнан чистарткан. *Ибрай әрчүе* – Балтач районы Смәел авылы янындагы болын шушылай атала. *Мәһди әрчүе* – Мамадыш районының Еники-Чишмә авылы янындагы урын атамасы. *Иван әрчүе* – Питрәч районы Тау Иле авылы янындагы Нурма елгасы бассейнында. *Мулла әрчүе* – 1. Питрәч районы Күн авылы янындагы җир атамасы. 2. Балтач районы Яңгул авылы янындагы болын атамасы. *Бәләкәй әрчү елгалары* – Баулы районы Бәйрәкә авылы янындагы елга (Бәйрәкә елгасы бассейны). *Ишемяр әрчүе* – Питрәч районы Шәле авылы янындагы басу атамасы. *Нәзир әрчүе* – Балтач районы Смәел авылы янындагы болын атамасы. *Иван әрчүе елгасы* – Питрәч районы Тау иле авылы янындагы елга атамасы.

Кара: *Ышна*.

***Баз***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлекнең биш мәгънәсе теркәлгән. Географик тирәлеккә мөнәсәбәтле бишенче мәгънәсе болай аңлатылган: «Балчык, таш, руда кебек нәрсәләр казып алына торган яки элек казып алынган урын». *Идел тирәсендә язгы су ташкыны калган ком базлары бар иде*. Ф. Сәйфи-Казанлы. // Шахта, штольня турында. *Тезләнеп ятып тирән базларда, Кәйлә уйнатып эшлиләр анда* (шахтада). К. Тинчурин (ТТАС, I: 108).

Кызганыч, бу сүзлектә бакыр базлары турында сүз юк. Бакыр базлары Татарстанның һәр районында очрый. «Социалистик Татарстан» газетасының элеккеге баш мөхәррире Гарәф Шәрәфетдинов үзе эшләгән газетада Бакыр базлары турында озак кына, күп матур мәгълүматлар тупланган рубрика алып барган иде.

*Баз* лексик берәмлеге белән географик атамалар шактый язылган: *Чикерткә базы* – Апас районы Иске Йомралы авылы

янындагы урын атамасы. *Бакыр базы* – Мамадыш районы Арташ, Саба районы Ельин, Мамадыш районы Кече Бүрсет, Сарман районы Ләтәү-Тамак, Кукмара районы Мәчкәрә, Саба районы Өч Нарат, Тукай районы Түбән Ләнәче, Мамадыш районы Югары Бүрсет авыллары янындагы бакыр базларыннан бакыр заводлары өчен бакыр алганнар. Атамалар шуңа мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгәннәр. *Бакыр елга/Аркылы елга* – Шушма елгасы бассейны, Лениногорск районы Иске Иштирәк авылы янындагы елга. *Бакыр базы елгасы* – Мамадыш районы Түбән Ушмы авылы янындагы елга, Ушмы елгасы бассейнында. *Бакыр базы тавы* – Зәй районы Әхмәт авылы, Сарман районы Дүсем авыллары янындагы тау атамалары. *Бакыр заводы* – Мамадыш районы Югары Сон авылында. Элек бу җирдә бакыр заводы булган. *Садрый базы* – Әгерҗе районы Ямурза авылында урман кырыендагы алан атамасы. *Балчык базы* – Апас районы Тутай авылы янындагы баз. *Балчык базы чокыры* – Тәтеш районы Чагылдым авылы янында. *Балчык базы тавы* – Кама Тамагы районы Олы Бортас авылы янындагы тау. *Балчык базы кизләве* – Кама Тамагы районы Уразлы авылында. *Балчык базы елгасы* – Әтнә районы Күәм авылы янындагы елга; *Балчык базы* – Буа районы Адав-Толымбай, Кама Тамагы районы Кече Кариле авыллары халкының балчык ала торган урыннары. *Дәрәвен базы* – Апас районы Багыш авылы янында. *Убыр базы күле* – Кама Тамагы районы Иске Казиле авылы янындагы күл. *Убыр базы чокыры* – Кама Тамагы районы Иске Казиле авылы янындагы чокыр. *Бүре базы* – Әлмәт районы Түбән Абдул, Буа районы Адав-Толымбай авылларында. *Бүре базы юлы* – Питрәч районы Шәле авылы янындагы юл атамасы. *Бүре базы елгасы* – Арча районы Югары Сәрдә авылы янында. *Бүре базы күле* – 1. Бола суы бассейны, Апас районы Кызыл Тау авылы; 2. Әрә суы бассейны, Яшел Үзән районы Күгәй авылы янында. *Бүре базы чишмәсе* – Әлмәт районы Түбән Абдул авылында. *Бүре базы чокыры* – Олы Шаһиян елгасы кушылдыгы, Апас районы Олы Болгаер авылында.

*Бакыр базы, баз* атамалары әдипләр иҗатында да кулланыла.

*Базы* – Азәрбайҗанда Кура-Аракса түбәнлегенең өске катламында югарыга күтәрелеп торган калкулык, тау, «кечкенә кашлак, калку җир». Бу термин рус региональ фәнни әдәбиятында очрый һәм, кайбер фикерләргә караганда, Кура-Аракса түбәнлегендә генә ныгып калган. Ләкин *базы* термины башка регионнарда да күзәтелә.

*Базырык* – тывалыларда «курган»ны аңлата. Алтайда урнашкан *Пазырык* курганнарын казып өйрәнү нәтиҗәләре әлеге табылдыклар җыелмасы безнең эрага кадәр беренче меңьеллыкта Алтайдагы матди культура турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

***Базар***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *базар* лексик берәмлеге болай аңлатылган: «Сатучы һәм алучыларның гадәттә даими рәвештә бергә җыелып сәүдә итүе, шул сәүдә урынына җыелган халык. *Колхоз базары. Базарга мал чыгару. Авылның уртасында зур базар кайный*. Г. Ибраһимов (ТТАС, I: 109).

*Икенче мәгънәсе*: базар җыела торган махсус урын, мәйдан. *Базар. Базарда магазиннар. Сәүдәгәрләр план корып ята таларга*. Һ. Такташ.

*Өченче мәгънәсе*: сату-алу мөмкин булган географик өлкә яки хуҗалык тармагы; товар әйләнеше сферасы. *Бөтендөнья базары. Тышкы базар, эчке базар* (ТТАС, I: 109).

Ләйлә Мәхмүтова мәгълүматларына караганда, *базар* лексик берәмлеге «Codex Cumanicus» (1303 ел) хезмәтендә күрсәтелә һәм фарсы алынмасы дип ныгытыла.

Наҗия Борһанова мәгълүматлары күрсәтүенчә, кайбер лексик берәмлекләр җыен атамалары булып яисә атама составында килеп халкыбызның тамырлары борынгы чорларга китүен дәлиллиләр. Телебездәге алынмаларны өйрәнү дә гаҗәп дәрәҗәдә әһәмиятле. Алар да халкыбыз тудырган телнең дәрәҗәле булуын, алынмалар алып һәм бирешеп яшәүләрен күрсәтәләр.

Н. Борһанова күрсәткән **Имән базары** җыенын Каманың уң кушылдыгы Омар елгасы ярында урнашкан Уразбакты, Түбән

Җәке авыллары халкы уздырган. Бу җыенның уздырылу вакыты рус крестьян календаре бәйрәме Иван көне (Иванов день, Иван Купала?) белән бер вакытка туры килә. Иван көнендә Омары авылында зур базар оештырыла, күрәсең, Имән җыены исеме дә шуннан алынган.

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *базар* лексик берәмлеге түбәндәгечә аңлатылган: «Базар – фарсы теле алынмасы. Борынгы *баh* – яшелчә һәм *зар* – нәрсә дә булса җыелган урын дигән сүзләрдән (Р. Әхмәтьянов). *Базар* сүзе күп кенә Европа телләренә (инглиз, француз, немец, испан, португал һ. б. телләргә) дә кергән. Испан һәм португал телләрендә «универмаг» мәгънәсенә ия. Төрек телендә – *пазар*. Рус телендә – *рынок* (немец теленнән кергән сүз) // *Базымсыз базар бозар* (базымсыз – кыюсыз, тартын+чак; әйберне арзанга сатып, базар бәясен төшерү турында). Мәкаль. *Базар мөнәсәбәтләре,* русча – *рыночные отношения*; маркетинг. // Кошлар базары.

Хәзерге вакытта шәһәрләрдә базарларның әһәмияте тагы да артты һәм базарлар саны, элекке белән чагыштырганда, бермәбер күбәйде (XX гасыр ахыры, XXI гасыр башлары). XIX гасыр урталарында Казан шәһәрендә атнасына өч базар эшләгән (дүшәмбе, чәршәмбе һәм җомга көннәрендә), базар мәйданнары да өчәү булган (*Печән базары, Балык базары* һәм *Ипи базары мәйданнары*)».

*Базар* термины белән шактый географик берәмлек атамалары ясалган: *Базар тавы* – Тау иле авылы янында. Бу авыл Яшел Үзән районында; *Базар тыкрыгы* – Балтач районының Курмала авылындагы тыкрык атамасы; *Базар уйазы елгасы* – Мамадыш районының Югары Сон авылы янында, Елан тау асты елгасы бассейнында. *Базар урамы* – Кукмара районының Янил, Баулы районының Яңа Шалты авылларында урам атамалары; *Базар күле* – Спас районының Мордва Йорт-күле авылында; *Базар елгасы* – Саба районы Кече Шыңар авылы яныннан агып үтә торган Кече Мишә елгасы бассейнында; *Базар йулы* – Саба районы Кече Шыңар авылы янында. *Базар уйазы елгасы* – Мамадыш

районы Югары Сон авылы янындагы Елан тау асты елгасы бассейнында. Болгар дәүләтендә сәүдә үзәге *Ага-Базар* булуын да онытмыйк.

***Бай***. Ул «елга, коры елга» төшенчәләрендә йөри. Аның бу мәгънәсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә теркәлмәгән. Татар гидронимнарының кайберләре бу термин белән ясалган. Мәсәлән: *Олы бай елгасы* – Пуп елгасы кушылдыгы Арча районында. *Кече бай елгасы* – Минзәлә елгасы кушылдыгы Минзәлә районында, Актаныш районындагы Адай авылы белән янәшә урнашкан Бикбау авылында. Дәүләтша, Дөмбакты, Ишбирде, Каһарман, Әрлән бае/ Әрлән шобагасы (печәнлек), *Йөзекәй бае* исеме алган үзәнлек-болыннар да теркәлгән. Минзәлә районының Калморза авылында *Каһир, Кәтрән*, *Мулла бае* исеме алган урыннар халык хәтерендә саклanган. *Бай ерганагы* – Балтач районының Чаптар авылы янындагы Чаптар елгасы бассейнында. *Түбән бай* – Спас районы Әҗмәр авылы янындагы урын атамасы. *Көтүче байы күпере* – Лаеш районы Имәнкискә авылы янындагы печәнлек һәм саз атамалары. *Мүк байы* – Буа районы Күл Черкене авылы янындагы печәнлек атамасы. *Озын бай* – Лаеш районы Имәнкискә авылы янындагы печәнлек атамасы. *Татлы бай елгасы* – Әтнә районы Күәм авылы янындагы елга. Күәм елгасы бассейнында. *Шайтанлы бай чишмәсе* – Биектау районы Чуваш иле авылында.

*Бай* компоненты әдипләребез иҗаында да кулланыла. Г. Ибраһимовның «Табигать балалары» дип аталган хикәясендә *бай* компоненты югарыда күрсәтелгән мәгънәдә кулланылган: «*Бездән ерак түгел Бүре баткан байлары бар*».

Татарстаннан читтә, Самара өлкәсендә яши торган татарлар телендә *бай* берәмлеге белән шактый гына географик атамалар теркәлгән. Олы Кинәле елгасының уң кушылдыгы *Сарбай* инеше, Кинәле-Чиркәс районындагы XVIII гасырның беренче яртысында нигезләнгән *Сарбай* исемендәге ике авыл, Самара ныгытылган саклагычы (линиясе) янында урнашкан шәһәр яны бистәсе *Сарбай* исемен *Сарбай* елгасыннан алган, XIX гасырда

нигезләнгән *Яңа Сарбай* авылы һ. б. *Салырбай* – Чиләбе өлкәсенең Варна районыннан ага торган елга, Урта Азия далаларында «үлгән үзән», «кипкән су юлы» мәгънәсен алган *Узбой* (*oküz* + *boj*), Сарыкамыш иңкүлегеннән Каспий диңгезенә кадәр сузылган бик борынгы үзән. Кайчандыр бу су юлы аша Аму-Дәрья елгасы суларын Каспий диңгезенә илткән.

Кайчандыр СССР составында булып, хәзер мөстәкыйль дәүләтләр булып яшәгән төрки халыклар телендә *бай~бой* компоненты очрый. Кыргыз географик атамалары арасында *Акбай* – Сокулук елгасының уң кушылдыгы, Республика карамагындагы Сокулук районында. Төрекмәнстанда борынгы су юлы *Кәлиф Үзбое* бар. Аму-Дәрья елгасыннан башлангычын алган Каракум каналы бу су юлы аша ага. Салаирда – *Аламбай елгасы*, Көнчыгыш Саянда – *Базарбай елгасы* теркәлгән.

***Бакал*** – «күл», «кечкенә күл» мәгънәсендә кулланыла. Аның бу мәгънәсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә теркәлмәгән.

Адлер Тимергалин фикеренә караганда, «Бакалдай» / *бакалмай, бакай* – тарихи лексик берәмлек. «Бакалы җыен» (бурят һәм монгол телләрендә *бакалтай* – «бакалы күл», «бака күле»). Көймәләр туктала торган җир: төрекчә – искелә, русча – пристань, дебаркадер, гавань, причал (бу рус сүзенең тамырында татар телендәге *чалу*, ягъни «бәйләп кую, эләктереп кую» мәгънәләре төсмерләнә). Кайбер язма чыганакларда *пристань* мәгънәсендә *тамга* сүзе дә кулланылган.

Охшаш сүз чуваш, мари телләрендә дә бар. Рус диалектында *бакай* – «елга култыгы, күлләвек, тоба, камышлы күл» (Р. Әхмәтьянов). Ә *сал* буендагы дебаркадерны элек *салдау* дип атаганнар (*саллау*– «сал ясау» мәгънәсендә).

Электә Казан шәһәрендә Казансу тамагы янында көймәләр туктый торган җир *бакалдай* дип аталган. 1841 елда ул 1300 гә кадәр судно кабул иткән һәм 1920 елга кадәр эшләп килгән.

Казан шәһәрендәге Бишбалта бистәсенең исеме дә биш бакалтай сүзеннән килеп чыккан дигән фикер бар.

*Бакалдай/Бакалтай* лексик берәмлеге белән географик атамалар да ясала.

Термин – конкрет географик берәмлек атамасы булып та, исем-атама составында да килә ала: *Акчарлак бакалы*, *Бәлит бакалы, Фирмы бакалы* – Карлы суы бассейны (Буа районы), *Китек бакалы* – Буа районының Түбән Наратбаш авылы янында, Зөя бассейнында; *Җәлил куагы бакалы* – Буа районының Карлы авылы яныннан ага торган Карлы елгасы бассейнында. *Мещаннар бакалы* – Буа районы Карлы авылы яныннан агып үтә торган Карлы елгасы бассейнында. *Бакал куле* – Спас районы Әҗмәр авылы янындагы Актай суы бассейнында. *Хәмит бабай бакалы* – Буа районы Карлы авылы янындагы кечкенә елга. *Камышлык бакалы* – Карлы авылы Буа районы. Камышлык елгасы бассейнында. *Бакалтай* – Балык бистәсе районы Тәберде Чаллысы авылындагы урам атамасы. *Каенсар бакалы* – Карлы авылы Буа районы. *Тәүкән бакалы* – Буа районы Түбән Наратбаш авылы янындагы Зөя елгасы бассейнындагы кечкенә күл. *Китек бакалы* – Буа районы Түбән Наратбаш авылы янындагы Зөя елгасы бассейнында. *Камышлык бакалы* – Буа районы Карлы авылы янындагы Карлы елгасы бассейнында. *Кара зирек бакалы* – Буа районы Түбән Наратбаш авылы янында, Зөя елгасы бассейнында. *Каенсар бакалы* – Буа район үзәге янындагы атама.

*Бакал* лексик берәмлеге белән ясалган атамалар татарлар хәзер яшәүче һәм кайчандыр яшәгән җирләрдә дә табылалар.

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *Бакалда, Бакалбина, Бакалдина, Бокалда* – «сазлык арасындагы күл, чокыр, язын су баса торган тугайлардагы вакытлыча ясалган күлләр, кечерәк култык, казылма, сикәлтә; сулы чокыр». Элекке Оренбург губернасында *Бакал* – елга. Башкортстанда *Бакал* – авыл һәм тау-калкулык атамалары булып кулланыла. Чиләбе өлкәсенең Саткы районында *Бакал шәһәре* – тимер рудасы чыгарыла торган үзәк. Ул *Бакал* елгасының югары агымына урнашкан. Тимер чыгара торган рудниклар һәм аны эшкәртү предприятиеләре XVIII гасырда төзелә. 1951 елда эшчеләр

бистәсе *Бакал* шәһәр статусы ала. *Бакалда* термины кергән атамалар Курган өлкәсендә дә байтак. Кырымның көнбатыш яр буйларында *Бакал* «елгада, диңгездә очлаеп кергән коры җир, борын». Урал регионында *Бакал* тавы бар. Украинада кечерәк күлләрне *бакал* дип атыйлар, Владимир өлкәсендә мондый типтагы су чыганакларын *бакалда, бакалбина* дип йөртәләр. Түбән Новгород өлкәсендә дә *Бакалды* атамалары бар. Идел буйларында исә *калдоба, калдобина* вакытлыча гына ясалган кечерәк күлләр, су тулган чокыр. Вятка бассейнында *бакалея* – «култык», «елга култыгы», «җыелган су, күл». Бу терминны руслар төрки телдән алганнар дип исәпләнелә. Мордва-эрзя телендә *бакалда* «чишмә», «сулы чокыр».

Атама составында терминнарның башка географик берәмлекләргә исем-атама буларак кулланылу очракларын, тәфсилле итеп, А.В. Суперанская тикшерә. Галимәнең «Тюркская ономастика» китабына урнаштырылган «Ономастический континуум» мәкаләсендә мондый юллар бар: «Безнең тарафтан үткәрелгән анализ шуны ачыклый, топонимнар составында кулланылган апеллятивлар аерырга тиешле географик берәмлек төрләре белән тулысынча туры килеп бетми, ягъни *дере* компоненты һәрвакытта да тарлавыкны гына, бугаз, тау сукмакларын һәм тау сырты аша үтә торган юлны гына күрсәтми, бәлки башка географик берәмлек атамалары да булып килә ала. Топонимик лексика күршедәге башка географик берәмлек атамаларына да «саркып» чыга. Басу уртасында калган урман яисә күл атамаларында географик апеллятивлар бигрәк тә күп төрле була. Таркалып, таралып кулланыла торган лексемалар составына, бигрәк тә *баш* (тау башы, чокыр башы, елга башы), *каш* (тау кашы, тарлавык кашы) апеллятивлары керә. Кулланылышы ягыннан тыгыз компакт апеллятивлар: *бугаз, борын, кыя, кыр/хыр, су, сырт, үзән, яйла*» (Суперанская, 1984: 11–12). А.В. Суперанскаяның: «...ялгызлык исемнәренең төрле төрләрен нәтиҗәле өйрәнү өчен, нинди дә булса төбәкнең бөтен ономастик киңлеген, аралыгын тоташтан алып анализларга кирәк», дигән

фикерен куәтлибез. Шуның өстенә, бу тоташ материаллар башка җирлекләрдәге ономастика мирасы белән чагыштырылса, нур өстенә нур булыр иде.

***Бакча***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *бакча* лексик берәмлеге исем дип ныгытылган һәм 1. Башлыча утыртып үстерелгән агачлык, куаклык яки чәчәклек (күбесенчә җиләк-җимеш үсемлекләреннән тора). *Шомырт бакчасы. Гөл бакчасы. Алма бакчасы. Алма бакчаларына төренгән зур авыл бик матур*. И. Гази. *Госпиталь бакчасында үсеп утырган өрек, чия агачлары ап-ак чәчәккә күмелгәннәр.* Ә. Айдар. // Парк, сквер. *Еракта, шәһәр бакчасында, музыка уйный.* И. Гази (ТТАС, II: 113).

2. Яшелчә яки җир җиләге утыртып үстерелә торган участок. *Яшелчә бакчасы. Җиләк бакчасы. Мәдинә, бәрәңге казылган бакчаның авыр, сыланчык туфрагына бата-бата, алга карап йөгерде.* Г. Минский (ТТАС, I: 63).

Диалектолог Л.Т. Мәхмүтова мәгълүматларына караганда, *баг* искергән сүз – фарсы алынмасы, «бакча» дип күрсәтелгән. Шул ук «Codex Cumanicus» (1303) хезмәтендә *бакча* һәм *бакчачы* лексик берәмлекләре дә ныгытылган (Мәхмүтова, 1982: 65).

А.К. Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *баг* сүзе «фигыль» дип билгеләнгән һәм «1. Бакча. 2. Йөзем бакчасы. (Мәхмүд Кашгарида)», дип ныгытылган.

*Бага* – тарихи термин. Борынгы дәүләтчелек термины. Илче, парламентар. Электә төркиләрдә кавемнең рухание, аксакалы «бага(ч)» дип аталган. Борынгы язмаларда *бага тархан, бага тәңрикән* титулы очрый. Билгеле «Илче-бага» җыры дошманга ышанып башын салган илче баганың фаҗигасе турында.

*Багбостан* фигыль дип ныгытылган һәм җимеш бакчасы дип аңлатылган.

*Бакча* лексик берәмлеген А.К. Тимергалин шул ук «Миллият сүзлеге»ндә болай сыйфатлый: «Бакча – гомумкыпчак сүзе (Р. Әхмәтьянов). Фарсыча *баг* сүзеннән, аңа кечерәйткеч *-ча* кушымчасы ялгап ясалган. Безгә тарихтан Казан ханбикәсе Сөембикәнең бакчасы мәгълүм (Казандагы Архиерий бакчасы).

Тасвирына караганда, ул бакча Шәрык бакчаларына охшатып эшләнгән була. Ихтимал, Сөембикәгә яңа эрага кадәр VII гасырда Бабил патшабикәсе Семирамиданың асылма бакчасы да мәгълүм булгандыр. // Гөлбакча. Алма бакчасы. Яшелчә бакчасы. Бәрәңге бакчасы. Балалар бакчасы – рус теленнән калька. Тагын кара: Җәннәт; Ирәм бакчасы; Гаден».

*Бакчаван* төрки сүз дип ныгытылган. Бакчачы. // *Кибар вә бау бер морза кызы тарафыннан гади бер бакчаванга ителмеш бу илтифатларның, әлбәттә, сәбәпләре булса кирәк!* Ф. Кәрими. А.К. Тимергалин сүзлегендә *Бостан* лексик берәмлеге болай аңлатылган: «Бакча; яшелчә бакчасы; плантация. //*Морза Туганскийның дачасы вә имениесе шундаен Таглардан берсенең итәгендә булып, тирә-яклары йөзем баглары, алма вә чикләвек бакчалары, вә тәмәке бостаннары илә ихатә кылынмыш иде.* Ф. Кәрими. Бостан ир һәм хатын-кыз исеме итеп кушылган. Исем компоненты буларак күзәтелә (Гөлбостан). Бәстан язылышы да очрый.

Күплек саны шәкеле – бәсатин».

*Бакча* лексик берәмлеге топонимнар ясауда шактый актив кулланыла: *Бакча күле* – Яшел Үзән районы Мулла иле авылы янында, Әрә суы бассейнында. *Көлек Хәйруллалары бакчасы* – Биектау районының Кодаш авылында. *Барский сад* – Питрәч районының Татар Казысы авылы янындагы бакча атамасы. *«Батан сад» бакчасы* – Буа районының Янтуган авылы янындагы бакча атамасы. *Яңа авыл бакчасы* – Тәтеш районы Кече Әтрәч авылы янындагы бакча атамасы. *Панка бакчасы кизләве* – Бия суы бассейны, Түбән Биябаш авылы Апас районы. *Голова бакчасы күле* – Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылы янындагы бакча күле. *Алма бакчасы* – 1. Теләче районы Кече Нырсы авылында болын атамасы. Анда элек алма бакчасы булган; 2. Кама Тамагы районы Олы Карамалы авылы янындагы бакча атамасы. *Алма бакчасы зираты* – Әтнә районы Олы Әтнә авылында. *Алма бакчасы тавы* – Саба районы Олы Шыңар авылы янында элек алма бакчасы булган. *Чия бакчасы* – Кама

Тамагы районы Олы Карамалы авылы янындагы бакча атамасы. *Чиялек* – Әлмәт районы Елхово авылы янындагы болын атамасы. Элек монда чия бакчасы булган. *Карлыган бакчасы* – Югары Ослан районы Югары Ослан авылы янында.

*Бакча* лексик берәмлеге төрки халыкларда да кулланыла. В.В. Радлов сүзлегендә бу компонент *бакчи, багчи, бакче, бакчэ, бахча, бахче, бахчи, бахчун, бахчэ, бачки, васса, васiе, васzi, baqhtscha, baqhtschi, bakzi, baxzy* формаларында бирелгән (фарсы теленнән), кырым татар телендә *бакча* «бакча», төрек *багча* «бакча», караим теленең кырым диалектында, татар телендә *бакча* форма-вариантлары белән төрки телләрдә актив кулланылышта.

*Бакча* лексик берәмлеге күп урыннарда географик атамалар составында очрый. Фарсы телендә *багче*, таҗик телендә *богча* «бакча» (*баг* «бакча», виноград үсә торган урын); таҗик телендә *богистан* «бакчалар иле», *бог* «бакча», «парк». Азәрбайҗан телендә *бакча, багчик* «чәчәк үсә торган урын», лезгин телендә *багча, бахча* «бакча», «җиләк-җимеш үсә торган бакча». Грузин телендә *баги,* әрмән телендә *баг* «бакча». Болгария республикасындагы диалекталь сүз *бахча* «болын», «печәнлек җир», халык телендә *бакча* «җиләк-җимеш үсә торган бакча»ны аңлата. Кырымда – *Бахчасарай;* Украинаның Донецк өлкәсендә – *Бахчевик;* Азәрбайҗанда – *Бахчакорд;* Грузиядә – *Багмарани, Багмари;* Сәмәрканд өлкәсендә – *Бахчакалан;* Таҗикстанда – *Бог* һәм *Богидара;* Иранда – *Багестан;* Әфганстан һәм Төркиядә – *Баг.*

***Балак*** **–** «кечкенә елга», «елганың кечкенә кушылдыгы». Бу термин татар гидронимиясендә һәм микротопонимиясендә кулланыла, ләкин ул бик актив түгел. *Күл балагы* – Казансу кушылдыгы (Биектау районы), Йылга *балагы* – Кугубор кушылдыгы (Балтач районы), *Инеш балагы* – Тамак кушылдыгы (Биектау районы), *Бола балагы – Бола кушылдыгы* (Апас районы). Башкортстанда: *Балак инеше* (Чакмагыш районы), *Сайбалак күл* (Балтач районы). *Аксу балагы* – Чуваш елгасы кушылдыгы.

Буа районы Норлат авылы. *Мулла күле балагы* – Буа районы Яңа Чәчкаб авылы янындагы кечкенә елга. *Балак күле* – Алексеев районы Урта Тигәнәле авылы янында, Тигәнәле елгасы бассейнында. *Балаклы күл* – Апас районы Чәтбаш авылы янындагы күл, *Балак фартал* – Тәтеш районы Кече Әтрәч авылы янындагы алан атамасы. *Балак чокыры* – 1. Буа районы Каенлык авылы янындагы. 2. Сарман районы Карашай-Саклау авылы янындагы коры чокыр атамасы. *Аксу балагы* – Чуваш елгасы кушылдыгы Буа районының Кыр Норлаты авылы янында.

Татарстандагы микротопоним атамалары: *Инеш балагы урыны, Сыза балагы урманы, Балак тугае* һ. б. Башкортстандагы авыл атамалары: *Иске Балак, Яңа Балак* – Чакмагыш районы авыллары һ. б.

***Балчык***. Бу лексик берәмлек «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә ике мәгънә аңлата дип бирелгән. *Беренче мәгънәсе* «исем» дип ныгытылган һәм болай дип аңлатылган. «Су буенда үзле масса булып әверелә һәм суы парланганда ката торган минерал. *Балчык катламы. Туфрак асты – балчык, ком асты – таш*. Мәкаль. *Менә күпер. Сары балчыклары Актарылып торган яр башы*. Ш. Мөдәррис. // Сыйфат мәгънәсе. Балчыктан яки махсус измәдән эшләнгән; балчыктан торган. *Балчык морҗа. Балчык дивар*. *Берсе балчык өйгә терәп, берсе аерым салынган тәбәнәк, киң балчык абзарларда атларның ашавы, сыерларның акрын гына күшәве ишетелде.* Г. Ибраһимов (ТТАС, I: 120).

*Балчыклык* лексик берәмлеге шул ук «Сүзлек»тә исем дип ныгытылган һәм «Сылау яки керамика өчен кирәкле балчыклар ятмасы; шундый балчыкны казып алу урыны», – дип аңлатылган (ТТАС, I: 120).

*Балчык, балчыклык* лексик берәмлекләре географик атамалар ясауда актив кулланылалар: *Балчык ермагы* – Кама Тамагы районы Кече Кармалы авылы янындагы Ылгыма кушылдыгы. *Балчык ермагы күле* – Кама Тамагы районы Уразлы авылы яныннан ага торган Ылгыма бассейнында. *Балчыклы урам* – Кама Тамагы районы Каратал авылындагы урам. *Балчыклы*

*күл* – Әлки районы Иске Алпар авылы янындагы күл, Чирмешән елгасы бассейнында. *Балчык куыгы* – Кама Тамагы районы Бишалаб янындагы җир атамасы. *Балчык күле* – Алексеев районы Кыр Шонталысы авылы янындагы күл. *Балчыклы елга* – 1. Балтач районы Борбаш; 2. Балтач районы Көек; 3. Балык Бистәсе районы Югары Тегермәнлек авыллары яннарындагы елгалар. *Балчыклы елга күпере* – Мамадыш районы Уразбахты авылы янындагы күпер атамасы. *Балчыклык* – Кукмара районы Күкшел авылы янындагы печән начар үсә торган эре кәсле урын. *Балчыклы кое* – Әтнә районы Югары Бәрәскә авылындагы кое. Хәзер бу кое күмелгән.

Э. Мурзаев мондый мәгълүматлар туплаган: *Балчуг/балчык* – «кызыл, сутлы балчык, баткак, быкырдык, саз»; казак телендә *балтык,* азәрбайҗан телендә *палчыг*. Топонимиядә: Азәрбайҗанда *Палчыглы* һәм *Палчыгоба* атамасы алган торак пунктлар бар. Әрмәнстанда *Палчыглы* атамасы белән бер тау очрый. Кырымда исә *Балчыккая* атамасы белән берничә кыя ташлар очрый. Мәскәүдәге бер урам *Балчуг* атамасы алган; Болгария дәүләтенең Кара диңгез яры янында урнашкан бер төбәгендә *Балчык* тавы теркәлгән. *Камка балчыг*ы – Алексеев районы Әшнәк авылы янындагы урын атамасы.

***Басма***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *басма* лексик берәмлеге «исем» дип бирелгән һәм «Су кырыеннан эчкәрәк кереп басып торырга (йөрергә) уңайлы булсын өчен махсус ясалган, корылган күперчек». *Пароход тавышын ишетү белән паром туктый торган зур басма тирәсендә кешеләр чабып йөри башладылар*. М. Гали. *Ак беләкле кызлар* [Агыйделнең] *ярларында Басмаларга басып кер уган*. Г. Афзал. (ТТАС, I: 128).

*Басма* лексик берәмлегенең тагын бер мәгънәсе: «Җәяүлеләр генә йөрерлек итеп эшләнгән һәм гадәттә озын булмаган тар күпер». *Авыррак сөякле Мисбах басма аркылы чыкканда суга егылып төшә язды*. Г. Әпсәләмов. *Агыйделгә басма салдым. Басма салдым – киң такта, Салмас идем дә киң такта, Сөйгән ярым шул якта*. Җыр (ТТАС, I: )

*Басма* лексик берәмлеге топонимнар ясауда шактый күп кулланыла: *Мәче басмасы* – Балтач районы Кили авылында. Мәче үтергәч басма салсаң, имеш, гөнаһ калмый дип салынган басма. *Басма төбе* – Баулы районы Татар Кандызы авылындагы урам атамасы. *Бабай басмасы* – Балтач районы Кили авылында. Кешеләр бу басма аша чыкканда сыгылып, тетрәнеп торган өчен шундый исем алган.

***Басу***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *басу* «исем» дип бирелә һәм: «Культуралы үсемлекләр үстерелә торган җир мәйданы, иген кыры», – дип аңлатыла. *Игеннәре өлгереп килә торган басуны нәрсә белән генә чагыштырырга мөмкин*! Г. Әпсәләмов. *Көн шундый якты, күк йөзе шундый зәңгәр, арыш басуы шундый матур дулкынлана*. И. Гази // Иген кырының игенчелек культурасы системасында махсус билгеләнгән аерым өлешләре. *Үлән басуы. Пар басуы. Фәсхи иптәш килгәнче, совхоз, әти-бабайдан калган юл белән барып, өч басудан котыла алмый иде. Хәзер алты басуга күчеп бетәбез инде*. Ф. Сәйфи-Казанлы. (ТТАС, I: 130).

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *басу* болай сурәтләнә: «Басу – электә халык кырны бишкә бүлеп, чәчү әйләнешен («биш басулы чәчү әйләнеше») түбәндәге исемнәр белән атаган: пар, уҗым, сабан, чалу (печән чабу өчен калдырылган җир), көтү кыры (В. Хаков). Пар басуын «такыр басу» дип тә атыйлар.

*Басу* сүзе борынгы болгар телендә «җир казу» мәгънәсенә ия булган, ә сука-сабаннарга кадәр җир казый торган көрәкне «басман» дип атаганнар.

*Басу* лексик берәмлеге белән географик атамалар шактый күп ясала: *Кадермәт басуы* – Мамадыш районы Югары Ушмы авылы янындагы басу. *Бурчыл басуы* – Буа районы Бакырчы авылы янындагы басу атамасы. *Бүкәнне басу* – Мамадыш районы Түбән Яке авылы янындагы басу атамасы. *Басу урамы* – Актаныш районының Семистрау (халык телендә Өшәр) авылында урам атамасы. (Бу авыл халкы күчкән. Күчүләренең

сәбәбе, зур су киләчәк дип көткәннәр, ә су килмәгән.) *Әширмә басуы* – Биектау районы Ямаширмә авылы янындагы басу атамасы. *Чыршылык басуы* – Мамадыш районы Түбән Яке авылы янындагы басу атамасы. *Танай басуы* – Апас районы Әҗем авылы янындагы басу атамасы. *Тау өсте басу* – 1. Саба районы Иске Керәнне авылы, 2. Питрәч районы Шәле авылы янындагы басу атамалары. *Тау басу* – 1. Балтач районы Арбор/Урбар авылы, 2. Балтач районы Көек авылы янындагы басулар атамасы. *Рафманкол басуы* – Әтнә районы Ябанчы авылы янындагы басу атамасы. *Рәми басуы* – Әтнә районы Яңа Шашы авылы янындагы басу (Рәхмәтулла исеме кыскартудан барлыкка килгән атама). *Якый басуы* – Азнакай районы Мәлбагыш авылы янындагы басу атамасы. *Якын басу* – Балтач районы Пүскән авылы янындагы басу атамасы. *Антон басуы* – Мамадыш районы Баскан авылы янындагы басу атамасы, *Каенсар кашы басуы* – Яшел Үзән районы Акъегет авылы янындагы басу атамасы.

***Баткак***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *баткак* лексик берәмлеге «сыйфат» дип ныгытылган. Мәгънәсе ачылган. *Беренче мәгънәсе*: эченә батарлык; былчырак, юеш, сыек балчыклы. *Тирә-як баткак сазлыклар һәм күлләр белән чолганып алынган иде.* Г. Әпсәләмов. *Баткак юлда көпчәкләр күмелә башлагач, кучерлар арбаларын ташлап киттеләр.* Ш. Усманов.

*Икенче мәгънәсе*: Юеш, пычрак җир өсте, аяк батардай сыек балчыклы урын. «Сүзлек...»тә бу мәгънәсе «исем» дип ныгытылган һәм мисал да китерелгән: *Җиде кат боз астыннан чыгар бака, Баткакларга, балчыкларга бата, бата.* Г. Тукай. *Урамның уртасыннан йөрерлек түгел, әмма өй буйларында шул баткак эченнән тар сукмак бар.* Г. Ибраһимов. //диалекталь. Шундый җирдәге ябышкак балчык. *Тагәрмәчләргә баткак ябышып калмасын. Аларны кырып торырга кирәк.* М. Гафури.

*Өченче мәгънәсе*. «Сүзлек...»тә аның күчмә мәгънәсе ассызыклана. Исем булуы ныгытыла һәм мисал китерелә: *Кешеләр тормыш баткагыннан чыгу юлын бергә эзлиләр*.

*Баткак* сүзе күп төрки телләрдә очрый: кумык, каракалпак, казак – *батпак, батпақ;* кыргыз, чыгтай – *баткак, батпакъ;* үзбәк – *батқок. Баткак* мәгънәсендә татар теле сөйләшләрендә сүзләр күп: *баткын, баткалак, батлак, батмак* һ. б. (Әхмәтҗанов, 2005: 108).

Бу лексик берәмлек белән Татарстанда су чыганаклары байтак. Тәтеш районының Бакырчы авылында *Баткак чишмәсе,* Апас районының Борындык авылында *Баткак күле,* Аксубай районының Яңа Ибрай авылында *Баткалак елга,* Нурлат районы Кычытканлы авылында *Баткылык сыза,* Балтач районының Кариле авылында *Баткак елга* һ. б. бар. Бу лексик берәмлек микротопонимнар составында да кулланыла. Мамадыш районының Еники-Чишмә, Биектау районының Мәмдәл авылында *Баткак болын* һ. б. атамалар очрый.

*Баткак* «тозлы күлләрнең төбендә очрый торган ләм, тозлы пычрак.

***Баткаклык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *баткаклык* лексик берәмлеге исем дип ныгытылган һәм мәгънәсе – баткаклы урын дип аңлатылган, мисал китерелгән. *Яз көннәрендә баткаклыктан бөтенләй үтеп булмый, җәй көне дә әз генә яңгыр яву белән хәзер бата башлый*. Г. Лотфи. *Кич булмаган Бу сазлыкны-баткаклыкны Ерып чыгарлык*. Ә. Исхак.

***Баткалак***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *баткалак* лексик берәмлеге исем дип бирелгән һәм мәгънәсе болай аңлатылган: елга, күл читләрендәге бик баткак балчыклы урын. *Бака туе баткалакта.* Мәкаль. (ТТАС, I: 133).

Бу лексик берәмлекләр кергән географик берәмлек атамалары байтак. Тәтеш районының Бакырчы авылында – *Баткак чишмәсе*, Апас районының Борындык авылында – *Баткак күле*, Аксубай районының Яңа Ибрай авылында – *Баткалак елга*, *Баткалак авызы* – Буа районы Адав-Толымбай авылы. *Баткалак күл* – Лениногорск районы Сугышлы авылы. Нурлат районы Кычытканлы авылында – *Баткылык сыза*. *Баткак* – Апсабаш авылы Биектау районы. *Баткак болын* – 1. Мамадыш

районы Еники-Чишмә; 2. Биектау районы Мәмдәл авыллары янындагы болын атамалары. *Баткак елга* – 1. Аксубай районы Иске Кармәт; 2. Арча районы Күпербаш, Кышкар, Кушлавыч; 3. Балтач районы Кариле; 4. Балтач районы Янгул авыллары янындагы болын атамалары. *Бурсык баткаклыгы* – Балтач районы ормабаш авылы янында. Актаныш районының Күҗәкә авылы белән чиктәш Бикбау авылы янында (Минзәлә районы) *Орышкан баткаклыгы* бар. Ул ел буена кипми. Язгы ташудан соң аңа түшәмә юл салалар, аннары бу түшәмәгә ел буена чыбык-чабык, тирес, коры салам өстәп торалар. *Биккол баткагы* да Бикбау авылы янында, Найдаш юлында. *Баткалак елга* – Аксубай районы Яңа Ибрай авылы. *Баткаклык* – Яшел Үзән районы Мамадыш-Әкил авылы янындагы баткаклык. *Баткак саз* – Арча районы Югары Сәрдә авылы янында. *Баткалак күле* – Лениногорск районы Сугышлы авылы янындагы күл. *Аргы баткалак* – Әлки районы Иске Алпар авылы янындагы баткак урын. Информант – И. Камалов. *Баткаклык* – Яшел Үзән районы Мамадыш-Әкил авылы янындагы баткаклык.

Бу терминнар әдипләребез иҗатында да еш очрый. Марсель Галиевнең «Рух» әсәрендә *баткаклык* лексик берәмлеге болай ныгытылган: «Ул чакта хәзерге цирк урынында *баткаклык* иде, шунда илтеп күмдем мин аның [Фәйзулла Туишевның] нәселле этен».

***Баш***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *баш* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган.

*Дүртенче мәгънәсе* болай аңлатылган: «Биеклеккә игътибар итәрлек булган берәр нәрсәнең югары өлеше, өске ягы. *Багана башы. Тау башына салынгандыр безнең авыл*. Г. Тукай. *Күзләр Эйфель манарасының башына күтәреләләр*. Г. Гали // Кыек түбә. *Кырлар үзгәргәннәр, садлар кипкән. Салам башлы өйләр кимегән*. Ә. Ерикәй. *Завод башы иләк шикелле иде... Нишләтте Фәсхи абзаң, ялт иттерде бит*! Ф. Сәйфи-Казанлы (ТТАС, I: 135).

*Бишенче мәгънәсе*: «Озынча нәрсәнең ике очының берсе яки оч ягы. Тау башы. Таяк башы. *Мостафин карандаш башы*

*белән өстәлне шакылдатып, тынлык урнаштырды*. Ш. Камал. //Авылның, урамның яки озынча зур корылманың билгеле бер очы. *Бик сагындым таныш кырларымны, Урманымны, күпер башымны*. М. Җәлил. *Бөркәүле зур лапас эчендә бер башта... ясмык... икенче башта... сугу машинасында борчак сугып яталар*. М. Гали (ТТАС, I: 135).

*Баш* лексик берәмлеге авыл атамалары составында еш кулланыла.Авыл исем-атамалары белән бәйләнешле рәвештә җыен атамалары составына кереп тә әйләнештә йөргәннәр.

Наҗия Борһанова мәгълүматларына караганда, «***Арбаш җыйынын*** июнь ахырында (Тукташ җыены үтүнең икенче атнасында) Вятканың уң кушылдыгы Өшия елгасы бассейнына урнашкан татар авыллары Югары Арбаш, Түбән Арбаш, Төркәш, Шепшеңәр, Хәсән, Ямбулат халкы бәйрәм иткән.

Җыен атамасы авыл исеменнән (ойконимнан) алынган. Авыл соңрак барлыкка килгән. XVIII гасырда Д.А. Корсаков тарафыннан бастырып чыгарылган Мамадыш өясе авыллары исемлегендә Арбаш турында түбәндәге мәгълүмат бирелгән: „Арбаш авыллары мөстәкыйль авыл буларак юк, Заит Саитов йөзлегенә кергән патшага хезмәт итүче унөч җан төрле авылларда яшилә“ (деревни Арбаш в натуре нет, жители в ней служилые татары тринадцать душ, живут по разным деревням, сотни Заита Саитова)».

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә җыенга сыйфатлама тәфсилле бирелгән.

Татар атамаларындагы *баш* термины «елганың башланган урыны, югары агымы» мәгънәсендә кулланыла. Бу термин татар су чыганаклары атамалары составында еш очрый. *Үгез Башы* атамасы Актаныш районының беткән авылы Үмәнәй янында теркәлгән. Бөгелмә районыннан ага торган Димскәй елгасының сул кушылдыгы *Акбаш елгасы* исемен алган. Лениногорск районыннан агып үткән Куак елгасының сул кушылдыгы *Сарбаш;* Нурлар районы җиреннән агып үткән Гәрәй елгасы кушылдыгы. *Баш чокыры* – Аюкөйдергән елгасы кушылдыгы (Апас рай-

оны) атамалары составында баш компоненты бар. *Җикән баш* – Аксубай районы Иске Татар Кармәте авылында басу атамасы. *Чирәм башы* – Алексеев районы Юеш Керкәле авылы янындагы атау исеме. *Мант башы* – Тәтеш районы Олы Тархан авылы янындагы калкулык атамасы. *Мант башы чишмәсе* – Тәтеш районы Олы Тархан авылы яныннан ага торган Тархан суы бассейнында. *Җиккән баш* – Аксубай районы Иске Татар Кармәте авылы янындагы басу атамасы. *Завод башы* – Сарман районы Мортыш Баш авылында. Элек бу урында тугым ясый торган завод булган. *Янган ындыр башы* – Балтач районы Иске Чепья авылы янындагы урын атамасы. *Мар башы* – Әлки районы Иске Чаллы авылы янындагы кыр атамасы. *Матмыр тау башы* – Биектау районы Өлә Казаклары авылы янындагы тау атамасы. *Су башы елгасы* – Нурлат районы Яңа Әмзә авылы янында, Гәрәй елгасы бассейнында. *Су башы аралыгы* – Азнакай районы Мәсгут авылында. *Су башы газизләре чишмәсе* – Спас районы Иске Рәҗәп авылы яныннан агып үтә торган Рәҗәп суы бассейнында. *Тоба башы күле* – Зөя елгасы бассейны, Апас районы Болын-Балыкчы авылы янында. Халык элек суны шушы күлдән эчкән. *Субаш чишмәсе* – Арча районы Ябынчы авылы янында. *Арбаш елгасы* – Кукмара районы Түбән Арбаш авылында, Шия елгасы бассейнында. *Иске күпер башы* – Питрәч районы Янцевар авылы янындагы күпер атамасы. *Кала башы* – Яңа Чишмә районы Тубылгытау авылы янындагы урын атамасы. *Карлыбаш* – Чүпрәле районы Яңа Ишле авылында, Олы Карлы елгасы башланган урын. *Кәҗә башы* – Кукмара районы Олыяз авылы янындагы урын атамасы. *Чирәм башы* – Алексеев районы Юеш Көрнәле авылы янындагы атау исеме. *Кошман башы* – Кошман суының башланган урыны, Апас районы Кошман авылы янында. Бу су һәм аның янындагы Кече Кошман авылы Казан ханлыгы чоры чыганакларында искә алына (Чернышев, 1971: 2190).

Бу термин шулай ук елга башланган урынга утырган авыл атамалары составында очрый: *Ашабаш, Ашытбаш, Мичәнбаш,*

*Мишәбаш, Шушмабаш, Минзәләбаш, Чаллыбаш, Курсабаш, Арбаш,* шәһәр тибындагы бистә *Карабаш* һ. б.

Моңа охшаш атамалар башка төбәкләрдә дә очрыйлар. Кубань гидронимиясендә *Субаши* – елга (Гулиева, 1969: 54); казак гидронимиясендә *Субасы* – инешләр (Койчубаев, 1985: 197); Кабарда-балкар гидронимиясендә *Субаши* – елга башы (Коков, 1966: 78).

Борынгы төрки телдә *vaš* «елганың югары агымы, башланган урыны» (ДТС, 1969: 86). В. Радлов сүзлегендә *баш* – «су башы, су башланган урын» (Радлов. т. IV. Ч. 2: 1549). *Баш* сүзе төрки телләрнең күбесендә *бас, пас, пазы, паш, пус* фонетик вариантлары белән елганың башланган урынын, югары агымын атый. Шулай ук бу компонент тау башы, калкулык башы һ. б. географик атамалар составында да килә. Мәсәлән, азәрбайҗан һәм кумык телләрендә бу апеллятив «холм», «исток», «большой», «главный», «верхний» мәгънәләрендә йөри. О.Т. Молчанова мәгълүматларына караганда, тау башы алтай телендә *баш* сүзе белән аңлатыла (*кырдын бажы*). А.Н. Баскаков Себер, Урта Азия, Төньяк Кавказ һ. б. җирлекләрнең терминнарын тәфсилләп тикшергән һәм, башка терминнар белән бергә, бу лексик берәмлекнең күрсәтелгән ареалда актив кулланылуын күрсәткән. Тыва диалектында – *бааш* (баажы), *паш* (пажы); кумандинлыларда – *баш (бажы), ээс тагдынъ бажында* – «биек тауның башында»; азәрбайҗанда *баш* – «баш, башланган урын (елганың), елга истогы, югары өлеш»; башкорт телендә *баш* – «баш (голова), югары өлеш, тау башы»; каракалпак телендә *бас* – «баш (голова); елга, инешнең башланган урыны, истәк югары өлеш, тау башы», *таудынг басында* – «тау башында»; кыргыз телендә *баш* – «нәрсәнеңдер башы, югары өлеш»; нугай *бас* – «баш, югары як, югары өлеш», *тав басы* – «тау башы»; татар телендә *баш* – «баш (голова), югары як»; *тау башы* – «тау башы (вершина горы)», тыва телендә *баш* – «баш», *даг баңы* – «тау башы»; хакас телендә *пас* – «баш, югары урын»; *тагъ пазы* – «тау башы».

Хакас теле диалектларында *тау башы* термины төрле вариантларда кулланыла. Мәсәлән: кәче диалектында (качинский диалект) – *таг пӧзи*, кызыл диал. *тагъ сыны, таг тиген*, бельтир диал. – *тигейи*, койбал диал. *таг ӱгӱ*, сагай диалект. – *таг пазы, таг тиген*. Шор телендә *паш*; тау башы – *сырты*; чулым төркиләрендә *пас;* түбән чулым төркиләрендә *айры бажы* – елга тамагы; борынгы төрки телдә *баш* – баш (голова); чыганак, елга башланган урын.

Дж. Клосонга таянып, О.Т. Молчанова *баш* терминының георафик атамаларда метафорик мәгънә белдерүен дә күрсәтә: *ыдык баш* – «святая вершина». *Отӱкен йыш башынта* – «на вершине горного леса Отӱкен». Челканлылар еш кына тау башын *тӧвӧ* дип тә атыйлар. *Баш* лексик берәмлеген метафорик мәгънәгә әйләндереп *тау башы* дип әйтү байтак төрки телләрдә, шул исәптән алтай телендә дә төрле әйбернең (мәсәлән, елганың) башланган урынын, югары агымын аңлата. *Баш* компоненты *бас, бажы, пас, паты* географик атамалар кулланылышында, *туу, кӧл суу* берәмлекләреннән кала, дүртенче урынны алып тора. *Баш* компоненты елга, күл, тау, авыл атамалары булып кулланыла. Ләкин ул тау-калкулык атамалары составында күбрәк йөри, мәсәлән, *Ак-Баш, ат-Бажы, Байбыш-Бажы, Башту-Бажы, Бети-Бажы, Кош-Бажы, Согоно-Бажы* һ. б. (О.Т. Молчанова).

Төрки телләрдә: *баш/бас/пас/паш* «баш» термины тау башларын, елга башын, елганың югары агымын, су башын, чыганакны, кыя, таш кыяларны атау өчен кулланыла һәм мисаллар китерелә: *Акбаш, Улубаш, Башкенд, Башюрях, Башбулак* һ. б.

Кырым топонимиясендә *баш, бас, бош* лексик берәмлеге кулланыла (А.Ф. Суперанская, З.Г. Исаева, Х.Ф. Исхакова). *Алабаш* – елга, Кебиту һәм Альми елгаларына кушылып Кара диңгезнең Каламит затонына коя. Төрек, кырым татарлары, команн телендә *баш* – 1) «баш», 2) «югары өлеш», 3) «баш, башланган урын», 4) «начальник-җитәкче», «башлык», 5) «баш кеше» (Радлов, IV: 15, 46– 1550); азәрбайҗан телендә 1) «баш, югары

оч», 2) «калкулык, кашлак», 3) «башланган урын», «елганың башланган урыны», «су башы», 4) «зур», «иң зур, иң әһәмиятле», 5) «югары», «югары урында урнашкан» (Бушуева, 1971); казак телендә *бас* – 1) «баш», 2) «предметның яисә затның югары өлеше», 3) «башланган урын» (Радлов, IV: 1524).

*Баш, агач башы* кебек лексик берәмлекләр әдипләребез һәм шагыйрьләребез иҗатында да шактый очрый.

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *агач башлары* гыйбарәсе күңелне тибрәндерерлек итеп матур кулланылган: *«Кечкенә малайның ул әйбәт әбине һич ачуландырасы килми. Ник дисәң, мондагы җиләк-җимешләрне, карлыган-бөрлегәннәрне шул әби үстерә, анасын көтә торгач бик ялыкса, тизрәк йоклап китсен дип, шау-шу иттереп биектәге агач башларын атындыра башлый...»*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» повестыннан мондый юллар укыйбыз: *«Хәзер менә утыз елдан артык вакыт узгач – шул ук җил, шул ук рәшә, шул ук тау башы, әмма йөрәк акыл белән тибә, тамак кипми, сулыш тигез».*

Вахит Имамовның «Утлы дала» романында мондый юллар очратабыз: *«Алдагы беренче мең җайдак үзәнлек эченә иңүгә, аларны биек тау башларыннан тәгәрәгән зур-зур ташлар, ук һәм пуля яңгыры каршылады».*

Татарстаннан читтәге төбәкләрдә көн иткән татарлар телендә дә *баш* апеллятивы актив әйләнештә йөри. Башкортстанда: Гафури районындагы Җилем елгасының уң кушылдыгы *Баткаклыбаш елгасы,* Баймак районында Шәрде елгасының уң кушылдыгы *Бишбаш елгасы,* Бөрҗән районында Олы Нөгеш елгасының уң кушылдыгы *Икебаш,* Зианчура районында Иргаеш елгасының уң кушылдыгы *Илбаш,* Нуриман районыннан агып уза торган Уфа елгасының сул кушылдыгы *Салдыбаш* елгалары бар. Башкортстанда *«баш»* апеллятивы белән торак пункт атамалары да байтак. Бөре районында Айбаш авылы, Чишмәле районында *Бүләкбаш,* Нуриман районында *Салдыбаштамак,* Тәтешле районында *Бырынбаш,* Бүздәк районында *Урзайбаш,*

*Иске Карбаш (Иске Карамалыбаш)* авыллары, Авыргазы районында *Үзәнбаш* (икенче исеме Иске Ибрай), Мәләвез районында *Өсбаш* (икенче исеме Исламгол) һ. б. исеме алган торак пунктлар бар.

Чиләбе өлкәсендәге Кыштым, Сосновски, Кочкар районнарында *Баш-Байтал* исеме алган күлләр һәм елгалар бар. *Карабаш* исемле шәһәр Чиләбе өлкәсендә урнашкан (яшәү урыны, авыл буларак ул 1822 елда нигезләнә, 1933 елдан ул шәһәр статусы ала). *Карабаш* исемен ул *Карабаш* исемле тау атамасыннан алган. Свердловск өлкәсендә Тавда елгасына сул яктан *Карабаш* елгасы килеп кушыла. Элекке Пермь губернасында *Алабаш* исемле авыл бар (Географический, 1873: 11). Элекке Пермь губернасының Верхотур өязендә *Югары Алабаш* исемле авыл теркәлгән. Пермь губернасының Осинск өязендә Олы Әмзә елгасы ярына урнашкан *Акбаш* яисә *Әмзәбаш* авылы теркәлгән. Шул ук губернаның Красноуфим өязендә Шәрәмә елгасы ярында *Акбаш* исемендә авыл урнашуы әйтелгән.

Самара өлкәсендә: Камышлы районында Бозбаш исемле татар бистәсе бар. Атаманың чыгышы татар теле белән бәйләнешле. Татар телендә *боз* термины боз кебек салкын, ә *баш* – «башланган урын, вак елгаларның һәм елгаларның башланган урыны», *Бозбаш* суын русча «Холодный исток», «Студенец» дип әйтергә мөмкин (Барашков, Дубман, 1996: 77).

Урта Азия җирлегендә борынгы шәһәр *Кошкарбашы, Атбаш* исемендә үзән һәм елга теркәлгән (Караев, 1986: 30). Карачай-Балкар гидронимиясендә *Субаши* – елга башы (Коков, 1966: 78), Кубаньда – *Субашы* – елга (Гулиева, 1976: 54), Кырымда *Субаш* – елга (Словник..., 1979: 538). Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *баш* апеллятивы Урта Азия, Кавказ, Россиянең Себер, Идел буе, Кара туфраклы үзәк регионнары, Казакстан һәм Төркия өчен характерлы. *Басюрях, Ешкибасы* елгалары һәм *Бас-эльген* күле Казакстанда урнашкан (Или арты Алатауның Талган уездында). Кыргызстан топонимиясендә: *Баш-Ичке-Су* – Аксай елгасының сул кушылдыгы

(Нарын өлкәсе, Атбаш районы), *Ак-Баш* авылы Ош өлкәсенең Сузак районында. *Камыш башы* – Талас өлкәсенең Токтогул районындагы авыл. Шундый ук авыл атамасы Ош өлкәсе Сузак районында бар. Кыргызстан ономастикасында *баш* компоненты белән 19 атама бар. Шуларның 11 е су чыганаклары, ә калган атамалары авыллар, таулар, тау үткелләре (Умурзаков, 1988: 37). *Рязань* өлкәсенең Михайлов районында Олыбаш инеше бар (Мурзаев, 1984: 76–77). Төньяк Кара диңгез регионындагы Рыбаковка авылында Карабаш атамасы алган микротопоним теркәлгән (Касим, 1978: 375). Кырым топонимиясендә баш компоненты белән ясалган атамалар байтак: *Джабаш, Алабыш, Тюа-Абаш, Карабаш, Чурабаш, Хастабаш, Терекли-Абаш, Экибаш, Акбаш, Казанбаш, Озенбаш, Кучук-Узенбаш, Биюк-Узенбаш, Чамлы-Узенбаш, Урбаш, Чурбаш, Чурубаш, Субаш, Сарыбаш, Ашагабашы, Кызылкарасубашы, Чольбашы.*

*Баш* термины алтай, тыва телләрендә «елга башланган урын», «һәр әйбернең югары өлеше», «баш» мәгънәсендә кулланыла, хакас телендә *пас* варианты йөри. *Атбажы* елгасы Алтайда ага. *Он-оос бажы* (*Ун авыз башы*) термины шулай ук башлангычларын тау башыннан алган тау елгаларын атау өчен кулланыла (Баскаков, 1969: 67– 68). Тывада Олы Енисей елгасына (Бий-Хем) Улуг-хем (большой исток) һәм Биче-хем (малый исток) кушылдыклары белән уң яктан *Баш-хем* елгасы килеп кушыла. В. Вербицкий мәгълүматлары күрсәтүенчә, төрки телләрнең алтай һәм алатау шивә-сөйләшләрендә Төньяк-Чуй тауларында, Машей елгасының югары агымында *Маашейбаш* тавы теркәлгән; Катунь елгасының уң кушылдыгы Ининең югары агымында *Инбашы* атамасы алган тау бар, Чулышман елгасы тамагында *Якпаш;* елга башланган урын, югары агым, чыганак *Субажы* исемен алган (Вербицкий, 1884, IV: 194).

***Бәке***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *бәке*: «Су алу һ. б. өчен бозны тишеп ясалган уем (елгада, күлдә һ. б.)». *Бәкедә кер чайкау. Бәкедән су китерү. Авылның бәке ачучысы. Унлап*

*бәке тишеп карадым – - тик бер генә балык та тота алганым юк.* Соц. Тат. (ТТАС, I: 1977, 206).

Рифкать Әхмәтҗановның «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә *бәке* турында мондый мәгълүматлар бар. «*Бәке* диалекталь *мәке* «прорубь» – мари *вäк, вäкы* сүзеннән (бу яңгырашны Казан арты сөйләше вәкилләре әдәби телгә керткәннәр); мари *вäкы* (> чуваш *вака́*) < болгари **ŵәкәс* борынгы төрки *öкӥ* ~ төрек *öкӥ* «бәке»; борынгы төрки варианттан турыдан-туры мишәр (Сергач) *өкө,* касыйм сөйләшендә *үке* «бәке» вариантлары килә; кара шулай ук чыгытай *öкү, öгү,* каракалпак – *үки* id., венгр телендә *vekid* болгари телдән. Кара: Räsänen, 1969: 370.

Чагыштыр: һинд-европа **оди* «күз» (шуннан рус. *óко, очкó, окнó*)» (Әхмәтҗанов, ТТЭС. 2005: 115).

*Бәке*нең татар теле сөйләшләрендә түбәндәге төрдәшләре бар: урта диалектның бөре, мамадыш, балтач, касыйм сөйләшләрендә *мәке, пәке, үке;* көнбатыш диалектның ләмберә, кузнецк, хвалын һәм чистай урынчалыкларында *вәке;* себер татарлары телендә *кыйу* – «бәке». Башкорт әдәби телендә *мәке* «бәке», сөйләшләрдә исә «кое». Мари телендә *бәке* мәгънәсендә *вäк, вäкы* сүзе йөри.

***Бит***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *бит* лексик берәмлеге *исем* дип ныгытылган һәм мәгънәләре болай аңлатылган. Нәрсәнең дә булса өсте, өске йөзе. *[Садыйкның] чалбар[ы] аяк битенә чаклы тип-тигез булып салына*. Г. Ибраһимов. *Мәрданша бабай... чиләктәге бәрәңгенең берсен бармак битләре белән басып, учакка бер-ике коры чыбык атты*. Г. Гобәй. // Битлек, циферблат. *[Мансуров] сары битле кесә сәгатенә күз төшереп, аны учына йомарлады*. Г. Бәширов (ТТАС, I: 169).

Тагын шундый мәгънәләре: Тау, калкулык, һ. б. ш. ларның авыш, сөзәк яны, өслеге. *Моннан бер йөз метрлап уңдарак разведчиклар кыя битендә чытырман куаклык эзләп тапканнар*. И. Гази; шигъри сөйләмдә нәрсәнең дә булса өс йөзе. *Караңгы төн, коеп яңгыр ява, Урам бите сазга күмелгән*. Ш. Маннур.

*Кырда салкын буран, җил себерә ялан битләрен.* Ф. Кәрим. (ТТАС, I: 169).

Оренбург татарларының каргалы һәм богырыслан сөйләшләрендә тау бите *тау кабагы* дип йөртелә (ТТЗДС, 2009: 371).

*Бит* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда шактый актив кулланыла: *Мичкә бите* – Әтнә районының Иске Җөлби авылындагы тау атамасы.

*Бит* лексик берәмлеге әдипләребез иҗатында файдаланыла.

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» дигән исем алган повестенда *тау бите* гыйбарәсе кулланыла: *«...Арасында сап-сары зонтик булып какы күренгән ужҗым басуыннан барасың-барасың да кинәт кенә тау битенә килеп чыгасың».*

Вахит Имамовның «Утлы дала» исеме белән дөнья күргән тарихи романында *тау бите* гыйбарәсе байтак очрый: *Өч-дүрт меңгә якын нәүкәрен югалтып Нокыш дигән елга ярына төшсә, ике тау битендә билгесез дошман гаскәре урман сыман тезелешеп тора.*

Марсель Галиевнең «Рух» хезмәтендә дә *тау бите* гыйбарәсе кулланылган: *«Тау бите буйлап, түбәтәй-түбәтәй булып, җете чәчәкле кыргый мәтрүшкәләр сибелгән».*

Роза Хәбибуллинаның «Мулла килене» романында *тау бите* термины һәм башка географик берәмлекләр матур сурәтләнгән: *«Хатынының көянтә-чиләк күтәргән сылу гәүдәсен, илһамланган йөзен күреп, табигатьнең бу илаһи матурлыгы, бу чишмә, бу чәчәкле тау бите Маһинурдан башка болай ук гүзәл, болай ук камил була алмас кебек тоелды».*

***Болак***. Татар телендә *болак* – «елга, елгачык, инеш, чишмә, чыганак, канал» мәгънәләрен белдерә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *болак* «инеш» дип бирелгән. Мисаллар: *Якында бер болак бар иде, суы салкын.* Дәрдемәнд. *Алар (елкычылар) малайны күтәреп якындагы болакка алып барып исенә китерделәр, кымыз эчерделәр.* Казан утлары (ТТАС, 1977: 176). В. Радлов сүзлегендә *болак* – «Казан татарларында инеш,

Казандагы канал исеме»дип теркәлгән (Т. IV, 2 нче кисәк, 1838). XVI гасырда *Болак* – Казан елгасының *табигый ермак* рәвешендәге сул кушылдыгы. Инкыйлапка кадәр ике чакрым озынлыкта булган бу ермак аша Иделдән кечерәк кораблар Кабан күленә кереп йөргәннәр, алар бай сәүдәгәрләрнең товарларын биредәге ярминкәләргә һәм сәүдә йортларына ташыганнар. *Болак* атамасы тарихи чыганакларда, Казан өязенең язу (писцовая) кенәгәләрендә *Олы Болак* буларак та телгә алына: «...Кабан күленнән чыгып, Казан суына тоташа торган *Олы Болак* ермагы...» Казан елгасына коя торган түбәнге өлешендә Болак тагын бер тармак хасил иткән һәм балак (чалбар балагы) рәвешен алган. Язу яисә теркәү (писцовая) кенәгәләрендәге мәгълүматлардан күренгәнчә, ул *Черек Болак* дип исемләнгән. *Болак* атамасының *балак* сүзеннән чыгып аңлатылуы да менә шушы күренешкә нигезләнгән булса кирәк («Соц. Татарстан» газ., 1984, 18 сент.).

1954–1956 елларда башкаланы су басудан саклау өчен дамба төзелү сәбәпле, Болакның тармакланып киткән, Казан елгасына койган урыны (тамагы) су астында калды. Моннан соң инде Кабан күле Болак аша су алыштыра алмады. Кайчандыр кечерәк кораблар йөзгән матур һәм мул сулы Болак ташландык хәлгә килде.

*Болак* исеме алган географик берәмлекләр Татарстан җирлегендә байтак очрый. *Болак* – Саба районы Күкчә авылы янындагы елга, ул Олы Мишә бассейнында. Чистай районында Болак Шонталы елгасының сул кушылдыгы бар. Баулы районының Покровский Урустамак авылы янында *Болак* Ык елгасына сул яктан килеп кушыла. Арча районы Яңа Кишет авылы янында *Болак* атамасы алган елга бар. *Сер-Болак* – Яшел Үзән районының Бело-Безводное авылы янында. *Мукри* (русча: Мокрый) *Болак* – Арча районы Урта Бирәзә авылы янындагы Бирәзә елгасы кушылдыгы.

*Болак* термины микротопонимнар составында да кулланыла: *Болак сызасы, Болак тугае, Сулъяк Болак урамы, Уңъяк Болак*

*урамы* һ. б. Алексеев районында *Мордва Болагы* атамасы алган авыл да бар.

*Болак*ның «чишмә, чыганак» төшенчәсендә йөрүе татар халкында сакланып калган. Аларны: «Болак башы – торак башы», «Суның башы – болак», «Суның башы болактан», «Болагы булмаса, үзәне дә кибә», «Болак суы эчмәгән» (ягъни чишмә суы эчмәгән) дигән мәкальләр дәлилли. Җирле халык телендә *болак* сүзе аерым географик берәмлек – «ермак», «канал» атамасы буларак билгеле. Аның, термин буларак, «инеш», «елга култыгы», «елга», «чишмә», «чыганак» мәгънәләре тоныклана бара.

Дәрдемәнднең «Кыш көнләре» дип исемләнгән шигырендә мондый юллар укыйбыз:

*Иелде ботаклар,*
*Карлар асылды;*
*Тагълар, болаклар –*
*Бар да басылды.*

Дәрдемәнднең бу шигырь тезмәсендәге *болак* термины халык телендә кулланылган «елга, елгачык, ермак, инеш, чишмә, чыганак, канал» мәгънә-төшенчәләрен аңлата.

Р. Әхмәтьяновның «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә *болак~булак* термины тәфсилләп тикшерелгән (ТТЭС, 2005: 145).

*Болак ~ булак* сүзе «Идегәй» дастанында кулланыла:

*Җәяү яткан хәйран йорт –*
*Ач көзәндәй бөгелеп,*
*Ач бүредәй чыелдап,*
*Ач арысландай үкереп.*
*Илеңә тавыш салыр ул;*
*Кырык көнлек чүленә*
*Айдынлы булак салыр ул.* (1988: 68).

*Айдынлы булак* – якты чишмә, инеш.

Кыргыз топонимиясендә *Айдын-Кёль* – күл атамасы. Ыссык-Күл өлкәсенең Тон районындагы (Умурзаков, 1988: 11) ул сулык *Якты күл* мәгънәсен белдерә.

Урта гасырлар галиме М. Кашгари үзенең хезмәтендә болакның «чыганак, канал, арык» төшенчәләрен күрсәткән. Л. Будагов, М. Фасмер, Э. Севортян сүзлекләрендә бу терминның (төрле фонетик төрдәшләре белән) гагауз, төрек, татар, казак, кыргыз, үзбәк, каракалпак, кумык, кабарда-балкар һ. б. төрки телләрдә «чишмә, инеш, ермак, канал, арык, су чыганагы, кизләү, күлләвек, сулык» мәгънәләре китерелә.

*Болак ~ булак*тан ясалган татар атамалары (татарларның тарихи Ватаннарында, ягъни хәзерге Россия төбәкләре киңлекләрендә һәм төрки халыклар кайчандыр яшәгән һәм хәзер дә көн итә торган җирлекләрдә очрыйлар. Мәскәү елгасы бассейнындагы чокырларның берсе *Булацкий* атамасын йөртә. Ульяновск өлкәсендә яши торган татарлар телендә *Кандыбулак* – Кондырча елгасының сул кушылдыгы, Самара өлкәсендә *Болак* – Сок елгасы кушылдыгы (Иске Ярмәк авылы, Камышлы районы) һ. б. Башкортстанда бу термин белән түбәндәге гидроним һәм топонимнар билгеләнгән: *Йылбулак* – Тюртюк елгасының уң кушылдыгы (Бишбүләк районы), *Кара болак* – чишмә, Инҗәр елгасының сул кушылдыгы (Архангель районы), *Җиде болак* – Олы Ык елгасының сул кушылдыгы (Күгәрчен районы), *Таш болак* – Касмарт елгасының сул кушылдыгы (Зианчура районы), *Калды Болак* – Урал елгасының сул кушылдыгы (Учалы районы) һ. б.; *Йылбулак-Тамак, Йылбулак-Матвеевка* – Бишбүләк районындагы авыллар. Чиләбе өлкәсендә *Кара болак* – елга һ. б. Таулы Шор төбәгендә *Пулук* – Тызас елгасының, *Плуг* – Олы Азас һәм Кондома елгаларының кушылдыклары; Казакстанда *Булак-Карасу, Булаккудук, Булактыколь, Булактысор* һәм *Кербулак* елгалары бар. Таулы Алтайда: *Сары Булак* һәм *Узун Булак, Булага* (елга), *Булаккы* (киң чокыр, ташландык басу), *Булук* (тау, киң чокыр, ташландык басу), *Ак булак* (елга), *Кайынгду-Булак* (елга), *Кош-Булак* (елга), *Музду-Булак* (елга), *Сары-Була*к (елга), *Тапчы булак* (тарлавык). М.Ф. Розен һәм А.М. Малолетко мәгълүматларына караганда, *булак* термины күләме зур булмаган елга атамалары составына

керә: Аргут елгасы бассейнында *Акбулак* ага, Алаха елгасы кушылдыгы *Карабулак* бар (1986: 28). *Булак (Булага)* терминының таралыш ареалы Монголиядән Балканга кадәр таралган (Мурзаевы, 1959: 303). Тывада *булак* – «тау үзәне», «инеш» (далада), «чишмә»: *Булак* (чишмә), *Булак* (елга), *Баян-Булак* (киң чокыр, ташландык басу), *Кыдыч-Чира-Булак* (елга), *Орто-Чира-Булак* (елга); Хакасиядә *Пустубулак* атамалары сакланган. О.Т. Молчанова хезмәтләрендәге мәгълүматлардан күренгәнчә, *болак* компоненты кергән географик атамалар Таулы Алтайда һәм Тывада күп түгел. Кустанай өлкәсендә *болак* чишмә буларак әйләнештә йөри.

*Болак ~ булак* термины кайбер географик киңлекләрдә мәгънәви үзгәрешләр кичергән, аерым очракларда корып баручы елгаларның, калкулык-тауларның атамалары составына кергән (мәсәлән, Тянь-Шаньда – *Чимбулак* яссы таулыгы, Азәрбайҗанда *Гейбулак* һәм *Агбулак* дип исемләнгән тау сыртлары бар; Кыргызстанда *Меңбулак, Талдыбулак* һәм *Сарыбулак* атамалары сакланган). Кыргызстанның Нарын өлкәсе Кочкор районында *Булак* – Каракужур елгасының уң кушылдыгы. *Булак-Суу* – Кызыл Аргын (Кызыл-Суу елгасы бассейны) елгасының сул кушылдыгы (Ош өлкәсе, Алай районы), *Булак-Башы* авылы Ош өлкәсенең Ләйлек районында. *Булак-Ашуу* атамасы алган ике тау сырты, тау үткеле Ыссык күл өлкәсенең Аксу һәм республика карамагындагы Панфилов районнары җирендә урнашканнар.

Кыргыз географик атамалары составында *Ак-Булак* исеме алган шәһәр тибындагы бистә бар. Ул Ыссык күл өлкәсенең Тюп районында урнашкан. *Ак-Булак* исеме бирелгән авыллар тагын Ыссык күл өлкәсенең Аксу, Ош өлкәсенең Базаркорган, шул ук өлкәнең Ләйлек районнарында очрый. *Ак-Булак* инеше Чон-Кемин елгасының уң кушылдыгы, *Бар-Булак* исемендәге авыл Ыссык күл өлкәсенең Тон районында урнашкан. Ош өлкәсенең Карасу районында *Баш-Булак* дип аталган авыл бар. Талас өлкәсе Талас районында *Беш-Булак* исеме алган тау Калба елгасының уңъяк ярына урнашкан. *Беш-Булак* авылы

Талас өлкәсенең Ленин районында, *Кёк-Булак* инеше Нарын өлкәсенең Атбашы районында, Улан елгасының уң кушылдыгы. Улан елгасын икенче төрле *Ат башы* елгасы дип тә атыйлар. *Кёк-Булак* атамасы алган елга Сонкёль елгасының сул кушылдыгы (Нарын өлкәсенең Кочкор районында). *Айгыр-Булак* – Ыссык күл өлкәсенең Жетиогюз районы җиреннән ага торган Чон-нарын елгасының уң кушылдыгы. Составында *болак* компоненты булган 10 атама торак пунктларныкы. *Май-Булак* – 1. Энилчек елгасының уң кушылдыгы (Ыссык күл өлкәсе, Аксу районы), 2. Кызарт елгасының уң кушылдыгы (Нарын өлкәсе Кочкар районы (Умурзаков, 1988: 11, 13, 14, 47, 136).

Географик атамаларның компоненты буларак, *булак* көнчыгыш фин халыклары топонимиясендә дә очрый. *Мари Эл* республикасында *Шайбулак* атамасы белән авыл бар. Әлеге термин Пермь краендагы пермяк авылларының атамаларында урын алган.

Кырым татарларында *булак* сүзе еш кулланыла. Аның таралыш даирәсе мәсьәләләре буенча Мәскәү галиме Э.М. Мурзаев махсус тикшеренүләр үткәргән. Гагауз халыкларында *Булак* – фамилия, казакларда да *Булакбай* исеме һәм *Булакбаев* (Булакбаева) фамилияләре бар.

Шунысын да әйтик, Нил елгасының сул як ярындагы Каир шәһәрендә *Болак* исемен йөрткән гавань бар. Анда данлыклы Мисыр борынгылыклары тупланган *Болак музее* эшли.

Урта гасырлар галиме М. Кашгари үзенең хезмәтендә аның «чыганак, канал, арык» төшенчәләрен күрсәткән. Л. Будагов, М. Фасмер, Э. Севортян сүзлекләрендә бу терминның (төрле фонетик төрдәшләре белән) гагауз, төрек, казак, кыргыз, үзбәк, каракалпак, кумык, кабарда-балкар һ. б. төрки телләрдә «чишмә, инеш, ермак, канал, арык, су чыганагы, кизләү, күлләвек, сулык» мәгънәләре китерелә. Болакның «чишмә, чыганак» төшенчәсендә йөрүен татар халкында сакланып калган «Болак башы – торак башы», «Суның башы – болак», «Суның башы болактан», «Болагы булмаса, үзәне дә кибә», «Болак суы эчмәгән» (ягъни чишмә суы эчмәгән) дигән мәкальләр дәлилли. Җирле

халык телендә *болак* сүзе аерым географик берәмлек – «ермак», «канал» атамасы буларак билгеле. Аның «инеш», «елга култыгы», «елга», «чишмә», «чыганак» мәгънәләре, термин буларак, тоныклана бара.

***Болын***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *болын* лексик берәмлеге болай аңлатылган: «Чабулык яки көтүлек җир. *Идел болыннарының иге дә, чиге дә юк, алар тугайларга сыеша алмыйча, тыгылышып утыралар*. Г. Бәширов. *Болыннарда көтү көткән чакта Уйлар белән бергә йөрдем мин*. Ә. Ерикәй (ТТАС, I: 177).

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, «Балыклы җыены яки Олы Болын җыены Алан җыеныннан соң (июнь башында) һәм Җамбай җыеныннан соң икенче атнада Мишәнең уң кушылдыгы Тәмте елгасы бассейнына урнашкан Күкчә, Балыклы, Тәмте, Олы Мәтәскә, Югары Мәтәскә-Җаңгил һ. б. авыллар халкы тарафыннан бик күңелле итеп үткәрелгән.

Галимә *Балыклы җыены* атамасын Балыклы авылы исем-атамасыннан дип, ә җыенның икенче атамасы *Олы Болынны* географик берәмлек исеменнән алынган дип яза. Шул ук вакытта Нажия җыен исемлегенә кергән авылларның исемлек-саны якынча гына бирелде дигән фикер үткәрә. Вакытлар үтү белән җыен үткәрү йоласының үтәлми башлавы, буыннар алышынган саен, халык хәтерен саегайта һәм җыенга кергән авыллар исеме, аның үткәрелү дата-вакыты онытыла барган. Шул ук вакытта Нажия Борһанова Е.А. Маловның «Миссионерство среди мухамедан и крещенных татар. Сб. статей» (Казань, 1992) хезмәтеннән *Зункуwак* атамасын таба, этимологиясен дә бирә: *Зункуак* < ихтимал, *озон* сүзеннән, *узун* + *куwак* «Озын агач»ны белдергәндер. Бәлки озын куактыр да, чөнки экспедиция-сәфәрләрдә йөргән вакытларда бакчаларында һәм янындагы урманнарында озын куаклар үскән авылларны байтак күрергә туры килде.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, *Йассы болын* җыенын июнь башында (Йансыбы җыены үтүнең беренче атнасында) Вятканың уң кушылдыгы Бурец елгасы бассейнына ур-

нашкан Адай, Купка, Аш-Бужи, Зур Сәрдек, Сәрдекбаш, Уразай, Кара Елга, Олыяз, Югары Казаклар, Түбән Казаклар авыллары халкы бәйрәм иткән.

*Яссы Болын җыены* атамасы аны үткәрә торган халыкның авыллары урнашкан җирлекнең үзенчәлекләрен күрсәтә.

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә: «*Болын* – борынгы төрки сүз. „Елга дугасы белән уратып алынган җир“ мәгънәсендә булган. Охшаш сүз монгол, бурят, алтай, эвенк телләрендә дә бар, ул чуваш һәм мари телләренә дә кергән. Татар диелектындагы *болын өстендә* (ягъни *печән өстендә*) сүзенең печәнлек буларак болыннарның зур икътисади әһәмияткә ия булганлыгы аңлашыла».

*Болын* лексик берәмлеге үзе генә дә, атама составында да халык телендә еш кулланыла. *Габделхаликъ болыны* Биектау районының Кодаш авылы белән янәшә урнашкан. Элек ул бик гүзәл иде. Заманасында ул сөреп ташланды. Хәзер чын мәгънәсендәге ташландык урын, анда шайтан таяклары үсеп утыра. Балтач районының Пүскән авылы янында шулай ук *болын* бар. *Болын атавы елгасы* – Балык Бистәсе районының Котлы-Бөкәш авылы яныннан ага торган Бүрсет суы кушылдыгы; *Болын елгасы* – Мамадыш районының Түбән Сон авылы янында, Сон елгасы бассейнында; *Болын очы* – Саба районының Сатыш авылындагы урам атамасы; *Болын чишмәсе* – Аксубай районының Яңа Үзи авылында, Олы Сөлчә елгасы бассейны; *Болын тавы* – Кама Тамагы районының Олы Бортас авылы янындагы тау атамасы; *Атау болыны* – Питрәч районының Татар Казысы, Арча районының Ташкичү авылларында болын атамалары. *Канач болыны* – Балтач районы Смәел авылы янындагы болын атамасы. *Шаблаб болыны* – Питрәч районы Янцевар авылы янындагы болын исеме. *Түбән печәнлек болыны* – Биектау районы Зур Кавал авылы янындагы болын. *Түбән оч болыны* – Саба районы Керәнне авылы янындагы болын. *Авыл очы болыны* – Актаныш районы Семистрау (Өшәр) авылы очындагы болын. *Чүннек болыны* – Биектау районы Ямаширмә авылы янындагы

болын атамасы. *Ермаклы болын* – Алексеев районы Юеш Көрнәле авылы янындагы болын атамасы. *Арт болын* – Буа районы Карлы авылы янындагы болын атамасы.

***Борма***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *борма* «исем» дип ныгытылган һәм түбәндәгечә аңлатылган: «Дугасыман кәкре бөгелеш, борылма. *Агыйдел, безнең ындыр турында кинәт кенә бер борма ясап, авылның эченә керә язып кала*. Г. Ибраһимов. // Сыйфат мәгънәсе: Бормалы, бормалары булган. *Борма елга суын эчеп Су буенда тал үсә. Е. Ерикәй. Хәйретдин... борма-борма баскычларменеп киткән биек кенә кызыл тауга (күрсәтә)*. М. Гали» (ТТАС, I: 179).

***Борылма***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *борылма* «исем» дип ныгытылган һәм *борылыш* сүзенә җибәрелгән. *Авылыбызны яртылай әйләндереп алган Агыйдел озынайды, борылмалар ешайды.* М. Әмир. // *Сыйфат мәгънәсе.* Борыла торган (ТТАС, I: 180).

***Борылыш***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу термин болай аңлатылган: «Берәр нәрсәнең икенче якка борылган, авышкан, тайпылган урыны; борма. *Урманнан юл белән килеп чыккан турыда Идел зур борылыш ясап ала*. Г. Ибраһимов. *Поезд юл борылышындагы пакгаузларны узып киткәч, Юныс Вәлишин сәгатенә карап алды да озатучыларга эндәште.* К. Нәҗми» (ТТАС, I: 180).

Халык арасында экспедиция-сәфәрләрдә йөргәндә, елга-инешләр агымнарын үзгәртеп, борылып аккан урыннарын һәм гомумән *сукмак, юл* һ. б. шундый топонимнарны җирле халыкның *борма, борылма, борылыш, борылу* дип атаулары ачыкланды. Сәфәрләрдән мин халык теленнән шушындый бер шигырьәйтем дә язып кайттым.

*Безнең Шушма суы борылу-борылу,*
*Борылулары саен бер җылу.*

*Борма, борылма, борылыш* лексик берәмлекләре белән географик атамалар да ясала. *Кызлар бормасы* – Мамадыш районы

Үсәли авылында бар. Элек бу урында кызлар су коена торган булган.

Бу терминнар әдипләребез һәм шагыйрьләребез иҗатында шактый күп очрый.

Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» китабындагы «Язгы сабан туйлары» дип исем куелган повестенда *Бормалы су буе* атамасы урынлы һәм матур кулланылган: *«Мәйдан беткәннән соң, көн кичкә авышкач, өйгә кереп кенә чыктык та, ал-кызыл, яшел, зәңгәрдән киенгән чуп-чуар кыз-хатыннар төркеменә ияреп, авылның урманга таба сузылып менгән югары очына, Бормалы су буена – Бөйдә болынына киттек».*

Бу мисалда *бормалы* термины су чыганагына мөнәсәбәтле. Ә әдипнең «Җидегән чишмә» романында *бормалы* термины топоним буларак «*Бормалы сукмак*» дип бирелгән: *«Тау кырыендагы бормалы сукмактан инеш буена төшеп менгәч, карт уйлана-уйлана Гайнан янына килеп туктады».*

Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *борылма* термины күңелне борчуга салып кулланыла: *«...Сүз йөри менә, сүз! Җәяүле бурандай астын гына себертеп халык арасында дерә дә шомлы сүз йөри, э-э. Әверлән дөрес акмый, борылмалар ясап әйләнгәләп ага икән, аны турайтырга кирәк, диләр. Чишмә шавы да кемнеңдер татлы йокыларын бүлдерә икән, аны да тындырырга кирәк янәсе».*

Бу юлларда бөек әдибебез Гомәр Бәширов экология мәсьәләләренең көн кадагына суга торган әһәмиятле проблема икәнлеген күрсәтә, бу өлкәгә игтибарсызлыкны матур гына итеп тәнкыйтьли.

Язучы Әсгать Салахның «Аккан сулар... Яшьлегем хатирәләре» исеме алган чәчмә әсәрендә Шушма елгасының *Борылыш* исемен йөрткән урыны телгә алына: *«Шушма елгасының Борылыш дип аталган иллә дә җайлы урынына электр станциясе төзи башладылар...»; «... Элмәк сыман булып килгән Борылышның станция урнашасы «муены»н казып-ерып чыгасы иде. Япь-яшь авыл кызларының авырлыктан иңкәеп, носилка*

*белән сулары агып торган балчык ташыганнары әле дә күз алдымнан китми»* (Казан утлары. 2013, № 1).

*Борма, борылма, борылыш* терминнары Татарстаннан читтә яши торган татарлар телендә дә табыла. Ульяновск өлкәсендәге Ялхавай районындагы Борма авылы атамасы нигезендә нәкъ шушы сүз – *борма* ята. Теплый Стан тирәсендәге бу авыл елга борылышында утырганга күрә шулай аталган (Барашков, Дубман һ. б., 1996: 76).

Бу термин башка төрки халыкларда да шактый еш очрый. Үзбәк телендә – *бурилиш, кайрилиш*; кыргызларда – *бурулуш, кайрылыш*; казакларда – *бүкмесін, бүгіліс, бурылыс;* каракалпак – *бурылма, айланыш*; кумык телендә – *айланма, бурулув, бюрюлюв*.

***Борын***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *борын* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм аның *төп мәгънәсе* болай аңлатылган: Кеше һәм хайваннар йөзендә сулыш алу һәм ис сизү органы. *Кылыч[ланып] торган озын һәм матур борын да егетнең йөзенә... горурлык биреп тора*. Ә. Фәйзи. *Сарыклар, басып торганнары да, ятканнары да, борыннарын җиргә төрткәннәр һәм еш-еш сулыйлар*. Г. Әпсәләмов.

*Икенче мәгънәсе* сүзлектә «томшык (кошларда)» дип бирелгән һәм мисал китерелгән. *Борыны, каз бәпкәсе борыны төсле, сап-сары булып очлаеп тора*. А. Шамов.

Аталган сүзлектә аның *өченче мәгънәсе* болай бирелгән: «Судно, пароход, көймә, самолёт һ. б.ның алгы өлеше. *Ул арада ... Казан ягыннан үткен борыны белән дулкыннарны кистереп, гаскәр төялгән икенче бер пароход килеп чыкты*. Г. Бәширов. *Маякчы хатын көймәнең борынын зур осталык белән агымга кыйгач тотып ишә башлады*. Г. Гобәй.//Нинди дә булса предметның алгы, гадәттә тар, очлаеп торган кырые. *Борыны китек балта. Ул соскыч борынына бераз ясмык оны элгән иде*. И. Гази. (ТТАС, I: 180).

М. Кашгари сүзлегендә *tay burnі* «тауның алга чыгып торган өлеше, борыны» (МК: 398). В. Радлов сүзлегендә госманлы

төрекләрендә *бурун* «коры җирнең су чыганакларына очлаеп кергән урыны, тау итәге, тау яны, тау асты» (Радлов, т. IV, ч. 2: 1822).

*Борын* терминының топонимнарда кулланыла торган коры җирнең су чыганакларына очлаеп кергән урыны булуы һәм шулай ук башка географик берәмлекләрдә дә очравы күрсәтелмәгән.

Татар су чыганакларында очлаеп кергән коры полосалар байтак. Аларда үлән яхшы үсә. Хайван һәм кош-кортлар шунда туеналар.

Географик атамаларда *борын* лексик берәмлеге белән *томшык* термины куллану да очрый.

*Кала борыны* – Яшел Үзән районы Мулла иле янындагы урын атамасы. *Мөхәммәт борыны* – Шәмәк елгасында, *Кәли борыны* – Кече Чирмешән елгасы бассейнында. Минзәлә районының Бикбау авылында *Атау борыны* Сай күл атавының Ыкка кереп торган, кеше борынына ошаган урыны. *Бәдәй борыны* – Ык ярының борынга охшаш, елгага кереп торган бер урыны. *Мүкле борын* – Озын уйның бер урыны. *Мүкле борын куагы* һ. б. Актаныш районында *Тугай борыны* – Сөн елгасындагы бер урын. *Урман борыны* – Арча районындагы Казиле авылы янындагы җир атамасы. *Усаклы борын* – Мамадыш районының Баскан авылы янындагы җир атамасы. *Кызыл борын асты чишмәсе* – Минзәлә районы Югары Тәкермән авылы янындагы Инеш бассейнындагы чишмә. *Шомыртлык борыны* – Кама Тамагы районы Атабай авылы янындагы урын атамасы. *Борыннар* – Әлки районы Яңа Камка авылы янындагы урман атамасы. *Борынчык тавы* – Актаныш районы Иске Байсар авылы янындагы тау атамасы.

*Борын* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында да файдаланыла.

Фоат Садриевның «Таң җиле» романында мондый матур юллар бар: *«Аръякта печән эшләренең уттай кызган вакытында хатын-кызлар әнә теге комлы борынга, ә ир-атлар нәкъ шушы турыга су коенырга төшәрләр иде».*

Вахит Имамовның «Утлы дала» исемендәге тарихи романында мондый юллар укыйбыз: *«Дөрес булса, тайҗутлар магул белән татар катнаш найман кабиләсе яшәгән Караборын тауларына, Кукы-Ката үзәнлегенә таба киткәннәр, ди».*

Шул ук авторның шундый ук исем алган тарихи романында *борын* күчерелмә мәгънәдә кулланыла: *«Биек баркас борынына сузылып яткан килеш, артта чылбыр булып сузылган касклар өстенә караш ташлый-ташлый, Андрей кенәз шулар хакында уйлап кайта иде».*

*Борын* термины төркиләр көн иткән җирлекләрнең күбесендә шактый еш очрый. Төрки телләрдә, мәсәлән, нугай, төрек, тата, кумык, үзбәк – *бурун*, башкорт *морон* «коры җирнең су чыганакларына очлаеп кергән урыны»н аңлата.

Кырым топонимиясендә *бурун* ~ *борын* термины белән түбәндәге атамалар әйләнештә йөри: *Карамрун, Чагурка-Бурун, Кара-Бурун, Никита-Бурун, Кильее Бурун, Утеки-Бурун, Деликли-Бурун, Тешикли-Бурун, Ак-Бурун, Джамбек-Бурун, Чилма-Терек-Бурун, Шулдан-Бурун, Лиман-Бурун, Кузгун-Бурун, Одаджи-Кларын-Бурун, Мердвенлер-Бурун, Ангар-Бурун, Монастыр-Бурун, Камыш-Бурун Исарлы-Бурун, Куртыры-Бурун, Чобан-Басты-Бурун, Кильбурун, Кольбурун, Япуль-Бурун, Монастырь-Бурун, Кутилия-Бурун, Хун* һ. б.

Көнбатыш Себер топонимиясендә борынны белдерү өчен *сиңер* сүзе кулланыла. Ул су чыганаклары ясауда да продуктив: *Карасиңәр* (Муминов, 1970: 13) һ. б. Урта Азия һәм Казахстанда *сингир* – «текә ярлы кыялы тау, борын». Ул иран телендәге *сен/санг* «таш» һәм төрки *кыр* «калкулык, калку җир» сүзләре кушылмасыннан ясалган дигән фикер бар (Конкашпаев, 1970: 179). Бу термин ярдәмендә ясалган байтак тау атамалары очрый: *Аксенгир, Карасингир, Кубасенгир* (Конкашпаев, 1951: 32–33). Монголиядәге *Сенхур* атамалары – *сенгир*нең фонетик яктан үзгәргән варианты. Борынгы төрки телдә *senir I* – «тау борыны»н (ДТС, 1969: 495) белдергән. Төрки телләр топонимиясендә киң кулланылган «сенгир» термины татар гидронимиясе

һәм оронимиясендә дә чагылыш таба: *Сеңер кизләве, Сеңер калкулыгы* һ. б.

***Бот***. Татар гидронимиясендә *бот* күчерелмә мәгънәдә – «елга кушылдыгы»н аңлата. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бот сүзенең күчерелмә мәгънәсе, ягъни «елга кушылдыгы», «тау тармагы»н белдерүе теркәлмәгән.

*Бот* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда актив кулланыла.

*Ибрай ышна боты – Аргы бот* – Балык Бистәсе районы Брыс елгасы кушылдыгы. Балык Бистәсе районыннан агып үтә торган Бәтке елгасы кушылдыгы – *Бәләкәй бот*, Әлки районыннан ага торган Кара елга кушылдыгы – *Кара елга боты;* Актаныш районы җирләреннән агып үтә торган Сөн елгасы кушылдыгы *Озын бот* исеме белән аталган. Тыва гидронимиясендә дә *Озын бот* елгасы бар. *Таҗи җире боты* – Саба районы Олы Шыңар авылы янындагы урын атамасы. *Ибрай ышна боты* – Лаеш районы Татар Янтыгы янындагы җир атамасы. *Ибрай* < *Ибраһим* исеме, *ышна* – «урман эчендә чәчүлек өчен төпләнгән, әрчелгән җир (ТТАС, III: 554). Бу атама күчерелмә мәгънәдә «елга кушылдыгы»н аңлата торган *бот* терминыннан ясалган. *Дүрмән боты* – Яшел Үзән районы Каратмән авылы янындагы урын атамасы. *Мәхмүт боты* – Яшел үзән районының Каратмән авылы янында Петьялка елгасына ялгана. *Атнач боты* – Яшел үзән районы Күгәй авылы янындагы җир атамасы. *Дүрмән боты* – Яшел Үзән районы Каратмән авылы янындагы урын атамасы.

*Бот* берәмлеге белән ясалган төрле типтагы географик берәмлек атамалары төрки халыклар яши торган регионнарда, мөстәкыйль дәүләтләрдә еш очрый.

О.Т. Молчанова мәгълүматларына караганда «...*бот* сүзе белән аталган географик берәмлекләрнең сыйфатлары... Алтайда *бот* сүзе, барлык төрки телләрдә булган төп, ягъни гәүдәнең бер әгъзасыннан тыш әле күчерелмә мәгънәдә дә кулланыла» (Молчанова, 1970: 33). Таулы Алтай һәм Тыва топонимиясендә

*бут* – «тау тармагы», «тау башы», «тау нигезе»н белдерә. Бу термин оронимик атамалар составында да еш кулланыла: *Көк бут, Сары бут, Кайынгду бут, Кара-Бут-Даг, Янтаг Бут, Бут* (Молчанова, 1970: 35). Бу терминның киң җирлекләргә таралу ареалы Э.М. Мурзаев хезмәтендә тәфсилләп күрсәтелгән (Мурзаев, 1984: 104).

***Ботак***. Татар халкы телендә *ботак* «елга кушылдыгы» мәгънәсендә дә кулланыла. Аның бу мәгънәсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә теркәлмәгән. *Ботак* үзенчәлекле гидронимик терминнарның берсе. Ул су чыганаклары атамаларының состав өлеше һәм үзе генә дә исем-атама буларак кулланыла. *Ботак* – Кырлай елгасы кушылдыгы (Арча районы), *Таллы ботак* – Казан суы кушылдыгы (Биектау районы), *Эчкәре ботак* – Шәмәк суы кушылдыгы (Биектау районы), *Олы ботак* – Кече Сөлчә елгасы кушылдыгы (Аксубай районы), *Кайынлы ботак* – Кече Чирмешән елгасы кушылдыгы (Әлки районы), *Ялгыз ботак* – Майна елгасы кушылдыгы (Спас районы), *Озын ботак* – Зөя елгасы кушылдыгы (Яшел Үзән районы) һ. б.

Төрки халыклар көн итә торган киң җирлекләрдә бу термин «елга култыгы», «елга тармагы», «ермак» мәгънәсендә исем-атамалар ясауда күп кулланыла. Көньяк Урал гидронимиясендә бу апеллятив күрсәтелгән мәгънәдә шактый күп очрый. *Чиләбе* өлкәсендә *Ачы Ботак, Кара Ботак, Ботак, Су Ботак* атамалары теркәлгән. Казак гидронимиясендә *Каработак, Жастыботак, Ботак* атамалары очрый. *Каработак* исемле елга *Актүбә* өлкәсеннән, *Тереботак* – Караганда өлкәсе җирләреннән ага.

***Буа***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу терминның ике мәгънәсе күрсәтелгән. 1) Суның юлын бүлеп, буып тоту өчен ясалган корылма. *Буа белән бөялгән инеш суларын электростанция өчен эшкә җигәрбез*. Н. Нәҗми. *Су җыю өчен кешеләр уңай гына урынга текә буалар торгызалар.* Г. Галиев. 2) Шушы корылма алдында буылып җыелып торган су, сулык. *Буада су коену*.

*Буа* термины географик атамалар составында актив кулланыла. *Карамасар буасы* – Апас районы Дүртөйле авылы янындагы Инеш бассейнында. *Буа күле* – Алексеев районы Юеш Көрнәле авылы янындагы Көрнәле суы бассейнында. *Буа башы чокыры* – Апас районы Азбаба авылы яныннан ага торган Имәнле суы бассейнында. *Буа буе сазлыгы* – Яшел Үзән районы Бәчек авылында. *Буа юлы күл*е – Апас районы Кече Болгаер авылы янындагы Олы Шаһиян елгасы бассейнында. *Буа суы* – Яшел Үзән районының Югары Урысбага авылы янында, Зөя елгасы бассейнында; Апас районы Ясаклы Барыш, Балык Бистәсе районы Казак Чаллысы авыллары янындагы елгалар. *Шакир буасы* – Кайбыч районы Шуширмә авылы янындагы буа. *Буа чишмәсе* – Казан суы бассейны (Биектау районы), *Буа суы* – Шушма елгасы бассейны (Лениногорск районы), *Буа* – Шушма елгасы бассейны (Балтач районы), *Буа кизләве* – Зөя суы бассейны (Буа районы). Юныс Йосыповның «Адай авылы тарихы» (Актаныш районы) китабында *Гали буасы* беркетелгән. Автор аны ташландык буа урыны дип биргән. Хуҗа гүр иясе булгач, тегермән дә сафтан чыккан. Бары атама гына безнең көннәргә килеп җиткән. Калморза авылында (Минзәлә районы) *Сайпар буасы* теркәлгән. Тегермәннәр эшләгән заманда ул Иске Ыкның Ык белән тоташкан урынына төзелгән була. Хәзер аның урыны һәм атамасы гына калган. *Күркә буасы* – Буа районы Кыр Норлаты авылы янында. *Буа* – түбәндәге микротопонимнар составында кулланыла: *Буа куаклыгы, Буа кирәмәте, Буа болыны, Буа ышнасы, Буа каенлыгы, Буа урамы* һ. б.

Татарстанда *буа* апеллятивы белән түбәндәге авыл атамалары бар: Иске Буа – Кайбыч, Биябаш – Апас районындагы авыллар. Буа шәһәренең (Буа районы) атамасы, Н.И. Золотницкий фикеренә күрә, *буа* терминыннан ясалган. Шәһәр исеме район атамасына күчкән. Баулы шәһәрен җирле халык *Акбуа* дип йөртә. *Буа* сүзе диалекталь фонетик вариантлар белән татар теленең барлык сөйләшләрендә очрый. Кайбер сөйләшләрдә, *буа* төшенчәсен белдерү өчен, рус теленнән алынган *пруд* сүзенең

диалекталь фонетик вариантлары йөри. Алар рәтенә *борот, пырыт, пырут, прыт, порт, пурт, пырт* һ. б. сүзләр керә. Түбән өлкәсендә *буа*ны *туан* дип атыйлар.

Төрле фонетик вариантларда *буа* сүзе барлык төрки телләрдә дә очрый. Мәсәлән; нугай – *бувам,* башкорт – *быуа,* кумык – *бувъан,* казак, каракалпак телендә – *бөгет* һ. б.

Г. Ибраһимов *тегермән буасы* гыйбарәсен болай куллана: *Җәй көне кибә төшкән Үзән елга көзнең бу яңгырлары белән ярларга күтәрелде; шул төнне Бикъяр белән Караюрга арасындагы тегермәннең буасын ерып алып китте».*

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *буа* термины кулланыла: *«Гайнан уенча, Камил Чаллы буасының койрыгы бу тирәгә кадәр менеп җитмәячәген белеп кайтырга да Ризванның авызын бер сүз белән томаларга тиеш иде».* Әмма ләкин экология мәсьәләсе җанны борчыган, йөрәкне кузгаткан фал инде ул. Буалар хәзер дә бик кирәк. Шул ук авторның «Җидегән чишмә» романында буаның кирәклеге менә ничек дәлилләнелә: *«Минһаҗның да бирешәсе килми иде: – Айһай, хаталанмыйсыңмы?! Игенчелектә буаның беркайчан да заманы узмый, персидәтел иптәш! Безнең бабайлар буаны тегермән тарттыру өчен генә бумаганнар. Күреп торасың бит: былтыр буа ерылганнан соң, Әверлән инеше, төбен ашап, аска төште, ярлары җимерелде, болыннар корыды, такырга әйләнде». «...Әверләндә буа буыйк без, буа!»*

Буа терминына карата Р. Әхмәтьяновның фикере мондый: *Буа* «пруд» – татар телендә халык этимологиясе буенча диалекталь *бүә* (гәйнә, минзәлә – *бүwә,* казан арты *бүгә*) «буа» сүзеннән ясалган. Шул ук диалектта *бөйә* id., *бүү* – «буа буу» > чув. *пêве, пүве, пүйе,* мари телендә *пүä, пүйэ, пүйа* id. (ТТДС, I: 107, 109, 111). Гомуми закончалык буенча *бүә, бүwә* варианты мишәр диалектыннан булырга тиеш һәм һәр ике вариантның уртак чыганагы *бүгә* < борынгы чыгтай телендә **бөрäк,* кара чыгтай телендә *бөгäн, бөгäт, бүгäт* «буа», *бөгä, бөги* «буа буу», *бөг* «буылган, бүлтәйгән урын» һ. б. Халык аңында *буа* елганың «буылган»

урыны булган; ләкин гомум-төрки планда ул күзәтелми, *буа* бөтенләй башкача атала (Әхмәтьянов, ТТЭС, 2005: 143).

Буа торак пункты да, бәлки, шушы *буа* терминына бәйләнешледер. Моны, ягъни бу атаманың этимологиясен яхшылап тикшерергә кирәк.

Татарстаннан читтә яшәгән татарлар телендә *буа* апеллятивы белән түбәндәге атамалар очрый. Ульяновск өлкәсендә: *Буалы* елга (Иске Кулаткы районы Яңа Яндовка авылы), *Югары оч пруды, Мансыр* яки *Каргалы пруды, Ишан пруды, Сайкин пруды, Ишкенә куак бумасы, Актау төбәгендәге бума* (Иске Кулаткы районы Иске Терешка авылы) һ. б. Микротопонимнар: *Буалы елга урманы* (Иске Кулаткы районы Иске Яндовка авылы), *Буа болыны* (Самара өлкәсе Камышлы районы Масеевка авылы) һ. б.

***Бугаз***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *бугаз* «ике диңгезне, күлне һ. б. шундый сулыкны тоташтыра торган тар су мәйданы» дип бирелгән һәм мисаллар китерелгән: *Керчь бугазы, Беринг бугазы. Босфорның агымы табигатьнең бер кызык парадоксыннан санала: бугаз суының өсте Кара диңгездән Мәрмәр диңгезенә ага, асты – Мәрмәр диңгезеннән Кара диңгезгә.* Совет әдәбияты (ТТАС, I: 186).

Татар топонимиясендә бугаз термины географик атамаларның состав өлеше буларак кулланыла: *Кара күл бугазы, Имәнле күл Бугазы, Йазлау күле бугазы, Бәтке күле бугазы, Бугаз ышнасы* һ. б.

Борынгы төрки телдә *Buqас* (II), *Buqас art* «тау сырты атамасы» дип теркәлгән (ДТС, 1969: 125). Радлов сүзлегендә *богаз*ның «тарлавык, елга тамагы», «култык» мәгънәләре бирелгән (Радлов. т. IV, Ч. 2: 1650).

Татар топонимиясендә *бугаз* апеллятивы географик атамаларның состав өлеше буларак кулланыла: *Кара күл бугазы, Имәнле күл бугазы, Йазлау күле бугазы, Бәтке күле бугазы, Бугаз тавы, Бугаз ышнасы* һ. б.

Төрки телләрдә *богаз* «бугаз»ны белдерә. Топонимиядә бу лексик берәмлек «үтү урыны, култык аша кичү урыны, тау

сырты» мәгънәләрендә кулланыла. Азәрбайҗанда ул «канал» мәгънәсен аңлата: Кыргызстанның көньягында *Богаз* – «таулар арасыннан үтә торган юл». Төрекмән телендә ул – «елга тамагы», «канал», «тарлавык»; караим телендә *кыр богаз (къыр багъаз)* – «таулар арасыннан үтә торган юл», гагаузлар телендә – «канал», тамак (Севортян, 1976: 2). Дунай болгарлары телендә төрек теленнән алынма итеп исәпләнгән *боаз* лексик берәмлеге «тау тарлавыгы», ә диалектларында «түбәнлек», «үзән», «тау елгасының башланган урыны» мәгънәсендә кулланыла (Григорян, 1975). Грек телендә *богази* «култык» мәгънәсен алып кулланыла. *Бугаз* термины «канал», «култык» мәгънәләрендә фарсы һәм гарәп телләренә дә алынма булып кабул ителгән. Караим телендә *къыр богъаз* «таулар арасыннан үтә торган юл», дип йөртелә икән (Эбасанов).

Нугай, үзбәк, азәрбайҗан телләрендә *бугаз* төрле фонетик вариантлар белән «канал, бугаз» мәгънәсендә кулланыла (чагыштыр: *Ангар-Богаз, Кебит-Богаз* – Кырымдагы бугазлар һәм култыклар, *Бугаз* лиманы һәм *Бугаз* торак пункты Тамань ярымутравында. *Кара-Богаз-Гол* – Каспий диңгезендәге култык) (Мурзаевы, 1959: 43). *Богаз* – Казакстандагы елга (Конкашпаев, 1963: 35). Босфор култыгының төрекчә атамасы *Бугаз* булуын да әйтергә кирәк. Фарсы чыганакларында, аерым алганда Низаметдин Шаминың «Җиңү китабы»нда, *Бугаз-Кум* атамасы бар. *«...Моннан соң Тимер Чудур – казак өлкәсенә яу белән бара һәм аны таларга әмер бирә. Шуннан соң ул гаскәре белән Бугаз-Кум урынчалыгына кыш үткәрергә китә»* (Тизенгаузен, 1941:123).

Кырым топонимиясендә бугаз компоненты белән ясалган атамалар күп: *Ставрея-Богаз, Гаспра-Богаз, Крача-Богаз, Гурбетдере-Богаз, Пелаки-Богаз, Эски-Богаз, Ангарски-Богаз, Акчокрак-Богаз, Конёк-Богаз, Сардемим-Богаз, Кокасан-Богаз, Дар-Богаз, Мискор-Богаз, Миэссис-Богаз. Алакат-Богаз, Кебит-Богаз, Смопу-Богаз Савлуксу-Богаз, Иограф-Богаз, Ташкабак-Богаз, Хавалык-Богаз, Кучук-Узенбаш-Богаз, Биюк-Узенбаш-*

*Богаз, Сюдюрмюш-Богаз, Гаврель-Богаз, Япраклыгёль-Богаз, Малая-Богаз, Ставрея-Богаз, Кокия-Богаз, Испшея-Богаз.*

Төрки телләрдә *богаз* – «тамак, бугаз, йоткылык». Географик атамаларда: «тау араларыннан үтә торган юл; тау сырты аша үтә торган юл; ике диңгезне тоташтырган, шулай ук утрау белән материк арасындагы тар урын; уйсулык; уйсу җир; елга тамагы; тар аралык; тарлавык; ике тау арасындагы тирән чокыр». Мисаллар: *Бугаз лиманы* (*лиман* – елгаларның диңгезгә койган урыннарында барлыкка килгән култык). *Бугаз борыны* (*борын* – елгада, диңгездә очлаеп кергән җир), *Бугаз* торак пункты (Тамань ярымутравында). Каспий диңгезенең көнчыгыш ярында *Кара-Богаз-Гол* култыгы. *Ангар* – Богаз исеме алган тау сырты аша үтү урыны (Кырымда), Украинаның Одесса өлкәсендә *Каролина Бугазы* исеме алган торак пункт бар. *Богаз* – Босфор култыгының төрек телендәге атамасы.

***Буерак*** – «чокыр; тирән канау, тирән озын чокыр; чокыр-чакыр, казылма, сикәлтә; уйсулык, уйсу җир». М.Ф. Розен һәм А.М. Малолетко хезмәтендә төрки телләрдә *чокыр* мәгънәсен аңлата торган *буерак (баерак, байрак)* төрки *байрак* дип бирелә. Бу лексик берәмлек бер урында озак көн иткән руслар тарафыннан да кулланыла.

*Буерак* термины белән Татарстанда шактый географик берәмлек атамалары ясалган: *Буерак* – 1. Ширәмәт елгасы кушылдыгы, Түбән Кама районы Ширәмәт авылы янында; 2. Шушма/Чишмә елгасы бассейнына утырган Яңа Чишмә районы Яңа Чишмә (Новочишминск) авылы янында. *Буерак* – Кама кушылдыгы, Чистай янында. *Сай буерак* – Югары Ослан авылы янында һ. б.

*Буерак* термины Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә очрый. Жигули таулары эргәсендә меридиональ юнәлештә ярылган кыска урыннар гаҗәп матур, тар һәм тирән тарлавыклар барлыкка китергәннәр. *Буерачни*к – «чокырлар белән яргаланган җир», *буерачина* – «кечкенә чокыр», «чокыр-чакыр, казылма, сикәлтә». Башка җирле үзенчәлекләре: «чокырлы, батынкы

урын», «тигезсез, таулы, чокырлы урын», «таулардагы үзәнлекләр, биектәге өзек-өзек җир», «урмандагы үтә алмаслык җир», «түбәндәге сазлыклы урыннар». Дериватлары: *буйрах, баераг, буерачек, буераковина, буерка*.

*Буерак* термины төрле урыннарда очрый: Идел буендагы Вольск шәһәре янындарак чокыр *Киң Буерак* (Широкий буерак)дип атала. Волгоград өлкәсендә *Буерак-Поповски* һәм *Буерачный* совхозлары, *Ташлы Буерак* (Каменный Буерак) исемендә бистә (поселок), тар, сай, чокыр атамалары бар.

***Буй***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *буй* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм аның тугыз мәгънәсе ачыкланган. Безнең тема өчен кирәклесе – бишенче мәгънә: Берәр нәрсәнең янәшә-тирәсе, аңа чиктәш тирәлек; шул яклар. *Стена буе. Чишмә буе. Тау буйлары. Урман буйлары тигез кар белән капланган иде.* М. Гали. *[Авыру хатынның] яңак буйлары һәм күз төпләрендә шактый тирән җыерчыклар сызылган.* Ш. Камал.

*Буй, буе* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда шактый актив кулланыла: *Арбор буе болыны* – Балтач районы Смәел авылы янындагы болын атамасы. *Бөркет буе* – Лениногорск районы Сугышлы авылы янындагы урын атамасы. *Буа буе сазлыгы* – Яшел Үзән районы Бәчек авылы янындагы сазлык. *Су буе урамы* – Азнакай районы Әгер авылында урам атамасы. *Су буе* – Олыяз елгасы, Саба районы Пүкәл авылы халкы телендә шушы исем белән әйләнештә йөри. *Су буе тавы* – Балтач районы Шода авылы янындагы тау атамасы. *Бу як чишмә буе* – Балтач районы Куныр авылында. *Валлар буе* – Буа районы Адав-Толымбай авылы янындагы бер урын атамасы. *Түбән буй* – Апас районы Күзкәй авылы янындагы басу атамасы. *Әге буе* – Балтач районы Түбән Кенә авылындагы урам атамасы. *Гриткә буе* – Биектау районы Упсабаш авылы янындагы урын атамасы. *Тоба буе* – Чүпрәле районы Иске Чокалы авылындагы басу атамасы. *Умарталар буе чыгышы* – Кама Тамагы районы Келәнче авылы янындагы чишмә. *Чулача буе* – Питрәч районы Шәле авылы

янындагы урын атамасы. *Борис тирмәне буе* – Биектау районының Упсабаш авылы янында. *Аксу буе елгасы* – Чүпрәле районы Түбән Чәке авылы янында Олы Яклы елгасына кушыла. *Алты аркан буе* – Әлки районы Иске Чаллы авылы янындагы җир атамасы. *Алты сука буе* – Балтач районы Нөнәгәр авылы янындагы җир атамасы.

*Буй* лексик берәмлеге әдипләребез һәм шагыйрьләребез иҗатында еш кулланыла.

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *буй* лексик берәмлеге шактый актив кулланыла: *«Ык буеннан әйләнеп кайтканнан бирле, Камил шушы яңа әсәре белән рухланып яши иде»*.

Мөхәммәт ага Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә (истәлекләр)» исеме алган китабында *яр буе* гыйбарәсе болай кулланыла: *«Хәмит мине Ялтаның яр буе урамыннан акрын йөрергә өйрәтә. Ә мин гел торып йөгерәм икән, үзем сизмим»*.

Вахит Имамовның «Утлы дала» романында *буй ~ буе* лексик берәмлеге кулланылган: *«Җаекны бер атна буе кичкәннәр... Сакмар буе. Уйлык күл өстенә акрын гына таң яктысы җәелә, ә Биләрдән ун көн чамасы элек үк килеп урнашкан йөзлек җайдаклары һаман йоклый әле»*.

*Буй* лексик берәмлеге төркиләр географик атамаларында да очрый.

***Гөрләвек.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә гөрләвек «исем» дип бирелә һәм 1. Көчле яңгырдан яки язын кар эрүдән барлыкка килеп, җир өстеннән аккан су. *Тау битләреннән беренче гөрләвекләр шаулап чокырларга төшәләр*. Ә. Еники. 2. Гөрләү, гөр килү тавышы. *Тәрәзәдән кайчак тонык кына кала гөрләвеге ишетелә*. М. Җәлил. // Сыйфат мәгънәсе. Шаулап, гөрләп торган. *Гөрләвек дулкыннар арасында зирәк кош кебек оча-калка килгән көймә... шып итеп туктады*. Ш. Камал (ТТАС, I: 287).

Бу термин су чыганаклары атамалары ясалышында очрый. *Гөрләвек чишмә* – Актай суы кушылды (Спас районы), *Гөрләвек чыгыш* – Биектау районында, Ашыт елгасы бассейнында.

*Гөрләвек* – әдипләр иҗатында очрый. Гомәр ага Бәшировның «Халыкка тимә, тисәң, игелек күрермен димә» повестенда *гөрләвек* термины бала чакларны искә төшерә торган иттереп кулланыла. *«Ул да түгел, чана эзләреннән челтерәп аккан яшькелт-сары карлы-бозлы гөрләвекләргә күз төште. Тиз генә кереп уенчык тегермәнне алып чыктым. Гөрләвеккә көйләп куюым булды, әй китте әйләнеп, чарыкларына күз дә иярми. Сабагы да онытылды, мәзин үзе дә».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» повестенда мондый җөмлә тезмәсе укыйбыз: *«Тышта бөтен район үзәген томалап, бурый-бурый дуамал җәйге яңгыр ява, яшен сызылып киткәндә бөтен поселокта электр линияләре ыңгырашып ала, урамнан, тополь мамыкларына бөялә-бөялә, күбекле ак гөрләвекләр ага иде».*

Татар халык шагыйре Равил Фәйзуллин гөрләвекне һәм кыр-басуларны болай тасвирлый:

*Гөрләвекләрдә тибрәнә*
*күкнең зәңгәрлекләре.*
*Тургай җырына коена*
*Кыр-басу киңлекләре.*

Саҗидә Сөләйм填нованың «Бер сәяхәт хакында хикәят» дип аталган китабына урнаштырылган «Сау булыгыз» исеме алган хикәясендә мондый юллар бар: *«Челтер-челтер гөрелдәшеп, урамда гөрләвекләр агып калды».*

Роза Хәбибуллинаның «Мулла килене» дигән романында *гөрләвек* лексик берәмлеге күчерелмә мәгънәдә кулланылган: *«Йоклар алдыннан [Маһинур] тыгыз итеп үрелгән калын толымнарын сүтә. Озын куе чәчләре елкылдап, гөрләвек булып, иңнәреннән агып төшә...»*

***Дала.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *дала* лексик берәмлегенең *беренче мәгънәсе* болай аңлатылган: «Күбесенчә үлән белән генә капланган, зур мәйданнан тора торган тигез җир (гадәттә корырак якларда)». *Очсыз-кырыйсыз дала, анда*

*бер генә агач, бер генә куаклык та юк. Ул кылган үләне белән генә капланган.* А. Әхмәт.// Гомумән, киң кыр, еракка сузылган тигез җир. *Калкынып Зәй даласыннан, кыймый гына елмайды ай.* Ә. Юныс.

*Икенче, сыйфат мәгънәсе*: «Дала рәвешендәге, далалы». *[Асылгәрәй] күзен ачып җибәрсә, инде үрне узганнар да. Алда тагын, шул ук шыксыз дала җирләр. Далалы якларга күчү. Украинаның далалы районнары.*

*Дала* сүзе белән топонимнар сирәгрәк ясалган. Спас районында *Дала күле* Идел бассейнында урнашкан. Шундый ук исемдәге күл Нурлат районының Би күле авылы янында бар.

Бу термин төрки, монгол телләрендә һәм санкритта «дала», «тигезлек» мәгънәсендә кулланыла. *Тала* – Кондома һәм Бия елгалары кушылдыклары. Бия елгасы кушылдыгы хәзер Таловка дип атала. П.К. Козлов хезмәтендә Хуанхэ елгасының югары агымына урнашкан *Одонь-Тала* (Йолдызлы дала) исеме алган, күлләре һәм сулыклары күп булган тигезлек турында әйтелә.

***Дәрья*** сүзенең «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә ике мәгънәсе бирелгән. 1. Елга, зур су. *Кичәбез киң дәрьяларны, урман, тауларны.* Ф. Кәрим.

2. *Күчмә мәгънәсе.* Берәр нәрсәнең зур микъдары, күплеге турында. *Шушы зур һәм матур бинага көн саен халык дәрьясы агыла.* М. Максуд (ТТАС, I: 320).

*Дәрья* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда кулланыла, ләкин артык күп түгел: *Дәрья борыны* – Әгерҗе районы Кичке Таң авылы янында, Иж суы бассейнында. *Дәрья күле* – Кичке Таң авылы янында (Әгерҗе районы), Иж суы бассейнында. *Дәрья күле* – Тәтеш районында, Куйбышев сусаклагычы бассейнында. *Агыйдел дәрьясы* – Агыйделнең Камага кушылган урыны.

Бу термин «Идегәй» дастанында теркәлгән:

*Анда әйтте Идегәй:*
*– Энҗү Дәрьяң – киң дәрья,*
*Бәнҗү дәрьяң – сай дәрья*
*Җаектан үтми тар түбә,*

*Тат торуным яу түбә;*
*Идел белән Җаекта,*
*Бөктәргеле Адырдан,*
*Саралтын суккан Сарайдан,*
*Әзгәри суккан Болгардан,*
*Нугайның нурлы йортыннан*
*Чыгып килә ятыр мын.*
(Идегәй, 1988: 113).

***Диңгез.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «исем» дип ныгытылган һәм аңлатмасы бирелгән. Океанның коры җир белән теге яки бу дәрәҗәдә чолгап алынган бер өлеше – тозлы әчкелтем сулы зур мәйдан. *Кара диңгез. Урта диңгез. Балтыйк диңгезе.* // Зур ясалма сулык; зур су мәйданы. *Казан порты яннарында Чайкала диңгез.* М. Хөсәен. *Әнә тагын яңа диңгез туды, Әнә тагын – Яңа бер шәһәр*. Х. Туфан (ТТАС, I: 309).

*Диңгез* сүзе белән ясалган атамалар байтак. *Диңгез аланы* – Мамадыш районының Югары Сон авылы янында, шушы ук авылда Диңгез аланы елгасы да бар. *Диңгез башы* дип аталган урын Бөгелмә районының Сугышлы авылында һәм Лениногорск районының Тимәш авылы янында бар. Борынгы заманда бу урында диңгез яры булган дигән фикер яши. *Диңгез күзе / Төпсез күл* дигән су Апас районының Аюкөйдергән авылындагы Аюкөйдергән суы бассейнында; *Диңгез күзе/ Сыгылмалы күл* – Апас районының Әлмәндәр авылы янында бар. Өлкәннәр сөйләвенә караганда, бу күл суыннан зур пароход борыны (алгы өлеше) табылган икән. *Диңгез күзе кизләве / Түмән кизләве* – Апас районындагы Кызыл Тау авылы яныннан ага торган Бола суы бассейнында. *Диңгез күзе чишмәсе* – Биектау районындагы Зур Солабаш авылы яныннан ага торган Сола суы бассейнында.

*Диңгез күзе* атамалары әдипләр иҗатында да шактый очрый.

Гомәр ага Бәширов «Чәңки-Чәңки, Чәңки җылан» дип аталган повестенда *чокыр* лексик берәмлеген һәм *Диңгез күзе* топонимын болай сыйфатлый: *«Савытыма су тутырып кире менәр-*

*гә борылганда, болын кырыендагы кара-кучкылланып торган кое сыман түгәрәк сулы чокыр янында туктадым. „Диңгез күзе“ инде бу. Аны бөтен авыл шулай дип йөртә. Ул , кечкенә булса да, кыш буе катмый, гел буланып ята. Аның суы чишмәнеке шикелле төссез түгел, коңгырт-кара төскә кереп, үзалдына куркыныч булып күренә. Аның төбе дә юк, диләр. Аңа башта колга төшереп караганнар – төбенә җитмәгән. Шуннан соң, башына таш бәйләп, дилбегә төшергәннәр – ул да җитмәгән... Картлар әйтә, төбе булырга, ул бит җир асларыннан туптуры диңгезгә барып чыга ди».*

Төрки телләрдә *тениз (тенис, тенгиз, денгиз)* «диңгез, зур күл» мәгънәсендә йөри. Көнбатыш Себер һәм Төньяк Казакстан җирлекләрендә бу термин белән шактый зур күлләрне атыйлар. Кайбер очракларда бу термин белән аерым күлләрне дә атыйлар: Омск өлкәсендә *Тенис* күле, Кустанай өлкәсендә *Тенгиз* атамасы алган күл бар. Бу термин топонимнар составында да шактый кулланыла. Омск шәһәреннән 170 чакрым көньяктарак юнәлештә *Селетытениз* (яисә *Селетыденгиз*) күле урнашкан.

***Дисәтинә.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *дисәтинә* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм болай аңлатылган: Россиядә метрик системага кадәр: 2400 квадрат метр сажинга яки 1,09 гектарга тигез җир үлчәү берәмлеге. *Әткәй Гыйрфан байдан бер дисәтинә урак белән ике дисәтинә печән чабарга алган*. Г. Ибраһимов (ТТАС, I: 307).

*Дисәтинә* лексик берәмлеге белән байтак кына географик берәмлек атамалары ясала: *Кәшә дисәтинә* – Кама Тамагы Олы Кариле авылы янындагы җир атамасы. *Качкыннар дисәтинәсе* – Кама Тамагы районы Бишалап авылы янындагы җир атамасы. *Дисәтинә* – Саба районы Яңа Мичән авылы янындагы җир атамасы. *Дисәтинә басуы* – Арча районы Сикертән авылы янындагы басу атамасы. *Дисәтинә җире* – Кукмара районы Өлге авылы янындагы җир атамасы. *Дисәтинә елгасы* – Арча районы Сикертән авылы янындагы елга, Кесмәс елгасына тоташа. *Зәр тисәтинә* – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы янындагы

басу атамасы. *Олы дисә*тинә – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы янындагы басу атамасы. *Зәр дисәтинә* – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы янындагы басу атамасы.

***Дулкын.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә ул «исем» дип бирелгән һәм түбәндәге мәгънәләре китерелгән: 1. Җил тәэсиреннән тирбәнү нәтиҗәсендә су өстендә барлыкка килә торган озынча калкучыкларның берсе. *Җил көчәйгән саен дулкын арта*. Ф. Кәрим. //күч. Гомумән, тигез өслектә барлыкка килгән дулкын сыман нәрсә. *Арыш басуы буйлап яшел дулкыннар чапты.* И. Гази (ТТАС, I: ).

***Елга.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *елга* – башланган урыныннан койган җиренә чаклы үзе салган үзәнлек буенча табигый рәвештә туктаусыз агып торган су. *Безнең авылның буеннан аккан бу елга Өршәккә, Өршәк Димгә, Дим Агыйделгә коя.* Г. Ибраһимов. *Елгаларда язгы су ташый*. Ф. Кәрим (ТТАС, 1977: 329).

*Елга* компоненты турында Р.Г. Әхмәтьянов мондый мәгълүмат бирә: «Елга (йылга), диалекталь *җылга* «река», диалекталь (Будагов 1: 439; ДС, III: 67) «суходол» > чуваш *йӑлка* «шеш үзән», мари (Исанбаев, 1978: 26) *йылга* «елга» < гомумкыпчак: нугай *йылга,* кыргыз *җылга,* казак, каракалпак *җылга* ~ уйгыр *йылга,* уйгыр диалекталь, үзбәк *җилга* ~ язма монгол *Qilga,* бурят *жалга* «елгасы булган сай үзән». Бу сүзнен *-у, -ү* варианты бар: башкорт (Бһһ, II: 73) *йүлгә* «сай үзән» ~ үзбәк *җулга* «үзән», казак *жулга* «елгачык» һ. б. һәм бу вариант сүзне хакас *жул, жүл,* чуваш *çӑл,* алтай диалекталь *йул* < борынгы төрки (ДТС, 1969: 277– 278) *Jul, jӱl* «чишмә, кое; тау елгасы» сүзе белән бәйләргә хокук бирә. Ләкин фонетик җәһәттән кайбер сораулар җавапсыз кала. Морфологик җәһәттән *йылга < йулгай* (*гай < -кай* «урын, төш») булса кирәк, кара: рус теле диалектларында *жалгай, ялгай* «коры яки бик кечкенә сулы үзәнчек» < төрки *йолғай* (кара: Аникин, 2000: 727; Räsänen, 1969: 200; ЭСТЯ, IV: 36– 37; Мурзаев. 1984: 180, 199, 232; Гарипова, 1998: 91– 94)» (Әхмәтьянов, ТТЭС, 2005: 176).

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә «*Йомум* гарәп теленнән алынган лексик берәмлек» дип күрсәтелә һәм диңгезләр; елгалар, күлләр (күплек санында) дип ныгытылган.

Элек *елга* сүзе бары уртача зурлыктагы агым суларны атау өчен кулланылган. Хәзерге татар телендә исә ул сүз зур һәм кечкенә елгаларны атау өчен дә файдаланыла: *Идел елгасы, Чулман елгасы, Зәй елгасы, Шушма елгасы, Агыйдел елгасы, Кирәмәт елгасы* һ. б.

*Елга* апеллятивы үзе генә дә аерым елга атамалары булып кулланыла ала, мәсәлән: *Елга* – Кама кушылдыгы (Балык Бистәсе районы), Олы Сөлчә кушылдыгы (Аксубай районы), Олы Үләмә суы кушылдыгы (Апас районы), Бөре елгасы кушылдыгы (Олы Чура авылы, Кукмара районы), Ык елгасы кушылдыгы (Күҗәкә авылы, Актаныш районы), Эстәрле елгасы кушылдыгы (Уразай авылы, Азнакай районы) һ. б.

Татарстан елга атамаларының күбесендә *елга* апеллятивы атама составында кулланыла: *Кабырга елгасы* – Балтач районы Иске Чепья авылы янындагы Арбор елгасына кушыла. *Караңгы үзән елгасы* – Мамадыш районы Тулбай авылы янындагы Шия суы бассейнында. *Йырынды елгасы* – Яшел Үзән районы Чүриле авылы янында Петьялка суы кушылдыгы.

Татарстанның Актаныш районындагы Иске Кадермәт авылында *Сабыр елгасы* бар. Ул бары яз көне кар сулары ярдәме белән ага. Кар суы җыелып, ташусыз акканга аны Сабыр елгасы дип атаганнар. Бу елгада кешеләр яз көне кер чайкаганнар, хәтта суын да эчкәннәр. *Атау елга* – Кече Чирмешән кушылдыгы (Әлки районы), *Нарат елгасы* – Зөя суы кушылдыгы (Буа районы), *Урта елга* – Карлы суы кушылдыгы (Буа районы), *Артышлы елга* – Олы Чирмешән елгасы кушылдыгы. *Зират елгасы* – Үрәтмә суы кушылдыгы (Түбән Кама районы).

*Елга* термины авыл атамалары һәм микротопонимнар составында еш очрый. *Елга* компоненты Татарстанда егерме сигез авыл атамасында очрый: *Куәтле Елга, Карамалы Елга, Кәкре*

*Елга, Кара Елга, Мөгезле Елга* һ. б. Микротопонимнар: *Елга басуы, Елга ышнасы, Елга күпере, Елга урманы, Елга тавы* һ. б.

Терминның аерым елга атамасы булып кулланылуы Татарстаннан читтә яши торган татарлар телендә дә күзәтелә. Ульяновск өлкәсендә: *Елга* – Кулаткы елгасы кушылдыгы (Усть-Кулаткы авылы, Иске Кулаткы районы), *Чалга* – чокыр исеме (Богдашкино авылы, Чардаклы районы) һ. б. Самара өлкәсендә: Жигули тирәсендәге Торново авылының төньягында басу уртасында *Югары Елгуша* (Верхние Елгуши) исеме алган үзән, кипкән урын бар. В.Ф. Барашков һәм Э.Л. Дубман фикеренчә, атама рус һәм татар теле сүзләре кушылып ясалган. Аның составындагы «елга» сүзе татар теленә нисбәтле. Камышлы районының Яңа Фәйзулла авылында Кондырча елгасын *Елга* дип атыйлар. Термин конкрет зур елганың бер кисәген атау өчен кулланыла. Камышлы районының Татар Байтуганы авылында *Елга* – Сок суы кушылдыгы. Башкортстанда: *Елга* – Дим һәм Мәтәү елгаларының уң кушылдыклары (Бәләбәй районы Әлшәй авылы), Юеш Калмаш елгасы кушылдыгы (Калтасы районы), Буй һәм Ык елгалары кушылдыклары (Туймазы һәм Яңаул районнары). Буйның кушылдыгы *Елга* Башкортстан картасында да күрсәтелгән (М., 1953).

*Елга* компоненты Татарстаннан читтә яшәгән татарлар телендә атамалар составында еш кулланыла. Ульяновск өлкәсендә: *Труша елгасы, Сыерчык елгасы, Киндераш елгасы, Сулак елга, Аркылы елга, Ислай ягы елгасы, Башсыз елгасы* – Тирешкә суы кушылдыгы (Яңа Кулаткы, Яңа Зимница, Иске Яндовка авыллары, Иске Кулаткы районы) һ. б. Самара өлкәсендә: *Тиләгәҗе елгасы, Нәзекәй елгасы, Камышлы елга, Торна елгасы, Соргыт елгасы, Карамалы елга* (Иске Ярмәк, Тат. Байтуганы авыллары, Камышлы районы) һ. б. Башкортстанда: *Абалак елга* – Бәрделәк елгасы кушылдыгы (Баймак районы), *Азак елга* – Тиләгән суының сул кушылдыгы (Зианчура районы), *Ачы елга* – Агыйделнең (Ишембай районы) һәм Нәкәс суының уң кушылдыгы (Күмертау районы) һ. б.

Башкортстан җирлегендә *елга* термины кергән авыл атамалары шулай ук күп: *Булат елга* (Яңаул районы), *Каен елга* (Бәләбәй, Туймазы районы), *Утар елга* (Тәтешле районы), *Сары елга* (Стәрлебаш районы) һ. б.

Шулай ук бу термин микротопонимнар составында да еш очрый: Ульяновск өлкәсендә *Сәнҗүк маңгае елгасы ачыклыклары, Чебеш елгасы күпере, Тирән елга өсте урманы, Иван елгасы кыры* һ. б. Самара өлкәсендә – *Имәнле елга басуы* һ. б.

Татар теле сөйләшләрендә *елга* термины төрле фонетик вариантлар белән еш очрый. Гәйнә сөйләшендә ул *җылга.* Д.Г. Тумашева мәгълүматлары күрсәтүенчә, Тубыл өлкәсенең Тубыл районы Лайтамак авылы халкы урталыктан ага торган елганы *йыгыш* дип йөртә, бараба татарлары елганы *јылга* дип әйтәләр. Татар диалектларында *җылу, җалу* «елга» мәгънәсендә кулланыла. Казан арты сөйләшләрендә һәм әдәби телдә дә көчле яңгыр вакытында һәм язын гына су ага торган ерганаклар *елга* дип атала. Темников, хвалын сөйләшләрендә *елга* дип үзән һәм тарлавыкларны атыйлар (ТТДС, 1969: 178). Кузнечиха урынчалыгында *елгалык* «кечкенә болын»ны аңлата (ДС, II: 80).

*Елга* терминының таралышы бик киң. Ул элеккеге СССРның төркиләр яши торган төбәкләрендә һәм *Көнбатыш Кытай* мәмләкәтләрендә дә очрый: каракалпакларда – *җылга*, уйгырларда – *йылга* (чокыр, коры елга юлы, елга), чувашларда – *йалка* (җылу, елга), *йалкав* (юеш урын), *йалма* (баткак, пычрак), башкортларда – *йылу*, казакларда – *жалу, җылым, җылу*, алтай телендә – *јылым* (чокыр, текә тау бите). Шулай ук: Казакстанда – *җилга* (джилга, жылга), Төрекмәнстанда – *джульга* (чокырдагы елга, елгачык), якут телендә – *элгә* (биек текә ярлы, тирән елга), Монголиядә – *жалга* (чокыр, коры елга юлы), Бурятиядә – *жалга, ялга* (чокыр, уйсу җир, коры үзән, канау, киң озын чокыр). *Жалга, Жалгай, Елгай, Ялгай* – күпсанлы түбән урыннарның атамалары (Бурятия). Эвенкиядә – *дэлгэ* (чокыр, елганың кипкән үзәне, киң һәм озын чокыр, канау), Тывада – *джалга* (ялпылык, уйсулык, уйсу җир; киң иңкү җир; тар сай чокыр), балкар

гидронимиясендә – *җайыу* (сайлык, кичү урыны), карачай-балкар телләрендә «елга» мәгънәсендә *суу, къобан, баргъан су* терминнары кулланыла. Шунысы игътибарга лаек: Чыңгыз-хан нөгәренең (нөкеренең) бер улы *Илга* исемен йөрткән.

Рус язучысы С.Т. Аксаков фикеренчә, элекке Сембер губернасындагы *Муелга* дигән атаманы руслар Иволга дип үзгәрткәннәр. Ока (Ука) суы бассейнында да *Елха* һәм *Жилка* атамалары очрый. Иркутск өлкәсендә Ленаның сул кушылдыгы *Илга* исемен алган. Томск өлкәсендә яши торган татарлар телендә бу термин *йылгъа* (мәсәлән, *Таштимер йылгьа*) рәвешле кулланыла. Кырымдагы Мариуполь греклары телендә *ялага* (чокыр, инеш, озын чокыр, сыза, коры инеш). Галим И.Ф. Фальк мәгълүматларына караганда, Иртыш, Ом, Тара елгаларын элек себер татарлары *Иртеш-Елга, Ом-Елга, Та-Елга* дип атаганнар. Хәзер *елга* термины кечерәк елгалар атамалары составында аерым урыннарда гына сакланып калган. Галим Бараба иңкүлегендә Уба күле (Яглы-елга) кушылдыгы *Кокьяглы,* Бакса елгасы кушылдыгы *Елгайчик* атамаларын теркәгән (1824: 435, 525). *Елга* апеллятивы Көнбатыш Себер елгалары исемендә (Тубыл бассейны һәм Иртышның урта агымнарында) еш кулланыла. *Чул* компоненты хакас телендә «елга, кечкенә елгачык» мәгънәсендә йөри: *Аншуль, Үзәнчул, Шепчул* һ. б. В.В. Радлов «Опыт словаря тюркских наречий» хезмәтендә *чул* сүзенең сагайларда «елга» төшенчәсендә кулланылуын язган (Т. III, ч., 2: 2175). *Чул/йул* – шор топонимиясендә (мәсәлән, *Йул* елгалары – Мундыбаш һәм Кондома кушылдыклары), *чул* – чулым төркиләрендә, *дьул* – алтайлыларда (мәсәлән, *Балыкты-Дьул:* Донидзе, 1973: 191) «елга» мәгънәсендә йөри (Бонюхов, 1972). М. Кашгари хезмәтендә *jul* сүзенең «чишмә», «чыганак» мәгънәсендә кулланылуы теркәлгән (МК, III: 4).

Хантылар яшәгән төбәкләрдә *игол (jыгъл)* компонентын алган гидронимнар шактый күп очрый. XVIII гасырда васюган хантылары телендә *jилга* термины «елга» мәгънәсендә кулланылган. Л.И. Калинина язуына караганда, *jилга* формасы хан-

тылар тарафыннан төрки *jыүъл* терминыннан бераз үзгәреп кабул ителгән. Соңгы форма тобол һәм тура татарларында әле дә кулланыла. А.П. Дульзон *игай* компоненты белән ясалган гидронимнарны да төрки катламга кертә. Мондый атамалар *Васюган* һәм *Юган* елгалары арасында күп очрыйлар: *Васюган, Калманигай, Калисанигай, Санынгай* һ. б.

Г.Ф. Саттаров *чул, йул, йулга, йылга* сүзләренең бер тамырдан булу мөмкинлеген әйтә (Саттаров, 1969: 168). Элек-электән елгалар тайгада юл күрсәткеч хезмәтен үтәгәннәр. Елга буйлап баргач, һичшиксез, берәр авыл, поселок һ. б. торак пунктлар очрый. Берничә йөз еллар элек Казансу һәм Мишә елгалары бассейннарында да куе, калын урманнар үскән.

Экспедиция-сәфәрләр вакытында өлкән яшьтәге аксакаллар сөйләвенчә, борынгы бабаларыбыз бер-берсен, елга буенча агып килгән йомычкадан белеп, йомычка агымына каршы барып таба торган булганнар. Елгалар, Себер тайгаларындагы кебек үк, безнең якларда да урман арасында йөрү өчен төп ориентир хезмәтен үтәгәннәр һәм үтиләр.

***Ерганак.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ерганак* ике мәгънәдә күрсәтелә: 1) Ташкын яки яңгыр суы белән юылып, ашалып ясалган, тирән булмаган сулы яки сусыз озын чокыр. *Бөтен ерганаклардан, кырлар өстен тонык гөрләтеп, шарлавыклар йөгерде*. Ә. Еники. *Ерганакның текә борылышында бер буа ялтырап ята*. Г. Гобәй; 2) Шундый урыннан ага торган язгы ташкын яки көчле яңгыр суы. *Нурын сибә кояш, тама тамчы, Ерганаклар ага, әнкәем*. Ф. Кәрим (ТТАС, 1977: 333).

Рифкат Әхмәтьяновның «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә *ерганак* турында мондый мәгълүмат бирелгән. «Ерганак (йырганак), диалекталь җырганак, башкорт (Бһһ, II: 96) *йырманак* «протока; обрывистая речка» > удм. *җъырганак* id мифологиясе буенча хөкем йөрткәндә «күп ерынтыларның берсе, ихтимал, *йыргы-нак* (*-нак* «күп беришле нәрсәләрнең берсе» мәгънәсен белдерүчән кушымча» ) яки *йыргым-ак:* мәгънәдәш сүзләр татар сөйләшләрендә күп кенә: *йырым, йырын, йы-*

*рымчаķ, йыргын, йыр-гынчаķ* һ. б. йыр-у; кара: нугай телендә йыранак «кул, чокыр». Кара: Ермак. Ер-ук» (Әхмәтьянов. ТТЭС: 177).

Татар топонимиясендә бу термин аерым су чыганакларының һәм атамаларының составында кулланыла: *Erганак* – Кама кушылдыгы (Алексеев районы), *Erганак* – Идел кушылдыгы (Югары Ослан районы), *Хәлил erганагы* – Минзәлә елгасы кушылдыгы (Минзалә районы), *Тау erганагы* – Балтач районының Нормабаш авылы янында. *Erганак* – Баулы районының Акбаш авылында, Димскәй елгасы бассейнында. *Бүре erганагы* – Балтач районы Нормабаш авылы янында. *Кузгалак erганагы* – Балтач районы Курмала авылындагы коры ерганак. *Бай erганагы* – Балтач районы Чаптар авылы янында, Чаптар елгасы бассейнында. *Кәҗә сакаллы erганак* – Балтач районы Пүскән авылы янындагы коры ерганак атамасы. Нурулла Гариф сүзлегендә ерганак болай кулланылган: *Ии Нижние овраг* (*Түбән Ия erганагы*).

*Erганак* термины Татарстаннан читтә яши торган татарлар телендә дә әйләнештә йөри. *Халидә erганагы* – Кулаткы елгасы кушылдыгы (Ульяновск өлкәсе), *Хәмидә erганагы* (Зианчура районы, Башкортстан) һ. б. Кыргыз топонимиясендә *Җырганак* исеме алган тау үткеле һәм тау сырты Ыссык күл өлкәсенең Ыссык күл районында урнашкан (Умурзаков, 1988: 69).

Татар теле сөйләшләрендә бу төр чокырларны, елгачыкларны атау өчен дә терминнар табыла. Мәсәлән, тирән ерганаклар урта диалектның Актаныш урынчылыгында *җай җир* дип йөртелә. Тобол, тара татарларында *erганак* дип кечкенә елга, канаулар атала.

***Ермак.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ермак*ның ике мәгънәсе бирелгән: 1. «Артык киң һәм тирән булмаган озын чокыр; ерганак». *Ат өстендә, казак шикелле алгарак ятып бар, ермаклар аркылы сикергәндә, ялга ныгырак ябыш.* М. Гали; 2) «Елганың, күлнең тар гына булып ярдан эчкә таба кереп торган урыны, култыкчык». *Ак күлнең югары башындагы*

*кереп торган ермагы миңа тагы да гүзәл һәм матур күренде.* М. Җәлил (ТТАС, 1977: 333).

Бу термин аерым бер елгаларның һәм елгачык атамаларының составында кулланыла: *Ермак* – Коры Үләмә суы кушылдыгы (Кама Тамагы районы), Ашыт елгасы кушылдыгы (Биектау районы), Апас районы Мөрәле авылы янындагы Инеш кушылдыгы. Буа районы Чәчкаб авылы янындагы Лащы елгасы бассейнында. *Габит ышнасы ерганагы* – Норма суы бассейны (Балтач районы). *Ермаклы болын* – Алексеев районының Юеш Көрнәле авылы янындагы болын. *Изге ермак* – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы янынан ага торган Коры Үләмә суының уң кушылдыгы. *Мәрәтхуҗа ермагы* – Кама Тамагы районы Олы Салтык авылы. Ылгыма елгасы бассейны. *Иске күпер ермагы* – Коры Үләмә суы кушылдыгы, Апас районы Кече Күккүз авылы янында. *Хөсәен тау башы ермагы* – Кама Тамагы районы Кече Салтык авылы янында. *Хабул ермагы* – Апас районы Кече Болгаер авылы янындагы ермак. *Пире ермагы* – Әгерҗе районы Салагыш авылы янындагы ермак. *Кәшәм ермагы* – Апас районы Зур Күккүз авылы янындагы коры ермак. *Плигин үлгән ермак* – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылында. *Такта ермак* – Биектау районы Кондырлы авылы янындагы географик берәмлек (Коры ермак) атамасы. *Дәү ерма*к – Кама Тамагы районы Уразлы авылы янындагы ермак. *Байди ермаг*ы – Яшел Үзән районы Айдар авылында, Әрәелга бассейнында. *Ермак* термины Нурулла Гариф бастырып чыгарган сүзлектә урын алган: «*Енгилдеевской овраг»* (*Җанкилде ермагы*). Кайбер очракларда русча язылган исемнәр һәм атамалар борынгылыкны саклыйлар. Бу очракта атама *Җангилде* язылышында булып, угыз кабилә-кавемнәре теленә мөнәсәбәтлелекне белдерергә мөмкин. Шунда ук: «*Бекечев овраг* (*Бикәч ермагы*), на р. Волге».

*Ермак* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында да очрый.

Вахит Имамовның «Утлы дала» исеме белән дөнья күргән тарихи романында *ермак нөгәрләре* гыйбарәсе кулланыла:

*Сүбүдәй берьюлы өчәр-дүртәр тарафка ермак нөгәрләре куарга мәҗбүр булды.*

Р. Әхмәтьянов сүзлегендә (ТТЭС, 2005: 177): «Ермак (йырмак), диалекталь *җырмак,* «новая протока, новое русло реки: глубокая промоина, против дамбы > чувашча *йармак* ~ чыгтай телендә (Будагов, II: 355) *йырмак, йыргамак,* казак (казакъ) – *җырмақ, жырмақ* «тирән ерганак, ерганак тобасы», борынгы кыпчак, төрек – *irmak, irmaқ*, үзбәк – *ирмақ* «агым, агынты» һ. б. (кара: Räsänen, 1969: 2002; ЭСТЯ, I: 664– 665)».

*Ермак* термины төрки телләрдә еш кулланыла. Уйгырларда – *яр*, кыргызларда – *жар*, казакларда – *жыра*, азәрбайҗаннарда – *ярган* (чокыр), үзбәкләрдә – *ермак*, төрекмәннәрдә – *ирмак* (елга, елга кушылдыгы) һ. б. Төркиядә *Кызыл Ирмак, Делидже-Ирмак, Етилъ-Ирмак* елгалары бар. Караим телендә «кечкенә елга, инеш»не белдерә торган *чырлах* апеллятивы (термины) *й~җ~з~с~ч~ш* авазларының тәңгәллекләре нигезендә *ермак*ка барып тоташа. Чуваш телендәге *çырма* сүзе «чокыр, кул, сыза, инеш, елгачык» төшенчәсендә кулланыла.

***Еру.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә – «Еру – 1) Су ташкыны белән юлдагы нәрсәләрне юып, җимереп үтү». *И яуды, и яуды яңгыр, күперләрне агызды, буаларны ерды*. А. Гыйләҗев; 2) «Сулыкны тотып тора торган ныгытманы җимерү, суга юл ачу». – *Алла сакласын, ул [Миркәй] авылга ут салыр, тегермәнне ерыр*. Н. Исәнбәт; 3) «Җирне озынлыкка казып нәрсә дә булса эшләү, үткәрү». *Безнең куллар канал ерырлар Идел кебек итеп, киң итеп*. Ә. Ерикәй. *[Бакчага] күлдән су ерып кертәм*. И. Гази (ТТАС, I: 335).

Р. Әхмәтьянов сүзлегендә: «*ер-у* (йыр-), диалекталь *җыр-у* «прорывать, рыть (канаву); разрывать, вспарывать» < гомум кыпчак, караим, нугай, кумык, чыгтай – *йыр-*, кыргыз, карачай, балкар – *җыр-*, казак (казакъ), каракалпак – *җыр-*, *id*. Уйгыр, үзбәк – *йир-, җир-* (каты р.), угыз, төрек – *yir-*, алтай телендә – *йыр-* «сүтү, кечкенә ярык ясау», тыва телендә – *чир-* «китү (китек ясау)», якут теле диалектларында *сыыр-* «еру» һ. б. Борынгы

төрки язмаларда бу сүз юк, ләкин дериватлары (*jirt – jirtuć* «ерткыч», кара: ДТС: 269) бар (кара: шулай ук чуваш телендә *çыр* – «ярны еру»)» (Әхмәтьянов, ТТЭС: 177).

***Ерык.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ерык* сүзенең су белән бәйләнеше, ягъни су чыганагыннан кереп киткән тар култык, яисә «кече елга, инеш» мәгънәсе бирелмәгән. «Ерык» термины, аерым су чыганакларының атамасы да булып кулланыла. Мәсәлән, *Ерык күл* дип Яшел Үзән районы Кече Өтәк авылындагы бер күлне, ә шул күлгә коя торган чишмәне *Ерык күл кизләве* дип атыйлар. Балтач районының үзәге Балтачта *Ерык чирмә* елгасы бар.

Рус телендәге «агым, инеш» мәгънәсен аңлата торган *ерик* сүзе төрки *ерык, җарык* сүзеннән үзгәргән. *Ерык~ерик* терминының таралыш ареалы бик киң. «Книга к Большому Чертежу» китабында Северский Донец елгасын тасвирлаганда, «елга, инеш, кечкенә елга» мәгънәсендә кулланыла торган *ерек* термины очрый. *Ерык~ерик~ерек* терминының таралыш ареалы бик киң. Белгород өлкәсендә – *Ерик суы,* Сызрань янында – *Ерик* тимер юл станциясе, Краснодар краенда – *Ерик, Черный Ерик* лиманнары, Ростов өлкәсенең Азов тирәсендәрәк – *Казачий Ерик,* Дон бассейнында *Сухой Ерик* хуторлары урнашкан. Кубань дельтасында *Ангелинский Ерик* дип аталган агымсу бар. Камышин шәһәреннән өстәрәк Иделгә *Иловатый Ерик* дип йөртелгән елга кушыла. Петербургны салган елларда Фонтанка суы *Безымянный Ерик* дип аталган. Шулай ук *ерик* Төньяк Кавказда, Украинада, Молдовада, Себердә һ. б. урыннарда очрый (Мурзаев, 1984: 202).

***Ерылу***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ерылу* лексик берәмлегенең мәгънәсе «су ташкыны басымы астында җимерелү, ачылу (буа һ. б. шулар турында)» диелгән: *Тегермән буасы бер ерылса, туктатып булмый бит аны*. Э. Касыймов (ТТАС, 1977: 335).

***Ерым***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ерым* – 1) Яңгыр һәм язгы кар сулары белән юылып, ашалып ясалган киң һәм

тирән озын чокыр. *Караңгы почмакка, ерымнарның берсенә, посып өлгергән [җинаятьче] Алмазга төбәп аткан.* Б. Камалов; 2) Махсус ерып, казып ясалган зур, озын канау. *Кабанның әле Болак дигән ерымы да бар*. Ә. Еники (ТТАС, 1977: 335).

*Ерым* аерым елгаларның атамасы булып та һәм атамалар составында да кулланыла: *Болак ерымы*– Казансу кушылдыгы, *Ерым* – Идел кушылдыгы, Югары Ослан районында; *Үләмә ерымы* – Кама Тамагы районында, *Бидәңге ерымы* – Тәтеш районында һ. б.

*Ерым* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында да кулланыла.

Вахит Имамовның «Татарлар Пугачев ягында» дип аталган әдәби эпизодлар белән баетылган тарихи очеркында *уйсулык* һәм *ерым* лексик берәмлекләре очрый: *«Уйсулыклар һәм ерымнар буйлап кача-поса гына баралар иде, каршыларына Григорий Закладнов килеп чыкты». «...Бу вакытта Зәй каласы ике елга һәм махсус ерым уртасындагы биек тауда урнашкан, тирә-ягы имән стеналар, 6 манара белән ныгытылган мәһабәт крепость булса да, аны саклаучы гарнизон һәм шәһәр кешеләре арасында икеләнү туа, каршылыклар башлана».*

Шул ук авторның «Утлы дала» романында *ерым* термины кулланылган: *«Ике ур эчендә дә очлы бүрәнәләр утыртылган тирән ерымнар бар. Кала диварлары белән эчтәге ур арасындагы ерымга су да җибәргәннәр».*

Айдар Хәлимнең «Кыйбла: хикәяләр һәм новеллалар» дип аталган китабында *ерым* терминын үз эченә алган мондый җөмлә очрый: *«Тирән буразналар, сай ерымнар белән ермакланып беткән яңакларны, шундый ук өзлеккән, муртайган тиреле ияк асларын, бугаз тирәләрен, бигрәк тә берсе өстенә берсе менеп беткән җыерчыклы түгәрәк тәңгәлендәге каты кылны кыру аның өчен гүяки үз тәнеңне кайрак белән кайрау, телеңне аркылы тешләп, тау чарлагындагы җиз үлән, кылган кыру кебек авыр эшләрнең берсе иде».*

***Ерынты.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә күрсәтелгәнчә, ерынтыны *ерым* шәрехләмәсеннән табарга мөмкин.

Мисаллар: *Ерынтылар, уйсу җирләр юелән телгәләнгән, бүлгәләнгән басулар һәм басулар урыны-урыны белән кардан арынып чуарланганнар.* А. Расих. *Бозлы юлны урталай кисеп, ерынты ерып җибәргәч тә, сул яктагы су тиз арада хәрәкәткә килде*. Н. Фәттах (ТТАС, 1977: 335).

*Ерынты* лексик берәмлеге су чыганаклары атамалары булып кулланыла: *Хәмит ерынтысы* – суын Иделгә илтә (Югары Ослан районы), *Булат ерынтысы* – Бидәңге кушылдыгы (Тәтеш районы), *Ерынты елгасы* – Яшел Үзән районы Чүриле авылы янындагы елга. Бу елга Петьялка бассейнында. Бу мисалда *д – т* авазлары чиратлашуы күзәтелә.

***Җәйләү I***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «искергән исем» дип бирелгән һәм түбәндәгечә аңлатылган: 1. Күчмә халыкларның җәй уздыру өчен төпләнгән урыны; җәйге тору урыны. *Бу җәйләүдә барлыгы унбиш тирмә бар*. Г. Ибраһимов. *Җәйләүләрне ташлап корал алып, Без китәбез, без китәбез, менеп лә атларга*. Жыр. // Аерым кабилә кешеләре тупланып яши торган урын, авыл. *[Либреттода] Тузгак әбиҗәйләвенең Казан ханы тарафыннан туздырылуы [күрсәтелә]* М. Җәлил; 2. Терлекләрне авылдан читтә, яшеллек мул булган урында яшәтү өчен махсус корылган ферма. *Җәйләү авылдан шактый ерак булганга күрә, сыер савучы кызлар, үзләренә җитешле азык-төлек алып, җәйләүдә куна-төнә гомер кичерделәр*. С. Рафиков. *Мал таптап бетергән яланда, ялandагы җәйләүдә дә тавыш-тын юк*. Г. Мөхәммәтшин. // Болында яки урман аланлыгында терлекләрне утлату өчен киртә белән әйләндереп алынган урын. *Җәйләүләргә бардык, бияләр саудык, Баш күнәкәй, баш күнәкәйләрне дә кулга алып.* Жыр; 3. геогр. Җир өсте тигез булган зур яссы калкулык; русчасы: плато. *[Ай-Петри] Кырым җәйләве дип йөртелә торган тигезлектән күтәрелеп тора.* Г. Иделле.

***Җәйләү II***. Фигыль. «Җәйне уздыру, җәй буена яшәү» дип бирелгән. *Кайларда кышлады, Кайларда җәйләде, Хыялда сакланган төсләрең*? С. Сөләйманова. *Җәй җәйләгән тезмә кыр*

*казлары Жырлап үтте көзләр җиткәнен.* М. Крыймов // Җәйге табигать кочагында ял итеп уздыру өчен шәһәрдән, авылдан читтә, җәйлек өйләрдә, дачаларда яшәү. *Атна арасында, тегенди көннәрдә сирәк-мирәк җәйләп ятучыларны искә алмаганда, (бу утрауларда) кеше-кара күренми диярлек.* Э. Касыймов (ТТАС, III: 806– 807).

Адлер Тимергалин җыеп чыгарган «Миллият сүзлеге»ндә *җәйләүгә* мондый аңлатма бирелгән: «1. Күчмә халыкларда җәй үткәрү урыны, җәйге торлак, җәйләвек, җәйге көтүлекләр; җәйге ферма. Бу сүз, фигыль буларак, җәйге чорны уздыру мәгънәсен бирә. Төрки телдә тагын *кышлау, көзәү* («Древнетюркский словарь») сүзләре дә бар, ә кышлау урыны – *кышлык* һәм, бәлки, *кышлавыч/кушлавыч* булыр. // *Ол йайлауда күзәде* – ул җәйләүдә көзләде (көз үткәрде). «Древнетюркский словарь»дан. Кайбер чыганакларда *йаглаг* формасы да күзәтелә. Г. Тукайның кырдагы җәйләүгә карата ностальгия хисләре белән сугарылган шигыре бар, ул анда «*Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!»* – дип игълан итә. *Җәйләү* сүзен «лагерь» мәгънәсендә куллану очрый. //*Ислам җәйләве* – ислам лагере (соңгы елларда яшьләргә ислам нигезләрен өйрәнү өчен оештырылган җәйге кыска курслар). *Санаклы җәйләү* сүзен дә очратырга туры килде (компьютерга өйрәтү лагере). 2. Киң булып җәелеп яткан калкулык; географиядә – плато».

*Җәйләү* лексик берәмлеге топонимнар ясауда актив кулланыла: *Җәйләү ягы* – 1. Тәтеш район үзәге янында. 2. Алексеев районы Балахчино авылы тирәсендә. *Бирге җәйләү* – Идел дельтасында (бу атаманы Әстерхан шәһәренә барган вакытта бер бабай әйтте). *Җәйләү* – Саескан тавы тирәсендәге урын, Мамадыш районының Югары Яке авылы янындагы урын атамасы. *Җәйләү кизләве* – Әтнә районы Ябынчы авылындагы, Түбән Кама районы Ширәмәт авылы янындагы чишмәләр. *Җәйләү урыны* – Питрәч районыШихазда авылы янындагы урын атамасы. *Җәйләү елгасы* – 1. Арча районының Ашытбаш авылы янында, Ашыт елгасы бассейнында; 2. Лениногорск районы-

ның Кирлегәч авылы янында, Вятка елгасы бассейнында. *Җәйләү күл* – Алексеев районының Юеш Көрнәле авылы янында, Көрнәле суы бассейнында. *Җәйләү чишмәсе* – 1. Кайбыч районының Кече Урсак авылы янында, Имәлле суы бассейнында; 2. Кама Тамагы районының Кыртапа авылы янында, Үләмә суы бассейнында. *Сон ягы җәйләве* – Мамадыш районы Колышчы авылы янындагы урын атамасы. *Аргы җәйләү* – Лениногорск районы Сарабиккол авылы янындагы җәйләү атамасы. *Урта җәйләү чишмәсе* – Лениногорск районы Сарабиккол авылы янындагы җәйләү.

*Җәйләү* термины белән Тукай районы *Борды Җәйләү* атамасы алган авыл бар.

Тарихи чыганакларда *Акҗәйләү* кеше исеме буларак та очрый.

*Җәйләү* лексик берәмлеге әдипләребез һәм шагыйрьләребез иҗатында искә алына. Галимҗан Ибраһимовның «Казак кызы» романында *җәйләү* лексик берәмлеге болай сурәтләнә: «*...Симез җылкылар уйнаклап йөргән җәйләүләрдә хәзер инде күз ачкысыз ачы буран белән яман җил ажгыра; ач бүреләр, көннең зәһәр суыгына түзә алмыйча, кич малга баруны исәпләп, шул карлы давыл эчендә караңгы төннәрне көтеп, тешләрен шакырдатып йөриләр*».

*Җәйләү* лексик берәмлеге төрле фонетик вариантлар белән төрки телләрдә шактый кулланыла: *джайла, джелав, жайлав, җайляв,* казак – *йаілау* «җәй үткәрү өчен ясалган корылма» (Радлов, IV: 4), нугай – *яйлав (яйла-)* 1) «Җәйлеккә урнашу», 2) туктап бераз вакыт кунак булу» (Нуг. сүзл.), төрки – *джайлау, джайлов (чайлов)* «җәйчелек, тау көтүчелеге» (Розова); *джайляу* – җәйгелек, җәйге көтүлек, кагыйдә буларак тау көтүлекләре. *Джайлау* – җәй мәгънәсендә йөри торган төрки *джай, җай, яй* термин-вариантларыннан ясалган. *Яйлу* – алтай телендә «җәйге тукталыш», «җәйге көтү йөри торган урын». Телец күле ярында *Яйлу* исеме алган бистә (гадәттә аны *Яйлю* дип йөртәләр) урнашкан. Кырымда – *Яйла, Караби-Яйла,*

*Демерджи-Ййла, Бабуган-Ййла,* азәрбайҗан телендә *яйла* – «таулык, калку җир, яссы тау». Бу җирдә терлекләр көтәләр. Үзбәк телендә *ёзлак* «җәйге көтүлек урын»; кыргыз телендә – *җайлоо*, диалектларында – *айлак;* алтай телендә – *jaly;* тыва һәм хакас телләрендә – *чайлаг* – «җәйге көтүлек», «җәйгелек»; балкар телендә – *җайлыкъ;* төрекләрдә *yayla* – «җәен хайваннарны көтә торган яссы тау», «җәй көне көтү йөртә торган урын»; Әфганстанның Бадахшанында – *айлаг;* таҗик телендә *джайлов* «тау көтүлеге». *Джайлаулар* төрле тауларда төрле биеклектә урнашканнар: Кырымда 1000 метрда, Урта Азия һәм Алтайда 2000–3500 метр, Кавказда – 2000– 3000 метр югарылыкта. Иң билгеле һәм күренекле җәйләү Кыргызстанның Сусамыр үзәнлегендә, Кыргыз сыртыннан көньякка таба сузылган. Шулай ук җәйләү Алай үзәнлегендә очрый. Шулай ук Ыссык күл янындагы тирән сөзәк чокырда урнашкан руслар сөйләшендә дә *джайлау* «күңел ачу, ял итү урыны» буларак кулланыла. Алма-Ата өлкәсендә – *Жайлау,* Джамбул өлкәсендә *Жайляуколь.*

Шушы ук рәткә тагын *яйла* термины да керә. Төрекмәннәрдә *яйла* яисә *яйлаг* «җәйге көтүлек урыны». Борынгы төрки телдә *jaj* – «җәй», *jajla* – «җәй үткәрү», *jajlaq* – «җәйгелек лагерь». Балкариядә – *Ййлау, Зайлау.*

***Җир***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә җирнең 27 мәгънәсе бирелгән. Монографиябездә без бу мәгънәләрнең географик атамалар белән бәйләнешле берничә төренә генә тукталабыз. *Җир* терминының беренче мәгънәсе: «Үз күчәрендә һәм кояш тирәсендә әйләнә торган, тереклек дөньясы булган планета». *Космостан караганда кечкенә генә күгелҗем шар булып күренә торган Җир планетасында яшәүчеләр бәхетле булырга тиеш*. М. Максуд (ТТАС, III: 776).

Кеше җирдән килгән, җиргә китә. Җирдә яшибез, үсәбез, тормыш көтәбез. Кем җир сөрә, кем икмәк үстерә, кем космоска очу өчен аппаратлар ясый, кем космоска оча, кемнәр бала үстерә. Бар шөгыль дә җирдә. Бар кешелек дөньясы, барча тереклек җир белән даими бәйләнештә. Менә шуңа күрә дә *җир*

термины катнашында һәр халык телендә географик атамалар күп кулланыла. Чөнки алар һәрдаим кирәк, без аларга һәрдаим мөрәҗәгать итәбез. Алар юнәлеш бирәләр, ориентир күрсәтәләр, адрес функциясе үтиләр. Менә шуның өчен дә татар халкы, башка күп халыклар кебек үк, җиргә һәрдаим мөрәҗәгать итә, *җир* термины кергән географик атамалар халкыбыз телендә бик күп.

Менә шуларның кайберләре генә: *Җир асты юлы* – Биектау районы Кече Солабаш авылы янындагы юл; *Җир күпер чишмәсе* – Лениногорск районының Иске Шөгер авылы янында, Шөгерчә елгасы бассейнында; *Давыллы җир* – Биектау районының Зур Кавал авылы янында; *Даулы җир* – Саба районының Тимершык авылы янында; *Дәүли җире* – Саба районының Йосыф-Алан авылында; *Дисәтинә җире* – Саба районының Яңа Мичән авылы янындагы җир атамасы; *Казак җире* – Кама Тамагы районының Уразлы авылы янында; *Казна җире* – Кама Тамагы районының Каратал авылы янында; *Карамышевлар җире* – Яшел Үзән районының Мулла иле авылы янында; *Вәлиулла җир өсте ышнасы* – Саба районының Олы Мәтәскә авылы янындагы җир атамасы; *Бикмар җире* – Тәтеш районының Кече Әтрәч авылы янындагы җир; *Җөри җире* – Мамадыш районының Югары Кыерлы авылында; *Марлы җире* – Буа районы Черки-Килдураз авылы янындагы басу; *Кәчтәй җире* – Азнакай районы Сасы күл (Бүләк) авылы янындагы җир атамасы; *Колнакса җирләре* – Яшел Үзән районы Күгәй авылы янындагы җир атамасы; *Чүриле җире* – Арча районы Кышлау авылы ягындагы җир атамасы.

Нурулла Гарифның тарихи чыганаклардан җыелган топонимнар һәм кеше исемнәре тупланып бирелгән сүзлегендә Ямаширмә авылына нисбәтле җир болай ныгытылган: «Ямашурмская земля (Ямаширмә авылы җирләре); Закруглинское заполе (Әйләнә кырдан соң урнашкан *җирләр*).

*Икенче мәгънәсе:* тереклек булган, кешеләр яши торган җир йөзе. *Кояш янә күк читеннән күтәрелеп, үзенең көндәге эшенә*

*– җирне пешерергә кереште*. Ш. Усманов. // Бөтен дөнья. *Брянскийның кара урманнары... Җирдә юктыр бер дә охшашы*. Ш. Мөдәррис (ТТАС, III: 776).

*Өченче мәгънәсе:* җир өсте; җирнең һава, атмосфера белән чикләнгән өслеге. *Еракта, кара җир белән зәңгәр күк килеп тоташкан урында, җил тегермәненең канатлары әкрен генә әйләнә*. И. Гази. //Аяк асты, басып йөри торган җир, юл. *Озакламас, Матур кошлар килер, Шатлык көен безгә сызарлар; Җирләр кибәр, Ерак киң кырларга Сабанчылар эшкә чыгарлар*. Ш. Маннур. // Гомумән, аяк асты (җир, идән һ. б.). *Пулат көзгесе пыяла, җиргә төшсә уала*. Н. Исәнбәт. //юнәлеш килеше формасы: җиргә. *Юан койрыгын җиргә чәнечте эт*. Г. Гобәй (ТТАС, III: 776).

*Дүртенче мәгънәсе:* Җир шарының өске катлавы, үсемлекләр үсә, үсемлек тамырлары азык ала торган катлау, туфрак. *Яңгырый мотор җырлары, Күпертә җирне сабан*. З. Мансур. *Җир туңган, окоп казып булмый, югалтулар бик зур*. Г. Бәширов (ТТАС, III: 776).

*Җиденче мәгънәсе*: билгеле бер халык, ил биләмәсе булган территория турында. *Рус җирендә без әсәрле эзлебез*. Г. Тукай. // Җир йөзенең берәр яктан характерлы кисәге, урыны. *Әйтә: без солдатта хезмәт иткән җирдә, ди, киндер бер дә юк, ди*. Г. Камал (ТТАС, III: 776).

Югарыда, ягъни *җир* сүзенең җиденче мәгънәсенә тап килә торган фикерләр шигъри юлларда һәм проза әсәрләрендә чагылыш таба.

*Сигезенче мәгънәсе:* туып-үскән ил, туган ил. *Җирем – минем алтын тәхет, җирем – гөлбостан*. Ә. Ерикәй (ТТАС, III: 776).

*Тугызынчы мәгънәсе:* Халыкның тормыш-көнкүреше яки тарихи вакыйгалар барышы белән характерлы булган урын, чагыштырмача зур булмаган, гадәттә административ территория. *Шулай да ... шәһәр җирендә бер кешенең дә ачтан үлүен әйтмиләр*. Г. Камал (ТТАС, III: 777).

Вахит Имамовның «Утлы дала»исеме алган тарихи романнан түбәндәге сүзләрне укыйбыз: *«Сездәге Айтуган остага ялланып иртәдән кичкә кадәр Мораса буендагы базларда казына идек тә, менә, башлыгыбыз Фаяз өстенә җир убылып, бахырыбыз бөтенләй ушсыз калды».*

*Унынчы мәгънәсе:* кемнең дә булса биләмәсе, аерым кеше яки оешма, коллектив хуҗалыгындагы урман, болын, чәчүлек. *Дәүләт җире. Колхоз җирләре. Безнең Мулла бояр җиренә нин-дидер көзге җыелышка хәтле кагылмаска кушты.* К. Нәҗми (ТТАС, III: 777).

Роза Хәбибуллинаның «Мулла килене»исеме алган романында *җир* лексик берәмлеге болай бирелгән: *«Лесхоз урман аланында солы чәчәргә җыена. Безгә дә җир сорап, бәрәңге утыртырга кирәк, – диде аталары. – Ат биреп торсалар, сабан белән сөрербез, бирмәсәләр, казырбыз». «... Чишмә тавы өстендәге урман яныннан бер бизнесмен әллә ничә гектар җир алган ди. Юл салдыра башлаган. Әллә курорт салдыра ди, әллә үзенә имение шунда...»*

***Җыпкы***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *җыпкы* – «исем, диалекталь сүз» дип бирелгән һәм мәгънәсе «Агым сулы суның тирән, агым көчле булган урыны, су юлы» дип ныгытылган. *Пароход йөри торган җыпкыга, маяклар белән билгеләнгән юнәлешкә керергә кирәк*. Ә. Баянов (ТТАС, III: 801).

Тау ягы халкы телендә бу термин еш кулланыла, ә Казан арты һәм Кама аръягы төбәкләрендә сирәк очрый. *Җыпкы* – Коры Үләмә суы кушылдыгы (Кама Тамагы районы), Бидәңге суы кушылдыгы (Тәтеш районы). *Сөзәй җыпкы кизләве* – Апас районы Чүри-Бураш авылы яныннан агып үтә торган Табар суы бассейнында. *Мутный җыпкысы* – Апас районы Дүртөйле авылы янындагы су юлы. *Сары алан җыпкысы // Саралан җыпкысы* – Тәтеш районы Кече Әтрәч авылы янындагы Инеш кушылдыгы. *Йәрми җыпкысы* – Инеш суы кушылдыгы Апас районы Дүртөйле авылы. *Имел җыпкысы* – Тәтеш районы Кече Әтрәч авылы янындагы кечкенә елга.

*Зират җыпкысы* – Апас районы Дүртөйле авылы янындагы кечкенә ермак.

*Җыпкы* лексик берәмлеге күбрәк халык телендә кулланыла. Тау ягында яшәүчеләр: «Безнең тирәдә элек җыпкылар күп иде, хәзер сулар саекты шул», – дип әйтәләр.

***Идел***. Татар телендә *идел* апеллятивы «зур елга» дигән мәгънә аңлата.

***Инеш***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «кечкенә, сай һәм тар елгачык». *Урман арасын кисеп бик сай сулы тар гына инеш ага.* Г. Гобәй. *Габделкаюмның үзләренең авыл кырыендагы сай гына кыр инешеннән башка суда коенганы юк иде.* М. Гали (ТТАС, 1: 394).

Татар халык шагыйре Г. Тукайның *«халкының эчкән суы бик кечкенә, инеш кенә»* дип язуы да, вак елгаларның инеш дип аталуларын куәтли.

Борынгы төрки телдә *eniš* – «түбәнлек», «уйсулык», «уйсу урын» (ДТС, 1969: 174). *Эң* – түбәнәю, *иңү* тамырыннан (тат., башк. *иң – ин),* шуннан ук тат., башк. *иннек, индек* – «төшү, түбәнгә төшү». Кырым, коман, кумык *эниш – енис* «таудан төшү урыны» (Ахметьянов, 1969: 357; Әхмәтьянов: 139). В. Радлов сүзлегендә *ініш* Казан татарларында «киң инеш» (т. 1, ч. 2: 1445).

Авыллар, торак пунктлар яныннан агып үтүче кечкенә һәм хәтта зур елгаларны да халык *инеш* дип атый.

*Инеш* термины атама булып та кулланыла һәм атама составында да килә ала: *Инеш* – Тәтеш районы Чагылдым авылы янында, Зөя елгасы бассейнында; Мөслим районы Тырыш авылы янында Калмия елгасына килеп кушыла; Кама Тамагы районы Алабирде авылы янында Коры Үләмә елгасына килеп кушыла; Минзәлә районы Югары Тәкермән авылы янында Минзәлә елгасына килеп тоташа; Апас районы Дүртөйле авылы янында Коры Үләмә елгасына кушыла; Минзәлә районы Гөлек авылы янындагы инеш; Кама Тамагы районы Олы Салтык авылы янында Ыргымага кушыла. *Инеш* – Бәтке, Урай,

Казансу, Мишә, Шушма, Ар һ. б. елгалар кушылдыклары (Балык Бистәсе, Арча, Саба, Балтач районнары). *Инеш* – Зөя елгасының уң кушылдыгы (Татарстан АССР картасы, 1953). Чуваш теле галиме Г.Е. Корнилов фикеренчә, Идел кушылдыгы Аниш елгасы атамасы татар теле термины *инеш*кә барып тоташа. Аниш елгасы 1627 елда төзелгән «Книга Большому Чертежу» хезмәтендә теркәлгән (Книга, 1950: 170). *Инеш* апеллятивы су чыганаклары атамаларының состав өлеше булып та кулланыла: *Заһир инеше* – Карлы елгасы кушылдыгы (Буа районы), *Алан язы инеше* – Казансу елгасы кушылдыгы (Биектау районы), *Таһир инеше* – Әмзә елгасы кушылдыгы (Нурлат районы), *Алмагач инеше* – Шумбут елгасы кушылдыгы (Балык Бистәсе районы) һ. б.

*Инеш* сүзе Татарстан җирлегендә микротопонимнар составында да зур урын алып тора: *Инеш аланы, Инеш тугае, Инеш тавы, Инеш күпере, Инеш ышнасы, Инеш басмасы, Инеш юлы* һ. б.

*Инеш, кечкенә елга* сүзләре Татарстаннан читтә яши торган татарлар сөйләшендә актив кулланыла. Ульяновск өлкәсендә: *Инеш* – Кулаткы елгасы кушылдыгы (Иске Мастяк, Усть-Кулаткы авыллары, Иске Кулаткы районы), шулай ук бу термин микротопонимнар составында да еш очрый: *Инеш урамы* (Иске Мастяк, Урта Тирешкә, Иске Кулаткы авыллары, Иске Кулаткы районы), *Инеш урманы* (Усть-Кулаткы авылы, Иске Кулаткы районы) һ. б. Саратов өлкәсендә *Инеш* Дергачев районы Сафаровка авылыннан ага, *Кәлиф инеше* дә Сафаровка авылында һ. б. Микротопонимнар: *Инеш юлы, Инеш сукмагы* һ. б. Самара өлкәсендә *Инеш* – Сок елгасы кушылдыгы (Камышлы районы Яңа Усман авылы); Похвистнев районы Мочали авылы; Елхавай районы Теплый стан авылы һ. б. *Инеш сазы* – Похвистнев районы Мочали авылында һ. б. Түбән Новгород өлкәсендә *Инеш* – Сергач районы Андреевка авылында һ. б.

Татар теле сөйләшләрендә *инеш* сүзенең төрле төрдәшләре (вариантлары) кулланыла. Урта диалектның казан арты лаеш,

казан арты керәшеннәре сөйләшендә *инеш*не белдерү өчен, *иҗеш* сүзе кулланыла (ТТДС, 1969: 156). Гәйнә сөйләшендә кечкенә елганы атау өчен, *бала йылга, бала җылга* апеллятивы йөри (ТТДС, 1969: 67). Көнбатыш диалектта *инеш* – «ага торган сай елга». Себер диалектының тобол сөйләшендә күлдән агып чыга торган кечкенә елганы *лагы* дип йөртәләр (Тумашева, 1961: 162). Балык Бистәсе районында тау астыннан агып чыга торган кечкенә елганы *Ай җылгасы* дип әйтәләр (ДС, 1953: 29).

Инеш, яисә кечкенә елгаларны аңлату өчен, төрки телләрдә түбәндәге терминнар кулланыла: кумык телендә – *гиччи оьзен* (РКС, 878); карачай-балкар телендә – *суучукъ баргъан суучукъ* (РКБС: 548); каракалпак телендә – *кишкене дәрья, дәрьяша;* өзек, өзекше (РКС: 885); казак телендә – *өзеншік, шагын өзен,* кишкене өзен (РКазС: 669); кыргыз телендә – *кичине өзөн, кичине дарыя, кичине аккан су* (РКирС: 737), чуваш телендә – *пĕчĕк юханшыв, сырма* (РЧС: 675).

***Иңкел*** термины «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә сыйфат, исем, кара *иңкү* дип бирелгән һәм мисал китерелгән. *Әти белән әни, «яңгырга китсә, черемәгәе» дип, иңкелрәк урыннардагы печәнне калкулыкка ташырга тотындылар*. Г. Бәширов. *Төн эчендә Карабаш иңкелендә шактый су җыелып өлгергән*. Ш. Бикчурин (ТТАС, III: 447).

*Иңкел* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында очрый.

Гомәр ага Бәширов «Җидегән чишмә» романында бу лексик берәмлекне кирәк урында матур итеп файдалана: *«Ә вышка торган саен якыная бара, әле иңкелләрне кичеп, әле сөзәк үрләргә күтәрелеп, болын буеның әллә никадәр җирен иңләп килә... Сөендек иңкелендә нindидер бер биек нәрсәнең селкенгәләп килгән башы күренде».*

***Иңкеллек***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек-термин *иңкүлеккә* җибәрелгән һәм мисал китерелгән. *Гомумән, бу район тигез урын булып санала, тик аның кайбер урыннарында гына кечкенә иңкеллекләр (подалар) очрый*. А. Фәткуллин (ТТАС, I: 447).

***Иңкү I***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек сыйфат дип күрсәтелгән һәм ул түбәндәгечә аңлатылган: «Әйләнә-тирә җирдән түбәнрәк, батыбрак торган, уйсу». *«Дымык күл»нең бер башында иңкүрәк, сазлыклырак урын бар.* Г. Мөхәммәтшин. *Үргә менгәндә тәпили-тәпили, иңкү җирләрдә аз-маз утырып, Исхак кичкырын гына Чаллыга килеп җитте*. А. Гыйләҗев. // Исем мәгънәсе. Шундый урын, иңкүлек. *Якуб иңкү буенча сузылган ак томанга күрсәтте.* И. Гази. *Инеш буендагы иңкүләргә зәңгәрсу сыек томан җәелә.* Г. Бәширов. (ТТАС, I: 447).

*Иңкү* лексик компоненты топонимнар ясауда актив түгел, шулай да очрый. *Иңкү сазлыгы* – Әтнә районының Ябынчы авылы янындагы сазлы урын; *Иңкү урын* – Биектау районының Селәңгер авылы янындагы урын атамасы һ. б.

*Иңкү* сүзе әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында да очрый.

Фоат Садриевның «Таң җиле» романында мондый юллар язылган: *«Күкрәктән сулга таба, бил турысы, сыгылып төшкән кебек иңкүләнеп тора».*

***Иңкүлек***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *иңкүлек* сүзенең ике мәгънәсе бирелгән. *Беренчесе* исем буларак ныгытылган һәм «Әйләнә-тирәдән җир чокырланып, батып торган урын, иңкүлек, уйсу җир» дип аңлатылган. *Ялгыз нарат яныннан елгага тар гына, сай гына чокыр кебек бер иңкүлек барып кушыла иде. Бу иңкүлек, бу тар гына батынкы җир елганың кайчандыр иске эзе булган*. Н. Фәттах. *Озакламый иңкүлектә кечкенә генә буа хасил булды*. Гәр. Рәхим.

*Икенче мәгънәсе* география белән бәйләнешле һәм ул болай аңлатылган: «Диңгез өсте тигезлегеннән дә түбән торган урын. // Диңгез өсте тигезлегеннән 200 метрдан югары булмаган тигезлек, түбәнлек. *Академик [Губкин] Икенче Баку районнарында – Иделдән алып Уралга хәтле булган шаять зур иңкүлектә – нефть эзли.* Г. Ахунов (ТТАС, I: 447).

*Иңкүлек* лексик берәмлеге белән географик атамалар байтак очрый:

*Тегермән бүләк иңкүлеге* – Азнакай районы Әлкәй авылы янында. Иңкүлек атамасы.

Әдипләр иҗатында *иңкүлек* сүзе кулланыла. Мөхәммәт ага Мәһдиев бу сүзне табигать күренешләрен сурәтләгәндә куллана: *«Кинәт дымлы җил исеп китте, күк йөзенең урман белән тоташкан ягыннан шомлы гөрелдәү ишетелде, яңгыр җиле уйнаклап күл кырыендагы сары иңкүлекне бөтерә башлады, ул арада кечерәк кенә зәңгәр-кара болыт кояшны каплады»*.

Вахит Имамовның «Сәет батыр» исеме алган тарихи повестенда иңкүлек сүзен очратабыз: *«Шулчак, бар иңкүлеккә таралган тынлыкны бозып, Чулман аръягында кыңгырау зеңләгән тавыш ишетелгәндәй булды...»; «Иңкүлек өстендә тынлык урнашса да, ул ничектер хәвефле һәм шомлы, шуңа күрә тәнгә кадалган шырпы кебек күңелләрне тырнап тора иде»*. Шул ук авторның «Утлы дала» исеме белән дөнья күргән тарихи романында да *иңкүлек* термины файдаланыла: *«Бик хуп, бик хуп, бик әйбәт! – дип, иңкүлектә бердәнбер ир-ат кына аваз салды. Ул эче-җаны үч һәм мәкер белән тулы Чагатай иде»; «...Сирәк-мирәк кенә иңкүлектәге атлар пошкырып куя»*.

Фирүзә Җамалетдинованың «Догалы корт: повестьлар, хикәяләр» китабында *иңкүлек* сүзе очрый: *«Иртәнге чыкны чөгендер төбенә шактый койгач, ул тураеп басып иңкүлеккә карап торды»*.

***Итәк***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *итәк* лексик берәмлеге исем дип ныгытылган һәм аның *дүртенче мәгънәсе* болай бирелгән: «Биек нәрсәнең түбәнгә таба сөзәкләнеп җәелеп киткән аскы кырые, чите». *Кыя итәге. Манара итәге. Алар тау итәгенә кадәр әкрен генә төштеләр дә, тигез җиргә килеп җиткәч, кинәт чабынырга тотынып, бик тиз якыная башладылар*. И. Гази. *Салам эскертенең итәгендә, һәммәсе бертугандай бер-берсенә сыенышып,... бодай сугучылар йоклап ята*. Г. Бәширов.

*Бишенче мәгънәсе*. Урман, болыт, күк һ. б. кырые. *Офык итәге. Юл сузыла урман итәгеннән, Туктат ямщик, туктат*

*атыңны*! Ш. Маннур. *Кояш аксыл болытлар итәгеннән чыгып, саф, зәңгәр күктә йөзә башлады.* Г. Гобәй. *Зәп-зәңгәр күк итәгенә барып тоташкан, очы-кырые күренмәгән бер кара урман бар.* А. Алиш.

*Алтынчы мәгънәсе*. Диңгез, елга, океан яры. *Карт Каспийның Сөзәк итәгендә, Балыкчылар ләмкә тарткannар.* М. Җәлил. *[Фәтхи] инеш итәгенә төшеп китте.* Ш. Камал (ТТАС, I: 433).

*Итәк* лексик берәмлеге топонимнар ясауда кулланыла: *Каенсар тау итәге* – Курмала авылы Балтач районында.

*Итәк* лексик берәмлеге, *тау итәге* гыйбарәсе, әдипләребез һәм шагыйрьләребез иҗатында еш очрый.

Вахит Имамовның «Утлы дала» исеме белән дөньяга чыккан тарихи романында *тау* итәге гыйбарәсе еш очрый: *«Чыңгызхан гаскәре Тибет тауларының итәгенә зәмһәрир салкын кыш уртасында аяк басты. Моны тангыт ханы Шидур белеп алгач, тау өркәчләре өстеннән кар ташкыны кузгалырлык итеп, ихахайлап көлде»... «Бачман тархан Саксин каласы янындагы Кызыл Сырт итәгендә Кара көеп утыра». «...Бату үзенең ыстанын Лачынтау итәгендәге Каурый чишмә буена корып куйды...» «Түземлеген җуйган Сүбүдәй үз кул астындагы өч төмәнне Таш Билбау итәкләре буенча, Агыйдел башына төбәп алып китте». «...Җүчи, Шәрәкыя итәгенә төзелешкән тирмәләр рәтенә килүгә үк, тын алырга да ара калдырмыйча, Чагатай солтанның чатырын әйләндереп атты».*

***Йаз.*** *Йаз* лексик берәмлегенең географик атамаларны анализлауда кабул ителгән мәгънәсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бирелмәгән. Ә менә Э.М. Мурзаевның хезмәтләрендә һәм «Борынгы төрки тел сүзлеге»ндә (Древнетюркский словарь) ул бар, *йазы* дип ныгытылган.

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *йаз* лексик берәмлеге болай аңлатылган: «*Йази* борынгы сүз. Дала. Диалектта *язы* формасында сакланган (зур кыр, дала). Язылу (җәелү) мәгънәсенә бәйле дип карала. // *Язи – ябан, язи – япан –* (җәелеп яткан) кырлар, далалар».

*Яз-йаз* лексик берәмлеге белән географик атамалар байтак ясала: *Югары йаз тавы* – Саба районы Тимершык авылы янындагы тау атамасы. *Югары йаз юлы* – Саба районы Тимершык авылы янындагы юл атамасы. *Түгәрәк йаз* – Саба районы Олы Шыңар авылы янындагы урын атамасы. *Түгәрәк* һәм борынгы төрки *jari* «кыр, тигезлек, дала» сүзләренә мөнәсәбәтле булырга мөмкин. Нурулла Гариф сүзлегендә «*Арпа (Арпа йаз)* елгасы, реч. в верх. бассейне р. Нурмы. – № 34» дип ныгытылган. *Алан йазы инеше* – Бөреле авылы янында, Биектау районында. *Алан т*ермины һәм борынгы төрки *jari* «кыр, тигезлек, дала» сүзләренә мөнәсәбәтле. *Жазы-Сай, Жазы-Токай* – кыргыз топонимнары (Конкабаев). *Чумка йазы күле* – Спас районы Кырый Йорткүл авылы янындагы күл. *Орйаз чирәмлеге* – Яшел Үзән районы Кече Ачасыр авылындагы урын атамасы. *Тирмән йаз* – Тәтеш районы Кече Әтрәч авылы янындагы чокыр. *Салайаз* елгасы – Зәй елгасының уң кушылдыгы. Бөгелмә районының Салайаз авылы янында.

Э.М. Мурзаев *йазы* терминын болай аңлата: «дала, тигезлек, кыр». Борынгы төрки телдә *jari* – «дала, тигезлек»; татар телендә *язы* – тау, «географик термин: 1. өсте тигез яки дулкынлы булган зур калкулык; 2. кырыйлары бөгелмәгән түгәрәк поднос»; «яссы таулык, яссы калку урын (җир өслегендә)». Хакас телендә *чазы* – «кыр», «дала», алтайлыларда *азы* – «кыр». «дала», «тигезлек», «киң». Азәрбайҗанда *Караяз* тигезлеге бар. *Агунҗаязы, Гиләзи, Сур-Язы* – Алтайда һәм башка урыннардагы атамалар.

Татар топонимиясендә *яз* лексик берәмлеге авыл атамалары составында очрый: *Дөбьяз, Торнаяз, Язлы Арташ, Әйшияз, Арпаяз, Аяз иле* һ. б.

***Йөрәк***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *йөрәк* лексик берәмлегенең аңлатмалары шактый күп.

Йөрәкнең *беренче* төп мәгънәсе «исем» дип бирелгән һәм болай аңлатылган: «Кан әйләнешен тәэмин итә торган мускуллы, капчык сыман үзәк орган. *Йөрәк эшчәнлеге. Йөрәк тибү. Кичәле-бүгенле йөрәккә ябышты. Чәнчеп-чәнчеп авырттыра.*

Э Касыймов. // Күкрәк куышының сул ягында шушы орган урнашкан урын. – *Менә, ышанмасаң, йөрәгемне тотып кара, балык кебек тыпырдый*. А. Шамов. *Мин сугышка керсәм, дошманымның йөрәгенә төзәп атамын*. Ф. Кәрим.

*Бишенче мәгънәсе*: Йөрәк лексик берәмлегенең бу мәгънәсе «күчерелмә» дип ныгытылган һәм «нәрсәнең дә булса үзәге, төп өлеше», – дип аңлатылган. Мисал китерелгән: *Сугыш башланып өлгермәде, дошман безнең илебезнең йөрәгенә сузыла башлады* (ТТАС, I: 471).

Сүзлектә *йөрәк* сүзенеең географик атамаларга мөнәсәбәтле мәгънәсе бирелмәгән. Ләкин ул географик атамалар составында кулланыла. Җир элек *йөрәк* кебек кадерле булган. Күрәсең, бу лексик берәмлек шуның өчен атамалар составында еш очрый. Җир кисәкләренең формасы йөрәккә охшаган булырга да мөмкин.

***Кабак I***. Татар географик берәмлек атамалары арасында *кабак* лексик берәмлеге белән ясалганнары да шактый очрый. Бу терминның мәгънәләре дә төрле.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә ул «исем» дип ныгытылган, аңлатмасы да бирелгән: 1. Сабаклары җиргә ятып үрмәләп үсә торган, шар сыман яки озынча зур җимешле яшелчә үсемлеге; Җимешнең итчел өлеше һәм эфир маена бай орлыгы азык итеп файдаланыла. *Кыяр түтәлләрен әйләндергән куе кабак яфраклары арасыннан атылып, Ибрай үзе килеп чыкты*. М. Әмир; 2. Шул үсемлекнең азык өчен кулланыла торган өлеше. *Кабаклары бик уңганнар: чиләк-чиләк булып тәгәрәшеп яталар.* Ф. Хөсни (ТТАС, II: 7).

***Кабак II***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә исем дип ныгытылган, аңлатмасы бирелгән: Күз алмасын алгы яктан каплап тора торган ике тире җыерчасы. *Солтан, курка төшеп, Зиннурның җыерчыклы кабаклары арасында хәйләкәр ялтыраган соры күзләренә карады*. А. Расих. *Кинәт Лида башын күтәрде, күп елаудан кабаклары шешенгән күзләрен Мухинга төкәде*... Ә. Айдар (ТТАС, II: 7).

***Кабак III***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «искергән исем» дип ныгытылган һәм аңа аңлатма бирелгән: Революциягә кадәр исерткеч эчемлекләр сату һәм эчү өчен бик гади җиһазлы махсус бина. *[Нигъмәтҗан] эш булмаса, кабак алдына барып, тамчылап, соранып эчте.* Ә. Фәйзи (ТТАС, II: 7).

Татар диалектларында *кабак* термины төрле мәгънәләр аңлата: *кабак* мишәр диалектында капканы (ворота) белдерә: *Кабакны йап, йаwып цык;* сергач сөйләшендә: *Кыдалар килде кабакка, кыз терәлде кабага* (мәкаль); ләмберә сөйләшендә: *Бак, кабакны ач, куйлар килә. Арт кабакны йил кайырган;* темников сөйләшендә: *Сорап тормады ул, кабакны ачты да чыгып китте.* 2. ләмберә сөйләшендә йорт, өй, хуҗалыкны белдерә (чаг.: азбар). 3. ләмберә сөйләшендә дә шулай: *Менә каршы кабак йанды. Каршы кабакта гына тыра ул.*

*Ач кабак* дип кычкыру кузнецк сөйләшендә егет йортының капкасын ачтыру: *Ач кабак, акча сип дип кычкыралар, аннан туйны кергезергә тотоналар.*

*Кабак эс[те]* мишәр диалектында капка төбен аңлата: *Машина кабак эстенә килеп туктады* – хвалын сөйләше; *Кабак эстә утырыр идегез – ләмбрә* сөйләше.

*Кабаг эстенә чыгу* корсун (Ульяновск өлкәсе), кузнецк сөйләшләрендә капка төбенә чыгып утыру: *Йазны егетләр килмиләр, йазны (кызлар) кабаг эстенә чыгалар.*

Наҗия Борһанова мәгълүматларына караганда, *кабак* атамасы алган җыен да булган. *Кабак җыены.* «Бу җыенны июль уртасында, печән чабу вакытында Алат һәм Гәреч (Галицкая дорога) юллары өстенә урнашкан Айбаш, Чуваш иле, Зур Кавал, Кече Кавал, Олы Күлбаш, Кече Күлбаш, Маҗар, Мәмдәл, Йуртыш, Яңавыл, (Яңа авыл), Чүрчиле, Упса башы авыллары халкы бәйрәм иткән».

1930 елларда бу җыен, үткәрү вакыты авыл хуҗалыгы эшләре кызган вакытка туры килгәнгә, күрә Биктау~Биектау җыены белән берләштерелгән һәм шуннан соң ул Биктау~Биектау

җыены үткәрелгән вакытта, ягъни июль башында үткәрелә башлаган.

Археология мәгълүматларына караганда, Казан ханлыгы чоры археологик һәйкәлләре Кабак җыены үткәрелгән җирлектә урнашкан Мәмдәл, Айбаш, Чуваш иле авыллары зиратларында табылган (Археологическая, 1981: №№ 1, 2, б. 118). XVI гасырның уртасында *Кабак җыены*ның үзәге Казансу тамагында урнашкан булса кирәк. Бу гөманлау авыл халкы телендә сакланып калган легенда-риваятьләр белән дә дәлилләнә (Наҗия Борһанованың 1966 елда оештырылган экспедиция-сәфәрләр вакытында халык теленнән язып алдынган мәгълүматлары шул хакта сөйли). Биектау районында урнашкан Зур Кавал авылы халкы элек Карабай бистәсендә яшәгән (хәзерге Казан шәһәренең Авиатөзелеш районындагы бистә-посёлок). Элгәреге Казан чорыннан ук килә торган мәгълүматлар тупланган архи әһәмиятле чыганакларда, «Татарстан АССР тарихы турында материаллар. 1565–68 һәм 1646 еллардагы Казанның теркәү кенәгәләре» («Материалы по истории Татарской АССР. Писцовые книги города Казани 1565–68 и 1646 г. Л., 1932») кебек теркәү-язу кенәгәләрендә, XVI–XVII гасырларга нисбәтле рус чыганакларының башкаларында да, Н.Ф. Калинин тарафыннан төзелгән һәм кушымта итеп бирелгән картада да ныгып калган географик берәмлек «Кабак капкалары» *Кабак җыены* белән бәйләнешле».

«Миллият сүзлеге» дип аталган әһәмиятле хезмәтне дөньяга чыгарган Адлер Тимергалин *кабак* терминын болай сыйфатлый:

*Кабак* – тарихи лексик берәмлек. *Беренче мәгънәсе*: Борынгы татар телендә – кальга капкасы, диалектларда – гомумән капка. // Кабак теп – капка төбе. Кайбер төбәкләрдә *кабак өсте – капка төбе. Кура кабак. Такта кабак. Икенче мәгънәсе*: Йорт, өй. Хуҗалык. // *Кабак башында дранча, Өстәл өстендә суланча* (тоз савыты). Борынгы җырдан. *Өченче мәгънәсе*: Магазин, хәрчәүнә; мәйханә.

Р. Әхмәтьянов, кабакның соңгы мәгънәсе борынгы телебездә булмаган, ул рус теленнән килә, дип саный. Шулай да Мәхмүд

Кашгари *кибет* сүзенең җирле (Урта Азия) төркисендә «шәраб сата торган урын, кабак» мәгънәсен теркәп калдырган (XI гасыр). Ә рус телендә бу сүз XVI гасыр урталарыннан очрый башлый һәм рус галимнәре аны татардан алынган сүзләр рәтенә кертәләр (Прыжов, 2009). М. Глухов *кабак* сүзе татарча *кабау «*куырдык, шашлык, кәбаб» сүзеннән дип яза. Алабуга керәшеннәрендә *кабак* дип, гомумән, аракыга әйткәннәр (*Хатыннарга пыйала белән тәгәрәтеп җибәрә кабакны*).

1545 елда рус гаскәре Казанда хан кабакларын яндырган (рус елъязмасы «И кабаки царевы пожгли» дип хәбәр итә). Бу сүз кереп урнашканга кадәр рус телендә *корчма* сүзе йөргән. Тагын шунысы мәгълүм: Мәскәүдә беренче кабак 1552 елда, Казан яулап алынганнан соң, патша әмере буенча ачыла. Явыз Иван халыкка аракы эчүне тыйган, аны опричникларына гына эчәргә рөхсәт иткән һәм Мәскәүдәге «Балчуч»та (татарча *балчык* сүзеннән; күрәсең, ул урам сазлы һәм пычрак булгандыр) кабак дип аталган махсус йорт салдырган. Шул рәвешле, Казанны талап алып кайткан алтын-көмеш ахыр чиктә патша казнасына барып керә. Кабакның казна өчен файдасын күргәч, Иван патша башка өлкәләрдә дә элекке «ирекле» корчмаларны бетереп, «патша кабаклары» ачарга боера. «Татар кабагында, мөсафирханәдәге кебек үк, ашарга-эчәргә мөмкин булса, Мәскәү кабагында фәкать эчәргә генә мөмкин булган» (Прыжов, 2009). Гади халыкка – крестьяннарга һәм бистәнекеләргә өйдә исерткеч эчемлек ясау тыелган, һәм алар шушы кабакларга йөрергә тиеш булганнар. Кыскасы, Россиядә исереклек менә шушы Явыз Иван кабагыннан башлана дияргә мөмкин. 1894 елдан Россиядә аракы сату тулысынча дәүләт кулына күчә.

*Кабак* лексик берәмлеге белән ясалган атамалар татар топонимиясендә шактый очрый: *Кабак байы болыны* – Биектау районы Чуваш иле янындагы болын атамасы. *Кабак җыйыны* – Яшел Үзән районы Кече Карауҗа авылы янында. *Кабак кыры* – Апас районы Акъегет авылы янындагы басу, кыр атамасы. *Кабак урамы* – Спас районы Ямбакты авылының бу урамында кабак

булган. Исем шуннан калган. *Кабак суы чишмәсе* – Мәтәскә суы бассейны (Югары Мәтәскә авылы Теләче районы). *Кабак суы* – Шәмәк елгасы бассейны. Арча районы Япанчы авылы янында. *Кабак елгасы* – Бакырлы суы кушылдыгы. Чүпрәле районы Алешкин Саплык авылы янында. *Кабак елгасы кизләве* – Чүпрәле районы Алёшкин Саплык авылы янында. *Кабак күле* – Сөн елгасы бассейнында, Актаныш районы Кәзкәй авылы янында. *Кабак күпере суы* – Зөя елгасы кушылдыгы. Яшел Үзән районы Мулла иле авылы. *Кабаклы елга* – Петьялка елгасы кушылдыгы. Биектау районы Юртыш авылы янында. *Кабак сазы* – Кече Чирмешән елгасы бассейны. Әлки районы Иске Алпар авылы янында. *Туктар кабагы* – 1. Ашыт елгасы бассейны. Олы Әтнә авылы Әтнә районы. Туктар исемле кешегә мөнәсәбәтле атама; 2. Иске Мәңгәр авылы янындагы урын атамасы. Әтнә районында. Татарстаннан читтәге төбәкләрдә яши торган татарлар телендә бу термин белән атамалар шактый кулланыла. Башкортстан татарлары телендә *кабак* термины белән ясалган атамалар очрый. *Канлы кабак* – Хәйбулла районыннан агып үтә торган Туратка елгасының сул кушылдыгы. *Кабак* – Башкортстанның Кырмыскалы районындагы бистә атамасы. Самара өлкәсендә *кабак* – чокыр. Ул Усолье һәм Березовка авыллары арасындагы тоз тауларында урнашкан. «Бу атама нигезендә „сөзәк җир, сөзәк урын, текә яр, куе үләнле тирән чокыр“ мәгънәсендәге төрки сүз *кабак* ята» (Барашков, Дубман һ. б., 1996: 102).

Татар теленең Оренбург татарлары сөйләшендә *тау кабагы* – тау битен белдерә (ТТДС, 1969: 185). В.В. Радлов сүзлегендә *кабакның* кара-кыргызларда «тау бите, яр кырые, яр» төшенчәсендә йөрүе күрсәтелә. *Кабак* сүзенең кыргыз телендәге мәгънәләре: 1) тау кашы өстендә дуга сыман урын; 2) сикәлтә, чокыр, батынкы җир. Казакларда *кабак* – күл яки елганың биек яры, упкын өстендәге текә яр; башкортларда *кабак* – елга кырыендагы текә яр; тыва халкында *хавак* – маңгай, калкулык кечкенә тау; хакас телендә *хамак* – «маңгай»; үрәнхәй телендә *кабак* – таучык, кечкенә тау (т. II, ч. 1: 435).

Таулы Алтай топонимиясендә *кабак* сүзе аерым бер географик объект атамасы булып та кулланыла ала. Көньяк Алтайда *кабак* – «тигез түбәле, озын сөзәк тау бите» төшенчәләрендә йөри. Алтайда бу термин географик атамалар ясауда актив кулланыла (мәсәлән, *Кабак, Бийик кабак* таулары, *Байкабак* елгасы һ. б. (Молчанова, 1973: 64–65). Тыва телендә *хавак* «зур булмаган тау» (төп мәгънәсе – маңгай). Анда *Чайлаг-хавак* исеме алган уйсу урын бар (*чайлаг* «җәйге көтүлек», *Даштыг-Хавак* (*даштыг* «ташлы»), ягъни *Ташлы Хавак, Ишты-Хавак* (*ишти* < эчке) (Розен, Малолетко, 1986: 44). Казакстанда *кабак* – елганың һәм күлнең биек яры, текә яр, упкын өстендәге кәрниз, тау киртләче. Бу апеллятив географик атамалар составында еш кулланыла: *Аккабак, Каракабак* һ. б. (Конкашпаев 1963: 18). *Кабак* компонентын эченә алган атамалар күп урыннарда очрый: Тянь-Шанда – *Кавактау* (тау), Ош өлкәсендә *Кабак* атамасы алган торак пункт һәм *Каракабак* елгасы бар. Азәрбайҗанда *Габагтепа* тавы һәм *Кабаклычай* елгасы теркәлгән. Кабарда-Балкар төбәгендә *Орта-Кабак, Тебен-Кабак, Аман-Кабак* исеме алган географик берәмлекләр бар. Омск өлкәсендә *Кабах* елгасы, Якутиядә (Сахада) *Кабах, Кабах-Сайылыга* елгалары ага. Тыва микротопонимиясендә *Чайлых-Хавак* һәм *Даштыг-Хавак* һәм Чарджоу өлкәсендә басу уртасында калган урман яисә күлләр исәпкә алынган (Мурзаев, 1984: 743).

***Кабакчы*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «искергән исем» дип бирелгән һәм «кабак (III) тотучы» дип аңлатылган // сыйфат мәгънәсе: *Кабак янында беркем юк. Кабакчы хатын белән ялгыз калды тик тал гына, Тибрәнеп акрын гына.* М. Җәлил. (ТТАС, II: 7).

***Кабырга***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлекнең күчмә мәгънәсе болай күрсәтелә: «Берәр урынның кабырга сыман калкуланып торган җире». *Бераз эзләп йөргәннән соң, [Габделкаюм] бер кабыргада әле бер дә кеше кулы тимәгән җиләклек тапты*. М. Гали (ТТАС, II: 30).

*Кабырга* термины топонимнар ясауда кулланыла: *Кабырга елгасы* – Балтач районы, Иске Чепья авылы янында, Арбор// Урбар елгасы бассейнында; *Кабырга тау* – Балтач районының Нормабаш авылы янында. Бу тау кабыргага охшаган; Биектау районының Ташлы Кавал авылы янындагы тау. *Шәм кабыргасы* – Буа районы Черки Кильдураз авылы янындагы калку урын атамасы.

*Кабырга* термины әдипләребез иҗатында еш очрый.

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында тау кабыргасы гыйбарәсе гүзәл итеп сыйфатлана: *«Элекке заманнарда илгә дошман явы ябырылгач, Алып бабай җиде улының җидесен дә сугышка озаткан. Бер улы киткән саен, тау кабыргасына бер тибә, типкән саен бер чишмә чыгара икән».*

***Кала***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *кала* «исем дип» ныгытылган, «сөйләм телендә» дип күрсәтелгән, аңлатмасы: шәһәр. *Бистәләрне узып, кырга чыктык, Калды, калды Казан каласы*. Ш. Маннур (ТТАС, II: 29).

*Кала* лексик берәмлеге татар халкының борынгы бәйрәмнәре җыеннар атамаларында да очрый. Нажия Борһанова мәгълүматлары күрсәтүенчә, *Калатау җыенын* халык яратып үткәргән.

*Калатау җыены.* Бу җыенны июньнең беренче декадасында Шимбер җыены үткәрелүнең икенче атнасында уздырганнар. Җыен Ашыт елгасының уң кушылдыклары Үртәм һәм Күәм елгалары тирәсенә урнашкан. Күәм, Әйшиясты, Үртәм, Казак Үртәме, Күлле Киме ~ Киме, Җилгелде ~ Җигелде, Бактачы, Каенсар авыллары халкының күңел ачу, ял итү бәйрәме булган.

Археологлар мәгълүматларына караганда, Әйшиясты белән Күәм авыллары арасында, Ашытның биек яры тирә-юнендә әҗеле (азелинская) һәм элгәреге татар культурасына мөнәсәбәтле әйше шәһәрлеге, зират-каберлек табылган. *Җыен* атамасы да шушы археология һәйкәлләренә нисбәтән барлыкка килгән булса кирәк.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда: «Казансуның югары агымында – Кесмәс һәм Кече Мишә елгалары

үзәнлегендә урнашкан авылларда июньнең уртасында, Күпербаш җыенын бәйрәм иткәннән соң ике атна үткәч, Калатау җыен-бәйрәмен Курсабаш, Мичәнбаш, Олыяз, Пүкәл, Өтернәс, Эзмә, Иске Шекше, Алан-Елга, Яңа Шекше, Мишәбаш, Явлаштау, Сәрдә, Иләбәр, Көек, Кызыл-Мишә, Бөкмеш авыллары халкы бергә җыелып уздырганнар, күңел ачканнар.

Археологлар фикеренә караганда (Фахрутдинов, 1975; Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье, 1981), Эзмә һәм Өтермәс авыллары янында болгар-татар археологик һәйкәлләре һәм җыенга исем биргән Өтернәс шәһәрлеге бар.

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *кала* термины болай аңлатылган: «Гарәпчә кальга сүзеннән («Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә – курган, крепость, ныгытма, замок, цитадель). Борынгы төрки телдә *кала* – шәһәрнең ныгытылган өлеше, цитадель; шәһәр («Кремль»гә һәм русча «детинец» мәгънәләренә дә туры килә). *Каланча* сүзе дә шул тамырдан.

Азәрбайҗанда *Кала* дигән шәһәр бар. Топонимист В.А. Никонов аның атамасы фарсы телендәге *кала* «калкулык, калку җирдәге ныгытма» дип аңлата. Таулардагы ташкыннарны бездә «ташкала» дип тә атыйлар. Харәземдә «эчке ишегалды булган һәм диварлар белән әйләндереп алынган торак» дип тә атала (Мурзаев). // *Калага барган кешедән өч көнгә акыл сорама*. Бу әйтемдә *кала* сүзе «мәдәни шәһәр» мәгънәсендә килә. *Мәскәү каласы ташкала, башкаларга баш кала*. Совет чорындагы җырдан. *Терк-Кала* – чеченнар Владикавказны шулай атап йөртәләр (атама *Терек* елгасы исеменнән). *Чефет-кала* (Кырымда), *Кайсар-кала* – Царьград. Тагын кара: Кальга, Кремль».

*Кала* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда еш кулланa: *Кала асты* – Әтнә районы Күәм авылы янындагы урын атамасы. *Кала асты елгасы* – Күәм авылы Арча районы. Күәм елгасы бассейнында. *Кала башы* – Яңа Чишмә районы Тубылгытау авылы янындагы урын атамасы. *Кала борыны* – Яшел Үзән районы Мулла Иле авылы янындагы урын атама-

сы. *Кала як баз* – Саба районы Иске Мичән авылы янындагы урын атамасы. *Кала асты* – Әтнә районы Күәм авылы янындагы урын атамасы. *Кала юлы* – 1. Саба районы Керәнне авылы, 2. Кама Тамагы районы Югары Барыш, 3. Кама Тамагы районы Яңа Сала авыллары янындагы юл атамалары. *Кала тавы урлары* – Аксубай районы Шәрбән авылы янындагы урын атамасы. *Кала тау урманы* – Саба районы Эзмә авылы янындагы урман атамасы. *Кала тавы елга*сы – Арча районы Түбән Аты авылы янындагы Аты елгасы бассейнында. *Кала тау* – 1. Сарман районы Каташ Каран, 2. Биектау районы Мәмдәл, 3. Мамадыш районы Уразбахты авыллары янындагы таулар атамасы. *Кала сазы* – Әлки районы Иске Камка авылы янында, Кече Чирмешән елгасы бассейнында. *Кыз кала асты* – 1. Балык Бистәсе районы Яншык авылы, 2. Аксубай районы Яңа Ибрай авылы яннарындагы урын атамалары. *Кыз кала асты сырты* – Аксубай районы Яңа Ибрай авылы. Урын атамасы. *Кыз кала асты елгасы* – 1. Бәтке елгасы бассейнында, Балык Бистәсе районы Яншык авылы, 2. Сөлчә елгасы бассейнында, Аксубай районы Яңа Ибрай авылы. *Коллар каласы* – Лаеш районы Имәнкискә авылы янындагы урын атамасы. *Иске кала йулы* – 1. Теләче районы Алан авылы, 2. Питрәч районы Кибәче авылы янындагы юллар атамасы. *Иске кала йылгасы* – Саба районы Кызыл Мишә авылы янында, Кече Мишә елгасы бассейнында. *Ислам каласы* – Саба районы Олыяз авылы янындагы тау атамасы. *Кече кала* – Аксубай районы Шәрбән авылы янындагы урын атамасы.

*Кала* лексик берәмлеге әдипләребез иҗатында шактый файдаланыла. Вахит Имамовның «Утлы дала» романында *кала* лексик берәмлеге еш кабатлана: *«Кашан каласына терәлеп торган яр буенда эреле-ваклы, җилкәнле-ишкәкле дистәләгән каек һәм көймәләр сырып алган иде».*

Марсель Галиевнең «Рух» китабында *кала* лексик берәмлеге еш очрый: *«Атилла ни өчен Рим каласын җимертмәгән? Бу сорау Рим каласының һәр ташына күзгә күренмәгән чөй-язулар итеп уелган.*

*Шәһәрләр шәһәре – Рим исән, ул мәңгелеккә вәгъдә итеп яши бирә. Шушындый мәшһүр каланы, кагылынмаган килеш, уналты гасыр аша бүгенге заманга чөйгән зат һуннар юлбашчысы даһи Атилла булыр».*

***Калку***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «сыйфат» дип ныгытылган һәм түбәндәгечә сыйфатланган: «Күтәрелеп торган, калкып торган». *Калку кырларда хәтфәдәй яшел уҗымнар күренде*. Г. Гобәй. *Урманнан чыгып сөргән җир арасыннан бер калкуга күтәрелдек*. Ф. Кәрим (ТТАС, II: 31).

***Калкулык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем» дип күрсәтелгән һәм түбәндәгечә аңлатылган: «Тирә-юнь белән чагыштырганда биегрәк булып, күтәрелеп торган урын». *Нуруллин калкулык итәгенә таба киткән иптәшен күрергә теләде, ләкин аны таба алмады*. А. Шамов. // географик термин. *Диңгез өсте тигезлегеннән 200 метр чамасы биек булган урын. Идел буе калкулыгы Урта Рус калкулыгы* (ТТАС, II: 32).

Калку, калкулык берәмлекләре географик атамалар ясауда кулланылалар: *Калкулыктагы чишмә* – Биектау районы Селәнгер авылы янындагы чишмә (бу авыл күптәннән бетте инде). *Таган өсте калкулыгы* – Арча районының Казанбаш авылы янында. *Мари калкулыгы* – Балтач районы Яңгул авылы янындагы калкулык атамасы. *Мар калкулыгы* – Чистай районы Яуширмә авылы янындагы калкулык атамасы. *Биш кул калкулыгы* – Сарман районы, Шәрләрәмә авылы янындагы калкулык атамасы. *Калку болынлык* – Балтач районы Кариле авылы янындагы калкулык җиргә урнашкан болын. *Калку урман* – Арча районының Ябынчы авылы янындагы элекке урман. *Имәнле калкулык* – Балтач районы Пүскән авылы янындагы калкулык атамасы һ. б.

*Калку, калкулык* лексик берәмлекләре әдипләребез иҗатында очрый. Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында мондый юллар укыйбыз: *«Сул яктагы калкулыкта кечерәк кенә бер авыл шәүләсе күренде».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» исеме алган повестенда *калкулык* термины дөньяга карашны киңәйтә: *«...Яшен уты калкулыкны ярата, диләр».*

Вахит Имамовның «Сәет батыр» исеме алган тарихи повестенда мондый юллар бар: *«Куе кылган каплаган иксез-чиксез дала буенча барып, бер якта дөя өркәчләре сыман калкып торган биек тау янына җиткәч, Сәет аргамагын текә калкулык өстенә юыртып менде дә уң кулын гайрәтле рәвештә югарыга чөеп, сугышчыларына тукталырга ишарә ясады»; «Ул [Габдрахман] күл буендагы калку гына бер түмгәк артына ышыкланып утырды».*

Айдар Хәкимнең «Кыйбла: хикәяләр, новеллалар» китабында *калкулык* термины шактый еш очрый. *«Бәләбәй–Бөгелмә калкулыклары... Җир асты сулары урталай бүленеп, чишмә-чыганаклар калкулыкларның иң биек тәңгәлләрендә яралып, бары тик көньяктан төньякка, төньяктан көньякка гына ага бу тирәләрдә».*

Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» дип аталган романында *калкулык* лексик берәмлеге очрый: *«Баланың гәүдәсен бераз читкә, Урал суы буендагы калкулыкка алып киттеләр».*

Роза Хәбибуллинаның «Мулла килене» романында *калкулык* лексик брәмлеге матур кулланылган, алдан ук бу роман күңелгә бик ошый торган булырга тиеш дигән фикер уята: «*Зур калалардан, олы юллардан бик еракта, калкулыклар ышыгында, урманнар уртасында утырган Көнкүрмешкә яз килде».*

Нурислам Хәсәновның «Сагыш» исеме алган китабыннан мондый җөмлә укыйбыз: *«Әнә бер читтә, калкулыктарак утырган, моңарчы тын гына гомер кичергән авыл яна».*

***Кальга.*** «Миллият сүзлеге»ндә Адлер Тимергалин кальганы болай бирә: «Кала, курган, ныгытма, кирмән, хисар (гарәп алынмасы); кремель, замок (рус алынмасы) (басым беренче иҗеккә төшә, асылда, йозак мәгънәсендәге сүз, немец теленнән үзенчәлекле калька), цитадель, форт. // Кальгатус – силми вә тәкаддүмч – тынычлыкның һәм үсешнең нигезе (таянычы, терәге, ныгытмасы)».

*Кремль* – «Шәһристан, цитадель, кальга, ирәк». Мәскәүдә Кремль 1339/40 елның кышында «Кәлтәле Ибан» тарафыннан имән бүрәнәләрдән төзелә, чөнки элекке крепость инде бик нык тузган була. Ләкин кремль төзү өчен, Мәскәү кенәзе Алтын Урдадан рөхсәт алырга тиеш булган. Шуңа күрә Мәскәү Кремле төзелешендә Алтын Урда ханнарының ихтыяры зур роль уйнаган дип әйтә алабыз. Кремль сүзенең төрки чыгышлы булуы турындагы гөман да шактый нигезле. Кремль сүзе рус теленә монгол-татарлар хакимлеге чорында гына керә, ә аңа кадәр шәһәр (мәс., Новгород) эчендәге кальганы (цитадель) руслар «детинең» дип йөрткәннәр. Рус елъязмаларында *кремль* сүзе кремник язылышында 1331 елда гына очрый.

Тарихчы М. Худяков *кремль* сүзенең рус теленә татар теле аша кергәнлегенә шикләнми. Ихтимал, кремль сүзенең килеп чыгышы монголча *хэрэм* – стена, дивар сүзенә бәйледер. Аның этимологиясен *кырым* һәм *кору* сүзләре белән бәйләргә омтылыш та бар. Ә бәлки бу очракта *кирмән* сүзенә таяну отышлырактыр.

Борынгы татар телендә «кремль» мәгънәсендә *ирәк* сүзе кулланылган. Казан Кремле борынгы кальга мәйданын били, ләкин биредә ханлык дәвере корылмалары калмаган диярлек. Фәкать Сөембикә манарасын һәм аның янындагы чиркәү «Введенская церковь»(церковь «Сошествия св. Духа» һәм 1854 еллардан «Дворцовая церковь» исеме белән билгеле) бинасын гына мәгълүм дәрәҗәдә ханлык чорына нисбәт итәргә мөмкин («Мөрәли мәчете»). Кремль капкалары һәм кайбер манаралар элекке урыннарын һәм исемнәрен саклаганнар дияргә ярый.

Казаннан һәм Мәскәүдән кала, руслар тарафыннан төзелгән кремльләр Түбән Новгородта, Псковта, Тулада, Ростовта, Смоленскида, Серпуховта һәм Әстерхан шәһәрендә билгеле».

***Камыш***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем» дип ныгытылган һәм түбәндәгечә аңлатма бирелгән: «Сазлыкларда үсә торган кыяклы биек үсемлек». *Утраулар куе соры тал һәм киң-киң кыяклы камышлар белән*

*капланганнар*. М. Әмир. *Күлне сыйпап җил исә, Тибрәнеп камыш үсә*. Ф. Кәрим (ТТАС, II: 38).

Югарыда аталган сүзлектә *камыш* сүзенең *өченче мәгънәсе:* «зифа, төз (кеше гәүдәсе турында)». *Ялтыр күзле, кара чәчле, тулы канлы, камыш буйлы бер егет, кулындагы камчысын уйната биреп, көлә-көлә нидер сөйли иде*. Г. Ибраһимов (ТТАС, II: 38).

***Камышлы***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *камышлы* сыйфат дип бирелә һәм түбәндәгечә аңлатыла: «камышы булган, үзендә камыш үскән». *Кайбер урыннарда өерле таллар арасында кечерәк кенә камышлы күлләр дә күренеп алалар*. М. Гали. *Сибай камышлы вак-вак утраулар арасыннан борып-сарып [көймәне] җиңел генә алып бара*. А. Гыйләҗев (ТТАС, II: 38).

***Камышлык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *камышлык* – «камыш (күп) үсә торган урын». *Миус елгасы буендагы камышлыкларга кадәр траншея казылды*. И. Гази (ТТАС, II: 38).

*Камыш, камышлы, камышлык* лексик берәмлекләре географик атамалар ясалышында шактый киң кулланыла.

*Камыш елгасы* – Зәй районының Кабан-Бастырык авылы яныннан ага торган Аулаш елгасы кушылдыгы; *Камыш күле* – Минзәлә районының Боерган авылы янындагы болын атамасы (күрәсең, элек анда күл булган, ул кипкәннән соң, урыны болын булып калган); *Камыш үзәк чокыры* – Апас районының Дәвеш авылы янындагы коры елга атамасы; *Камыш чишмәсе* – Аксубай районы, Иске Кармәт авылы янындагы Кирәмәт елгасы бассейнында. *Камышлы елга* – Зәй районы Кәрәкәс авылы янындагы, Аулаш елгасы бассейнында һәм Биектау районының Зур Битаман авылы яныннан ага торган Ашыт елгасы бассейнында; *Камышлы күл* – Актаныш районының Куян авылы янында, Агыйдел елгасы бассейнында; *Камышлы саз* – Биектау районы, хәзер беткән Әсән авылы яныннан ага торган Ашыт елгасы бассейнында; *Камышлы сазлык* – Балтач районы Яңгул авылы тирәсеннән агып үтә торган Шушма суы бассейнында. *Кече камышлы* – Әлмәт районы Камышка авылы янында,

Сәрәпәле елгасы бассейнында. *Камышлык бакалы* – Буа районының Карлы авылы янынннан ага торган Карлы елгасы бассейнында; *Камышлык елгасы* – Чүпрәле районының Кече Аксу авылы янынннан ага торган Аксу буе елгасы кушылдыгы; *Камышлык рәте* – Кукмара районындагы Вахит авылы янындагы урын атамасы.

*Камыш* сүзенең икенче мәгънәсе Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романында болай ныгытылган: *«Җырлаганда казакъның акыннары аның зифа буен төз камышка охшаталар, билең нечкә, күзләрең тирән, керфекләрең уктай, үзең айдай, дип мактыйлар иде».*

*Камышлы* елгасы атамасы Гомәр ага Бәшировның «Намус» романында очрый: *«Камышлы елгасы буйлатып, яшәрә башлаган тау кырыеннан, акрын гына сыер көтүе үтеп бара».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» повестенда мондый юллар бар: *«Камышларга сыенып күл буенда ут чәчәкләре томаланып утыра иде». «...Урман артында күк гөрелтәгәне ишетелде, кинәт кенә дымлы җил исте, шаян дымлы җилгә ут чәчәкләре шом белән бөтерелделәр, камышлар ыңгырашып куйды».*

Фоат Садриевның «Таң җиле» романында *камыш* лексик берәмлеге әсәрне үзенчәлекле итеп, күңелне әллә нишләтеп, кошлар белән кешеләр бәйләнешендәге каршылыкларны күрсәтеп тасвирларга ярдәм иткән: *«Ана үрдәк мөмкин кадәр тирәнгәрәк чумды, әмма барыбер төпкә үк төшеп җитә алмады – су аны күтәрә башлады. [Аңа бер ир аткан]. Мәңге өскә күтәрелмәс өчен ул бер камыш сабагын капты һәм казналары белән җан көченә кысты...»*

*Камышлык* – Вахит Имамовның «Сәет батыр» атамасы белән дөнья күргән тархи повестенда очрый. *«Селәүсен кебек йомарланып, егет күл буена алып килә торган юлдан беркадәр читкәрәк, куе камышлыклар эченә кереп ятты». «...Дага авызында өч-дүрт йөзгә якын җайдак җыелып тора, ә калган бар сугышчы таулар уртасындагы түгәрәк күл буена, һәртөрле*

*камыш, саксаул агачлары, эреле-ваклы ташлар артына посып яткан иде».*

Шул авторның «Утлы дала» исемендәге тарихи романында *камыш* лексик берәмлеге болай бирелгән: «*Камышлар* арасыннан ара-тирә сөрән салган үрдәк, казгыш, торна тавышлары гына түгел, дулкыннан дулкынга сикереп уйнаган чөгә, чабак, корбан балыкларының чупылдавы да Онон өстендә яңгырап ишетелә».

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *камыш* лексик берәмлеге рус теленә төрки телләрдән алынган алынма. Камыш кирәгеннән артык дымлы һәм юеш урыннарда күп үсә. Безнең илебездә камышның 30 төре бар. Борынгы төрки сүзлектә *qamiš, qamuš* «тростник, кыяклы ашлык, кыяклы үсемлекләр, күрән, камыш» дип бирелгән. Төркиләрдән алынган *камышатник* лексик берәмлеге әлегә кадәр сакланып калган һәм ул камыш куе булып үскән күлне аңлата һәм бу күлләр Кара туфраклы үзәк төбәкләрдә сазлыкка әйләнгәннәр. Себер халкы телендә кулланыла торган *камышло* лексик берәмлеге – «куе камыш үскән урын, баткаклык, камышлы, уйсу яр». Камыш лексик берәмлеге Россиянең Кавказ, Идел буе төбәкләрендә, Урал, Алтайда, Урта Азиядә, Казакстанда, Кавказ арты дәүләтләрендә һ. б. төбәкләрдә күл, елга, торак пунк атамалары буларак бик актив кулланыла. Әйтик, *Сарыкамыш күле* Төрекмәнстанның бер су да килеп кушылмый торган тирән үзәнендә, диңгез тигезлегеннән шактый түбәндә урнашкан. Чувашча *хамаш* «камыш» лексик берәмлеге *Хумашвар чокыры* атамасында кулланылган (Нестеров, 1980: 45). Якутча *хамус* термины торак пункт – *Хомустаг* атамасын оештыруда катнашкан.

Кыргыз топонимиясендә *камыш* лексик берәмлеге шактый кулланыла: *Сары-Камыш* – Нарын өлкәсе Кочкор районында, ага торган Кочкор елгасының уң кушылдыгы. *Сары-Камыш* таулары шул ук өлкәнең Джумгал районында. *Сары-Камыш* авыллары – Ыссык күл өлкәсенең Ыссык күл һәм Аксу, Ош

өлкәләренең Ленин, Нарын өлкәсенең Джумгал районнарындагы авыллар.

***Капка***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *капка* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм аның мәгънәсе болай аңлатылган: корылма, стена, койма һ. б. ш. урыннарда кереп-чыгып йөрү өчен махсус эшләнгән ачыклык һәм шул кереп-чыгып йөрү урынын ябу өчен тупсалы җайланма. *Шул вакыт завод капкасыннан бик күп кешеләр күренде*. А. Алиш. *Бер көтү малай, тупырдашып, басу капкасына таба йөгерә иде*. И. Гази // Күчерелмә мәгънәдә, сөйләмдә: хуҗалык. *Капка рәтеннән көтүгә бер сыер яки алты баш сарык яки ике кәҗә җибәргән кешедә иртә, кич берәр тапкыр ашыйбыз*. М. Гали (ТТАС, II: 45).

Соңгы очрактагы капканың мәгънәсе географик атама белән дә бәйләнешле булырга мөмкин. Капка – хуҗалыкка мөнәсәбәтле лексик берәмлек.

*Капка* казан арты минзәлә, каргалы (Оренбург өлкәсе), тепекәй (Башкортстан) сөйләшләрендә – хуҗалык, йорт (хозяйство, дом). *Өчйөз алтмыш қапқа бу аwылда* – балтач сөйләше. *Әз генә, ди, безнең аwылыбыз: әллә унсигез, әллә унтугыз гына қапқа. Дамбаста эшләдем, хат килә: унҗиде қапқа җандык, дип* – мамадыш сөйләше. *Албайда йөз ун қапқа җанды бер җылны* – Казан арты керәшен сөйләше. *Бездә ике йөз илле қапқа булган* – лаеш сөйләше. *Мында Казан ягыннан да булган, биш йөз илле қапқа булган* – каргалы сөйләше. *Уналтынчы йылны җитмеш қапқа йанды* – минзәлә сөйләше. *Йитмеш қапқа йандык бед* – тепекәй сөйләше.

*Арата капка* минзәлә сөйләшендә – *киртә капка* (ворота из жердей).

*Қалай қапқа* дип бөре, минзәлә сөйләшләрендә урыс капканы (тесовые ворота со скатной крышей) атыйлар.

*Қамыш қапқа* әстерхан сөйләшендә – камыштан үргән җил капка (ворота из камышей).

*Қапқа эце* – бараба диалектында ишегалды.

*Қәртә қапқа* – пермь сөйләшендә арата капка.

*Тақта қапқа* – минзәлә сөйләшендә калай капка. *Тақта қапқасының башын сүтеп алган, машина керәлми апқайтканда дип.*

*Тимер қапқа* – әстерхан сөйләше, *урысча қапқа* – минзәлә сөйләше: к.: қалай қапқа (ТТДС, 2009: 388).

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, *капка* лексик берәмлеге җыен атамалары составында да кулланыла. *Кушкапка җыенын* Сулы һәм Сая (Казансуның уң кушылдыклары) ярына утырган Зур Битаман, Кече Битаман, Ювас, Әсән, Бикнарат, Кодаш, Зур Көек, Олы Рәс, Кече Рәс авыллары халкы июнь ахырында бергә җыелып үткәргәннәр. Җыелып күңел ачу җыенының атамасы *Кушкапка* Зур Битаман авылы янындагы Кушкапка исемен йөрткән тауга нисбәтән барлыкка килгән. Халык телендә сакланган риваятьләргә караганда, бу урында ныгытылган җирле үзидарә булган. *Кушкапка* җыенының икенче исеме *Кушнарат,* шулай ук, географик атама исеменнән алынган.

*Кушкапка* исемендәге җыен Тау ягы төбәгендә дә үткәрелгән. Тау ягы белән Казан арты нык бәйләнгән.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, *Кушкапка* зур җыен исәпләнгән һәм аны арыш серкә очырган вакытта – июнь урталарында Зөя елгасының сул кушылдыклары Бола һәм Чирмешән елгалары бассейнына урнашкан Югары Балтай, Түбән Балтай, Зур Бакырчы, Кече Бакырчы, Кара Борнаш, Чирү, Каратун, Колчык, Көлкәш, Чирмешән, Чәтбаш, Коллар, Шәмәк, Күкшем, Тутай, Аксу, Дәүләки, Багыш авыллары халкы үткәргән.

Р.Г. Фәхретдинов белдергәнчә, җыен үткәрелә торган урында монгол чорларына кадәрге вакытларга нисбәтле шактый гына археологик истәлекләр урнашкан. Боларга Бигеш, Чирмешән, Иске Көлкәш, Кызыл Тау авыллары җирлекләре керә (Фахрутдинов, 1976: №№ 1508–1517).

Җыен атамасы *Кушкапка* – «пар капка» мәгънәсен аңлата һәм ул ниндидер ныгытылган пункт яисә ныгытылган шәһәрлек булып, күрсәтелгән авылларның үзәге булган күрәсең.

*Капка* лексик берәмлеге Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә болай дип бирелгән: «*Капка* – искечә *капу, капугъ*

(күк капусы ачылу сүзендә сакланган). Чыгышы – *каплау* сүзеннән. *Кап, капкач* сүзләре дә шул тамырдан килә. Сөйләшләрдә – *кабак* (күк кабагы ачылу сүзе шуңардан).

*Ач кабак кычкыру* кузнецк сөйләшендә килен төшкәндә егет йортының капкасын ачтыру. *Кабак эс(те)* мишәр диалектының ләмбрә, хвалын сөйләшләрендә «капка төбе»: *Кабаг эстенә чыгу* – мишәр диалектының карсун, кузнецк сөйләшләрендә капка төбенә чыгып утыру. *Кабак-кура* чистай сөйләшендә капкалар, каралтылар. *Кабак II* стәрлетамак сөйләшендә үр (возвышенность).

*Капка* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда шактый актив кулланыла: *Такталачык капкасы* – Актаныш районы Чалманарат авылы янындагы урын атамасы. *Зират басу капкасы* – Актаныш районы Семистрау (Өшәр) авылының басу янындагы капкасы. *Биш мунча ягы капкасы* – Азнакай районы Әлкәй авылының капка атамасы. *Танай капкасы* – Азнакай районы Әлкәй авылы янындагы урын атамасы. *Бикбау капкасы* – Балтач районы Арбаш авылы янындагы урын атамасы. *Ялгалы капкасы* – Актаныш районы Чалманарат авылы янындагы элекке капка атамасы. *Зират капкасы* – Әлки районы Иске Чаллы авылы янындагы капка атамасы. *Мрәз капкасы* – Саба районы Олы Шыңар авылы янындагы урын атамасы. *Му капкасы* – Арча районы Иске Му авылында. Бу капка Казанбаш авылыннан югарырак булган. *Басу капкасы* – Апас районы Иске Йомралы авылы янындагы капка атамасы. *Басу капкасы ягы* – Апас районы Иске Әнәле авылы янында юнәлеш күрсәтә торган атама. *Капка имән күле* – Майна елгасы бассейны. Спас районы Иске Рәҗәп авылы янындагы күл. *Капкалы куак* – Буа районы Карлы авылы янындагы урын атамасы. *Капкалы тау* – Кама Тамагы районы Балчыклы авылы янындагы тау атамасы. *Капка чокыр тавы* – Баулы районы Татар Кандызы авылы янындагы тау атамасы. *Капкалы куак* – Буа районы Карлы авылы янындагы урын атамасы. *Кала капкасы* – Яшел Үзән районы Мулла иле авылы янындагы атама. *Югары оч басу капкасы* – Актаныш районы

Семистрау (Өшәр) авылы янындагы басуга бару юлы. *Камы капкасы* – Азнакай районы Әлкәй авылында.

*Капка* лексик берәмлеге әдипләребез иҗатында шактый очрый. Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» повестенда *капка* лексик берәмлеге еш кабатлана: *«Капка төбенә ни арада өч-дүрт хатын-кыз җыелып өлгергән, барысы да яшь катыш елмаю белән тыкрыктан чыгып килгән Асафны карап торалар иде».*

Шәриф Хөсәеновның «Мәхәббәт сагышы» дигән повестенда мондый юллар очратабыз: *«Бар өмете, бөтен хыяллары һәм ниятләре күз ачып йомганчы чәлпәрәмә килгән капка төбеннән Хәбир көчкә кузгалып китте. Елыйсы килде».*

Рәисә Хәбибуллинаның «Мулла килене» романында *басу капкасы* гыйбарәсе оста сурәтләнгән: *«Ирек белән Рәйсә җәяүләп басу капкасына якынлаштылар... Күңеленнән егет малайларның капка ачуларын тели, шуңа өметләнеп кесәсенә вак акчалар да салган иде. Капка ябык, малайлар юк... Аларның кайтасыларын ишетмәгәннәр шул... Ирек чемоданын җиргә куйды да, капканы киереп – атлы арба үтәрлек итеп ачты. – Әйдә, «килен», төкле аягың белән рәхим ит безнең авылга!– Рәйсәне күтәреп ачык капкадан алып керде. – Бәхет капкасы бу, белеп тор! Без ачып керткән киленнәр бар да безнең авылга гомерлеккә килделәр!»*

***Капу, капуг***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем, искергән» дип бирелгән һәм беренче мәгънәсе «кара: *капка*» дип ныгытылган. *Зиндан капусы янында ук бер төнге каравылчы солдат стенага сөялеп гырылдап йоклamakта иде*. Ш. Мөхәммәдев.

*Икенче мәгънәсе* «кара: *капкач*» диелгән. *Тәрәзәмнең капусына Моңлы кош килеп кунган.* Җыр (ТТАС, II: 17).

А.К. Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә: *капу, капуг* «борынгы төрки» дип бирелгән һәм *беренче мәгънәсе* болай аңлатылган: «Капка. *Кап/кап-а ябу, каплау* фигыленнән (Р. Әхмәтьянов) // *Күк капусы ачылу* (күк кабагы ачылу – метеор ян-

гыры, йолдыз яңгыры; ләкин электә төньяк балкышының гына күк капусы ачылу дип аталган булуы бик мөмкин, сүзнең бу мәгънәсе 1966 елгы «Татарча-русча сүзлек»тә дә теркәлгән). Шушыңа бәйле рәвештә *капу* сүзе «бәхет капкачы ачылу» мәгънәсен дә белдергән.

Электә ай шикелле түгәрәк итеп ясалган капканы «айкапу» дип атаганнар. *Үзе өчен бер кемсә хәер сорашмактан бер капу ачса, Алла хәзрәтләре ачар аңа фәкыйрьлектән җитмеш капу.* Муса Акъегет».

*Икенче мәгънәсе:* «Борынгы төркичәдә идарәсенең кабул итү бүлмәсе. // *Капуг башчысы* – борынгы чорда ханның кабул итү эшләрен оештыручысы. Аны «капуг башлар» һәм «капуг ил башы» дип тә йөрткәннәр. Тагын кара: *Кабак»*.

*Капу* берәмлеге белән географик атамалар күп түгел: *Капу* – Кама елгасы ярындагы кечерәк кенә калкулык, Чаллы шәһәре янындарак. *Капу елгасы* – Ширәмәт елгасы бассейнында.

Бу лексик берәмлек төрки халыкларда шактый очрый. Төрек телендә *капу,* кырым татарлары телендә *капу, хапу* «ишек, капка; император сарае» (Радлов, II: 414–415, 1693). Кырым татарлары телендә *хапу*, төрек телендә *капу* «тар үтеп йөрү урыны, капка, ишек». *Капу күпере* – Әтнә районының Ябынчы авылы янындагы элекке күпер.

*Капу, Айкапу* – әдипләр иҗатында кулланыла. Вахит Имамовның «Утлы дала» исемендәге тарихи романында бу сүзне очратабыз. *«Айкапуга килеп җиттеләр, бәхәс өзелеп калды. Андрей игътибар биреп үтте: имән бүрәнәләр арасына комташ тутырып ясалган Болгар стенасының калынлыгы дүртбиш адым икән».*

***Каш***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *каш* лексик берәмлегенең дүртенче мәгънәсен аңлау өчен *кашлак* сүзен карарга тәкъдим иткәннәр. *Әнә шул кашка чыккач та, Дадашев промыслолары күренер, – диде Хәлил.* Ш. Камал. *Иртәнге кояш авыл янындагы каш артыннан яңа гына күтәрелеп чыккан.* С. Җәләл. // Сыйфат мәгънәсе: тау бите сыман калкып торган.

*Каш җир түгел, киресенчә, бик аулак уйсу имеш. Арышлар бик сыгылмалы, Газзә бик моңсу имеш.* С. Баттал. *Тиресле җирләрдә, кашрак урыннарда җирләре булган кешеләр ара-тирә ургалый да башладылар*. М. Гали.

*Бишенче мәгънәсе* «диалекталь» дип күрсәтелгән. Калкулык. *Зур-зур таулар башында, Текә ярлар кашында, Тора тезелеп олуг яу*. М. Җәлил. *Байтак юл алгач, сәфәрчеләрнең игътибарын тау кашындагы дәү-дәү комташ кантарлары җәлеп итте.* А. Гыйләҗев (ТТАС, II: 77).

***Кашлак.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «бу термин сыйфат дип ныгытылган һәм калкып чыгып торган, калку җир (рельеф турында»)», дип аңлатылган. *Әйбәт тә соң алмагачка җирнең бераз кашлагы*. С. Хәким. *Тау башындагы кашлак урыннарда кар инде эреп беткән*. Ф. Хөсни. // Исем мәгънәсе *[Газинур] фермалар артындагы кашлакта казыла торган землянкаларга таба юнәлде.* Г. Әпсәләмов (ТТАС, II: 78).

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге...»ндә *каш* терминының мәгънәсе «Кашлак җир; калкулык өсте» – дип бирелгән.

*Юрункаш* – Тибет тирәсендә башлана торган зур гына елга. Хотан елгасының кушылдыгы. Атаманың мәгънәсе – «ак» яки «ачык нифрит». Агып ятучы нифрит дип тә аңлаталар.

*Каш, кашлак* сүзләре күчерелмә мәгънәдә елга ярының читен, читләрен, яр буйларын аңлата. Бу терминнар топонимнар ясауда еш катнаша: *Каш кизләве* – Тәтеш районының Келәш авылы янында, Келәш елгасы бассейнында. *Каш урманы* – Буа районының Бикмураз авылы янында, урман атамасы. *Каш чирәме сазлыгы* – Кама Тамагы районының Даныш авылы, Ылгыма елгасы бассейнында. *Каш чирәме чишмәсе* – Кама Тамага районы, Даныш авылы яныннан ага торган Ылгыма елгасы бассейнында. *Зәлпәк кашы* – Кама Тамагы районы Кече Бортас авылы янындагы биек урын. *Мәскәү кашы* – Тәтеш районы Келәш авылы янындагы тау атамасы. *Җиләклек кашы* – Яшел Үзән районының Татар Танае авылындагы куаклык атамасы. *Түгәрәк тау кашы* – Кайбыч районы Олы Кайбыч авылы

янындагы тау атамасы. *Мунчала кашы* – Кама Тамагы районы Яңа Сала авылы янындагы тау атамасы. *Кыстау кашы* – Буа районы Зур Кырлангы авылы янындагы калкулык атамасы. *Сиңгел кашы* – Кама Тамагы районы Зур Кариле авылы янындагы тау атамасы. *Чилек кашы* – Буа районы Каенлык авылы янындагы урын атамасы. *Кәзә кашлагы* – Балтач районы Иске Чепья авылы янындагы урын атамасы. *Шәм күле кашы* – Апас районының Әлмәндәр авылы янындагы урын атамасы. *Идел кашы калкулыгы* – Кама Тамагы районы Олы Салтык авылы янындагы җир атамасы. *Чилек кашы* – Буа районы Каенлык авылы янындагы урын атамасы. *Чыгыш кашы* – Спас районы Иске Рәҗәп авылы янындагы урын атамасы. *Каенлы каш* – Кама Тамагы районы Яңа Сала авылы янындагы урын атамасы. *Каенсар кашы басуы* – Яшел Үзән районы Акъегет авылы янындагы басу атамасы. *Кар урманы* – Буа районы Бикмураз авылы янындагы урман атамасы. *Каш басуы* – Кама Тамагы районы Кече Салтык авылы янындагы басу атамасы. *Олан кашы чокыры* – Яшел Үзән районы Карамасар авылы янында. Карамасар суы кушылдыгы. *Җиләклек кашы* – Яшел Үзән районы Татар Танае авылы янындагы куаклык атамасы. *Карама кашы* – Яшел Үзән районы Мулла иле авылы янындагы калкулык атамасы. *Кайынлык кашы* – Кама Тамагы районы Олы Бортас авылы яныннан агып үтә торган Коры Үләмә елгасы кушылдыгы. *Каенлы каш* – Кама Тамагы районы Яңа Сала авылы янындагы урын атамасы.

Боларга өстәп *Кашлак каенлыгы, Каш ышнасы* һәм *Каш урманы* микротопонимнарын мисалга китерергә мөмкин.

*Каш, кашлак* лексик берәмлекләре әдипләребез иҗатында да очрый: Гомәр ага Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» китабындагы «Язгы сабан туйлары» повестенда *кашлак* термины печән чабу эше белән бәйләнешле рәвештә кулланылган: *«Безнең сәнәк тамга Аҗги амбары янындагы кашлак урынга чыкты. Әти, каһәрләнеп: – Әй, нәләш, нәләш!– диде. – Чәнчелеп кенә китсен! Уңмадык! Югары башы тап-такыр, суга башташ өлешен гел ат кузгалагы баскан!»*

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *күз өстендәге каш* гыйбарәсе күчерелмә мәгънәдә һәм гаҗәп үзенчәлекле кулланылган: *«Соң бит шуны да белмәскә син! Ни җитте агач кына түгел ләбаса! Бу тирәнең күз өстендәге кашы бит ул. Улларыбызны шушы карама төбендә озатып калдык. Аңа сугышта үлгән ике йөз кырык ир-атның күз нуры йогып калган».*

Борынгы төрки телдә дә *qač* – «елга яры, кырые, чите», *jar qaši* – «яр кырые» яисә «чите» рәвешле кулланылган (ДТС, 1969: 431; МК, III: 152). В.В. Радлов сүзлегендә төрки телләрдәге *кас~каш* терминының «биек яр, зур елга һәм диңгезнең калку яры, күтәренке урын, вал» төшенчәләре күрсәтелгән (т. II, Ч. 1: 345, 386).

Татар теле сөйләшләрендә *каш* – калкулык, кашлак, күтәренке урын. (Себердә *каштакъ* – тау инеше, тау чишмәсе). Казак, алтай телләрендә *кас* – каш, елганың текә яры, калку яр, вал, якутча *хас* – каш, яр, биек текә яр; хакасларда *хас* – яр, биеклек, калкулык, нәрсәнең дә булса чиге.

Бу терминнар белән ясалган топонимнар һәм гидронимнар Татарстаннан читтә яши торган татарлар телендә дә актив кулланыла. Ульяновск өлкәсендә: *Каш кизләве* – Барыш районы Иске Тимушкә авылы янындагы чишмә. Микротопонимик атамалар ясауда да катнаша: *Кашлак болыны, Кашлак каенлыгы, Каш урманы, Каш ышнасы, Каш урамы* һ. б.

*Каш, кашлак* сүзләренең таралыш ареаллары Э.М. Мурзаев тарафыннан тикшерелә (1984: 265– 266).

О.Т. Молчанова мәгълүматларына караганда, Алтайда *Ямак-Каш* елгасы ага (1979: 176). Якут Сахасында *Хас-Юрях, Хастах* елгалары һәм *Хас-Билир* күле теркәлгән (Комаров, 1964), *Каштак* – Кемерово өлкәсендә тау һәм бистә атамасы, 1697 елда бу бистә янында көмеш рудасы табылган. Иртыш елгасының югары агымындагы бер кушылдыгы *Каштак* исемен йөртә (Розен, Малолетко, 1986: 47). Н.А. Баскаков мәгълүматларына караганда, «Алтайда *каскак* термины „текә кыя, кырт киселгән кыя» мәгънәсен бирә. Чарыш елгасы системасында

*Каскак* атамасы алган тау һәм елга, Усть-Күксә районында *Каскакту* атамасы белән тау һәм елга теркәлгән. Тывада *каскак* – урман, куаклыклар белән капланган, кырт киселгән кыя. Каа-Хем районында *Каскак* тавы һәм *Каскак-Бары* үзәнсу иңкүлек урыны бар. *Бары* сүзе „алгы өлеш“ дигән мәгънә аңлата» (Баскаков, 1969: 64–71).

*Каш* сүзе турындагы фикерләрен А.М. Малолетко болай формалаштыра: «Иртыш елгасына сул яктан килеп кушыла торган Вагай елгасының югары агымында аңа *Каш* елгасы тоташа. Или елгасы кушылдыкларының да берсе *Каш* исемен ала. Бу телесларның легендар елгасы – Эрен-Кабырга. Хотан елгасы Кунь-лунь кабыргасыннан төньякка таба агып төшкән *Каракаш* һәм *Юрункаш (Урункаш)* елгалары кушылуыннан барлыкка килгән. Алтайда, Эликманар авылы янында Катунь елгасына *Уренкаш (Уренгаш)* инеше кушыла. Тывада мондый елга атамаларын беркадәр башка фонетикада (яңгыраштa) күрәбез: Сейба елгасы тамагыннан югарырак Енисейга уң яктан *Кара-Хаш* елгасы, Азас елгасына сул яктан *Хурек-Хаш-Хем,* Бий-Хем елгасына уң яктан *Кара-Хаш* елгасы кушыла, Хемчик кушылдыгы Барлык елгасына уң яктан *Кече Похаш, Урта Похаш* һәм *Олы Похаш* елгалары кушыла.

Составларында бары якут телендә «ак, чиста, якты» мәгънәләрендә кулланыла торган *урунг (юрунг, урун),* русча «черный» төшенчәсен аңлата торган *кара* сүзе кергән атамаларның төрки телгә нисбәтен барлыкка килүенә ышанырга була. Үзләренең төзелешләре белән бу топонимнар *Карасу-Аксу, Карачул-Акчул, Карагем-Аккем* тибындагы төрки оппозицияләргә тәңгәл киләләр. *Каш (Хаш)* термины белән кулланылган, югарыда сүз алып барылган *Кара-Каш, Урунг-Каш* төзелешле гидронимнардагы *каш (хаш)* терминын төркиләр тарафыннан онытылган «елга», «су» компонентлары дип карарга мөмкин булыр иде. Югарыда аталган термин белән ясалган гидронимнар түгәрәгенә Алтай һәм Тыва җирлекләрендә аларга фонетик яктан якын *гаш* компонентын алган күпсанлы *Езгаш,*

*Ологаш, Телегаш, Кулагаш* һ. б. гидронимнарының төрки телгә мөнәсәбәтле булуының бәхәссез икәнен күрәбез. Бу очракта *хаш/каш/гаш* терминнарын төрки телдә *су* мәгънәсен аңлата торган *агаш* компоненты белән бәйләргә мөмкин» (Малолетко, 1992: 144–146). Моннан соң А.М. Малолетко югарыда сүз алып барылган топонимнарның төрки чыгышлы икәнлегенә икеләнүен түбәндәге фикер белән дәлилләмәкче була: «Обь елгасының түбән агымындагы сул кушылдыгы *Кондага Хаш* атамасы алган елга коя. Шул ук елганың уңъяк ярында Пиләр белән Казым елгалары тамагында коми телендә „йорт, торак, яшәү урыны“ мәгънәсендә кулланыла торган тел тидермәслек *горт* термины белән *Хашгорд* бистәсе бар. Төрки йогынты килеп җитмәгән Көнбатыш Себернең төньягындагы *Хаш* топонимы югарыда сүз алып барылган топонимнарның килеп чыгышындагы төрки гипотезаны инкарь итәргә дәлил булып тора». Галим фикерен болай дәвам итә: «Бу топонимнарның иран гипотезасы нигезендә аңлатыла алуларына китерә торган дәлилләргә тукталыйк. Беренчедән, фарсы теле йогынтысы зур булган Таклы-Макан бушлыгының көньягында *каш* компоненты белән елга атамалары булу; икенчедән: Тыва һәм Алтайдан кала, төркиләр яшәгән барлык җирлекләрдә югарыда сөйләнгән типтагы атамаларның бөтенләй очрамаулары, яисә аз очраулары.

Курд телендә *каш* – „чокыр“ яисә „уйсу җир“. Рельефның мондый рәвешен елга челтәренең беренче үрнәге, төп үрнәге итеп карарга мөмкин» (Малолетко, 1992: 145).

А.Н. Малолетконың топонимнар һәм гидронимнарның килеп чыгышын иран гипотезасы белән бәйләргә тырышуы күңелдә мондый сораулар уята: 1) төрки йогынтысы килеп җитмәгәнне галим кайдан белә, дәлилләре нинди? Дәлилләр китерелмәгән; 2) хезмәттә китерелгән бары бер *Хаш-гурт* топонимы гына топонимнар барлыкка килүдәге төрки гипотезаны инкарь итә аламы? 3) төркиләр яшәгән бөтен җирлекләрдәге топонимнар фронталь рәвештә тикшерелгәнме? Тикшерелмәсә, галим әйткән фикер нәрсәгә таяныла? 4) курд телендәге *каш* турыдан-

туры «елга», «су» мәгънәсен аңлатмый бит. Ә элек һәм хәзер дә төрки телләрдә *каш* «елга», «инеш»не дә аңлаткан һәм аңлата.

***Киләк.*** Бу термин татар телендәге сүзлекләргә кертелмәгән, чөнки телебез борынгы, халкыбызның тарихы, телебез кебек үк, биниһая борынгы һәм катлаулы. Күп лексик берәмлекләр телдән төшеп калган. Сүзнең мәгънәләре тараю күренеше бара һәм барачак.

Халык телендә ул умарталык белән бәйләнешле рәвештә кулланыла.

*Киләк* лексик берәмлеге белән ясалган географик берәмлек атамалары очрый.

*Киләк* термины, мисаллардан күренгәнчә, Татарстанның Тау ягы, Казан арты, Кама аръягында яшәүче татарлар телендә (өлкәннәр авызында) әйләнештә йөри.

*Киләк сазы* – Яшел Үзән районы Мулла иле авылы янындагы саз. Әрә елгасы бассейнында. *Киләк күле* – Аксубай районы Иске Ибрай авылы янындагы күл. *Кара киләк елгасы* – Нурлат районы Кычытканлы авылы янындагы Мораса елгасы бассейнында. Кара һәм чистай сөйләшендәге *киләк* – «урманда умарталык өчен бүлеп алынган урын» (ТТДС, 1969: 245) сүзләренә мөнәсәбәтле. *Зәкәй киләге* – Әлки районы Иске Чаллы авылы янындагы кыр атамасы. *Закир умарта киләге* – Спас районы Әҗмәр авылы янындагы урын атамасы. *Киләк урыны* – Әтнә районы Ябынчы авылы (бу авыл хәзер беткән инде). *Нәмәт киләге* – Әлки районы Иске Чаллы авылы янындагы кыр атамасы. *Әсән киләге* – Нурлат районы Иске Әлмәт авылы янындагы урын атамасы.

***Киртә***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *киртә* сүзе исем дип бирелгән һәм аның өч мәгънәсе дә аңлатылган. Безнең өчен аның икенче мәгънәсе кулай булачак: «Өй, бакча, басу һ. б. әйләнәсендә егып, ботакларыннан арындырылган, юан булмаган озын агач кәүсәсе; колга. Шундый агач кәүсәләрен казык баганалар арасына буйга салып эшләнгән аралы койма. *Киртә тоту. Илгизәр, киртә арасыннан кысыла-кысыла кереп, әтисе*

*янына килде*. Г. Бәширов. *Скважина алды мәйданчыгы киртә белән әйләндереп алынган.* А. Әхмәт (ТТАС, II: 104).

Монда киртә сүзенең географик атамаларга нисбәтле мәгънәсе махсус күрсәтелмәсә дә, географик атамаларда киртә лексик берәмлеге очрый һәм шуңа күрә без аны география атамаларына нисбәтле рәвештә итеп тә карыйбыз.

***Киртәле***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *киртәле* лексик берәмлеге сыйфат дип бирелгән һәм мәгънәсе: «Киртәләп алынган, киртәләнгән», – дип аңлатылган. *Киртәле кибәнгә мал керм*әс. Мәкаль (ТТАС, II: 104– 105).

***Киртәлек***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә киртәлек лексик берәмлеге исем дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай аңлатылган: «Киртә тоту өчен яраклы агач». *[Хәйдәр белән Карлыгач] Күпме киртәлек кирәк буласын белү өчен, бакча әйләнәсен үлчәргә тотындылар.* Г. Бәширов (ТТАС, II: 105).

*Киртә* лексик берәмлеге белән ясалган атамалар байтак. *Бозау киртәсе* – Мамадыш районы Колынчы авылындагы урын атамасы. *Сыер киртәсе* – Әтнә районы Яңа Җөлби авылы янындагы урын атамасы. *Сыер киртәсе елгасы* – Әтнә районы Яңа Җөлби авылы янындагы елга, Сәрдә суы кушылдыгы.

***Кичү*** I. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *кичү* лексик берәмлеге «фигыль» дип ныгытылган һәм «Үтү, үтеп чыгу (гадәттә елга аркылы, шулай ук үтүе кыен булган урыннардан)», дип аңлатылган. *Безнең бу походыбыз икешәр километрлы биек тауларны, ыргылып аккан тирән суларны җәяү кучүгә бәйләнгән*. Т. Гыйззәт. *Боз ачылгач Идел кичү уңайсыз булыр*. М. Галәү. *Алар фронт сызыгын кичтеләр*. И. Гази. // Күчерелмә мәгънәдә. Зур каршылык, кыенлыкларны җиңеп чыгу турында. *Туган илнең тынычлыгы өчен Утлы давылларны кичәбез*. Ә. Ерикәй. *Кыю кичтем сугыш газабын.* М. Хөсәен.

***Кичү*** II. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *кичү* II «исем» дип ныгытылган һәм «елганың икенче ярына җәяүләп яки ат белән үтәрлек, кичәрлек сай, сөзәк ярлы урыны; елга үткеле», дип аңлатылган: *Илгизәр белән берничә малай*

*тракторга җайланган тырмалар төркемен, күпергә сыймаганлыктан, кичүгә чыгарып яталар*. Г. Бәширов. *[Малай] бу тирәдәге кичүләрне, сукмакларны яхшы белә икән*. М. Шабай. // Елга аша икенче ярга чыгару өчен махсус җайландырылган урын. *Эшчеләр ашыга-ашыга кичү төбенә җыела башладылар*. Ф. Сәйфи-Казанлы.

*Кичү бирү* – «саегу, бер ярыннан икенче ярына кичәрлек хәлгә килү». *Агыйделнең суы кибә: әүвәле ат йөздереп йөргән җирләр кичү бирә*. М. Әмир. *Кичү бирмәс елга юк, Батыр җиңмәс дошман юк*. Мәкаль (ТТАС, II: 117).

*Кичүлек,* кара: кичү II. *Кичүлектә дошман гаскәрләрен карап алу.*

*Кичү* сүзе гидронимнар һәм топонимнар ясауда шактый актив кулланыла: *Кичү буасы* – Биектау районындагы Зур Кавал авылы янындагы буа; *Кичү тау башы* – Лениногорск янындагы Иске Шөгер авылы янындагы тау; *Кичү чишмәсе* – Биектау районындагы Зур Кавалның *Кичү буасы* янындагы чишмә; *Кичү башы елгасы* – Балтач районындагы Түнтәр авылы янындагы Түнтәр елгасы кушылдыгы; *Кичү елгасы* – Арбаш елгасы кушылдыгы, Балтач районының Арбаш авылы янында; Карлы елгасы кушылдыгы, Буа районының Карлы авылы янында. *Сөендек кичү суы* – Әлмәт районының Сөләй авылы Урсала елгасы бассейнында. *Тамак керә кичү* – Буа районы Түбән Наратбаш авылы, Зөя елгасы бассейнында. *Ташкичү юлы* – Теләче районы Кече Нырсы авылы янындагы юл; *Ташкичү елгасы* – 1. Арча районы Ташкичү авылы, 2. Баулы районы Мортаза, 3. Зәй районы Әхмәт, 4. Баулы районы Олы Урыссу, 5. Сарман районы Рангазар, 6. Әлмәт районы Яңа Кәшер авыллары янындагы елга-сулыклар атамасы. *Ташкичү күпере* – Теләче районы Кече Нырсы авылы янындагы күпер атамасы, *Ташкичү чалуы* – Яшел Үзән районы Татар Танае авылы янындагы чалу-печәнлек; *Ташкичү чишмәсе* – 1. Арча районы Кысна авылы, 2. Баулы районы Мортаза, 3. Әлмәт районы Яңа Кәшер авыллары эчендәге яисә яннарындагы чишмәләр.

*Кичү* лексик компоненты әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында да кулланыла.

Гәмәр ага Бәшировның «Намус» романында *кичү* термины бик кирәкле урында кулланыла: *«Оныта күрмә, әткәйгә әйт, атларны кичүгә иртәгә үк җибәрсен, берсекөнгә калдырмасын».*

Вахит Имамовның «Татарлар Пугачев явында» исеме алган әдәби эпизодлар белән баетылган тарихи очеркында *кичү* лексик берәмлеге кулланыла: *«Күп санлы, зур отряд туплаудан тыш Бәхтияр, әлбәттә, Кама, Нократ кичүләрен саклау турында да онытмый. Шул максат белән ул үзенең ярдәмчесе, походный старшина Габдулла Мостаевны Шуран кичүен сакларга озата».* Шул ук авторның «Утлы дала» романында *Кичү елгасы* атамасы да очрый: *«Ул чакны Кормаш би үзенең яраннарын, туган-тумачасын Кичү елгасы буена ауга дәшкән иде».*

*Кичү* лексик берәмлеген Фәүзия Бәйрәмова да «Кырык сырт» романында уңышлы куллана:

*«Биредә яшәүче татарларның гомер-гомергә үзләре генә белгән кичү-сулыклары булган, кыргый җәнлекләр артыннан алар тау сыртларын кичкәннәр, су юлы буйлап диңгезләргә хәтле барып җиткәннәр».*

*Кичү* лексик берәмлегенең таралыш ареалы бик киң. Уйгыр телендә *кеч*, чагатай – *кäч* «елга аша чыгу, яныннан үтү, үтеп китү» (Радлов, II: 1142–1144); төрек телендә *keçтек* 1) нәрсәнедер кичеп чыгу, яныннан үтеп китү, агып үтү (елга турында) һ. б., 2) үтеп чыгу, күчеп китү (Төрек сүзлеге); караим теленең кырым диалектында *кэч* «үтеп китү» (Караим сүзлеге); үзбәк телендә *кечик, кечув* «кичү», «елганың җәяү яки ат белән кичәргә мөмкин булган сай урыны» (Донидзе, 1980).

***Кое.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *кое* «Җирнең сулы катламыннан су алу өчен текә казылган (гадәттә, җимерелмәс өчен, стеналары агач бура белән буралган) тирән чокыр». *Озак та үтмәде, мөлдерәмә сулы чиләк кое авызыннан килеп тә чыкты*. Г. Гобәй (ТТАС, 1979: 125).

Борынгы төрки телдә – *Quduy* (ДТС 1969, 464). Борынгы уйгыр телендәге *quduγ,* башкортча – *қозоқ,* кумыкча – *къую.* казакча – *қудық,* кыргызча – *кудук,* үзбәкчә – *қудуқ, чукур,* төрекмәнчә – *гуйы,* алтайча – *кутук,* тывача – *кудук,* каракалпакча *қудық* – «кое». В.В. Радлов сүзлегендә *кыiу* апеллятивы «боздагы бәке»не аңлата. *Куi* сүзе – елга үзәне, яр, кырый, тау куышлыгы. Татар әдәби телендәге *кое*, диалекталь *кыйу~козык* сүзләре борынгы төрки телдәге *кодук* сүзеннән килеп чыккан. *Таг, сарыг, кодык* һ. б. шундый сүзләр, азактагы тирән тел арты тартыклары [қ] һәм [ғ] авазларының йотылуы нәтиҗәсендә, *тау, сары, кое* әйтелеше алганнар. Борынгы төрки телдә *kadгу, adак, кудук* һ. б. сүзләрдәге *d* урынына татар телендә *й* сонанты языла, мәсәлән: *тау, сары, кое.* Тамырдагы *[у]* авазы татар һәм башкорт телләрендә *[о]* булып әйтелә.

«Кодекс Куманикус» (1303 ел) хезмәтендә *койо, кыйы* «кое», кырым татарлары телендә *кофе* – «кое» (Махмутова).

А.К. Тимергалин хезмәтендә *кодык* «борынгы» дип ныгытылган һәм «кое» дип күрсәтелгән. Нократ-глазов сөйләшендә *кодык* дип бәкегә әйтәләр. Борынгы төрки телдә тагын «кое» мәгънәсендәге *козуг* сүзе дә йөргән. 1950 елдагы «Татарча-русча сүзлек»тә кое сүзенең «скважина» мәгънәсе дә теркәлгәнлеген әйтеп китик (мәс,. нефть скважинасы). Язылышта *кодуг* варианты да күзәтелә. // *Алты Кодык – Аральск шәһәренең баштагы исеме. Кодугына карай гына каугамыз* (чиләгебез) *бар.* Акмулла.

*Кое* дип, гадәттә, акмый торган су чыганакларын атыйлар. Ләкин Казан артының кайбер урынчалыкларында бу термин зур булмаган инеш, чишмәләрне дә белдерә. Терминның мәгънәсе киңәя. *Имәнле кое, Наратлы кое* елгалары – Питрәч районы Шәле авылында бар. Бу күренеш Дим буе топонимиясендә дә чагылыш таба.

Татар теле сөйләшләрендә «кое» мәгънәсендә байтак кына диалекталь терминнар очрый. Урта диалектның гәйнә һәм Тау ягы урынчалыкларында *кой, оро* сүзләре «кое» төшенчәсен аңлаталар. *Кое* сүзенең мәгънәсе үзгәргән очраклар да бар.

Мәсәлән, красноуфим, гәйнә сөйләшләрендәге *козок, кодок* – «бәке», эчкен сөйләшендәге *коток* – *«*яңгырдан соң җыелган су», минзәлә сөйләшендә *койолок* – *«*суда бөтерелеп кайнап чыга торган җир». Пермь татарларында *кодок «*бәке»не белдерә. Башкорт теленең әй-йөрүзән сөйләшендә дә бу сүз әлеге мәгънәдә йөри. Шул ук телнең инйәр, эйек-сакмар сөйләшләрендә *койо* – *«*сыгылып тора торган сазлык, урамдагы пычрак» төшенчәләренә ия. Дим, кырмыскалы сөйләшләрендә *койолок* – «чишмә башы, су өермәсе, упкын».

Фин-угор телләренең пермь тармагына керә торган комиязьви диалектларында очраган «кое» мәгънәсендә кулланылучы *кодем* һәм венгр телендәге kit сүзләре төрки телдән кергән дип исәпләнә (Лыткин, 1967: 139).

*Кое* термины географик берәмлек атамалары ясауда шактый актив кулланыла. Ул – аерым су чыганакларының атамалары булып хезмәт итә ала. *Кое* – Ашыт бассейнындагы (Биектау районы), Олы Үләмә бассейнындагы (Апас районы), Кукмара районындагы Пычак авылындагы, Биектау районы Кодаш авылындагы су чыганаклары (коелар).

*Кое* термины топонимнарның состав өлеше буларак та еш очрыйлар. *Кое чирәме елгасы* – Кече Чирмешән елгасы кушылдыгы (Әлки районы), *Кое чишмәсе елгасы* – Кече Чирмешән елгасы кушылдыгы (Әлки районы), *Кое чишмәсе* – Олы Мишә елгасы бассейны (Саба районы), *Кое инеше* – Бәтке елгасы кушылдыгы (Балык Бистәсе районы). Актаныш районының Иске Кадермәт авылы янында *Коелы чокыр*, *Хәйдәр күле* исеме алган географик берәмлекләр бар. Бу очракта *Хәйдәр күле* атамасындагы *күл* термины коены аңлата. *Иске авыл коесы* – Актаныш районының Адай авылында, авылның элекке урынындагы су чыганагы (авыл аксакаллары әйтүенә караганда, аннан әле дә су алып була икән). *Сабанай коесы* / *Кушмалы кое* – Сабанай чокырына казылган һәм кушма утыртылган су чыганагы. Актаныш районындагы Күҗәкә авылы белән күршедә урнашкан Минзәлә районындагы Бикбау авылында *Сабирҗан коесы* һәм *Габдулла мулла коес*ы теркәлгән.

*Югары кое* – Мамадыш районы Түбән Сон авылында. *Габделхак коесы* – Әтнә районы Әйшияз авылындагы кое. *Габделхәй коесы* – Яшел Үзән районы Күгәй авылында. *Габдрахман коесы* – Апас районы Кече Бакырчы авылындагы кое. *Кара кое* – Мамадыш районы Колышчы авылы. Бу кое янында кара үгезне корбанга чалганнар. *Сибгат коесы* – Апас районы Түбән Балтай авылы яныннан агып китә торган Чирмешән суы бассейнында. *Шыкра кое* – Буа районы Кыр Кайбычы авылында.

Микротопонимнар: *Кое әрәмәсе, Кое каенлыгы, Кое утары, Коелар башы урамы, Кое рәте, Кое төбе* һ. б.

*Кое* компоненты әдипләр иҗатында кулланыла. Фатыйх ага Хөснинең «Йөзек кашы» повестенда *кое* сүзе файдаланыла: *«Теге якта, авылның арт урамыннан килеп күпергә таба сузыла торган юл буенда, таш кое кала»*. Шул ук авторның «Без яшь идек» повестенда *кое* термины күчерелмә мәгънәдә кулланыла: «*Шуның өстенә, акча күреп өйрәнмәгән авыл хатынын акчасы да кызыктыра, ирсез-атсыз калган өйдә кирәк-ярак төпсез кое кебек»*.

Мөхәммәт Мәһдиев «Без – кырык беренче ел балалары» повестенда менә нинди җөмлә куллана: *«Морҗаның коесы туры икән. Ягъни юшкәсен ачкач, мичкә башыңны тыксаң, күк йөзе күренә»*. *Кое* терминының бу мәгънәсе инде онытылды. Классикларны уку татар теленең онытылган, онытыла башлаган берәмлекләрен кайтару өчен дә гаять әһәмиятле.

*Кое* сүзе күчерелмә мәгънәдә китап атамасы булып та кулланыла ала.

Таһир Шәмсуаровның «Моң коесы» исемле китабы бар.

Зариф Мөэминовның «Безнең мирас» журналында урнаштырылган «Мәрьям» повестенда *кое* лексик берәмлеге болай кулланылган: «*Байларның байларча, коры әрдәнәсе, су алу өчен шунда гына коесы – барысы да әзер*.

Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә *кое* сүзе гидронимнар ясауда актив кулланыла. *Кое* – Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районындагы Иске Атлаш авылында. Шул ук авыл-

да тагын *Кое тавы* исемен алган микротопоним бар. Самара өлкәсе Камышлы районындагы Татар Байтуганы авылында *Кое*, *Кое башы* (монысы чишмә исеме) һ. б. Башкортстанда: *Кое* – Әбҗәлил районы Аумыш, Әлшәй районының Кармыш, Балтач районындагы Яңа Балтач авылларындагы чишмәләр. Башкортстанның Зианчура районында *Коебар* исемле авыл атамасы теркәлгән. Оренбург өлкәсенең Северный районындагы Бакай авылында *Кое* – халык су эчә торган су чыганагы.

*Кудук* лексик берәмлеге һәм аның вариантлары күп төрки телләрдә, ә *худаг* халха – монгол һәм бурятларда әйләнештә йөри.

Радловның «Опыт исследования тюркских наречий» дип аталган сүзлегендә Кырым татарлары, коман һәм төрек телләрендә *кую, кию, куiу* «кое»ны аңлата. Караим теленең кырым диалектында *къуйу* «кое» (Караим сүзлеге), төрки телләрдә *кую* «кое, чокыр, иңкүлек».

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *кое, гую, кудук* терминнары көньяк Кырым ярымутравыннан Көнчыгыш Себергә кадәр таралган. Бу термин Идел буйларында, Кырым, Төньяк Кавказ, Урта Азия җирлекләрендә көн иткән төрки һәм хәтта төрки булмаган, шул исәптән шушы тирәдә яшәүче руслар телендә дә кулланыла. Ул рус теле мохитенә татарлардан һәм калмыклардан алынган булса кирәк. Кайбер төрки телләрдә *кое* термины «чыганак» мәгънәсендә очрый. Төрекмән телендә *гуйы* термины белән бергә *гудук* («күмелгән кое» мәгънәсендә) кулланыла. Термин Әстерхан тирәсендәге далаларда һәм ярым сахра, ярым чүл булган төбәктә яшәүче халыклар телендә дә әйләнештә.

*Красный Худук* – Әстерханнан көнбатыштарак урнашкан. *Сайкудук* һәм *Таллыкудук* атамасы алган коелар Идел аръягында һәм Урал өлкәсендә очрыйлар; Гурьев өлкәсендә *Балкудук* атамасы алган кое бар. Туры мәгънәсендә ул *Баллы кое,* ә күчерелмә мәгънәдә «суы бик тәмле, эчә торган» дип әйтелә. Актүбә өлкәсендә *Кудук* һәм *Кудуксай* атамалары халык телендә актив кулланыла. Куляб өлкәсендә *Кудукли* атамасы очрый.

Күкчәтау өлкәсендә *Кудук-Агаш* атамасын халык актив куллана. Омск өлкәсендә – *Кудук-Чилик,* Бохара өлкәсендә *Кулкудук* атамасы бар.

Якутия-Сахада Ф.И. Комаров *Кудук* исемле торак пунктны, *Кудакта* исемле елганы билгеләгән (Комаров, 1964: 50). Кыргызстанда *Ак-Кудук* атамасы белән өч топоним теркәлгән. Шуларның икесе авыл атамасы, алар Нарын өлкәсенең Актала һәм Кант районнарында. Ә берсе су чыганагы – Нарын елгасының уң кушылды (Умурзаков, 1988: 15).

*Худаг, хулаг* терминнары белән атамалар Монголиядә шактый кулланылалар. Гобий Алтаенда *Ганц-Худаг* коесы ялгыз һәм бердәнбер су чыганагы. *Цаган-Худах* – Ак кое һ. б.

Татар теле сөйләшләрендә «кое» мәгънәсендә байтак кына диалекталь терминнар очрый. Урта диалектның гәйнә һәм Тау ягы урынчалыкларында *кой, оро* сүзләре «кое» төшенчәсен аңлаталар. *Кое* сүзенең мәгънәсе үзгәргән очраклар да бар. Мәсәлән, красноуфим, гәйнә сөйләшләрендәге *козок, кодок* – «бәке», эчкен сөйләшендәге *коток* – «яңгырдан соң җыелган су», минзәлә сөйләшендә *койолок* – «суда бөтерелеп кайнап чыга торган җир». Пермь татарларында *кодок* бәкене белдерә. Башкорт теленең әй-йөрүзән сөйләшендә дә бу сүз әлеге мәгънәдә йөри. Шул ук телнең инйәр, эйек-сакмар сөйләшләрендә *койо* – «сыгылып тора торган сазлык, урамдагы пычрак» төшенчәләренә ия. Дим, кырмыскалы сөйләшләрендә *койолок* – «чишмә башы, су өермәсе, упкын».

Фин-угор телләренең пермь тармагына керә торган коми-язьви диалектларында очраган «кое» мәгънәсендә кулланылучы *кодем* һәм венгр телендәге *kut* сүзләре төрки телдән кергән дип исәпләнә (Лыткин, 1967: 139).

***Куак***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *куак* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай бирелгән: «Төптән үк диярлек ботакларга тармакланган тәбәнәгрәк агач үсемлек». *Чия куаклары, алмагачлар Чәчәкләргә күмелеп утыра*. Ә. Ерикәй. *Чем-кара җимешләрен елтыратып нигәдер*

*гажәпләнгәндәй, карлыган куаклары карап тора.* Г. Бәширов (ТТАС, II: 178)

***Куаклык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *куаклык* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай аңлатылган: «Куаклар үсә торган урын, әрәмә». *Үләннәр, Илсөярнең ак каеннары, су читендәге тал-тирәкләре будка тирәсендәге куаклыклар – бөтенесе дә саргая башлаганнар иде.* Г. Гобәй. *Алкин чыга: – Сездә куаклыклар алган камап кырлар арасын.* Ш. Мөдәррис (ТТАС, II: 178).

*Куак* һәм *куаклык* лексик берәмлекләре географик атамалар ясауда киң кулланыла.

*Чияле куак* – Сарман районы Рангазар авылы янындагы басу атамасы. *Кәзә куагы* – Сарман районы Рангазар авылы янындагы басу атамасы. *Бутан куагы* – Апас районы Колгына авылы янындагы калкулык атамасы. *Афу куагы* – Чүпрәле районы Түбән Каракитә авылы янындагы урын атамасы. *Камышлы куак күле* – Апас районы Кылчык авылы, Чирмешән елгасы бассейны. *Дурман куагы (сазлык)* – Азнакай районы Әлки авылы янындагы сазлык, Куйгалдаш елгасы бассейнында. *Куак арты* – Кама Тамагы районы Иске Казиле авылы янындагы урын атамасы. *Куак болыны* – Саба районы Олы Шыңар авылы янындагы болын атамасы (элек анда куаклык булган. Аны чистартып болын ясаганнар). *Куаклык урман* – Апас районы Кече Болгаер авылы янында. *Куак су буе әрәмәлеге* – Лениногорск районы Түбән Чыршылы авылы янындагы әрәмә атамасы. *Югары Куак* – Буа районы Бик-Үти авылы янындагы куаклык атамасы. *Камышлы куак күле* – Апас районы Кылчык авылында. *Чыршылы куак* – Арча районы Урта Аты авылы янындагы урман атамасы. *Чытырлы куак* – Актаныш районы Иске Байсар һәм Буа районы Яңа Чәчкаб авыллары янындагы урман атамасы. *Алач куагы* – Буа районы Кыр Кайбычы авылы янындагы урман атамасы. *Алач куагы елгасы* – Буа районы Кыр Кайбычы авылы янында. *Аю куагы* – Апас районы Кормаш авылы, Балык Бистәсе районы Котлы Бөкәш һәм Чистай районы

Татар Талкышы авыллары янындагы урын атамалары. *Аю куагы өсте* – Чистай районы Зирекле авылы янындагы калкулык атамасы. *Аю куак сазы* – Кукмара районы Өлге авылы янындагы Кенә елгасы бассейнында. *Таң куагы сазлыгы* – Апас районы Колгына авылы янындагы Зөя елгасы бассейнында. *Өч куак* – Буа районы Карлы авылы янындагы урын атамасы. *Куаклык* – Саба районы Эзмә авылы янындагы урын атамасы. *Куаклык урман* – Апас районы Кече Болгаер авылы янындагы әрәмә атамасы. *Каз куагы* – Аксубай районы Дума авылы янынннан агып үтә торган Шәрбән суы бассейнында. *Теләү куагы* – Кама Тамагы районы Кече Карамалы авылы янында Уй елгасы кушылдыгы. *Баян куагы* – Балтач районы Чаптар авылында Баян исемле кеше җирендәге куаклык. *Юкәле куак* – Яшел Үзән районы Норлат авылы янындагы куаклык атамасы. *Юкәле куак елгасы* – Арча районы Корайван авылы. *Юкәле куак* – Буа районының Бик-Үти һәм Иске Суыксу авыллары янындагы кырлар атамасы; Кайбыч районы Олы Урсак авылы янындагы урман атамасы. *Югары куак* – Буа районы Бик-Үти авылы янындагы куаклык атамасы. *Өдер куаклыгы* – Биектау районы Чуваш иле авылы янындагы куаклык атамасы. *Даулы куак* – Саба районы Олы Кибәче авылы янындагы куаклык атамасы. *Әхмәт куаклыгы* – Саба районы Кече Шыңар авылы янындагы басу атамасы һ.б.

***Кул.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *кул* II иске, диалекталь «инешле ерынты, сулы сыза» дип бирелгән. *Болар [өч елга] кушылалар да, ул җиргә чаклы кечкенә кул гына булып агып яткан Өзән елганы берьюлы зурайтып җибәрәләр.* Г. Ибраһимов (ТТАС, II: 186). В. Радлов сүзлегендә *кол – кул*ның таранчы, чыгтайларда «елга юлы»н белдерүе теркәлгән (Радлов, т. II, ч. 1: 583). Керәшен татарлары сөйләшендә *кул* – «үзән, чокыр», урта диалектның гәйнә һәм красноуфим сөйләшләрендә *кул* һәм *кулара* терминнары «ике тау арасындагы үзән»не белдерә (ТТДС, 1969: 208, 209). Башкорт теленең караидел сөйләшендә *кул, кулат* – «уйсулык, уйсу җир, тар сай чокыр».

*Кул* термины белән ясалган атамалар байтак: *Үгез кулы* – Лениногорск районы Урдалы авылы янындагы урын атамасы. *Кул чокыры* – Тәтеш районы Сөендек авылы янында (Зөя бассейны). *Габдрахман кулы* – Азнакай районы Карамалы авылы янындагы урын атамасы. *Тимерле кул* – Азнакай районы Чубар Абдул авылында. Мәллә елгасы бассейнында. *Карамалы кул* – Азнакай районы Күк Тәкә авылы янындагы җир атамасы. Бу очракта кул – ике тау арасындагы үзән. *Ишлекәй кулы* – Баулы районы Акбаш авылы янындагы Миләшле кул елгасы бассейнында. *Байбак кулы* – Баулы районының Татар Кандызы авылы янындагы чәчүлек җир (чокыры да бар). *Чирмеш кулы* – Баулы районы Исергәп авылы яныннан агып үтә торган Томбарлы елгасы бассейнындагы урын атамасы. *Бүре кулы* – Азнакай районы Октябрь Бүләге авылы янындагы урманлы чокыр. *Хуҗи кулы* – Сарман районы Рангазар авылы янындагы җир атамасы. *Нәмәк кулы* – Азнакай районы Сарлы авылы янындагы урын атамасы. *Кәшмәй кулы* – Баулы районы Акбаш авылы янындагы урын атамасы. *Мәчет кулы суы* – Баулы районы Акбаш авылы яныннан ага торган Ютазы елгасы бассейнында. *Җиләкле кул* – Азнакай районы Октябрь Бүләге авылы янындагы урын атамасы. *Каенлы кул* – Буа районы Түбән Наратбаш авылы янындагы Сибел елгасы кушылдыгы. *Иксан кулы өсте* – Аксубай районы Карамалы авылы янындагы басу атамасы. *Ишлекәй кулы* – Миләшле кул бассейны. Баулы районы Акбаш авылы янында. *Абзан кулы* – Лениногорск районы Урдалы авылы янындагы алан атамасы. *Кәли кулы* – Лениногорск районы Иске Иштирәк авылында Кәли исемле кеше умарта тоткан җир.

Актаныш районы Иске Балтач авылы басуындагы *Юкәле Кул суы* танылган шагыйрә Фәйрүзә Мөслимованың «Юкәле Кул» шигырендә болай искә алына:

*Юкәле Кул суы ага*  
*Кыр-басу уртасыннан.*  
*Төнбоеклары тирбәлә*  
*Уйларга талган сыман.*

*Юкәле Кул акрын ага,*
*Көтеп арадлыр Шәбез.*
*Суга йомычка салыйк та,*
*Узышыйк әле, ягез!*

Актаныш районының Кадермәт авылы янында, авылның көньяк юнәлешендә бер ерым бар. Аны *Ялкау кул чокыры* дип йөртәләр. Терпеле елгасына кушылучы башка ерымнарга караганда ул иң соңыннан, иренеп кенә эрегән. Ул Терпеле елгасына иң ахырдан гына килеп кушылган. Борынгы авылдашлар ташу бетүне *Ялкау кул* суы гадәтеннән белгәннәр. «Ялкау кул ерымының суы Терпелегә килеп кушылгач ташу бетә», – дип әйткәннәр алар. Акрын гына бозлары эрегәнгә күрә аны *Ялкау кул ерымы* дип атаганнар. Исем-атамалар дөньясы да кызыклы. *Каракош кулы* – Азнакай районы Сәпәй авылы янындагы урын атамасы.

*Кул* компоненты белән микротопоним атамалары да очрый: *Коры кул басуы, Байбак кулы ышнасы, Миләшле кул урманы, Мәчет кулы күпере, Байбак кулы тавы, Сабантуй ягы кулы* һ. б.

*Кул* компоненты белән ясалган атамалар читтәге төбәкләрдә дә шактый теркәлгән. Ульяновск өлкәсендә: *Карамалы кул, Наратлы кул, Зирексар кулы* – Иске Кулаткы районының Яңа Кулаткы һәм Иске Зеленай авыллары елгалары. Саратов өлкәсендә: *Ташлы кул, Яман кул* – Камышлы районындагы елгалар (хәзер исә сусыз чокырга әйләнгәннәр). Башкортстанда: *Каракул* елгасы – Караидел районындагы елга. Бүздәк районыннан ага торган Түрүш елгасының уң кушылдыгы *Кыскакул. Минеш кулы* – Авыргазы районы Иске Морадым авылы янындагы үзән җир һ. б. Чиләбе өлкәсендә: *Сәярә кулы, Чытыркул* – коры елгалар. Саратов өлкәсендә: *Ташлы кул, Ташлы кул өсте басуы, Чытыркул урманы* – Камышлы районы Иске Ярмәк авылындагы урын исемнәре. Самара өлкәсендә: *Дәүләткул* – Камышлы районындагы татар авылы. Башкортстанда составына *кул* компоненты кергән түбәндәге авыл атамалары бар: *Шәрлекул* (Благовар районы), *Имәнле кул* (Чакмагыш районы), *Каракул* (Архангел районы), *Кыскакулбаш* (Бүздәк районы).

Башкортстанда *кул* компоненты белән микротопонимнар да байтак: Архангел районында бер урын *Канкул* исемен йөртә.

Төрки телләрдә: төрекмән – *гол;* башкорт, татар, үзбәк – *кул;* уйгыр, төрек, борынгы төрки, тыва, хакас – *кол;* чуваш – *хул* терминнары *кул* мәгънәсендә кулланыла алулары белән тагын икенчел, күчерелмә планда йөриләр. Боларга *тармак, коры елга юлы, чокыр, кушылдык, үзән* кебек сүзләр керәләр.

«Елга», «үзән», «елга култыгы» мәгънәсен аңлата торган *кол* сүзе Урта Азиядә, нигездә, елга атамалары составында килә: *Алтыкол, Каракол, Кенг-кол, Музкол, Нарынкол, Сарыкол* һ. б. Бу компонент ялгыз гына кулланылмый, бары тик атамалар составында гына очрый. Бу аның борынгылыгын күрсәтә (Караев, 1986: 27). *Чаткал* елгасының мәгънәсен С. Караев болай аңлата: «*чат* – «елга култыгы», «тармак», кыргыз телендә чат «елгалар бер-берсенә кушылыр алдыннан, алар арасында калган урын» + *кал. Кал* – ниндидер борынгы сүз булып, хәзер ул кулланылыштан төшеп калган булса кирәк. Бәлки, ул элек «елга» мәгънәсендә дә кулланылгандыр» (Караев, 1986, 29). *Каракол* – Пржевальск шәһәренең элекке исеме. Дагстанда *Ачикол* елгасы бар. *Агачлыкол* (урманда су ага торган иңсү урын) – Кабарда-Балкариядә. Төньяк Кавказда *Иткол* исемле данлыклы туристлык комплексы бар (Мурзаев, 1984: 283). Алтай топонимиясендә «кол», «коол» форманты турында О.Т. Молчанова яза һәм ул аның таралыш ареалы күрсәтелгән карта да биргән (Молчанова, 1979: 66–68).

*Кол~кул* термины кечерәк елга атамалары составында актив кулланыла. Джунгардиядә *Баин-кол, Цаган-кол*; Алтайда – *Каракол, Аккол* елгалары; Шориядә *Таштагол, Мастакол* һ. б.; Енисей елгасының югары агымында *Баян-кол* һ. б. елгалар бар. Бу терминны төрки телләрдән монголлар да алынма итеп алганнар һәм ул алар телендә актив кулланыла. *Хал-хингол* «Халха – монголлар елгасы», *Цаган-хол* «Ак елга» һ. б. (Малолетко, 1992: 51). «Кет» топонимиясендә *кул, ул* сүзләре «елга» мәгънәсендә кулланыла. Шунысы әһәмиятле, аның таралыш

җирләре төрки *чул* («елга», «инеш») термины белән тәңгәл килә (Дульзон, 1960: 5). *Кул* сүзенең таралыш ареалын профессор Э.М. Мурзаев тикшерә. Бу сүз Урта Азиядә, Төньяк Кавказда һ. б. җирләрдә очрый.

***Култык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *култык* «диңгез, күл һәм башка сулыкларның коры җиргә уенты рәвешендә кереп торган өлеше» диелгән. *Кара-бугаз-гол култыгы, Фин култыгы. Бәсер елгасы – бәләкәй елга, әмма ләкин, бик боргалана-боргалана акканга күрә, култыклар күп үзендә.* Ш. Камал. *Көчле агым боз кисәкләрен култыклардан кагып чыгара.* Ә. Фәйзи (ТТАС, II: 188). Борынгы төрки телдә *қолтіқ – култиқ* – «култык», «елга кушылдыгы»н аңлаткан (МК, I: 440). Радлов сүзлегендә терминның «елга култыгы» мәгънәсе теркәлгән (т. II, Ч. 1: 987).

Термин су чыганаклары атамалары составында бик еш очрамый. Шулай да экспедиция-сәфәрләребез вакытында кайбер атамалар теркәлгән. Бу термин үзе генә дә елга атамасы булып кулланыла алган. *Култык* – Кама Тамагы районында Ылгыма суы, Биектау районында (элекке Дөбьяз районы) Ашыт суы, Теләче районындагы Тәмте суы кушылдыклары һ. б.

Бу термин елга атамалары һәм гомумән топонимнар составында да килә: Минзәлә районында Бикбау авылы яныннан ага торган Ык елгасындагы олы, жылым тарта торган култык *Яланяр култыгы* дип атала. *Култык* – Кама Тамагы районы Олы Салтык авылы янындагы аерым җир атамасы. *Култык сазлыгы* – Кама Тамагы районының Олы Салтык авылы янында, Ылгыма елгасы бассейнында. *Култык чирәме* – Кама Тамагы районының Олы Салтык авылы янында аерым җир атамасы. *Култык чишмәсе* – Саба районының Урта Мишә авылы янында, Мишә елгасы бассейнында. *Кече култык* – Буа районы Адав-Толымбай авылы янында. *Кече култык елгасы* – Майна елгасы кушылдыгы (Спас районы), *Олы култык елгасы* – Актай елгасы кушылдыгы (Спас районы), *Култык күле* – Сөн елгасы бассейнындагы су чыганагы (Актаныш районы), *Култык чишмәсе* –

Сөлчә елгасы бассейны (Аксубай районы), *Култык сазлыгы* – Ылгыма суы бассейны (Кама Тамагы районы). *Юлдаш култыгы сырты* – Лениногорск районы Түбән Чыршылы авылы янындагы урын атамасы. *Талип култыгы* – Әлки районының Иске Чаллы авылы янындагы урын атамасы. *Уразай култыгы* шулай ук Иске Чаллы авылы янындагы урман култыгы. *Карга оялаган култыгы* – Әлки районы Иске Салман авылы янындагы җир атамасы. *Хисамый култыгы* – Саба районы Иске Җөри авылында (Олы Мишә елгасының бу урынында Хисамый исемле кеше батып үлгән). *Казма култыгы* – Тәтеш районы Олы Тархан авылы янындагы алан атамасы. *Айтуган култыгы* – Апас районы Кошман авылы янындагы урын атамасы. *Казма култыгы* – Тәтеш районы Олы Тархан авылы янындагы алан атамасы. *Кәрәкәй култыгы* – Буа районы Адав-Толымбай авылы янындагы култык (бу култыкта кәрәкә балыгы күп булган).

*Култык* – прозада һәм шигърияттә дә еш кулланыла.

Гомәр ага Бәширов «Кунак кызлар килде утырмага» повестенда *култык* сүзе урынына *күрфәз* сүзен куллана. *Күрфәз* сүзе «култык» мәгънәсен аңлата: *«Зәңгәр диңгезләрдә аккошлар төсле генә йөзеп баручы ап-ак кораблар, кыя ташлар арасында шул кораблар кереп туктый торган зәңгәр сулы аулак күрфәзләр бар».*

Г. Бәширов «Җидегән чишмә» романында *култык* терминыннан матур файдалана: *«Урман эченә култык булып уелып кергән аланнан казлар кыйгылдаганы, аларның тонык кына гүләгәннәре ишетелә иде. Нинди ераклардан кайталар, кайларга китәләр, рәхмәт төшкерләре! Ләкин адашмыйлар...»; «...Була бит яр кырыенда шундый тын култыклар. Андагы бөтерчеккә барып эләккән йомычкалар, яфрактыр, фәләндер я дәү агымга чыга алмыйча, я батмыйча тик әйләнә шул чүп-чар арасында...»*

Шул ук романда автор *Сандугач култыгы* атамасын куллана: *«Җидегән халкы Фәйрүзәне „Сандугач култыгы“н сөрдерергә юл куюы өчен һаман гафу итә алмый, аңа һаман үпкәли иде әле».*

Фоат Садриев та «Таң җиле» романында *култык* терминын куллана: *«Ыкның җылы сулы, төбе ләмле култыкланып торган тар гына урынына чабышып барып керделәр».*

Тажи Гыйззәтнең «Әдрән диңгез» дип аталган шигырь юлларында *култык* сүзе кулланыла:

*Әдрән диңгез, зәңгәр диңгез,*
*Ай, зәңгәр диңгез.*
*Култыклары йөз дә сигез,*
*Ай йөз дә сигез.*

Роберт Әхмәтҗановның исем куелмаган бер шигырендә *култык* компонентының күчерелмә мәгънәсе болай китерелә:

*Мәхәббәт һәм гүзәл җир турында*
*син җырладың кояш култыгында.*
*Мин кушылдым җырга – ике, пар җыр,*
*акчарлактай киңлек офыгына*
*Очып китте бездән! Күк диңгездә*
ике сулыш калды икебездән.

Нурислам Хәсәновның «Иңрәү» повестенда мондый юллар укыйбыз: *«Көн сүрелеп кичкә якынлашкач, урман полосасы буендагы арыш басуында, култыктарак, Басыйр комбайны туктап калган иде».*

Зариф Бәширинең *«Тау култыкларында»* исеме алган романы бар.

*Култык* лексик берәмлеге белән ясалган атамалар Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә бар: Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы, Саратов өлкәсенең Камышлы һәм Похвистнев районнарында *Култык күле* атамалары бар.

*Култык* компоненты кайбер очракларда микротопонимнар составында да килергә мөмкин. *Култык* – Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы, Барыш районнарында, Саратов өлкәсенең Дергачев районында, Чиләбе өлкәсенең Ваһап районнарында беркетелгән аерым урыннар исемнәре. Күренгәнчә, бу термин-

ның таралу ареалы киң. Самара өлкәсендәге *Култык* – Сок елгасы кушылдыгы. Саратов өлкәсендәге Дергачев районының Сәфәр авылында *Култык* – елга һ. б. Бурятиядә – *Култык* топонимы теркәлгән (Мельхеев, 1969: 9). *Култык* – Байкал күленең көньяк-көнбатыш өлешендәге атама. Камчатканың Олютор районында *Култук* һәм *Кутлушино* исеме алган култыклар, Камчаткадагы Петропавловск шәһәрендә *Кутлушное* күле, Азәрбайҗанда *Ачы Култык,* Каспий диңгезендә *Уле култык* атамалары сакланган.

Төрки телләрдә бу компонент төрле фонетик вариантларда әйләнештә йөри. Азәрбайҗан телендә *голтуг* – «тар, сай, култык», «елганың иске юлы»; үзбәк телендә *култик* – «култык»; нугай һәм кумык телләрендә *колтык* – «елганың иске юлы», «култык» мәгънәсендә термин буларак кулланыла.

Мәшһүр тюрколог Н.К. Дмитриев язуына караганда: «Татар телендәге *култык,* төрки *qoltuk* төрки *кул* тамырыннан башлангыч ала һәм *култык асты* (подмышка), *урман алды култыгы* (залив перед лесом) мәгънәләрен белдерә. Дон елгасы тирәләрендә „колтук“ термины „урман“ мәгънәсендә дә йөри» (Дмитриев, 1958).

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *култук/колтык* – «тар, сай, ябык диңгез яки күл култыгы». Бу термин Идел буе топонимиясендә дә очрый. Көнчыгыш Себердә ул «чокыр», «пароходлар кышлый торган урын», «елганың кечкенә генә култыгы барып терәлгән урын». Якутия-Сахадагы Индигиркада *култык* – «култыкның тын очы». Томск өлкәсендә *култук* «елга борылышындагы ярымутрау». Байкалда – *Култук* «култык ягыннан исә торган җил», Донда – «урман». Төрки *qoltiq кул* тамырына кайтып кала һәм мәгънәсе: 1) «култык», «урман алдындагы култык».

***Күл*** термины «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә теркәлгән. «Бөтен яктан да ярлар белән уратып алынган табигый сулык һәм су түгелеп, җыелып барлыкка килгән кечкенә сулык; күлдәвек» (ТТАС, II: 295). Борынгы төрки телдә *көл* дип «күл,

су җыелып тора торган урын» аталган (ДТС, 169: 313). *Күл* термины «Идегәй» дастанында кулланыла:

*...Ул чуарны мен, – диде. –*
*Күн давылбыз так, – диде.–*
*Җил карамый җил, – диде. –*
*Тотар бавы сум алтын*
*Асыл шонкар кош бирим,*
*Күл әйләнә чөй, – диде. –*
*Бер бите айдай балкыган,*
*Бер бите көндәй салкыган,..* (Идегәй, 1988: 34)

*Идегәй ирнең көнендә*
*Ил казнасы бай булды.*
*Биләгәне кол булды,*
*Әйләгәне мал булды;*
*Җәеп салса – көмешен –*
*Җәйрәп яткан күл булды;*
*Өеп салса алтынын –*
*Әлдермештәй тау булды.*
*Ашаган казы – ял булды,*
*Эчкәне сары бал балды.* (Идегәй, 1988: 35).

Күл – *kol* терминының «күл» мәгънәсендә йөргүен Радлов теркәгән (Радлов, т. II, ч. 2: 1465). Н.А. Баскаков гомумтөрки күлнең монгол телендә «елга, чишмә, сазлы күл»не аңлатучы *гол* апеллятивы белән генетик бәйләнешенә игътибар итә (Баскаков, 1969: 65). Э.М. Мурзаев *күл~гол* терминнарын махсус тикшеренү кирәклеге турында яза (Мурзаев, 1964: 13). Бу сүз төрле фонетик төрдәшләр белән төрки телләрнең барысында да табыла. Мәсәлән: кумык – *кёл;* нугай – *къол;* кыргыз, казак, хакас, каракалпак – *көл;* үзбәк – *кўлė;* чуваш *кўлĕ* һ. б.

XV гасырда яшәгән Хәсән Кайгының иҗатына табигатькә якынлык, аңа янәшә яки капма-каршы куяю юлы белән кешенең рухи халәтен, әхлакый, иҗтимагый күренешләрне тасвирлау хас. Әдипнең бер шигырендә *күл, су* сүзләре болай искә алына:

*Күлдә йөргән кыңгыр каз,*
*Кырда йөргән дуадак,*
*Авылдагы яманнар*
*Күчеп-кунып йүрмәгән*
*Кыр кадерен ни белсен!*
*Су кадерен ни белсен!*
*Ир кадерен ни белсен!*
*Җир кадерен ни белсен!*
*Күчсә куна белмәгән,*
*Акылына күнмәгән, –*
*Кунса күчә белмәгән,*
*Йорт кадерен ни белсен!*

Хәсән Кайгының тумышы Идел-Йорт белән бәйләнешле. Ул Олуг Мөхәммәт даирәсендә әүвәл Сарайда, аннан Казан ханлыгында яши, хөрмәтле, дәрәҗәле кешеләрнең берсе була. Гомеренең ахырында Нугай ханлыгына күчеп китә (Миңнегулов, 2006: 126–127).

*Күл* термины аерым күлләр атамасы булып кулланыла: *Күл* (Биектау районының Кодаш һәм Зур Көек авылларындагы күл атамасы). Гидронимик атамалар составында да шактый очрый: *Күлләр елгасы* – Курса суы кушылдыгы (Саба районы), *Атау күле* – Казан суы кушылдыгы (Биектау районы), *Бетле күл* – Бәйрәкә суы кушылдыгы (Баулы районы), *Балак күле* – Тигәнәле елгасы кушылдыгы (Алексеев районы), *Батунный күле* – Актай бассейны (Спас районы), *Канлы күл* – Гөбенә елгасы бассейны (Яшел Үзән районы).

*Ерык күл* – 1. Яшел Үзән районы Кече Өмәк авылы яныннан агып үтә торган Зөя елгасы бассейнында; 2. Питрәч районы Тау иле авылы яныннан агып үтә торган Норма суы бассейнында. *Юкәле киләк күле* – Алексеев районы Тигәнәле авылы янындагы күл һ. б. Актаныш районының Адай авылы тирәсендә күлләр байтак: *Акбалык, Акманай, Гарифә, Киндер, Кышкы, Мортыш, Мәртен күлләре.* Минзәлә районының Бикбау авылында *Кирмәнчек күле, Кар, Киндер, Кондызлы, Йөзәй,*

*Бетле, Иске авыл, Кәкре күл, Олы күл* бар. *Олы күл* атамасы алган күлләр Татарстанда да, аннан читтәге төбәк-урыннарда да шактый очрый, ләкин аларның һәрберсенең үз үзенчәлекләре һәм үз сыйфатлары бар. Аларның байтагы тарихи чыганакларда да теркәлгән. Нурулла Гарифның югарыда аталган китабында *Олы күл* болай сурәтләнә: «Большое (Олы күл) арв. вотч. оз. на Горной стороне, близ р. Волги – № 207. Б. 53. № 29». *Олы күл* тамаклары, Төнбаклы күлләре бар. Минзәлә районының Калморза авылында *Ислам күле, Кәкре күл, Ярimән күле, Михәйлә күлләре* бар.

*Күл* – Татарстанда утыз сигез авыл исем-атамасында һәм микротопонимнар составында кулланыла: *Күл коесы, Күл сукмагы, Күл болыны, Күл тавы, Күл ышнасы, Күл әвене* һ. б.

*Күл* термины һәм аның белән ясалган топонимнар тарихи чыганакларда (елъязмаларда, теркәү кенәгәләрендә, акт материалларында, генераль ызанлау карта-аңлатмаларында, халык санын исәпкә алу документларында, тарихи-статистик, тарихи-географик һ. б. кыйммәтле тарихи әдәбият-чыганакларда), карталарда, кадастр материалларында татар халкының күпсанлы рухи хәзинәләре – борынгы кулъязмаларда, кабер ташларындагы гыйбрәтле шигырь юлларында, авыллар тарихларында еш очрый. Нурулла Гарифның тарихи чыганаклардан тупланган сүзлегендә *Җиде күл* атамасы болай бирелгән: «Едигол (Җиде күл), озеро, совр. д. Семиозерка. – № 76» (Н. Гариф, 2011: 54).

2009 елда экспедиция-сәфәргә чыккач, Яшел Үзән районының Зур Карагуҗа авылына да кердем. Өлкәннәр белән сөйләштем, сүз борынгылыклар турында барды. Шушы авылда яшәп көн иткән шагыйрә Суфия апа миңа авылның татар телендә элек *Җиде иле* дип йөртелүен әйтте. Хәзер татарча атама онытылган, аны руслар да һәм татарлар да Семиозерка дип кенә йөртәләр. Суфия апаның нәселе зыялылык белән сугарылган булганга, ул ханым авылның чын һәм борынгы атамасын әти-әнисеннән отып калган. Димәк, авыл да *Җиде иле* һәм күл дә *Җиде күл* дип йөртелгән. Бәлки, ул үзенә атаманы шул күл-

ләргә нисбәтән алгандыр. Ләкин шул ук вакытта борынгы татар телендә *ете* хәзерге *җиде* мәгънәсендә кулланылган. Тарихи чыганакларда *ете* (хәзерге җиде) кабилә-кавем атамасы буларак та очрый. Бәлки авылга *ете* (җиде) кавем-кабиләләре нигез салгандыр.

*Күл* лексик берәмлеге әдипләребез иҗатында киң файдаланыла. Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романында *күл* термины кулланыла: *«Якты күл җәйләвеннән чыгып, сәгать ярымнар баргач, ат өстендә чабып килгән бүз балалар очрады, карт балалардан Әхмәт авылының кайда күчкәнен сорады».*

Гомәр ага Бәширов иҗатында диңгез, тау, елга, инеш, күл, урман кебек географик терминнар шактый күп кулланыла: *«Синең алдыңда барган саен яңа илләр, яңа шәһәрләр елгалар, күлләр ачыла. Һәркайсының нindидер искиткеч ягы, сокланмгыч яки куркыныч яклары бар. Кәгазь өстендәге сары һәм бигрәк тә кызыл урыннар – башы күкләргә тигән карлы таулар булып, зәңгәр урыннар дулкынланып торган диңгезләр булып җанлана».*

Фоат Садриевның «Таң җиле» романында күл термины күңелне, халәтне әллә нишләтеп, шомландыру белән тутыра: *«Ана үрдәк тәненә яндырып ядрә керүен һәм каны ага башлвын сизде, һавага кан исе таралды...Ул, балалары белән хушлашып, берничә кычкырды да, мәрхәмәтсез кулларга эләкмәс өчен әле генә үзләре күтәрелгән күлгә таба борылды». «...Кабык күленең яр буенда йөзүче бер оя чүрәкәй үрдәк таң җиленә куанып куркылдашып куйды...»*

Шагыйрә Салисә Гәрәеваның исем куелмый гына язылган шигырендә мондый юллар укыйбыз:

*Акчарлаклар уйнак түгел,*
*Килер кыш кунак түгел!*
*Агач, җил, күл телен аңлап*
*Борлыга минем күңел.*

*Күл* – Татарстаннан читтә яшәп яткан халык телендә дә актив кулланыла. Башкортстанда: *Йылтырак күл* (Мәчетле

районы, Яңа Мишәр авылы), *Йылтыр күл* (Күгәрчен районы Нукай авылы), *Кирәкмәс күл* (Әбҗәлил районы Таштимер авылы), *Киң күл* (Илеш районы Юлдаш авылы) һ. б. Чиләбе өлкәсендә: *Ала күл, Алтын күл, Идрәс күл, Буклы күл* (Кыштым һәм Кара Күл районнары) һ. б. *Күл* сүзе Башкортстанда авыл атамалары составында да кулланыла: *Баллыкүл* – Әлшәй районындагы бистә, *Балыклыкүл* – Авыргазы районында, *Каракүл* – Дуван районында, *Чуртанлыкүл* – Балтач районында, *Кортлыкүл* – Караидел районында һ. б. Ульяновск өлкәсендә: *Үти күле, Сулы куак күле, Әбәй күле, Карамалы күле, Упкын күле* – Иске Кулаткы районының Яңа Зеленай, Зирекле, Иске Тирешкә, Югары Тирешкә авылларында. Бу өлкәдә *күл* сүзе микротопонимнар составында да актив кулланыла. *Кул йулы, Күл басуы* – Иске Кулаткы районының Иске Мастяк авылында һ. б. Самара өлкәсендә: *Җирексәр күле, Сары күл, Бака күле, Мөбаракша күле* яисә *Ташбаш күле, Беренче күл, Икенче күл, Сазлык күле* – Похвистнев, Камышлы районнарының Мочали, Татар Байтуганы, Иске Ярмәк авылларындагы күлләр. Самара өлкәсендәге кайбер микротопонимнар: *Күл тавы, Озын күл йулы, Олы күл арты кыры, Яриәхмәт күле* умарталыгы – Камышлы районының Иске Ярмәк, Шонталы районының Татар Әбдекие авылларында. Төмән өлкәсе Ялутор районында *Күл авылы* бар.

Бурятиядә *кол, кул (хул)* апеллятивлары «күл» мәгънәсендә кулланыла: *Котокель, Биракуль, Шаракул, Куль (Кульск), Кули* һ. б. (Мильхеев, 1969: 38). О.Т. Молчанова язуынча, Новосибирск өлкәсенең көнбатыш төбәгендә, шулай ук Омск өлкәсендә, Павлодар өлкәсенең төньягында *күл* терминын эченә алган атамалар шактый актив, ә Алтайда һәм Кемерово өлкәсендә сирәгрәк кулланылалар. Новосибирск өлкәсенең көнбатышында *куль* урынына *гуль* термины әйләнештә йөри (Молчанова, 1966. Вып. 3–15). Бу урында *Байкал* күлен искә алып китү урынлы булыр. «Бу күл атамасының килеп чыгышын күп галимнәр якут телендә „бай“ мәгънәсен аңлаткан *бай* һәм шул ук телдә

„күл“ төшенчәсендә кулланылган *кел (кель)* термины белән бәйлиләр. Бу аңлатма дөреслеккә якын булуы белән аерылып тора, күл чынлап та балыкка бик бай. Әмма тел галимнәренең соңгы еллардагы тикшеренүләре нигезендә, Байкал атамасы төрки-монгол телләрендәге сүз *байгал* – „зур су чыганагы“, “зур бассейн“га нисбәтән аңлатыла. Димәк, Байкал „зур су чыганагы“ дигән мәгънә аңлата», – дип нәтиҗә ясый М.Н. Мельхеев (1969: 114). Себер буйлап сәяхәт иткән В. Радлов, Алтай төбәгендә *Сарыкель* исемендәге күл теркәгән (1989). Кыргыз топонимиясендә *Ак-Көл* дигән дүрт атама теркәлгән. Өчесе гидронимиягә нисбәтле, ә берсе тау сыртын, тау үткелен атый. Гидронимга мөнәсәбәтлеләренең икесе – күл, ә берсе – елга. Мең Кош елгасының сул кушылдыгы (Нарын өлкәсе Жумгал районы). *Баш-Көл* күлләре һәм елгасы да Нарын елгасының сулъяк ярында. Алар Нарын өлкәсенең Тугызторос районында урнашканнар. *Кара-Көл* Кёгарт елгасы бассейнындагы күл (Ош өлкәсе Сузак районы). *Кара-Көл* – Ош өлкәсенең Сузак һәм Талас өлкәсенең Токтогул районнарында; *Кара-Көл* – Катта – Калай-Махмуд (сох) елгасының югары агымындагы күл (Ош өлкәсе Батенкен районы). *Сары-Көл* – Нарын елгасының уң ягына урнашкан күл – Ыссык күл өлкәсе Джетиогуз районы һ. б. Кырым топонимиясендә түбәндәге күл атамалары теркәлгән: *Аджиголь, кара-коль, Ениколь, Барак-Коль, Улуколь, Япрак-Коль, камышлы Коль, Сарыколь, Монаколь, Айгуль, Аиргуль, Ашага-Аиргуль, Юкары Аиргуль, Пиникуль, Доркуль* һ. б. В. Тизенгаузенның фарсы чыганакларыннан файдаланып эшләнгән хезмәтендә, аерым алганда Низам-эддин Шәминең «Җиңүләр китабы»ннан алынган бер өзегендә, *Кырык-Күл* исеме алган урын атамасы теркәлгән. «Туктамыш патша үзенең гаскәрләренә *Кырык-Күл* дип йөртелгән урында җыелырга әмер бирә. Без үз отрядыбыз белән билгеләнгән урынга килдек, ләкин Туктамыш ханны тапмадык һәм аңа нәрсә булганын да белмибез» (Тизенгаузен, 1941: 115). *Күл* термины белән ясалган топонимнарның таралыш ареалы Э.М. Мурзаев тарафыннан тикшерелгән (1984: 312–313).

***Күлдәвек, күлләвек***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *күлдәвек* – «кар эрегәннән яки яңгыр яуганнан соң җыелып калган су». *Сәлимгәрәев тәрәзә буена килеп, аның күлдәвекләр аркылы күлмәк итәкләрен җыеп сикереп чыгуын күзәтте.* Г. Ахунов. *Машиналар батып утырган чокыр-чакырлар, һәр җирдә җыелган су күлдәвекләре ялтырап яталар.* М. Хәсәнов (ТТАС, II: 295).

*Күлдәвек* лексик берәмлеге халык телендә шактый еш кулланыла: *Хәлимә күлдәвек өстеннән сикереп чыгып, артка карамый гына, алга таба йөгерде. Авыл янында бер күл бар, ләкин ул күлдәвек кенә.*

*Күлдәвек* сүзе әдипләр иҗатында да очрый. Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романында мондый юллар укыйбыз: *«Янякта бил тиңентен аксыл томанда утырган карурман кала. Бормаланып аккан яп-якты инешләр, кечкенә күлдәвекләр ялтырап кала».*

*Күлләвек* термины географик берәмлек атамалары сыйфатында һәм үзе генә дә байтак кулланыла. *Тай күлләвеге* – Кама Тамагы районы Келәнче авылы җирендә, Төбәк елгасы бассейнындагы кечкенә күл. *Ат үлгән күлләвек* – Актаныш районы Өшәр авылы янында, Агыйдел суы бассейнында. *Яу чапкан арты күлләвеге* – Актаныш районы Өшәр авылы янындагы күлләвек. *Күлләвек* – 1. Кайбыч районы Олы Кайбыч авылы янындагы күлләвек (ул хәзер беткән); 2. Кама Тамагы районы Келәнче авылы янындагы бу зур күл дә инде кипкән; 3. Кама Тамагы районы Кыртапа авылында; 4. Апас районы Әҗем авылында; 5. Питрәч районы Иске Йорт авылы янында. *Күлләвек өсте* – Питрәч районы Иске Йорт авылы янындагы урын атамасы. *Күлләвек тавы* – Питрәч районы Иске Йорт авылы янындагы тау атамасы. *Күлләвек сызасы* – Кама Тамагы районы Келәнче авылында. *Юалы күлләвек* – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы янындагы кечкенә генә күл, Коры Үләмә бассейнында.

*Күлләвек* сүзенең мәгънәсен ачу өчен, сүзлек төзүчеләр укучы игътибарын *күлдәвек*кә юнәлтәләр. Мондый мисал ки-

терәләр: *Борылманы үтүгә зур-зур күлләвекләр очрый башлады.* А. Гыйләҗев. *Ул ераклашкач, күлләвек аша сикерде, юлын дәвам иттерде.* А. Расих (ТТАС, II: 295).

Мисаллардан күренгәнчә, бу термин прозаиклар иҗатында да һәм шагыйрьләр тарафыннан да кулланыла.

«Таштугай» дип аталган халык җырында *күләүек* термины кулланыла:

*Таштугай ла буе, ай күләүек,*
*Күләүек тә түгел, саз икән.*
*Сазларында сайрар кошлары юк,*
*Моңлы кошкайлары каз икән!*

Бу берәмлекләр татар теле сөйләшләрендә шактый кулланыла. Минзәлә сөйләшендә вак күлләрне, эчкен сөйләшендә күл яки акмый торган суларны, тау ягы, керәшен татарлары телендә су җыелып торган сазлырак җирләрне *күлләвек* дип йөртәләр (ТТДС, 1969: 282). *Күлләwәт* минзәлә сөйләшендә сазлы күл өстендә ачык урын. *Кичә Шәйәхмәт күлләwәтеннән бер чүрәкәй атып алдым* (ТТДС, 1969: 282). Оренбург татарлары телендә (сөйләшендә) *күлләвек* «түбән юеш урын». Соңгы елларда күлдәвек, күлләвек сүзләре әдәби телгә дә кабул ителде. Җыелган суларны атау өчен, татар теле сөйләшләрендә тагын түбәндәге сүзләр дә кулланыла: казан арты этнә сөйләшендә *бөйенде* – «яз көне җыела торган кар суы», минзәлә урынчылыгында – *чөгермәк,* эчкен сөйләшендә – *коток,* казан арты лаеш сөйләшендә *суwалма* – «язын су басучы болын», сергач, мәләкәс урынчылыгында яңгырдан соң су җыелуны «су тору» дип атыйлар.

*Күлләвәт* дип кәкре күлләрне атыйлар. *Кәкре күлләвәт* – Сөн суы бассейны (Актаныш районы), *Насый күлләвәте* – Сөн суы бассейны (Актаныш районы) һ. б.

***Күпер.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә күпер лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм *беренче мәгънәсе* болай аңлатылган: Елга, чокыр, тимер юл һ. б. ш аша үтеп йөрү өчен төзелгән корылма. *Тимер юл күпере. Челтәрле күпер такта-*

*сын Җиз дагалы ат таптасын*. Җыр. *Сабир абзый, елга аша яңа агач күпердән чыкканда, су белән тулы казларга игътибар итте*. Ә. Еники.// күч. Сөйләнә яки языла торган фикерләр арасындагы логик бәйләнеш, эзлекле күчеш.

*Икенче мәгънәсе*: Су читендә пароходка, паромга керү, көймәләр туктау, кер чайкау өчен такта яки бүрәнәләрдән ясалган корылма, мәйданчык. *Паром туктый торган күпердә, кулына кармак сабы тотып, Салих утыра*. Г. Мөхәммәтшин. *Гаҗәеп аяз көннең якты кичен мин Кабан күле читенә ясалган бер агач күпер өстендә каршы алдым*. Ф. Әмирхан.

*Күпер сугу* – сөйләм телендә «елга яки чокыр аша күпер салу, күпер төзү (ТТАС, II: 301).

Күпер лексик берәмлеге җыен атамалары ясауда да кулланыла.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, «Казансуның югары агымында, аның сул кушылдыгы Кесмәс һәм Кече Мишә елгасы, аның кушылдыклары ярында урнашкан авыллар халкы 8 җыен үткәргәннәр. Ә бу очракта безгә кирәклесе ***Күпербаш җыены.*** Бу җыенны май ахырында Кече Мишә һәм Мичән елгалары үзәннәрендә урнашкан Югары Утар, Түбән Утар, Керәнне, Бакшанды, Курсабаш, Өчөйле авыллары халкы үткәргән.

Җыен атамасы, күрәсең, Күпербаш географик атамасына нисбәтле рәвештә барлыкка килгән».

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге» хезмәтендә *күпер* лексик берәмлегенә мондый аңлатма бирелгән: «Төп мәгънәсе – елга, чокыр, тимер юл һ. б. ш. аша үтеп йөрү өчен төзелгән корылма. Электә сәүдәгәрләргә һәм яугирләргә елга аша кичү өчен тире каплар-күпүрүкләр хезмәт иткән. Эчләренә печән, мамык тутырылган шундый берничә кап өстенә утырып елганы кичеп чыкканнар. Күпүрүкләрне күп итеп җыеп, алар өстенә такта тезгәч, хәзергечә әйтсәк, пантон күпер хасил булган.// Күпер салу. Күпер сугу. Күпер төзү. Тагын кара: Күпрек».

*Күпрек* лексик берәмлеге «Миллият сүзлеге»ндә болай аңлатылган: «Борынгы сүз. – Күпер; сират күпере. / Тәүбә итмәй

нитәк күпрек үткем мына? Әхмәд Ясәви. Күпрекче – күперче. Бу сүз, мәсәлән, Тимер Котлыг хан ярлыгында очрый. Электә күперчеләр су юлларындагы күперләрнең төзеклеген күзәткәннәр һәм аларны төзәтү өчен халыктан махсус салым җыйганнар (И.Н. Березин)».

*Күпер* лексик берәмлеге топонимнар ясауда актив кулланыла. *Исмәкә күпере* – Балтач районы Түбән Кенә авылы янындагы күпер атамасы. *Күперле тау елгасы* – Биектау районы Әлдермеш авылы. *Күпер тавы* – Теләче районы Кече Нырсы авылы янындагы тау атамасы. *Күперле елга* – Арча районы Урта Аты, Саба районы Шекше, Чистай районы Татар Талкышы, Балтач районы Борнак авыллары янындагы елгалар. *Күперле тау кизләве* – Апас районы Кызыл Тау авылы янындагы кизләү. *Күпер очы* – Кама Тамагы районы Даныш, Каратай авылларындагы урам атамалары. *Күперле чокыр* – Тәтеш районы Үтәмеш авылы янындагы чокыр. *Чүннек күпере* – Теләче районы Кече Нырсы авылы янындагы күпер атамасы. *Мунчала күпере* – Чүпрәле районы Каракитә авылы янындагы күпер атамасы. *Мунчала буасы күпере* – Теләче районы Кече Нырсы авылы янындагы күпер атамасы.

*Күпер* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында кулланыла.

Фатыйх Хөснинең «Йөзек кашы» повестенда *күпер* лексик берәмлеге очрый: *«Күпер чыдарлык, таллар безнең файдага, яртылаш җиргә сеңеп беткән ташландык складлар берәүне дә кызыксындырмыйлар булса кирәк, әнә шул берәү дә кызыксындырмый торган яктан кинәт кенә без кызыксынсак, начар булмаячак».*

Вахит Имамовның «Утлы дала» исеме алган тарихи романында да *күпер* термины очрый: *«Әнә, капкаларыннан сулы ерым өстенә төшерелгән күпер каршында Алтынбәк хан үзе чабышка чыгарга җыенган айгыр төсле уңлы-суллы сикереп бәргәләнә».*

***Күрән.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *күрән* лексик компоненты «исем» дип, «сазда үсә торган тар, озын кыяклы

күпьеллык үлән; русчасы осока» дип аңлатылган. *Агачлардан дымлы урыннарда үсә торган зирекне, үләнчел үсемлекләрдән һәртөрле күрәннәрне, эт тигәнәген... күрсәтергә мөмкин. Ботаника. Атыр чәчкә бу көндә бар үләннәр, Үсәр суда камыш белән күрәннәр.* М. Гафури (ТТАС, II: 309).

*Күрән* лексик берәмлеге географик берәмлек атамалары ясауда кулланыла. *Йәри күрәне* – Баулы районы Байлар авылы янында сазлык, Ык елгасы бассейны. *Күрәнлек* – Актаныш районы Яңа Әлем янындагы җир атамасы. *Күрәнлек сазлыгы* – Азнакай районы Күк Тәкә авылы янындагы сазлык. *Күрән сазы* – Актаныш районы Иске Байсар авылы янындагы сазлык.

*Күрән* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында очрый. Фоат Садриевның «Таң җиле» романында *күрән* лексик берәмлеге үзенчәлекле итеп кулланылган: *«Әгәр анда-санда күбекләр акмаса, басма янындагы судан чыгып торган яшел түмгәкнең бөгелеп төшкән күрәнен агым туктаусыз селкетмәсә, Ыкның мәңгелек хәрәкәте бөтенләй сизелмәс тә иде».*

***Күтер*** төрки-татар гидронимиясендә «сазлы юеш урын» төшенчәләрен аңлата. *Күтер* сүзе гидроним һәм макротопонимнар атамалары арасында да очрый: *Күтер сазы* – Сөн буе бассейны (Актаныш районы), *Күтер күпере, Күтер аланы, Күтер басмасы* һ. б. Татар теленең минзәлә, эчкен сөйләшләрендә *күтер* – «сазлык, камышлар белән әйләндереп алынган түмгәкләр».

*Күтер* термины әдипләр иҗатында да кулланыла. Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясендә *күтер* формасы болай бирелгән: *«Ул (аҗдаһа) камышлы һәм кеше керә алмый торган күтерлекләрдә була, ди. Аны минем бабам күргән: буе унбиш колач, калынлыгы ат чаклы, ди».*

*Күтер* сүзе башка телләрдә дә очрый: монгол, бурят, калмык, коми телләрендә – *кужир, кудыр, куду-гур, кудук, куду, гуджир, гудыр* («тозлы саз, тозлы сулы инеш, тозлы туфрак, тозлак» мәгънәсендә).

***Кылган.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *кылган* «исем» дип ныгытылган һәм аңа мондый аңлатма бирелгән:

«Кыяклылар семьялыгыннан яфракларын озын тар кыяклар тәшкил иткән, йомшак себеркәч чәчәкле дала үләне; русчасы: ковыль». *Дала һәм чүл үсемлекләре корылыкка чыдам булалар; андый үсемлекләргә мисал итеп кылган һәм әремне күрсәтергә була*. Ботаника. *Кыякларын җәя кылганнар, Тубылгылар суза яфрагын*. Ә. Ерикәй.

*Кылган чугы* – кылганның себеркәчле чәчәге. *[Кызның чәчләре] кылган чугыдай аксыл-сарылар*. М. Хәсәнов.

***Кылганлык*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «исем» дип ныгытылган һәм «Тоташ кылган үскән урын, тоташтан кылган каплаган җир» дип аңлатма бирелгән. *Агыйдел дә буе, ай, кылганлык, бер бөртекләре дә кыл кебек*. Җыр. *Тимербикә апа... кылганлык(ны) күрсәтте*. Ә. Бәян (ТТАС, II: 220).

Әдипләр иҗатында кылган термины кулланыла: Фатыйх ага Хөснинең «Тау чишмәсе» хикәясендә күңелебездә, йөрәгебездә зур урын алган *кылган* термины кулланылган: *«Минем өемдә, кунак бүлмәсендә, пианио өстендә кышын да, җәен дә төс салмый торган кылган букеты тора. Кайбер җирләрдә кылганны «Әбиләр чәче» дип тә йөртәләр икән. Бик тә төгәл әйтелеш. Чынлап та, әбиләр чәче кебек аксыл-саргылт ул, әбиләр чәче кебек йомшак-сыек. Кагылма, кагылсаң, менә-менә тузгып, очып китәр кебек...»*

Марсель Галиевнең «Рух» китабыннан проза рәвешендә язылган күңелгә якын шигъри тәлгәш укыйбыз: *«Җәяүле диңгез [Олуг Дала] өстеннән җил йомгагы булып кылганнар йөгерә – дала дулкыннары. Шул дулкыннар арасында, ерагайган саен якынаеп, якынайган саен ерагаеп, ак җилкән тибрәнә»*.

Вахит Имамовның «Утлы дала» романында мондый юллар бар: *«Әтрәк кылганнар өстенә йөзе белән капланды һәм бөтенләй икенче дөньяга күчкән кебек булды. Кылганнардан ана сөте, атлар тире, кымыз, учактагы төтен, кызган кояш, сабый бала тәне, бал кортлары, ләйсән яңгыр, мөлаем яз, челтерек ерганаклар, төнбоеклы күл, талгын чишмә, ат кылы, яңа*

*гына савылган бия сөте... тагын әллә никадәрле сихри исләр барысы бергә кушылып аңкый иде».*

***Кыр***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем дип» ныгытылган һәм мәгънәсе болай аңлатылган: 1. (Урманнан, авыл һәм шәһәр утырган җирдән аерма лы буларак) урмансыз тигезлек, зур тигез ачык мәйдан. *Тулган ай үзенең моңсу нурларын урманнар, кырлар өстенә чәчеп әкрен генә йөзә*. Г. Әпсәләмов. *Безнең алда чит-читләре кара урман белән чикләнгән кыр күренеше ачылды*. Ф. Әмирхан. // Сыйфат мәгънәсе. Кырда булган, кырга урнашкан, кыр буйлап барган (юл турында).

2. Иген игү өчен эшкәртелә торган җир мәйданы, басу; ашлык үстерелә торган мәйдан, басу. *Мин бит бу кыр, бу басуда сабан сөргән, тырма тырмалаган, утаулар утап, ураклар урган идем.* М. Гафури. *Сул кул якта аксыл бодай һәм солы кырлары, кояш нурлары астында ялтырап, дулкынланып торган төсле күренә иделәр. Ш. Камал* (ТТАС, II: 223– 224).

*Кыр* лексик берәмлеге татар халкының борынгы чорлардан үткәрелеп килгән җыен бәйрәмнәре атамаларында да кулланыла.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда: «Урта Казансу һәм аның уң кушылдыклары Бирәзә, Ия елгалары ярына утырган Өчиле, Бирәзәбаш, Урта Бирәзә, Зур Бирәзә~Арча асты Бирәзә, Югары Әзәк, Түбән Әзәк, Мөндеш~Карачирмә, Югары Мәтәскә, Түбән Мәтәскә, Кәче, Күкчә-Бирәзә авыллары халкы бергәләшеп июль башында Күкчә җыйыны, икенче төрле *Олы кыр* җыйыны оештырганнар.

Археологлар мәгълүматларына караганда, әлеге җыен бәйрәме үткәрелә торган җирлектә, үзәге Арча шәһәрлеге булган бу урыннарда болгар-татар археологик һәйкәлләре табылган».

*Кыр* лексик берәмлеге белән топонимнар шактый күп ясалган. *Атау кыр* – Балтач районы Пүскән авылы янындагы кыр атамасы. *Кыр инеше* – Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылы янындагы инеш. *Кыр капкасы* – Әлки районының Иске Чаллы, Теләче районының Кече Нырсы авылларында бар

(элек мондый *капкалар* һәр авыл башында булган). *Сахалин кыры* – Яшел Үзән районы Тау иле авылы янындагы кыр атамасы. *Азлан кыры* – Чистай районы Яуширмә авылы янындагы басу атамасы. *Кыр инеше чишмәсе* – Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылы янындагы Кыр инеше бассейнында. *Кыр ягы* – Тәтеш районы Кече Әтрәч авылындагы урам атамасы. *Урамбай кыры* – Биектау районы Өмбе авылы янындагы кыр атамасы. *Торна кыры* – Чүпрәле районының Кече Чынлы, Балтач районының Курмала авылларындагы кыр атамасы. *Ликанур кыры* – Чирмешән районы Кара Чишмә авылы янындагы кыр атамасы.

Нурулла Гариф сүзлегендә *кыр* термины болай күрсәтелгән: «Еланское поле (*Ялан* авылы – кыры) – № 105».

*Кыр* термины әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында кулланыла. Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында бу лексик берәмлек шактый еш очрый: *«...Сиңа яраса, безгә ярамый, Фәсхетдин абзый. Ник дисәң, анысын да әйтим: безнең синекедәй үрә катырып Бөгелмәгә илтеп салган алты почмаклы яңа йортыбыз да, кесәгә керергә торган симез пенсиябез дә юк! Ишеттеңме! Безнең бөтен карап торганыбыз, юанычыбыз, куанычыбыз менә шушы туган туфрагыбыз – кырларыбыз, тугайларыбыз, татлы суларыбыз!»*

Мөхәммәт ага Мәһдиевнең гүзәл иҗатында *кыр, урман* туры һәм күчерелмә мәгънәдә кулланылган: *«...Яктыра башлады. Урман да бетте. Кырда салкынча, себерә торган буран. Иртәнге сорылыкта урман кырындагы училище бинасы күренә. Бер катлы агач йорт, урман буена сыя алмыйча, кырдагы кар диңгезенә таба сузылып таралып ята».*

*Кыр, кер, кир, хир, хыр* – кырым татарлары, төрек, казак һ. б. төрки телләрдә «нәрсәнең дә булса чит-чите, кырые», төрек телендә – «дала, тигезлек», көнчыгыш себер төркиләре диалектында «биек яр, елга уентыгы», шулай ук казак телендә «Иртыш белән Балхаш арасында таулы дала» (Радлов, II: 732–733). Төрки *кыр* – «калкулыкның югары ягы, яссы таулык, биек

булмаган тауның сырты, тәбәнәк таулар, калкулыклары булган дала, күтәренке урыннар» (Розова). Таҗик телендә *кир* – «калку урын, калкулык, үр, кечкенә таулар белән капланган урыннар»; ногай телендә *кыр* – «дала, кыр»; «басу» (Ногай сүзлеге); кырым татарлары телендә *къыр* – «дала (диалекталь сүз)», көньяк диалектларында *хыр* – «урман үсмәгән, тау сыртлары биек булмаган сөзәк тау» (О.А. Эбасанов).

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, төрки телләрдә *кыр* компонеты белән күп атамалар ясалган: Иртыш белән Балхаш арасында *Кыр* – күтәренке дала; Тывада – *Кара-Кыр* елгасы һәм *Хангай-Кыры* тавы; Хакасиядә – *Тастыгхыр* тавы; Алтайда – *Аткыр, Аюкыр* тавы, *Кырлык* елгасы, *Кырлык* торак пункты; Бурятиядә – *Нарат-Хэрэ* тавы; Якутия-Сахада – *Таях-Кырдала* исеме алган торак пункт; Төрекмәнстанда – *Капланкыр, Челюнгкыр;* Казакстанда – *Аккыр, Каракыр;* Үзбәкстанның Ташкент өлкәсендә – *Кыр-Арык;* Үзәк Тянь-Шань һәм Кыргызстанда – *Карлыккыр* сырты; Кыргызстанның Ош өлкәсендә – *Кыркол;* Фирганә кабыргасының көньяк-көнбатыш сөзәклегендә – *Сары-Кыр* кабыргасы. Болар Ош өлкәсенең Сузак районында урнашканнар; *Сары-Кыр* тавы Чон-Кой-Су елгасының сулъяк ярына урнашканнар (Ыссык күл өлкәсе). *Кара-Кыр* – Нарын өлкәсе Тогузторо районындагы тау, *Кара-Кыр* – елга, Он-Арча елгасының уң кушылдыгы (Нарын өлкәсе Тянь-Шань районы), Таҗикстанда *Киртау, Тузкыр, Каракыр* таулары; Азәрбайҗанда *Кыраг-Мучилан* һәм *Кыраг-Кесамам* торак пунктлары; Төньяк Кавказның Зур Черек үзәнендә *Бегий Кыр,* Баксан үзәнендә *Кыр Башы* таулары бар (Мурзаев, 1996: 112).

***Кыя***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *кыя* «исем» дип бирелгән һәм аның мәгънәсе түбәндәгечә аңлатылган: «Үтә текә таш тау; шундый тауның текә бите; үтә текә таш тауда чыгып тора торган зур таш». *Юл барган саен, куркыныч җирләрдән үтә. Аста – тирән чокырлар, икенче якта – өскә ава торган кыялар, ташлар*. М. Гафури. *Су буенда бер кыя бар, Ямьләп тора Иделне.* Ә Ерикәй. // Кыя формасындагы нәрсә (күбрәк

боз тавы турында). Алга карыйм: бозлар кыясында Седов тора, алга кул сузган. Ф. Кәрим.

*Кыя тау* – кара: *кыя. [Җик], куркыныч якынлашканын сизеп, кыя тауга менеп баса да, тиз генә җәясен алып, Уразмәт белән сүз куешу буенча, көмеш угын һавага атып җибәрә*. М. Җәлил.

*Кыя таш* – текә тауда чыгып тора торган зур таш. *Мин онытылып сиңа карап калдым, Баскан килеш кыя ташына.* Ш. Маннур (ТТАС, II: 246).

*Кыя* термины ялгыз гына атама булып та һәм атама составында да сирәк кулланыла: *Кыя тау* – Бөгелмә районының Сугышлы авылындагы тау.

*Кыя, кыя ташлары* лексик берәмлекләре әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында киң кулланыла.

Мөхәммәт ага Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә (истәлекләр)» исеме алган китабында *кыя* сүзе очрый: *«Менә илле бишенче елга кадәр моннан узганда поезд акрыная иде, әнә карагыз әле, теге кыя башында граниттан уеп эшләнгән иптәш Сталин һәйкәле бар иде, аны бер политический гаепле скульптор ун ел буе эшләгән, илле сигезенче статья, шуны эшләгәч өенә кайтарырлар дип ышанган ул».*

Вахит Имамовның «Татарлар Пугачев явында» исеме белән дөньяга чыккан, әдәби эпизодлар белән баетылган тарихи очеркында *кыя ташлары* гыйбарәсе күңелне шатландырып сурәтләүгә булышлык иткән: *«1762 елда олы-олы кыя ташлары тутырып ясалган әлеге буа шул көенчә тора. «Надан» сәүдәгәрләр белән «томана» крестьяннар төзи дә белгәннәр соң!»*

Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» романында *кыя* термины кулланылган: «*Һәм бу таш-кыялар, Аурупа белән Азия кыйтгасы арасында чик сызыгы булып, мәңгелеккә катып калганнар».*

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *кыя* термины чит төбәкләрдә дә очрый. Төрки телләрдә *кая* – «кыя, кыя таш, таш кыя». Дериватлары: *гаjя, хая;* үзбәк телендә дә *коя* нәкъ шулай, югарыда күрсәтелгән мәгънәдә. Якут телендә *хая*

*(хайа)* – «таш кыя, кыя таш, текә кыя ташлы сөзәклек». Болгар телендәге диалекталь «кыя таш» мәгънәсендәге *кая* төрек теленнән алынма дип карала. Фарсы телендә төрки телдән алынма *кая* термины «таш кыя, кыя таш, калкулык, тау бите» мәгънәләрен аңлата. Ялта янында *Ставрикая* кыясы бар. Грек телендә *ставро* «крест, тәре» дигән сүз. Кырым татарларында *Кызыл Кая* атамасы алган тау бите бар. Ростов өлкәсендә *Каяла,* Дагстанда *Каякент,* Азәрбайҗанда *Каялы* һәм *Аггая* атамалары берничәшәр урында бар. Ян култыгында *Буорхая иseме* алган ирен һәм диңгезгә, күлгә яки елгага очлаеп кергән коры җир, ягъни борын ныгытылган. Каракомда *Акджагая* исеме алган ташлы батынкы урын бар. Аның төбе океан тигезлегеннән 81 метр түбәндә ята. Оренбург өлкәсендә *Каялы* елгасы бар. Красноярск краенда Чуна елгасының уңъяк кушылдыгы *Хая* елгасы һәм аның ярына урнашкан *Чуна* атамасы алган торак пункт теркәлгән. Якутиядә *Урюнг-Хая,* Хакасиядә кыя таш кабырга *Хаялыгхыр* һәм *Сары кабырга Сарыгхаялар* бар. Тывада *Кызыл-Хая* һәм *Кок-Хая* таулары теркәлгән. Алтайда *Адар-Кайа* елгасы һәм шул ук исемдә тау бар. Кемерово өлкәсендә *Кийә* торак пункты бар.

Кырымда *кыя ~ кая* термины белән ясалган түбәндәге атамалар бар: *Бака-Таш, Бока-Таш, Теке-Таш, Текне-Таш, Эски-Таш, Эки-Таш, Койташ, Акташ, Таракташ, Биюк-Таракташ, Кок-Таш, Кызыл-Таш, Иман-Таш, Яман-Таш, Боташ, Сююр-Таш, Топракая, Грамата-Кая, Кильсе-Кая, Хыз-Кая, Ак-Кая, Тапрак-Кая, Топрак-Кая, Коянчик-Кая, Сандык-Кая, Чатал-Кая, Чал-Кая, Паралам-Кая, Парагиным-Кая, Эльчан-Кая, Шан-Кая, Элькен-Кая, Кормен-Кая, Гемин-Кая, Ворон-Кая, Баланын-Кая, Параланын-Кая, Самар-Кая, Исар-Кая, Бор-Кая, Анастас-Кая* һ. б.

Төркиядә *Каялыдаш* тавы сырты һәм түбәсе, *Каялы, Каялы-Усыклар* таулары ныгытылган.

Кыргыз географик атамалары арасында *кыя* термины белән ясалган елга, тау сырты һәм авыл атамалары еш очрый:

*Ак-Кыя* елгасы – Ош өлкәсенең Сузак районындагы Кёгарт елгасының сул кушылдыгы. *Ак-Кыя* – Нарын өлкәсенең Актала һәм Кочкор районнарындагы, Ош өлкәсенең Совет һәм Фрунзе районнарындагы авыл атамалары. Кыргызстанда *Коккия* сырты һәм *Коккия* елгасы бар, *Кызыл-Кия* Ош өлкәсендә; Казакстанда *Кызылкия* һәм *Аккия* атамалары бар. Төньяк Казакстан өлкәсендә *Киялды* атамасы теркәлгән. *Кияли* и *Кияли-Чек* атамалары Үзбәкстанның Андижан өлкәсендә очрый, Ферганә өлкәсендә *Киялы курганча* атамасы бар. Нахичеванда (Әзербайҗан) *Киялды* атамасы теркәлгән (Мурзаев, 1984: 277).

Төрки халыклар яшәгән җирлекләрдә *кая, кия* терминнарының төрдәш вариантлары шактый һәм алар катнашында күп атамалар теркәлгән: кыргыз телендә *кыя* – «текә тау бите», «текә тау итәге», үзбәк телендә *кия* – «сөзәклек, авышлык», «сөзәк урын, сөзәк җир», «юл өеме» (тимер юлда), «төшү урыны», «төшә торган урын», «тау бите», «кыек төшкән», «кыйгач». Карапалпак һәм казак телләрендә *кыя (кия)* – «текә тау», «сөзәклек», «авышлык», «текә кыя», «кыя таш». Алтай диалектларында *кају* «сөзәклек», «сөзәк тау итәге». *Кыя (кия)*нең югарыда китерелгән бөтен мәгънәләрен берләштереп караганнан соң, Г. Конкашпаев «кыя, кыя таш», «сөзәклек, авышлык»ны аңлаткан *кая* терминын да шушы ук рәткә кертә. Үзбәкләрдә *кия* термины «сөзәк җир, сөзәк урын», «тау бите», «тау итәге», «сөзәклек», «авышлык» булса, ә *коя* термины – «кыя», «кыя таш». Уйгыр (кашгар) телендә *кия таш* – «кыя, кыя таш», «ташлар». Таҗикларда төрки телдән алынган, «кыя, кыя таш», «текә яр» мәгънәсендә кулланыла торган *кия* термины Розова тарафыннан тикшерелгән. О.Т. Молчанова мәгълүматларына караганда, алтайлыларда кулланыла торган *кају* терминын тыва телендә «як», «кырый» мәгънәсендәге *хажыы*; хакас *хазы* – «яр», «кырый»; якут *кытыы* – «яр», «кырый»; монгол телендә *хажуу* – «ян-як»; калмыкларда *хажьу* – «ян-як», «кырый» терминнары белән чагыштырып күрсәтә.

***Кыяк.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *кыяк* лексик исем берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай аңлатылган: 1. Суганда, сарымсакта, иген һәм үләннәрнең кайбер төрләрендә була торган озын тар яфрак. *Калмас [кәҗәдән] кәбестә, суган кыяклары.* Г. Тукай. *Сөмбелләрнең кыягында Таң чыклары мөлдери.* Ә. Ерики; 2. Сөйләмдә. Кыяк үлән. *[Күлнең] тирәләре яшел кыяклар, шаулап торган камышлар белән капланган икән.* А. Алиш (ТТАС, II: 245).

***Кыяклык.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу термин «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе: «Кыяклар үскән урын; кыяклар үскән җир», – дип бирелгән (ТТАС, II: 245).

***Кыяк үлән*** – ботаника термины – кыяклылар семьялыгыннан терлек ашатуга китә торган күпьеллык чүп үлән; русчасы: осока. *Бу алан хәзер сарут, күзлут, алабута һәм саргайган кыяк үләннәр белән күмелеп калган.* А. Гыйләҗев. *Яр буенда кыек үлән, кыеп аласы иде, Мәңге сагынмаслык итеп карап каласы иде.* Җыр (ТТАС, II: 245).

*Кыяк* берәмлеге белән географик берәмлек атамалары байтак ясалган: *Кыяклы болыны* – Биектау районы Чуваш иле авылы янындагы болын атамасы. *Кыяклы күл* – 1. Спас районы Әҗмәр авылы янындагы Актай суы бассейнындагы, 2. Спас районы Ямбакты авылы янындагы күлләр. *Кыяклы күл урамы* – Спас районы Иске Рәҗәп авылындагы урам атамасы. *Кыяклык* – Спас районы Әҗмәр авылы янындагы болын атамасы. *Кыяклык сазы* – Яшел Үзән районы Мулла иле авылы янындагы саз. *Кыяклы күл* – Кама Тамагы районы Иске Кариле авылы янындагы, Коры Үләмә елгасы бассейнындагы күл. *Кыяклы күл урамы* – Спас районы Ямбакты авылындагы урам атамасы. *Кыяклы чишмәләре* – Биектау районы Зур Кавал авылы (бу чишмәләр Ташсу урманы буенда).

***Межа.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлекнең мәгънәсе *ызан* терминына юнәлдерелгән. Мисал *[Тарантаслы кеше] арыш басуы межасына каерып керде дә туп-туры авыл уртасына таба юл тотты*. Г. Галиев.

*Межа* лексик берәмлеге географик берәмлек атамалары ясауда катнаша: *Межа елгасы* – Лаеш районы Татар Янтыгы авылы янындагы елга. *Межа суы* – Мамадыш районы, Түбән Ушмы авылы янындагы елга.

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» исеме алган повестенда мондый юллар бар: *«...Безнең әни үз гомерендә бер сәгать ял иттеме икән? – дип күзләреннән сагыш коеп сөйләде ул басу межасыннан атлаган көйгә»*. Шул ук авторның «Ут чәчәге» повестенда мондый юллар язылган: *«Ат арбасы белән бу межадан кемдер узган һәм межада озын булып үскән алабаш чәчәкләренең саплары арба күчәренә эләгеп дегеткә буялган иде»*.

***Оран*** – тарихи берәмлек (шул ук *уран*). Электә татарларда, башкортларда, кыргызларда, казакларда яуга чакыру авазы; лозунг, пароль булган. Кыргызларның бер кабиләсендә *уран! – ор!* сүзе чакыру булып хезмәт иткән, башка кабиләләрдә кабилә башлыгының исемен кычкырганнар һ. б. (Е.Н. Шипова). Монгол-татарларның «алга» мәгънәсендәге *хура* (хурраччи) сүзеннән дә булырга мөмкин (Ура! авазы шушы сүздән таралган дип тә саныйлар). «Кыйссаи Йосыф»ның бер борынгы нөсхәсендә бит кырыенда «уран – галәмәт мәгънәсенә вә ләкаб вә исем мәгънәсыгә; гасакирне камал вакытында истигъмал иделүр» дигән искәрмә бар. //*Мин уйладым оранлы ун туганым бар. Унысы да асыл затлы баһадирлар* («Кыйссаи Йосыф»-тан). Монда *оранлы* «сугышчан, гайрәтле» мәгънәсендә килә. «*Йөрәгеңне уят әле туган. Ишетелер шулчак Соңгы Оран, Бабайларның баш очында курган – Өсләренә бөркет оя корган*». Ибраһим Биектаулы.

Тагын кара: «*Уран; Ура кычкыру*».

***Оч***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *оч* компоненты нәрсәнең дә булса (гадәттә шәһәрнең, авылның, урамның) уртадан, үзәктән ераклашкан ягы, чите, башы дигән мәгънәне аңлата диелгән. Мисаллар китерелгән: *Түбәнге оч, Үрге оч. Бакчаның аргы очы. Бармас идем мин шул очка, Җаным сөйгән шул очта.*

*Жыр. Команда тавышы, казарманың бер очыннан икенче очына яңгырап, бөтен халыкның йокысын ачты*. К. Нәҗми (ТТАС, II: 483).

*Оч* компоненты топонимнар ясауда шактый актив кулланыла: *Морза очы* – Алексеев районы Зур Тигәнәле авылының бу очында бай морза яшәгән. *Морзалар очы* – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы янындагы урын атамасы. *Сөләйман очы* – Баулы районы Татар Кандызы авылында урам, урам очы (анда Сөләйман исемле кеше яшәгән). *Ташкау очы* – Арча районы Бирәзәбаш авылыннан рус авылына бару ягындагы урам. *Чегәннәр очы* – Апас районы Зур Күккүз авылындагы урам атамасы. *Чәкән тавы очы* – Баулы районы Бәйрәкә авылындагы урам очы. *Чебен очы атавы* – Әгерҗе районы Салагыш авылы янындагы атау. *Мадиар очы* – Баулы районы Бәйрәкә авылындагы урам очы. *Малмыж очы* – Балтач районы Шеңшеңәр авылындагы урам очы. *Чаллы очы* – Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк авылындагы урам атамасы. *Ерак оч* – Актаныш районы Суыксу авылындагы урам атамасы. *Казан кеше очы* – Сарман районының Азалак, Кәүҗиәк, Усай, Нөркәй авылларындагы урам атамалары. *Басу очы болыны* – Арча районы Байкал авылы янындагы болын атамасы. *Болын очы* – Саба районы Сатыш авылындагы урам атамасы. *Болын очы урамы* – Кукмара районы Мәчкәрә авылының бер урамы атамасы. *Карга очы* – Балтач районының Балтач авылы янындагы җир атамасы, Шеңшеңәр авылындагы урам атамасы. *Хәмит очы* – Чистай районы Татар Ялтаны авылындагы урам атамасы. *Чылан очы* – Арча районы Казанбаш авылындагы урам атамасы. *Сабантуй очы* – Баулы районы Бәйрәкә авылында. *Малмыж очы* – Балтач районы Шеңшеңәр авылындагы урам атамасы. *Куян бабайлар очы* – Апас районы Зур Күккүз авылында урам атамасы. *Казаклар очы* – 1. Биектау районы Зур Кавал авылы, 2. Кама Тамагы районы Олы Кариле авылларындагы урам атамалары. *Югары оч* – Апас районы Биябашы авылындагы урам атамасы. *Битаман очы* – Чистай районы Татар Ялтаны авылындагы урам атама-

сы. *Теге оч* – Чистай районы Татар Ялтаны авылындагы урам атамасы. *Түбән оч зираты* – Сарман районы Шарләрәмә авылы янындагы зират. *Түбән оч күле* – Чистай районы Татар Баганасы авылы янындагы күл. *Түбән оч кизләве* – 1. Тәтеш районы Иске Бидәнге, 2. Апас районы Зур Кайбыч, 3. Яшел Үзән районы Мамадыш-Әкил, 4. Буа районы Яңа Чәчкаб авыллары эчендәге һәм яннарындагы чишмә атамалары. *Чүриле очы* – Биектау районы Юртыш авылындагы урам атамасы. *Апач очы* – Алексеев районы Зур Тигәнәле авылындагы урам.

*Оч* лексик берәмлеге әдипләребез һәм шагыйрьләребез иҗатында еш очрый.

Нурислам Хәсәновның «Сагыш» дип аталган китабындагы «Тәкъдир» повестенда *оч* лексик берәмлеге кулланылган: *«Юк, ризалашмады Хәкимҗан. Түбән очны югары очка алыштырмады. Аңа Яшьләр урамы түгел, ата-ана нигезе – үзенеке кадерле. Яланаяк чабып үскән үзән буйлары, бөтен рухын биләп торган чишмәле болыннар...»*

***Оя.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ояның бишенче мәгънәсе* болай диелгән: Кем яки нәрсәләр бик күп тупланган, яшәгән, яүкән урын. *Кандыр буе, ай, Кара урман, Киек җәнлеккәйләр оясы*. К. Тинчурин. *Кырлар ала-кола... чокыр-чакыр , чүп-чар, билчән, әрем оясы*. М. Гафури. // Бер тирәгә тупланып, укмашып үскән үсемлекләр төркеме. *Оясы-оясы белән гөмбәләр очрау. Тик бер оя шомырт, матурланып, Ап-ак чәчәк белән киенгән*. Ш. Маннур. *Утрауларга охшап, оя-оя булып үскән куаклар, ... киң болынлыкны уратып алган әрәмәлекләр күзгә ташлана*. М. Хәсәнов.

*Күчерелмә мәгънәсе:* Нәрсәнең дә булса чыганагы, киң таралган, хөкем сөргән җире. *Акчишмә суы... ничә меӊ еллардан бирле. Тирә-юнен сазландырып, бизгәк оясы булып ята*. К. Тинчурин. *Минем эшкә ярдәм итте Фәннәр академиясе, Илебезнең фән чишмәсе, Бөек фикер оясы*. М. Җәлил (ТТАС, II: 490–491).

*Оя* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда шактый актив кулланыла: *Бурсык оясы* – Апас районы Татар Черкене

авылы янындагы тау атамасы. *Аю оясы* – Апас районы Тәүгелде авылы янында. *Ябалак оясы ерганагы* – Биектау районы Зур Кавал авылы янындагы ерганак. *Торна оясы* – Әтнә районы Яңа Кишет авылы янындагы басу атамасы.

*Оя* лексик берәмлеге әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатыда еш очрый: Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында туган йорт, туган оя турында менә нинди сүзләр язылган: *«Иске булса да төп оя, җиде буынны тирбәтеп үстергән җылы бишек бит ул! Йөрәгемнең астын-өскә китереп, бөтенесе күңелемнән үтте: үлем-җитеме дә, шатлык белән рәхәте дә. Күз алдына китереп кенә карагыз: күпме баланың дөньяга килгәндә беренче тавышын ишеткән бу нигез, ничә кешенең монда актык сулышы өзелеп, соңгы тапкыр күзләре йомылган».*

Вахит Имамовның «Утлы дала» исеме алган тарихи романында *Бөркет-оя* атамасы матур кулланылган. *«Җиңелмәс баһадир» җыен карт-коры, малай-шалай карамагында гына калган тирмәләрне талап-җимереп йөрүдән ямь тапмады, ярсыган селәүсен шикелле ыргый-сикерә, Кикрикле тау, Бөркет-оя дигән биек, текә өркәчләр өстенә томырылды».*

***Печән.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *печән* лексик берәмлеге исем дип бирелгән һәм мәгънәсе болай аңлатылган: 1. Мал-туарга азыкка дип чабылган яки чабып киптерелгән үлән. *Печән кибәне. Печән чабу. Печән җыю. Әле иртә белән генә кояш нурларына каршы нәфис чәчәкләрен тибрәндереп утырган яшел үлән хәзер печән булып аяк астында ята*. Г. Бәширов. 2. *Күчерелмә мәгънәсе:* Печән чабу эше. *Печәнгә төшү. Печән өсте. Әле Хәнәфи туганга әйттем, печәнгә кешене күбрәк җибәр, дидем*. Г. Әпсәләмов. *Озакламый печән өлгерә, кешеләрнең күп өлеше печәндә булачак*. Ш. Камал (ТТАС, II: 511).

***Печәнлек.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *печәнлек* лексик берәмлеге исем дип бирелгән һәм мәгънәсе түбәндәгечә аңлатылган: 1. Печән итеп әзерләрлек әйбәт үлән үсә торган болын, тугай яки алан. – *Быел фермаларда малны ишәйтәбез,*

*терлек азыгы бик күп кирәк булачак!– дип [Тимергали агай] печәнлекне ... артыграк алган иде*. Г. Бәширов. *Гомәр... кайда нинди чокыр, нинди куаклык, печәнлек барлыгын бик ачык хәтеренә төшерде*. Ә. Еники.

2. Абзарда яки лапаста печәнне тутырып саклау өчен ясалган урын, тезмә. *Ата казлар каңгылдый, печәнлекләрдә бөтен авылны шаулатып тавыклар кытаклый*. Г. Бәширов. *Сәфәргали... тезмәгә, печәнлеккә менеп, коры печән өстенә йөзе белән капланды да, әнисен сагынып, тавышсыз гына елап җибәрде*. Ф. Хөсни. (ТТАС, II: 11).

Адлер Тимергалин сүзлегендә болай диелгән: «Печән – Борынгы төрки телдә – *пичән* (үрмә үсемлек). Татар теле сөйләшләрендә *печән/печин* – үлән, ут; чәчәк. Мәсәлән, *алма печәне* – исле ромашка, *тарак печән* – торна баш, тырнавык, *гүзәлдәшле печин* – сукыр кычыткан, *садап печин* – сукыр кычыткан, *садап печин* – мәче борчагы, *җара печин* – алоэ. Р. Әхмәтьянов *печән* сүзен «*билчән* сүзенең дублеты» дип атый. Шушыларны искә алганда, печән сүзен печ-ү/пыч-у (аркылыга кисү) фигыленнән чыгару кыен».

Охшаш сүз башка төрки телләрдә, шул исәптән чуваш телендә дә бар.

Электә печән *чабылып* түгел, *урып* алынган. // *Авыр сөйәкле печән* – юан сабаклы чүп үләннәрдән торган печән.

*Печән өсте* – Халык календаренда печән чаба торган ай, чор. Шунысы кызык: электә, йола буенча, печән вакытында кияүләр кәләшләре белән тауларга, сахраларга чыгып йөргәннәр, аларга печән эшеннән азат булу хокукы бирелгән булган. Н. Исәнбәттән».

*Печән, печәнлек* лексик берәмлекләре географик атамалар ясауда шактый кулланыла: *Бүксә печәнлеге* – Балтач районы Пүскән авылы янындагы кушамат белән бәйләнешле печәнлек атамасы. *Печән байлары* – Апас районы Иске Йомралы авылы янындагы атама. *Печән юлы елгасы* – Балык Бистәсе районы Биектау авылы янында Шомбыт суы кушылдыгы. *Печәнлек*

*болыны* – Балтач районы Кариле авылы янындагы болын атамасы. *Печәнлек елгасы* – Мамадыш районы Кече Сон авылы янындагы Сон елгасы кушылдыгы. *Печәнче күле* – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы янындагы күл. *Йәгъфәр печәнлеге* – Биектау районы Иске Рәс авылы янындагы печәнлек атамасы. *Каравыл печәнлеге* – Биектау районы Чуваш иле авылы янындагы печәнлек атамасы. *Керәшен печәнлеге* – Балтач районы Нормабаш авылы янындагы печәнлек атамасы. *Сыза печәнлеге* – Буа районы Түбән Наратбаш авылы янындагы печәнлек атамасы. *Таллык печәнлеге* – Мамадыш районы Югары Ушмы авылы янындагы печәнлек атамасы. *Түбән печәнлек агачлыгы* – Зур Кавал авылы янындагы печәнлек атамасы. *Түбән печәнлек* болыны, *Түбән печәнлек* елгасы, *Түбән печәнлек* чишмәсе – болар барысы да Биектау районының Зур Кавал авылы янында урнашкан. *Мулла печәнлеге* – Биекау районы Иске Рәс һәм Өлә Казаклары авылларындагы печәнлек атамалары. Бу урыннардагы печәнне авыл кешеләре муллага чабып биргән. *Карт мулла байы печәнлеге* Лаеш районы Имәнкискә авылы янындагы печәнлек атамасы. *Клеверлы печәнлек* – Балтач районы Норма авылы янындагы печәнлек атамасы.

Бу терминнар халык авыз иҗатында һәм әдипләр әсәрләрендә очрый.

***Почмак***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *почмак* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай бирелгән: 1. Ике урам кисешә торган урын. *Әфләтуннар почмагында күп кешеләр җыелып сөйләшеп тора.* Ф. Фәйзи. // Сыйфат мәгънәсе. *Урам чатындагы Баһау олы урам юлыннан елга урамына борылганда, почмак йорттан бер төркем халык чыкты.* А. Таһиров.

*Күчерелмә мәгънәсе:* Үзәктән бик ерак, читтәге як, урын, төбәк. – *Эләктерсәләр инде (жандармнар сине) Енисейгә генә озатмаслар, Якутстанның ерак, караңгы почмакларына ташларлар*. Г. Ибраһимов. *1905 елгы революция дулкыннары шушы тын гына почмакны да читтә тын гына калдырмый.*

Ш. Камал. // Шәһәр, ил һ. б.ш. ның читтәге бер өлеше, районы, төбәге, урыны турында. *1929 елда булган соңгы юбилее уңае белән (Г. Камалга) Советлар иленең төрле почмакларыннан хатлар һәм телеграммалар килә.* М. Гали. *Махно бандасы Украинаның төрле почмакларында аеруча активлык күрсәтергә тотынды.* А. Шамов (ТТАС, II: 536–537).

*Почмак* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда актив кулланыла. *Бурсык почмагы* – Мамадыш районы Катмыш авылы янындагы басу атамасы. *Бурсык почмагы урманы* – Кукмара районы Югары Өскебаш авылы янындагы урман атамасы.

*Почмак* лексик берәмлеге әдипләребез иҗатында шактый күп очрый. Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» повестенда *почмак* лексик берәмлеге еш кулланыла: *«Бакча почмагына җитеп урамга чыгуга, биткә коры һава, тузан, җылы таш исе бәрелде. Асаф әлеге сихри дөньядан кинәт кенә аерылгач сискәнеп, дереЛдәп алды. Шундый ук хәлне Сылу да кичерде булса кирәк, чылдырап сөйләшеп килгән уңайдан, ул да кинәт айнып китте, тынып калды һәм тузанлы юлга аяк басканда, ничектер, беләген ычкындырды да бакча почмагына карап куйды».*

Фоат Садриевның «Таң җиле» романында *урам почмагыннан* гыйбарәсе күңелле итеп файдаланган: *«Фәрит малайларның урам почмагыннан борылганда койрыкларын гына күреп калды».*

Язучы Әсгать Салахның «Казан утлары» (2013. №1) журналында дөнья күргән «Аккан сулар...» чәчмә әсәрендә *почмак* лексик берәмлегеннән болай файдаланыла: *«Елховой сельпосы урта урам белән Чәпешләр урамы почмагында, биек нигезгә салган алты почмаклы агач бинада иде».*

Нурислам Хәсәновның «Тәкъдир» повестенда мондый сүзләргә тап булабыз: *«Башка чыккач та, әтисенең тау ташларыннан өеп салган сарае да бер почмактан утырып, җирдән өскә таба баскыч-баскыч булып ярылып киткән».*

***Рәт***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *рәт* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай аңлатылган: Берсе янына берсе урнашкан, бер-бер артлы яки бер

сафка тезелгән кешеләр. әйберләр җыелмасы. *Халыкның алгы рәте, зур магазиннар тезелгән урамга җитәрәк, текә кыяга бәрелгән төсле, кинәт кенә туктады*. К. Нәҗми. *Язгы чәчәкләр белән бизәлгән зур залның бер башыннан икенче башына хәтле ике рәт сузылган өстәл өстендәге ашамлыклар инде шактый ашалды.* А. Шамов. (ТТАС, II: 604).

*Рәт* лексик берәмлеге географик берәмлек атамалары ясауда байтак кулланыла. *Борчак рәте* – Балтач районы Кили авылы янындагы басу атамасы. *Чиялек рәте* – Буа районы Бик-Үти авылы янындагы урын атамасы. *Бурсык рәте* – Апас районы Әҗем авылы янындагы басу атамасы. *Атау рәте* – Балтач районы Биктәш авылы янындагы басу атамасы. *Сиртмәле рәт* – Балтач районы Смәел авылы янындагы басу атамасы. *Шомырт рәте* – Яшел Үзән районы Кече Өтәк авылы янындагы басу атамасы. *Чыршы рәте* – 1. Яшел Үзән районы Карашәм авылында. Элек бу урында чыршы үскән, хәзер кыр; 2. Балтач районы Кили авылындагы басу атамасы; 3. Саба районы Түлешкә авылында. Элек бу урында чыршы үскән. *Кәрпи рәте ышнасы* – Биектау районы Өсбе авылы янындагы басу атамасы. *Усаклы рәт* – Буа районы Бик-Үти авылы янындагы җир атамасы. *Якын карамалар рәте* – Буа районы Кайбыч авылы янындагы басу атамасы. *Казаклар рәте* – 1. Апас районы Әлмәндәр авылы, 2. Кама Тамагы районы Кече Бортас авылындагы урамнар атамасы. *Каен рәте* – Буа районы Норлат авылы янындагы урман атамасы. *Түбә рәте* – Апас районы Дүртөйле авылы янындагы юл атамасы. *Янбулат рәте* – Балтач районы Кили авылы янындагы басу атамасы. *Ташлы рәт* – Кама Тамагы Бәки авылы янындагы кыр атамасы. *Алабуга рәте* – Яшел Үзән районы Юынчы авылы янындагы урын атамасы. *Каршы рәт басу* – Балтач районы Пүскән авылы янындагы басу атамасы. *Шыкра рәте* – Буа районы Бик-Үти авылы янындагы басу атамасы. *Егерме җиде җир рәте* – Буа районы Бик-Үти авылы янындагы басу атамасы. *Егерме чыбык рәте* – Чүпрәле районы Зур Аксу авылы янындагы юл атамасы.

*Рәт* лексик берәмлеге әдипләребез иҗатында очрый. Фатыйх ага Хөснинең «Бер ана балалары» исемле хикәясендә мондый юллар укыйбыз: *«Үлгән артыннан үлеп булмый, нишләмәк кирәк, калды, җылый алган чаклы җылады, ләкин күз яше белән тамак туймый, балаларын үстерергә кирәк, хуҗалыкны алып барырга, кеше рәтеннән төтен чыгарырга шулай ук кирәк иде»....* *«Соңыннан, кыш асрап чыгарга азык җиткерә алмау сәбәпле, сыерын сатып, кәҗәгә калды – кеше рәтеннән көтүгә куарга сыеры булмагач, баштарак бик борчыла иде Мәсрүрә түти».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» повестенда мондый юллар язылган: *«Сылу аның белән рәттән, үзенә аерым юл ярып барды».*

***Сабан туе, сабантуй.*** Татар халкының милли бәйрәме. Ул элек яз көне кар беткәч тә, чәчүгә чыкканчы үткәрелгән, хәзер исә язгы кыр эшләре тәмамланганнан соң уздырыла (үткәрү вакыты хакимиятләр тарафыннан билгеләнә, төгәл даталары юк, ләкин Сабантуй көнен чәчәүгә кадәр үткәрүнең тискәре яклары да булган, чөнки, чәчү кичеккәнгә, туфрак дымын югалткан һәм уңыш түбәнәйгән). Сабан туен элек бер җомгадан икенче җомгага кадәр бәйрәм иткәннәр (В. Беркутов). Бәйрәм үткәрүгә рөхсәтне мулла бирә торган булган.

Ел тәүлеге көтеп алынган җыен булганга, *Сабан туен* «газиз сөрән» дип тә атыйлар (Чистай якларында). Глазов якларында *Сабантуй* үткәрүне «сабан чабу» дип атаганнар, ә уеннарда катнашучыны «сабан чабучы» дигәннәр. *Сабан туе* өчен халыктан җыелган йомырка һәм башка бүләкләр Минзәлә сөйләшендә «чирмә» дип, авыл борынча бүләк җыеп йөрүче «чирмәче» дип аталган.

Бу бәйрәмнең тарихи аналогын, мәсәлән, борынгы Кытайда игенчелекне уйлап табучы хөкемдар Шень-Нун хөрмәтенә ел саен апрельдә яки майда уздырылган бәйрәмнән дә эзлиләр. Тик шулай да ул бәйрәм, нигездә, җыр һәм музыка бәйрәме булган, ә татар *Сабан туе* эчтәлеге белән борынгы грекларның Олимпия бәйгесенә дә тартым. Язучы Нурихан Фәттах татар

*Сабантуйлары* программасы белән борынгы Шумердагы Яз бәйрәме, шулай ук Борынгы Мисырда үткәрелгән бәйге-уеннар арасында булган охшашлыкларга (чүлмәк вату, баганага үрмәләп менү, аркан тартыш, көрәш) игътибар итә. (Шунысын да әйтеп китик: Н. Фәттах бу очракта *сабан* терминын «җир эшкәртү коралы» мәгънәсендә түгел, бәлки «Саба алиһәнең ире» мәгънәсендә аңлый. Кызганычка каршы, язучының этимологик тәҗрибәләре моның белән генә чикләнми, һәм ул *туй* сүзен, урысчалаштырыбрак әйтеп, ирләрнең җенес органы фаллоска китереп тоташтыра.)

«Чүлмәк вату» уены, ихтимал, борынгы «явыз рух»ларны куу йоласы белән бәйледер. Тубыл һәм Төмән ягы татарларында киленне алып килгән арбага бәреп, чүлмәк вату йоласы булган. *Сабантуйны,* үзенә бертөрле «Бөтендөнья уеннары» рәвешендә дә уздырып, яңа исем белән «Идегәй бәйгесе» дип атарга тәкъдим итүчеләр булды (Д. Шәрәфетдинов).

*Сабантуй* лексик берәмлеге топонимнар ясауда кулланыла: *Сабан-туй очы* – Баулы районының Бәйрәкә авылында. *Сабан туе болыны* – Балтач районының Яңгул авылы янындагы болын атмасы һ. б.

Гомәр ага Бәширов «Туган ягым – яшел бишек» повестының «Язгы сабан туйлары» дип аталган бүлегендә көрәшүчеләр көч сынашкан вакытта халыкның дулкынлануын болай тасвирлый: *«Халык дулкынлана, гөжли, тора торгач үзеннән-үзе кычкырып җибәрә, эһелдәп куя. Көрәшнең иң кызык сулышын – берәрсенең җирдән суырып алып күтәреп чөйгән вакытын күрмичә калмас өчен, бөтен дөньяларын онытып, берсен берсе кысып, этә-төртә эчкә таба керәләр».*

Фатыйх ага Хөснинең йөрәккә барып җитә торган иҗатында (бу очракта «Сабан туе» хикәясендә) мондый юллар очрый: *«Күпме кирәк кешегә очып китү өчен, Бигрәк тә сабан туе вакытында».*

Акъегетнең (Рөстәм Фәйзуллин) «Сәлам әйт, җил» исеме белән дөнья күргән шигырендәге юлларның мәгънәсе бик матур:

*Сәлам әйт син болындагы*
*Сабантуй колгасына.*
*Бәлки аның ал яулыгы*
*Җилферди булыр шунда.*

***Саз.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *саз* сүзенең берничә мәгънәсе бирелгән. 1. Өстенә су чыгар-чыкмас яки чыгып торган баткак җир. *[Карамый торганда], азгынрак сыерлар, елгага су эчәбез дип барып, сазга төшеп баталар.* М. Гали. *Әкрен жилгә лепердиләр Сазда мүкләр.* Ә. Ерикәй.

Артык сулану-юешләнү нәтиҗәсендә җебеп баткакка әйләнгән җир, аяк асты. *Аз гына яуса да гөрләвекләр ага торган бистә урамнары бүген бөтенләй сазга әйләнгәннәр иде.* К. Нәҗми. *Су ера-ера үкреп елап тырмашучы сирәк машиналар сазга әйләнгән юлларда мескенләнеп, кызганыч булып калалар.* М. Шабаев. (ТТАС, II: 614).

Радлов сүзлегендә *сас, саз* – «саз, сазлык җир, камыш» (Радлов, т. IV, Ч. 1: 394– 397).

***Сазлы.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «сыйфат» дип ныгытылган һәм ул «...өлешчә яки тулысынча сазланган, сазга әйләнгән урын» дип бирелгән. *Ун чакрым калынлыгындагы сазлы, пычрак урманүтәргә туры килде.* М. Максуд. *Әле болай яңгырсыз да җир юеш, хәтта күп урыннар сазлы иде. Яңгыр утырып явып, сөрү эшен туктату куркынычы булганга, Гыймазов хафаланып йөрде.* С. Рафиков (ТТАС, II: 615).

***Сазлык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *сазлык* лексик берәмлеге исем дип бирелгән һәм «Сазлы җир» дип аңлатылган: *Күлнең кибә-кибә сазлык булып калуы. Сазлык кошлары. Бу урманнарның эчендә селкенчәк сазлыклар очрый.* Г. Ибраһимов. *Сазлыкта бакалар бакылдавы ишетелә.* Г. Кутуй.

*Икенче мәгънәсе* сыйфат дип күрсәтелгән һәм «сазлыкка әйләнгән; сазлы» дип аңлатылган. *Сазлык җирләр файдаланылмыйча, әрәм булып ята. Алардан да файда алуны күздә тотарга кирәк.* Соц. Тат. (ТТАС, II: 615).

***Сазлыклану***. Сазлыкка әйләнү, сазлану. *Елга болынын куаклыклар, ...Займыш болынын урыны-урыны белән чүп үлән баскан һәм алар сазлыклана башлаган.* Соц. Тат. (ТТАС, II: 615).

*Саз, сазлы, сазлык, сазлыклану* терминнары терминнары белән географик атамалар шактый ясала.

*Саз* – Тәтеш районының Зур Әтрәч авылы янында; Кама Тамагының Бишалаб авылы янында, Үләмә суы бассейнында; Яшел Үзән районының Татар Танае авылы янында, Гөбенә суы бассейнында; Апас районының Зур Күккүз авылы янында, Коры Үләмә суы бассейнында; Әгерже районының Иж-Бубый авылы янында, Бубый суы бассейнында; Буа районының Черки-Килдураз авылы янында, Зөя елгасы бассейнында.

*Саз* термины атамалар составында да еш кулланыла: Әлки районы Иске Алпар авылында – *Акчарлак сазы*, Актаныш районы Ахун авылында – *Аргы саз*, Сарман районының Илексаз авылында – *Саз кизләве,* Апас районының Шуширмә авылында – *Саз елгасы*, Апас районы Әлмәндәр авылында – *Саз күле. Саз арасы* – Азнакай районының Мәлбагыш, Сарман районының Янурыс авыллары янындагы урын атамалары, *Саз буе* – Буа районының Черки-Килдураз, Әлки районының Иске Салман, Балтач районының Биктәш авыллары янындагы урын атамалары. *Саз болыны* – Яшел Үзән районының Мамадыш-Әкил авылы янындагы болын атамасы, *Саз кизләве* – Чүпрәле районының Татар Шатрашаны авылы янындагы кизләү, Олы Яклы елгасы бассейнында.

Балык Бистәсе районындагы Олы Әшнәк авылының бер очы – *Саз башы*, Яшел Үзән районының Мамадыш-Әкил авылының бер болыны – *Саз болыны*, Баулы районы Бәйрәкә авылының бер очы – *Сазлык очы*, Саба районының Татар Икшермәсе авылындагы бер тау *Саз тавы* атамасын йөртәләр.

Татарстанның төрле районнарында *Саз-Тамак* авылы һәм тимер юл станциясе, *Рус Сарсазы, Сарсаз-Әрәмә, Сарсаз-Баграж, Югары Баткак* һ. б. атамалар очрый. Саный башласаң, аларның саны егермедән дә артып китә.

*Сазлы багана юлы* – Теләче районының Кече Нырсы авылы янындагы юл атамасы; *Сазлы елга* – Алексеев районы Урта Тигәнәле авылы янындагы, Тигәнәле елгасы бассейнында; *Сазлы күпер* – Апас районының Чирмешән авылы янындагы күпер атамасы; *Сазлы мөлек елгасы* – Саба районының Мичән авылы янындагы елга, Мичән елгасы бассейнында; *Сазлы чокыр чишмәсе* – Лениногорск районы Кирлегәч авылы янында, Шушма/ Чишмә елгасы бассейнында. *Сазлык* – Саба районының Керәнне, Тәтеш районының Үтәмеш, Лениногорск районының Ормышлы, Кама Тамагы районының Атабай авыллары янында бар. Саба районының Мичән, Арча районының Наласа авыллары янында, Мамадыш районында Сон елгасы бассейнында *Сазлык* атамасы алган елгалар очрый. Саба районының Иләбәр авылы янында *Сазлык басу* атамасы алган урын бар. *Сазлык очы* – Ютазы районының Бәйрәкә авылында урам атамасы һ. б.

Югарыда аталган терминнар әдипләр иҗатында еш кулланыла. Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *сазлык* термины болай кулланылган: *«Сазлык өсте, сагайган сыман, берничә сулышка тынып торды, аннары казлар бөтен көтүе белән бер якка йөгерешергә тотындылар».*

Мөхәммәт ага Мәһдиев «Без – кырык беренче ел балалары» дигән повестенда *сазлык, чишмә, елга, таллар, камышлар, елан, аждаһа, урман* һ. б. кебек лексик берәмлекләрне бик матур куллана. *«...Урман белән ике арада бер сазлык бар. Анда чишмәле елга ага, таллар, камышлар үсә. Кара болыт белән давыл килгән вакытларда шул камышлык арасыннан әллә ниткән ыңгырашкан тавыш ишетелә, ди. Монысы аждаһа, имеш. Урманда елан гына түгел, бурсык дигән ерткыч та бик хәтәр нәрсә икән».*

Вахит Имамовның «Казан дастаны» дип аталган тарихи романында *сазлык* лексик берәмлеге күчерелмә мәгънәдә кулланыла. *«Газиз атаңның бәхетсезлек сазлыгына кереп батуына нигә сөенәсеңдер? Алайга китсә, күреп торам, син дә күлнең төбен күккә аскан Искәндәр Зөлкәрнәен түгел әле... Өй бүрәнәләре*

*шартлап ярылырдай зәмһәрир суык көннәр төзелешеп китте. Сазлык эченә батып әрәм булган мәңгелләргә суыктан катып үлүчеләр өстәлде. Җайдакларны хәзер бер саз гына түгел, һәр меңлектә купкан бизгәк, үләт чире йөзләп-йөзләп йотты».*

Роза Хәбибуллинаның «Мулла килене» романында *саз, сазлык* лексик берәмлеге болай бирелгән: *«Көзге яңгырлар башлангач, бер баруында Ирекнең машинасы сазга кереп чумды. Машинасын калдырып, әнисе янына җәяүләп китте. Тракторлар ергалап бетергән юл тоташ сазлыкка, тирән чокырлар күлләвегенә әверелгән иде».*

*Саз, сазлык, сазлы, сазлыклану* терминнары белән Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә атамалар шактый күп.

Ульяновск өлкәсенең Барыш районы Иске Тимушкә авылында сазны *сас* дип әйтәләр. Төмән өлкәсе Тобол районы Лайтамак авылында кайчандыр сазлык булган урынны белдерү өчен, *коуыл* сүзе кулланалар. Тара сөйләшендә кечкенә урман белән капланган сазлыкны *целек* дип әйтәләр.

*Саз* җирле географик терминының таралыш ареалы бик киң. «Мордва җөмһүриятенең мәркәзе Саранск һәм аның яныннан агып үтә торган Инсар суы ярына урнашкан Инсар шәһәре атамасы карел, фин, фин-угор телләрендә „сазлык, баткаклык урын“ мәгънәсен аңлата» (Инжеватов, 1974: 149). Пермь краеның Барда районында *Саз елга* (русча Зязельга) дигән авыл бар.

Алтай, хакас, татар телләрендә *сас* – «саз»-«тетрәвек» (өстендә үлән үсеп утырган сазлык). Алтайның рус телле халкына бу термин «сазлыклы болынлык» мәгънәсендә кереп урнашкан. Томск өлкәсендә күп еллардан бирле яшәүче рус халкы төрки *саз* термины белән түмгәкле сазламык урынны атый. Элекке Тобол губернасында бу мәгънәдә *сазь* термины кулланылган; Демьянка елгасының югары агымында бер саз *Олы саз сазлыгы* («Болото Уму-саз») дип аталган. Казакларда *саз* – сазлыклы урын, юеш болын, сазлы баткаклыкны аңлата.

Радлов сүзлегендә *сас~саз* – «баткак урын, камышлы саз». *Баткак* сүзе күп төрки телләрдә очрый: кумык, каракалпак, ка-

зак – *батпак, батпақ;* кыргыз, чыгтай – *баткак, батпақ;* үзбәк – *батқок.* Баткак мәгънәсендә татар теле сөйләшләрендә сүзләр күп: *баткын, баткалак, батлак, батмак* һ. б.

Кыргыз топонимиясендә *Баткак-Суу* (карталарда *Батпак-су*) – Нарын өлкәсе Кочкар районындагы Сонкел елгасының сул кушылдыгы (Умурзаков, 1988: 37).

Э.М. Мурзаевның җирле география терминнарына багышланган фундаменталь хезмәтендә *сас-саз*ның Урта Азия илләрендә, Алтайда, Көнбатыш Себердә, Идел–Урал буйларында, Кырымда таралуы әйтелә. Шулай ук автор бу терминның Төркиядә очравын, Воронеж өлкәсендәге торак пункт *Сасовка* һәм Рязань өлкәсендәге *сас* терминын төрки *саз* белән бәйләп карый. Кырымда *Са-зих-Дере, Саз-Кор* исемле су-инешләр бар (Словарь, 1979: 483). Казакстанның Кызыл Орда өлкәсендә *Сазды,* Азов диңгезенең көнчыгыш ярында *Сазанлык* урыны бар, *Сакмар* бассейнындагы Ток суының уң кушылдыгы *Сазлы суы,* Ыссык-Күлнең төньяк юнәлешендә *Сазановка* (хәзер ул Ананьево) дип аталган зур авыл бар. Кыргызстанда *Кара-Саз* авылы Нарын өлкәсенең Кочкор районында урнашкан; шундый ук атама алган елга Ыссык күл өлкәсе Тон районындагы, Кече Нарын елгасының уң кушылдыгы. Барабада *Саскүл* һәм *Соскүл* исемен йөрткән күлләр бар; Төмән өлкәсендә *Көексаз* һәм *Тумарлы саз* исемле сазлар, Башкортстанда *Чермәсаз* (Черек саз), Курган өлкәсенең көнчыгышында *Сазлы күл* исемле күл бар. Казакстанның Алма-Ата өлкәсендә *Саз* исемле торак пункт, Чимкент өлкәсендә *Састобе;* Алтайда *Сас* һәм *Сасбажы* исемле шәһәрләр бар. Төркиянең Европа өлешендә (Босфор янындарак) Кара диңгезгә коя торган *Сазлыдере* суы, Үзәк Анатолиядә *Солтан Сазлыгы* дип аталган сазлыклы урын бар. *Сас* сүзе Алтайда яши торган руслар телендә «сазлыклы болын» төшенчәсен аңлата (Богданов, 1963: 37– 53). Төмән өлкәсендәге иске дин тота торган руслар түмгәкләр белән капланган сазлыклы урыннарны *сас* дип атыйлар. Элекке Тубыл губернасында сазлыклы урыннар *саз* дип йөртелгән; Демьянка елгасының

югары агымындагы сазлыкларның берсе *Олы саз* дип әйтелгән (Розен, Малолетко, 1986: 75). Микротопонимнар: Иске Кулаткы районының Иске Атлаш авылындагы бер урам *Аю сазы* урамы дип йөртелә. Самара өлкәсенең Келәүле районы Яңа Фәйзулла авылында – *Саз,* Камышлы районының Татар Байтуганы, Иске Ярмәк авылларында *Мостафа умарталыгы сазлыгы, Фирмы сазлыгы, Мүк чишмәсе сазлыгы, Кырык чишмә сазлыгы, Күлләр туры сазлыгы* атамалары очрый. Башкортстанда *Убалы сазы* Учәле районы Илчегул авылында теркәлгән. Башкортстанның Калтасы районында – *Саз,* Зилаир районында *Ямансаз, Япарсаз,* Туймазы районында *Олы саз башы* авыллары бар. Түбән Новгород өлкәсенең Сергач районы Андреевка авылында *Саз, Сазлык* атамалары очрый.

*Саз* сүзе төрки телләрнең күбесендә бар. Кыргыз, хакас телләрендә – *саз~сас,* казак – *саз,* чуваш – *шур,* башкорт – *шар* («камышлы саз» мәгънәсендә). Венгр телендә «саз, сазламык урын»ны аңлата торган *sar/sarat* термины борынгы төрки телдән алынган (Р. Әхмәтьянов).

*Саз, сазлы, сазлык* сүзләрен аңлата торган төрдәшләр татар теле сөйләшләрендә күп очрый. Чистай сөйләшендә сазлыкны аңлату өчен – *баткылык, пылата,* минзәлә урынчалыгында – *ачылык,* кеше үтә алмаслыгын белдерү өчен – *йамансаз,* гәйнә сөйләшендә – *йепсәк,* дым белән капланган мүкле җир – *чүллек,* тау ягы урынчалыгында – *сазамык,* андагы ук керәшен татарлары телендә *күләwек, күләү, мулаталык,* мордва-каратайларда – *мулаталык,* казан арты балтач сөйләшендә һәм нагайбәк керәшеннәре телендә – *сазамак,* мәләкәс ягында – *сазамык,* эчкен татарлары сөйләшендә – *семелек,* минзәлә, эчкен урынчалыгында сазлыклы күлне – *күтер,* сазлык, баткаклыкны – *түмгәклек, баткылык,* сазламык дымлы җирне – *суткак,* сергач сөйләшендә – *сеңгәк, сеңгәлчек,* хвалын урынчалыгында – *сеткелек,* зәй керәшеннәрендә сазлы болынны – *четермән,* Кама Тамагы төбәгендә яшәүчеләр телендә су җыелып торган сазлы җирләрне белдерү өчен *күләwек* терминнары кулланыла.

Көнбатыш Себер татарлары сөйләшендә дә *саз, сазлык*-ны белдерү өчен төрле лексик берәмлекләр кулланыла. Омск өлкәсендә урнашкан тара сөйләшендә сазлыкны, бата торган урынны *күтәргәк* дип йөртәләр, кипкән саз исә – *как саз,* Төмән өлкәсенең Кече Уват авылында урман эчендәге кечкенә сазны *кыулцак* диләр (Розен, Малолетко, 1986: 75).

***Сай.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *сай* терминының берничә мәгънәсе бар:

*Беренче мәгънәсе*: тирән түгел (су һәм сулыклар, чокырлар, шулай ук савыт-саба, баш һәм аяк киемнәре һ. б. турында). *Сай сулы инешне ерып чыгу. Сай канау.[Бабай] сөрелгән җирне карышлап үлчәп карады. – Сай... – диде. Гәрәйнең сабан тотуын яратмады*. М. Җәлил.

*Икенче мәгънәсе*: тирән түгел урын (суда). *Вак балыкларның чуртаннан куркып сайга чыгуы.*

*Өченче мәгънәсе*: «исем, диалекталь сүз» дип бирелгән. Ул – тугай, үзәнлек, болын култыгы дип аңлатыла. *[Хатын-кызларга һәм бала-чагага урманның җиләкле урыннарын күрсәтеп йөрүче:]* Аннан, *менә теге сайга төшегез. Мин арырак китеп тагын эзлим.* М. Фәйзи.

Борынгы төрки телдә *сай* «вулкан атудан соң барлыкка килгән ташлы урын, буш тигезлек» (ДТС, 1969: 481). В. Радлов сүзлегендә *саі* 1) сай елга, 2) вак ташлар белән капланган сай елга, 3) буш тигезлек, 4) тар озын чокыр, 5) елга мәгънәсендә бирелгән (т. IV, Ч. 1: 219– 220).

*Сай~тай~җай~чай* «сай сулы, тирән булмаган елга» мәгънәсендә Татарстанда түбәндәге елга атамаларында урын алган: *Аксай* – Бөгелмә районында, Зәй елгасының уң кушылдыгы; *Сай елга* – Әлки районында, Ата елгасы кушылдыгы; *Сай Нажҗар күле* – Баулы районында, Ык елгасы бассейнында. *Сай елга* – Саба районында Олы Мишә кушылдыгы. *Актай* – Иделнең сул кушылдыгы, *Каратай* – Зәйнең сул кушылдыгы һ. б. Минзәлә районының Бикбау авылында *Сай күл, Сай күл тамагы, Сай күл тугае* һ. б. атамалар очрады. *Сай елга*

*урамы* – Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк авылы янындагы урам атамасы. *Сай елга чишмәсе* – 1. Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк, 2. Чирмешән районы Бәркәтә авыллары янындагы чишмәләр атамасы. *Сай кичү елгасы* – Мамадыш районы Түбән Сон авылы янындагы елга. *Сай кичү чишмәсе* – Мамадыш районы Түбән Сон авылы янындагы чишмә. *Сай күл* – Лаеш районы Атабай авылы янындагы күл (Эк. прим. ф. 1355; ед. хр. 412, л. 48). *Сай үзән* – Саба районы Олы Нырты авылы янындагы үзән. *Сай үзәк чокыры* – Апас районы Зур Күккүз авылы янында кечерәк елга булган һ. б.

Татарстанның Азнакай районнарында Урсай исемле авыл атамалары бар, бу берәмлек микротопонимик атамалар составында да кулланыла: *Сай елга урамы, Урсай күпере* һ. б.

*Энҗү дәрья – киң дәрья*
*Бәнәҗү дәрья – сай дәрья.*
*Аннан ары Актүбә,*
*Аннан ары тар Җаек,*
*Мәкергә оста Шаһ Тимер*
*Анда килеп туктады.*
*Чүлдән килгән чирүе*
*Җаектан килеп су эчте –*
*Җаек кайтып бер төште.*
(Идегәй, 1988: 131– 13)

*Сай* термины әдипләр һәм шагыйрләр иҗатында кулланыла.

*Сай* татар телендә кайчандыр «елга»ны белдергән. Габдулла Тукайның исем куелмаган бер шигырендә мондый юллар укыйбыз:

*Күк күгәрчен – күлләрдә, ак күгәрчен – сайларда;*
*Сагыну түгел, саргаерсың – җиләк пешкән айларда.*

Бу шигырьдә *сай* сүзенең елга икәнлеге аңлашылып тора.

1977 елда Лениногорскида шундый бер җыр тексты язып алынды, шуннан өзек китерелә:

*Сакуксайның* (суык су, елга) *сулары ага микән боз булып,*
*Сакуксайның буйларында йөрдек микән кыз булып?*

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында казларның безнең як салкыннарыннан куркып җылы якларга китүгә әзерләнүләре күңелләргә үтеп керә торган итеп бирелгән: *«Алар [казлар] хәзер яр буенда, ярым сазлыкның түмгәкләре арасында чүпләнеп йөриләр, сайлыкта җим эзлиләр, инешкә кереп коенып чыгалар да төзәтенәләр, каурыйларын аралыйлар. Кайберләре канатларын җәеп, бөтен көчләренә кагыналар да тыела алмыйча йөгереп китәләр».*

Ә. Әфләтунов типтәрләрнең елганы *җай* дип атауларын билгеләп үтә һәм «Зәй, Җаек гидронимнарының нигезендә борынгы татар телендә елганы белдергән шушы термин ята», – дип яза (Әфләтунов, 1961: 164). *Сай, тай, чай* компонентларының «елга» мәгънәсен белдерүләре хакында археограф-галим Һ.В. Йосыпов та язып калдырган (Юсупов, 1964: 7; 1971: 224). Бу фикерне куәтләп, Г.Ф. Саттаров борынгы телебездә *чай~сай~тай~шай~ зай~зәй~җай~йай* тәңгәллекләре яшәвен, татар сөйләшләрендә *[ч]– [с]– [т] – [ш]– [з]– [җ]– [й]* авазлары чиратлашуының әле хәзер дә саклануын күрсәтә (Саттаров, 1969: 32–33). Г.Ф. Саттаровның бер хезмәтендә *җай* терминының елга икәнлеген дәлилли торган бер гыйбарә бар: *«Җайның күрке яр белән, ярның күрке тал белән».* М.З. Зәкиев фикеренчә, борынгы төрки телдә кулланылышта йөргән *җай~чай~зәй~зөя* – халык телендә «елга» мәгънәсендә кулланылган диалекталь вариантлар (Зәкиев, 1977: 88).

*Сай* компонентын эченә алган су чыганаклары атамалары Татарстаннан читтә яшәгән татарлар һәм төрки халыклар телендә дә актив кулланыла. *Башкортстан* җирлегендә түбәндәге су чыганаклары атамалары кулланыла. *Карасай* елгасы Баймак районында Туяләскә килеп кушыла, *Камысай* – Күгәрчен районында Нәкәс суына кушыла, *Киндерсай* – Хәйбулла районында Таналык суына килеп кушыла һ. б. Башкортстанның Миякә районында *Җәнәби-Урсай* авылы бар. Микротопонимнардан Мәләүз районында *Аласай* үзәне, Бөрҗән районының Галиәкбәр авылы янында *Багсай* тавы һ. б. атамалар теркәлгән. Самара

өлкәсендә: *Сай* елгасы Камышлы районының Чуваш Байтуганы авылы янында Сокка кушыла. Чиләбе өлкәсендә: *Калмык-сай, Текә сай, Чулак сай* атамалары алган елгалар Нагайбәк, Агап, Бредин районнары җирләреннән ага.

Кардәш төрки телләрнең күбесендә бу тамырның төрле фонетик вариантларының гидронимиягә караган мәгънә белдерүе югарыдагы фикерне тагын да ныграк дәлилли. Мәсәлән, азәрбайҗан телендә – *чай,* каракалпак телендә – *сай,* төрекмән, кумык диалектларында – *чай,* төрекчә – *çay,* үзбәк теленең нухи сөйләшендә – *җай,* – болар барысы да «елга»ны аңлата. Кубаньда *чай* – «тау елгасы», Балкария республикасында *җайыу* – «сай сулык». Башка төрки телләрдә *сай* – «коры елга юлы, ком, вак таш». Якут телендә *сай* «агым» төшенчәсендә кулланыла. Алтайлылардагы *сай* һәм тыва халкы телендәге *сайыр* – «вак ташлар белән капланган чокыр, елга үзәне». *Саі*ның В.В. Радлов сүзлегендә бирелгән мәгънәләре: 1) сай елга; 2) вак ташлар белән капланган сай елга; 3) буш тигезлек; 4) тар озын чокыр; 5) елга. Башкорт әдәби телендә *сай* – «елгадагы су үсеме», диалектларында – «ләм, су үсеме, ике тау арасы». Монгол телендәге *сайр* «вак ташлар белән капланган коры елга үзәне» мәгънәләрен белдерә. С.М. Молла-Заде фикеренчә, *чай* сүзе күп гидронимнар составына керә. Шулай ук бу термин шактый гына ойконимнар (торак пункт атамалары) составында да урын алганнар: *Кенарчай, Эмберчай, Кашкачай, Агчай, Карачай* (Молла-Заде, 1978: 138). Казаклар яши торган Чуй далаларында (Алтай) *Аксай* елгасы ага. Казакстандагы *Аккудук сай* – «Ак кое үзәне» мәгънәсен аңлата. *Аксай* – сай, ягъни «кар сулары белән туклана торган елга». *Сарфысай* – «Сары елга» һ. б. Кыпчаклар (половецлар) «сай» терминын Төньяк Кавказга (Терек кушылдыгы *Аксай*) һәм Дон бассейнына (Ростов өлкәсендә елга һәм торак пункт атамасы *Саксай* – «сак кабиләләре елгасы») алып килгәннәр (Розен, Малолетко, 1986: 74). Кыргыз топонимиясендә дә өч *Ничке-Сай* атамасы теркәлгән. *Абшыр-Сай* – Ош өлкәсенең Ноокат районындагы иңкүлек, шундый ук

атаманы шул ук төбәктән ага торган елга да йөртә. *Сокур-Бел-Сай* – Терек елгасының сул кушылдыгы (Касан-Сай елгасы бассейны), Ош өлкәсе Алабук районы. *Сокур-Булак* инеше Арпа елгасының уң кушылдыгы (Нарын өлкәсе Атбашы районы). Шул ук өлкәнең Карасу районында *Каратай* атамасы алган авыл һәм Совет районында *Каратай* тавы бар (Словарь, 1988: 10, 143). Э.М. Мурзаев мәгълүматлары күрсәтүенчә, *сай* сүзенең таралыш даирәсе бик киң (1984: 491–492).

***Сала*** сүзе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә теркәлгән. Ул – искергән сүз «авыл, авыл җире» дип аңлатылган (ТТАС, 11: 619). Татарлар яшәгән төбәкләрдә *сала,* «авыл, авыл җире» дигән мәгънә белдерү белән беррәттән, «елга кушылдыгы» төшенчәсендә дә йөргән. Бу термин гидронимнар һәм микротопонимнар атамаларында да урын алган: *Урсала* – Зәй елгасының уң кушылдыгы (Әлмәт районы); Көшкәт елгасы бассейны (Балтач районы). Нурулла Гариф хезмәтендә *Енасала* – «яңа» авыл Арча даругасында, хәзер Татарстанның Арча районындагы *Яңа Сала* авылы.

Башкортстанда *сала* компоненты белән күл атамалары теркәлгән. Авыргазы районының Иске Морадым, Күгәрчен районының Түбән Сюрбай, Йомагузы авылларында, Мәләүз районының Смак авылында, Чишмә районының Яңа Ябалаклы авылында *Салабаш* күлләре бар.

Бу атама тарихи чыганакларда, елъязмаларда, Казан, Самара һ. б. губерналарның авыл атамалары килеп чыгышларын яктырткан хезмәтләрдә урын алган. *Салаяз* елгасы – Зәй суы кушылдыгы, *Салаур суы* – Кече Сөлчә кушылдыгы, *Урсала каенлыгы, Урсала күпере, Урсала сазы, Салайаз тугае* һ. б.

Кырым татарлары телендә *сала* компоненты белән түбәндәге атамалар кулланыла: *Сала, Кодж-Сала, Бугаз-Сала, Бич-Сала, Фюити-Сала, Мачи-Сала, Фотсала, Олусала, Улусала, Бия-Сала.*

В.В. Радлов *сала* сүзенең кыргыз телендә – «бармак аралары, елга кушылдыгы, елга култыгы», сагай, койбалларда – «аяк һәм

кул бармаклары», шор телендә – «ботак, үсенте» мәгънәләре булуын теркәгән (т. IV, Ч. 1: 49). Бурят телендә *sala* – 1) «тармак», «аерылып киткән урын», 2) «елга култыгы, елга кушылдыгы, ермак». Мәсәлән: *Арға сала* (Көнбатыш кушылдык) – Оленек елгасының сул кушылдыгы (Вилюй округы: Пекарский, Вып. VII: 2036). *Сала* һәм *һала* – «аерма, чат, тармакланып киткән урын», *һалаа, хала* – тармакланып киткән урында урнашкан басу уртасында калган урман яисә күл, *һала хээрэ* – тармакланып киткән урында урнашкан басу. Кыргыз телендә *сала* «уйсу урын, түбәнлек», каракалпакларда «тармак, ермак, бармак аралары» мәгънәсендә булса, үрәнхәй телендә *сала* – «тармак, ботак, бармак». *Сала* сүзе долган һәм якут телләрендә дә бар: *Орт-Сала, Кок-Сала* һ. б. Бу термин монгол телендә дә очрый. Монгол телендә *сала* – «тармак, ботак, чыганак, ермак, су башы, елга башы» һәм «елга кушылдыгы, ермак». Таймырда *Аргасала* һәм *Батысала* елгалары теркәлгән, Алтайда *Салатал, Аксала, Салаял* елгалары бар. *Джуруынсал* һәм *Карасал* исемендәге елгалар Донга сул яктан килеп кушылалар. Бу терминның киң җирлекләргә таралу ареалын Э.М. Мурзаев тикшерә (Мурзаев, 1984: 494). Көнбатыш Кытайда Кара-Иртыс елгасына сул яктан коя торган Джелта елгасының сул кушылдыгы *Аксала,* Кобдо елгасы системасында *Харсала* елгалары бар.

«Кече Енисей елгасының югары агымында монгол-төрки телләреннән аңлатылган һәм „ак кушылдык“ мәгънәсендә кулланылган *Саган-Сала* елгасы ага. Бу исем-атама, саф төрки топоним Агатырның бик уңышлы калькасы. Ак мәгънәсендә кулланылган беренче төрки компонент *аг* (ак), монгол телендә шундый ук, ягъни ак төсне белдергән *саган* термины белән тәңгәл килә. Әгәр икенче „кушылдык“ сүзгә-сүз тәрҗемә иткәндә „ботак“, „тармак“ мәгънәсен белдерә торган *сала* компоненты белән параллель үткәрсәк, Агатыр гидронимының икенче компоненты *атыр* шулай ук „кушылдык“ төшенчәсен белдерә дип карый алабыз. Шулай фикер йөрткәндә борынгы төрки, тыва телләрендә „елга кушылдыгы“ (төп мәгънәсе „тармак“) мәгъ-

нәсен белдергән *адыр* терминына төрки телләрдә „тармакланып киткән урын, аерма, чат“ төшенчәсендә кулланылган *адыр* һәм *азыр, айир, айыр* һ. б. фонетик вариантлары белән параллель үткәрү урынлы булыр» (Малолетко, 1992: 50).

***Сөрән.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *сөрән* лексик берәмлеге искергән «исем» дип бирелгән һәм мәгънәләре күрсәтелгән. 1. Авыл бәйрәмнәрендәге атлы спорт уеннары һәм ярышлары; 2. Шундый ярышларга өндәп, чакырып, аваз салып йөрү; шул йола. *Сагынып көткән сабан туйлары җитте... Малайлар, яшүсмерләр, иртә таңнан торып, язгы кояш белән бергә үк диярлек сөрән чабарга чыгып, сабан туен башлап җибәрделәр. Күңел түзмәде. Мактый бабайның... алашасына атланып мин дә сөрәнгә чыктым. Бөтен урамнарны тутырып иңләп, кибеп җитмәгән чатыр-чотыр чәчрәтеп, шаулап, шаярып, көлешеп: – Сөрәнгә, сөрәнгә, сөрәнгә! Сөрән беткәч, сабан-сука төрәнгә! – дип такмаклый-такмаклый чабып йөрибез.* Ш. Маннур.

***Сөрән кычкыру*** – кара: сөрән салу. *Агайларның кайберләре сөрәннәр кычкырып аю качырырга тотындылар, кайберәүләр утлы агачларны алып, чаткыларын чәчеп селкә башладылар.* М. Гафури.

***Сөрән салу*** – 1. сөрәнгә чакырып, өндәп аваз салу, кычкыру; 2) гомумән, өндәп, чакырып аваз салу, кычкыру. *Күбеккә баткан җирән атларын чыбыркылап, кыргый тавыш белән сөрән салып басу капкасыннан коралллы отряд килеп керде.* К. Нәҗми. *Атланыгыз атларыгызга, алыгыз сөңгеләрегезне, тагыгыз чукмарларыгызны! дип сөрән салыр идем.* М. Әмир. 3) каты кычкыру; каравыл салу. *Хулиган! – дип сөрән салды Илгиз.* Б. Камалов. *Таң әтәче һәр төнне һаман шулай сөрән салып кычкыра да иртә белән үзе юкка чыга иде.* М. Шабай. *Сөрән сугу* – эшлексезләнеп тырай тибеп йөрү. *Данилов кинәт кенә борылды да ачуланып кычкырды: «Ни эшләп йөрисез монда сөрән сугып? Марш роталарыгызга!* Г. Бәширов (ТТАС, II: 718).

***Сөрәнче*** – 1. Сөрәндә, ярышта катнашучы; 2. Сөрәнгә өндәп, сөрән салып йөрүче (ТТАС, II: 718).

*Сөрән* лексик компоненты географик берәмлек атамалары ясауда байтак катнаша. *Сөрән йылгасы* – Арча районындагы Югары Сәрдә авылы янындагы елга, Сәрдә суы бассейнында. *Сөрәнчеләр елгасы* – Саба районы Юлбат авылы янында, Казкаш елгасы бассейнында.

***Су.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *су* сүзенә берничә төрле аңлатма бирелгән. 1) Гөрләвек, елга, күл һәм диңгезләрне барлыкка китерә торган сыекча (саф хәлендә – водород һәм кислородның химик кушылма-сы). *Әнә сиңа күкне томалап килгән кара болыт: ул су бөртекләреннән түгелме?* Г. Коләхмәтов. 2) Инеш, елга, күл, диңгез һ. б. ш. *Диңгез дигән су шундый зур, аның очын да, кырыен да күреп булмый.* А. Шамов. 3) Дым, юешлек. *Солы саламына су үткән.* Г. Бәширов (ТТАС, II: 674).

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *су* лексик берәмлеге түбәндәгечә сурәтләнгән: «Төркиләр, барыннан да элек, утны, һаваны һәм суны хөрмәт итәләр...» (Семиоката Феофилакт, «История», М., 1957). Борынгы бабаларыбыз суны дөньядагы бөтен нәрсәнең башлангычы һәм чыганагы итеп күзаллаганнар. Җир үзе дә дөнья океаны төбеннән үрдәк кабып чыккан балчыктан барлыкка килгән имеш. Татар телендә «кояш, ай, йолдызлар бата һәм кала», ягъни бу сүзләрдән үк без борынгы ата-бабаларыбызның бөтен дөньяны су әйләндереп алган дип ышанган булуларын күрәбез (кояшка карата байу (баю) сүзе дә кулланыла, монысын Р. Әхмәтьянов төрки телләрдәге әкренәю, тукталу; күчеп килеп утыру» мәгънәсендәге сүздән дип аңлата). Болгарлар суны пакьләнү чарасы дип белгәннәр, изге чишмә сулары белән дәвалаганнар. Татар зиратлары елга яки элекке елга үзәне буенда, гадәттә, авылга карата аръякта урнашкан булган, чөнки шулай итмәгәндә үлгән кешеләрнең җаны авылга кайта дип уйлаганнар. Мәчетләрдә, кагыйдә буларак, суга якынрак җирдә, әйтик, берәр күл буенда төзелгән була. // *Каен суы – русча березовый сок* (ләкин «морковный сок инде

кишер суы булмас, аны мәс., язучы Гадел Кутуй «кишер сыгынтысы» дип атаган). Гомумән, су сүзендә үсемлектә була торган «сыекча» мәгънәсе бар. Хайван организмындагы, әйтик, иттәге сыекчаны «сүл» диләр («каен сүле» – «кан» плазмасы»)».

*Су* лексик берәмлеге тормышыбызның төрле өлкәләренә бик күптәннән үтеп кергән инде. Менә шуның өчен дә А. Сент-Экзепюри безгә мондый кадерле фикер калдырган: *«Су! Синең тәмең дә, төсең дә, исең дә юк. Сине тасвирлап бетерергә дә мөмкин түгел, нәрсә икәнеңне белмичә генә синең белән ләззәтләнәләр! Сине тормыш өчен кирәк дип әйтеп булмый, чөнки үзең тормыш».*

Дөньяда, тормышта иң кирәкле әйберләрнең берсе – су. Шуны истә тотып булса кирәк, борынгы бабаларыбыз элек-электән авылларын урман белән капланып алган зур елга ярларына һәм аларның тирә-юненә, күл буйларына, чишмәләрдән сулар мул чыккан, җире уңдырышлы булган урыннарга нигезләгәннәр. Халыкның көнкүреше тормыш ихтыяҗы су чыганаклары, урман кебек табигый байлыклар ярдәмендә үтәлгән. Һәр зур һәм кечкенә су чыганакларына (гомумән бөтен географик берәмлекләргә дә) әби-бабаларыбыз атама куйган. Халык су чыганакларына атама биреп кенә чикләнмәгән, бәлки күбесенең исеменә атап җырлар һәм шигырьләр дә чыгарган. Һәр атама үзе бер зур тарих ул. Чишмә, су-инеш атамалары дастаннарда, тарихи җырларда, легенда-риваятьләрдә, табышмак-әйтемнәрдә еш кулланыла. Әби-бабаларыбыз суның кадерен белгәннәр, зурларын һәм кечкенәләрен дә (гомумән барлык төр географик берәмлекләрне дә) аерым исемнәр белән атап йөрткәннәр. Авыллар халкы басудан кайтышлый яки күрше авылларга барганда юл арасын чакрымнар белән түгел, бәлки исемле елга, инеш, ерганак, чишмә һәм сызалар белән үлчәгән. Халык авыз иҗатында бабаларыбыз табышмаклар формасында суны болай итеп тасвирлаганнар:

*Исе юк, төсе юк,*
*Аннан башка тормыш юк.*

*Булмаган җире сирәк,*
*Үзе һәрвакыт кирәк.*

Бу табышмак суны сыйфатлау өчен эпиграф итеп кулланылган А. Сент-Экзюпери фикере белән аваздаш. Язучылар кайсы илдән булуларына карамастан, иҗатларында халык авыз иҗаты мәгълүматларыннан һәрдаим файдаланалар, шуның белән әсәрләрен баеталар, бизәклиләр һәм зур уңышларга ирешәләр.

Халкыбызның үзәге чал гасырлар тирәнлегеннән килгәнгә күрә, аның авыз иҗаты да тарих төпкелләре белән тоташкан тормыш тәҗрибәсен туплау нәтиҗәсендә иҗат ителгән, гомер юлында очраган күренешләрне ул аз сүз, күп мәгънә белән ачып салырга сәләтле булып җитлеккән.

Татар халкының борынгы, бай авыз иҗатында су әһәмиятле һәм лаеклы урын алып тора. Борынгы бабаларыбыз «елгаларым – тормыш тоткаларым» дип, гомумән табигать, аның байлыклары беләнербөтен булып яшәгәннәр, тулы канлы тормыш алып барганнар. Чишмәләргә карата кулланылган «Башы тауда – аягы диңгездә» дип халык уйлап тапкан гыйбарә аларның җитез, йөгерек, эшчән, гавәмгә намус белән хезмәт итүчән табигатьләрен сурәтли. Җир-әнкәнең зәңгәр күзләреннән сикереп чыккан җәннәти ширбәттәй тере сулар – Раббыбыз тарафыннан безгә җибәрелгән иң зур бүләкләрнең берсе, изге аманәт. Аларга кадер һәм тәрбия кирәк. Идел, Кама, Иртыш, Енисей, Актай, Зәй, Ангара һ. б. кебек зур елгалар да кайчандыр кечкенә генә болан баласы да атлап чыга алырлык бәләкәй чишмәләрдән башланып киткәннәр. Исәбе-хисабы булмаган чишмә, инеш, елга-су кушылдыклары белән туклана-туклана, алар зур елгаларга әверелгәннәр. Җирдән килеп җиргә киткәнгә, җир асты һәм җир өсте суларына кушылып әллә кайларга барып чыкканга күрә, аларны мәңге яшәр өчен яратылган үлемсез, илаһи чыганаклар буларак кабул итәбез. Һәм бу вазгыять буыннан-буынга күчкән. Шагыйрьләр һәм башка каләм ияләре иҗатларында суның могҗизага тиң үзенчәлекләре нечкә һәм нәзакәтле итеп ачыла.

*Изге* атамасы алган чишмә-чыганаклар республикабыз районнарында күп. Кайчандыр, ниндидер сәбәпләр нәтиҗәсендә авылларын, туган туфракларын ташлап киткән, вакытлар үтү белән олыгайган, авырый башлаган өлкәннәр, туган авылларының изге туфракларыннан ага торган Изге чишмәләрнең суын соратып алалар. Шул суны эчкәч алар сихәтләнәләр, күзгә күренеп көрәяләр. Кеше белән табигать һәм табигать нигъмәтләре үзара нык бәйләнгән. Изге чишмәләрнең үз серләре, үз мөмкинлекләре зур. Күп сугышларның шаһиты булган Җир-анабыз аркылы Аллаһы Тәгаләбез безне зурлаган, шифалы сулар, җир асты казылмалары байлыгы, файдалы җиләк-җимешләр үсә торган болын-басулар, урман-әрәмәләр, тау-калкулыклар, үзән-тугайлар белән щйлщндереп алган. Безне, сугыш чоры балаларын, табигать нигъмәтләре ачка үтермичә саклап калды да инде.

Изге чишмәләрнең, гомумән суларның кешеләргә сәламәтлек, сихәт бирүләрен күрсәткән мисал-могҗизалар күп очрый. Мондый мәгълүматларны мин экспедиция-сәфәрләрдә йөргәндә күп ишеттем һәм язып алдым.

Топонимнарны өйрәнүнең бер әһәмиятле үзенчәлеге шунда, алар чикләрне белмиләр. Чөнки борынгы төркиләр һәм шул исәптән татарлар да теге яки бу тарихи сәбәпләр нигезендә төрле урыннарга сибелеп утырганнар һәм аларның «эзләре» кайда булсалар, шунда калган.

Биектау районында Гәр атамасы алган рус авылы урнашкан. Бу авылда халык тарафыннан Күз чишмәсе дип аталган чишмә суында көмеш катнашмасы булуы ачыкланган. Өлкәннәр сөйләвенә караганда, бу чишмә янына марилар һ. б. милләт халыклары һәрдаим килеп суы белән бит-күзләрен юалар һәм зур-зур савытларга тутырып суны үзләре белән алып китәләр икән. Бу авылга экспедиция-сәфәргә килеп өлкәннәр белән сөйләшү өчен авыл буйлап йөргәндә чишмә янындагы бу хәлне үз күзләрем белән күрдем.

Шушы ук төбәкнең Гәрдән ерак булмаган Җиде Иле (Семиозерка) авылында Изге чишмә бар (руслар килеп утырганчы

бу авылда татарлар яшәгән; Семиозерканың татарча Җиде Иле авылы икәнен миңа Зур Кавал авылында яшәп вафат булган Суфия әйтеп калдырды). Аның суы составында да көмеш катнашмасы бар икәнлеген халык белеп алган. Авыл халкы бу чишмә суыннан да сәламәтлекләрен кире кайтару өчен файдалана. Бу чишмә-кизләү суы күрше авыллар һәм читтә яши торган халыклар өчен дә кадерле. Туганнары янына чит яклардан кайткан халык та бу суны үзләре белән алып китә икән. Чишмә суында күзләр өчен файдалы матдәләр көмештән башка да бар ахрысы. Чөнки халык чишмә суы белән бит-күзләрен да юа, кирәк икән су алып кайтып коена да. Авыл халкы суның ифрат та шифалы икәнлегенә басым ясый.

Тарихта шундый легенда-риваять сакланып калган. Искәндәр Зөлкарнәйн (Александр Македонский) гаскәре белән Мисыр тирәләренә яулап алу сугышына барган вакытта аның солдатларына ниндидер йогышлы авыру эләгә һәм алар күпләп вафат була башлый. Искәндәр патша үзе һәм аның бер- ике якын кешесе генә исән кала. Шушындый вазгыятьтән соң патша, яулап алу сугышларын дәвам итү өчен, иленә кире кайтып, гаскәрне өр-яңадан җыярга мәҗбүр була. Искәндәр патшаның үлемнән котылып калуының сәбәбе көмешкә нисбәтле. Юлда йөргәндә дә ул ашау өчен көмеш кашык һәм су эчү өчен шундый ук савыт йөрткән һәм шуңа күрә аңа үлем сирпелә алмаган. Элек тә һәм хәзер дә байтак гаиләләр аш-су белән эш иткәндә көмеш савыт-саба һәм көмеш кашыктан файдалана. Бу гамәл юкка гына түгел билгеле. Су кебек үк көмешнең дә серләре, үз үзенчәлекләре бар...

Халык хәтере – сак һәм гамьле хәтер. Биләрдәге Хуҗалар тавы һәм аннан чыга торган Изге чишмә янында һәрдаим кеше була. Алар янына төрле диннәрдәге халыклар да килә. Изге урыннар, кемнең кем булуына карамастан, һәркемне үзенә тарта.

Изге чишмәләр безнең җирлектә генә түгел, башка урыннарда да очрый. Согыд Гарәбстанына хаҗ кылырга барган кешеләр зур гына полиэтилен савыт белән Зәм-Зәм чишмәсеннән алын-

ган су алып кайталар. Зәм-Зәм суы изге су санала һәм аннан авыз иткәндә үзеңә, гаиләңә әйбәт теләкләр теләргә кирәк дип әйтәләр һәм бу теләкләр, һичшиксез, кабул килә дигән фикер бар. Бу илнең изге җирендә чыккан изге суны бөтен дөньяның ислам динендәге халкы күтәреп кайтып туганнарына, дусларына, белгән-күргәннәренә өләшә. Кырыс атеизм чорлары үтеп, халык үзенең чын асылына кире кайта, Аллага шөкер.

Бакый дөньядагы *Кәүсәр чишмәсе* атамасы Коръәндә урын алган. Намаз укыганда да ул һәрдаим, һәр рәкагать саен кабатлана. Чишмә исеме Коръән кадәр Коръәндә искә алына икән, аның суындагы көчнең илаһилыгы үзеннән-үзе аңлашыла. Намаздан соң багышлауда «– Йә, Раббым! Кәүсәр чишмәсе суларыннан ләззәт алырга насыйп итсәңче», – дигән сүз-теләкләр кулланыла.

Күлләр тормышы да гыйбрәтле. Алар да барлыкка киләләр, яшиләр һәм озак еллардан соң юкка чыгалар, китәләр. Якынча мәгълүматларга караганда, Җир йөзендә 12 миллион чамасы күл бар. Безнең илебездә (Россиядә) күлләр саны 3 миллион тирәсе. Аларның иң зурлары – Каспий, Арал диңгезләре, Байкал, Ладога һәм Онега күлләре. Гидрологлар республикабызда 9 меңнән артык күл исәпләгән. Соңгы 15–20 ел эчендә аларның байтагы сусаклагычлар астында калды һәм кипте. Хәзер суларның җир астына китүе күзәтелә. Упкын күлләре барлыкка килә. Табигать һәм шул исәптән сулар да дөньяларына механик рәвештә тыкшынуны яратмыйлар.

*Саки күле* Кырымда урнашкан. Бу күлнең шифалы ләме турында борынгы грек галиме Птолемей, борынгы Рим язучысы һәм галиме өлкән Плиний дә язганнар. Бу күл хәзинәсе белән борынгы скифлар да файдаланганнар.

Саки – дөньякүләм әһәмиятле курортларның берсе. Урнашкан урыны куе агачлык белән капланган зур парк, анда матур-матур буалар, фонтаннар бар, гөлләр үсә. Шулар арасында дәвалау йортлары тезелеп киткән. Янәшәдә җылы сулы Кара диңгез.

Бу кечерәк кенә күл ике өлештән тора. Берсендә шифалы ләм, икенчесендә тоз һәм химия сәнәгате өчен чимал хәзинәсе тупланган. Майланып ялтыраган һәм күкертле водород исе килгән кара ләм, күп төрле авыруларны дәвалый, могҗизалар ясый.

Тянь-Шань үзәгендә, *Сон* күле ята (республикабызның Мамадыш районында *Сон* елга-чишмәләрен, Сон авылларын, Актаныш районындагы *Сөн* елгасын, Вятканың (Нократ) уң кушылдыгы *Шөн~Сөн~Өшен* географик атамаларын искә алыйк. *Шөн~Сөн~Өшен* янында Түбән Шөн, Урта Шөн һәм Өшенбаш авыллары утырган). Анда, диңгез өстеннән 3000 метр биеклектә бернинди куак, агач юк. Күл буендагы болыннарда яшел үлән үсә. Бу җирләр Кыргызстанның иң әйбәт көтүлекләре. Бу күл буенда халыклар тарихка кадәрге чорда ук яшәгәннәр. Халык монда күлнең матурлыгына, әйбәт климатка кызыгып килеп утырган. Риваятьләрнең иң киң таралганында, бик борынгы заманда бу күл урынында зур шәһәр булган диелә.

Вакытлар үтү белән ул шәһәрне җир йоткан һәм аның урынына зур күл барлыкка килгән. Бу күлнең төбе тикшерелмәгән, легенда бәлки булып үткән ниндидер күңелсез күренешне истә тотадыр.

Халыкта шундый сүз йөри. Имеш, бу су буена Манас батыр килеп йөри торган булган. Манас – кыргыз халык дастаны каһарманы. Бу күл янындагы Ташта да Манас батыр тулпарының эзләре бар дип уйлыйлар.

Кавказның Минераль сулары районы – Җир шарындагы гаҗәеп урыннарның берсе. Табигать монда кешегә җир куенындагы күп төрле шифалы чыганакларны бүләк иткән.

Монда су эчертеп, ванна кертеп кенә дәваламыйлар. Пятигорскидан унике чакрымда, олы юл буенда Тамбукан күле җәелеп ята. Тамбукан күлендәге ләм – иң файдалы, шифалыларның берсе санала.

Республикабызның һәр районында Изге чишмәләр, суының шифасы күп булган улак-чишмә-кизләүләр байтак. Халык аларның игелеген күрә һәм һәрдаим файдалана.

Су – чисталык бирә, пакьләндерә. Ул язучылар, әдипләр иҗатында да киң кулланыла.

Татар ономастикасында *су* сүзе шактый географик атамалар һәм кеше исемнәре составында да очрый. *Идел суы, Чулман суы* (Чулман – Каманың югары агымы, Агыйдел белән кушылганга кадәр өлеше), чагыштыр: Алтайдагы *Чулышман* елгасы, Сахада (Якутия) *Чульман* районы. *Сон суы* Мамадыш районында, шул ук районда Ушмы суы кушылдыгы *Суык су* елгасы бар. *Су башы газизләре чишмәсе* – Спас районында Рәҗәп суы бассейнында. *Сулы әкә* – Кама Тамагы районында Коры Үләмәнең сул кушылдыгы. *Сулы сыза* – Рангазар суының сул кушылдыгы, Сарман районы Рангазаз авылы янында. *Сулы тау* – Балык Бистәсе районы Югары Тегермәнлек авылы янындагы тау атамасы. Тау кырыенда матур гына күл булган, хәзер ул беткән, ә атама калган. *Сулы тәкәрле йылгасы* – Кирмән суы бассейны, Мамадыш районы Урта Кирмән авылы янында. *Сулы үзән* – Бөрсет/Бүрсет суы кушылдыгы, Югары Кыерлы авылы янында (Мамадыш районы). *Сулы чокыр* – 1. Бәрле суы кушылдыгы. Апас районы Иске Чәчкаб авылы янында, 2. Олы Шаһиян суы кушылдыгы, Апас районы Олы Болгаер авылы янында. *Су тегермәне* – Кама Тамагы районы Бәрлегуҗа авылы янында. *Сусыз елга* – Карлы суы кушылдыгы – Чүпрәле районы Иске Кәкерле авылы янында һ. б. Татарстанда су компоненты авыл атамасы составында да кулланыла: *Югары Суыксу, Түбән Суыксу, Аксу, Карасу, Аксубай, Субаш, Субаш Аты, Су-Елга, Сулы, Сулы* (поселок) *Суыксу* һ. б. Бу берәмлек микротопонимнар составында да урын ала: *Суыксу тавы, Байсу күпере, Суыксу урманы, Карасу аланы, Аксу тавы* һ. б.

*Су* – борынгы төрки телдә су мәгънәсендә кулланылган *sub~sug~suw* сүзенә барып тоташа (ДТС, 1969: 512–513, 515). В. Радлов сүзлегендә *суп~суб~-сув* (Радлов, IV: 787–790), *суу, су=суу, суг* (IV: 743– 74б, 755) «су, елга, сыеклык, юешлек» мәгънәләрен аңлата дип бирелгән. Төрки телләрдә бу сүз суны аңлату белән бергә «елга» төшенчәсендә дә йөргән һәм аның

таралышы бик киң. Мәсәлән, чувашча *шыв* (чуваш диалектларында – *шу*), азәрбайҗан, уйгур һәм казак телләрендәге *су,* татар диалектларында *сыw*, нугай, үзбәк һәм кумыклардагы *сув* – барысы да «су» мәгънәсенә ия; каракалпак, кыргыз һәм алтай телләрендәге *суу,* хакаслардагы һәм тывалардагы *суг* – «елга» төшенчәсендә кулланыла. Шушы фикергә таянып булса кирәк, галим Ф.С. Хәкимҗанов та суның «елга» мәгънәсендә кулланылуын күрсәтә. Ул болгар чоры кабер ташындагы язманы болай укый: *Cärimsän sivna barsa ölti* «Чирмешән суына барганда үлде». Аның фикеренчә, болгар кабер ташындагы *сїи* сүзе гомумән суны гына түгел, ә «елга» мәгънәсен дә аңлата. *Су* – мәгънә ягыннан бераз үзгәрә һәм «елга» сүзе белән тагын да аныклана (конкретлаша).

*Су* компоненты белән ясалган атамалар Татарстаннан читтә яшәүче татарлар һәм башка төрки халыклар телендә дә кулланылалар.

Башкортстан татарлары телендә *су* компоненты белән түбәндәге гидронимнар теркәлгән: *Сулы күрия* – Караидел районында Уфа елгасының сул кушылдыгы, *Сулы кызыл* – Әлшәй районында Уршакның сул кушылдыгы, *Карасу* – Әбҗәлил районында Казмаш, Баймак районындагы Югары Тавлыкай, Мәчетле районындагы Сөләйман авыллары янындагы елгалар. Татар атамалары шулай ук Ульяновск, Самара, Саратов, Әстерхан, Оренбург, Чиләбе, Пенза, Рязань, Новосибирск, Тобол, Төмән һ. б. күп өлкәләрдә көн күрүче татарлар телендә кулланылалар.

Кырым топонимиясендә дә алар күп очрыйлар: *Аксу* (Олы Үзән бассейнындагы елга, Кара диңгез буенда, Алушта янында), *Аксу-Дере* (Карасу бассейнында, Кара диңгез янындагы елга), *Карасу, Кучук-Карасу, Биюк-Карасу, Аджису, Байсу, Бийсу, Койсу, Кабаксу, Кобаксу, Сиксу, Савлук-Су, Чурук-Су, Суук-Су, Гүрлюк-Су, Курюк-Су, Чурюк-Су, Чюрюк-Су, Алсу, Бакал-Су, Токсан-Су, Учан-Су, Эльтиген-Су, Серен-Су, Тенсу, Аргин-Су, Батанын-Су Айян-Су, Синап-Су, Акар-Су, Темис-*

*Су, Кечит-Су, Сунгу-Су, Савлук-Су, Сары-Су, Курючь-Су, Вур-Кутуню-Су, Балкая-Су, Аджису* (Кара диңгез бассейнында).

О.Т. Молчанова мәгълүматларына караганда, *су* термины үзе генә аерым су чыганагы атамасы булып бик сирәк (Суг елгасы), ләкин шул ук вакытта ике, өч сүздән тора торган гидронимнар составында еш кулланыла: *Олы Суг, Кече Суг.* Болар, нигездә, атамаларында беренчел – *су,* икенчел «елга» мәгънәсендәге *су* сүзе булган су чыганаклары (Молчанова, 1979: 91). Енисей һәм Абакан бассейннарында күп гидронимнар *суғ* сүзе белән ясалганнар: *Казынсуғ, Сарысуғ, Демирсуғ, Изагсуғ; Алтайда: Суғ, Суғат, Карасуғ, Менсуғ* (1979: 528– 529). *Су* апеллятивы руслар тарафыннан *са* рәвешле дә кулланыла: *Коксу – Кокса, Сулы – Сула* һ. б. Хакас, шор, тыва, алтай теленең төньяк диалектларында *суg* вариантында йөри (карталарда *сук* дип языла). Шорларда диалекталь вариантлардан *зуг, сунг, су, зу* әйләнештә йөри. Бу диалекталь вариант формалары рус телендә *-са, -за, -зы* рәвешле кулланыла: *Одиакса – Адйаксуг, Кораса – Каразуг, Кабырза – Кёбюрзуг, Егоза – Игесу* (Абдрахманов, Бонюхов, 1966: 159–169). Тыва топонимиясендә *суг* термины еш күзәтелә: *Ак-Суг, Олы* һәм *Кече Чинге-Суг* (чинге – тар) каналлары Барун-Хемчик районында, *Суг-Бажи* торак пункты Каа-Хем районында, Бай-Тайга районында *Суглуг* («сулы»), *Суглуг Хову* үзәнлеге (Сулы кыр, Сулы дала). А.М. Малолетко фикеренә караганда, *су* термины белән гидронимнар актив ясалганнар һәм ясалалар, ләкин алар чагыштырмача «яшьрәк» исәпләнәләр. «Аларның барлыкка килүе XIII гасырдан да алда түгел. Борынгы чыганакларда *су* компоненты белән ясалган топонимнар күренми. Күрәсең, мондый топонимнар барлыкка килү соңрак, төрки даирәгә кыпчак кабиләләре тәэсире белән бәйләнешледер. Безгә *су* сүзенең кечерәйтелгән формасы белән ясалган берничә гидроним билгеле. Сайлюгем кабыргасының көньяк битеннән агып төшкән Кобло елгасының сул кушылдыгы *Суок* елгасы һәм аның сул кушылдыгы *Суёк*» (Малолетко, 1992: 81). Кыргыз топонимиясендә *Айран-Суу* атамасы белән

дүрт топоним теркәлгән. Аларның берсе – гидроним, Нарын өлкәсенен Тяньшан районы җирләреннән ага торган Чон-Нарын елгасының уң кушылдыгы. Калган өчесе Ыссык күл, Нарын өлкәләрендәге тау сыртлары һәм тау үткелләре. Ыссык күл өлкәсенең Аксу районында, *Җылуу-Суу* исеме алган тау бар, ул Тескей Ала Тауның кабыргасы (Ыссык күл өлкәсе Джетиогюз районы). *Джыллуу-Суу* Сох елгасының югары агымында Ыссык күл өлкәсенең Тон районында. *Кашка-Су* авыллары Ош өлкәсенең Джаныджал районында очрый. *Кашка-Суу* – инеш, Алтындарга елгасының сул кушылдыгы. *Кызыл-Су* атамасы алган авыллар Ош өлкәсенең Карасу һәм Сузак районнарында урнашканнар (Умурзаков, 1988: 12).

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *су*/*суу*/*сув*/*суг* лексик берәмлеге күпьяклы, күпкырлы, ягъни универсаль термин буларак елга, инеш, күл, чишмә, кечкенә елга, гомумән барлык төр су чыганаклары атамалары ясауда актив кулланыла. Башка формалары: якут телендә – *суу*; үзбәк, кумык һәм ногай телләрендә – *сув;* чувашларда – *су*/*шу*/*шыв;* себер татарларында – *суг.* Дериватлары *зуг*/*сунг*/*зух* русча фәнни әдәбиятта -*са*/-*за*/-*зы* рәвешле язылалар. Шор телендәге географик атама *Аргысуг* карталарда Аргазы, ә *Карасуг* – Караса дип языла (Абдрахманов-Бонюхов, 1966: 164). Борынгы төрки формасы: *sub, suw, suq.* Бу лексик берәмлек географик атамалар ясаганда ясалма терминнар барлыкка китерәләр: *суат* – «сугару урыны», *учарсу*/*учарсув* – «шарлавык» (сүзгә сүз тәрҗемәдә – «оча торган су»); *субашы* – «су башланган урын»; *суак* – «арык», «сугару каналы»; *субасма* – «су басу, ташкын»; *суайрычи* – «суайырча», *агынсу* – «бик көчле агым», «тиз, кызу агышлы су»; *карасу* – «чыганак, чишмә». Сары уйгурлар телендә *су телык* – «кое» (сүзгә сүз тәрҗемә иткәндә «су тишеге») (Малов, 1957: 105). *Аксу, Карасу, Кызылсу, Коксу, Кашкасу, Тузтусу, Суук (Соок) суу* һ. б. су чыганаклары атамалары бихисап. Татарстанда -*суы* компоненты белән тәмамланган атамалар: *Авылсуы, Каргалысуы, Чытлыксуы* һ. б. Атамаларның алгы по-

зициясендә тора торган гидронимнар да шактый күп: *Субашы-Йылгасы, Суыксу-Йылгасы, Суаралык-Йылгасы* һ. б.

*Су яны, су буе, яр. Яр* сүзе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «елга, диңгез, күл кебек сулыклар әйләнәсендә күтәрелеп торган коры жирнең чите» (ТТАС, 1981: 643). Бу компонентлар Татарстан һәм гомумән татар халкы телендә актив кулланыла. Су яны, су буен, ярны белдерү өчен татар теле диалектларында төрле төрдәшләр бар. Алексеев, элекке Краснобор районнарында яшәүчеләр телендә су яны – *тугай,* сергач сөйләшендә – *пар йаны,* эчкендә – *су бите,* пенза сөйләшендә – *верех* (ул русча *берег* сүзен бозып әйтүдән килә). Темников татарлары телендә *йан йагасы* – су яры, кырыйлары, яр; түмән, тобол татарлары сөйләшләрендә – кыр, елга яры. Омск өлкәсе Тара районында *сай йагасы* – елга яры, Мөслим, Актаныш якларында ул ярлавык, вак-төяк ярлардан торган урын; кузнецк сөйләшендә *йага* – күл буе; темников, хвалын, кузнецк сөйләшләренең урынчалыкларында *йагалай* – күл буе.

*Су яры, яр* сүзе төрки телләрдә түбәндәгечә чагылыш таба. Хакас телендә *чар, хас, суғ чары;* үзбәк телендә – *кирғоқ, сақ, ил, буй, лаб;* каракалпак – *жаға жағыс, қыр, кырақ;* казак – *жаға;* карачай-балкар телендә – *джагга, суу джагъа, суу бойну;* кумык – *сув къырый, ягъа;* кыргыз – *өзөндүн бою;* чуваш – *çыран, çыр, шыв хĕрри* һ. б.

***Сукмак***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *сукмак* «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай аңлатылган: «Кешеләр, хайваннар йөрүдән тапталып ясалган тар гына юл». *Урман сукмагы. Тау сукмагы. Сукмак салу. Кыр сукмагы.Таллык арасындагы сукмаклардан сылу кызлар су ташыйлар*. К. Нәҗми. *Чыклы сукмак, көмеш тамчыларда Калган төсле синең эзләрең*. З. Мәҗитов (ТТАС, II: 681).

*Сукмак* лексик берәмлеге белән географик атамалар шактый ясалган. *Карлыган сукмагы* – Питрәч районы Шәле авылы янындагы сукмак атамасы. *Кәчим сукмагы елгасы* – Балык Бистәсе районы Олы Елга авылында. *Якуп сукмагы* – Мамадыш

районы Югары Бүрсет авылы янында урнашкан урман сукмагы атамасы. *Кучтерәй сукмагы* – Мамадыш районы Кече Бүрсет авылы янындагы сукмак атамасы. *Саба сукмагы* – Питрәч районы Кибәче авылы янындагы сукмак атамасы. *Сәфәр сукмагы* – Кукмара районы Чуллы авылы янындагы сукмак атамасы (Сәфәр исемле кешенең өе шушы сукмак янында булган). *Бала Тукай сукмагы* – Әгерҗе районы Салагыш авылы янындагы сукмак.

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *сукмак* сүзе файдаланыла: *«Куаклар арасында башка киелгән капчык күренде, ул да түгел, сукмак өстенә салынып үскән тамчылы миләш тәлгәшләрен як-якка этәреп, каршысына Минһаҗ үзе килеп чыкты».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» повестенда *сукмак* лексик берәмлеге матур һәм урынлы кулланылган: *«Ташлытау юлын кыскартыр өчен олы юлны калдырып, болын сукмагыннан да йөргәлиләр иде, водокачка янындагы басмадан чыкканда Асаф, йөрәге туктаганны тойган хәлдә, бер-ике мәртәбә Сылуның беләгеннән тотты, әмма кыз басмадан чыгуга матур гына итеп беләген ычкындыра белә, басмадан беләгеннән тотырудан да ары һич узмый һәм уздырмый да иде».*

С.М. Солтанова һәм Н.Г. Габдрахманова авторлыгында 2011 елда «Идел-Пресс» полиграфия нәшрият компексында «Күңел яктысы» исемендә дөнья күргән китаптан мондый юллар укыйбыз: *«Аның [21 ел Арча педагогия көллиятенең директоры булып эшләгән Илдус Габдрахман улы Сәгъдиевнең] һәрвакыт әйтә торган сүзләре бүген дә колакта яңгырый: «Тормышта баганалы юллар түгел, ә үзең салган сукмак кадерле. Тауга менү – авыр, төшү – бик җайлы. Юлыгыз һәрвакыт туры булсын».*

***Сыза***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *сызаның* – «коры елга» мәгънәсендә йөрүе күрсәтелгән, мисал да китерелгән: *Исәпсез-хисапсыз инеш һәм сызалар, эре һәм вак елгалардан шаулап агып килгән язгы кар сулары белән тулган Идел [кузгала].* С. Сабиров (ТТАС, II: 693).

Татар гидронимиясендә *сыза* термины аерым елга атамалары буларак та, атамалар составында да кулланыла: *Сыза* – Зәй районында Аулаш елгасы, Әлки районында – Ата, Саба районында – Симет, Биектау районында – Тамак, Апас районында – Бола, Тәтеш районында – Тархан елгалары кушылдыклары. *Сыза чишмәсе* – Түбән Кама районындагы Уратма кушылдыгы. *Җәрәкәй сызасы* – Мөслим районындагы Калмия кушылдыгы. *Урман сызасы* – Спас районындагы Актай елгасы кушылдыгы. *Сумыл нимес сызасы* – Олы Мишә елгасы бассейнында, Питрәч районының Шәле авылы янында. *Сыза туры* – Саба районының Түбән Симет авылы янындагы урын атамасы. *Чәчәвәнлек сыза* – Кама Тамагы районы Кече Болгаер авылы янындагы сыза. *Булат сызасы* – Апас районы Дүртөйле авылы янында, Инеш бассейнындагы сыза. *Усаклы сыза* – Әгерҗе районы Салагыш авылы янындагы сыза. *Биш өйле сызасы* – Әгерҗе районы Салагыш авылы янындагы *сыза. Сыза буе* – Буа районы Карлы авылы янындагы коры елга. *Сыза елгасы болынлыгы* – Чистай районы Татар Ялтаны авылы янындагы болынлык атамасы. *Сыза печәнлеге* – Буа районы Түбән Нараташ авылы янындагы печәнлек атамасы.

Юныс Йосыповның «Адай авылы тарихы» дип аталган китабында *Алакаен сызасы* искә алына. Сызаны, башкача, буйга сузылган һәм киң булмаган уйсулык дип тә булыр иде. Язгы-көзге чорларда, явым-төшем вакытында аннан су агып тора. Моннан сызаларның күл белән күл, күл белән инеш, я ике елга арасында сузылган булуы аңлашыла. Адайлыларның кайберләре сазламыкларны тоташтырган уйсулыкларны да *сызалар* дип атый. *Атнагол төбәге сызасы, Атнаш сызасы, Котый сызасы, Мунча җиреклеге сызасы, Күгәннек сызасы, Мортыш сызасы / Мыртыш сызасы, Озын тал сызасы, Олы күрән сызасы*. Шул ук авторның «Бикбау авылы» дип исемләнгән китап-брошюрасыннан алынган мисаллар (Бикбау авылы Минзәлә районына керә. Ул Актаныш белән Минзәлә чигендә): *Дөмбакты сызасы. Әмирхан чүмгәле сызасы* – ике сулык арасындагы коры

иңкүлек. *Казынды сызасы* Дөмбакты белән ике арадагы сыза. *Камышлы күл сызасы. Тирән Уй сызасы* – Тирән уйдан Юалык итәгенә чаклы сузылган бик озын сыза.

*Сыза* компоненты белән микротопонимнар да ясалган. *Сыза елгасы болынлыгы, Сыза кыры, Сыза урманы, Урмандагы сыза, Сыза аланы, Сыза күпере, Сыза тугае.*

*Сыза* термины шагыйрьләр иҗатында да очрый. Кадыйр Сибгатуллинның үзенә бер матур, көчле шигъри әсәрендә *сыза* сүзе күңелләрне сулкылдатып куя. «Давыл» дип аталган шигырь юлларында *сыза*ны ул менә ничек итеп бирә (Кама турында).

*Төптән эшчән суың актарыла,*
*Күктә яшен, болыт.*
*Сызаларың ярда ярылып ята*
*Тоташ яра булып.*

*Сыза* сүзе белән ясалган атамалар татарларның тарихи ватаннары булган җирлекләрдә дә әйләнештә йөриләр. Ульяновск өлкәсендә: *Сыза, Әхмәт сызасы, Шәмәк сызасы* – Иске Кулаткы районындагы Иске Кулаткы авылындагы коры елгалар. Самара өлкәсендә: *Шәмәк сызасы* – Камышлы районындагы Теплый стан авылындагы коры елга һ. б. Башкортстанның Бакалы районында *Таллысыза* исемендә авыл бар.

Кырым гидронимиясендә *сыза~суза* термины белән түбәндәге су чыганаклары атамалары очрый: Сөтле Су бассейнында төрки телдәге *ком* сүзеннән ясалган *Комлы сыза* һәм Мокрый Ял елгасының уң кушылдыгы, Шайтан елгасы һәм аның варианты *Шайтан сызасы. Ярли-Сузъ, Ярсуза, Ярли-Сузань* төрдәшләре дә теркәлгән (Сл., 1979: 638).

***Сырт.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *сырт* лексик берәмлегенең дүртенче мәгънәсе «исем» дип бирелгән һәм ул «Буйга сузылган тау түбәсе» дип аңлатылган. *Юлның уң ягында, яшел сыртын калкытып, озын тау сузылып ята*. И. Гази. *Түр тәрәзәдән урам аръягындагы биек тауның сырты күренә*. Г. Әпсәләмов. // Буйга сузылган калку җир. *Авылдан ике кило-*

*метр ераклыкта сөзәк сырт буйлап тимер юл үтә*. Ә. Еники.// Гомумән, буйга сузылган калку-күтәренке нәрсәнең түбәсе. *Бер дулкын сыртыннан алга сикереп киткәндә, икенчесе бәреп аны (көймәне) артка чигерә, ул тагын алга үрмәли, тагын сыртка күтәрелә, тагын сикерә иде*. Ш. Камал.

*Сырт* сүзенең бишенче мәгънәсе «сыйфат» дип ныгытылган һәм ул болай аңлатылган: «Калкып-күтәрелеп тора торган; калкулык, сырт (дүртенче мәгънәсе) рәвешендәге». *Сырт җир. Сырт басу. Яз үзенекен итә. Басуның сырт урыннары инде ачылып беткән*. Ф. Сәйфи-Казанлы (ТТАС, II: 704).

*Сырт* лексик берәмлеге топонимнар ясауда шактый актив кулланыла: *Сырт атавы* – Актаныш районының Өшәр (Семистрау) авылы янындагы атау исеме (су астында калачак дигәч, бу авыл халкы күрше авылларга күчеп утырган). *Сырт йулы урманы* – Тәтеш районының Келәш авылы янындагы урман атамасы, *Сырт чишмәсе* – Лениногорск районының Югары Чыршылы авылы янында ага торган Чыршылы елгасы бассейнында. *Сырт елгасы* – Яшел Үзән районының Зур Карауҗа авылы яныннан ага торган Петьялка елгасы кушылдыгы. *Сыртлык* – Әгерҗе районының Ямурза авылы янындагы урман атамасы. *Чиялек сырты* – Минзәлә районы Боерган авылы янындагы болын атамасы. *Кыз кала асты сырты* – Аксубай районы Яңа Ибрай авылы янындагы урын атамасы. *Каен сыза сырты* – Актаныш районы Кәзкәй авылы янындагы урын атамасы. *Кыз кала асты сырты* – Аксубай районы Яңа Ибрай авылы янындагы урын атамасы. *Шалканлык сырты* – Лениногорск районы Түбән Чыршылы авылы янындагы урын атамасы. *Нәҗми мулла сырты* – Әгерҗе районы Салагыш авылы янында (Нәҗми исемле мулланың болынлыгы булган). *Карама сырты* – Әгерҗе районы Салагыш авылы янындагы калкулык атамасы. *Алмагач сырты* – Әгерҗе районы Салагыш авылы янындагы калкулык атамасы. *Чиялек сырты* – Минзәлә районы Боерган авылы янындагы болын атамасы. *Юлдаш култыгы сырты* – Лениногорск районы Түбән Чыршылы авылы

янындагы урын атамасы. *Иске авыл сырты* – Сарман районы Мортыш-Баш авылы янындагы калкулык атамасы.

*Сырт* лексик берәмлеге әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында еш очрый.

Вахит Имамовның «Татарлар Пугачев явында» дип исемләнгән, әдәби эпизодлар белән баетылган тарихи очеркында *тау сырты* гыйбарәсе очрый: *«Ике биек тау сыртының уртасына утырган һәм инде галәмәт зурайган бу заводның (Белорет заводы) төтенен Агыйдел буйлап искән җил бүген дә сәгате-минуты белән читкә алып китә».*

Вахит Имамовның «Утлы дала» исеме алган тарихи романында кулланылган *тау сырты* гыйбарәсе күңелдә борчу хисләре уята: «*Мәркет җайдаклары, тау сырты буенча әрле-бирле сугылып, әллә ничаклы вакыт үткәрделәр, әмма Тимучинның эзен тапмадылар».*

Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» романында сырт термины еш кулланыла: *«Кырык сырт... Урал тауларын аркылы чыгу өчен, мәгърибтән мәшрикъка үтәр өчен, шушы кырык сыртны кичәргә кирәк булган. Кышларын үтә алмаслык кар-бураннарга батып утырган, җәйләрен тирән тау елгалары һәм төпсез сазлыклары белән сагалап торган кырык сырт». «Асылгәрәй картның юлында очраган бу беренче тау сырты Кырыктау дип атала иде. Урал тавының көньяк-көнчыгышында, кыйбла якка карап сузылып яткан бу сырт дала белән тау арасында чик булып тора. Бу яктан юлга чыгучылар өчен ул – беренче, Уралның теге ягыннан килүчеләр өчен соңгы сырт иде».*

Прозаик һәм шагыйрә Фирүзә Җамалетдинованың «Мин тау түгел, ләкин түбәм күктә...» дигән сүзләр белән башланган шигырь юлларында *тау сыртлары* гыйбарәсе очрый.

*Мин тау түгел, ләкин түбәм күктә...*
*Шуңа күрә миңа рәхәт бугай.*
*Телим икән тау сыртларын күрәм,*
*Телим икән яшим менә шулай –*
*Берни күрми генә...*

*Сырт* термины шактый күп төрки халыклар телендә очрый: *сырт* – төрек телендә *сирт*. Кырым татарларында *сырт* «җилкә, арткы як, тау сыртын, калкулык»ны белдерә (О.А. Эбасанов; Халилов Б., 1978); төркиләрдә *sirt* – «сырт» (Наджарова, 1977); караим теленең кырым диалектында *сырт* «җилкә» (Караим сүзлеге); ногайларда *сырт* – 1) «нәрсәнеңдер тышкы ягы», 2) «төньяк» (Ногай сүзлеге); азәрбайҗан телендә *сырт* – «яссы, сузылган калкулык, тау сырты; биек, югары» (Бушуева, 1971). *Сырт* – шактый сузылган биек булмаган яссы калкулык, субүләр таулар тезмәсе, ике елга арасы, киң һәм тәбәнәк таулар тезмәсе.

***Тал***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *тал* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе түбәндгечә аңлатылган: «Гадәттә су буйларында кыяк булып үсә торган, озын һәм сыгылмалы чыбыклы, озынча тар яфраклы агач». *Талны чыбык чагында бөгәләр*. Мәкаль. *Су буенда таллар бар, Яфрагында баллар бар*. Җыр. *Талга кунып, тал тибрәтеп Сайрый сары сандугач*. Җыр. // Диалекталь. *Өянке. Елга буенда...үткән елны ауган карт тал агачы бар иде, шуның өстенә утырдык.* Ә. Айдар (ТТАС, III: 22).

***Таллык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе дә аңлатылган: «Таллар күп үсә торган, күп үскән урын». *Су буенда вак таллык, Вак таллыкта вак балык*. Җыр. Т*ашу баскан болын, Тугайларны. Су астында калган таллыклар.* С. Урайский (ТТАС, III: 24).

*Тал, таллык* берәмлекләре географик атамалар ясауда шактый актив кулланылалар: *Абу таллыгы* – Азнакай районы Мәсгут авылында бар. *Абышка таллыгы* – Азнакай районы Сарлы авылы янындагы тал үсә торган урын. *Түбәнге таллык* – Баулы районы Исергәп авылы янындагы урам атамасы. *Түгәрәк тал* – Алабуга районы Бәзәкә авылы янындагы урын атамасы. Т*ал асты чишмәсе* – Биектау районы Суыксу авылында. *Тал буга яры* – Сарман районы Янурыс авылы янындагы урын атамасы.

*Тал, таллык* лексик берәмлекләре әдипләребез иҗатында кулланыла. Фатыйх ага Хөснинең «Йөзек кашы» повестенда

мондый җөмлә белән танышабыз, анда *тал* лексик берәмлеге кулланыла: *«Таллар, елганың уң як ярлары буйлап, һаман сузылалар».*

Фоат Садриевның «Таң җиле» романында табигатькә зур урын бирелә һәм шул исәптән *тал* лексик берәмлегә дә кулланыла: *«Ул [«Таң җиле»] аның [Нуриасманың] тән һәм җан җылысын сеңдереп, Нуриасма гомере буе омтылган, җанына рәхәтлек, йөрәгенә көч алган Ык буйларына, болыннарга, әрәмәләргә, иген басуларына шул җылыны таратырга очты, аның инде бүтән беркайчан да алар янына килмәячәген хәбәр итәргә ашыкты...»*

***Тамак***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *тамак* сүзенә мондый аңлатма бирелгән: «Елганың башка зуррак елгага кушылган яки күлгә, диңгезгә койган урыны». Мисаллар да китерелгән: *Асылгәрәй хәрби юлаучыларны Танып тамагына кадәр генә озатып куярга тиеш иде.* М. Шабай. *Яшел Елга тамагын үткәч, җәелеп яткан чирәм бар.* М. Әмир (ТТАС, III: 27). Борынгы төрки телдә *Тамаү* II, *tamay iduq* – топонимик термин буларак беркетелеп калган (ДТС, 1969: 529). *Тамаг ыдук башда сӳңусдімis – Без Изге Тамаг тавы янында сугыштык* (Малов, 1951: 32; Айдаров, 1971:100). Хакас телендә *тамах* – «елга тамагы», «ермак».

Татар топонимиясендә *тамак* термины үзе генә дә атама булып кулланыла ала. Биектау районының Юртыш авылында бер елга *Тамак* дип атала. *Тамак* – Мамадыш районы Усәли авылы янында Бүрсет һәм Кече Бүрсет елгалары кушылган урын.

*Карамал тамагы* – Азнакай районы Карамалы авылы янындагы урын атамасы. *Ике су тамагы* – Саба районы Төрек-Тәмте авылы янында ике су килеп кушылган урын атамасы. *Юныс тамагы* – Актаныш районы Кәзкәй авылы янында Сөн елгасы кушылдыгы.

*Тамак* термины атамалар составында еш кулланыла: *Сартамак суы* – Түбән Кама районы Кызыл Чапчак авылы. *Сазлы тамак елгасы* – Игәнә елгасы кушылдыгы (Сарман рай-

оны), *Тар тамак* – Ык елгасы (Исергәп авылы янында), *Тамак елгасы* – Петьялка елгасы кушылдыгы (Яшел Үзән районы), Петьялка елгасын Күлбаш авылы халкы *Тар тамак* дип йөртә. *Баллы тамагы чишмәсе* – Куак суы бассейны (Лениногорск районы) һ. б. Актаныш районының Адай авылында *Кама тамагы* – Кама юлы Минзәләгә бара торган урынга бирелгән атама. *Дәүләтша тамагы* – Солтан күлен Иске Ык белән тоташтыручы тамак. *Күзән тамагы* – шул исемдәге күлне Ык белән тоташтырган сулы тамак. *Маткауш тамагы* – елганың Ыкка койган урыны. *Өянке тамагы* – язгы ташу чорында Ык елгасыннан болынга су ага торган тамак. Ул – елның башка фасылында сусыз була. *Камышлы тамагы* – Камышлы инешенең Ыкка койган урыны (Минзәлә районының Калморза авылында). Минзәлә районының Бикбау авылында *Бүре тамагы* – Уйлык күлен Баҗана елгасы белән тоташтыручы тамак, *Тәкә күле тамагы* – ташу чорында күлне Ык елгасы белән ялгый. Елның калган вакытында тамак сусыз кала. *Артамак болыны* – Тәтеш районының Олы Тархан авылы янындагы болын атамасы. *Тал тамак елгасы* – Апас районы Танай-Турай авылында, Олы Үләмә бассейны, *Чигер тамагы* – Актаныш районы Кәзкәй авылы янындагы урын атамасы. *Артамак болыны* – Тәтеш районы Олы Тархан авылы янындагы болын атамасы. *Асыл тамак елгасы* – Актаныш районы Елан авылы яныннан аккан Сөн елгасы бассейнында. *Чурна тамагы* – Мамадыш районы Югары Сон авылында. *Бабай тамагы* – Буа районы Түбән Наратбаш авылы янындагы урын атамасы. *Аргы тамак елга*сы – Теләче районы Җәнәй авылы яныннан ага. *Тамак* лексик берәмлеге аерым су чыганакларының, елга авызына урнашкан ойконим һәм микротопонимик атамаларның состав өлеше булып килә. Бу күренеш башка төрки телләрдә дә күзәтелә (Коков, Шахмурзаев, 1970: 116; Мурзаевы, 1959: 227; Муминов, 1967: 3). Борынгы төрки телдә ул оронимик термин булган (ДТС, 1969: 32, 529; Айдаров, 1971: 100*). Күл тамагы* – Спас районы Әҗмәр авылы янындагы тамак. Актай елгасы

бассейнында. *Арбур тамагы* – Балтач районы Смәил авылы янындагы атама.

*Тамак* компоненты авыл атамалары һәм микротопонимнар составында да килә. *Мәлләтамак, Мортыштамак, Кама Тамагы, Бәйрәкәтамак, Теләнче Тамак, Ләшәүтамак* авыллары Татарстанда урнашкан. Микротопонимнар: *Тар тамак ягы, Сазлы тамак кыры, Тамак тавы* һ. б.

*Тамак* термины әдипләребез иҗатында очрый.

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романыннан мондый юллар укыйбыз: *«Үз өендәге краннан чурылдап су агу аңа чишмә тамагында сандугач сайраудан матуррак ишетелә».*

Вахит Имамовның «Утлы дала» романында *Идел тамагы* гыйбарәсе кулланылган: *«Кул сузымындагы Саксин каласына юлланган Мүнкә ханнан бер хәбәр юк, ә Идел тамагына киткән Гөек инде Биләр янына ук килеп җиткән... Җаекны бер атна буе кичкәннәрдер». «...Сакмар тамагында, Бачман тарханга буйсынып яшәгән Актүбә каласын сытып үтүгә үк, Бату хан төмәнбашларны чатырына җыйды». «...Андрей кенәзнең кунак сәяхәте турындагы Болгар мәмләкәтенә инде Ука тамагындагы Янкала кирмәненнән үк чыгып киткән иде».*

*Тамак* терминының географик берәмлек атамаларына нисбәтле мәгънәсе күп төрки телләрдә очрый.

*Тамак, томак:* коман, чагатай телендә *тамак* – «бугаз» (Радлов, III: 993); караим теленең кырым диалектында *тамакъ* – «аңкау, тамак» (Караим сүзлеге); ногайларда *тамак* – 1) «тамак, йоткылык», 2) географик мәгънәсе «елганың икенче елгага койган урыны (Ногай сүзлеге); казакларда *тамак* – «тамак, елганың икенче елгага койган урыны, ермак» (Донидзе, 1971); хакас телендәге *тамах* – «елганың икенче елгага койган урыны, елга ермагы, тарлавыкка керү урыны», турыдан-туры тәрҗемәсе – «тамак, йоткылык» (Бушуева, Волостнова, 1968). «*Тамак* – тамак, елганың икенче елгага койган урыны, керү урыны» (Мурзаевы, 1959).

*Тамак* сүзе татарлар яшәгән бөтен Россия җирлекләрендә еш очрый.Самара өлкәсендәге *Коры тамак* – Олы Кинәле елгасының сул кушылдыгы һ. б.

Башкортстанда түбәндәге ойконимнар *тамак* компоненты белән ясалган: Калтасы районында – *Буатамак,* Бишбүләк районында – *Зиреклетамак,* Бөрҗән районында – *Каратамак,* Благовар районында – *Каргалытамак,* Туймазы районында – *Мәтәүтамак,* Бәләбәй районында – *Казанлытамак,* Бакалы районында – *Камышлытамак, Чукалытамак, Мәнәүзтамак.* Эстәрле елгасы тамагына салынган шәһәр *Эстәрлетамак ~ Стәрлетамак* исемен йөртә һ. б.

Пермь татарлары телендә *тамак* сүзе урынына *түз* сүзе кулланыла. Бу апеллятив ойконимнар составында да актив йөри. Уин районында *Әри-Түз, Башап-Түз, Тәләс-Түз* исеме алган авыллар бар.

*Тамак* компоненты алган топонимның таралыш ареалы киң. Карачай-Балкар гидронимиясендә – *Тамак суу* (Коков, Шахмурзаев, 1970: 116); Грузиядә – *Бештамак* (Малка, Баксан, Чеһем, Черек, Терек елгалары бергә килеп кушылган урын); Кыргызстанның Ош өлкәсендә *Тюе-Тамак* атамасы алган елга бар (Ган, 1909: 26); Көнбатыш Себердә – *Карагайтамак, Цуцкатамак* бар (Муминов, 1970: 3); *Өч-Тамак* – Омск өлкәсенең Знаменск районындагы авыл. Шиш елгасы (Иртышның Омск шәһәре янындагы агымы). тамагына урнашкан авыл *Шиштамак* дип атала. *Кактамак, Карагай Тамак* елгасы Төмән өлкәсендә бар. *Тар Тамак* авылы Себернең Тара елгасы бассейнында, *Усть-Тамак* авылы Иртыш елгасы бассейнында, *Бабасан Тамак* авылы Бабасанда, *Тамак күле* – Тобол елгасы бассейнында. Кырымда Алма елгасы тамагына урнашкан торак пункт *Алма-Тамак* исемен йөртә.

Э. Мурзаев мәгълүматларына караганда, Кырымда тагын Сиваш һәм Азов диңгезләренә якын урында, Сиваш бугазы янында гына *Тамак* исеме алган урын бар. Чегем тарлавыгындагы бер тар аралык *Кызыл Тамагы* дип йөртелә (Кабарда-Балкария).

***Тарлавык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем» дип беркетелгән һәм болай аңлатылган: «Таулы җирләрдә текә ярлы тар үзән». *Георгий Ломидзе бу вакытта тирән тарлавык төбендә һушсыз килеш ята иде.* Г. Әпсәләмов (ТТАС, III: 44).

*Тарлавык* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда кулланыла. *Мәшәт тарлавыгы* – Азнакай районы Мәлбагыш авылы янындагы тарлавык атамасы. *Шалкан тарлавыгы* – Азнакай районы Әлкәй авылы янындагы тарлавык атамасы.

*Тарлавык* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында шактый файдаланыла. Вахит Имамовның «Утлы дала» романында *тарлавык, тарлавык ерымнары* гыйбарәсе шактый кулланыла: *«Чыннан да, Кулан башы дип аталган бер өркәч яныннан узып барган чакта кар ташкыны кузгалып, Чыңгызханның төмән ярым җайдагын тарлавык ерымнары астына мәңгелеккә күмде... Әгәр ул гаскәрен берничә нөгәргә бүлмәсә, Җигулат тауларындагы тарлавыкларга кергәч, юньле-башлы селкенә алмаячак». «Басмач тархан, тирән тарлавык төбе буйлап аккан Акчишмәгә төбәлеп, тик утыра». «...Тарлавык юлына борылып карагач, Бачман тархан ташка кадаклап куйгандай хәрәкәтсез калды».*

***Тарлау.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу термин «исем» дип билгеләнә һәм аңа түбәндәге сыйфатлама бирелгән: 1. Болын яки урман уртасындагы аерым басу. *Тарлавына тары чәчкән, Татлысына кинәнгән*. Мәкаль. *Урыс кызы урамда, Чирмеш кызы чирәмдә, Татар кызы тарлауда, урак ура барнауга* (Такмак); 2. Басу эчендә сөрелми калган урын (гадәттә сазламык җир яки куаклык). *Әнә аерым тарлау булып тал әрәмәсе утыра.* А. Гыйләҗев (ТТАС, III: 44).

*Тарлау* термины җыен атамасы булып та әйләнештә йөри.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, ***Йанил җыйынын*** яки ***тарлау җыйынын*** июнь уртасында (арыш чәчәк аткан вакытта) Вятканың уң кушылдыгы Бурец елгасы бассейнында урнашкан Янил, Ядегәр, Бүлиле, Тарлау, Югары Шәмәрдән, Түбән Шәмәрдән, Бөйәр авыллары халкы үткәргән.

Җыенның беренче атамасы *Янил* < *Яңа* + *ил* «яңа авыл» (җыен вакытында бу авылда ярминкә уздырганнар).

*Тарлау* атамасы авыл исеменнән алынган. Борынгы төрки телдә *tarlaq* «кыр», «басу» мәгънәсендә йөргән.

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *тарлау* терминының ике мәгънәсе дә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндәгечә бирелгән һәм ул тагын шундый өстәмә язган: «Р. Әхмәтьяновта: „Басу уртасындагы урман“. „Древнетюркский словарь“ буенча, *тарлаг* – гомумән басу, иген кыры, эшкәртелгән җир».

*Тарлау* термины географик атамалар ясауда актив кулланыла: *Тарлау* – Балык Бистәсе районындагы Биектау авылының Чаллы ягы басуы исеме; Мамадыш районының Күк Чишмә авылындагы җир атамасы. Әтнә районы Олы Мәңгәр авылының да бер өлеше *Тарлау* дип атала. *Тарлау аланы* – Тукай районының Бигеш авылы янындагы алан атамасы. *Тарлау асты* – Балтач районы Яңгул авылы янындагы урын атамасы. *Тарлау басуы* – Теләче районының Олы Мишә авылы, Әгерҗе районының Салагыш, Арча районының Урта Пошалым авыллары янындагы басулар атамасы. *Тарлау болыны* – Мамадыш районының Арташ, Баскан авыллары янындагы болын атамалары. *Тарлау елгасы* – Саба районының Язлы Арташ авылы янында, Арташ елгасы бассейнында; Нурлат районының Кизләү авылы янында, Зур Чирмешән елгасы бассейнында. *Тарлау калкулыгы* – Әгерҗе районының Салагыш авылы янындагы урын. *Югары тарлау* – Балтач районы Смәел авылы янындагы басу атамасы. *Морза тарлавыгы* – Азнакай районы Сәләй авылы янындагы басу атамасы. *Югары тарлау* елгасы – Балтач районы Түбән Кенә авылы янында ага торган елга. *Тарлау куаклыгы* – Балтач районының Яңгул авылы янындагы куаклык атамасы. *Тарлау сырты* – Сарман районының Азалак авылындагы калкулык атамасы. *Тарлау елгасы* – Кукмара районы Янил авылы янында, Бөре елгасы бассейны. *Тарлау сазлыгы* – Мамадыш районының Түбән Сон Көек авылындагы урам атамасы.

*Тарлау* лексик берәмлеге әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында киң кулланыла. Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» романында топонимнар һәм алар барлыкка килүнең нигезе булган ономастик терминнар шактый күп кулланыла: *«Яңа хакимияткә җир җитми – Зәйтуганның әкияти урманнарын кисеп, бөдрә әрәмәләрен киптереп, иген чәчтерәләр, тарлауларга колхоз малын кертеп тутыралар».*

*Тарлау* термины Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә кулланыла. *Тарлау, тарик, тарла, талог* терминнарын Э.М. Мурзаев искә ала. Төрки һәм төрки булмаган телләрдә бу терминнар «сөрелгән җир», «эшкәртелгән җир» мәгънәсен аңлата. Борынгы төрки телдә *tarlaq* – «кыр, басу»; калмык телендә *taran* – «кыр, орлык, ашлык бөртеге»; халха-монгол телендә *тариа*(*н*) – «икмәк, ипи, ашлык бөртеге», *тари-аланг* – «җир эшкәртүчелек», «кыр~басу»; эвенк телендәге *тари* – «чәчү, орлык чәчү, чәчү чәчү». Төрек телендә *tarla* – «кыр, басу». Болгар (Дунай буе) телендә диалекталь вариант *тарла* шулай ук «кыр һәм басу». «Басу, кыр» мәгънәсендәге атамалар: Тывада – *Тарлаг,* Омск өлкәсендә – *Тарлык,* Монголиядә *Тариалан* һәм *Тариат* атамалары бар.

***Тармак.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *тармак* лексик берәмлегенең күчерелмә мәгънәдә килүе ачык итеп болай аңлатылган: «Бер төп өлештән аерылып чыгып торган яки аерымланып киткән һәртөрле бериш озынча предметлар турында». *Елга тармагы. Куе урман эченә алып кергән юл, бара торгач тараеп, тармакларга бүленде*. И. Туктар. *Уралның безгә караган итәгенең тармаклары сырт-сырт булып тезелеп китәләр*. Г. Ибраһимов (ТТАС, III: 44). Димәк, *тармак* лексик берәмлеге башка мәгънәләре белән беррәттән, «елга тармагы»н да аңлата.

В. Радлов сүзлегендә *тармак* (Идел тармагы) Казан татарлары сөйләшендә «елга кушылды» дип бирелгән (Радлов, т. III, ч. 1: 1905).

*Тармак* термины татарлар яши торган урыннарда географик атамалар буларак әйләнештә йөри.

Татарстанда: *Олы тармак* – Әлки районы Иске Салман авылы янында Мөкәш чокыры кушылдыгы. *Ихсан тармагы* – 1. Арча районы Орнашбаш авылы янында, Болан атавы елгасы бассейнында, 2. Сарман районында Минзәлә елгасы кушылдыгы. *Мәскәү тармагы* – Әлки районы Иске Салмаш авылы янындагы Мәкәш чокыры елгасы бассейнында. *Кырый тармак* – Әлки районы Иске Салман авылы янында, Мәктәп чокыры кушылдыгы. *Кырый тармак күле* – Әлки районы Чуваш Кичүе авылы янында. Кече Чирмешән елгасы бассейнында. *Каенлы тармак* – Сөн елгасы кушылдыгы (Актаныш районы), *Чишмәле тармак* – Актай кушылдыгы (Спас районы), *Чибәр тармак* – Зәй елгасы кушылдыгы (Зәй районы), *Ибрай тармагы* – Иганә елгасы кушылдыгы (Мөслим районы), *Кырык бер тармак елгасы* – Рәҗәп суы кушылдыгы (Спас районы), *Тармак суы* – Гөбенә елгасы кушылдыгы (Апас районы); *Тармак чаты* – Ямбакты авылы янында (Спас районы), *Тармак борылышы* – Зәй елгасы кушылдыгы (Зәй районы), *Каенсаз тармагы* – Питрәч районы Чыты авылы янында, Иске авыл суы кушылдыгы. *Мәкү тармагы* – Әлки районы Иске Салман авылы янында, Мәкәш чокыры елгасы бассейнында. *Каенсаз тармагы* – Питрәч районы Чыты авылы янындагы Иске авыл суына кушыла. *Ихсан тармагы* – Арча районы Орнашбаш авылы янында, Болан атавы елгасы кушылдыгы.

*Тармак* термины әдипләребез иҗатында шактый еш кулланыла: Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» романында мондый җөмлә укыйбыз: *«Бик югарыдан, җиһан биеклегеннән караганда, Уралтау көньякка таба кинәт кенә чәрдәкләнеп, таралып-тармакланып китә».*

Төрки телләрдә бу термин шактый актив. Үзбәк, кыргыз, нугай, башкорт, каракалпак телләрендә *тармак* шулай ук «елга кушылдыгы»н белдерә. Бу термин фин-угор телләренең кайберләрендә очрый. Мари телендә татар теленнән алынма буларак кабул ителгән *тармак* сүзе түбәндәге төшенчәләрне белдерә: 1) үсенте; 2) елга култыгы; 3) ботак (МРС, 1956: 584).

Кырымдагы мариуполь греклары телендә *тарама* – «коры елга» (таралыш ареалы – Азов диңгезенең төньяк өлешләре). Ул күбрәк ияртүче кисәк белән янәшә кулланыла. Апеллятив үзе генә аерым су чыганагы атамасы булып сирәк кулланыла. *Тарама* – Днепрның һәм Коры Ял елгаларының сул кушылдыгы. *Тарамьска* – Днепр өлкәсенең Югары Днепр районы җирләреннән агып килеп Днепрга кушыла торган елга (Сл., 1979: 72, 553, 609).

***Татар.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә аңлатылганча, ул «исем»: 1. Башлыча Татарстанда һәм күрше өлкәләрдә, республикаларда яши торган халык һәм шул халыкның бер вәкиле. *Якупның алдында яшь, бик яшь, хәтта малай гына диярлек сары тутлы бер татар утырып тора иде*. И. Гази. // Сыйфат мәгънәсе. Шул халыкка мөнәсәбәтле. *Татар теле. Татар әдәбияты, татар көйләре;* 2. Җыйма мәгънәсе: Татар халкы, татарлар. *Татарда тел юк, әдәбият юк, диючеләрне... кызгандым. Әйе, бездә әдәбият бар һәм дә бай әдәбият*. Г. Тукай. *Бусагадан узган кеше Чәй эчми чыкмас өйдән. Бу йола безнең татарда Гомер-гомердән килгән;* 3. Диалекталь. Гомумән, кеше, ир кеше, ир-ат. *– Ай-яй, оста татар икәнсең, – диде түтәй, – көн саен сиңа күкәй чәчәрләр, көн саен сиңа күкәй ашатырлар. – Эчеңә тияр*. Ш. Маннур; 4. Искергән. Кырым, Кавказ якларында һәм Себердә яшәүче кайбер төрки кабиләләрнең, этник группаларның уртак атамасы. *Кырым татарлары. Алтай татарлары. Азәрбайҗан татарлары*; 5. Тарихи. Борынгы заманнарда Көнчыгыш Себердә, Монголиядә һәм Кытайда яшәп, монгол, маньчжур телләрендә сөйләшкән кабиләләрнең уртак атамасы.

*Татар зелпесе.* Зелпенең корылыкка чыдамлы төре. *Комлы һәм туфрак изри торган җирләрне ныгыту өчен татар зелпесе, тирәк һәм имән агачлары утырталар*. Умартачылык.

*Татар өрәңгесе (чаганы)* – өрәңгенең далаларда, ачык җирләрдә үсә торган төре (ТТАС, III: 52).

*Татар-башкорт.* Җыйма исем. Татарлар һәм башкортлар (бергә алганда). *Бу вакытта инде татар-башкорт батальоны урамда сугыша иде.* К. Тинчурин (ТТАС, III: 52).

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә татарлар турында мәгълүмат кызыклы, күп информация бирә.

*Татар, татарлар* исемен (атамасын) хәзерге вакытта Идел һәм Урал буе татарлары (Казан татарлары, мишәрләр, керәшен татарлары, Әстерхан татарлары), Себер татарлары (Тура, Төмән, Ишим, Ялутар, Иртыш, Тубыл, Тара, Бохара, Чат, Ачинск, Бараба, Томск татарлары) һәм Кырым татарлары йөртә. Элегрәк исә, узган гасырда һәм XX гасыр башларында, Россиядә яшәгән күп кенә төрки халыкларны, атап әйткәндә, азәрбайҗаннарны Кавказ татарлары дип, хакасларны Минуса яки Абакан татарлары дип, шулай ук казакларның шактый өлешен Семипалатинск татарлары дип, аннары Төньяк Кавказ халыкларының бер өлешен һәм Үзәк Азиянең төньягы халкын (татар-уйгурларын) татарлар дип йөрткәннәр.

«Татар теленең диалектологик сүзлеге»ндә (1993) *татар* сүзенең башкачарак мәгънәләре дә теркәлгән. Мәсәлән, «Ул хәзер татар бит инде кызлар артыннан йөрергә» дигәндә *татар* – «никахлы, кибынлы» мәгънәсендә килә. Ә *«Биш татар күтәрә алмаганны күтәреп азапланма инде»* гыйбарәсендә *татар* сүзе «ир, иркәк» мәгънәсендә. Ә Сергач якларында хатын-кыз «татарым» дигәндә ирен күздә тота.

Кайбер галимнәр *татар* сүзе кытайча *та-та* сүзеннән килеп чыккан дип уйлыйлар. Бу сүз «шапшак, кыргый» мәгънәсендә. Әмма тарихи-лингвистик тикшеренүләр кытайларның электә төньяк күршеләрен *татар* дип йөртүләрен, соңыннан гына бу сүзгә тискәре мәгънә салуларын күрсәтә.

Мәнгү хан Монголия башкаласы Каракорымга Европадан килгән миссионер Рубруквиска болай дигән: «Без, татарлар, бер Аллага ышанабыз, аның белән яшибез һәм үләбез...», ягъни ул үзләрен *татарлар* дип атый.

Әбелгази (XVII гасыр) *татар* сүзе башта хан исеме булган дип саный. А.В. Анохинның «Алтайлыларда шаманлык буенча материаллар» (Ленинград, 1924) дигән китабында Маңзыр исемле алтайлы шаман ата-бабаларының рухларына

(әрвахларга) мөрәҗәгать иткәндә *Татар* исемле шаманны телгә алып, аны безгә шактый аңлаешлы төрки телдә «Абыкаем Татар – кам, атаклы һәм бөек кам» дип атый. Димәк, аларда *Татар* ялгызлык исеме булып та йөргән (әйтик, бездәге *Үзбәк* исеме шикелле).

Татар этнонимы Россиядә һәм Көнбатыш Европада XII гасырдан мәгълүм. XI гасырда Мәхмүд Кашгари кыргызларның күршесе булган татарларны телгә ала. «Диване лөгатет-төрк»тә гарәпчә «Татар жилүн минәт төрк», ягъни «Татар – төркиләрнең бер тармагыдыр» диелгән.

1248 елгы бер әрмәнчә кульязмада татарларның, ук кебек «үткен» һәм «җиңел» булганга, «тур» һәм «ар» дип аталуы, шуннан аларның «татар» дигән исеме килеп чыгуы әйтелгән. 1245–1247 елларда Монголиядә булган италияле монах Плано Карпини биредәге «су-монгаллар»ның, үз җирләре аша аккан *Татар* елгасы исеменә бәйләп, үзләрен *татар* дип атаганнарын хәбәр итә. Плано Карпини үзенең «Монгаллар тарихы» китабының ахырына: «Без татар дип атаган Монгаллар тарихы тәмам», – дип нокта куя, ягъни аларны бер халык дип саный.

1236–1237 елларда монгол-татарлар белән үзе очрашкан венгр монахы Юлиан да: «Татарлар... ниндидер *Тартар* елгасы буенда яшәгәнгә, татар дип аталалар», – дип яза. Шуннан соң татар этнонимы *тартар* рәвешендә Көнбатыш Европада да телгә керә. Европа телләрендә *тартар* сүзе «үлгәннәр дөньясы, тәмуг, җәһәннәм» мәгънәсендә йөри. Ягъни татарлар җәһәннәмнекеләр, тәмугтан чыккан кешеләр булып аңлашыла. Шуның аркасында Көнбатыш халкы аңында татарларга карата бик тискәре мөнәсәбәт калыплашкан. Хәер, Көнбатышта берзаман үзләреннән көнчыгышта булган барлык халыкларны, хәтта русларны да «тартар» дип атый башлаганнар (М. Зәкиев). Изге Людовик: «Без тартарны Тартарга атарбыз», – дип әйткән, имеш.

Кытай тарихчысы Мын-гут (XIII гасырның беренче яртысы) төркиләрне – *ак татарлар,* монголларны – *кара татарлар,* маньчжурларны *су татарлары* дип атый.

XIV–XV йөз татар әдәбияты истәлекләреннән «Бабахан дастаны» поэмасында *татар иле, татар шәһәре* телгә алына. Аның төп каһарманы Таһир да үзен «мин татармын» дип атый. Дастанның ахырында мондый юллар бар: «Әле Багдад шәһәрендә йөрерләр, әле Татарның эчендә гизәрләр».

Н.А. Баскаков *татар* сүзен төрек телендәге *tatar* – «атлы хәбәрче, илче» сүзе белән дә, калмык һәм монгол телләрендәге *татр* – «сакау» сүзе белән дә бәйләп карый.

Мирфатыйх Зәкиев *татар* сүзе төрки этнонимнар калыбы буенча ясалган һәм аның беренче өлеше *тат* «ят җир кешесе, чит кабилә кешесе, түбән катлау кешесе, крепостной» мәгънәсендә булып, соңгы өлеше *эр – ир* борынгы чорда гомумән «кешеләр» мәгънәсендә кулланылган, соңга таба гына ир-ат мәгънәсен алган дип яза. Шул рәвешле ул *татар* сүзенең төрки чыгышлы булуын дәлилли һәм «татар» этнонимының үзатама булмыйча, тышкы атама булуын күрсәтергә тырыша. Кыскасы, шунысы бәхәссез: татар этносы тарихы «татар» этнонимы тарихы белән тәңгәл түгел, халык *татар* сүзен үзатама итәргә теләмәгән, үзенең Болгардан булуын онытмаган. Олуг шәхес Мөхәммәдъярның XV гасырда язган «Төхфәи мәрдән» поэмасында *татар* сүзенең мыскыллау сүзе буларак кулланылганлыгын ачык күрәбез. Поэмада Безбаз Хушнәваны:

*Аллаң-мәзһәбең белмәүче татар син,*
*Бу дөньяда һәм эттән дә начар син, – дип сүгә.*

Монда без, монгол-татарлар җирле кавемнәр тарафыннан ассимиляцияләнгән булсалар да, илдәге халыкның исеме *татар* булып киткәнлеген истә тотарга тиеш (Ш. Абилов буенча).

Удмуртлар безне *бигәр/бүгәр* дип, марилар *суас/сүәз* дип атап йөрткән, мордвалар *пичкась* дип, калмыклар *кара мангыт* дип, казаклар һәм үзбәкләр *нугай* дип, ханты-мансилар *тил* һәм *чат* дип атап йөрткәннәр (Р. Әхмәтьянов). *Пичкась/печкась* сүзе *бәҗәнәк* (печенег) сүзеннән килә, ихтимал, мордва халкы очраткан беренче төркиләр *бәҗәнәк* булганнардыр. Боларга

өстәп шуны да әйтик: В.К. Магницкий фикеренчә, марилар телендә *суаслар* – татарлашкан чувашлар булырга тиеш («Нечто о чувашах, татарах и мишарях». Действия Нижегородской губернской архивной комиссии. Т. III, Н.-Новгород, 1898). Н.А. Спасский чувашларның татарны *тодор* дип атавы турында яза. Мишәрләр татарны *ногыр/ныгыр, логыр* һәм *кулугур* дип атаганнар.

Пермь краендагы күпчелек татарлар үзләрен *көңгөрләр* дип атыйлар. Шуны искәртик: бәҗәнәкләр дә үзләрен *көңгөр* дип йөрткәннәр.

*Татар* сүзе кушма этнонимнарда да очрый: *сигез татар, тугыз татар, утыз татар* һ. б.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы Сәлам Алишев татарларның этник тәшкиләте турында түбәндәге нәтиҗәләргә килә. XV–XVI гасырларда оешкан Казан ханлыгының төрки халкы ике төп компоненттан – болгарлардан һәм кыпчаклардан торган. Кытай чигендә XII гасырда яшәгән борынгы татар кабиләләре Идел буйларына килмәгәннәр һәм татар халкын барлыкка китерүдә катнашмаганнар. Казан ханлыгы халкы составына, кыпчаклардан тыш, Алтын Урдадан бүтән бер кабиләнең килеп керүе хакында фараз кылырлык дәлилләр юк. *Татар* атамасы кытай һәм гарәп чыганаклары (һәм сәүдә) аша Көнбатыш Европага һәм Руська килеп җитеп, тулаем Алтын Урда халкына нисбәт ителгән. Урта Идел буе төркиләрен һәм күп кенә Шәрык, Кавказ халыкларын Көнбатыш Европада һәм Россиядә киләчәк дәверләрдә дә традиция буенча *татар* дип атауларын дәвам иткәннәр. Ә безнең халык үзенең исеме итеп *татар* атамасын рус империясе басымы астында фәкать XX гасыр башында гына кабул иткән. Сәлам Алишев Казан татарларыннан бераз читтәрәк яшәгән һәм рус дәүләтенә кергән мишәрләрнең *татар* исемен элегрәк кабул иткәнлекләрен күрсәтә.

Гомумән, татар халкының милләт булып оешуында ислам диненең тоткан урыны гадәттән тыш зур. Мөселманнар арасына кыпчак, нугай яки, әйтик, фин-угор төркемнәре килеп кергән

очракта, алар ислам мәдәнияте йогынтысына бирелгәннәр һәм берничә буын дәвамында болгарлашканнар һәм татарлашканнар.

Тел ягыннан классификацияләгәндә татар теле алтай телләре гаиләсенең төрки тармагына карый. Бу төркемгә тагы төрекләр, азәрбайҗаннар, башкортлар, үзбәкләр, казаклар, төрекмәннәр, кыргызлар, каракалпаклар, карачайлар, кумыклар, нугайлар, тывалар, хакаслар, якутлар, гагаузлар һәм кайбер башка халыклар керә. Ф. Фәсиев татар теленә иң якын тел дип башкорт телен билгели, бу телләрдә 85 процентка якын уртак төрки сүзләр булуын ачыклый.

Тулаем алганда, дөньядагы төрки халыклар саны 120 миллионнан артык. Татар теленең дәүләтара мөнәсәбәтләр теле буларак озын тарихы бар. Татарча рәсми дипломатия стиле Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында формалаша. Татар дәүләтчелеге таркалганнан соң да, XVI– XIX гасырларда татар теле Россия белән Кытай, Һиндстан, Төркия, Иран, Урта Азия һәм Кырым ханлыклары, Төньяк Кавказ кенәзлекләре белән сәяси аралашу теле булып хезмәт иткән.

Берләшкән Милләтләр Оешмасының тел комиссиясе татар телен дөньяның теләсә кайсы почмагында аңлашып була торган 14 телнең берсе дип игълан итте. Чыннан да, әйтик, төрек теле төрки телләр арасында иң күп таралганы булса да, ул гомумтөрки типтан ераграк тора, ә татар телендә тугандаш телләр белән уртак тамыр сүзләр проценты югарырак. Татар теле лексикасында Якын Көнчыгыш (гарәп-фарсы һәм, димәк, борынгы шумер һәм Мисыр) сүзләре, Европа, рус телләреннән алынмалар һәм Ерак Көнчыгыш, Кытай эзләре бар. Гарәп һәм фарсы алынмалары татар телендә гамәли лексиканың өчтән берен алып тора, Көнбатыш Европа һәм рус сүзләре исә 10–15 процент тәшкил итә. Соңгы вакытларда рус алынмаларын гарәп-фарсы сүзләре һәм гомумтөрки тамырлы сүзләр кысрыклавы сизелә. Бу процесс тагын да дәвам иткән очракта, уртаклык индексы югарырак булырга мөмкин, ләкин моның да чиге бар шикелле. Әмма яңа сүзләр уйлап чыгару белән мавыкмаска,

төрек теленең XX гасырда ясалма сүзләр хисабына сикерешле үзгәрүе аркасында килеп чыккан катлауылануларны булдырмау, өлкән буынның яшь буынны аңламый башлавын кисәтү чарасын күрергә һәм уртаклык индексын киметмәскә тырышырга кирәк, чөнки татар телен әлеге 14 тел исәбенә керткән күрсәткеч – нәкъ менә шушы уртаклык.

Төрек теле безгә, татарларга, ничек кенә якын тоелмасын, без бу телнең йогынтысын үз җилкәсендә татыган һәм, аның богауларын читкә алып ташлап, иркен татар теле мәйданына чыгарга йөрәге җиткән Габдулла Тукайның төрек теленә түбәндәгечә бәя биргәнлеген дә онытмаска тиешбез: «Бу персиян үзенең „сәнә, мәнә, сән үләсән, мән үләм, нәда-нишәрсәнә“ләренә, ягъни үз милли теленә бер кадак кишмиш кадәр генә ригаясе булса, төрекләрнең шушы чиркәнеч сонгый телләре белән „шигырь“ язмас һәм әүзане шигырьдән кишмиш үлчәме кадәр генә хәбәре булса, „якыйн, вә ашәфтә хун“ сүзләренең вәзендәш түгеллекләрен сизәр иде». Кыскасы, туган телебезне «сонгыйлыктан», ясалмалылыктан, корамалыктан сакларга кирәк.

*Татар ау эте* – Кострома ау эте. Көнчыгыш Европага татарлар алып килгән ау (эзәрлекләүче) этләренең иң саф токымы. А.П. Сабанеев рус аучыларының «бурзайлар белән киек эзәрлекләү сунарын, һичшиксез, татарлардан алган» булулары турында яза. Бу токым әсир төшкән татар кенәзләрен һәм морзаларын Ярославль, Кострома төбәгенә күчереп утырткannan соң тарала.

*Татар җоры* – җенес бизләреннән хуш исле матдә алына торган болан (кабарга). Бу атама Низамида очрый. *Татар җоры, ашап сөнбел чәчәкне, хуш исләр аңкытып йөрсә – гаҗәпме?* («Хөсрәү вә Ширин»нән).

*Татар календарь бәйрәмнәре.* Билгеле булганча, ел фасылларының мөһим мизгелләренә багышланган бәйрәмнәрне «календарь бәйрәмнәр» дип атау кабул ителгән. Бездә андый бәйрәмнәр дүртәү: 1) язгы көн-төн тигезләшү мизгеленә (21–23 мартлар), ягъни язгы сәвиягә туры килгән *Нәүруз бәйрәме;* 2) иң озын көннәргә (22– 25 июньнәр) туры килгән *җәйге нар-*

*дуган бәйрәме;* 3) иң кыска көннәргә (22– 25 декабрьләр) туры килгән *кышкы нардуган бәйрәме;* 4) көзге көн-төн тигезләшү мизгеленә (21– 23 сентябрьләр), ягъни көзге сәвиягә туры килгән *Сөмбелә бәйрәме.* Кара: *Җәйге һәм кышкы нардуган бәйрәме, Нәүруз* һәм *Сөмбелә бәйрәмнәре.*

*Татар кашык* – искергән сүз. Элек агач кашыкны шулай атаганнар.

*Татар ПЭН-үзәге* (ПЭН-центр) – Татарстан Республикасы язучыларының иҗтимагый оешмасы. 1995 елда төзелгән.

*Татар теле* – төрки телләрнең болгар-кыпчак төркеменә карый. Гомумән, *татар теле* борынгы кыпчак теле нигезендә формалашкан дип карала. Татар теле агглютинатив тел (яңа сүзләр һәм грамматик формалар сүзнең тамырына яки нигезенә, гадәттә, тотрыклы кушымчалар ялгану юлы белән ясала торган тел), аңа сингармонизм хас.

Болгар-кыпчак телләренә нисбәтән, Мәхмүд Кашгари (XI гасыр) фикере игътибарны җәлеп итә. Ул: «...кыйфкыз, кыйфчак, угуз, тухси, ягма, чигил, игърак, җарук телләре тик төркичәдер вә ямәк һәм башкорт телләре бу телләргә якындыр. Әмма рум якынындагы болгар, суар, бәҗәнәк телләре читләре кыскартылган кием кебек бер төркичәдер», – дип язган (тәрҗемәсе Л. Җәләйдән алынды, ихтимал, *читләре кыскартылган* сүзен «итәк-җиңнәре кыскартылган» дип алу отышлырактыр). Ф. Фәсиев *читләре кыскартылган* («мәхзуфәт-әлэтраф») сүзләрен кушымчаларны кыскартып, йотыбрак сөйләү дип аңлый.

*Татар* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда актив кулланыла: *Татар басуы* – Балтач районы Дорга авылы янындагы басу атамасы. *Татар башы* – Апас районы Акхуҗа авылының бер очы шулай атала. *Татар болыны* – Саба районы Иске Икшермә авылы янындагы болын атамасы. *Татар Ялтаны юлы* – Чистай районы Ишәле авылы янындагы юл атамасы. *Татар юлы* – Нурлат районы Кизләүле авылы янындагы юл атамасы. *Татар очы* – 1. Чүпрәле районы Зур Аксу, 2. Аксубай

районы Иске Татар Кармәте авылларындагы урамнар атамасы. *Татар урамы* – 1. Әлки районы Татар Әхмәте, 2. Әлки районы Чуваш Кичүе авылларындагы урам атамалары. *Татар чишмәсе* – Чистай районы Чуваш Ялтаны авылы янындагы чишмә (Кече Мишә елгасы бассейны).

*Татар* этнонимы белән авыл атамалары да күп ясалган. Түбәндәге авыл атамалары Г.Е. Корнилов хезмәтләреннән алынды:

«*Татар Баклауш* – д. т., 283, Пишнерь Баклауш, Казан ул., Новая Кишит, Татаркасинская волость: Большие Татаркасы (Татаркасинское общество), Кумур-касы (Татар касы) (Татаркасинское общество), Малые Татаркасы (Татаркасинское общество), Ямалкино (Татар-Касы) (Татаркасинское общество).

Татаркасинское общество, включает дд. Большие Татаркасы, Кумуркасы (Татар-касы), Малые Татаркасы, Ямолкино (Татар-касы), с. Большой Сундырь, Козмодемьян. у., Татаркасин в., 48–49.

Татар-касы – д. ч. 46, Кумур-Касы, входит в Татаркасинское общество, Козмодемьян у., Татаркасин. в., 49.

Татар-касы – д. ч. 51, Ямолкино, входит в Татаркасинское общество, Козмодемьян у., Татаркасин. в., 49.

Татаркасы: Большие, – входит в Татаркасинское общество, Козмодемьян у., Татаркасин. в, 48.

Татаркасы: Большие ~, – входит в Татарксинское общество, Козмодемьян у., Татаркасин. у, Татаркамин. в., 48.

Татаркасы: Малые ~, – входит в Татаркасинское общество, Козмодемьян у., Татаркасин. в., 48.

Татаро-Волчья ~д. т., 587. Чистоп у., Кутемин в., 219.

Татарская Айша – д. т., 145, Казан у., Чепчугов в., 219.

Татарская Багана – д. т., 1388, Чистоп. у., Муслумкин. в., 221.

Татар[ская] Икшурма – д. т., 1003, Мамадыш. у., Абдин. в., 75.

Татарская Омара – д. т, 1348, Уразбахтино, Мамадыш у.; Благовещенско-Омар. в., 86.

Татарская Похтала – с.т. 704, Спас. у., Гусихин. в., 109.

Татарская Тулба – д. т. 519. Мамадыш. у., Кляуш. в, 82.

Татарская: Айша ~, Казан. у., Мульмин в., 18.

Татарская: Вер[х]няя ~ Майна, Чистоп. у., Биляр. В, 212.

Татарская: Средня[я] [С]таро-[К]иреметь, Верхняя Киреметь, Чистоп. у., Аксубаев. в., 211.

Тат [арскiе] Агайбаши – д. т. 842, Лаишев. у. Саралов. в. 68.

Татарские Кирмени – д. т. 1199, Средние Кирмени, Мамадыш. у. Мало-Кирмен, в. 83.

Татарские Наратлеи – д. т. 378, Свияж. у., Азелеев в. 96.

Татарские Савруши – д. т. 670. Друж Савруши, Мамадыш. у., Елышев. в., 78.

Тат[арские] Саралы – д. т. 1398. Лаишев у., Саралов. в., 68.

Татарские Саркасы – д. т. 894, Чистоп. у., Изгар. В., 217.

Татарские Челны – д. т. 485, Средние Челны, Чистоп. у., Старо Челнин. в. 228.

Татарск[ие] – : Подлесные ~ Юрткули. Спас у., Юртк. в., 119.

Татарск[ие] – : Средние Юрткули, Вершины речки Нарабкуль, Спас. у., Ютку. в, 119.

Татарский Студенец – д. т. 1094, Спас. у., Алькеев в., 107.

Татарск[ий] Толкиш – д. т. 2888. Чистоп. у., Муслюмкин в., 221.

Татарский Янтык – д. т. 1235. Лаишев. у., Чирпов в., 72.

Тат[арсий] – : Ново-Адам, Чистоп. у., Ново-Адам. в., 222.

Татарский – : Средний ~ Толкиш, Токмакла, Чистоп. у., Каргалин. в., 218.

Тат[арский] – : Старо-Адам, Чистоп. у., Ново-Адам. в., 222.

Татарский: Урмат – Казан у., Мульсин. в. 20.

Татарско Ахметево – д. т. 1068, Спас у., Юхмачин. в., 120.

Татарско Танаево – д. т. 1293. Татарско-Мамадыш Тавельдино, Свияж. у., Азелеевская в., 96.

Татарское Алькино – д. т. 169, Чистоп. у., Изгар в., 217.

Татарское Бурнаево – д. т. 968, Спас. у., Кузнечихин в., 112.

Татарское Бурнашево – с. р. 871, Свияж.. у., Юматов в., 105.

Татарское Кадряково – д. т. 92, Бидарили, Казан. у., Ар. в., 2.

Татарское Макулово – д. т. 155. Свияж. у., Клянчинск. в., 98.

Татарское Мамат коз[ино] – д. р. 664, Свияж. у., Ташев в., 102.

Татарское Муллино – д. т. 620. Елшанка, Спас. у., Морасин. в., 113.

Татар[ское] Сунчелеево – д. т-ч. 1150. Чистоп. у., Старо-Мокшин в., 228.

Татарское Тенишево – д. р-т. 626, Малое Мереткозино, Тетюш. у., Богород в., 122.

Татарское Тюгульбаево – д. т. 1468. Спас. у., Кузнечихин в., 111.

Татарское Шапкино – д. т-ч. 435. Спас. у., Кузнечихин в., 111.

Татарское-Мамадышь-Тавельдино – д. т. 1293. Татарско-Танаево, Свияж. у., Азелеев в., 96.

Татар-Утяшкино – д. т. 1320, Чистоп. у., Ерыклин. в., 216.

Татарский [возможно Татарский] – д. т. 1344, Боль. Кукмор. Мамадыш у., Старо-Юмьин в., 91.

Толкиш: Средний Татарский ~, Токмакла, Чистоп. у., Каргалин. в., 218.

Толкиш: Татарск[ий] ~, Чистоп. у., Муслюмк. в., 221».

*Татар* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында да кулланыла. Марсель Галиевның «Чыдам тау да, үзән дә без...» исеме алган шигъри энҗеләрендә үткән тарихыбыз матур яктыртыла:

*Алтай-Саян бишегеннән калкып чыгып,*
*Кыйтгаларны иңләп таралганбыз.*
*Әле Скиф, Камәр, әле Сармат булып,*
*Төрле исемнәрдә танылганбыз.*

*Карабаир юргаларда җилеп кенә,*
*Тау-упкыннар аша ыргылганбыз.*
*Карпат диеп, Альп, Татр, Әтил, диеп,*
(Әтил – Атилла хөрмәтенә кушылган тау исеме).
*Кыяларга исем ыргытканбыз.*

*Ак түрекләр, Күк түрекләр булып, янә –*
*Чиксез Себер, Идел, уралдан без.*
*Бөркет кошлы каганатлар төзеп,*
*Ефәк юлын билгә ураганбыз.*

*Баллы, канлы язмыш... Күпме илләр төзеп,*
*Нигезенә мәрмәр таш булганбыз.*
*Җан-тән кушып, күпме кавемнәрнең*
*Үрчү кодрәтенә аш булганбыз.*

*Гасыр арты гасыр, меңьеллыклар кичкән*
*Төрле халык, диеп атамагыз!*
*Таргитайлы! Атиллалы, Кубрат ханлы халык –*
*Бер тамырдан, бер үк атадан без!*

*Ә соңрак... Кыпчак, нугай, казак булып,*
*Дала күкрәгендә таркалганбыз.*
*Колач җәеп, аерым-аерым үсәбез дип,*
*Киңәергә теләп, тар калганбыз.*

*Үзебезме теләп, и татарым, һаман*
*Соң чиккәчә җитеп, чигенәбез?*
*Кем ул әйтә: Олы тарих келәменә*
*Алтын язу белән чигелмәбез?!*

*Кайтавазлар иңри, юашланып:*
*Бүгеннән без бәлки... бөгелмәбез...*

***Тау.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *тау* сүзенең мәгънәсе шактый күп: 1. Җир өстенең һәр яктан текә биегәеп, күтәрелеп торган шактый зур урыны. *Тау башы. Тау итәге. Тау текәлеге. Тау белән тау бер түгел*. Мәкаль. *Биек тауның башы – якын, төбе – ерак* (күренә). Мәкаль. *Яратам мин үзебезнең авылны, бигрәк тә яратам авылның төньягын каплаган зур тауларны*. Г. Ибраһимов (ТТАС, III: 54).

*Тау* компоненты татар географик атамаларын ясауда күп кулланыла: *Тау асты чокыры* – Яшел Үзән районының Юынчы

авылы янында (Әрә елгасы бассейны), *Тау бавыры күле* – Буа районының Исән авылы янында (Олы Бола елгасы бассейны), Әлки районының Иске Чаллы авылы янында. *Тау башы ягы* дигән кыр атамасы бар. *Тау башы кизләве* – Апас районының Багыш авылы янында (Чирмешән елгасы бассейны), *Тау буе күле* – Балтач районының Иске Чепья авылы янында (Арбор/Урбар елгасы бассейны), *Тау ягы басу* – Яшел Үзән районының Карашәм авылы янындагы тау атамасы. *Айдар тавы* – Яшел Үзән районы Күгәй авылы янындагы тау атамасы. *Югары урман тавы* – Биектау районы Туктамыш авылы янындагы тау.

*Золный гура* – Спас районы Әҗмәр авылы янындагы тау атамасы. Анда ком да, кызыл балчык та көл төсендә булган. *Тракый тавы* – Мамадыш районы Баскан авылы янындагы тау. *Тугай тавы* – Лениногорск районы Кирлегәч авылы янында. *Тукмаклы тавы* – Мамадыш районы Колышчы авылы янындагы тау. *Туктар әле тавы* – Яшел Үзән районы Олы Карауҗа авылы янында. *Тукай тавы* – Апас районы Кошман авылы янында. *Турбай тавы* – Азнакай районы Кәкре Елга авылы янында. *Туры тау* – 1. Баулы районы Бәйрәкә, 2. Буа районы Карлы, 3. Мамадыш районы Югары Бүрсет авыллары янындагы таулар. *Туры тау елгасы* – Нурлат районы Яңа Әмзә авылы янындагы тау. *Тутам тавы* – Биектау районы Өлә Казаклары авылы янындагы тау. *Түбән алан тавы* – Әлмәт районы Яңа Кәшер авылы янында. *Түгәрәк тау* – 1. Әлки районы Иске Чаллы; 2. Арча районы Орнаш; 3. Чүпрәле районы Татар Шатрашасы; 4. Чүпрәле районы Түбән Чәке авыллары янындагы таулар. *Түкә тавы* – Апас районы Кызыл Тау авылы янында. *Түр төбәк тавы* – Нурлат районы Иске Әлмәт авылы янындагы тау атамасы. *Уба чишмәсе тавы* – Азнакай районы Мәлбагыш авылы янындагы тау атамасы. *Тырачы тавы* – Мөслим районы Сикия авылы янындагы тау атамасы. *Ужа тав*ы – Биектау районы Мәмдәл авылы янындагы тау атамасы. *Умарта тавы* – Сарман районы Дүсем авылы янындагы тау атамасы. *Уразман тавы* – Азнакай районы Үчәлле авылы янындагы тау атамасы.

Нурулла Гариф сүзлегендә *тау* сүзе болай ныгытылган: «Илантова Гора (Елантау) Казанның көнбатыш юнәлешендә, Казан елгасы янындагы тау».

Шунысы игътибарга лаек, Татарстанның Азнакай районында *Чатыр тау* атамасы бар. Кырымда *Чатыр даг* атамасы алган данлыклы тау күккә ашып утыра. Кырым татарлары угыз телле төрки халыклар төркеменә керә, шуңа күрә алар телендә сүз башындагы һәм сүз ахырындагы тартык авазлар яңгыраулашалар. Алар телендә башка аермалы үзенчәлекләр дә бар.

Төрки телләрдә топонимнар ясалышындагы сыйфатларның берсе шуннан гыйбарәт: күп очракта атамалар тезмәсендә сүзләрнең мәгънәсе үткән гасырларда ук, күптән урнашкан тормыш рәвешен, халыкның этнография, тел үзенчәлекләрен ачыклыйлар, сиздерәләр һәм күрсәтәләр.

*Тау* берәмлеге белән ясалган авыл атамалары да Татарстанда шактый: *Тау иле* – Түбән Кама районының Сосновка авыл җирлегендә, Яшел Үзән районының Күгәй авыл җирлегендә. Мамадыш районында *Тау Иле* авыл җирлеге бар, *Таулар* – Тукай районының Боерган авыл җирлегендә, Балык Бистәсе районының Шомарбаш авыл җирлегендә урнашканнар. *Таулы Дөреш* – Тукай районында Иске Дөреш авыл җирлегендә, *Таулык* – Тукай районының Теләнче-Тамак авыл җирлегендә урнашкан.

*Тау* компонентын үз эченә алган авыл атамалары Казан ханлыгы чорында ук булган: Җөри юлы өстендә, Норма елгасы бассейнында *Тау иле* (Ходящево); Арча юлы өстендә *Таузар,* Мишәнең югары агымында, Җөри юлы өстендә *Таутирмән* авылы (Чернышев, 1971: 288) һ. б.

*Тау* термины дастаннарда, легенда-риваятьләрдә һәм әдипләр иҗатында киң файдаланыла. Аны без «Идегәй» дастанында еш очратабыз:

*Тауда ятты тай бакты,*
*Кырда ятты куй бакты,*
*Елкы бакты – кол булды,*
*Өстендә ямар тун булды.*

*Тау* лексик берәмлеге элекке җыен атамаларында очрый.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, «июль аеның беренче декадасында, Кушкапка җыены үтүнең икенче атнасында, Сая (Сулы елгасы кушылдыгы) һәм Казансу елгасының уң кушылдыгы Сулы елгалары ярына урнашкан Төпйаз, Чыршы, Тарышна, Суксу, Кондырлы, Сая, Иске Өбрә, Абла, Зур Әлдермеш, Кече Әлдермеш авыллары халкы бергә җыелышып *Биктау/Биек тау* җыены үткәргәннәр. Җыен үткәрелә торган җирлектә XVI йөзнең беренче яртысына нисбәтле археология һәйкәлләре табылган (Археологическая, 1981: 45, № 128– 131).

Җыен атамасы, күрәсең, *Биктау* < *Биек тау* «Высокая гора» топонимыннан (торак пункт атамасыннан) барлыкка килгән. XVI гасырның уртасына кадәр җыен үзәге Казансу елгасының Түбән агымында, Биектау һәм Бимәр авыллары янында урнашкан булса кирәк. С.М. Шпилевский мәгълүматына караганда, Бимәр авылы янындагы тауда борынгы шәһәрлек эзләре калган. Халык телендә сакланып калган легенда-риваятьләрдәге мәгълүматлар җыен үткәргән халыкның Казансуның түбән агымыннан күчеп утыруын әле дә хәтерендә саклый. Зур Әлдермеш авылы халкы Дәрвишләр авылыннан (Дербышки бистәсе) күчеп килеп урнашкан».

*Кече Биктау җыены*. Бу җыен июнь башында яшьләр уены буларак үткәрелгән. Аны Гәреч (Галицкая дорога) юлы буена утырган авылларда үткәргәннәр.

Казансуның югары агымында – Кесмәс һәм Кече Мишә елгалары үзәнлегендәге җирләрдә үткәрелә торган җыеннарның берсе – *Казан тавы җыены* июньнең икенче декадасында, арыш чәчәк аткан вакытта Казансуның югары агымында урнашкан Иске Төрнәле, Кече Төрнәле, Чүк, Көтек, Көек, Казанбаш, Казиле, Күпербаш, Казанка авыллары халкы тарафыннан үткәрелгән.

Бу җыен үткәрелгән җирлектә XVI гасырга нисбәтле археологик һәйкәлләр табылган. Җыен атамасы үзенә исемне географик берәмлектән алган», – дип уйларга ярый.

Шулай ук аның мәгълүматлары буенча, «*Тау* уен җыены Апас районының Чүри-Бураш авылы янында май ахырында үткәрелгән. Авыл янында Үләмә елгасының уңъяк ярындагы биек борында (елгага очлаеп кергән коры җир) борынгы бабаларыбызның шәһәрлек һәм авыллык хәрабәләре билгеләнгән.

Җыенның *Тау* атамасы, күрәсең, шушы археологик истәлекләр белән бәйләнешледер. Шулай ук *тау* лексик берәмлеген борынгы төркиләрдә этноним булып әйләнештә йөргән һәм хәзер дә татар, төрекмән, үзбәк, кыргыз, каракалпак һәм тывалыларда очрый торган *тау* этнонимы белән бәйләргә мөмкин».

Адлер Тимергалин төзеп чыгарган «Миллият сүзлеге»ндә *тау* һәм аны аңлаткан башка терминнарга түбәндәге аңлатмалар бирелә:

«*Тау* – гомумтөрки – *тау, таг*. Кайбер төрки телләрдә – *даг*. Иделнең аръягын «Тау ягы» яки «Җәбәлстан» дип атаганнар (Җәбәл – тау, гарәпчәдән). // *Таг тачка кавушмас, кише кишигә кавушур*. Борынгы төркичәдән. *Тауга кычкырма, тавышың кире кайтыр»*. Мәкаль.

Тагын кара: *Таг*.

*Таг* борынгы форма – тау. Кайбер төрки телләрдә – даг. // *Аюдаг* – Аюдау (Кырымда), *Дагстанда* (Тау иле, Җәбәлстан)».

Тагын кара: *Даг; Җәбәл*.

*Даг I* төрки сүз. «Татарча әдәбиятта таг язылышы да очрый. // *Аюдаг. Боздаг* (бүздаг – соры тау).

*Җәбәл* гарәп алынмасы – тау, куһ (фарсы алынмасы). // Җәбәл әл-Кимәр – Камәр таулары (Комор таулары, Ай таулары – Африканың көнчыгыш ярларында). *Җәбәл Гарәфәт*– Мәккә янындагы Гарәфә тавы. Җәбәләте нур тавы / *Җәбәл ән-Нур* – бу таудагы Кира куышында Мөхәммәдкә беренче вәхи килгән. *Җәбәл Мусса*~Тур тавы, Библиядә – Синай тавы. *Җәбәл Рәхимәт* – Рәхимлек тавы (җәннәттәге биек тау).

Күплек шәкеле – җибал.

*Тау тишеге* – мәгарә, гар (гарәп теленнән алынма) тау кушыгы, кәһаф (гарәп). Борынгы чорда мәгарәләр торак булып

та, дошманнан качып сыена торган урын булып та, шулай ук мәетләрне күмү урыны булып та хезмәт иткән. Мәс., Авраам (Ибраһим пәйгамбәр) Ефрон дигән берәүдән Махиела мәгарәсен 400 сикель көмешкә сатып алган. Сара, аннары Ибраһим үзе, аннан соң Исхак һәм Ревекка, Лия һәм Йагкуб шул мәгарәдә җирләнгәннәр.

Тагын кара: *Мәгарә*.

*Тау төге* – асбест, тау йоны (җепселле минерал).

*Мәгарә* (гарәп) – гар (гарәп), тау тишеге, тау куышы (куышлыгы), кәһаф (гарәп). Башкорт якларында *тау өе, ташкуыш, мәмейрә* сүзләре очрый. Татарстанда Кама Тамагы районы территориясендә Иделнең уң як ярында урнашкан *Сөйке мәгарәсенең* озынлыгы 280 м, ә Юрьев мәгарәсе тагын да озынрак – 360 м. Алар гипс катламнары юылу аркасында барлыкка килгән. Кайбер төбәкләрдә, мәс., Сарман районы үзәге тавында ташландык бакыр базы – кеше кулы ясаган мәгарә бар. XX гасыр урталарында балалар кереп адашканнан соң, әлеге «баз»ның авызын томаларга мәҗбүр булганнар.

*Гар* (гарәп алынмасы) – «Мәгарә, тау тишеге, тау куышы. Гар шәриф – изге мәгарә, тау куышы. Г. Исхакыйда *гар тишеге* дигән сүз очрый.

Күплек саны шәкелләре – *әгъуар* һәм *гийран*.

*Әгъуар* (гарәп алынмасы) – «Гарның күплек саны шәкеле (*мәгарәләр*), тагын башкача – *гийран*.

*Гийран* (гарәп), тагын башкача – әгъуар.

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *Йөрмә таулар* гыйбарәсе кулланылган һәм ул болай аңлатылган: «*Йөрмә таулар* – дюналар (бу атама инкыйлабка кадәр „Мәдрәсәи Мөхәммәдия“нең уку программасында телгә алына».

*Тау* терминының географик атамаларда кулланылышы әдипләр иҗатында да күп очрый.

Гомәр ага Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» исемендәге повестының «Язгы сабан туйлары» бүлегендә Гыйбаш абзыйның игелекле гамәлләре сурәтләнә: *«Гыйбаш абзый, халык-*

*ка йөрергә якын да, җайлы да булсын дип, тау кырыйларын казып яңа юллар сала; кырын-ярын юлларны әледән-әле тигезләп тора, язын-көзен томалана башлаган чишмәләрне тазарта, «Мал эчерергә дә кирәк, урак өстендә үзебезгә дә су якын булыр», – дип, әллә кайлардагы басу түрләрендә яңа чишмәләр казый. Бу изге хезмәтләре өчен аңа рәхмәт яудыралар, ул салган яңа юлларны «Гыйбаш юлы» дип йөртәләр».*

Хәсән ага Туфанның «Узып барышлый» шигырендә *таулар* лексик берәмлеге кергән шигырь юллары сискәндерерә:

*Таулар, таулар...*
*Адәмнәрнең гомере*
*Сезнекеннән кыска бугай да,*
*Кеше булып җирдә яши алу,*
*Матур нәрсә үзе шулай да.*

Татар халык фольклор патриархы Нәкый ага Исәнбәт *тау* лексик берәмлеге белән *«Тау тауга бәрелмәсә, адәм адәмгә бәрелер»,* – дигән мәкаль тапкан.

Нәкый ага Исәнбәтнең «Син сазыңны уйнадың» шигырендә *тау* сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланыла.

*Кайгылы күңлем тавында*
*Яңгырады кылларың,*
*Яңрады ул моңлы кыллар...*
*Син сазыңны уйнадың.*

Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» исеме белән дөнья күргән романында Урал алдында һәм аның артында *тау* компоненты *тау* термины белән ясалган тау атамалары шактый күп кулланылган: *«Тауларның һәрберсенә халык үзенчә исем биргән. Очлытау – шуларның иң биеге. Заманында аннан бакыр чыгарганнар, аннан соң бу тирәләрдән җир мае сыгалар... Алыптауда исә тимер чыккан, халык аннан сугыш кораллары ясаган. Беләүлетаудан исә таш чыгарганнар, Зәйтугандагы күп корылмалар шул таштан салынган. Әнә бер-берләренә тоташып,*

*Бөркет һәм Туктартау, Ташкеләт һәм Җәйләү, Кырык чишмә таулары, Каратай сыртлары тезелеп киткән. Шунда ук халык печән әзерли, мал йөртә торган Баязит һәм Якуп тарлаулары».*

Башкортстанда яши торган татарлар телендә: *Уралтау, Курмантау, Кырыктау, Масимтау* һ. б. атамалар очрый.

Россия төбәкләрендә һәм БДБ илләрендә яши торган татарлар, төрки халыклар һәм төрки булмаган халыклар телендә дә *тау* сүзе кушылып ясалган атамалар шактый очрый.

Урта Идел буенда яши торган татарлар телендә *Сарытау* (Саратов), *Әүлия тавы, Жигули таулары* һ. б. бар.

Казакстанда *Тимертау, Күкчәтау* шәһәрләре; *Дыхтау* (балкар телендә *Тыхтау*) – зур Кавказ җирләгендәге иң биек тау башы. Бу атама *Дик-Даг* рәвешле кулланыла һәм текә кыя мәгънәсен аңлата. *Дагада* – Каспий диңгезендәге таулы утрау атамасы. Дагстанда *Тюзтау* һәм *Ярудаг* (Кызыл тау) атамалары бар. Кырымда *Ярудаг* тавы очрый. Төрекмәнстанда Кара-Бугаз култыгының көнчыгыш ягындагы текә яр *Кулагдаг-чинк* дип йөртелә. *Даг* компоненты белән ясалган атамалар Төркия һәм Иран дәүләтләрендә очрый. Себер, Урта һәм Үзәк Азиядә *Каратаг, Актаг, Куруктаг, Мазартаг* таулары бар. Үзәк Азиядә тагын бик зур *Алтынтаг* кабыргасы теркәлгән. Таулы Алтайда О.Т. Молчанова *Сарымсак-Туу* «Биек Саргылт тау» атамасы теркәгән. *Таулы Алтай* атамасы составында *тау, таулы* берәмлеге бар.

*Даг* термины Тывада очрый. Анда *Чинге-Даг, Оршаль-Даг, Диль-Даг* атамалары бар. *Даг бажы* – «тау башы», *даг кыры* «тау кабыргасы». Кырымдагы *Чатырдаг,* Татарстандагы *Чатыртау*, Актүбә өлкәсендәге *Шатырлы*, Тянь-Шаньдагы *Чатыр-Күль*, Чарджоу өлкәсендәге *Чатырдене* калкулыгы географик берәмлекләрнең, ягъни күлләрнең яр буйлары, кыяфәт һәм күренешләре, тауларның гөмбәз һәм чатырны хәтерләтүләре белән бәйләнешле. *Чатыр, чадыр, шатыр* сүзләре рус теленә төрки телләрдән кергән дип исәпләнә.

***Таш.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *таш* «металлардан башка һәртөрле каты минерал, тау токымы» дип бирел-

гән. Мисаллар да китерелгән. *Ак таш. Чуер таш. Кайрак таш. Таш карьеры, Ташны ташка чаксаң, уты беленер.* Мәкаль. *Мин таш ваттым, юлга таш түшәдем.* Ә. Ерикәй. *Тау өсләрендә өем-өем ташлар аунап ята. Безнең колхозда ул ташлардан матур-матур өйләр салалар.* А. Әхмәт (ТТАС, III: 56).

***Ташлы***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ташлы* – «Ташлары күп булган (урын, җир). *Ташлы юллардан менә бел үргә*! З. Мансур. *Бастым да мин ташлы текә ярга, Карап торам туган елгага.* Ә. Исхак. *Идел буе ашлыдыр, Ашлы түгел, ташлыдыр.* Җыр (ТТАС, III: 59).

***Ташлык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ташлык* «ташлары күп булган җир, урын» дип бирелгән. Мисаллар китерелгән: *Яхшы җир ятып калмас, ә ташлыкка чәчсәң ни дә, чәчмәсәң ни, барыбер шайтак таягы гына үсә.* И. Гази. *Монда җир вак ташлык булып, юл ул кадәрле үк бозылмаган.* А. Гыйләҗев. *Ташкент таулары ташлык, анда чәчмиләр ашлык.* Җыр. Бу мисалларда *ташлык* – исем. Түбәндәге мисалда *ташлык* сүзе сыйфат мәгънәсендә кулланыла. *Ташлык җиргә тары чәч.* Мәкаль (ТТАС, III: 59).

Таш компоненты «Идегәй» дастанында очрый:

> *Сарай дигән каласы,*
> *Сиксән күчә арасы,*
> *Сары мәрмәр Алтын Таш* (Сарай шәһәрендәге хан бистәсе)
> *Сигез йортка дан булды.*

Адлер Тимергалин «Миллият сүзлеге»нда *таш* лексик берәмлеге һәм аның белән бәйле сүзләргә аңлатмалар бирелгән.

*«Таш I* гомумтөрки *тал* сүзеннән. Чуваш телендә *таш* – *чул.* (Шуңа нигезләнеп, «Чаллы» атамасын «Ташлы» дип тә аңлаталар.) Р. Әхмәтьянов *ташлау* фигылен дә *таш* сүзеннән чыгара. Диалектта *ташаю* – ташка әйләнү. Сөйләм телендә кирпеч йортларны «таш йорт» дип атау күзәтелә. // *Ташаяк. Ташмаңгай. Ташбака. Акташ. Чуерташ. Ваккташ.*

*Керәч ташы* – известьташ. *Чакматаш. Пыялаташ* – слюда. *Катламташ* – сланец. *Кыяташ. Тегермән ташы. Мунча ташы. Янарташ* – ташкүмер (кайчагында метеорларны «янарташ» дип атау очрый). *Ташбилге. Каберташ (кабер ташы).*

Роберт Әхмәтҗановның бер шигырендә *таш елады* дигән сүзләргә тап булабыз. Мондый сурәтле сүз яңа түгел. Г. Тукайда «Исеркәп ушбу хәлне *кычкырып елый* хәҗәрләр дә» дигән сүзләргә тап булабыз (*хәҗәр* – таш). Гомумән, табигатьтә кыя ташларның чык белән каплануы, юешләнүе – гадәти хәл.

*Таш II тар.* – юл буена чакрым саен куелган ташка нисбәтән, ике таш арасы, ягъни бер чакрым.

*Таш атымы җир* – таш ыргытып була торган ара.

*Ташбака I тар.* – Борынгы элгәрләребез, теге дөньяда мәңгелек тормыш символы итеп, кабер өстенә ташбака сыны ясап куя торган булганнар. 1979 елда археологлар Кузнецкий Алатауның көнчыгыш тармакларында борынгы Себер халкы моннан 30 мең еллар элек ясаган шундый таш сынга юлыкканнар. Ташбака сыртына төшерелгән күк йөзенең йолдызлы картасында Зур Җидегән чүмечен, Тимерказык йолдызын һәм Кассиопея «урындыгы»н аермачык танып була.

Р. Әхмәтьянов борынгы кыпчак-куман телендә ташбаканың «чирәп бака» дип аталуы, русча *черепаха* сүзенең дә шуннан килеп чыгуы турында яза *(череп* сүзе дә куманча чирәптән). Кызганычка каршы, П.Я. Черных үзенең «Историко-этимологический словарь современного русского языка» исемле сүзлегендә (1994) бу версияне телгә алмый. Тагы шуны да әйтик: «Древнетюркский словарь»да *ташбака* сүзенең «мөгезбака» (мүңүзбака) дигән синонимы да теркәлгән.

*Ташбака II* – Урта гасырларда, кальга диварын җимерү өчен, гарәпләр файдаланган җайланма, таран.

*Ташбасмаханә* – литография.

*Ташбилге* – борынгыдан калган язулы (мәхкүкатлы, эпитафияле) таш, *тияк* (тийәк). Татарстанда *Ташбилге авылы* да бар // *Тарихтагы юллар буенда Ташбилгеләр, ядкарь каберләр.* Х. Туфан.

*Ташкаләм* – грифель.

*Ташкош* – татар халкының тынлы музыка коралы, таш сыбызгы. Күгәрчен, үрдәк, әтәч, кәккүк рәвешендә яндырылган кызыл яки ак балчыктан ясалган сыбызгыдан гыйбарәт. Аның 2–4 тишеге була, тавышы көчле, кискен тембрлы.

*Таштабан диал.* – табанча, тимераяк. Атама электә балаларның бозда аякларына таштабан бәйләп шууларына ишарәли. Чыннан да, иң борынгы «тимераяк»ларның сөяктән булуы мәгълүм. «Башкорт теленең диалектлары сүзлеге»ндә *таштабанга* яңарак аңлатма бирелә: «Табанына тимер куеп, агачтан эшләнгән коньки».

*Таш, ташлы, ташлык* лексик берәмлекләре әдипләр иҗатында һәрдаим кулланыла.

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында күңелгә ятышлы итеп *урман, болын* һәм *таш* терминнары кулланылган, экологиягә зур әһәмият бирелгән: *«Болай урманнарны бары утын гына итеп, болыннарны силос кына, «яшел масса» гына, тауларны җансыз таш кына итеп күрә башласак, кош-кортны да кырып бетерсәк, бу дөньяларның нинди яме калыр икән».*

Мөхәммәт ага Мәһдиев *ташны* болай кулланана: *«– Нәрсә бу?– дип сорыйм. Ул авыр сулый. – Нәрсә бу? Ташмы әллә?– дим, шаярып.*

*– Әйе, энем, таш, – ди. Аннан сөйли: – Су буена төштем. Аннан ике төрле таш алдым. Берсе катламлы таш, икенчесе чыпчык ташы. Бәлки, ул ташларга ата-бабалар баскандыр? Бәлки, сабый вакытта яланаяк аларга мин баскандырмын? Аннан урманга бардым. Нарат, чыршы күркәсе җыйдым. Аннан утын әрдәнәсеннән байтак әйбер җыйдым. Нарат, юкә, имән бүкәннәреннән берәр тәгәрмәч кисеп алдым. Ул авыр сулады.*

*– Ә безнең тегендә юк... Мин торган район үзәгендә, дим. Анда болар юк...»*

*Таш* сүзе топонимнар составында еш очрый: *Таш аланы* – Аксубай районы Иске Ибрай авылы янындагы алан. *Таш елга* – Апас районындагы Кече Күккүз авылының басу атамасы. *Таш*

*елга* – Катмыш елгасы кушылдыгы (Катмыш авылы, Мамадыш районы). *Таш буа елгасы* – Буа районының Иске Тинчәле авылы янында зур Тинчәле елгасына кушыла. *Өлә ташлавы* – Биектау районы Өлә Казаклары авылы янындагы урын атамасы. *Таш елгасы* – Апас районының Югары Ындырчы авылы янында Бийә суына кушыла. *Таш елга басуы* – Тәтеш районының Келәш авылындагы басу атамасы. *Битек таш* – Яшел Үзән районы Татар Танае авылы янындагы таш атамасы. *Ташлы болын* – 1. Яшел Үзән районы Синтәк, 2. Арча районы Югары Сәрдә авыллары янындагы болын атамалары. *Ташкичү сазлыгы* – Баулы районы Мортаза авылы янындагы сазлык. *Ташлы үзән елгасы* – Алан Сырнасы елгасы бассейнында, Арча районы Мөрәле авылы янындагы елга; *Ташлы чокыр* – Баулы районы Салих авылы янындагы коры чокыр атамасы; *Ташлык чокыры* – Кайбыч районы Салтыган авылы янынан ага торган Ышланды суы кушылдыгы һ. б.

*Таш* компоненты белән ясалган авыл атамалары Казан ханлыгы чорында да булган. Нугай юлы өстендәге *Ташкирмән,* Тау ягындагы *Ташкабак* (Ташевка) авыллары ул чорда гөрләп яшәгәннәр.

*Таш, ташлы* лексик берәмлекләре белән авыл атамалары да байтак очрый. Татарстанда: *Ташбилге* (Әлки районы), *Ташкабак* (Югары Ослан), *Ташкирмән* (Лаеш районы), Т*ашкич, Ташкичү* (Арча районы), *Ташкичү* (Тукай районы), *Ташкичү* (Буа районы Бик-Үти авыл советына карый), *Ташкичү* (Буа районы Тимбай авыл советына карый), *Таш-кичү* (Ютазы районы), *Ташлы* (Әгерҗе, Баулы, Мамадыш районнары), *Ташлы елга* (Кукмара районы), *Ташлы Кавал* (Биектау районы), *Ташлык* (Түбән Кама районы), *Ташлыяр* (Мөслим районы), Ташлыяр (Теләче районы), *Ташсу* (Биектау районы), *Ташчишмә* (Әтнә районы), *Ташъелга* (Мөслим районы), *Торнаташ* (Тукай районы), *Ике басу Арташ* (Саба районы), *Олы Арташ* (Мамадыш, Саба районнарында).

Чуваш галимнәре җыеп чыгарган хезмәттә *таш* компоненты белән түбәндәге атамалар бирелгән.

«Ташевка – с. р. 397, Свияж. у., Ташев. в. 101.

Ташевская волость, включает: Гребени, Ключищи (с), Матюшина, Николаевская Слобода (Ежевка), Новое Маматкозино, Сиетово (с), Старое Маматкоз(ино) (2 общ.), Татарское Маматкоз[ино], Ташевка (с), Шаланга (с), Свияж. у.101– 102.

Ташкил – д. чр.,129, Чедра Сола, Царевококшай у., Себе-Усад в. 156.

Ташкирмен <Ташкирмель> д, ст. кр. т., 1221, Лаишев.у. Саралов в., 67.

Ташкич – д. т. 348, Мамадыш. у., Ново-Чурилгин. в., 86.

Ташкич – д. т. 815, Кудайгулово, Казан. у., Мамсин. в., 18.

Ташла Илга – д. т. 7688, Мамадыш. у., Кляуш. в., 82.

Ташла Илга – д. т. 464, Мартыновка, Мамадыш. у., Сатыш. в., 88.

Ташлинур – д. т. 602, Старач Шора, Казан. у., Мамсин. в., 17.

Ташлияр – д. р. 567, Мамадыш. у., Абдинск. в., 75.

Ташлык – д. т. 320, Кук Чешма, Мамадыш. у., Шеморбаш. в., 92.

Ташнур – д. чр. 29, Царевококш. у., Моркин. в., 148.

– Ташнур: Второй ~ Царевококшай. у., Больше-Шигапов. в., 141.

– Ташнур: Первый ~ Царевококшай. у., Больше-Шигапов. в., 141».

Төрки телле халыклар яшәгән төбәкләрдә һәм республикаларда да *таш* компоненты белән шактый күп географик атамалар очрый.

Алтай, шор, хакас телләрендә *таш,* татар телендә дә *таш* «камень». Хакас, алтай телләре диалектларында *тас* шул ук мәгънәдә. *Таш* терминыатамалары ясауда кулланыла. Мәсәлән, *Акташ, Акташ руднигы*. Тывалылар телендә «таш» мәгънәсендә *даш* лексик берәмлеге йөри.

*Чатыр таш* – Памирдагы Аличур үзәнендә урнашкан. Кырым топонимиясендә *таш* компоненты белән атамалар күп кулланыла. *Бака-Таш, Бока-Таш, Теке-Таш, Текме-Таш, Эски-*

*Таш, Эки-Таш, Койташ, Акташ, Таракташ, Биюк-Таракташ, Кок-Таш, Кызыл-Таш, Иман-Таш, Яман-Таш, Сююр-Таш, Боташ* һ. б.

Кыргыз топонимиясендә *таш* лексик берәмлеге белән күп атамалар ясалган: *Ак-Таш таулары* – Алай кабыргасы, Ош өлкәсе Алай районында; *Ак-Таш тау* – Фирганә кабыргасы, Ош өлкәсе Сузак районы; *Ак-Ташы тау* – Кара Джерго кабыргасы, Нарын өлкәсе Кочкор районында. *Беш-Таш* атамалы күл *Беш-Таш* елгасының югары агымында. Талас өлкәсенең Талас районында шундый ук исем тау сыртын кечү урыны очрый. Шунда ук *Беш-Таш* атамасы алган елга бар, ул – Озын Акмат елгасының сул кушылдыгы.

***Ташу.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ташу* сүзенең ике мәгънәсе бирелгән. 1) Бик артык, күбәеп яки, кайнаудан кабарып, агым юлыннан яисә савыт стеналарыннан читкә чыгу, читкә агу (сыеклыклар турында). *Сулар артып, ташып чыкты ярларыннан* (Г. Тукай); 2) Ташкын күренеше. *Тик язгы ташудан соң бөтенләй үк тынарга өлгермәгән елга суы гына тиз-тиз алга йөгерә.* С. Җәлал. *Буа яңгыр ташуына гына бирешерлек түгел иде.* Г. Бакиров (ТТАС, III: 59–60).

***Ташкын.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ташкын* – «ташу күренеше, үзәннәрне һәм иңкүлекләрне басып киткән көчле су агымы». *Ташкынның комы калыр, Кайгының моңы калыр.* (Мәкаль). Ташкын сүзенең тагын бер мәгънәсе – «ярлардан ташып чыккан; бик күп булып су ага торган». *Бу тарлавыкта гаять зур ташларны тәгәрәтеп, шаулап ташкын су ага.* А. Шамов (ТТАС, III: 57– 60).

«Идегәй» дастанында да *ташкын* сүзе бар.

*...Арыдан торып Идегәй,*
*Норадынга тулган аны әйтте:*
*– Җиде кичә беренсә,*
*Җир ялгышмас, морза углым!*
*Җиде дәрья кушылып,*
*Котырынып ташканда,*

*Җил каектай умравын*
*Җилгә биреп ашканда,*
*Ташкын тирән дәрьяны*
*Болыттай үткән морза углым!*
(Идегәй, 1988: 230).

*Ташкын* термины Дәрдемәнд шигырендә бик матур кулланылган:

*Кырны, тугайларны алды язгы сулар ташкыны,*
*Кем, чәчеп нурлар шифалы, йөргезеп җил, килде яз.*
Дәрдемәнд.

Гомәр ага Бәшировның «Язгы сабан туйлары» исемле повестенда *ташу, су* сүзләре матур итеп кулланыла: *«Шул кичтән башлап авыл тынлыгына яңа аваз өстәлә: ташу авазлары. Иртән торып чыгасың – шаулый төнен тыңлыйсың – шаулый. Китә шуннан салам яндырып ут көймәләре агызулар, китә су буенда чыр-чу килеп сикерешү, шаярышулар».*

*Ташкын, ташу* сүзләренең сөйләшләрдә түбәндәге тәрдәшләре очрый: Зәй керәшеннәре телендә – *күч,* кузнецки сөйләшендә – *жажура,* Мәләкәс төбәгендә – *палуй,* Төмән татарлары сөйләшендә – *йәйү.*

Төрки телләрнең күбесендә *ташкын* түбәндәгечә кулланыла. Хакас телендә – *тасхын, суғ тасханы;* үзбәк – *тошқин сув, дарье тошқини;* кыргыз – *суу ташкыны, кирген суу;* казак – *су тасу, тасқын су*; каракалпак – *суў тасқыны, тасыў алыў;* карачай-балкарларда – *суу къобуу;* кумык телендә – *су ташыв, ташгъын* һ. б.

*Сил*. Ташкын сүзенең бер төрдәше – *сил*. Бу сүз «Татар теленен аңлатмалы сүзлеге»ндә: «Таулы җирдә көчле яңгыр яки кар эрү сәбәпле барлыкка килә торган хәтәр ташкын» дип бирелгән. *Сил төшү. Силнең көтүләрне, тирмәләрне агызып алып китүе. Яңгыр силе, кар силе* (ТТАС, II: 650).

*Сил* лексик компоненты язучылар һәм шагыйрьләр иҗатында шактый еш очрый.

Дәрдемәнд иҗатында мондый юллар бар: *«И, Җаек! Син кай илләрнең күз яше, нинди хәсрәт силләренең юлдашысың!..»* (бу очракта *сил* күчерелмә мәгънәдә кулланылган).

*Бозлы яңгыр, сил дип әйтерлек көчле ташкынның китергән зыянын ул көнне генә бәрәү дә әйтә алмады* (Нур Әхмәдиев).

*Фатыйх бабай ярда, нәкъ су кырыена утырды. Үзенең, үткән тормышын Агыйделнең шушы болганчык агымы, силнең бер-берләренең өсләренә менүче ак-соры карлы боз кисәкләре белән чагыштырды. Шушы үлемнәр белән тулы һәм серле егерменче гасырда аның тормышы да болганчык агым булып үтте. Силнең аклары күбрәк бугай, ә аның тормышында сорысы күбрәк урын алып тора* (Ягъсүф Шафыйков).

«Миллият сүзлеге»ндә *сил* болай аңлатыла: «Тау елгаларында кыска вакытлы ташу, ташкын, сыйа. «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә *сәел* язылышы да теркәлгән. Бу сүз рус теленә *сель* рәвешендә кергән, һәм, гадәттә, бүгенге татарча чыганакларда русча язылыш кабатлана // *Сил тик агар күздин яше.*

Күплек саны шәкеле – *сөюл»*.

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *сель* «ургылып аккан ташкын сулары, ярсулы, бик көчле, ләм һәм таш катнашмасыннан торган кыска вакытлы, тауларда коеп яуган яңгырлардан соң барлыкка килгән агым». Бу пычрак агым чокырлар һәм үзәннәрдән ага. Үзе белән ул күп каты әйберләр агыза, су басулар ясый һәм җимерә, халыкка күп зыян сала. Бу лексик берәмлек күп төрки телләрдә *сель, силь, сел* төрдәш-вариантларында очрый. Төп чыганагы гарәп телендә «ярларыннан чыгып аккан көчле агым»ны аңлата. Бу лексик берәмлек рус телендәге фәнни әдәбиятта да шактый күп очрый. Ул Таҗикстан географик атамалары составында да очрый: *Сельдара* елгасы; Азәрбайҗанда *Сельчай* һәм *Сельбасан* елгалары; Иранда *Абсель* атамасы алган торак пункт бар.

***Тегермән***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем» дип бирелгән: «Бөртекле ашлыкларны ярма яки он итеп тарттыру өчен корылган җайланма (машина) – төп

өлеше бер-берсенә ышкылып әйләнә торган ике көпчәктән – таштан тора. *Нинди тегермән диген әле [безнең тегермән]? Су тегермәне дә, күрше авылныкы кебек, җил тегермәне дә түгел, пар тегермәне*! Г. Бакиров. *Киң буа өстендә шаулап Тегермән тартып тора. Оннарның яхшы сортлысы Артканнан артып тора*. Г. Латыйп. // Нәрсәне дә булса, ваклый, изә, төя торган төрле машиналар. *Сөяк төю тегермәне. Ит тегермәне*» (ТТАС, III: 64).

*Тегермән буасы* – суны тегермән чарыкларын әйләндерерлек биеклеккә күтәрү өчен буып куелган урын. *Тегермән буасында, эри башлаган яшел боз өстендә, дәрт кергән ана казлар каңгылдаша булыр*. И. Гази (ТТАС, III: 64–65).

*Тегермән* сүзе топонимнар ясауда актив кулланыла: *Тегермән арты* – Балтач районының Кариле авылы янында; *Тегермән дугае* – Арча районының Иске Кырлай, Балтач районының Смәел авыллары янындагы тугайлар атамасы; *Тегермән юлы* – Апас районының Дүртөйле авылы янында; *Тегермән колагы* – Актаныш районының Иске Байсар авылы янындагы алан атамасы; *Тегермән сазы* – Алексеев районының Олы Кернәле авылы янында; *Тегермән чокыры* – Буа районының Бикмураз авылы янында элек тегермән булган урын; *Тегермән үре* – Балтач районының Яңгул авылы янында үр атамасы. *Түбән Тегермән* – Балтач районы Смәел авылындагы урын (тегермәннәр, белгәнебезчә, элек һәр авыл янында булган. Бу очракта атама болынны белдерә). *Түбән тегермән дугае* – Балтач районы Смәел авылы янындагы дугай/тугай атамасы. *Матаука тегермәне* – Лениногорск районы Сугышлы авылы янындагы тегермән атамасы. (Белгәнебезчә, элек һәр авыл янында тегермән булган. Кызганыч, хәзер алар юк.)

*Тукмак тегермәне* – 1. Саба районы Елыш, 2. Теләче районы Казаклар авылларындагы тегермәннәр атамасы.

*Тегермән* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында еш кулланыла. Гомәр ага Бәшировның «Сандугачны кем үтергән?» хезмәтендә *тегермән* турында мондый сүзләр бар: *«Аргы якның ын-*

*дыр артында, басуның иң биек урынында, канатлары белән җилпенеп, иске җил тегермәне утыра. Аның гөр-гөр килүе, әллә кай төшләренең шыгырдавы басу капкасыннан чыккач ук ишетелә башлый. Якынрак барган саен бу гөрелте көчәя, бара торгач, тегермән алдындагы бүкәндә утырган Хәйрулла абзыйның үзен дә күрәсең.*

*Ул елларда әкият бик күп тыңлагангамы, ничекме, кайчакларны миңа бу тегермән ниндидер әкияттән төшеп калгандыр кебек тоела иде. Артларыннан дию пәрие куып килүен белгәч, диюдән качып өенә кайтып баручы патша кызы, әфсен укып, үзе тегермән булган, аны коткаручы батыр егетне тегермәнче иткән бит. Моның чынлыгына шулкадәр ышанасым килә, зәңгәр күктә зыр-зыр әйләнгән тегермән канатларына күземне тутырып-тутырып карыйм. Тегермән шундый гөрелди, аның канатлары шундый сызгыра, әгәр дә ул тагын да җәһәтрәк әйләнә башласа, мөгаен, җирдән бөтенләй аерылып очып китәдер...»*

... Гомәр ага Бәширов «Туган ягым – яшел бишек» повестының «Җирән кашка сагышы» дип исем куелган беренче бүлегендә *тегермән буасы* турында мондый сүзләр яза: *«Мин инде киләсе елга, колын тайдан кырыкмышка чыккач, аңа атланып Убырышный (алпавытларга түләнә торган оброк сүзеннән килеп чыккан булса кирәк) һәм Мунчалка дигән урман аланнарына ат ашатырга йөрүләр, анда барганда малайлар белән узышулар, җәйнең эссе көннәрендә зират астындагы тегермән буасында аны коендырып кайтулар турында да хыяллана башлаган идем».*

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында да *тегермән буасы* гыйбарәсе кулланыла: *«Гайнан су буена төшкәндә, этисе Харис алып килгән бульдозерчылар тегермән буасы янында Минһаҗ карт белән киңәш коралар иде. Алар янына Идрис тә килеп туктады».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» дип аталган повестыннан мондый юллар укыйбыз: *«Тегермәнгә якынлашасың... Леперdäп утырган ике катлы тегермән йортына*

*киләсең, арбаңны агач күпердән дәңгердәтеп тартып өскә алып менәсең».*

Нурислам Хәсәновның «Сагыш» исеме алган китабына урнаштырылган «Тәкъдир» повестенда *Тегермән тавы* атамасы кулланылган: *«Кояш, олы бер алтын тәңкәдәй, Тегермән тавы артына тәгәри».*

***Тоба, туба***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу термин «исем» дип ныгытылган һәм аның ике мәгънәсе бирелгән: 1. Елга, күл һ. б. сулыкларда бик тирән урын, упкын, чоңгыл. *Минем урында башка берәү булса, әллә кайчан үлгән, яисә тобага ташланган булыр иде*. А. Шамов. *Ата-анасы белә микән, Балалары төшә тобага*. Җыр. // Сыйфат мәгънәсе. *Ваем төбе тоба су, батарсың да китәрсең, Тәвәккәллек – көймәдер, ишәрсең дә китәрсең*. Мәкаль; 2. Елганың киңәеп һәм тирәнәеп, күл сыман булып торган урыны (бу мәгънәсе аның диалекталь төрдәш (вариант) буларак бирелгән) (ТТАС, III: 111).

*Тобалы*. Лексик берәмлекнең сыйфат мәгънәсе болай аңлатылган: «Үз агымында тоба *(2 нче мәгънәсе)* яки тобалар хасил иткән, тобалары күп булган. *Иж сулары тирән, бик тобалы. Әйләнәсе аның тал-тирәк*. Т. Гыйззәт (ТТАС, III: 111).

«Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә (Казан, 2009) *тоба* терминының дүрт мәгънәсе бирелгән:

*Беренче мәгънәсе*. Мәләкәс, сергач, чистай, тархан, тау ягы керәшеннәре телендә – «упкын, суның тирән җире».

*Икенче мәгънәсе*. Пермь сөйләшендә – «текә ярлы сазламык елга урыны».

*Өченче мәгънәсе*. Шул ук пермь сөйләшендә – «текә ярлы, тирән, суы акмый торган күл».

*Дүртенче мәгънәсе*. Минзәлә, эстәрле сөйләшләрендә – «елганың тирән, киң һәм тынычрак аккан урыны» (ТТЗДС, 2009: 636).

Татар топонимиясендә *тоба* термины гидронимик атама буларак шактый кулланыла: *Тоба күле* – Ата елгасы бассейнында (Әлки районы); *Сафура тобасы* – Ык суындагы урын; *Тоба башы* – Зөя бассейнындагы күл; *Тоба суы* – Әгерҗе районында

Иж елгасы кушылдыгы; *Тоба күле* – Яшел Үзән районындагы Әрә бассейнындагы күл. Минзәлә районының Бикбау авылында *Мутау тобасы*, *Мутау тобасы тармаклары*, *Олы тоба күле, Олы тоба күле тармаклары, Мутау тобасы атавы, Тоба атавы чишмәсе, Тоба буе шобагасы, Тоба тамаклары, Тоба урманы* атамалары бар. *Арттагы тоба* – Буа районы Зур Кырлангы авылындагы печәнлек җир шулай атала. *Әйләнмә тоба күле* – Әлки районының Чуаш Кичүе авылында.

*Тоба* компоненты авыл атамалары булып та кулланыла: *Тоба* – Түбән Кама районында урнашкан Каенлы, Әгерҗе районындагы Тирсә авыл җирлекләрендәге авыллар. Кама Тамагы районында урнашкан Кирельски атамасы алган авыл җирлеген халык *Тоба* дип йөртә. *Шәмси тобасы* – Яңа Чишмә районы Зирекле авылы янындагы урын атамасы. *Урта тоба* – Буа районы Зур Кырлангы авылы янындагы печәнлек атамасы. *Алдагы тоба* – Буа районы Зур Кырлангы авылы янындагы печәнлек атамы. *Аеры тоба аланы* – Баулы районы Исергәп авылы янындагы алан атамасы. *Тоба атау* – Буа районы Бик-Үти авылы янында Олы Бола елгасының тирән урыны. *Төпсез дыба* – Зөя елгасы бассейнында, Буа районының Адав-Толымбай авылы янындагы сулык, тирән урын.

*Туба, тоба* термины төрки телләрдә «ермак, елганың түбән агымы» мәгънәсендә дә кулланыла: *Туба* елгасы Енисейның уң кушылдыгы; Иделнең түбән агымында *Актүбә* (русча Актуба) елгасы бар. Аның ярында *Актүбә* шәһәре урнашкан.

Башкортстан җирлегендә: Дүртиле районындагы Иске Баиш һәм Уфа районының Зубово авылларында *Тоба-күл* атамасы, Балтач районының Тушкыр авылында *Иртыштоба* атамасы бар.

Татар теленең керәшен татарлары, мәләкәс, сергач, чүпрәле, чистай, Тау ягы, тархан шивәләрендә *тоба* – «упкын, суның тирән җире», гәйнә сөйләшендә – «текә ярлы, сазламык елга урыны», «текә ярлы, тирән күл». Пермь татарлары сөйләмендә *тоба* – «текә ярлы сазламык елга урыны» (ТТДС, 1969: 416). Башкорт теле сөйләшләрендә бу сүз «упкын, елга колагы»

мәгънәсенә ия. Мари телендә шул ук мәгънәдә *тавә* сүзе йөри. А.Х. Ишбулатов *тоба* сүзен башкорт һәм фин-угор телләрендәге лексик параллельләр арасында карый (Ишбулатов, 1970: 23). Мордва телендә *дуба* – «тирән урын», казак диалектларында *тымо* – «тар култык».

Каракалпакстанда *Туба* исеме алган торак пункт, Красноярск краенда *Туба, Тубинский* торак пунктлары бар. Алтай телендәге *туба* – «чоңгыл», грузин теле сөйләшләрендәге *тба, това, тобо* «күл», «тирән (су)» төшенчәсендә кулланыла. Грузиядә һәм Дагстанда *тба~тоба* берәмлекләре белән түбәндәге су чыганаклары атамалары очрый: Боржоми шәһәреннән көньяк-көнчыгыш юнәлештә *Табацкури* күле, Бакуриани янында *Кихисостба* һәм *Цирестба* күлләре, Дагстанда *Гогилантба* күле теркәлгән (Мурзаев, 1984: 547– 548).

***Томшык*** термины «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бар. Аның ике мәгънәсе теркәлгән. *Беренчесе* «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай аңлатылган: «Кош авызының мөгез матдәле, очлаеп торган алгы өлеше, борыны». [*Акчарлаклар] кинәт суга ташланып, корбаннарын томшыкларына эләктереп алып, тизлек белән яңадан һавага күтәреләләр*. А. Шамов. *Чыпчык... томшыгын ике яклап тактага кайрап ала*. Ә. Фәйзи. *Тукран агач тукылдата: тук-тук-тук. Минем томшыктан нык томшык юк, юк, юк*. Н. Арсланов. *Икенче мәгънәсе* сүзлектә «тупас мәгънә» дип ныгытылган һәм аңлатмасы болай: «Йөз, бит, борын, танау». *[Кемнең дә булса] томшыгына тондыру*.

*Томшык борын* – аска яки өскә кәкрәйгән очлы борын. *Калтайның ... буе тәбәнәк, йөзе шадра, борыны томшык.* Г. Ибраһимов (ТТАС, III: 116).

Татар топонимиясендә *борын* сүзенә параллель рәвештә кулланыла торган хайван һәм кош гәүдәсенең бер әгъзасы – *танау, томшык* сүзләре шулай ук микротопонимнар ясауда шактый актив катнашалар. *Томшык басуы* (бу басу хәзер инде беткән Селәнгер авылы янында иде, элекке Дөбьяз, хәзерге Биектау районы).

Казак, каракалпак, кыргыз, алтай, тыва, якут телләрендә *борынның* оронимиягә караган мәгънәсен белдерү өчен, *тумсык, тумчук, думчук, томшук, томсук, тумул* терминнары кулланыла. Аларның килеп чыгышын Р. Әхмәтьянов гомумтөрки телдәге *тум* «калкып чыгып торган нәрсә» сүзенә бәйләп аңлата.

Термин һәм атама буларак *томшык* сүзенең кулланылыш дәрәҗәсе барлык халыкларда да бер төрле түгел. Алтай топонимиясендә ул термин булып кына йөри (Молчанова, 1973: 63).

*Томшык,* борын, кош борыны мәгънәләре белән беррәттән, географик атамаларда диңгезгә, күлгә яки елгага очлаеп кергән коры җирне, кырларның урманга очлаеп кергән урыннарын, тау тармагын, кыя, кыяташны да аңлата. Борынгы төрки телдә *tumšuq* «томшык», «кош борыны», «хортум» (фил хортумы) мәгънәләре бар. Татар телендә «томшык, бит, танау» мәгънәләре белән югарыда күрсәтелгән географик мәгънәләре дә өстәлә; башкортларда – *томшок*, тыва телендә – *думчук*, уйгыр, кыргыз, үзбәк телләрендә – *тумшук*, алтайлыларда – *тумчук*, якутларда – *тумус*, хакас телендә *тумзук* терминнары теркәлгән. Төрки географик терминологиядә анатомик терминнарга нисбәтле түбәндәге атамалар бар: *Тумус, Тумустаг* таулары, Саха-Якутиядәге Олекма тауларында *Тумуллур* бусагасы, Таҗикстанның көньяк өлешендә *Кызылтумшук* калкулыгы, Устюртта *Аксумтук* калкулыгы, Сәмарканд өлкәсендә *Тумшук* калкулыгы, Тарим исемендәге батынкы урында (Кытай) ага торган Аксу елгасында *Тумсук* исеме алган калку урын күрсәтелгән. Казак топонимиясендә *Кебиртумсык* – тозлы борын, чыгынты (Конкашпаев, 1963: 66).

***Тугай***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *тугай* термины «исем» дип ныгытылган һәм аның *беренче мәгънәсе*: «Елга ташыганда су баса торган болын (гадәттә дуга сыман ярымутрау кебек була)». *Елганың бер ягы – зур һәм карт урманлы биек таулар, икенчесе – яшел үләннәр, ал-гөл чәчәкләр белән түшәлгән зур, киң тугай*. Г. Ибраһимов. *Тыныч сулыш алган киң тугай йомшак үлән белән капланган*. Ф. Кәрим.

*Икенче мәгънәсе*: «Елганың дуга сыман бормалы урыны». *Тиз генә чишенеп, суга сикердем һәм... тугайны иңләп йөзә башладым*. Сов. әд. *Борылып аккан су буйларын тугай диләр, Төркстанда татарларга нугай диләр*. Шура.

***Тугайлану.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу термин «фигыль» дип ныгытылган һәм мәгънәсе дә аңлатылган: «Дуга шикеллерәк бормалану». *Барыбыз да урман эченнән тугайланыбрак киткән юлга карап куйдык*. Ф. Булатов (ТТАС, III: 145).

***Тугайлы***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу термин «сыйфат» дип ныгытылган һәм ике мәгънәсе бирелгән. *Беренче мәгънәсе*: «Тугае булган, тугае бар—. *Украина иле тугайлы. Тугайлары озын курайлы*. М. Җәлил. *Кайда урын аның күңеленә якынрак: биш ел буе кайнашкан плотинамы, әллә шушы тын тугайлы елга буемы?* А. Гыйләҗев.

*Икенче мәгънәсе*: «Бормалы, тугай-тугай». *Тугайлы су буйлары* (ТТАС, III: 145).

***Тугайлык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем» дип бирелгән һәм ике мәгънәсе аңлатылган: 1. Елга үзәнлеге; болынлык. *Тигез тугайлык... тау белән елга арасында яткан тар гына бер мәйдан булганлыктан, ул елдан-ел да буш кала*. Ә. Еники. *Гөбенә суы буы тугайлыкларында түгәрәк күлләргә сикереп төшеп, су чәчрәтә-чәчрәтә йөзеп, чумып йөргән чаклар* [искә төшә]. З. Бәшири; 2. Елганың дуга сыман бормалы урыны (ТТАС, III: 145).

***Тугай-тугай***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу гыйбарә «сыйфат» дип бирелгән һәм мәгънәсе аңлатылган: «Бормалы-бормалы, дуга сыман (елга турында)». *Идел буе тугай-тугай, Тугай саен бер тургай*. Җыр. // Рәвеш мәгънәсе. Бормалы-бормалы булып. Балыкчының урамы Тугай-тугай әйләнгән. Бәет (ТТАС, III: 145).

Татар географик атамалары составында *тугай, тугайлы, тугайлык, тугай-тугай* компоненты белән түбәндәге географик берәмлек атамалары очрый: Лениногорск районының Кирлегәч авылы һәм Әтнә районының Олы Әтнә авылы янында *Тугай*

*болыны* атамасы бар. *Тугай елгасы* – Балтач районының Смәел авылы янынннан агып үтә торган Шушма елгасы бассейнында. *Тугай тавы* – Лениногорск районының Кирлегәч авылы янында. *Тугай чишмәсе* – Арча районының Ташкич авылы янында (Кесмәс елгасы бассейны). *Кече Тугай* – Әтнә районы Әйшияз авылы янындагы тугай атамасы. *Вахит тугае* – Азнакай районы Сарлы авылы янында. *Шабган дугае* – Балтач районы Шеңшеңәр авылы янындагы *тугай~дугай* атамасы. *Ялгыз каен дугае* – Саба районы Олы Шыңар авылы янындагы тугай атамасы. *Чукай тугае* – Балтач районы Кариле авылы янындагы тугай атамасы. *Чишмә дугае* – Саба районының Тимершык авылы янындагы тугай. *Тукранбаш тугайлыгы* – Балтач районы Пүскән авылы янындагы урын атамасы. *Чаж тугайлыгы* – Чаж (кыяк) үлән үскән тугайлык. Балтач районы Чапшар авылы янында. *Тугайлы елга* – Кама елгасы кушылдыгы. Балык Бистәсе районы, Грахан авылы янында. *Тугайлы күл* – Сөн елгасы бассейнында, Актаныш районы Семистрау авылы тирәсендә булган. *Тугай-тугай елга* – Кама елгасы кушылдыгы, Спас районы Кузнечиха авылы янында.

*Тугай* термины халык җырларында, әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында еш күренә.

Мәсәлән, ул «Дим буе» дип аталган татар халык җырында бик матур файдаланылган:

*Димдә тудым, Димдә үстем,*
*Җиләк җыйдым тугайда.*
*Әй, матур Дим буе,*
*Бик сагындым бу юлы.*

Тугай лексик берәмлеге «Танып буйлары» дигән халык җырында аеруча матур яңгырый:

*Танып буйкайлары тугай-тугай,*
*Тугайлары яшел камышлы.*
*Барыбыз да шушы җирдә туган,*
*Сатып алып булмый язмышны.*

Г. Ибраһимовның «Табигать балалары» дип исемләнгән хикәясендә *тугай* сүзе кулланыла: *«Унике чалгы алды-артлы тезелешеп тугайны бер әйләнгәч, нуры белән балкылдап кояш та күтәрелде... Җаннар киңәеп үк киттеләр. Рәхәт соң, валлаһи, шундый чакларда киң тугайларда күкрәк киереп печән чабулар!»*

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *тугай* лексик берәмлеге матур сыйфатлана: *«Инешнең аргы ягыннан Ыкка кадәр җәелеп яткан әрәмәле, җиләк-җимешле, түгәрәк күлле зур болынны борынгы бабаларынча «Алтынбикә тугае» дип йөртәләр».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» повестенда мондый тезмәләр урын алган: *«Чү... Кояш катыш рәшә, ерак тугай артында ук сузылып яткан зәңгәрсу тау бите, үлән исе, тыгыз җил – сез кинәт кенә күңелне кузгаттыгыз... Кайда сез – ул кызлар?»*

Кардәш төрки халыклар телендәге *тугай, тагай, токай, тукай,* чагатай телендәге *токаі* – «түбән урыннардагы елга борылмаларындагы урманнар» (Радлов, III: 1147); татар теленең тобол диалектында *тоғаі* – «урман белән капланган болын, түбән урын», бараба диалекты вәкилләре телендә *тоғай* – «елга борылмасы»; казак телендә *тоғай* – «урман» (Радлов, III: 1158–1159); ногай телендә «болын» (Ногай сүзлеге).

Н.Ф. Розен, А.М. Малолетко тыва телендә, бигрәк тә җирле халык сөйләшендә *Баян-Дугай* атамасы кулланылуын ачыклаганнар.

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *тугай* «су астында кала торган урын». Төркиләрдәге *тогай/токой/тукай/тугай* – «тугай, су баса торган болыннардагы үсемлекләр, урман, куаклыклар, елга ярындагы урманнар, су баса торган урыннардагы болыннар, иңкүлек, уйсу җир, түбәнлек җир, елгадагы ярымутрау һәм утрау, елга борылмасындагы урман, култык, елга борылмасы, елга яки күлләрдә кечкенә култык». Тугайның төп мәгънәсе – «терсәк». Монгол телендә *тохой* – «терсәк, борылыш, елга бормасы». Бу сүз рус теленә дә алынган. Россиянең

географик берәмлекләре арасында Тамбов өлкәсендәге *Токой* елгасы теркәлгән. Кыргызстанда *Орто-Токой,* Джунгариядә *Булун-Тохой* атамалары очрый.

***Тура***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *тура* борынгы исем дип бирелгән һәм «шәһәр, кала» дип ныгытылган (ТТАС, III: 170).

***Туралы*** III. Шул ук сүзлектә бу лексик берәмлек борынгы исем дип бирелгән һәм мәгънәсе «шәһәрдә яшәүче (кеше турында)» диелгән. *Бу матур киемле кеше туралы иде* (ТТАС, III: 171).

Төрки-татар топонимиясендә «яшәү урыны, шәһәр, авыл» мәгънәсендәге *тура* сүзе аерым урын алып тора. Борынгы төрки сүзлектә *tura* – «ныгытылган яшәү урыны, крепость».

А.К. Тимергалин җыеп чыгарган «Миллият сүзлеге»ндә *тура* лексик берәмлеге түбәндәгечә анализланган:

*«Тура тар.* – «Древнетюркский словарь» буенча: «Тура – ныгытылган торак, кальга». Борынгы төркичәдә *тура* сүзе «саклагыч», «саклану» мәгънәсенә ия булган, ахры (мәс., Мәхмүд Кашгарида *тура-калкан* – «калкан һәм башка саклану җайланмалары» мәгънәсендә). Б.Д. Греков һәм А.Ю. Якубовскийлар *тура* сүзен «хәрби лагерьны саклаганда кулланыла торган күчмә саклагыч җайланма» (үрмә) дип аңлаталар һәм бу, асылда, Мәхмүд Кашгаридагы төшенчәгә туры килә. Себер татарлары электә шәһәрләрне – «тура» дип, шәһәр халкын «туралылар» дип атаганнар. Мәсәлән, рус елъязмалары безгә Себердәге *Яулы тура, Кызыл тура, Сузга тура* (Күчүм ханның хатыны *Сүзге ханбикә* исеме буенча) кебек шәһәр исемнәрен китереп җиткергән. Бу очракта татарча *тура* сүзе рус телендәге *острог* (ныгытма) сүзенә тәңгәл. Остроглар югары башлары очланган («заострённый») казык баганалар киртәсе белән әйләндереп алынган булган. *Острог* сүзе исә соңыннан татар теленә «төрмә» мәгънәсендә *баструк/вастрок* булып кергән. // *Яза күрмә, җитәр, артык, Тукай, вастрок бар бит; Куярлар астырып дарга, ятып тор бер дә кузгалмай.* Г. Тукай. «Сорыкортларга».

Шахмат фигураларыннан кальга манарасына охшаган «ладья»ның башка исеме «тура» булуы игътибарга лаек. Дөрес, милләтпәрвәр рус шахматчылары соңгы атаманы санга сукмыйлар, монысы да игътибарны җәлеп итә.

*Тура(к) диал.* – Аяк табаны, аяк(ча), тәпи. Борынгы төрки телдәге *тугур-ак – тояк* сүзеннән. Охшаш сүз чуваш, монгол, калмык телләрендә дә бар. Әдәби телдә «төклетура» атамасында сакланган».

*Тура* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда да катнашкан. *Тура суы* – Биектау районының Иске Тура авылы янында. «Бу авыл атамасы Тура – Старая Тура – Турба, дер. на Алатской дороге дип Казан ханлыгы чорында булган авыл атамалары исемлегендә урын алган» (Чернышев, 1971: 288). Татарстанның Яшел Үзән районында *Яңа Тура* дип аталган рус авылы бар.

Төрки һәм монгол телләрендә *тура* «шәһәр, йорт, тору урыны» мәгънәсендә йөргән. Татарлар элек Төмән шәһәрен *Чимги-Тура,* алтайлылар Бийск шәһәрен *Дьяш-Тура* дип атаганнар. *Таулы Алтай* әэлек *Ойрош-Тура* дип аталган.

*Турачак* – «йорт», «кечкенә өй»: Бия елгасы ярындагы *Турачак* авылы атамасы шушы терминнан ясалган. Тубылда–*Ялуторовск* шәһәре бар. Алтайда *Актура, Турачак, Тураты* елгалары ага. Эвенкиянең үзәге *Тура* исеме йөрткән. Хакасиядә *Туралык* атамасы алган елга һәм тау, Башкортстанда Уфа янында *Туратау* дип аталган тау бар. Ачинск елгасы ярындагы Ачинск торак пунктында (яисә *Ачыг Турада), ачыг* кабилә-кавемнәре урнашкан. В. Радлов Себердәге Кузнецк шәһәренең җирле атамасы халык телендә *Абатура* (ул Том елгасы кушылдыгы Аба ярында урнашкан) дип йөртелүен теркәп калдырган. Том елгасы ярына утырган Томск *Том-Тура* булган. Академик Г.Ф. Миллер Тоболның сул кушылдыгы *Ура* елгасы атамасын себер татарлары телендә кулланылган *тура* – «шәһәр» сүзе белән нисбәттә карый. Бу елга ярында *Верхняя Тура, Нижняя Тура, Верхотурье, Туринская Слобода* (Слобода-Туринск

районы үзәге) исеме алган авыллар бар. Тобол өлкәсе Яркәү районындагы борынгы татар авылы *Тоболтура* атамасы алган. Кабардино-Балкариядә *Тура-Хабла* исемле борынгы авыл булган. Чит илләрдә – Словакиядә Братиславадан бераз төньяктарак, Миява елгасы ярында *Тура-Лука*, Көнбатыш Слоцки өлкәсендә *Иске Тура* топонимнары очрый.

***Туш***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *туш* II – кыш көне елга-күлләргә боз өстенә чыккан су. *Идел өстенә туш чыккан, ләкин әле боз батмаган иде.* А. Расих. *Бу әле су түгел, боз өстенә чыккан туш кына.* Ш. Бикчурин (ТТАС, III: 180). Татар теленең эчкен сөйләшендә *туш* мәгънәсен *душ* термины аңлата. Шушы ук ояга тагын *җылу* сүзе дә керә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә ул – «елга» яки күлнең кышын да туңмый калган, боз белән капланмаган өлеше».

***Түбә***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *түбә* компоненты берәр биек нәрсәнең иң югары өлеше, югары очы, дип бирелгән. *Яшкелт таулар зәңгәр күккә башларын сузып торалар. Нинди биекләр алар: итәкләрендә торып, түбәләренә карасаң, башыңнан түбәтәең төшеп китәр*. Д. Аппакова. *Карасу чыршылар[ның] түбәләренә тияр-тимәс кенә булып күзгә авыр болытлар агыла.* Г. Әпсәләмов (ТТАС, III: 281).

*Түбә*нең тагын бер мәгънәсе сүзлектә болай аңлатылган: кечерәк калкулык, калку урын. *Урамнан чыгып, Юкә борыны дип йөртелә торган түбәгә күтәрелгәч, Сәфәргалинең күз алдында авыл... уч төбендәге кебек булып ачылып калды*. Ф. Хөсни. *Түбән җирдә бер түбә Үзен тауга санаган*. Мәкаль. // сыйфат мәгънәсе. Калкуланып торган, калку. *Берәр түбә җиргә менгәч, [ул] ... еракка тик кенә һәм озак кына карап тора*. Ә. Еники. *Урындык ясыйсы каенны әллә кайдагы ерак урманнан түбә җирдә үскәне[н] ... сайлап алып кайтты.* Г. Бәширов (ТТАС, III: 281).

*Түбә* компоненты географик берәмлек атамалары ясауда байтак катнаша. *Сөйә түбә* – Әлки районы Түбән Әлки авылы янындагы калкулык атамасы. *Бөтен түбәсе* – Азнакай

районы Әсәй авылы янындагы биек тау атамасы. *Чардуган түбә* – Балтач районы Алан авылы янындагы урын атамасы. *Алан түбәсе* – Саба райны Йосыф-Алан авылы янындагы тау атамасы. *Урта түбә* – Буа районы Каенлык авылы янындагы урын атамасы. *Усак түбә* – Баулы районы Яңа Шалты авылы янындагы урман атамасы. *Чардуган түбә* – 1. Саба районы Олы Шыңар, 2. Балтач районындагы Алан авыллары яннарындагы җир атамалары. *Тәүшәм түбәсе* – Әтнә районы Мөндеш авылы янындагы басу атамасы. *Каенсар түбәсе* – Теләче районы Югары Мәтәскә авылы янындагы урын атамасы. *Каенсаз түбәсе* – Яшел Үзән районы Юынчы авылы янындагы калкулык атамасы. *Очлы түбә* – Азнакай районы Карамалы авылы янындагы калкулык атамасы. *Тәүшәм түбәсе* – Арча районы Мөндеш авылы янындагы басу атамасы. *Түбә саз* – 1. Мамадыш районы Шәмәк, 2. Балтач районы Түбән Кенә авыллары янында. *Түмгәкле түбә* – *Каен түбә* атавындагы түмгәкле, кыяк печән үсә торган урын, чабыла торган җир. *Түгәрәк түбә печәнлеге* – Лаеш районы Имәнкискә авылы янындагы печәнлек атамасы. *Түгәрәк түбә печәнлеге елгасы* – Лаеш районы Имәнкискә авылы янында, Борыс елгасы бассейнында. *Түбәтау* – Мамадыш районы Олыяз авылы янындагы тау атамасы. *Түбә сазы* – Балтач районы Түбән Кенә авылы янындагы Кенә елгасы бассейнында. *Түбә саз чишмәсе* – Мамадыш районы Шәмәк авылы янында, Арбаш елгасы бассейнында. *Тәкәле түбә* – Әлмәт районы Сөләй авылы янындагы урын атамасы. *Кирәмәт түбәсе* – Арча районы Югары Мәтәскә авылы янындагы урын атамасы. *Салкын түбә* – Азнакай районы Карамалы авылы янындагы тау атамасы. *Каенсаз түбәсе* – Яшел Үзән районы Юынчы авылы янындагы калкулык атамасы. *Ком түбә* – Балтач районы Яңгул авылы янындагы калкулык атамасы.

*Түбә* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында очрый.

Вахит Имамовның «Утлы дала» исеме алган тарихи романында *тау түбәсе* гыйбарәсе болай кулланыла: *«Һавада аждаһа сыман ысылдап очкан ядрәләр кыя тау түбәсенә барып*

*төшкәч кенә, яман гөрселдәүдән һәммәсе берьюлы тезләренә чүкте». «Аның [Мирхаҗиның] кайчандыр бөтен Болгар илендә абруй һәм шөһрәт казанган Давыт сәет улы икәнлеген белгәч, Тәмтүбә аймагының башлыгы Кормаш би Мирхаҗины кунакка дәшеп алды».*

Бу термин белән ясалган атамалар бараба татарлары сөйләшендә, алтай, шор телләрендә кулланылалар.

М.Ф. Розен һәм А.М. Малолетко мәгълүматларына караганда, алтай телендә *тёбё,* шор телендә *тёбе, тёбо* – «тау», «түбә» мәгънәсендә кулланыла. Алтайда – *Тёбелер* «биеклекләр», Шориядә *Улугтёбе* (өч биеклек), П.-С. Паллас сүзлегендә Кузнецк янындагы «хози» – *тюбе,* Барабада – *тюбя.* Күп төрки халыкларда *тапа, тобе, дюбе, тюбе, добо* «тау башы» мәгънәсендә билгеле.

***Тыкрык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *тыкрык* термины «исем» дип бирелгән һәм болай аңлатылган: «Ике параллель урамны тоташтыра яки кырга алып чыга торган кечкенә урам». *[Фәтхия] зур урамнан сулга, кечкенә тыкрыкка борылды, ... карны ерып,... арткы кечкенә, фәкыйрь урамга чыкты.* Г. Ибраһимов. *Салам түбәле өйләрне үтеп, Агыйделгә алып төшә торган кечкенә тыкрыкка борылуга, ... Ибрай очрады.* М. Әмир (ТТАС, III: 185).

*Тыкрык* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда еш кулланыла: *Сәрвәр тыкрыгы* – Кукмара районы Чуллы авылында (ул тыкрыкта Сәрвәр исемле карчык торган). *Карабай тыкрыгы* – Балтач районының Смәел авылындагы тыкрык атамасы. *Базар тыкрыгы* – Балтач районының Курмала авылы янындагы тыкрык атамасы. *Бүре бабай тыкрыгы* – Апас районы Зур Күккүз авылындагы тыкрык атамасы. *Урман буе тыкрыгы* – Балтач районы Пүскән авылындагы тыкрык атамасы. *Апаралар тыкрыгы* – Апас районы Зур Күккүз авылындагы тыкрык (апара – кушамат). *Тыкрык авызы* – Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылындагы атама. *Бирге тыкрык авызы* – Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылы янындагы Каенлы ел-

гасына тоташкан урыны (суы яз көне генә була). *Бирге тыкрык авызы* – Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылы янындагы сөрелми торган чирәм җир атамасы. *Тыкрык җыен* – Яшел үзән районы Тау иле авылында урам атамасы. *Тыгырык күле* – Әлки районы Югары Әлморза авылындагы күл (*к* һәм *г* авазлары өлкәннәр телендә бик еш алмаштырылып әйтелә). *Тыгырык чирәме* – Кама Тамагы Яңа Сала авылы янындагы урын атамасы. *Кәвәл тыкрыгы* – Питрәч районы Янсуар авылында. *Кәҗә тыкрыгы* – 1. Кукмара районы Сабанчы (Аты), 2. Мамадыш районы Владимир авылларындагы тыкрыклар һ.б.

*Тыкрык* лексик берәмлеге язучылар һәм шагыйрьләр иҗатында да кулланыла. Фатыйх ага Хөснинең «Берәү килә, берәү китә» повестенда кулланылган *тыкрык* лексик берәмлеге күңеле шомландырып куя: *«Кулыбызга берничә адрес килеп керде. Беренчесе кайдадыр шәһәр читендәрәк тар гына тыкрыкта, яны белән салынган ике катлы өйнең беренче каты булып чыкты».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» исеме алган повестенда *тыкрык* лексик берәмлеге шактый еш кулланыла: *«Бераздан тыкрыклардан кызлар чыркылдаганы ишетелде».*

Вахит Имамовның «Утлы дала» исемендәге тарихи романында *урам-тыкрык* лексик берәмлеге кулланыла: «*Урам-тыкрыкларны, тау өстеннән ургып аккан ташкын сыман тутырып, сафлар Алтын капка һәм Шәрык капка тарафына юл алды».*

***Уба.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *уба* термины «диалекталь исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе: 1. Җирне казылып ясалган чокыр, җәнлек оясы һ. б. ш. Убылган урын. *[Сентябр:] Күктән тамчылар, агачлардан яфраклар коям, әрләннәрне, йомраннарны убаларына кадәр куам*! Г. Галиев; 2. Тигез җирдәге кечерәк калку урын. *Ерак та ла җирдән, һай, күренә Убаларга салган таш кала*. Җыр (ТТАС, III: 203).

*Уба* термины белән географик атамалар байтак ясалган. *Бүре убасы* – Сарман районы Рангазар авылы янындагы җиргә

казылып ясалган чокыр, җәнлек оясы. *Дуңгыз убасы* – Апас районы Болын-Балыкчы авылындагы урам атамасы. *Аргы тирән уба күле* – Апас районы Болын-балыкчы авылы янындагы күл. *Олы еланлы уба, Кече еланлы уба* – Апас районы Кормаш авылы янындагы урын атамалары. *Уба чокыры* – Апас районы Кече Күккүз авылында, Мәме елгасы бассейнында. *Уба күле* – Буа районы Черки-Килдураз авылында, Зөя елгасы бассейнында. *Уба чишмәсе* – Азнакай районы Мәлбагыш авылында, Мәлбагыш елгасы бассейнында.

Татар теленең диалектологик сүзлегендә минзәлә, оренбург сөйләшләрендә *уба* – «җиргә казылып ясалган чокыр, җәнлек оясы һ. б. ш.» диелгән; камышлы сөйләшендә, нагайбәк керәшеннәрендә ул – «кечкенә калкулык» (ТТДС, 1969: 451). *Уба чишмәсе тавы* – Азнакай районы Мәлбагыш авылы янындагы тау атамасы. *Уба-китә күле* – Яшел Үзән районы Мамадыш-Әкил авылы янындагы күл. *Баһаветдин убасы* – Апас районы Болын-Балыкчы авылы янында, Зөя елгасы бассейнында. *Мәрҗән убасы* – Апас районы Болын-Балыкчы авылында, Зөя елгасы бассейнында. *Түки убасы күле* – Апас районы Кормаш авылы янында, Зөя елгасы бассейнында.

*Уба* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында да кулланыла.

***Уемтык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *уемтык уем* сүзенә җибәрелгән. *Уем* сүзенең географик атамаларга караган мәгънәсе болай аңлатылган: «Җир өстендә казылган, ашалган урын, чокыр» *[Чатыр тавының] яңгыр сулары тирән уемнар белән сырлаган һәм яшел куаклыклар каплаган итәкләрендә чиксез-хисапсыз санда суер колонияләре яши*. М. Хәсәнов (ТТАС, III: 295).

*Уем, уемтык* терминнары географик атамалар ясауда очрыйлар: *Уем (чокыр)* – Лаеш районы Ябынчы авылында. *Уемтык җир* – 1. Биектау районы Зур Сулабаш, 2. Әтнә районы Ябынчы авылларында.

Бу терминнар әдипләр иҗатында кулланыла. Вахит Имамовның «Утлы дала» исеме алган тарихи романында мондый

җөмлә укыйбыз һәм анда *уемтык* лексик берәмлегенә юлыгабыз: *«Учыклар ышыкланыр өчен ясалган уемтыклар һәм манараларны тирәләп, баштанаяк коралланган шыгавыллар гына йөренә, әле аларның да күбесе диварларда койма такталары сыман тезелеп торган таш калканнар арасыннан сузылып, курсыбый газизләрен манзара кыла иде».*

***Уентык.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем» дип ныгытылган һәм «Уелып торган урын, киртләч», – дип аңлатылган. Мисаллар да китерелгән. *[Илдар] әкрен генә торды да, бияләйләрне мич уентыгына җылыга китереп салды.* Г. Гобәй. *Кәрниз уентыгында, купкан-сынган һәр такта ышыганда чәүкә оялары бик күп иде.* Каз. утл. (ТТАС, III: 296).

Бу термин язучылар иҗатында кулланыла. Нәбирә Гыйматдинованың «Нурулла» исемендәге бәянында мондый юллар бар: «*Нурулла әлеге аймакка беркайчан да тимер ургыч керттермәде. Бабайлар каны тамган уентыкны ул ел саен ике-өч карт белән чистартыр һәм азактан шәһитләр рухына дога кылдыртыр иде*».

***Уй***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *уй* диалекталь исем дип ныгытылган һәм «Түбән җир, иңкү җир, иңкүлек» дип аңлатылган. Мисал китерелгән: *Ук аттым уйга төште. Ул уйдан кошлар очты*. Г. Әпсәләмов. (ТТАС, III: 299).

*Уй* лексик компоненты топонимнар һәм гидронимнар ясалышына да өлеш кертә: *Уй елгасы* – Ылгыма суының сул кушылдыгы (Кама Тамагы районының Салтыган, Кече Карамалы авыллары янында); Уй – Чирмешән районы Яңа Кади авылында Инеш кушылдыгы. Чагыштыр: *уй* – «иңкүлек, иңкү җир». *Кече уй* елгасы – Чишмә/Шишмәнең уң кушылдыгы, русча ул *Кичуй* елгасы дип йөртелә. Бабаларыбыз телендә бу елга *Кече Уй* дип йөртелгән. Руслар килеп утырганнан соң ул *Кичуй* итеп үзгәртелгән, *Кичуй* > *Кече Уй* елгасы ярына *Кичуй* > *Кече Уй* авылы утырган. Анда руслар, татарлар көн итә һәм рәсми рәвештә авыл *Кичуй* дип атала.

Актаныш районында *Тирән уй* – Сөн елгасы кушылдыгы. Минзәлә районының Бикбау авылында *Тирән уй* – тирән чокырлы урын. *Тирән уй сызасы* – Тирән уйдан Юалык итәгенә чаклы сузылган бик озын сыза.

*Олы уйлык* һәм *Кече уйлык* – Менделевск районының Турай авылы янындагы (Кама бассейны) елгалар да шушы ук рәткә керәләр. *Мачунай уйы* – Чүпрәле районы Югары Каракитә авылы янындагы иңкүлек.

*Уй* термины Татарстаннан читтә яши торган татарлар телендә дә кулланыла: *Зирекле уй* – Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы җирләреннән ага торган елга, Тирешкә елгасы кушылдыгы һ. б.

***Уйдык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *уйдык* лексик берәмлегенең *беренче мәгънәсе* «уелып кергән урын, уентык». *Көмеш сулы тугайлар янындагы көпшәләр уйдыкларда үсеп чыга*. А. Гыйләҗев. *Фирүзә тау уйдыгындагы каенлыкка юнәлде*. М. Хәбибуллин.

Бу лексик берәмлекнең *икенче мәгънәсе*: «Җир яки нинди дә булса яссылык өстендә аерылып торган бер кисәк, кечкенә мәйданчык». *Үткән-сүткән юлаучылар гына анда бер кишәрлек, монда бер уйдык чабып, арба төбенә салып киткәлиләр*. А. Гыйләҗев.

Бу лексик берәмлекнең *өченче мәгънәсе*: «Берәр нәрсә күп булган урын». *Уйдык таптым. Җиләк уйдыгы* (ТТАС, III: 299).

*Иске зират уйдыгы* – Саба районы Олыяз авылы янындагы урын атамасы.

*Уйлык* һәм *уйдык* лексик берәмлекләренең мәгънәсе бер-берсеннән ерак түгел кебек.

***Уйсу***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *уйсу* сүзе «әйләнә-тирә җирдән чокыраебрак торган, иңкел» дип бирелгән. *Уйсу җирләрдә әле җир юеш*. Ш. Камал. *Уйсу җирләрдә зур-зур чуар күлләр җыелды*. Ә. Еники (ТТАС, III: 302).

***Уйсулык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем» дип бирелгән һәм ул «Әйләнә-тирә җирдән

чокырланып, батып торган урын, уйсу җир» дип аңлатылган. *Урыны-урыны белән кара туфраклы уйсулыклар бөтенләй саз-га әверелгән.* А. Шамов. *Уйсулыкта үскән бодайлар арасыннан чыгып килгән Мәрданша бабайның көрәк кадәр ак сакалы күзгә бәрелде*. Г. Гобәй (ТТАС, III: 302).

*Уйсу, уйсулык* лексик берәмлекләре белән географик ата-малар очрыйлар. *Кара куак уйсулыгы* – Апас районы Колгына авылы янындагы урын ~ уйсулык атамасы. *Уйсу җир* – Идел ярының Югары Ослан янындагы урыны, *Карама куак уйсулы-гы* – Апас районы Колгына авылы янындагы уйсу җир атамасы.

*Уйсу* компоненты әдипләр иҗатында очрый. Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романында *уйсу* болай бирелгән: *«Кибеп, кызарып торган уйсуның кыйбла ягына утырган унлап тирмәгә карагач, Азымбай бер күз салуда уртадагы зур ак киез өйне күрде. Арыслан байныкы шушы булырга тиеш», – диде.*

*Уйсулык* лексик берәмлеге Мөхәммәт ага Мәһдиев иҗатында да очрый. «Ачы тәҗрибә» исеме алган китабында мондый юл-лар укыйбыз: *«Андагы табигать гүзәллеге, андагы сихри уйсу-лыклар, куаклар, чишмәләр, болыннар... барысы да көеп беткән».*

Вахит Имамовның «Казан дастаны» дип аталган тарихи әсәрендә *уйсулык* термины кулланылган: *«Бәкләр белән әмирләр күлнең [Меңказ күле] вак-вак таллыклар белән капланган поч-магында, Хәдичә ханәш җитәкчелегендәге байбичәләр, кызлар, кәнизәкләр – һәммәсе берьюлы төнбоеклар яткан уйсулыкта коенып чыктылар».*

Роза Хәбибуллинаның «Мулла килене» романында *уйсулык* кебек географик атамалар еш кулланыла. *«Тирән чокыр уйсулы-гыннан ташып, бакча артларына печән кибәннәре өйделәр».*

Нурислам Хәсәновның «Сагыш» исеме белән дөнья күргән китабында урнаштырылган «Иңрәү» повестенда мондый юллар укыйбыз: *«Гимнастерка җилкәләренә бәреп чыккан аксыл тир эзләре – әйтерсең чүл уйсулыклары төшерелгән карта».*

***Улак***. Халык телендә бу термин чишмәне дә аңлата. Аның бу мәгънәсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә теркәлмәгән.

*Улак* термины топонимнар ясауда шактый кулланыла. *Улак* – Кама Тамагы районы Бәки авылы янындагы Шаһиян елгасы бассейнында; Тәтеш районының Олы Әтрәч авылы янындагы Әтрәч елгасы бассейнында. *Улаклы басу* – Лениногорск районы Сугышлы авылы янындагы басу атамасы. *Улак суы* – Тәтеш районы Алабирде авылында, Инеш бассейнында. *Габдрахман улагы* – Апас районы Багыш авылындагы чишмә. *Бипи улагы* – Кама Тамагы районы Кече Бортас авылында (бу чишмә Бипи~Биби исемле кечкенә генә гәүдәле карчык йорты янында чыккан, суы бик тәмле). *Вафа улагы* – Кама Тамагы районының Кече Бортас авылында булган, бу чишмә хәзер ябылган. *Мәчет улагы* – Кама Тамагы районы Иске Барыш авылында, Коры Үләмә елгасы бассейны. *Минһаҗ улагы* – Кама Тамагы районы Кече Бортас авылы янында булган. *Таш улак* – Кама Тамагы районы Олы Бортас авылы яныннан ага торган Коры Үләмә елгасы бассейнында. *Мулла улагы* – Кама Тамагы районы Кече Бортас авылы яныннан ага торган Коры Үләмә елгасы бассейнында. (Бу чишмә мулла йорты янында урнашкан булган. Суы бик тәмле. Бу чишмә суын халык әле дә бик яратып эчә.) *Шәмкә улагы* – Кама Тамагы районы Иске Барыш авылы янындагы чишмә. *Чурныш кирәмәте улагы* – Кама Тамагы районы Кыртапа авылы янындагы чишмә. *Улак авызы* – Апас районы Дәүләки авылы янында. *Айдар улагы* – Биектау районы Мәмдәл авылы янындагы чишмә. *Биш улак чишмәсе* – Лениногорск районы Тимәш авылындагы улак-чишмә. Элек бу биш улактан су ага торган булган. Аның янында җыен уздырылган. Хәзер суы азайган. *Каен улак кизләве* – Апас районы Кошман авылындагы кизләү. *Алты улак* – Имәлле суы бассейнында, Кайбыч районы Олы Урсак авылы янындагы чишмә-кизләү. *Чурныш кирәмәте улагы* – Кама Тамагы районы Кыртапа авылы янында. Коры Үләмә суы бассейнында. *Салкын улак* – 1. Апас районы Кече Болгаер авылы янында, Олы Шаһиян суы бассейнында, 2. Кама Тамагы районының Кече Салтык авылы янында. 3. Тәтеш районы Зур Әтрәч авылы янындагы улак-чишмә. *Салкын улак күле* –

Кама Тамагы районы Кече Салтык авылы янында, Ылгыма елгасы бассейнында.

*Улак* термины әдипләребез һәм шагыйрьләребез иҗатында очрый.

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *улаклы чишмә, чишмә улаклары* гыйбарәләре кулланыла: *«Минһаҗ, сөйләшә торгач, иң кырыйдагы улаклы чишмә турысына барып басты да биленә таянып сызгырырга тотынды: Фью... Фью...» «Комиссия членнары кич буе Җидегәннең җирен-суын карап йөрделәр, халык белән сөйләштеләр. Алар белән килгән фотограф тәмам эштән чыгып корыган җимеш бакчасын, аунап яткан Җидегән чишмә улакларын, сусыз калып ярлары ишелеп төшкән Әверлән инешен, тагын шундый бик күп хәрабәләрне фотога төшереп алды».*

Равил Фәйзуллинның «Илбагар утлар. Фәлсәфи язмалар, әдәби портретлар, хатирә-уйланулар» китабыннан мондый юллар укыйбыз: *«[Җәен] теләсәң – үләндә ауна, җиләген өзеп кап, теләсәң – кызынып ят, елга-күлләрдә коен, чишмә улагыннан аккан су толымына йөзеңне куй».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» повестенда *улак* бермлеге матур кулланыла: *«Агай-эне тын гына капчык тутыра, ара-тирә таш астындагы улактан аккан җылы онны учына салып уып карый. Эре тартмыймы?» «...Ишектә ак чәчле, ак мыеклы, кып-кызыл битле карсак бер абзый күренә. ...Елмаеп кына улак янына килә, аккан онны учына ала, уып карый да мөшкәдән коелу тизлеген үзгәртә – ак тузанлы сүс бау, шомарып сөяккә әйләнгән боргычлар...»*

Вахит Имамовның «Утлы дала» тарихи романыннан мондый юллар укыйбыз: *«Кыялы таудан бер фәрсах арада Улаклы чишмә булыр, шуның янына кил».*

Талантлы прозаик һәм шагыйрә Фирүзә Җамалетдинованың «Буранда» хикәясеннән мондый юллар бар: «*Мондый да (буранда) юлга чыкмыйлар. Әнә, Хәтимә карчыкка кер дә кун. Юлчыларны көтеп тора ул, – диде миңа кое янындагы улактан*

*атына су эчереп торучы иске фуфайкалы агай. – Йортын – мосафирлар, коесының суын атлар ярата».*

Роза Хәбибуллинаның «Мулла килене» исеме алган романында *улак* термины гаҗәп матур кулланылган: *«Көянтәчиләк алып, Мирфәезе белән Куш чишмәгә суга баргач кына [Мәһинур] авылын ничек сагынганын аңлады. Агач улактан ургылып аккан көмеш суга карап: «Мин сездән башка ничек яшәдем микән?» – дип уйлады».*

***Умарта***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *умарта* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай аңлатылган: «Бал кортларын асрау өчен махсус эшләнгән әрҗә яки эче куыш юан багана (чолык). *Ә хәзер! Саннарына чыга алмаслык икешәр корпуслы зәңгәр буяулы такта умарталар*. Г. Галиев. *Бакчада ике-өч баш умарта күренә*. А. Алиш. // Шул әрҗәдә яки багана эчендә яшәүче кортлар. *Иген белән, җир-су белән, умарта белән дөнья көтте [Шибай карт]*. Г. Ибраһимов. *[Нуретдин абзый:] Менә умарта асрыйбыз, үзегез беләсез, ел саен диярлек бал бүлешмичә калганыбыз юк*. Ә. Еники (ТТАС, III: 307).

***Умарталык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *умарталык* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм болай аңлатылган: «Умарталар куелган урын; умарта (балчылык) хуҗалыгы». *Су буенда, урманнан ерак түгел бер урында, колхозның умарталыгы да бар икән.* М. Гали (ТТАС, III: 307).

Адлер Тимергалин умартаны болай сурәтли: «Умарта сүзе башкортта да үзгәрешсез яңгырый. Охшаш сүз чуваш диалектында, удмурт, мари, каракалпак, уйгур телләрендә дә бар икән. Р. Әхмәтьянов бу сүзнең аларга татарчадан кергән булуы мөмкин дигән фикердә. Әмма мари кебек урман халыкларының чолыкчылык шөгылен безнең бабаларыбыздан «откан» булуы ике сарылы, ягъни шикле. Агачтан төрле нәрсәләр ясауга килгәндә, мари осталары бүген дә дан тота.

Р. Әхмәтьянов, Кавказ телләрендәге *мартан* – «умарта; кәрзин» сүзен борынгы ирани *мәрдан* – халык сүзе белән дә бәй-

ләргә мөмкинлек бирә, дигән фикерне әйтә. Рус теленә мөрәҗәгать итсәк, бу мәсьәләне шактый ачыклый алабыз. В. Даль сүзлегенә теркәлгән *борть* (диалектта «бортя») сүзе безнең *умарта* сүзенә тәңгәл диярлек. «Борть – бал кортлары ияләшкән эче куыш агач, куыш агач төбе», – дип яза В. Даль. Чолыкчылар үсеп утырган агачларда махсус куыш ясап кыргый бал кортларын ияләштерә торган булганнар. Сүзлек авторы ясалма чолыкны тәфсилләп сурәтли, аның бик кызыклы детальләрен атап күрсәтә. Кайчагында чолыкчылар агачка кәрзин итеп үргән умартаны элеп куя торган булганнар.

Шул рәвешле *умарта* сүзе Евразиядә киң таралган икән. Әгәр аның ирани тел белән бәйләнышы хак булса, төп чыганакны шул телдән эзлисе була дигән сүз. *Умарта* сүзен «үлем» мәгънәсендәге *мур*/*мор* сүзе белән бәйләргә тырышу (Р. Батулла) нигезләнми».

*Умарта, умарталык* терминнары географик атамалар ясауда шактый кулланылалар: *Умарта бакчасы* – Мөслим районы Тырыш авылы янындагы бакча атамасы. *Умарта тавы* – Сарман районы Дүсем авылы янындагы тау атамасы. *Умарта бакчасы чокыры* – Буа районы Каенлык авылы янындагы Инеш кушылдыгы. *Умарта юлы* – Мөслим районы Әмәкәй, Мамадыш районы Катмыш авыллары янындагы юллар атамасы. *Умарта елгасы* – Мамадыш районы Үсәли авылы янындагы Бүрсет суы кушылдыгы. *Умарта кизләве* – Апас районы Идрәс-Тинки авылы янындагы Көрәнлек елгасы бассейнында. *Умарталар буе чыгышы* – Кама Тамагы районы Келәнче авылы янында. *Умарталар чокыры* – Кама Тамагы районы Келәнче авылы. *Умарталы елга* – Биектау районы Зур Кавал авылында, Инеш кушылдыгы. *Умарталы елга чишмәсе* – Биектау районы Зур Кавал авылы янындагы чишмә. *Кискән марталык* – Чирмешән районы Бәркәтә авылы янындагы урын атамасы. *Нурук бабай муртасы* – Аксубай районы Иске Татар Кармәте авылы янындагы элекке умарталык. *Умарталык чокыры* – Алабуга районы Турай авылы янындагы чокыр атамасы. *Умарталык чишмәсе* –

1. Мамадыш районы Югары Сон авылы янышнан агып үтә торган Сон елгасы бассейнында, 2. Чирмешән районы Яңа Кади, 3. Кама Тамагы районы Олы Яңа Сала авыллары янындагы чишмәләр. *Умарталык кизләве* – Тәтеш районы Иске Бидәнге авылы янындагы чишмә-кизләү. *Умарталык болыны* – Әлмәт районы Ялхавай авылы янындагы болын. *Умарталык асты* – Лениногорск районы Түбән Чыршылы авылында. *Умарталык аланы* – Биектау районы Айбаш, Кама Тамагы районы Бәрлегуҗа авыллары янындагы алан атамалары. *Умарталык* – Апас районы Аюкөйдергән, Әлмәт районы Ялхавай, Мамадыш районы Тулбай авыллары янындагы умарталыклар. *Умарталык/Әрәмәлек* – Азнакай районы Сасы күл (Бүләк) авылындагы умарталык. *Умарталык елгасы* – Мамадыш районы Өчиле, Лениногорск районы Түбән Чыршылы, Мамадыш районы Югары Сон, Әлки районы Иске Чаллы, Саба районы Тәмте авылларындагы яннарында умарталыклар булган елгалар.

*Умарта, умарталык* лексик берәмлекләре әдипләребез иҗатында еш файдаланыла.

«Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *умарта кортлары* гыйбарәсе болай бирелгән: *«Яңгыр артыннан чыккан кояш нурлары умарта кортларын җанландырып җибәрде, алар төрле якка таба оча башладылар». «Бал исе аңкып торган алан һавасы, мондагы тын иркенлек, умарта кортларының гөжләүләре аны тынычландырып, күңелен күтәреп җибәрде».*

Фоат Садриевның «Таң җиле» романында мондый юллар бар һәм анда *умарта* лексик берәмлеге оста кулланылган: *«Кичтән умартасына кайтып җитә алмыйча, зәңгәр чәчәкнең уртасына кереп йоклаган бал корты озын сабакның җилдә чайкалып куюыннан чак кына егылып төшмәде...»*

***Унгуз*** – елганың иске үзәне, иске юлы, елга юлы (елганың су ага торган төп юлы). Мәхмүт Кашгари язуынча: «Угызлар хәтта аңлатып тормыйча да Сыр-Дәрьяны *Угыз елгасы* дип белгәннәр». Кайбер төрки карталарда Амудәрьяны әлегә кадәр

*Окуз* дип атыйлар. Чыгышы белән ул «елга» мәгънәсендәге *ӱгӱз, ӱӱс* сүзенә барып тоташа һәм шушындый билгеләмә белән ул хакас теленең кызыл диалектында табыла. *Ӱгӱз* формасы Орхон һәм Енисей ярларында табылган борынгы төрки истәлек-һәйкәлләрендә дә ныгып калган. Хакас топонимиясе бу терминны Хакас елга атамаларында әйбәт саклап калган. *Унгуз* термины географик атама буларак фәнни әдәбиятта «озын булып сузылып бер тигезлектә урнашкан уйсулык, уйсу җир, тозлак, тозлы туфраклык, такырлык»ны аңлата. Алар Көньяк һәм Төньяк караком чикләрендәге итәк-баскычларда очрыйлар. Төрекмәннәр еш кына коры елга, кипкән үзәнне (бу рәткә *Узбой* да керә) *унгуз* дип атыйлар. Бу ояга тагын, килеп чыгышы, кайдан барлыкка килүе бәхәсле булса да, Кыргызстандагы *Джеты-Огуз* (ягъни Җиде елга) атамасы алган елга һәм курорт керә.

***Упкын***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек исем дип бирелә һәм болай аңлатыла: 1. Текә, тирән яр; җирдә бик тирән ярылган урын. *Аста төбе күренми торган, ахырына җитү мөмкин булмаслык упкын*. Ә. Баянов; 2. Елга яки күл төбендәге тирән чокыр; чоңгыл. *Кайбер урыннарда шундый упкыннар очрый, анда аяк баскан кеше бервакытта да исән котыла алмый, суыра, йота.* Г. Бәширов // күч. Кемне яки нәрсәне дә булса тарта, өстери торган һәм аны һәлак итәргә яки берәр начар хәлгә төшерергә мөмкин булган әйләнә-тирә мохит һ. б. [*Меньшевиклар, эсерлар*] *революцияне төпсез упкынга батырмакчы булалар, тик көчләре генә җитми*. И. Гази (ТТАС, III: 309– 310).

*Упкын* термины белән Татарстанда шактый күп географик берәмлек атамалары ясалган: *Упкын күле* – Арча районы Олы Бәрәзә авылында; Баулы районы Әпсәләм авылында. *Упкынлык сазлыгы* – Биектау районының Чәмәк авылы янында, *Упкын чишмәсе* – Баулы районы, Бәйрәкә авылы яныннан ага торган Бәйрәкә елгасы бассейнында. *Упкан күл* – Әгерҗе районы Салагыш авылы янындагы. *Упкан чокыры* (күл) – Әгерҗе районы Наҗар авылы янында. *Упкын (сазлык)* – Биектау районы Яңа

Рәс авылы янында. *Упкын чишмә* – Сарман районы Рангазар авылы янында. *Упкын чокыры* – Апас районы Борнаш авылы янында.

*Упкын* берәмлеге әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында да кулланыла. Хәсән ага Туфанның «Тынма давыл» шигырендә *упкын* сүзе йөрәкне сыздырып, авырттырып искә алына:

*Өстә – дулкын,*
*Аста – упкын*
*Куллар сала салыма.*
*Сукма, дулкын, упма, упкын:*
*Кайтыйм ярым янына.*

Айдар Хәлимнең «Кыйбла: хикәяләр, новеллалар» китабында *упкын* сүзе кергән мондый җөмлә бар. *«Гүя хәзер шушы мәҗлес даирәсеннән, аның бүгенгесеннән, ниндидер утлы ыргаклар күк гөмбәзенә ыргылды, аннан бу ыргаклар Разия чәчләренә калфак булып кайтарылган ай элпәсен, аннан Разиянең үзен дә упкынга өстери башлады...»* Айдар Хәлимнең шул ук китабында *упкын* термины күчерелмә мәгънәдә дә бирелгән: *«...Бәгърем тагын да истәлекләр упкынына убылды».*

Марсель Галиевнең «Рух» китабында искиткеч гамьле, матур төзелгән сүзләр белән туган телебездә мондый мәдхия укыла: *«Кылычтан кыелмаган ул, упкынга убылмаган, ялкыннан ялманмаган ул, алтынга алданмаган – менә шундый үлемсез тел бит ул – Ходай кодрәте белән иңдерелгән – Газиз ана теле!»*

Роза Хәбибуллинаның «Мулла кияве» дигән романында *упкын* термины күчерелмә мәгънәдә кулланыла: *«Кояш сүнмәде, зәңгәр күктә һаман нурларын сибә, тик дөнья башка, җаннарны тетрәндергән хәбәр бар шатлыкны, рәхәтне юып төшерде, кичәге көн белән бүгенге көн арасына упкын булып төште, кичәгедәй тормыш булмаячак...»*

***Ур.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ур* терминының ике мәгънәсе бирелгән. *Беренче мәгънәсе* «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай аңлатылган: «Дошманнан саклану өчен,

шәһәр һәм крепость тирәли койма урынына казылып ясалган ныгытма, траншея һәм вал». *Икенче мәгънәсе* «диалекталь термин» дип күрсәтелгән һәм мәгънәсе дә аңлатылган: «Текә ярлы коры елга, тирән чокыр». *Кара урманның уртасында Төлке уйный торган урлар бар*. Җыр // Ясалма инеш, канау. *Чишмәдән ерак та түгел ур суы ага* (Ә. Баянов) (ТТАС, III: 310).

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә «Ур *тар*. – Электә шәһәрләрне саклау өчен аның тирәли казылган чокырларны яки, киресенчә, балчык өемнәрен «ур» дип атаганнар. Гарәпчә *әсвар*. Русчада очрый торган «Перекоп» атамасы да төрки «ор (ур)» терминының тәрҗемәсеннән гыйбарәт. Р. Фәхреддиннең Кирилл хоруфатына күчерелгән бер хезмәтендә *үр* язылышы алынган. // *Мин үзем «Бөгелмә» берлә «Чистай» шәһәрләре арасында булган «үр»ләр берлә шәех Шамил рәсемене күргән вакытларымда әсәрләнәм, фикер дәрьясына гарык булам*. Р. Фәхреддин.

Тагын кара: *Өек*».

*Өек* Адлер Тимергалин төзеп чыгарган «Миллият сүзлеге»ндә татар сүзе дип ныгытылган һәм «Калку җир, өем җир; ур, әсвар (гарәпчә)» дип аңлатылган. «*Ермак өеге* (Себердә Ермак – илбасар Василий Тимофеевич Аленин үтерелгән җир). Ләкин Һади Атласида *өек, уек* «казылмыш өн, мәгарә» мәгънәсендә очрый, ягъни *өек* сүзенең русча «окоп» мәгънәсе дә булган, дип уйларга мөмкин. Бу сүзне «дамба» мәгънәсендә кулланып булыр иде».

«Татар теленең диалектологик сүзлеге»ндә *ур*ның Алабуга керәшеннәре телендә «текә ярлы сусыз коры елга» мәгънәсендә йөрүе күрсәтелгән (ТТДС, 1969: 455). Зәй керәшеннәре телендә *ур* – «елга», «тирән чокыр». Сарман һәм Минзәлә төбәгендә яши торган татарлар телендә бакчаларга терлек-туар кермәсен өчен казыла торган тирән канауны һәм аннан чыккан балчык өеме белән әйләндереп алынган кечкенә үр сыман биеклекне элек *ур, үр* – «чокыр дип атый торган булганнар.

*Ур* термины татар су чыганаклары, микротопонимнар һәм авыл атамалары составында кулланыла: *Салаур елгасы* –

Аксубай районындагы Кече Сөлчә кушылдыгы. *Ур елгасы* – Арча районындагы Аты елгасы, Яшел Үзән районыннан агып үтә торган Зөя елгасы кушылдыклары. *Ур башы елгасы* – Арча районындагы Наласа елгасы кушылдыгы. *Урсай елгасы* – Зәй елгасының уң кушылдыгы, Әлмәт районының Урсай авылы янында. *Урсала елгасы* – 1. Зәй елгасының уң кушылдыгы, Әлмәт районының Урсала авылы янында; 2. Көшкән елгасы бассейнында, Балтач районының Көшкәтбаш авылы янында. *Кала тавы урлары* – Аксубай районы Шәрбән авылы янындагы урын атамасы.

Авыл атамалары: *Урсай, Урсай чишмә, Урсала, Урсала баш* һ. б. Урал алды җирлегендә *Урсай-Йәнәби, Урсай* һәм *Рус Урсае* һ. б. авыллар бар.

*Ур* термины белән ясалган атамалар читтәге төбәкләрдә дә очрыйлар: Якутиядә (Саха) *Ур* елгасы – Зөя кушылдыгы (Пекарский, 1830: 3056). *Ур* елгасы – Ока кушылдыгы. Мокша бассейнында *Урлейка* суы ага. Г.П. Смолицкая бу атаманы татар телендәге *ур* + мордва телендә «чокыр, елга» төшенчәсендәге *лей* компоненты + *ка* кушымчасы кушылып ясалган дигән фикер әйтә (1973, 230, 236).

*Ур* термины әдипләр һәм шагыйрләр иҗатында да кулланыла. Вахит Имамовның «Утлы дала» романында *ур* термины байтак очрый: *«Пайтәхетне әле урыс яулары вакытында ук ике катлы биек урлар өеп ныгытканнар икән». «Алар [сүс уралган зур кисәүләр] көтелмәгән дошманнарны шомландырырдай көчле ялкын чәчми, шулай да дивар каршындагы эчке урны, сай ерымны, тар күперне яктыртырга ярап тора инде».*

Атамалары составында кулланылган, яисә аерым елга исемнәре булып йөргән *ор* компонентын да шушы ояда карыйбыз. *Ор* компоненты белән төрки халыклар, аерым алганда, татарлар яши торган төбәкләрдә географик атамалар шактый күп: Арча районында Ашыт елгасының уң кушылдыгы *Оры* атамасы алган. Балтач районында Шушма елгасының уң кушылдыгы –

*Ор суы* ага. Арча районында *Югары Оры, Түбән Оры* авыллары, Балтач районында *Ор* авылы бар.

Алтай төркиләре – шорлар *ора* терминын «озын чокыр»ны атау өчен кулланалар. Бу халыклар көн иткән җирлектә *Ораш* атамасы алган елга ага *(ора* – «елга», «чокыр» + *ш* – кечерәйткеч кушымча: Бонюхов, 1972: 7). Хакас телендә *ор* – «ерту», «казу». Төрекмәннәрдә һәм Мәхмүт Кашгари сүзлегендә *уры/ уру* – «ашлык саклау өчен ясалган чокыр» (кыргыз, казак, каракалпак телендә *ор* – «канау», «чокыр»; чагыштыр: Перекоп култыгы кырым татарлары телендә *Ор-капу* дип йөртелә һәм ул *ор* «канау» + *капу* «капка» сүзләре кушылып ясалган). Бу терминның югарыда күрсәтелгән мәгънәләренең иң игътибарга лаегы һәм әһәмиятлесе «тирән канау», «тирән озын чокыр», «крепость тирәли казылган канау» (Севортян, 1972: 467).

Татар телендә *үр* термины – «калкулык» мәгънәсен аңлата. Хәзерге үзбәк әдәби телендә *ур (уриш)* топонимнар составында килеп түбәндәге мәгънәләрне аңлата: а) зур булмаган калкулык, кечкенә тау, кашлак, иңкүлек, үзән; б) «чокыр», «текә яр»; в) «үзәнлек», «көтүлек», «утлавык» (Худҗамбердиев, 1974: 12–13). Азәрбайҗан телендә *оруш* – «үзәнлек», «утлавык», «көтүлек». Кыргыз телендә *ер* – «күтәренке урын», төрек телендә *ор* – «күтәренке калку урын, биек урын, ясалган калку урын». Тыва «телендә бу термин – «үзәк, калкулык, үзәнлек, тигезлек» мәгънәләрен аңлата. Үрәнхәй телендә *ор* – «калкулык, түбә, баш, оч, өс» төшенчәләрендә кулланыла. *Үр~ор* терминнарын мансий телендәге *урр* (тунгус) *урэ-урэл* – «таулар», бурятмонгол *ургэлэ* – «күтәренке урын» сүзләре белән чагыштырырга мөмкин.

***Урам***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *урам*ның *беренче мәгънәсе* «исем» дип бирелгән һәм аңлатмасы түбәндәгечә: «Гадәттә ике яклап рәттән тезелеп киткән йортлар арасында җәяүлеләр, атлылар, машиналар һ. б. йөрү өчен булган озынча ачыклык, юл. *Солтан зур-зур атлап урам аша чыкты да тыкрыкка борылды*. Г. Бәширов. *Күп бусагаларны, озын*

*урамнарны таптый торгач, Миңлебикә әби окружной суд йортына барып керде*. К. Нәҗми. // Уртасыннан шундый юл үткән янәшә йортларның ике рәте. *Кире адрес: «Мәскәү» дигән, Аннан язган урамын*. М. Җәлил. // Шундый ике рәтнең йортларында яшәүчеләр. *Бөтен урамны аякка бастыру»*.

*Икенче мәгънәсе*. Сыйфат дип ныгытылган һәм нәрсә аңлатуы түбәндәгечә күрсәтелгән: «Урамдагы, урам хәрәкәтенә бәйле булган, урамга чыга торган. *Урам юлы. Урам фонарьлары. Урам ишеге. Урам капкасыннан кергәч, сул якта түбән, тәбәнәк иске агач өй*. Г. Ибраһимов. // Урамда була торган. *Урам хәрәкәте. Урам тавышы*.

*Өченче мәгънәсе*: «Бинадан тыштагы урын, ачык һава. *Шакир урамга чыккач киң итеп бер сулады*. Г. Минский. *Чәйдән соң Шакир абзый, Сәйфулла һәм Мәдинә өчәү бергә урамга чыктылар*. Ә. Еники» (ТТАС, III: 311).

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *урам* «Шәһәр-авылларда, гадәттә, ике яклап тезелеп киткән йортлар арасындагы ачыклык, юл. Урау сүзеннән килеп чыккан дип уйланыла, ягъни урам сүзенең мәгънәсенә караганда, электтә урамнар ниндидер бер үзәк тирәсен әйләндереп алган божра рәвешендә булганнар дип уйларга мөмкин. Ихтимал, бу шәһәрне саклау максатларын күздә тоткандыр. Мондый түгәрәк урамнар борынгы Мәскәүгә дә хас булган (мәс., Мәскәүнең мәркәзен ураган «Садовое кольцо»). Р. Әхмәтьянов урам сүзен *ор канау, окоп* сүзе белән дә бәйли. Башкорт сөйләшендә бәләкәй урам – ишегалды. // Урам йөртү – электә караклыкта, уйнаш итүдә һ. б. шундый җинаятьләрдә гаепләнгән кешене урам буенча йөртеп мәсхәрә итү.

Фарсы телендә *урам – күчә* (үзбәк телендә дә кергән).

*Урам* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда шактый катнаша: *Дәүләт урамы* – Саба районы Сатыш авылындагы урам атамасы. *Дубрау урамы* – Чүпрәле районы Мочали авылындагы урам. *Дуңгыз атавы урамы* – Аксубай районы Яңа Ибрай авылындагы урам. *Дүртүл урамы* – Аксубай рай-

оны Такталы авылындагы урам атамасы. *Жибидур урамы* – Яшел Үзән районы Олы Карауҗа авылындагы урам атамасы. *Җаппар урамы* – Әтнә районы Олы Әтнә авылында. *Бишалаб урамы* – Тәтеш районы Кече Әтрәч авылының бер урамы атамасы. *Бишбалта урамы* – 1. Саба районы Тенеки, 2. Кама Тамагы районы Яңа Сала авылларындагы урамнар атамасы. *Биш мунча урамы* – Лениногорск районы Сугышлы авылындагы урам атамасы. *Биш өйле урамы* – Әгерҗе районы Салагыш авылындагы урам атамасы. *Биш тай урамы* – Мамадыш районы Түбән Яке авылындагы урам атамасы. *Дүртүл урамы* – Аксубай районы Такталы авылындагы урам атамасы. *Жигули урамы* – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылында. *Бозау очы урамы* – Аксубай районы Яңа Ибрай авылындагы урам атамасы. *Тәңкә урамы* – Мамадыш районы Югары Ушмы авылындагы урам атамасы. *Тегәрҗеп урамы* – 1. Мамадыш районы Баскак, 2. Чирмешән районы Иске Кади, 3. Апас районы Кошман, 4. Саба районы Олы Мәтәскә, 5. Балтач районы Салавыч авылларындагы урамнар атамасы.

*Урам* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында шактый очрый. Фатыйх ага Хөснинең «Йөзек кашы» исемле повестенда авыл урамнарын сагыну болай бирелгән: *«Төн бик әйбәт... Шундый төннәрдә яшь чакны искә төшерәм мин, авыл урамнарында кычкырып җырлап йөрисем килә башлый».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» повестенда *урам* лексик берәмлеге кергән мондый җөмлә бар: *«Алар [Асаф белән Сылу] клуб рәшәткәсе буйлап салынган таш сукмактан түбәнгә – базар урамына таба атладылар, рәшәткә башларыннан үрмәләп чыккан сирень, гөләп агачларының чәнечкеле үсентеләре кызыйның тәнен җәрәхәтләр дип куркып, Асаф койма ягына чыкты».*

Вахит Имамовның «Утлы дала» тарихи романында *урам* лексик берәмлеге матур кулланылган: *«Иң караңгы һәм иң хәтәр төннең дә таңы була бит ул. Безнең урамга да бәйрәм килми калмас».*

***Уран*** – «борынгы төрки» дип ныгытылган һәм аңлатмасы болай: «Яуга чакыру авазы, башкача – оран». Уран формасы «Древнетюркский словарь»га да теркәлгән: «*Көк бөри» болсунгыл уран – «Бүз бүре» уранызбыз булсын. // Дидем: Бу ун уранлу кардәшдәрим...*» Кол Гали. (Бу очракта уранлы/оранлы «сугышчан», «гайрәтле» мәгънәсендә килә.)

***Ура кычкыру*** – бу сүз рус теленә төрки телдән (татардан) кергән дигән фикер яши (*уран* – ярсулы кычкыру, һөҗүмгә чакыру). Р. Әхмәтьянов: «Ура! Сүзе татарча ура (окружай) сүзеннән дигән фикер дә игътибарга лаек (төркиләрнең төп тактикасы – дошманны урау була)» – дип яза. Ләкин аны монгол-татарларның *хура* – «алга» сүзе белән аңлату акылга муафыйк. Шуны да әйтергә кирәк: М. Фасмер үзенең «Этимологический словарь русского языка» дигән хезмәтендә *ура*! сүзен немец телендәге *«hurra»*дан чыгара. Һәрхәлдә, «русское ура» дип, аерым сүзгә хуҗа булуны берничек тә аңлап булмый. Даулашкан очракта исә Евразиядә *ура* сүзе беренче нәүбәттә татар исемен саклап калган милләткә тиешле».

***Урман***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә урман сүзе исем дип «шактый зур урын алып, тоташ күп булып үсеп утырган агачлар төркеме, шулай ук күп булып агачлар үскән мәйдан» мәгънәсен белдерүе билгеләнгән. *Урман әле ялангач, ләкин ачылып килә торган яшел бөреләрдән тәмле исләр аңкый.* И. Гази. *Төнге караңгы җил агач башларын дулкынлата-дулкынлата урман өстеннән әллә кая ашыга.* Һ. Такташ. (ТТАС, III: 314).

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда: «Урта Казансу һәм аның кушылдыклары тирә-юнендә *урман җыены,* икенче атамасы *урман җыигү* үткәрелгән. Бу җыенны май ахырында Чиканас, Иске Кырлай, Субаш-Аты авыллары халкы бергә җыелып күңел ачкан».

*Урман* сүзе белән республикабызда байтак атамалар ясалган: *Урман асты кизләве* – Апас районындагы Борнаш авылы яныннан ага торган Инеш ярындагы кизләү. *Урман юлы* – Баулы

районында Исергәп авылыннан урманга бара торган юл. *Урман елгасы* – Арча районындагы Гөберчәк авылы янында, Кесмәс елгасы бассейнында; Чистай районы Татар Ялтаны авылында, Кече Чирмешән елгасы кушылдыгы; Кама Тамагы районының Чаллы авылы янында, Коры Үләмә суы бассейнында. *Алга урманлыгы* – Чистай районы Татар Ялтаны авылы янындагы урманлык атамасы. *Алгы урман чокыры* – Апас районы Иске Әнәле авылы янында. *Урман авызы болыны* – Тәтеш районы Олы Тархан авылы янындагы болын атамасы. *Урман авызы* – Тәтеш районы Олы Тархан авылы янындагы урын атамасы. *Урман асты* – Апас районы Борнаш авылы янындагы җир атамасы. *Урман эче чишмәсе* – Чирмешән районы Яңа Кади авылы янындагы чишмә. *Урман канавы* – Балтач районы Норма авылы янындагы урын атамасы. *Урман коесы* – Апас районы Дүртөйле авылында, Олы Үләмә елгасы бассейнында. *Урман чишмәсе* – Биектау районы Зур Кавал авылы янындагы чишмә һ. б.

Вахит Имамовның «Утлы дала» романында *урман* лексик берәмлеге еш кулланыла. *«Нәүкәрләр Болгар урманнарында йөзәрләгән читән коймалар, биек баскыч, күчмә манаралар әзерләгән иде. Манараларын тыштагы ур өстенә мендереп тезгәч, Биләр каласы тәмугътан калыккан урман боҗрасында калган кебек булды».*

Роза Хәбибуллина «Мулла килене» романында *урман* лексик берәмлеген аның игелеген күрсәтү өчен матур куллана: *«Тормышлары гел Робинзон Крузоныкы кебек: мең еллар буе сөрелмәгән урман туфрагына утырткан бәрәңге дә, яшелчәләр дә, куандырып, искитмәле уңыш бирде. Болардан тыш үзләре утыртмаган-чәчмәгән байлыкны урман бирде. Җәй көне җир җиләге, кара җиләк, көзгә кергәч, беренче мәртәбә мүк җиләге җыйды Зәйнәп. Очсыз-кырыйсыз урманда берүзең йөрү куркыныч иде».*

***Утар*** термины «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе дә аңлатылган. *Беренче мәгънәсе*: «Терлекләрне һавада тотар өчен ферма ихатасында

киртә белән уратып алынган урын. *Алар янәшә атлап үзәк ферма утарына таба юнәлделәр.* М. Хәсәнов. *Абзардан барлык сыерларны утарга чыгарганнар*. Ә. Еники».

*Икенче мәгънәсе:* «Гадәттә бай йорт-каралтылары булган алпавыт җире, biләмәсе. *Сукачылар, алпавыт утарыннан бу якка таба җилдерткән атларга текәлеп, бер урында катып калдылар*. И. Гази» (ТТАС, III: 321).

*Утар* лексик берәмлеге борынгы заманнардан ук уздырыла торган җыен атамаларында да кулланыла. Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, «Урта Казансу һәм аның кушылдыклары тирә-юнендә *Утар-Аты җыены* үткәрелгән. Май башында аны Утар-Аты халкы үзе генә бәйрәм иткән».

*Утар* лексик берәмлегенең «Татар теленең зур диалектик сүзлеген»дә 4 мәгънәсе бирелә. *Беренче мәгънәсе:* минзәлә, Түбән Кама керәшеннәре, Оренбург өлкәсендәге каргалы, стәрлетамак сөйләшләрендә аерым кешеләрнең йортында терлек ябу өчен киртә яки читән белән тотып алынып, өсте ачык яки ябык булган урын (открытый или закрытый загон для скота во дворе; карда). *Абзарларына, утарга кереп салам алып чыгалар икән. Утарның йартысы түшәмне була торганыйы, салам тутырырга* – минзәлә сөйләшендә. *Мин тептә берүзем. Хәйреттин утарына барып җиттем.* – Оренбург Каргалысы халкы сөйләшендә очрый. *Утарлары урынына мунча салганнар.* – Түбән Кама керәшеннәре сөйләше.

*Икенче мәгънәсе:* мамадыш, минзәлә, нагайбәк керәшеннәре телендә колхозның фермалары янында вакытлыча терлек ябып тоту өчен киртәләр белән әйләндереп алынган ачык яки ябык урын, ферма каралтылары (открытый или закрытый загон для скота на колхозной ферме). *Утарларны җылда тазарталар ыйы, быйел җуг әле.* – мамадыш сөйләше. *Калхузның утары йабык булмый. Сыйырларны фермы янында саwалар да утарга җибәрәләр.* – минзәлә сөйләше.

*Өченче мәгънәсе:* минзәлә сөйләшендә иген чәчү өчен уратып алынган җир (загороженное место для посева).

*Дүртенче мәгънәсе:* чүпрәле сөйләше, к.: *мурталык* (ТТЗДС, 2009: 686).

Адлер Тимергалин җыеп, төзеп дөньяга чыгарган «Миллият сүзлеге»ндә *утар* лексик берәмлеге түбәндәгечә сыйфатланган: «Утар сүзе төрки телләрдә киртәләнеп алынган көтүлек, яшел үләнле болын, көтүчесез көтү» мәгънәсенә ия. Русча хутор һәм отара (ачык далада җәйләүче зур сарык көтүе) сүзләре дә шушы утар сүзеннән (Р. Әхмәтьянов). Электә утарлар шәһәр чикләрендә дә булган (мәс., Казанда Шакир солдат утары). Тагын кара: *Утак; Хутор»*.

*«Утак* – тар. Чатыр, куыш, тирмә, корбаг (бор.). Утар мәгънәсенә дә ия булса кирәк. Фарсы теле сүзлегендә «палата, камера» мәгънәсендә очрады. Тагын кара: *Утә, Ута*».

*Утә, ута* – «искергән сүз дип ныгытылган, аңлатмасы: «Бүлмә; номер (кунакханәдә)». Бу сүз борынгы төркичәдәге *отаг* – тирмә, чатыр, палатка, торак сүзеннән килә. Төрек телендә *утак* – тирмә, палатка. Охшаш сүзләр башка төрки телләрдә дә күзәтелә. Гомумән, бу сүзне *ут* һәм *учак* сүзләренә бәйлиләр. Димәк, русча *очаг* сүзе белән дә бәгланыш ачыла. Ихтимал, рус телендәге *хата* сүзе дә төптә шушы *ута* белән кардәш булыр (көньяк-көнбатыштан килгән *хата* сүзенең аерым сөйләшләрендә «бүлмә» мәгънәсенә ия булуын В. Даль дә күрсәтеп яза). //*Утаг, бутаг, Уртасында сарыг йанъ*. Табышмак (җавабы – кавын). Тагын кара: *Учак*».

*Учак* термины Адлер Тимергалин җыеп, төзеп чыгарган «Миллият сүзлеге»н дә мондый аңлатма алган. *Беренче мәгънәсе*: Гомумтөркидә – мич, таган; чыртан, калау (диал.). Мәхмүд Кашгари сүзлегендә *оч* рәвешендә теркәлгән. Этимологиясе *ут* сүзенә барып тоташа (мәс., чуваш телендә дә *учак, вучак* сүзе *вут – ут* сүзе белән баглы). Аерым төрки телләрдәге *отаг* (тирмә, юрта, чатыр, куыш, палатка, торак) сүзе дә «ут яга торган урын» мәгънәсендә. Русча – костёр. Электә *казан асу* – «учак ягып ашарга пешерү» мәгънәсенә ия булган. Хәзер авыл мичләрендә мич белән янәшә казан астына ягыла торган урын-

ны *учак* диләр. Бу сүз рус теленә *очаг* рәвешендә кергән (*домашний очаг, родной очаг,* шулай ук «туган йорт» мәгънәсендә).

*Икенче мәгънәсе*: Иске татар әдәбиятында – шахта, рудник, мәгъдән чыганагы; мәркәз. // *Сугыш учагы. Гаилә учагы. Мәдәният учагы.*

*Өченче мәгънәсе*: Электә җинаятьче муенына кыздырылган хәлдә кидерелә торган коршау, суынгач аны баш аркылы салып ташлый алмаганнар (Р. Әхмәтьянов буенча).

Галимҗан Шәрәфнең *учак* сүзен «җыелып сөйләшә торган урын, түгәрәк, даирә, хилка» мәгънәсендә кулланган очрак бар. // *Бу җентекләү иптәшләр учагы өчен язылган иде* (автор Зәки Вәлидинең Казанда нәшер ителгән китабы турында 1916 елда «Шура» журналында басылган «Төрек-татар тарихи» исемле тәфтишле рецензиясен күздә тота).

*Утар* термины географик атамалар ясауда шактый актив кулланыла. Бу лексик берәмлек Нурулла Гарифның әйтеп үтелгән хезмәтендә дә еш очрый:

*«Кече, Арткы Утар* авылы – алпавыт авылы, Нугай юлы өстендәге Глухой исеме алган күл янында, хәзерге вакытта ул Утар (рус. Отары) бистәсе карамагында (Казан шәһәрендә).

Атары Трои (*Өч Утар авылы*), Нугай юлы өстендәге алпавыт авылы, Озын күл янында. Хәзерге вакытта ул Казанның *Отары (Утар)* бистәсе карамагында. Атары Средние (*Урта Утар авылы*), Нугай юлы өстендәге алпавыт авылы, Озын күл янында. Хәзерге вакытта ул Казанның *Отары (Утар)* бистәсе карамагында».

*Утар як басу* – Саба районы Кызыл Мишә авылы янындагы басу атамасы. *Утар йулы* – Саба районы Олыяз авылы янындагы юл атамасы. *Утар йылгасы кизләве* – Утар елгасы бассейны. Апас районы Чүти авылы янында. *Утар очы* – Арча районы Иске Му авылындагы урам атамасы. Утар авылына китә торган урам. *Утар чокыры* – Алексеев районы Әшнәк авылы янындагы чокыр атамасы. *Утар чишмәсе* – 1. Балтач районы Арбор/Урбар авылы янында; 2. Йугары Кандыз елгасы бассейнында.

Баулы районы Яңа Шалты авылы янындагы чишмә. *Утар урманы* – Саба районы Көек авылы янындагы урман атамасы. *Утар елгасы* – 1. Аты елгасы бассейны. Арча районы Урта Аты авылы Арча районында; 2. Гөбенә суы бассейны. Апас районы Чүти авылы янында; 3. Калмийә елгасы бассейны. Мөслим районы Иске Карамалы авылы янында; 4. Мәүләшә елгасы бассейны. Әлки районы Иске Алпар янындагы утар; 5. Ушмы суы кушылдыгы. Мамадыш районы Югары Ушмы авылы янындагы елга; 6. Мичән елгасы бассейны. Саба районы Курсабаш авылы янындагы елга.

*Утар* лексик берәмлеге әдипләребез иҗатында кулланыла. Вахит Имамовның «Утлы дала» исемендәге тарихи романында *утар* термины еш очрый. *«Әнә ул [Хәмбәл] инде сәфәрнең тәүге көнендә үк Чирмешән янындагы Шәрбән кальгасы белән Исмәгыйль авылын җимереп узган, әллә ничә утарларны нигезенә тиклем яндырган». «Аның акбүз аты гына, утар тарлыгыннан котылу шатлыгын тоеп, әледән-әле уйнаклап ала, саф алтыннан коеп ясалган очлам түбәсен бизәүче өч тавис каурые да вакытлыча җанлангандай була».*

***Утрау***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу термин «исем» дип бирелгән һәм ул болай ныгытылган: «Һәр ягыннан да су уратып алган коры җир. *Олы Шырдан үрен менгәч тә, диңгез уртасындагы биек утрауга салынган Зөя шәһәре күренде*. М. Гали. *Диңгез эчендә утрау бар, аның өстендә кала*. Дәрдемәнд. // Күчерелмә мәгънәсе. Тирә-юньдәгеләрдән читтә, аерылып торган нәрсә турында. *Казан вокзалында Мәскәүгә китүче «Татарстан» поездын озатырга төшкән йөзләгән халык арасында алар аерым утрау булып басып торалар иде*. А. Гыйләҗев (ТТАС, III: 322).

*Утрау* сүзе географик берәмлекләр ясауда шактый очрый. *Утрау* Лениногорск районы Ормышлы авылындагы кыр атамасы.

Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда*, атрау, отрау, утрау,* нигездә, топонимиядә сакланып калган иске термин.

Татар халкы телендә ул *утрау* дип йөртелә. Бу терминның таралыш ареалы бик киң. Түмән өлкәсендә яшәүче татарлар телендә дә ул *утрау* «урмансыман кечкенә агачлык», дип кулланыла. Каспий диңгезенең төньяк-көнчыгыш яктагы полоса-җирлеген һәм Каспий диңгезен дә җирле халык исәпләнгән казаклар *Атрау* дип атый. Элекке вакытларда Балхаш күле *Атрау-Күл* дип йөртелгән. Казакстандагы, яр кырыйлары сары төстәге һәм бормалы булган *Сарыесик-атырау* исеме алган ком массивы атамасын казак галиме Г.К. Конкашпаев «*есик* «ишек» һәм «үтеп китә торган урын (проход)» дип аңлата. Е. Койчубаев исә бу атаманы мәгънә үзгәреше кичергән дип уйлый һәм «*сары* + *ич (эч)* + *жак* (?)» сүзләре кушылып «киң эчке өлеш», ягъни Балхаш күле яр буеның бер өлеше дип карый.

***Үзәк***. Әдәби телдә бу сүзнең географиядә сакланган мәгънәсе: үзәкләнеп агу – уртадан гына агу (елга турында: ТТАС, III: 726). Борынгы төрки телдә – *ozuk* II. *ozuk suv* – «кечкенә су чыганагы» (ДТС, 1969: 395). В. Радлов сүзлегендә алтай, телеут телләрендә *өзөк* – «елга», кыргыз телендә ул *ос+ак* рәвешле ясалган һәм «үзән» мәгънәсендә кулланылган дип теркәлгән (т. I, Ч. 2: 1302). Татар телендә элек *үзәк* сүзе «елга, коры елга, чокыр» төшенчәсендә йөргән. Бу термин белән ясалган атама тарихи чыганакларда теркәлеп калган. Казан янындагы *Тирән үзәк* – Идел кушылдыгы. Тарихи чыганаклардан билгеле булганча, Явыз Иван Казанны *Тирән үзәк* (ягъни Тирән елга) ягыннан килеп, штурм белән алган (История. 1937: 120). Бу су чыганагы (елга) теркәү кенәгәсенә теркәлгән: «...меж Волги и Терсузака от протопоповских покосов от кривые заводи с верхние взголови по р. Терсузик и по тереузецкое устье...» (Невоструев, 1977: 99). Билгеле булганча, теркәү кенәгәләрендә географик атамалар бозылып язылганнар. Монда сүз, әлбәттә, *Тирән үзәк* елгасы турында бара. Үзәк компонентын алып ясалган атамалар Татарстанда һәм аннан читтә яшәгән татарлар телендә һәм, гомумән, төрки халыклар телендә шактый күп кулланыла.

*Тирән үзәк* – Арча районындагы Олы Мәңгәр авылында коры елга, печән үсә торган болын. *Камышлы үзәк* – Апас районының Багыш авылында Чирмешән елгасы кушылдыгы. *Камышлы үзәк* ярында шул ук исемдәге кизләү дә бар. Кайбыч районының Олы Кайбыч авылында *Камышлы үзәге чокыры* (Бәрле кушылдыгы) билгеләнгән. Бакырчы авылы буенда Шайтан суының кушылдыгы булган *Тирән үзәк елгасы* (Чирмешән бассейны) ага (Апас районы). *Карамалы үзәк* – Олы Урсак авылы басуында Имәнле елгасы кушылдыгы. Аның янында Карамалы үзәк кизләве дә бар. *Тирән үзәк, Сай үзәк* – Кече Күккүз авылы елгалары (Апас районы). Бу мисалларда *үзәк* терминының элек «елга» мәгънәсендә кулланылганлыгы күренә. Димәк, *үзәк* сүзе элек-электән халык телендә «елга», «су» мәгънәсендә кулланылган һәм югарыда саналган гидронимнарда элекке мәгънәсе белән ныгып та калган. *Киртәле үзәк* – Апас районы Чүти авылы янында Гөбенә елгасына кушыла. *Камыш үзәк кизләве* – Апас районы Дәвеш авылында. *Камыш үзәк чокыры* – Апас районы Дәвеш авылы янындагы коры елга атамасы. *Үзәк суы* – Актаныш районы Кәзкәй авылы янындагы елга. *Аю үлгән үзәк* – Апас районы Олы Урсак авылы яныннан агып үтә торган Имәлле суы кушылдыгы. *Камышлы үзәк* – Апас районы Багыш авылы янында Чирмешәнгә кушыла. *Арткы үзәк* – Апас районы Чәтбаш авылы янында Бола елгасына кушыла.

*Үзәк* компоненты белән Татарстанда түбәндәге микротопонимнар язып алынды: Яшел Үзән районының Күгеш авылында район үзәген исеме белән атамыйлар, ә *Үзәк* дип кенә йөртәләр, Буа районының Яңа Чәчкаб авылында *Үзәк* – урын исеме, Азнакай районының Әлкәй авылында *Үзәк киртә юлы* – юл атамасы.

Башкортстанда *үзәк* сүзе белән түбәндәге елга һәм авыл атамалары бар: Хәйбулла районында Сакмар суының сул кушылдыгы *Таллы үзәк* елгасы ага. Шул ук районда *Тирән үзәк* – Ташлы елгасының сул кушылдыгы. Башкортстанда Җалаер районында *Камышүзәк, Чуртанүзәк* авыллары, Хәйбулла районында *Татырүзәк* авылы бар. Чиләбе өлкәсендә *Сарыүзәк*

елгасы ага. Самара өлкәсендәге Ставрополь районында *Узюково* авылы бар. Ул, удел авылы буларак, XVIII гасырның беренче яртысында барлыкка килгән. Җирле халык хәтерендәге риваятькә караганда, «монда элек мордвалар килеп, авылның бер очына урнашканнар. Алар Буян, Узюк һәм Бинарад исемле туганнар булганнар. Алардан Иске Буян, Яңа Буян, Узюк, Иске Бинарад һәм Яңа Бинарад авыллары барлыкка килгән». «Топоним нигезендә кеше исемен инкяр итмичә, – дип язалар Барашков һәм Дубман, – Узюк авылы янында элек атамасы төрки булган Узек (Узюк) елгасы аккан һәм гидроним үз исемен авылга биргән булуы бик ихтимал. Төрки телләрдә һәм кайбер рус сөйләшләрендә күмәклек исем *үзәк* «елганың иске юлы, ерик» мәгънәсендә йөргән» (Барашков, Дубман, 1996: 173).

Каракалпак һәм алтай телләрендә *өзек* термины «елга, инеш» мәгънәсендә йөргән. Составларында *озек//öзек* компонентларын алган, җәен кибә торган дала елгалары Казакстанда «ермак, зур булмаган үзән» мәгънәсен аңлаткан (Конкашпаев, 1963: 138). Бу терминның төрки телләрдәге мәгънәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) үзән, кечкенә сусыз үзән; 2) ерганак, чокыр, сикәлтә; 3) күлне хәтерләтә торган су җыелган кыр; 4) диңгез тавышы, диңгез шаулавы. *Өзек* сүзе «чыганак» төшенчәсендә кулланыла торган *өз* сүзенә *-а(к)* кушымчасы ялгану юлы белән ясалган (Севортян, 1974: 510).

Н.А. Баскаков фикеренчә, *өзек – өзөк* термины борынгы уйгыр телендәге *угус* сүзенә *-ек* кечерәйтү, иркәләү кушымчасы ялгану юлы белән ясалган, ягъни, үзгәреш нәтиҗәсендә, *ўгўс + ек > ўўзек> оозек> ўзек* төрдәшләрен кичергән, *угус* сүзе шул ук телдәге *угу* һәм *су* сүзе белән бәйләнгән (Баскаков, 1969: 65).

Алтай телендә *озёк* – «инеш, кечкенә елга, үзән, тау үзәне». Майма елгасы кушылдыгы *Кызылозёк* һәм шундый ук исематама алган торак пункт бар. Бу термин *озен/öзöн* вариантлары белән параллель рәвештә кулланыла. Мәсәлән, *Тойозен* – Сумультин кабыргасындагы таулардагы үзән (Розен, Малолетко, 1986: 64). А.М. Малолетко фикеренчә, *озек* форманты белән

ясалган гидронимнар шактый күп һәм ул түбәндәге мисалларны китерә: Алтайда – *Кок-үзек,* ул Чуй елгасына тоташа; Башкаус елгасы системасында үтүе кыен булган елга мәгънәсен алган *Бертозек* гидронимы; Таулы Алтай янындагы *Кызылозек,* Аргут елгасы системасындагы *Ак-узюк;* Иж елгасы системасындагы Чепша елгасының уң кушылдыгы *Узек* һ. б. Урта Азиядә, Кызыл-Орда шәһәреннән түбәндәрәк, Сыр-Дәрьяның бер кушылдыгы *Караозек* исемен алган һәм Тирән ермак мәгънәсен белдергән *Тирән-озек* торак пункты бар. Көнбатыш Казакстанда «ачы елга» төшенчәсен аңлаткан *Ощиозек* елгасы ага (Малолетко, 1992: 81).

*Үзәк* сүзе белән ясалган атамалар элек төрки халыклар яшәгән урыннарда да очрый. Мәсәлән, Украинадагы Терна елгасының су кушылдыгы – *Озак*. *Курган-Озак* авылы атамасының өлешләре төрки телдән кергән алынмалар дип карала. Бу – галим О.С. Стрижак фикере (1965, 258). *Озек, öзöк* терминнары белән ясалган атамаларның таралыш ареалларын Э.М. Мурзаев тикшергән (1984: 406–407).

***Үзән***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *үзән* сүзенең ике мәгънәсе бирелгән: 1. Елга яры буендагы уйсу җир. *Тиздән үзәннәрдә, елгаларда Гөрләр яз җыры*. Г. Хуҗи. *Кояшның беренче нурлары үрләргә, томанлы үзәннәргә, күлләргә төште.* Г. Әпсәләмов. // Таулар яки калкулыклар арасындагы озынча җир. *Кереп киттек таулар арасына, Кергән саен, үзән тарая*. Ш. Маннур. *Авыл яныннан башланып, калкулыкның уң ягыннан узып киткән үзәнне [Нуруллин] бик җентекләп ике мәртәбә карап чыкты*. А. Шамов; 2. Су юлы, су аккан эз. *Йомшак йонлы кара пустау киеп, ята әле чиксез басулар, Үзәннәрдә әле, шау-гөр килеп, җемелдиләр язгы ташулар.* Ә. Исхак (ТТАС, 1981: 725).

*Үзәнлек* термины «исем» дип ныгытылган. *Беренче мәгънәсе*: үзәне булган урын, түбәнлек, иңкүлек җир. *Казанка үзәнлегендә, Идел буйларында, Аккош урманнарында көннәрнең озакка утыруын белдереп, иртән-кич җиңел ак томан йөзә.*

Г. Әпсәләмов. *Яшьләр, парлашып, ындырлар артына – елга буена, үзәнлеккә төшеп китәләр.* Ә. Айдар. *Икенче мәгънәсе.* Дымны яңгыр һәм кар суларыннан гына алучы сусыз болын, иңкүлек. *Әнә, урманнан ерак түгел, җәелеп киткән киң үзәнлектә тигез генә урамнары, ферма каралтылары белән зур гына авыл... күренә.* Г. Минский.

*Үзәнләнү* (географик мәгънәле фигыль) – түбәнлеккә, иңкүлеккә, болынга әйләнү.

*Үзәнсу*: үзәнсу җир – түбәнлек, уйсу урын. *[Гөлсем] бодай җирен, күзгә чалынырдай һәр үзәнсу урынына, һәр калкуына кадәр җентекләп күздән кичерде.* Г. Бәширов.

Югарыда әйтелгәнчә, *үзән* сүзе элек «елга» мәгънәсендә кулланылган, ә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә ул «су юлы, су аккан эз» дип бирелә, димәк, бу сүз әле дә «елга»ны аңлата. *Үзән* термины үзе генә дә географик атама булып кулланыла ала һәм атамалар составына да керергә мөмкин. *Үзән* – Апас районының Тутай авылы тирәсендә, Бола елгасы бассейнында урнашкан урын атамасы. *Үзән асты елгасы* – Мамадыш районындагы Тулбай авылы янында, Шия елгасы бассейнында. *Үзән болыны* – Яшел Үзән районының Бишнә авылы янындагы болын атамасы. *Үзән күле* – Апас районындагы Дәвеш авылы янында, Зөя бассейнында. *Үзән сигез* – Яшел Үзән районының Мулла Иле авылы янындагы чалу атамасы. *Олы үзән* – Саба районының Кырбаш авылы янындагы үзән; Апас районының Югары Балтай авылы янында, Чирмешән елгасы бассейнында. *Мәмәтәй үзәне* – Балтач районының Арбаш авылы янында, Арбаш елгасы бассейнында. *Билле үзән* – Апас районының Түбән Балтай авылы янында. *Таншырмә үзәне* – Арча районындагы Наласа авылы янындагы Наласа инеше бассейнында. *Таллык үзән* – Саба районындагы Явлаштау авылы янындагы үзән атамасы, *Таллык үзән елгасы* – Саба районы Явлаштау авылы яныннан агып үтә торган елга, Кече Мишә елгасы бассейнында. *Күллек үзәне* – Балтач районы Нөнәгәр авылы янындагы үзәнлек атамасы. *Күл урыны үзәне* – Балтач районы

Пүскән авылы янындагы үзәнлек атамасы. *Чирмеш үзәнлеге* – Балтач районы Янгул авылы янындагы үзәнлек атамасы.

*Үзән* сүзе Татарстан микротопонимнары арасында да шактый очрый: *Үзән тавы, Үзән тугае, Үзән каенлыгы, Үзән урманы* һ.б.

Көнбатыш диалектның темников, кузнецки, хвалын сөйләшләрендә дә *үзән* һәм тарлавыклар «елга» дип йөртеләләр (ТТДС, 1969: 178).

Г.Ф. Саттаров *өзән* – үзән сүзенең *«җан + җан»* тезмәсеннән торуын күрсәтә. «Елга» төшенчәсе берсендә *өз – үз,* икенчесендә *өн – ән* сүзе белән белдерелгән ике кардәш кабиләнең бергә кушылуыннан барлыкка килгән контаминацион topoлексема, ди галим. Татар антропонимиясендә очрый торган *Өзәнбай* исеме – *Елгабай* дип аңлатыла. Борынгы заманда ул, *өзән~үзән* (елга) буенда туган ир балага йола белән нисбәтле рәвештә кушылган исем буларак кулланылып, Казан татарларында *Өзәнбаев* фамилиясендә сакланган (Саттаров, 1972: 54– 55).

*Үзән* сүзе елга атамасы буларак Г. Ибраһимов иҗатында кулланыла. Аның «Татар хатыны ниләр күрми» дигән повестенда *үзән елга* болай сыйфатлана: *«Үзән елга якты кояш астында көньяктан төньякка таба ялтырап ага ага да алдына каршы чыккан ташлы тауларга барып бәреләә, бу киң биек ташларны үтеп чыга алмагач, кинәт кояш баешы ягына таба борыла да китә. Агым буенча сул ягында киң сазлыклар, тугайлар, болыннар, бай печәнлекләр тудыра, алар эчендә таллар үстерә, киң, зур, якты күлләр ясый; уң ягыннан баскычланып-баскычланып тауның биек ак ярлары йөгерәләр-йөгерәләр дә, бу ак ташлар, елганың тирән ятуларыннан берсе турында кинәт тукталып, текә стена белән су өстенә асылалар. Моны үткәч, ташлар бетә, зур тау елгадан эчкә таба, сөзәкләнеп кереп, менә-менә дә куе урманга барып терәлә».*

Гомәр аганың «Җидегән чишмә» романында *үзән* лексик берәмлеге кулланыла. *«Бригадир да, үз каршысында салмак кына чайкалгалап баручы йөз тонналы бу гигант манараның*

*үзән чыкканда күпмегә авышуын, кырын-ярын урыннан узганда кайсы арканның артык чигенә кадәр тартылуын, кайсы тракторның җир тырнап үкерүен колагы белән ишетеп, күзе белән күреп кенә калмый, нәкъ дирижердай, бөтен тәне белән тоядыр».*

Мөхәммәт ага Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә (истәлекләр)» исеме алган китабында *үзән* сүзе шактый очрый: «*Инде хәтәр холыклы кешеләр яшәгән Мөрәлене дә чыктык, алда әле ике үзән бар, буран да кыюланды».* Шул ук авторның «Без – кырык беренче ел балалары» исеме алган повестенда *үзәнлек* лексик берәмлегe кулланыла: *«Сугышка кадәр аяк йөзеннән үскән печән үзәнлекләрдә хәзер билдән».*

Вахит Имамовның «Сәет батыр» дип аталган тарихи повестенда *үзән, үзәнлек* лексик берәмлекләре еш очрый. *«1707 елның сентябрь уртасында Агыйдел һәм Бәрсуан елгалары кушылган үзәнлек кабат баштанаяк коралланган ирләр, иярләнгән атлар белән тулды».* Шул ук авторның «Утлы дала» романында *үзәнлек* термины еш кабатлана: *«Зур табаны хәтерләткән үзәнлек тип-тигез кыр булып күренсә дә, аны кечкенәрәк өчме-дүртме елга кисеп үткән». «Соңгысында да үзе белән җиде-сигезгенә ирне алып, Сары Айгыр үзәнлегенә таба сунарлыкка китте».*

Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» дип аталган романында географик атамалар ясауда кулланыла торган терминнар, шул исәптән *үзән-үзәнлек* лексик берәмлеге дә еш очрый: *«Аста, алар (таулар) арасында, киң үзәнлекләр, тирән елгалар, эреле-ваклы авыллар».*

Төрки халыкларда *үзән* сүзе түбәндәге мәгънәләренә ия: кыргызлардагы *өзөн,* казакча *өзен,* уйгыр телендәге *өзән* – «кушылдык»; якутча – *урех* һәм кумыклардагы *өзен* – «елга»: урянхай телендәге *озан* – «елга дуены» .

*Үзән* сүзе кергән географик атамалар Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә шактый күп очрый. Башкортстан гидронимиясендә: Белорец, Бөрҗән районнарында *Үзән* – Агыйделнең сул

кушылдыгы; *Ерүзән* – Салават, Дуван, Караидел районы җирләреннән агып Уфа елгасына сул яктан килеп кушыла. *Чиләбе* өлкәсе җирләреннән *Ерүзән* елгасы агып уза.

Башкортстанда *үзән* сүзе түбәндәге авыл атамаларында кулланыла: Караидел районында *Юрүзән* бистәсе (поселогы), Бүздәк һәм Белорецки районнарында *Үзәнбаш* авылы һәм бистәсе, Авыргазы районындагы *Үзәнбаш* авылының икенче исеме Ибрай һ. б. Пенза өлкәсендә *Ерүзән* һәм *Әләзән* авыллары бар. Шунысы игътибарга лаек, элек төрки халыклар Днепр елгасын *Özü, Üzü* дип атаганнар.

В.В. Радлов *өзен* сүзенең казак, бараба татарларында, кара-кыргызларда *өзөн, үзен, өсән, өсендү*нең «елга, елгачык, агым, тиз ага торган» төшенчәләрендә йөрүен теркәгән (т. I, Ч. 2: 1293, 1303, 1893). Э. В. Севортян сүзлегендә бу термин: 1) агым; 2) елга юлы; 3) уйсулык, уйсу җир, тар сай чокыр, ялпылык; 4) кечкенә тарлавык; 5) елга уртасындагы коры җир берәмлеге; 6) дала мәгънәләрендә кулланыла (Севортян, 1974: 510–511).

Урта Идел буендагы *Олы Үзән* һәм *Кече Үзән* елгалары Саратов һәм Урал өлкәләренең җирләре аша ага. В. Семенов Самара җирләрендә *Яңа Үзән* өязен һәм шул ук исемдә өяз үзәген билгеләгән, бу өяз җирләренең борынгы татар истәлекләренә бик бай булуы хакында язган. 1627 елда төзелгән «Книга Большому Чертежу» хезмәтендә Идел бассейнында Самара тирәләрендә *Үзән, Кече Үзән, Агач Үзән* (Узень Деревянная) елгалары теркәлгән (Книга, 1950: 143, 144). Кырым топониямисендә үзән компоненты белән түбәндәге атамалар теркәлгән: *Кара-Ёзень, Куру-Озень, Кара-Узень, Орта-Узень, Биюк-Узень, Болгар-Узень, Кабоплу-Узень, Озенбаш, Узенбаш, Кучук-Узенбаш, Биюк Узенбаш, Чамлы Узенбаш, Тут-Терек-Ёзин, Кючюк-Ёзен, Махаил-Ёзен, Биюк-Деренын-Ёзен, Улу-Ёзен, Чардах-Ёзен, Казыклы-Ёзен, Кокаузен, Курузен* һ. б. Казакстандагы Мангышлак өлкәсенең *Яңа Үзән* шәһәр хакимиятенә керә торган *Үзән бистәсе* барлыгы мәгълүм.

Госманлы төрекләре дәверендә *Днепр* (ә ул, югарыда күрсәтелгәнчә, төркиләр тарафыннан *Osu (үзән)* дип аталган) ярында *Озю (Үзән)* кальгасы төзелгән. Ул шул ук исемдәге вилаятьнең башкаласы булып торган. *Үзән* елгасының *Азуглы (Узуглы) Үзән* дип аталган кушылдыгы да бар. П. Семенов фикеренчә, Днепр елгасындагы Березань утравы атамасы *Бүре Үзән ада* сүзеннән килеп чыккан. Ука суы бассейнында очрый торган Березан атамасы да шушы нисбәттә карала ала. *Үзән* сүзе Кырымдагы елга атамалары составында да очрый. Топонимистлар аны төрки *үзән* сүзе белән бәйләп карыйлар. Э.М. Мурзаев мәгълүматларына караганда, «үзән» термины кергән атамаларның таралыш даирәсе бик киң (Мурзаев, 1984: 407).

***Үр***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *үр* терминының берничә мәгънәсе китерелгән. 1. Әйләнә-тирә белән чагыштырганда биегрәк булган, сөзәкләнеп яки текәрәк менгән урын, калкулык. *Үр өстенә күтәрелгән чакта, якты болытлар җирлегендә (сугышчыларның) шәүләләре күренеп кала да, иңкелгә төшкәч, тагын күренмәс булалар*. Г. Бәширов. *Әби белән [Рифгать] чананы җилтерәтеп алып киттеләр. Бары тик үргә менеп җиткәч кенә туктадылар*. А. Әхмәт; 2. Нәрсәнең дә булса югары ягы. *[Зыя белән Гөлсем] киенеп чыктылар да урам буйлап үргә таба менеп киттеләр*. Г. Ибраһимов. *Су үргә акмас. Мәкаль.//Гомумән өске, югары як. [Шәрәф] артына әйләнеп карамый, күктән килгән тавышны тыңлагандай, башын үргә күтәрә.* М. Фәйзи; 3. Күчерелмә мәгънәдә: нинди дә булса эштә күтәрелеш, үсеш, уңыш. *Икмәк фронтында яңа үрләр яулау. Эшең бер үргә китсә, анда инде бөтенесе синең өчен, синең файдага эшли*. Ф. Хөсни.

***Үрге.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек сыйфат дип бирелгән һәм «Берәр нәрсә белән чагыштырганда югарырак булган яки гомумән югарыда, үрдә булган» дип аңлатылган. Мисаллар: *Җәй көне үрге әрәмәдә үткәрелгән вакытлар Мәдинә өчен хәзер күңелле, матур төш шикелле булып калдылар*. Ш. Камал. – *Менә үрге оч Баһау байның Хафизы китте*. М. Гафури.

*Үр, үрге* лексик берәмлекләре белән топонимнар очрый. *Үрге болыны* – Саба районының Иске Җөри авылы янында (бу болын башкаларыннан аермалы буларак үрге, үрле урында, бераз калку җирдә урнашкан. Халык шуңа аны *Үрге* болын дип атый). *Түбә үре* – Кукмара районының Мәмәшир авылы янында (бу үр түбәгә охшаган). *Ишки үре* – Мамадыш районының Югары Ушмы авылы янындагы үр атамасы. *Ваһаб үре* – Биектау районы Әлдермеш авылы янындагы үр атамасы. *Җәлил үре* – Арча районы Казанбаш авылы янындагы урын атамасы. *Йанык үре* – Мамадыш районы Тулбай авылы янындагы урман януга нисбәтле атама. *Ишки үре* – Мамадыш районы Югары Ушмы авылы янындагы үр атамасы.

*Үр* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында да урын алган. Фоат Садриевның «Таң җиле» романында *үр* термины кулланыла: *«Алдагы көнне генә анда көчле яңгыр явып үткән булган. Коточкыч текә үрдән төшкәндә – сул якта урман, уң якта тирән чокыр икән – машина уйнаклый башлаган».*

Вахит Имамовның «Утлы дала» романында *үр* термины еш кулланыла: *«Гази-Бәрәҗ, карак мәче кебек күзләрен ялтыратып, тиз арада үр артына китеп юкка чыкты. Биләр халкы җиңел сулап куйды. Әмма ашыкканнар...» «Бер яулаган үрдән кире төшмиләрдер».*

Айдар Хәлимнең «Кыйбла: хикәяләр, новеллалар» дип исемләнгән китабында *үр* компоненты болай кулланылган: «*Карыннары тук, капчыктан черек бәрәңгеләрнең туңы, җылыдан эреп, арка чокырыннан саркып төшкән үсмерләр, Имәнлек үренә җиткәнче, бу кахулның һичшиксез татар булуы-булмавы турында бәхәсләшеп кайттылар...». «...Үрне төшкәндә, чак-чак кына үлемнән калдылар». ...Балак бете үргә үрләсә, шулай тиләрә ул». «...Үрдәге күпер түбәненнән ташуның икенче дулкыны якынлаша иде».*

***Чабу***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чабу* лексик берәмлеге «фигыль» дип ныгытылган һәм мәгънәсе түбәндәгечә аңлатылган: үлән яки игенне чалгы яки чапкыч машина белән

кистерү, кистереп ташлау. *Печән чабу. Машина белән чабарлык урыннарны машина белән, машина кермәслек җирләрне чалгы белән чабарга булдылар*. Ш. Камал. *Бабайлар колхозның борчагын, ясмыгын чаптылар, уракчылар артыннан зур-зур эскертләр, кибәннәр куя бардылар*. Г. Бәширов (ТТАС, III: 396).

Бу фигыльдән *чабулык, чабын, чабынлык* исемнәре ясалган һәм бу лексик берәмлекләр топонимнар ясауда шактый актив кулланыла. Халык телендә *Чабу җир, Чабулык урын, Чабулыкта безнең урын* дигән гыйбарәләр әле дә кулланылалар.

***Чабулык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чабулык* лексик берәмлеге «исем, сөйләмдә кулланыла, кара: *чабынлык*» дип ныгытылган. Мисалы: *Колхоз чабулыклары* (ТТАС, III: 397).

***Чабын***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чабын* лексик берәмлеге «исем» диелгән. Ул сөйләм телендә кулланыла, «кара *чабынлык*»: *Агыйделнең аръягында атлар йөри чабында*. Җыр [Шәрәф:] *Бу безнең чабын. Бу чүмәләләр безнеке. Без аны икәүләп чаптык. Әнием белән икәү күбәләдек*. М Фәйзи (ТТАС, III: 397).

***Чабынлык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чабынлык* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм «печән чаба торган, печән чабарга билгеләнгән урын; болын» дип аңлатылган. Мисаллар: *Галимә апаның безнең арбада булуы матурлык өстенә матурлык бирә, чабынлыкка барып җитүләр сизелми дә кала иде*. М. Гафури. [*Нәгыйм*:] *Коммунаның участкасы моташ бер җирдә булганлыктан, чабынлыгы да, иген басулары да Үрге әрәмәгә якын*. Ш. Камал (ТТАС, III: 397).

*Чабу, чабулык, чабын, чабынлык, чабылдык, чабула* лексик берәмлекләре географик атамалар ясауда актив катнашалар.

*Чабула* – Кукмара районы Вахит авылы янындагы печән чаба торган коры елга. *Чабынды елгасы* – Арча районы Мөрәле авылы; Балтач районы Курмала авылы янындагы су атамалары. *Мулла чабуы* – Кама Тамагы районы Кече Тормы авылы янындагы печәнлек атамасы. *Мулла чабылдыгы* – Саба районы Олы Шыңар авылы янында муллага нисбәтле урын (бу җирдә-

ге печәнне халык муллага чабып биргән). *Мулла чабындысы* – Теләче районы Байкал, Арча районы Мөрәле, Ютазы районы Олы Урыссу, Балтач районы Пүскән, Арча районы Сикертән, Саба районы Тимершык авыллары яннарындагы атамалар.

***Чаган***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чаган* лексик берәмлеге «диалекталь исем» дип ныгытылган һәм «өрәңге» диелгән. *Шаулап торды шулчак талгын гына Ак каен да, имән, чаган да*. З. Мансур. *Кипарислар, биек чаганнар... сузылып үскән*. Ш. Маннур.//сыйфат мәгънәсе. Чаганнан эшләнгән, чаганнан ясалган. *Ишек ачылды, зур чаган табак белән кымыз күтәреп Тукал керде*. Г. Ибраһимов (ТТАС, III: 398).

***Чаганлык***. Шул ук сүзлектә бу лексик берәмлек «исем» дип күрсәтелгән һәм мәгънәсе чаган урманы, чаган үсеп утырган урын буларак ныгытылган (ТТАС, III: 398).

*Чаган* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда шактый катнаша. *Чаган елгасы* – Мамадыш районы Түбән Ушмы авылы янынннан ага, Ушмы елгасы бассейнында. Бу атама яр кырыйларында үскән *чаган* – өрәңге (ТТАС, III: 398) агачына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән. Татар теленең камышлы, бөре, минзәлә, гәйнә сөйләшләрендә *чаган* «өрәңге» агачын аңлата (ТТДС, III: 471).

Монгол телендәге *цагаан, чагаан* да, бурят телендәге *сагаан* (диалекталь *цагаан*) да «ак» мәгънәсенә ия. Татар теленә *чаган* сүзе монгол теленнән кергән дигән фикер бар (Фасеев, 1969: 189). Астрахань өлкәсендәге Иделнең Иске Идел култыгы башланган урыннары *Чаган* дип йөртелә (Поверстное, 1899). *Сагаан нур* – Бурятиядәге күл. *Чаган* – Оренбург өлкәсендәге елга.

***Чагыл***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чагыл* лексик берәмлеге «исем», «калкулык; кояш нурлары төшә торган тау бите» дип бирелгән. Мисаллар: *Тауларга ла мендем шул, дип шонкар чөйдем, шонкар чөйдем. Чагылларга төшкән лә шул*. Җыр. [*Асылгәрәй*] *киң басуларны, ерактагы серле кара урманнарны һәм тау-чагылларны... яңадан җентекләп күзәтергә тотына*. М. Шабай (ТТАС, III: 398).

*Чагыл, чагыллы, чагылды* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда шактый кулланыла. *Чагыл тавы* – Сарман районындагы Дүсем, Актаныш районындагы Иске Байлар авылларындагы тау атамалары. *Чагылды асты* – Азнакай районы Октябрь Бүләге авылы утырган урын. *Чагыллы елга* – Эстәрле суы кушылдыгы. Азнакай районы Карамалы авылы янында. *Чагыллы урманы* – Азнакай районы Октябрь Бүләге авылы янындагы урын атамасы. *Чагыллы елга башы* – Азнакай районы Карамалы авылы янында Чагыллы елгасы кушылдыгы. *Биек чагыл таулары* – Баулы районы Татар Кандызы авылы янында. Чабылмый кала торган урыннарны *чагыл* дип атыйлар.

***Чалбар*** – «елга һәм инеш кушылдыгы». Татарстан гидронимиясендә бу апеллятив күчерелмә мәгънәдә кулланыла һәм елга-су атамалары ясауда катнаша: *Чалбар* – Кече Мишә суы кушылдыгы (Саба районы). *Чалбар балак күле* – Минзәлә районының Бикбау авылында.

*Чалбар* апеллятивы монгол телендә *салбар* рәвешле һәм Себер гидронимиясендә дә «елга култыгы, кушылдыгы» мәгънәсендә йөри (Кузьмина, 1969: 35).

***Чалу.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чалу* термины «искергән исем, диалекталь сүз» дип ныгытылган, мисаллар китерелгән һәм бу сүзнең нәрсә аңлатуын белү өчен «кара: *чалулык*» дип күрсәтелгән. *Карлыгачтай уйнаса, сандугачтай сайраса, Ил ямьнәре басулар, чалулар шатлана*. К. Тинчурин. *Төннәр җитеп чыклар төшкәч, берни булмаган кебек, гади арбага утырып чалуга китте егет*. С. Баттал (ТТАС, III: 405).

***Чалулык.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу термин «исем, диалекталь сүз» дип бирелгән һәм мәгънәсе «печән чаба торган болынлык, печән чабыла торган урын» дип аңлатылган. *Франц Иосифовичның башына печән кайгысы төште. Ул өяз башкарма комитетына Идел артындагы болыннардан чалулык сорап барды*. И. Гази (ТТАС, III: 405).

*Чалу, чалулык* терминнары географик атамалар ясауда шактый актив кулланылалар. *Чалулык* – Аксубай районы Иске

Кыязлы авылы янындагы болынлык атамасы. *Чалулык елгасы* – Буа районы Карлы авылы, Карлы елгасы кушылдыгы. *Чалулык күпере* – Буа районы Карлы авылы янындагы күпер атамасы. *Чалу* – Апас районы Иске Йомралы, Спас районы Иске Йорткүл авылларындагы печәнлек җирләр, печән чаба торган урын атамалары. *Чалу чишмәсе* – Апас районы Идрәс-Тинки авылы янындагы чишмә. *Чалу җире* – Кама Тамагы районы Кече Бортас авылы янындагы җир атамасы. *Чалу юлы* – Буа районының Яңа Тинчәле авылы халкы телендә юл атамасы. *Солтан чалуы* – Яшел Үзән районы Тау иле авылы янындагы печән чаба торган чалулык җир. *Матрос чалуы* – Яшел Үзән районы Мулла Иле янындагы печәнлек атамасы. *Атау чалуы* – Яшел Үзән районы Мулла Иле авылы янында болын атамасы. *Малай чалуы* – Әлки районы Иске Чаллы янындагы печәнлек атамасы. *Малай чалуы елгасы* – Әлки районы Иске Чаллы авылында. Суы яз көнендә генә була. *Тау иле чалуы* – Яшел Үзән районы Мулла Иле авылы янындагы печәнлек атамасы. *Ишми чалуы* – Яшел Үзән районы Мулла Иле авылы янындагы болын атамасы. *Чалу печәнлеге* – Спас районы Кырый Йорткүл авылы янындагы печәнлек атамасы. *Олы чалу* – Яшел Үзән районы Күгәй авылы яныннан агып үтә торган Әрә елгасының (чокырының) Айдар авылы ягындагы чалулыгы (печәнлек урыны). *Мулла чалуы* – 1. Апас районы Зур Күккүз авылы, 2. Әлки районы Иске Чаллы, 3. Чүпрәле районы Каракитә авыллары халкы бу печәнлекләр җирендәге печәнне муллаларга чабып биргән. *Мулла чалуы* – Әлки районы Чуваш Кичүе авылы янындагы печәнлек, болын атамасы. *Мулла чалуы сазлыгы* – Имәлле суы бассейны, Апас районы Шыгай авылы янындагы чалулык. *Озын чалу* – Чүпрәле районы Түбән Чәке авылы янындагы кыр атамасы. *Алан чалуы күлләре* – Яшел Үзән районы Татар Әҗәле авылы янындагы бу күлләр хәзер кипкән. *Алан чалуы сазлыгы* – Яшел Үзән районы Татар Әҗәле янындагы бу сазлык хәзер кипкән. *Балтыр чалуы* – Кама Тамагы районы Олы Салтык авылы янындагы чалу атамасы.

***Чат***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чат* лексик берәмлегенә түбәндәге аңлатма бирелгән: 1. *Чат* – исем. Ике яки берничә урам кисешкән урын. *Тегермәнгә борылып киткән урам чатыннан Мәдинәнең каршысына ике атлы килеп чыкмасынмы*! Г. Минский. [*Хәйретдин*] *кайбер көннәрне станция тирәләрендә, шәһәрнең зуррак урам чатларында, үзенең зур ломовой чанасына утырып, дежурлык итә*. М. Гали.

2. Ике яки берничә юл кушылган яисә кисешкән урын. *Ике юл чатындагы күрсәткеч баганага аркылы-торкылы кадакланган ике такта кисәге кемгә кая китәргә кирәклекне әйтеп торалар*. Ш. Камал. *Тармакланып киткән өч юл чатында алгы частьларның юнәлешен күрсәтергә калдырылган бер төркем сугышчылар янында туктарга, юынырга һәм бераз тамак ялгап алырга булдык*. А. Шамов.

*Чат башы* – чат, урам кисешкән урын. *[Фәхри] Гәүһәрне капка төбенә чаклы озатып, кулын кысты, аның караңгы төндә, чат башында югалганын карап калды*. Г. Ибраһимов (ТТАС, III: 411–412).

*Чат* компоненты топонимнар ясауда катнаша. *Тайгак чаты* – Апас районы Югары Балтай авылындагы чат. *Чат* – Мамадыш районы Үсәли авылыннан Мамадышка һәм Түбән Сон авылларына китә торган юллар чаты (хәзер авыл уртасындагы мәйдан). *Чат арасы* – Тәтеш районының Бакырчы авылы янындагы урман атамасы. *Чат әрәмәсе* – Актаныш районы Иске Кормаш авылы янындагы әрәмә атамасы. *Чат кизләве* – Чүпрәле районы Зур Чынлы авылындагы кизләү атамасы. *Чат куагы* – Мамадыш районы Түбән Сон авылы янындагы урман атамасы. *Чат күпере* – Питрәч районы Шәле авылындагы күпер атамасы. *Чат чокыры* – Яшел Үзән районы Татар Танае авылы янында, Гөбенә елгасы бассейнында. *Карабай чаты* – Апас районы Тәүгелде авылындагы чат. *Кара бия чаты* – Яшел Үзән районы Акъегет авылында. *Чидыр чаты* – Кайбыч районы Хуҗа Хәсән авылы янындагы урын атамасы. *Марта чаты* – Апас районы Багыш авылы яныннан ага торган Чирмешән

елгасы бассейнында. Умарталыкка бара торган чат. *Урта чат кизләве* – Апас районы Урта Биябаш авылында. *Чыршы чаты* – Апас районы Багыш авылында, Чирмешән елгасы бассейнында. *Чыршы чаты кизләве* – Апас районы Багыш авылы янында. *Аю чаты чокыры* – Яшел Үзән районы Югары Урысбага авылы янында, хәзер бу елганың суы беткән. *Тычкы юлыш чаты* – Апас районы Багыш авылы янында. *Эчке юлыш чаты* – Апас районы Багыш авылы янында. *Таш елга чаты* – Апас районы Багыш авылы яныннан ага торган Ташлы елганың Чирмешәнгә кушылган урыны. *Таяк чаты* – Апас районы Олы Балтай авылы янындагы урын. *Таяклар чаты кизләве* – Апас районы Олы Балтай авылы янында Чирмешән суына кушыла. *Таллар чаты* – Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылы янындагы урын атамасы. *Чат суы* – Эстәрле елгасы кушылдыгы (Азнакай районы Балтач авылы).

*Чат* термин берәмлеге әдипләребез иҗатында байтак очрый.

Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *чат* лексик берәмлеге болай искә алына: *«Җиде чатның гарасатына, давылларына күкрәкләрен куеп, биек кыя башында мәгърур басып торучы пар эрбет агачы иде бу».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» исеме алган повестенда *чат* термины очрый: *«Базар тарала башлаганчы юлга чыгарга кирәк иде, Асаф вакытны чамалап Ташлы тауның олы юлыннан читкә аерылып кергән ат юлы чатына таба юнәлде».*

Марсель Галиевнең «Рух» китабында *Чат суы* искә алына: *«Чишмә тавыннан караганда, туган авылым кочакка сыя да бетә. Әнә, каен урманының ике тарафыннан Нөгеш, Чат сулары агып чыга да, авыл эчендә кушылып, Эстәрле инешенә әверелә».*

Нурислам Хәсәновның «Сагыш» исеме алган китабындагы «Тәкъдир» повестыннан мондый юлларга игътибар итәбез: *«Колхоз рәисе Касыйм әле беркөн генә әйтеп торды: «Хәкимҗан абый! Әйдә, Әхмәтшалар чатында салынган яңа йортка күч. Яшьләр урамында рәхәтләнеп яшәрсең, – диде».*

***Чаука***. Бу лексик берәмлекнең «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә мәгънәсе болай аңлатылган: «Куак, куаклык; вак агачлык». *Тсс! дип хәбәр итәм атыма, Яшеренәбез чаука артына*. Ф. Кәрим. (ТТАС, III: 414).

***Чаукалык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем, диалекталь сүз, кара: *чаука*» дип ныгытылган. *Су алып кайткач, чаукалыклардан чыбык-чабык җыйгалап, калай чәйнекне таганга асып, ут ягып Бәдри чәй кайната башлады. Ак юл. Чакыр буйлап киткән тар сукмак белән ... берничә ел элек киселгән чаукалыкка барып чыктылар*. А. Таһиров (ТТАС, III: 414).

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *чаукалык* болай аңлатылган: «Чаукалык диалекталь лексик берәмлек – куаклык, әрәмәлек. Бу сүзне *лесо* (посадка) мәгънәсендә тәкъдим итүчеләр булды. Чыннан да, чаукалык сүзенең мәгънәви функцияләре әдәби телебездә файдаланылмый ята диярлек».

*Чаукалык* лексик берәмлеге белән ясалган географик атамалар да очрый: *Чаукалык* – Баулы районы Яңа Шалты авылы янындагы әрәмә атамасы. *Чаукалык тау* – Баулы районы Исергәп авылы янындагы әрәмә атамасы. *Чаукалык урманы* – Баулы районы Салих авылы янындагы урман атамасы.

Марсель Галиевның «Рух» исеме белән дөнья күргән китабында *чаукалык* лексик берәмлеге кулланылган: *«Безнең Васильево янындагы дачалар бер меридианда, араны ике күлдә чаукалык бүлеп тора»*.

***Чик***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чик* лексик берәмлеге «исем» дип бирелгән һәм болай аңлатылган. 1. Нәрсәне дә булса күрсәтү өчен шартлы рәвештә билгеләнгән сызык, ызан. *Күк биянең башы минем Алмачуарның кабыргасындарак булган хәлдә чикне дә узып китәбез*! Г. Ибраһимов. // Ике янәшә булган административ бүленешне аерып тора торган табигый (елга һ. б. ш.) яки шартлы бер сызык. *Район җирен кисеп, чиккә кадәр Килеп җитте җиңел машина*. Ш. Мөдәррис. // Берберсе белән янәшә булган ике дәүләтнең җирен яки суын аерып

торган сызык. *Аларны... өч көн эчендә киендереп, бөтен сугыш кирәк-яраклары биреп, Көнчыгыш Пруссия чигенә, генерал Самсонов армиясенә озаттылар*. М. Гали.

2. Берәр нәрсәнең кырые, чите, чит сызыгы. *Диңгезнең чиге булган кебек,чыдамлылыкның да чиге бар.* А. Шамов. *Карыйдыр идем басу капкасына, Шушыдыр дип чиге дөньяның.* З. Мансур (ТТАС, III: 425).

*Чик* термины географик атамалар ясауда да катнаша. *Шыңарлар чиге* – Саба районының Түбән Симет авылы янындагы кыр атамасы. *Утыз имән чиге* – Аксубай районы Иске Кыязлы авылы янындагы урын атамасы. *Чик тавы* – Лаеш районы Янтык авылы янындагы атау исеме. *Чик атавы елгасы* – Лаеш районы Татар Янтыгы авылы, Брыс елгасы бассейнында. *Чик бүләк басуы* – Баулы районы Бәйрәкә авылындагы басу атамасы. *Чик елга* – Чистай районы Чуаш Ялтаны авылы янында, Кече Чирмешән кушылдыгы. *Чик кизләве* – Чүпрәле районы Яңа Дуван, Апас районы Мөрәле авыллары янында. *Сулып чиге күле* – Кама Тамагы районы Олы Яңасала авылы янындагы бу күл кипкән, атамасы гына калган. *Мари межасы* – Мөслим районы Симәк авылы янындарагы чик  атамасы. *Шыңарлар чиге* – Саба районы Түбән Симет авылы янындагы урын атамасы.

*Чик* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында очрый.

Марсель Галиевның «Рух» исемле китабында мондый юллар язылган: *«Кыйтгаларда ил-җир чикләре шәйләнгәнче үк, Атлантик океаннан алып Тын океан ярларына чаклы киңлекләрдә татар төркиләрнең таш меңгерләр, таш балбаллар куеп калдыруы «Монда без булдык!» дигән олы сер түгелмени!»*

Вахит Имамовның «Утлы дала» исеме алган тарихи романында мондый фикер белән танышканда *чик* лексик берәмлеге белән очрашабыз: *«Муром, Суздаль, Ростов кенәзлекләреннән җыелып килеп рус угрыларының әле Ука тамагындагы Янкаланы, әле чирмеш, ар, әрҗә, мукшылар яшәгән Мәртүбә вилаятен талап китүләренә болгарлар инде күптән күнеккән һәм тышкы чикләрне саклау өчен ялланган казакларны да,*

*гадәттә, Ука, Сура елгалары тирәсенә туплап тота торган иде».*

***Чирәм.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чирәм* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе «Эшкәртелмәгән, бер дә сөрелмәгән җир» дип күрсәтелгән. *Вилдан абзыйларың да безнең белән бергә янәшә чирәм алганнар икән, шулар белән алмашлап сөрергә булдылар*. Г. Ибраһимов. *Алтын бодай дулкынлана Без күтәргән чирәмдә*. З. Маннур.

***Чирәм җир*** – 1) кара: *чирәм*. *Әйдәгез, дуслар, егетләр, кызлар, Чирәм җирләргә иген игәргә*. Җыр (ТТАС, III: 432).

*Чирәм* лексик берәмлеге топонимик атамалар ясауда шактый актив. *Чирука чирәме* – Буа районы Яңа Чәчкаб авылы янындагы урын атамасы. *Алан чирәме* – Сарман районы Мортышбаш авылы янындагы басу атамасы. *Алан чирәме чокыры* – Кама Тамагы районы Олы Яңасала авылы янында. *Алексей чирәме* – Апас районы Кара Борнаш авылы янындагы Бола елгасы бассейнында. *Түгәрәк чирәм* – Кама Тамагы районы Олы Салтык авылы янындагы җир һәм елга атамалары. *Түгәрәк чирәм елгасы* – Лаеш районы Татар Янтыгы авылы янында Брыс елгасына тоташа. *Түгәрәк чирәм кизләве* – Апас районы Кошман авылында, Кошман елгасы бассейнында. *Түгәрәк чирәм чыгышы* – Кама Тамагы районы Кече Салтык авылы янындагы чишмә. *Түгәрәк чирәм чишмәсе* – Лаеш районы Татар Янтыгы авылы янындагы чишмә. *Чуаш үлгән чирәме* – Чистай районы Акбулат авылында. *Тыгрык чирәме* – Кама Тамагы районы Яңа Сала авылы янындагы урын атамасы. *Чирәм колавы* – Актаныш районы Семистрау (Өшәр) авылы янындагы урын атамасы. *Чирәмлек* – Кама Тамагы районы Олы Салтык авылында. *Чирәм туктаган җир кизләве* – Апас районы Борнаш авылында. *Карама асты чирәме* – Арча районы Мөндеш авылы янындагы чирәмлек атамасы. *Мөрмәт чирәме* – Апас районы Әҗем авылы янындагы басу атамасы. *Тәкәрлек чирәме* – Кама Тамагы районы Олы Салтык авылы янындагы җир атамасы. *Бәймәк чирәме* – Кама Тамагы районы Олы Яңа Сала авылы янындагы урын атамасы. *Чирука*

*чирәме* – Буа районы Яңа Чәчкаб авылы янындагы урын атамасы. *Олы чирәм* – Буа районы Адав-Толымбай авылы янындагы урын атамасы. *Олы чирәм басуы* – Чүпрәле районы Иске Кәкерле авылы янындагы басу атамасы. *Орйаз-чирәмлеге* – Яшел Үзән районы Кече Ачасыр авылы янындагы урын атамасы. *Киң чирәм чишмәсе* – Спас районы Иске Рәҗәп авылы янындагы күл. *Бәймәк чирәме* – Кама Тамагы районы Яңа Сала авылы янындагы урын атамасы. *Назулат чирәме* – Сарман районы Мортышбаш авылы янындагы басу атамасы. *Намаз укый торган чирәм* – Апас районы Зур Күккүз авылы янындагы урын атамасы. *Ибли чирәме кизләве* – Апас районы Коштавылы авылы янындагы урын атамасы. *Йолдыз чирәме* – Кама Тамагы районы Олы Салтык авылы янындагы басу атамасы. *Юкәле куак чирәме* – Апас районы Олы Урсак авылы янындагы Имәлле суы кушылдыгы.

***Чиру.*** *Чиру* лексик берәмлеге, кызганыч, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә юк. 1966 елда Мәскәүдә дөнья күргән «Татарча-русча сүзлек»тә *чиру* «1) рать, войско; // войсковой; 2) диалекталь сүз *стая* (только волков)» мәгънәсендә теркәлгән. 2007 елда дөнья күргән «Татарско-русский словарь»да бу лексик берәмлек, тарихи исем буларак, «1. войско – *гаскәр*» дип бирелгән: *йөз меңлек чиру белән һөҗүм итү* – нападать стотысячным войском; *монголлар чируе* – монгольское войско. 2. стадо, стая, рой; скопление, сборище, группа; *саранча чируе* – стая саранчи» мәгънәсендә күрсәтелгән.

«Миллият сүзлеге»ндә (2007) *чиру* – «гаскәр, яу, армия; һөҗүм, ябырылу. Сәиф Сараида *чәри* язылышы очрый. // *Дошман чәрисе. Аксак Тимер чируе. Яңа чиру* (Төркиядә – янычарлар). Соңга таба бу сүз татар телендә «ишле халык» мәгънәсендә дә кулланыла башлаган» дип бирелгән.

*Чиру* лексик берәмлеге белән түбәндәге географик атамалар ясалган: *Чиру билгесе* – Апас районы Кошман авылы кырындагы үзән. *Чиру болыны* – Апас районы Дәвеш авылы янындагы болын атамасы. *Чиру каты* – Апас районы Дәүләки авылы янындагы җир атамасы.

Әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында *чиру* «гаскәр» мәгънәсендә кулланыла. Вахит Имамовның «Сәет батыр» исеме алган тарихи повестенда мондый юллар бар: *«Ялгызыма гына, барыбер, якты көн юк. Ятим итмә, чируеңә мине дә ал, Сәет батыр». «...Бәйрәкә батыр күтәргән әләм астына без дә басыйк. Ул чакта безгә Тәукә хан нәүкәрләре дә кяфер Питр падишаһның чируләре дә һич куркыныч булмас. Юлыбыз берәү генә»*. Шул ук авторның «Утлы дала» исемендәге тарихи романында мондый юллар укыйбыз: *«Далай, Буир күлләре буеннан кубып, Онон елгасына таба кара татар чируе килә, сәрдәрләре Тимерҗан бәк икән».*

***Чит***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чит* лексик берәмлегенең *икенче мәгънәсе* түбәндәгечә аңлатылган: Берәр предмет (урман, торак пункты һ. б.ш.) кырыендагы җир урын. *Кышлакның иң читендә ялгыз бер өй булган. Куаклы урман читендә машиналар тынып калганнар*. Ш. Маннур. // Чокыр, яр, елга кебек нәрсәләрнең кырые. *Чокыр чите. Күл чите*. Солдат яр читендә җитәкләшеп торган балаларга борылып карады. Г. Гобәй. // Юл, урам һ. б. ш. кырыенда, аларның һәр ике ягында буйдан-буйга сузылган урын. *Юл читендә кар кисәкләре торалар тезелешеп, Барысы да иелеп калалар «Хуш, исән бул»– диешеп*. Ш. Бабич. *Урамның читеннән күп йөрдек, уртасыннан йөреп карыйк әле.* Ф. Хөсни.

*Өченче мәгънәсе:* Нинди дә булса мәйдан, өслек, пространствоның кырыен чикләүче сызык. *Кояш янә күк читеннән күтәрелеп, ...көндәге ... эшенә кереште*. Ш. Усманов. *Шул чакта офык читендә бер нокта күренде*. А. Алиш (ТТАС, III: 433).

*Чит* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда кулланыла: *Чит елга* – Лениногорск районы Урдалы авылы тирәсеннән аккан Шушма / Чишмә елгасы кушылдыгы. *Чит кирәмәт* – Мамадыш районы Олыяз авылы янындагы урын. *Читләш кыр* – Чүпрәле районы Кече Чынлы авылы янында. *Читтәге елга* – Балтач районы Нөнәгәр авылы яныннан ага торган Кугубор елгасы бассейнында.

*Чит* лексик берәмлеге әдипләр иҗатында очрый. Вахит Имамовның «Казан дастаны» китабында: *«Булат сөзәк яр читендә су эченә аякларын тыгып утырган* бер сылуны инде күптән күз уңына алып куйган иде». Шул ук авторның «Утлы дала» исемендәге тарихи романында чит лексик берәмлеге кулланыла: *«Ләкин мәйдан читенә иярләреннән сикереп төшкәч, алар өс-баш кагу, үзләрен ипкә-сапка китерү белән дә азапланып маташмады».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» повестыннан мондый юллар укыйбыз: *«Урманны чыгуга уҗым басуыннан коры йомшак җил бәрелде, юл читеннән ук булып атылып анда-санда тургайлар күтәрелде».*

***Чишмә***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чишмә*нең бер мәгънәсе «җир астыннан агып, бәреп чыга торган су чыганагы» диелгән. *Аларның шул сүзләрен җиңги су алырга чыкканда, чишмә ягыннан ишетеп кайткан*. М. Гали. *Уң кулда таудан чишмә чыгып тора*. Ф. Бурнаш. // *Сирәк*. Кайбер сыек казылма байлыкларның чыганагы. *Бәлки, тагын берәр җиребездә Нефть чишмәләре табылыр*. Ш. Маннур.

*Икенче мәгънәсе:* «Нәрсәнең дә булса чыганагы, башлангычы, нигезе». *Илһам чишмәсе. Гыйлем чишмәсе. Китап – белем чишмәсе*. Н. Исәнбәт (ТТАС, III: 437). Каюм Насыйри елга башланган урынның да чишмә дип аталуын билгеләп үтә (Насыйри, 1890: 14).

Адлер Тимергалин сүзлегендә *чишмә* турында түбәндәгечә язылган: «Кизләү, болак, чыганак. // *Әүлия чишмәсе. Газизләр чишмәсе. Изгеләр чишмәсе. Яхшылар кизләве (чишмәсе). Чишмәи рәхмәт. Салкын чишмә* (телдә «җылы чишмә» төшенчәсе дә бар).

Тагын кара: *Чәшмә.*

*Чәшмә* сүзе фарсы алынмасы. Чишмә, болак, кизләү, чыганак, гайн (г.), мәнбаг (г.), чыгыш. Г. Гыйльманов «Татар мифлары» китабында *чишмә* сүзен татарча *тишмә* сүзеннән чыгара. Аның этимологиясе белән килешеп булмый билгеле».

*Чишмә* сүзе фарсы телендәге «күз» мәгънәсенә ия булган *чашм – чешм* яисә «чыганак, чишмә»не белдерә торган *чäшме* сүзенә барып тота (ПРС, 1960: 163–164). В. Радлов кара-кыргыз телендәге *чiчма* терминының «чишма, чыганак» төшенчәсендә йөрүен һәм аның фарсы теле алынмасы икәнлеген күрсәтә. Бу апеллятив башка төрки телләрдә дә шулай ук «чишмә, чыганак»ны, елга, инешләрнең башланган урыннарын аңлата (Радлов, т. III. Х. 2: 2147).

Татар топонимиясендә *чишмә* сүзе үзе генә дә һәм атамалар составында да кулланыла: *Чишмә* – Әлки районы Түбән Әлки, Аксубай районы Иске Татар Әдәмсуы, Апас районы Күкшем, Мамадыш районы Бөрсет-Сөкәче, Югары Ослан районы Бакча-Сарай, Чирмешән районы Карачишмә, Чистай районы Чуваш Ялтаны, Лениногорск районы Ормышлы авылы, Аксубай районы Карасу, Яшел Үзән районы Чүриле, Спас районы Иске Рәҗәп, Мамадыш районы Түбән Сон, Алексеев районы Кыр Шынталысы, Кама Тамагы районы Даныш, Аксубай районы Шәрбән, Арча районы югары Сәрдә авылларындагы чишмәләр. *Чишмә әрәмәсе* – Лениногорск районы Түбән Чыршылы янындагы әрәмә атамасы. *Йортлар урыны чишмәсе* – Буа районы Яңа Чәчкаб авылының элекке урыны. *Елга башы чишмәсе* – Биектау районы Мәмдәл авылы янындагы чишмә. *Чишмә тавы* – Саба районы Иске Җөри авылы янындагы тау атамасы. *Чишмә өсте* – Яшел Үзән районы Синтәк авылы янындагы урын атамасы. *Чишмә күле* – Әлки районы Чуваш Кичүе авылы янындагы күл. *Чишмә күпере* – Арча районы Казиле авылындагы күпер атамасы. *Чишмәләр башы елгасы* – Арча районы Наласа авылы янында. *Чишмәле үзән* – Кукмара районы Пычак авылы янындагы үзән. *Чишмә тавы урамы* – Теләче районы Югары Кибәхуҗа авылындагы урам. *Чишмәле тау* – Азнакай районы Әгерҗе авылы янындагы тау. Тау борыныннан чишмә чыга. Шул ук исемдәге тау Лениногорск районының Иске Шөгер авылы янында да бар. *Чишмә сызасы* – Сарман районы Мортыштамак авылы янында. *Чишмә тегермәне* – Арча райо-

ны Югары Сәрдә авылы янындагы тегермән атамасы. *Чишмә Шыңар елгасы* – Кукмара районы Өлге авылы янында. *Адаш чишмәсе* / Инеш суы – Актаныш районының Адай авылында. Моннан башка авылда тагын *Сабанай, Салкын, Ташчишмә, Өч төтен, Дания* һ. б. исемендәге чишмәләр бар. Минзәлә районының Калморза авылында *Чишмә* – Камышлы күпереннән түбән яктагы ярдан тибеп чыккан су чыганагы. *Чишмә сукмагы* – авылдан чишмәгә салынган җәяүлеләр сукмагы.

*Чишмә // Шушма* елгасы тарихи чыганакларда да чагылыш тапкан. *Чишмә* сүзе микротопонимнарда (*Чишмә атавы, Чишмә урманы, Чишмә ышнасы* һ. б.) һәм авыл атамалары исемендә дә катнаша. Татарстанда 57 авыл атамасында *чишмә* термины кулланыла: *Яңа Чишмә, Чишмә* (алар бишәү), *Чишмәбаш* (алар икәү), *Кара Чишмә, Улаклы-Чишмә, Таза-Чишмә, Суык-Чишмә* (алар икәү), *Салкын-Чишмә* (алар өчәү) һ.б.

*Сабыр чишмәсе* – Актаныш районының Иске Сафар авылында урнашкан (авылның төньягындагы тау итәгендәге ерымнан яз көннәрендә кар сулары ага. Бу ерымны Сабыр чишмәсе дип атаганнар. Аның суы чиста һәм йомшак. Яз көннәрендә халык анда кер юган). *Аманлык коесы* – Бүрсет елгасы бассейнында, Мамадыш районының Катмыш авылы янында (бу очракта *кое* термины чишмәне аңлата. Шуңа күрә аны чишмә атамасы белән бергә урнаштырдык. Чишмәнең коены, коеның чишмәне аңлату очраклары шактый).

*Чишмә* сүзе әдипләр, шагыйрьләр һәм халкыбыз авыз иҗатында киң кулланыла. Габдулла Тукай «Туган җиремә» дип аталган шигырендә мондый юллар иҗат иткән:

*Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,*
*Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың...*

Гомәр ага Бәшировның гүзәл әсәре «Җидегән чишмә»дә без анда мондый юллар очратабыз: *«Уңга борылып умарталыкка күтәрелер алдыннан, Җидегән чишмә тавышы яңадан йөрәк сагышын кузгатты. Иң соңгы кичне хәтерләтте. Бер-берсеннән*

*ерак түгел җиде тамырдан бәреп чыккан җиде чишмә. Борын-борын заманнарның бер шагыйрь җанлы кешесе бу могҗизага карап сокланып торган да, җиде туганны җидегән йолдызга тиңләп, «Җидегән чишмә» дип атаган».*

Фатыйх ага Хөснинең «Тау чишмәсе» хикәясендә *чишмә* турында мондый сүзләр язылган: *«Чишмәнең тагын бер хасияте шунда: бу як кешеләре аны «Шифалы чишмә» дип йөртәләр, авыру-сырхау тигән кешеләр, бигрәк тә олы-кара ерак җирне якын итеп шушы чишмәгә килә, коенып, суын эчеп, әл-хәл ала имеш. Бер эчү белән генә кинәт терелеп китмәсә, өендә азлап эчеп, әкренләп-әкренләп терелү өмете белән, бидунлап-чиләкләп тә ташып торалар имеш».*

Татарстаннан читтәге төбәкләрдә яшәгән татар халкы телендә «чишмә» термины актив кулланыла. Башкортстанда: Кырмыскалы районы җирләреннән агып үткән Уршак елгасы кушылдыгы *Шишмә/Чишмә* елгасы, Мәчетле районыннан агып үткән. Ык елгасының уң кушылдыгы да *Чишмә* дип атала. *Чишмә* сүзе белән Башкортстанда авыл атамалары һәм микротопонимнар да шактый: *Ташчишмә, Тукмакчишмә* – Илеш һәм Миякә районнарында, *Этколшишмә* – Белорецки районындагы хутор, *Яланчишмә* – Ярмәкәй районында, *Салкын чишмә* – Мәчетле, Туймазы районнарындагы авыллар. Җ. Киекбаев исәпләве буенча, 17 авыл атамасында *чишмә* термины бар.

Ульяновск өлкәсендә: *Сарай чишмәсе* – Кулаткы районы Иске Тирешкә авылындагы чишмә һ. б. Самара өлкәсендә: *Әүлияләр чишмәсе*, *Тәмле чишмә*, *Шарлык чишмәсе, Чагыл чишмәсе* (Камышлы районы) бар, Иске Ярмәк (Похвистнев районы), Гали авылларындагы чишмәләр, ага-ага инешкә әверелеп, Камышлы районының Татар Байтуганы авылы янынннан агучы Сок елгасына кушылалар һ. б. Самара өлкәсендә *чишмә* белән микротопонимнар да шактый күп: *Чишмәле тау* – Камышлы районы Иске Усман авылында, *Нәҗекәй чишмәсе басуы, Йулга чыккан чишмә тавы* – Камышлы районы Иске Ярмәк, Татар Байтуганы авылларындагы басу һәм тау һ. б.

Э. Мурзаев мәгълүматларына караганда, *чишмә* лексик берәмлеге төрки һәм төрки булмаган халыклар яши торган җирләрдә дә очрыйлар. Мәсәлән: Молдовада – *Чишмә;* Оренбург өлкәсендә – *Чишмәбаш;* Таҗикстанда – *Сары-Чишмә;* Кашкадәрья өлкәсендә – *Чишмәмирон* һәм *Чишмә;* Сәмәрканд өлкәсендә – *Чашма,* Сәмәркандның үзендә – *Чашма-Акаб* мавзолее; Иранда – *Чешмаханә* һәм *Чешменуры,* Тегеран янында – *Чишмәшах;* Төркиянең Урта диңгезе яры буенда – *Чишмә* ярымутравы; Төркиянең үзәк өлешендә Туз күленең көнбатышында – *Чишмәле;* Әфганстанның көнчыгышында – *Чашмани.*

Татар теле сөйләшләрендә *чишмә* сүзенең төрле төрдәш-вариантлары очрый. Типтәрләрдә чишмәне – *сишмә*, Башкортстандагы байкыбаш сөйләшендә *тишмә* дип әйтәләр. Казан арты авылларында чишмәне – *сишмә, тишмә, шишмә* дию киң таралган. Мишәр диалектының темников, ләмбрә, кузнецк сөйләшләрендә *чишмә* урынына *күзләү, күзләвек* терминнары йөри. Шул ук диалектның мордва-каратай сөйләшендә *чишмә* урынына *чыганак* сүзеннән файдаланалар. Урта диалектның камышлы сөйләшендә *күзләү* – «бәрәңге күзен алу». Чишмәләр күп булган урынны кузнецк сөйләшендә – *күзләвеклек,* глазов сөйләшендә *чишмә-күз* диләр.

Чишмә күзен, чишмәнең су бәреп чыга торган җирен дә сөйләшләрдә аерым-аерым атыйлар. Мәсәлән, кузнецк сөйләшендә *күзәнәк, чыгым,* темников – *кузанак,* гәйнә сөйләшендә – *җир кендек.* Җир астыннан күз-күз булып тибеп чыккан өчен, алар шулай аталалар (ТТДС, 1969: 279, 280, 254, 491, 573).

Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районының кайбер авылларында яши торган халык *чишмә* урынына *чыгым* термины куллана. *Алтынбай чыгымы* – Иске Кулаткы районының Яңа Кулаткы авылы яныннан аккан Инеш суы кушылдыгы, *Зур ак чыгым* – Иске Кулаткы районының Иске Зеленай авылындагы чишмә.

Урта диалектның кайбер сөйләшләрендә (мәсәлән, Тау ягында) чишмәне *кизләү* диләр. *Кизләү* – топонимга да әверелгән. Татарстанның Апас районында *Җиде кизләү*, Нурлат районында

*Кизләү* исемле татар авыллары бар. Кама Тамагы тирәләрендә *кизләүләр* дип сазлыкта акмый гына чыгып ята торган чишмәләрне атыйлар. *Кизләү* – татарның үз сүзе, югарыда әйтелгәнчә, *чишмә* татар теленә фарсы теленнән алынган. *Кизләү* термины аерым, конкрет бер елга атамасы булып та кулланыла ала: *Кизләү* – Аксубай районында Кирәмәт елгасы бассейнындагы, Нурлат районындагы Олы Чирмешән елгасы бассейнындагы, Чүпрәле районындагы Аксу елгасы бассейнындагы чишмәләр. *Кизләү* сүзе гидронимнар составында да кулланыла: *Кизләү елгасы* – Нурлат районындагы Гәрәй елгасы кушылдыгы. *Хуҗалар кизләве* – Алексеев районы Биләр авылы янында. *Барый кизләве* – Яшел Үзән районы Күгеш авылында, Әрә суы бассейны. *Баскыч алан кизләве* – Апас районы Кошман авылында, Кошман суы кушылдыгы. *Кизләүле елга* – Биектау районыннан агып үтә торган Ашыт кушылдыгы; *Ванька кизләве* – Кайбыч районы Чүти авылы янында. *Васби кизләве* – Апас районы Колчык бистәсендә. *Гайса бабай кизләве* – Кама Тамагы районы Иске Казиле авылында. *Гайшә әби кизләве* – Апас районы Түбән Биябаш авылында. *Урман асты кизләве* – Апас районы Борнаш авылы янындагы җир атамасы. *Умарта кизләве* – Апас районы Идрәс-Тинки авылы янында. *Гайшә кизләве* – Яшел Үзән районының Күгәй авылы халкы телендә кулланыла. *Казаклар кизләве* – Апас районы Бакырчы авылында, Чирмешән елгасы бассейнында. Кари *кизләве* – Яшел Үзән районы Күгәй авылында. *Кәрам ышнасы кизләве* – Апас районы Төбәк Черкене авылында, Табар суы бассейнында. *Умарталык кизләве* – Тәтеш районы Иске Бидәңге авылы янындагы умарталык.

Бу термин белән микротопонимнар да ясалган: *Кизләү аланы, Кизләү тавы, Кизләү күпере* һ. б.

*Кизләү* термины әдипләр иҗатында да урын ала. Язучы Әсгать Салахның «Казан утлары» (2013, № 1) журналында басылып чыккан «Аккан сулар...» чәчмә әсәрендә *кизләү* термины болай кулланыла: *«Әни өйдә юк, ул бәлки кизләүгә суга, я булмаса кер чайкарга киткәндер».*

*Кизләү* сүзе Башкортстандагы топонимнар составында очрый: *Кизләү* – Бишбүләк районындагы Азнакай, Дәүләкән районындагы Микәш, Караидел районындагы Бартым авылларындагы чишмәләр. Ульяновск өлкәсендә түбәндәге гидронимнар теркәлгән: *Корбан кизләве* – Похвистнев районындагы Яңа Мансур авылында; *Кизләү елгасы* – Иске Кулаткы районындагы Яңа Кулаткы авылы яныннан агып үткән Тирешкә елгасы кушылдыгы.

Бу термин белән микротопонимнар да ясалган: *Татар кизләве яны, Зур кизләү* – Иске Кулаткы районы Яңа Кулаткы авылындагы урын һәм болын атамалары һ. б.

Татарстанда, Ульяновск, Самара, Саратов, Оренбург, Чиләбе һ. б. өлкәләрдә яши торган татарлар телендә *чишмә, кизләү* сүзләре урынына *чыгыш* термины кулланыла. Бу термин чишмә атамасы булып йөри һәм елга атамалары составында килә ала: *Чыгыш, Алач чыгышы* – Кама Тамагы районыннан агучы Үләмә суы кушылдыклары. *Пулат чыгышы* – Кама Тамагы районындагы Ылгыма суы кушылдыгы. *Умарталар буе чыгышы* – Кама Тамагы районы Келәнче авылында. *Әй елгасы чыгышы* – Кама Тамагы районы Кече Кариле авылында. *Ат улагы чыгышы* – Тәтеш районы Олы Әтрәч, Яшел Үзән районы Олы Ачасыр, Тәтеш районы Алабирде авылларындагы чишмәләр. *Аурлут чыгышы* – Кама Тамагы районы Олы Бортас авылы янында. *Ситдыйк чокыры чыгышы* – Кама Тамагы районы Келәнче авылы янындагы чишмә. *Чана чыгышы* – Буа районы Черки-Килдураз авылы янындагы басу атамасы. *Чана чыгышы (чишмә)* – Балык Бистәсе районы Бикчурай авылы янындагы чишмә. *Салкын чыгыш* – Тәтеш районы Зур Әтрәч, Кама Тамагы районы Олы Кариле авыллары янындагы чишмә-чыгышлар. *Сапи чыгышы* – Тәтеш районы Кече Әтрәч авылы янында (*Сапи – Сафиулла* исеменең кыскартылган варианты.

Җирле халык авыл янындагы елгалар турында сөйләгәндә: «Аның чыгышы да (ягъни чишмәсе дә) бар», – дип өстәп куя.

Билгеле булганча, Идел буенда яши торган башка халыклар кебек үк, борынгы бабаларыбыз аерым күл, елга, чишмә һ. б. су чыганакларына табынганнар. Безнен регионда хәзер дә шактый күп чишмәләр *Изге, Әүлия, Хозыр-Ильяс* исемен йөртә. Халык арасында бу чишмәләрнең зур кодрәткә ия булуына (мәсәлән, су тоту, саулыкны кайтару көченә һ. б.га) ышану киң таралган. Хәзерге көнгә кадәр су чыганакларына (аеруча чишмәләргә) карата сакланган зур ихтирам шул борынгы табынулардан килә.

Чишмәләр халкыбызда чисталыкны, сафлыкны, пакьлекне калку итеп күрсәтү өчен чагыштыру берамлеге итеп кулланыла. Күл, елга, чишмә һ. б. төрле су чыганакларына багышлап чыгарылган җырлар халкыбызның җыр хәзинәсендә аерым урын тота. Хәзер дә яратылып башкарыла торган җырларга түбәндәгеләр керә: *«Кандыр буе», «Су юлы», «Агыйдел каты ага», «Фазыл чишмәсе», «Бормалы су», «Түгәрәк күл», «Дим буе», «Тын Иделкәй», «Бер тауда ун чишмә», «Су буйлап», «Идел», «Сәрдә җыры», «Байкал суы»* һ. б.

Чишмәләргә багышлап язылган кайбер җыр исемнәре, аерым урыннардагы чыганак-чишмәләрнең исеменә әверелеп, халык теленә кергән. Мәсәлән, С. Хәким сүзләренә чыгарылган татар халык көе «Фазыл чишмәсе» исеме белән шагыйрьнең туган авылы – Күлле Кименең бер чишмәсе атала башлый.

Татарстан җирендәге һәр авылда диярлек хатын-кыз исеме белән аталган чишмәләр очрый. Бу, мөгаен, чишмәне кадерләп торган шәхес белән бәйледер. Әйтик, *Абыстай чишмәләре* шактый очрый. Авыл халкы мулла хатынын абыстай дип йөрткән. Абыстайлар авыл балаларын укырга өйрәткәннәр, кулларыннан килгәнчә, яшь буын күңелендә мәгърифәт чаткылары кабызганнар. *Зөбәйдә, Канифә чишмәләре, Зәбидә, Сәрия күлләре, Сәлия, Оркыя, Шәңкә әби елгалары* шул исемдәге хатын-кыз исемен мәңгеләштергәннәр .

Электәге мәҗүси халыклар елга, диңгез, күл, чишмә, буа, кое кебек су чыганакларына табынганнар, аларны изге һәм илаһи әйберләрнең берсе итеп караганнар. Республикабыз җи-

рендә очрый торган шактый сандагы изге су-чишмәләр, шушы чорлар белән бәйләнешле булып, шул заманнар истәлеге буларак, буыннан буынга күчә-күчә, хәзерге көннәргә килеп җиткән. Изгелекне тагын икенче күзлектән дә карарга мөмкин. Чишмә суының минераль тозларга бай булуын, сәламәтлек өчен шифалы матдәләрне үз суында күп туплавын искә төшерик. Алар бит җир астыннан чыгалар. Республикабызның җир асты катламнарында кеше сәламәтлеген саклау өчен кирәк булган йөзләрчә матдәләр тупланган. Аннары, читтә яшәгән һәр кеше үз туган ягын ярата, йөрәге авырткanчы сагына, туган як табигате, туган нигез туфрагы аны үзенә тарта. Җирсеп кайткан кеше өчен үз ягының чишмәләреннән салкын су алып эчү дә кадерле бит! Авырткан йөрәкләргә шифа, сагынган күңелләргә дәва булган чишмә суларын ничек изге су дип әйтмәссең!..

Чишмәләр – барлык төр сулыкларның башлангычы, тукландыра торган чыганаклары. Чишмә яшәүдән туктаса, елга-күлләрдә су бетәчәк, авылда ямь калмаячак. Хәзерге авыллар бай һәм матур, һәр йорттан берәр транспорт чыга. Ә табигать ярлылана, чирәм, үлән үсми, авыл эчендәге һәм тирә-юнендәге чишмә-чыганакларны чистартып тормагач, алар кибәләр. Шуны истә тотып, Татарстан Министрлар Советы 1978 елда, җирле су чыганакларын саклау максатыннан чыгып, 29 елганы, 30 күлне табигать тыюлыклары исемлегенә кертү турында карар кабул иткән иде. Боларга: Иж (Әгерҗе), Эстәрле (Азнакай), Олы һәм Кече Сөлчә (Аксубай), Сөн (Актаныш), Кече Чирмешән (Алексеев), (Әлки), Бәрле (Апас), Казан суы (Арча), Ютазы һәм Димскәй (Баулы), Шушма (Балтач), Зөя (Буа, Апас, Яшел Үзән), Сөлчә (Югары Ослан), Туйма (Алабуга), Норма (Кукмара), Шушма (Лениногорск, Чирмешән һәм Чистай), Дала Зәе (Лениногорск, Әлмәт, Зәй һәм Түбән Кама), Бөрсет-Бүрсет (Мамадыш), Минзәлә (Мөслим, Минзәлә), Олы Чирмешән (Чирмешән һәм Октябрьск), Мишә (Саба, Питрәч, Лаеш), Игәнә (Сарман), Бәтке, Әшнәк, Суша, Шомбыт (Балык Бистәсе), Үләмә (Тәтеш), Талкыш (Чистай) елгалары керә.

Бу елгалар үзләренең матур яр буйлары, тәмле һәм файдалы чишмә-чыганаклары белән кешеләр күңеленә шатлык, юаныч, сәламәтлек өстиләр, зәвык тәрбиялиләр. Күлләрдән: Казылган күл (Актаныш), Упкын (Алексеев), Акташ упкыны (Әлмәт), Олы Күл (Апас), Күл (Югары Ослан), Кара күл, Кәрәкәле күл, Мунчала күле (Биектау), Раиф, Белобезводный, Собакино, Провальный (Яшел Үзән), Карамалы, Урман күле (Кама Тамагы), Чуртан күле, Атаман күле, Чиста күл, Безымянный күле (Спас), Столбище, Кара күл, Сапуголи, Архиерей күле, Мүкле күл, Соломыков күле, Куян күле, Кәвәл күле, Чиста күл (Лаеш), Кара күл (Нурлат), Урман күле (Питрәч), Кара күл (Балтач) керә. Бу карар йогынтысында табигатькә игътибарлы мөнәсәбәт шактый көчәйгән иде. Чишмәләрнең вак һәм эре елгаларны су белән тәэмин итү чыганагы булуын искә алып, Татарстан Югары Советы «Чишмә» дигән чаралар оештырырга да чакырган иде. Аңа җавап итеп, республикабызның күп кенә урыннарында чишмәләрне барлау һәм чистарту оештырылды. Буа, Лениногорск, Мөслим, Азнакай, Чүпрәле, Кукмара, Аксубай, Саба, Апас һ. б. районнарда бу эшкә бик теләп катнаштылар, мәктәп укучылары да читтә калмады. Аксубай районы Яңа Дума мәктәбе укучылары мәктәп директоры җитәкчелегендә чишмәләрне чистарталар, кышын елгада бәке ачалар, бозын чабып торалар. Мондый мисалларны күп итеп китерергә мөмкин.

Ләкин хәзерге вакытта Татарстан җирлегендәге зур һәм кечкенә елгалар зур игътибарга мохтаҗ. Чишмә-чыганаклар томалану аркасында вак елгаларның күбесе кибеп бетте. Безгә аккан суны кадерләп саклау җитми.

Халкыбызның «йөзек кашы» саналган күлләрнең дә хәзер күбесе яшәүдән туктады. Республикабызда меңнән артык күл кибеп бетте һәм урыннары сөрелде. Халык тормышында күлләрнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеген «Күлем минем – күзем минем» дигән мәкаль раслый. Күл – күз белән чагыштырыла. Күлләрнең болай кибүе бары игътибарсызлык аркасында

булды. Ләкин әле матур, суы мул гына булган, тирә-юнендәге халыкны шатландырып, үзенең яшәвен дәвам иткән күлләр дә байтак. Аларны бик нык сакларга кирәк. Моның өчен аларга махсус паспортлар булдырырга һәм катгый исәпкә алу мөһим. Урыннарда күл кипкән саен, шул күл урнашкан җирдәге җитәкчеләрнең шәхси җаваплылыгын тәэмин итәргә кирәк. Күл дә – ил байлыгы, димәк, халык байлыгы. Күлләрне чистартуны гамәлгә кертсәк, алар төбеннән хуҗалык, җир өчен бик кыйммәтле ашлама алырга мөмкин булыр иде. Югары оешмалар моны көн тәртибенә куярлар бәлки. Басуларны сөргән вакытта елга-инеш, күл һ. б. чыганаклар буйларындагы чирәм җирне ялгыш кына булса да сөреп ташлаудан сакланырга кирәк. Чөнки яз көннәрендә тирә-юньдәге балчык, су чыганакларына төшеп, алар төбендәге чишмәләрне каплый, суын саектыра, төпләренә юшкын булып утыра.

Табигатьне саклау безнең җәмәгатьчелек өстендә. Исән чишмәләрне коткарып калырга, моңа кадәр яшәп килгән күлләрне савыктырырга әле соң түгел. Бары тик хуҗалык җитәкчеләре күңелендә табигатькә, су чыганакларына мәрхәмәт дигән бер хис уяту кирәк. Ләкин әйләнә-тирә мохитка, су чыганакларына әһәмият бирә торган җитәкчеләр саны бармак белән генә санарлык. Халык хуҗалыгын елга, инеш һ. б. су чыганакларыннан башка күз алдына китереп булмый. Елга-суларга шулай бармак аша гына каравыбыз якын киләчәктә, һичшиксез, тез астыбызга сугачак.

Башка республикаларда (әйтик, Чувашстанда) чишмәләрне планлы рәвештә чистарта башладылар. Ә менә Балтыйк буе республикаларында «Чишмәләр көне» үткәрелә. Бу көнне дистәләгән чишмәләр чистартыла. Аларга багышланган җырлар җырлана, уеннар уйнала. Мондый эшләрне безнең республикабызда да оештырырга мөмкин булыр иде.

Табигать байлыгы чиксез түгел. Һич кичекмәстән табигатькә ярдәм итү юлларын уйларга кирәк. Киләчәк буыннар безне начарлык белән искә алмасыннар иде.

***Чокыр***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чокыр* сүзенең *икенче мәгънәсе* «Җир өстендә яңгыр яки кар сулары туфракны юып барлыкка китергән озын, текә ярлы тирән урын, тирән иңкүлек; ерынты», дип бирелгән. *Монда Хәбирә карчык тыкрыгыннан үткәч тә шактый тирән, Әлбәк чокыры дип аталган сазлы һәм куе тал-тирәк үскән чокыр киткән.* Ш. Камал. *Чокырның төбендә, бака яфраклары арасында челтерәп салкын су ага*. И. Гази (ТТАС, III: 439). М. Кашгари сүзлегендә *казган јәр – уңкир – чуңкир, баткоклик ер, серерик ер* – «кар һәм яңгыр сулары белән юылган җирләр» (МК, 1: 411). В. Радлов сүзлегендә таранчы, кара-кыргызларда *ўнкўр* – «чокыр, уйсу урын, тау куышлыгы» (Радлов, I, Ч. 2: 1814).

Татарстан гидронимиясендә *чокыр* термины аерым елга атамасы булып та, елга атамалары составында да кулланыла. *Алан чокыры елгасы* – Шия суы кушылдыгы (Мамадыш районы). *Куш чокыр елга*сы – Кандыз елгасы кушылдыгы (Баулы районы). *Мал чокыры елгасы* – Ата елгасы кушылдыгы (Әлки районы). *Төкеш чокыры елгасы* – Калмия елгасы кушылдыгы (Мөслим районы). *Тау асты чокыры* – Яшел Үзән районының Юынчы авылы янында, Әрә елгасы бассейнында. *Кече чокыр* – Яшел Үзән районы Кече Өтәк һәм Апас районы Төбәк Черкене авыллары янындагы чокырлар, соңгысы Табар елгасына тоташа. *Камыш үзәк чокыры* – Апас районы Дәвеш авылы янындагы коры елга атамасы. *Бурычлы чокыры* – Апас районы Биябашы авылы янындагы елга-чокыр. *Бурышлы чокыры* – Апас районы Тәүгелде авылы янындагы чокыр. *Чокыр култыгы* – Әлки районы Иске Салман авылы янындагы урын атамасы. *Тырыйк чокыры* – Буа районында Кыр Кайбычы авылы янындагы Инеш бассейнында. *Убыр чокыры* – Апас районы Идрәс авылы янындагы Көрәнлек елгасы бассейнында. *Өч өзекләр чокыры* – Апас районы Аюкөйдергән авылы янындагы Тымбы елгасы кушылдыгы. *Мари чокыры* – Арча районы Наласа авылы янындагы чокыр атамасы. *Марта бакчасы чокыры* – Апас районы Дәүләки авылы яныннан ага торган Чирмешән суы кушылды-

гы. *Айблат чокыры* – Мамадыш районы Акман авылы янында. *Айманышки чокыры* – Кама Тамагы районы Иске Казиле авылы янында. *Айтуган чокыры* – Яшел Үзән районы Югары Урысбага авылы янында. *Айу аланы чокыры* – Тәтеш районы Келәш авылы янындагы чокыр. *Тау асты чокыры* – Яшел Үзән районы Юынчы авылы янындагы елга-чокыр. *Чокыр* – Апас районындагы Олы Үләмә елгасының сул кушылдыгы. *Ышна чокыры* – Яшел Үзән районында Әрә суы кушылдыгы. *Иске авыл чокыры* – Актаныш районының Адай авылында. Минзәлә районының Бикбау авылында *Кәшби чокыры, Ишәкәй чокыры* – авылның Түбән очындагы коры чокырлар һ. б. бар.

Актаныш районының Сәфәр авылында 1 Май урамы уртасыннан бер чокыр сузылган. Чокырның бер башы басудан башлана, ә икенче башы Терпеле елгасына кушыла. Шушы чокыр янында Сәгъди дигән абзый яшәгән. Шуңа бу чокырны *Сәгъди чокыры* дип йөрткәннәр. Бу чокырдан үтеп йөрү кыен булганга, Сәгъди абзый аның аша күпер салган булган. Хәзер инде аның урынында яңа күпер. Бу күперне дә *Сәгъди күпере* дип атыйлар.

Бу термин микротопонимнар составында да актив кулланыла: *Чокыр яны кыры, Чокыр буе, Чокыр култыгы* һ. б.

*Чокыр, чоңгыл, су, яка* һ. б. кебек лексик берәмлек-терминнар татар топонимиясендә элек-электән киң кулланылып килгәннәр һәм шуңа күрә алар әдипләр иҗатында да очрыйлар.

Гомәр ага Бәшировның һәр хикәя, повесть, романнарында географик терминнар, топонимнар очрыйлар. Әдипнең «Туган ягым – яшел бишек» басмасында урнаштырылган «Өйдән-өйгә» повестенда *чокыр* термины болай бирелгән: *«Менә югары очны да уздык, урамга ярып кергән тирән чокыр башын да уздык. Атылып мәчет янына да килеп чыктык».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә (истәлекләр)» китабында *чокыр* термины очрый: *«...Күрәбез, кызгылт-чия күн пальто кигән таза гәүдәле бер абзый сулы чокырларга басмаска тырышып койма буйлап узып бара».*

Айдар Хәлимнең «Кыйбла: хикәяләр, новеллалар» исеме белән дөнья күргән китабында чокыр сүзе шактый еш очрый: *«Көрәк сабына таянып, ул бер омтылыш белән чокырдан сикереп чыкты...»*

Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» исеме алган романында *чокыр* сүзе йөрәкләрне әллә нишләтеп җибәрә: *«Сөргендә вакытта ул (Мәһинур абыстай) Аллаһтан бер генә нәрсә сорады – туган ягына кайтып җитүне, мәңгегә шул туфракта калуны. Гүр иясе булып ач далада, уртак чокырда ятасы килмәде аның».*

Татарстаннан читтә яшәгән татарлар телендә дә *чокыр* шактый актив кулланыла. Самара өлкәсендә: *Муста чокыры, Усаклы чокыр* – Камышлы районының Яңа Усман, Татар Байтуганы авылларында коры елгалар. *Ибрай чокыры* – Северный районының Сукай авылында, Котлыгыш елгасы кушылдыгы һ. б. Бу өлкәдә *чокыр* термины белән микротопонимнар да очрый: *Әтәч чокыры кичүе, Зур чокыр тавы, Каран чокыры тавы* – Камышлы районының Иске Ярмәк, Татар Байтуганы авылларында.

Пермь крае Березовка районында *Чокыр* авылы бар.

Төрки телләрдә дә бу термин кулланылышта еш очрый: якут телендә *ункюр* «текә ярлы тирән күл, текә яр», күлләрнең тирән урыннары да *ункюр* дип атала (Гриценко, 1970: 1961). Казак телендә *чукур, чункур* – «чокыр», үрәнхәй – *ўнгўр* – «оя, аю оясы», казылып ясалган урыннар (Катанов, 1903: 262). Халха-монгол телендә *хунхур* – «түбәнлек, чокыр, түбән урын», бурят-монголларда *хунхэр* – «чокыр» (РБМС, 1954: 352). Урта Азиядәге Карадәрья бассейнында *Караункур* елгасы ага. Казакстанда *Караунгур* һәм *Унгуртас* топонимнары кабатлана. Азәрбайҗанда *Чухурьюрд, Гарачухур* исеме алган торак пунктлар бар. Бу термин Төрекмәнстан топонимиясендә дә актив кулланыла. Мәсәлән: *Чукур, Чукургала, Чукурюрт* исемендәге торак пункт атамалары һәм *Чукуркум* комлыклары. Урта Азиянең Байсунтау тауларында, тау араларында калган *Мингчукур* исеме алган басу һәм күл теркәлгән. Алтайда *Курчукур* күле,

Иранда *Чокуркенд* исеме алган торак пункт бар. Украинада, Черновицкий өлкәсендә *Чугур* – Прут һәм Дунай елгаларының сул кушылдыклары. (Сл. 1979: 615). Терминның таралыш ареалы Кавказдан Көнчыгыш Себергә кадәр.

***Чоңгыл*** термины «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «искергән сүз», «елгадагы яки күлдәге бик тирән чокыр, бик тирән урын» дип бирелгән. *Үрдәкләр йөзеп китәләр дә чоңгылда яткан усал җәен авызына кергәннәрен сизми дә калалар.* М. Әмир. *Левитанның «Чоңгыл янында» дигән рәсемен карагандa, аркылы салган бүрәнәләргә басып, аргы яктагы урманчыкка чыгып китәсе килә башлый.* Г. Бәширов (ТТАС, III: 441).

В. Радлов *чуңкур, чукур, чуңкурчак* сүзләренең таранчы, кара-кыргызларда: 1) тирән җир, 2) уем, иңкүлек, чокыр; телеутларда *чоң* «чуму, тирәнгә төшү» дигән мәгънәне аңлатуын яза (Радлов, III, ч. 2: 203а). Вамбери *чоңгыл* сүзенең «кечкенә буа, җыелган су, күлләвек» икәнлеген күрсәтә.

Бу термин географик атамалар барлыкка китерүдә дә катнаша: *Әбүзәр чоңгылы* – Кама бассейнында, Атабай авылы тирәсендә. *Чоңгыл каенлыгы* – Зөя бассейнында Яшел Үзән районында. *Җамали чоңгылы* – Кама бассейнында, Саескан тавы тирәсендә. *Чоңгыл күле* – Идел бассейнында, Жигули таулары янында.

*Чоңгыл* термины галимнәр, әдипләр иҗатында очрый. Гомәр ага Бәшировның «Чәңки-Чәңки, Чәңки җылан» повестенда *чоңгыл* турында мондый сүзләр язылган: *«Бу төпсез чоңгыл, сихерләгәндәй, мине үз яныннан җибәрми торды. Сагаеп кына шуның дерелдек кырына барып бастым да курка-курка гына көтә башладым: менә хәзер кайнап чыккан шикелле актарылыр-чайкалыр да, нәрсә дә булса калкып чыгар, я булмаса китапларда язылган әвен тикле теге диңгез балыгы күренеп китәр...».* Шул ук авторның «Җидегән чишмә» романында ономастика терминнары бик күп, хәтта онытыла башлаганнары да калкып чыккан. Классик әдип энҗе-мәрҗәннәрне хәтер төпкеленнән эзләп таба һәм халыкка кире кайтара. Гомәр аганың

бу романында *чоңгыл* термины еш кулланыла: *«Һи, җырлар, бәетләр күпме чыккан әле монда. Әле бу өстән-өстән йөгертеп кенә! Ә-ә-әнә теге биек ярны күрәсезме? Серле тау ул. Анда эчкә кереп югала торган яшерен юллар, чокырлар, әллә нәмәкәйләр бар. Борынгы бабайлар анда бакыр чыгарганнар. Ә аста җәennәр ята торган хәтәр дә тирән чоңгыллар бар. Шул бакыр тавының хуҗасы Пугачау явы килә башлагач нишләгән? Алтын-көмешен, бала-чагасын арбага төягән дә чабып килгән шәпкә тау өстеннән шул чоңгылга атылган!»*

Фатыйх ага Хөснинең «Сабан туе» хикәясендә мондый җөмлә укыйбыз: *«Күрәсең, барысы да эчендә булгандыр [хатыны Мәсрүрә пешекләгәнгә], килеп җитүебез булды тугайга, борылып карарга да өлгермәдек, чишенеп-мәшәкатьләнеп тормыйча, әле генә киенеп чыккан өр-яңа өс-башы белән, өч метрлы ярдан туп-туры чоңгылның нәкъ күзенә ыргылып төшмәсенме!»*

Вахит Имамовның «Сәет батыр» дип исемләнгән тарихи повестенда *чоңгыл* үзенчәлекле, шомлы итеп кулланыла: *«Падишаһның күзләрендә сәер, кыргый бер ут яна, аның һәр сүзе Михляевны әсир итә, гомумән, аны бу минутта гүя сихри чоңгыл үзенә тарта иде».* Авторның «Утлы дала» исемендәге тарихи романында мондый юллар укыйбыз: *«Шарлама читендә торган Айлы бикә нәкъ шулвакыт, керпе сыман бөгәрләнеп, чоңгыл өстенә томырылды һәм шундук юкка чыкты. Ясүгәй болан шикелле сикергәләп елга өстенә ыргылды. Берничә мизгелдән инде ул да, ук сыман томырылып, чоңгыл эченә кереп чумган иде».*

Бу термин төрле мәгънәләр белән татар теле сөйләшләрендә еш очрый. Урта диалектның минзәлә сөйләшендә *чөңгөл* – «болыннарда, елга буйларында язгы ташу вакытында кечкенә чокырларга кереп калган күлләр», *йөгермәк* – «кар һәм яңгыр сулары җыела торган уйсу җир», *чоңгол* – «сикәлтә, юлдагы чокыр-чакырлар»; гәйнә сөйләшендә *чумгыл* – «су төбендә барлыкка килгән чокыр, чоңгыллар». Типтәрләрдә суның тирән урыны – *чоңгылт* дип йөртелә.

*Чоңгыл*ны Башкортстандагы эйек-сакмар сөйләшендә *соңгор/соңгол* диләр, ул «су упкыны, су өермәсе, су төбендәге чокыр»ны белдерә. Галимнәр язуынча, Самара өлкәсенең Келәүле районыннан агып үтә торган Олы Чирмешән елгасының уң кушылдыгы *Суңгур* атамасын йөртә, аның башлангычының төрки телдән булуы шик уятмый (Барашков, Дубман и др., 1966: 161). Көнбатыш Себердә чоңгылны белдерү өчен *соңол* термины йөри. Анда *Сунгул* исемле күл дә бар. Якут телендә *чөңөрө* – 1) тирән урын, 2) кечкенә күл, елга кушылдыгы, 3) Якут Сахасындагы күл, торак пункт атамалары: *чөңөlөх* «кечкенә күл»; *Чөңөlөк* – Лена дельтасындагы күл (Пекарский, XIII: 3670). Казакстан гидронимиясендә *шунгыл* (карталарда – *чунгул*) – «күлнең яки елганың бик тирән урыны, упкын, су өермәсе; чоңгыл, тоба» (Конкашпаев, 1963: 41). Төрекмән телендәге *чунгул* – «елгаларның түбән агымнарында тирән сөзәк чокыр», монгол телендәге *цунхээл* – «елга, күл төбендә тирән чокыр, чоңгыл, тоба».

***Чура***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «искергән тарихи исем» дип бирелгән, *беренче мәгънәсе* болай аңлатылган: Әсирлеккә төшеп, кол ителгән кеше. [Уразмәт:] *Хан җиребезне безнең тартып алды, ... Бар ир затын чура-кол итте*. М. Җәлил.

*Икенче мәгънәсе*: Алтын Урда чорындагы ханнарның сәяси вассалы, аерым гаскәр башлыгы.

*Өченче мәгънәсе*: XVII–XVIII гасырларда әсирлеккә төшеп крепостной ителгән кеше. *Йомышлы татарлар пленга төшкән кыргыз-кайсак, калмыкларны алып кайтып, хуҗалыкларында чура (крепостной) итеп җиргә утырта торган булганнар*. С. Алишев (ТТАС, III: 447).

А.К. Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *чура* «тарихи» дип беркетелгән һәм аңлатмасы болай тасвирланган: «Төрки шаһанатта, Идел буе Болгар илендә, Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында хезмәттәге аксөякләрнең титулы (аны болгар чоры кабер ташларындагы «йуари, йөри» атамасы белән тәңгәлләштерәләр).

Соңрак бу сүз «буйсынган кеше, вассал, кол» мәгънәсен алган. Рус телендәге «холоп» мәгънәсенә дә туры килә. Р. Әхмәтьянов аны санскрит теленнән үк кергән дип фараз итә (*яугир, хәрби* сүзеннән). *Чура* сүзе *Акчурин, Байчурин, Канчурин, Карачурин, Колчурин, Синчурин, Тинчурин* фамилияләрендә катнаша. Русларда сакланган *Чуриков, Чуренных* кебек фамилияләрне дә шушы рәткә кертеп карарга кирәк.

Татарча язма чыганакларда сакланган немец *чурам,* поляк *чурам* сүзләренә караганда татар аксөякләре тоткан коллар арасында чит ил кешеләре дә булганлыгы күренә. // *Кутунай хатыныннан сатуб алган Әрина улы Курманай атлыг чурамны энемез Динмөхәммәд морзага мирас итәм.* Васыятьнәмәдән (XVII гасыр). *Кол-чура, чура-кол».*

*Чура* лексик берәмлеге белән географик берәмлек атамалары да очрый. *Чура алачыгы күле* – Арча районындагы Наласа елгасы бассейнында. *Чура апай урамы* – Арча районы Казанбаш авылындагы урам атамасы. *Чура алачыгы күле* – Арча районы Абҗабар авылы янындагы, Аты елгасы бассейнында. *Чура алачыгы үзәне елгасы* – Арча районы Наласа авылы янында, Наласа елгасы бассейнында.

***Чүнник***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *чүнник* термины «исем, диалекталь сүз» дип бирелгән һәм «Умарталык, умарталар куелган урын, бал корты хуҗалыгы», дип ныгытылган. *Иске чүнниктә чокырга күмелгән җирдән әллә никадәр бодай чыкты.* Г. Бәширов (ТТАС, III: 479).

*Чүнник* термины географик атамалар ясауда да актив кулланыла. *Мәннаф чүнниге* – Мамадыш районы Югары Яке авылындагы умарталык атамасы. *Мохыт чүннеге* – Питрәч районы Шәле авылындагы умарталык атамасы. *Чапи чүннеге елгасы* – Мамадыш районы Владимир авылы янындагы Кече Бүрсет суы кушылдыгы, *Чиннек болыны* – Биектау районы Ямәширмә авылы янындагы болын атамасы. *Әхмәтша чүнниге* – Мамадыш районы, Югары Бүрсет авылы янындагы урын атамасы. *Чүннек аланы* – Арча районы Сикертән авылы янындагы алан атама-

сы. *Чүннек асты чишмәсе* – Лаеш районы Татар Янтыгы авылы янындагы чишмә. *Чүнник күпере* – Теләче районы Кече Нырсы авылы янындагы күпер, *Чүнник тавы* – шул ук авыл янындагы тау атамасы. *Чүннек чишмәсе* – Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк авылы янында. *Мулла чүннеге елгасы* – Теләче районы Алан авылы янында. *Әхмәтша чүннеге* – Мамадыш районы Югары Бүрсет авылы янындагы урын атамасы. *Шәйхулла чүннеге* – Мамадыш районы Югары Бүрсет авылы янындагы урын атамасы. *Ибети чүннеге* – Мамадыш районы кече Бүрсет авылы янындагы умарталык атамасы.

***Шарлавык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу термин болай аңлатылган: 1. Түбәндәге яки ярындагы ташларга бәрелә-бәрелә шаулап ага торган сай су. *Теләсә нинди фонтанны да борып куярга, туктатырга, хәтта язгы шарлавыкларны да тыярга мөмкин.* А. Шамов. *Кар эреп бетте. Шарлаыклар гөрләшеп актылар да, каядыр, җир астына төшеп югалдылар*. Н. Дәүли. *Үзән шарлавыгы да арба аудара*. Мәкаль.

2. кара. *Шарлама. Шарлавыклар тау елгаларында бигрәк тә еш очрый.* Физ. геог. *Үзенең чая гомерен таудан ага торган шарлавык төсле тиз һәм шаулап уздырган йөрәкле егет минем күңелгә дә әнә шулай нык булып утырып калды*. Ф. Хөсни. (ТТАС, III: 492).

***Шарлавыклы.*** Сыйфат: шарлавыклары булган, шарлавыклардан торган; шарлавыклар аша уза торган. – *Мин таулы, кыялы, шарлавыклы юлларны җәяү җиңеп чыккан кеше.* Ә. Фәйзи (ТТАС, III: 492).

***Шарлама.*** Исем. Елганың су ташкыны текә биеклектән төшә торган урыны. *Тянь-Шань тауларыннан шаулап аккан шарлама төсле, Арысландай каһәрләнгән тавышлар бар, гаҗәп көчле*. М. Гафури. *Текә тауга озак карап торсаң, ул агып килә сыман тоела, әйтерсең шарлама кебек югарыдан ишелеп төшә.* Г. Әпсәләмов. // Күчмә мәгънә белдерә. Кискен үзгәреш. *[Тормыш] агымын көчәйтә, я акрынаеп тора да, шарлама ясап, кинәт түбәнгә ургыла*. А. Гыйләҗев (ТТАС, III: 492).

***Шалтыравык, шалтыравыклы*** лексик берәмлекләренең географик исемнәргә нисбәтле мәгънәсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бирелмәгән.

*Шарлавык, шарлама, шалтыравык* терминнары географик берәмлек атамалары буларак еш очрыйлар: *Шарлавык* – Әлки районы Түбән Әлки, Апас районы Дәвеш, Буа районы Яңа Тинчәле авыллары янында. *Шарлавык чишмәсе* – Сөлчә елгасы бассейнында, Чирмешән районы Яңа Кади авылында. *Шарлавык асты болыны* – Биектау районы Юртыш авылында. *Шарлавык чокыры* – Актаныш районы Иске Байсар авылындагы урын атамасы. *Шарлавыклы күл елгасы* – Алексеев районы Урта Тигәнәле авылы янында Тигәнәле елгасына кушыла. Шушы ук авыл янында *Шарлавыклы күл* атамасы алган су чыганагы да теркәлгән. *Шарлама* – 1. Аксар суы башланган урын, Зәй районы Югары Шепкә авылы янында; 2. Апас районы Иске Йомралы авылы янында; 3. Кама Тамагы районы Иске Казиле авылы янында. *Шарлама күл* – Актаныш районы Куян авылында, Агыйдел елгасы бассейнында. *Шарлама чыгыш* – Кама Тамагы районы Иске Казиле авылында. *Шарлама чишмә* – Мамадыш районы Түбән Козгынчы һәм Өчиле авыллары янында. *Беренче шарлавык* – Буа районы Иске Суыксу авылы янында. *Икенче шарлавык* – Буа районы Иску Суыксу авылы янындагы Иштуган суында. *Сарсаз шарлавыгы* – Әлки районы Иске Чаллы авылы янындагы шарлавык атамасы. *Шалтыравык чишмә* – Түбән Кама районы Ширәмәт авылында, Ширәмәт елгасы кушылдыгы. *Шалтыравык* – 1. Арча районы Мөндеш авылындагы, Ия елгасы бассейнында; 2. Кама Тамагы районы Кече Кариле авылы янындагы Коры Үләмә суы бассейнында. *Шалтыравык йылга* – 1. Норма суы кушылдыгы. Балтач районы Чапшар авылында; 2. Томбарлы елгасы кушылдыгы. Баулы районы Татар Томбарлысы авылы янында. *Шалтыравык елгасы чишмәсе* – Кама Тамагы районы Кыртапа авылы янында, Коры Үләмә елгасы бассейнында. *Шалтыравык кизләү* – Кайбыч районы Олы Урсак авылы янындагы кизләү, Имәлле елга-

сы бассейнында. *Шалтыравык кизләү елгасы* – Кама Тамагы районы Олы Салтык авылы янында, Ылгыма буе бассейнында. *Шалтырамалы чишмәсе* – Биектау районы Суыксу авылы янында, Сая елгасы бассейнында. *Шалтыравыклы кизләү* – 1. Төбәк суы бассейнында, Кама Тамагы районы Келәнче авылы янында; 2. Олы Шаһиан суы бассейнында, Кама Тамагы районы Олы Болгаер авылында. *Шалтыравыклы кизләү чокыры* – Кама Тамагы районы Келәнче авылы янында. *Шалтыравык тавы* – Кама Тамагы районы Кече Кариле авылы янындагы тау атамасы. *Шалтыравык чишмә* – Арча районы Өчиле авылы янында. *Шалтырама чишмәсе* – Биектау районы Чуваш иле авылы янындагы чишмә.

Бу терминнар әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында кулланыла. Фатыйх ага Хөсни «Йөзек кашы» повестенда *шарлавык* терминыннан матур файдаланган: *«Үзенең чая гомерен, таудан ага торган шарлавык төсле, тиз һәм шаулап уздырган ул тәвәккәл егет минем күңелгә дә әнә шулай нык булып утырып калды»*.

Вахит Имамовның «Утлы дала» дип дөньяга чыккан тарихи романында *шарлама, шарлавык* терминнары файдаланыла: *«Ә бер ук очышы кадәрле ара узуга, елга, кисәк сынган сыман, текә шарламага әверелә». «Андрей, биек таудан аккан шарлавык сыман, капылт кайнап купты»*. Монда *шарлавык* күчерелмә мәгънәдә кулланылган.

Язучы Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» романында мондый юллар бар: *«Тау араларыннан челтерәп чишмәләр агып чыга, алар, кыя ташлардан түбән сикереп, шарлавык ясыйлар. Шарлавыклар исә тау елгаларына коялар»*.

Бу терминнар төрки телле халыклар географик атамалары буларак та, атамалар составында да киләләр.

Татар телендә *шарлама* «шарлавык, шарлама, агым, ачыш» мәгънәләрен аңлата. Кыргызларда ул – *шаркыратма*, төрекмәннәрдә – *шарлавук*. Чагыштыр: *шарла* фигыле «тиз агу», «шылтырау», «челтерәп агу», «чылтырап агу» мәгънәләрен дә аңлата.

Төмән өлкәсендә *Шарлама* елгасы ага. *Шарлаук елгасы* Үзбәкстанда Хорезм һәм Красноводский өлкәләре җирләрен сугара. *Шаршара* – үзбәк һәм таҗик халыкларында «елгадагы бусага», «шарлама», «ургыл, каты агым (елганың бик каты ага торган урыны)». Чагыштыр: үзбәкләрдә *шар* – «тавышка ошатып гөбердәп, чурлап, челтерәп, шалтырап агу». *Шаркырама* – «ургылып чыгып, быкырдап кайнап, ярсып һәм дулкынланып, ярсуланып җиргә чыгып агу», «буйсынмас, көчле булып ага торган елга». Таҗикстанда *Шаршара* елгасы ага.

***Ызан.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ызан* компоненты «исем» дип бирелгән һәм «Җир биләмәләре, кишәрлекләр арасында чирәмле буй яки тирән буразнадан гыйбарәт сызык, чик», дип аңлатылган. *Яшел ызаннар белән шакмакланып беткән кыр өстендә, дулкын-дулкын булып зәңгәр рәшә йөзә.* А. Алиш. *Ул юлдан читтәрәк, тирән ызанга кереп йоклаган иде.* Г. Бәширов (ТТАС, III: 544).

***Ызандаш***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек «исем» дип ныгытылган һәм аңа мондый аңлатма бирелгән. «Ызан буенча күрше, кем белән дә булса ызаннары уртак, чиктәш булган кеше». *Ызандашларының сүзен күңеленә сеңдергән саен, аның йөзе яктыра барды*. Г. Мөхәммәтшин // Сыйфат мәгънәсе. «Ызаннары уртак, янәшә, чиктәш булган». *Берсе белән берсе ызандаш җирдә эшләүдән сакланып килгән Шәрәфнекеләр дә, Зәйдулланыкылар да бер ызанда эшли башладылар.* Г. Галиев (ТТАС, III: 544).

*Ызан, ызандаш* лексик берәмлекләре топонимнар ясауда катнаша: *Ызан кискән* – Кама Тамагы районының Каратал авылы янындагы җир атамасы, *Ызан күле* – Апас районының Төбәк Черкене авылы яныннан агып үткән Табар елгасы бассейнында (бу күл хәзер кипкән). *Мәхмүт ызаны* – Әтнә районы Ябынчы авылы. *Биек ызан юлы* – Саба районы Көек авылы янындагы юл.

Нурулла Гарифның сүзлегендә *ызан* сүзе урын алган: «Бетковская межа (Бәтке *ызаны*) – № 54. Ямашурминская

Куркачевская да Урмацкая Новые межи (Ямаширмә, Коркачык, Урмат авылларының яңа ызаны) – № 81» (Н. Гариф, 2011: 53).

*Ызан* термины әдипләр иҗатында да очрый. Гомәр ага Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» дип исемләнгән китабындагы «Язгы сабан туйлары» повестенда *ызан* сүзе очрый: *«...Чаба башлаганчы күрше белән ике арага ызан сызарга кирәк икән әле. Әти кечтеки абыйга, елга буена төшеп, андагы казыктан туп-туры үзенә таба үлән ерып менәргә кушты. Үзе, чалгысын тотып, бу баштагы билгегә килеп басты».*

Фатыйх ага Хөснинең «Без яшь идек» повестыннан шундый юллар укыйбыз: *«Сыерга ашлык әзерлисе бар, әниләре капчык тоттырып, елга буйларыннан, ызаннардан чабылмыйча калган калдык-постык үләннәрне җыеп алып кайтырга җибәргән».*

Айдар Хәлимнең «Кыйбла: хикәяләр, новеллалар» китабында *ызан* термины болай файдаланылган: *«Монда дус та, дошман да юк, ә бары тик тигез туганлык, бер-береңә изге теләкләр генә хөкем сөргән бу даирәдә беркем дә күрә алмаган, күрү мөмкин дә булмаган бер бөек сәхифә ярала иде: ул да булса, Бәгърем дигән егет, гармунын күтәреп, үз гадәтләре, үз холыклары белән үз тормышының яңа ызаннарына чыгып килә иде...»* (бу очракта *ызан* термины күчерелмә мәгънәдә кулланылган).

***Ындыр***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ындыр* лексик берәмлеге «исем» дип беркетелгән һәм *беренче мәгънәсе* болай бирелгән: «Урылган ашлыкны саклау, киптерү, сугу, җилгәрү өчен махсус җайланган урын, корылма». *Ындырыңда ни булса, келәтеңдә шул булыр*. Мәкаль. *Ябык ындыр эчендә, тирә-яктагы бөтен әйберләрне селкетеп, сугу машинасы үкерә, җилгәргеч зырылдый, кешеләр кайнаша*. Г. Әпсәләмов.

*Икенче мәгънәсе* исә диалекталь дип бирелгән: «Бәрәңге бакчасы». *Өстәлне җыештыргач, [Гайния] ындырдан бер чиләк эре бәрәңге алып кайтты, кое төбендә корып юды да, пешереп безне сыйлады.* Г. Ибраһимов (ТТАС, III: 546).

*Ындыр арты* – 1. Гомумән йорт-каралтылар артындагы урын. – *Мин дә уракка чыгыйм әле, ...Ындыр артыннан үземә бүлеп бирерсез дә, тик кыркып ятармын шуны.* Г. Бәширов.

***Ындырчы***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу термин «исем» дип ныгытылган һәм аңлатмасы түбәндәгечә бирелгән: «Ындыр эшендә эшләүче». *Якуп: «Армый эшләгез», – дип кычкырды. Ындырчылар рәхмәт әйттеләр.* И. Гази. *Садыйков... ындырчылар янында да булырга өлгергән.* С. Рафиков (ТТАС, III: 546).

*Ындыр, ындырчы, ындыр арты* гыйбарәләре географик берәмлекләр ясауда шактый кулланылалар, чөнки элек һәр авылда *ындыр* һәм *ындыр табаклары* булган. *Түбән ындырчы күле* – Апас районы Кормаш авылы янындагы күл. *Ындыр арты* – Лениногорск районы Түбән Чыршылы авылы янындагы урын атамасы. *Ындыр арты* яисә *Коерык* – Мөслим районы Симәк авылы янындагы урын атамасы. *Ындыр арты басу* – Балтач районы Көек авылы янындагы басу атамасы. *Ындыр арты сазлыгы* – Кукмара районы Чуллы авылындагы географик берәмлек. Ул Чуллы елгасы бассейнында. *Ындыр елгасы* – 1. Арча районы Утар Аты, 2. Чистай районы Кече Бахты авыллары янындагы елгалар. *Ындыр тавы* – Мамадыш районы Вахит авылы янындагы тау атамасы. *Ындырчы елгасы* – Апас районы Югары Ындырчы авылы янындагы атама. *Ындырчы тавы* – Апас районы Болын-Балыкчы авылы янындагы тау атамасы. *Ындырчы урамы* – Яшел үзән районы Татар Танае авылы янындагы урам атамасы.

*Ындыр* термины әдипләр иҗатында еш очрый. Фатыйх ага Хөснинең «Без яшь идек» повестенда *ындыр* лексик берәмлеге кулланыла: *«Бер көнне колхоз ындырында ашлык тазарткан җиреннән әлеге шул кесәсенә бодай тутырып алып кайткан бу, ләкин барып чыкмады, шундук артыннан колхоз председателе Ярулла абзый протезлы аягы белән шакы-шокы килеп тә керде».*

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» исеме алган повестенда *ындыр* лексик берәмлегә кулланылган: *«Ындыр*

*артында тачкасына ярты кочак ат кузгалагы салган сипкелле, борыны кубалакланган бер малай, күзләрен челт-челт йомып, сәерсенеп Асафка карап торды да тачкасын ташлап авылга йөгерде».*

Фоат Садриевнең «Бәхетсезләр бәхете» исемендәге романының икенче китабында *ындыр табагы* термины кулланылган: *«Партком утырышыннан соң ул комбайнчылар янында да сөйләшеп алган, ындыр табагында да булган, яңа сортларны да берәм-берәм барлап чыккан иде».*

Язучы Әсгать Салахның «Казан утлары» (2013, № 1) журналында дөнья күргән «Аккан сулар...» чәчмә әсәрендә *ындыр табагы* лексик берәмлеге кулланыла: *«Ындыр табагыннан караңгы төшкәч кенә кайтып китәсең, ә таң беленү белән үк, иртәнге сәгать дүрттә-биштә сиңа кабат торып китәргә кирәк».*

***Ышна.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *ышна* лексик берәмлеге «исем, искергән сүз» дип бирелгән һәм болай аңлатылган: «Урман эчендә чәчүлек өчен төпләнгән, әрчелгән кыр». *Ышна бүлешү*. // Сыйфат мәгънәсе: «ышнага мөнәсәбәтле». *Ышна хуҗалыгы.*

*Ышна ачу* – урманны төпләп, яндырып, агач-төпләрдән арындырып, чәчүлек (ышна) ясау.

*Ышна җире* урманны төпләп, яндырып, агач-төпләрдән арындырып ясалган чәчүлек җир. *Ышна җиренә мендек без, Өч авыл бергә җыелып.* Бәет (ТТАС, III: 554).

А.К. Тимергалин җыеп чыгарган «Миллият сүзлеге»ндә *ышна* лексик берәмлеге тарихи яктан аңлатылган: «1. Урман төпләп һәм яндырып ясалган иген басуы. // *Ышна ачу.* 2. Урман эчендә чәчүлек өчен яки печән чабып алу өчен аерым хуҗалыкларга бүлеп бирелгән алан. Аерым хуҗалыклар заманында ышналарның исемнәре дә булган».

*Ышна* лексик берәмлеге топонимнар ясауда актив кулланыла. *Ышна* – Буа районының Адав-Толымбай авылы, Апас районының Иске Әнәле, Кама Тамагының Каратал, Балтач районының Биктәш, Саба районының Алан-Елга авылы, Яшел Үзән

районының Зур Ачасыр, Аксубай районының Яңа Ибрай авыллары янындагы басу атамалары; *Ышна басуы* – Апас районының Сатмыш, Тәтеш районының Келәш, Яшел Үзән районының Татар Танае авыллары янындагы басулар; *Ышна яңасы* – Буа районының Күл Черкене авылы янындагы зур печәнлек; *Ышна ригәсе* – Тәтеш районының Кече Әтрәч авылы янындагы өсте ябылган әвен; *Ышна тавы* – Кайбыч районы Зур Кайбыч авылы янында, *Ышна чирәме* – Кама Тамагы районы Балчыклы авылы янында. *Габит ышнасы* – Балтач районының Норма авылы янындагы басу атамасы. *Таһир бабай ышнасы* – Апас районы Аюкөйдергән авылы янындагы басу атамасы. *Крипит ышнасы* – Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы янындагы басу атамасы. *Ышна тавы елгасы* – Мамадыш районының Кече Сон авылы янынннан ага торган Сон елгасы бассейнында. *Минглич ышнасы* – Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылы янындагы басу атамасы һ. б. *Миңкә бабай ышнасы* – Апас районының Аюкөйдергән авылы янындагы басу атамасы. *Кыз ышнасы* – Апас районы Кызыл Тау авылы янындагы басу атамасы. *Кыяк ышнасы* – Балык Бистәсе районы Катмыш авылы янындагы басу атамасы. *Кыяр ышнасы* – Тәтеш районы Олы Әтрәч авылы янындагы басу атамасы. *Ат ышнасы* – Биектау районы Юртыш авылы янындагы басу атамасы. *Абыз авыл ышнасы* – Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында (Кама Тамагы районындагы Менглич авылын икенче төрле Абыз авыл дип йөртәләр). *Вәчкә ышнасы* – Апас районы Аюкөйдергән авылы янындагы басу атамасы. *Кече ышна* – Спас районы Кырый Йорт күл авылы янындагы басу атамасы. *Кырый ышна* – Апас районы Кече Күккүз авылы янындагы җир атамасы. *Җитен ышнасы* – Әгерҗе районы Ямурза авылы янындагы көтү урыны. *Карлыган ышнасы* – Апас районы Дүртөйле авылы янындагы ышна атамасы.

*Ышна* лексик компоненты бәетләрдә «Ышна бәете», әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында очрый.

***Юл***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *юл* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе дә бирелгән.

*Беренче мәгънәсе*: «Бер торак пункттан икенче торак пунктка яки эш урынына һ. б. (гадәттә аерым транспорт ярдәмендә) йөрү өчен хезмәт итә торган тапталган яки махсус түшәлгән җир буе, җир кишәрлеге». *Ат юлы. Чама юлы. Юл салу. Юлга таш түшәү. Юл – юл булыр, тигез булыр, үргә менәр, Түбән төшәр, бер киңәер, бер тар булыр*. Р. Мингалимов. *Күзге кебек ялтырап яткан асфальт юлдан машиналар үтеп тора*. А. Әхмәт. // Өстеннән яки эченнән хәрәкәт, аралашу башкарыла торган тирәлек турында. *Һава юлы. Су юлы*.// Берәр тоткарлык, киртә һ. б. аркылы үтәргә мөмкин булган урын. *Су икенче юл тапкан ахры, забой коры*. И. Гази. *Үзебезнекеләр ягына ничек юл табарга*? К. Нәҗми. *Икенче мәгънәсе*. «Бергә җиргә, урынга барып җитү өчен сайланган яки эзләп табылган уңайлы маршрут, юнәлеш». *Юл югалту. Юлны юлга чыккач табалар*. Мәкаль. – *Син юлны яхшырак беләсең: чык алга*! И. Гази. //Алган юнәлеш, бару юнәлеше. *Без тагын үз юлыбыз белән киттек*. Ф. Әмирхан. *Ну, Әпрәү, монда эшең бетте. Бар инде юлыңа*. М. Фәйзи. *Мәче... муенын сузып һаваны иснәде, аннары килгән юлы белән ялкау гына кайтып китте*. И. Гази (ТТАС, III: 606).

А.К. Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *юл арачы* лексик берәмлеге түбәндәгечә ныгытылган: «тарихи сүз. Алтын Урда ханлыгында юлларны карап, тәртиптә тотучы».

*Юл* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда шактый актив кулланыла. *Бушанчы юлы* – Кайбыч районы Олы Урсак авылы янындагы юл атамасы. *Бүре юлы* – Балтач районы Норма авылы янында (бу юл буйлап авылга бүреләр килгән). *Пугачев юлы* – Әгерҗе районы Тирсә авылы янындагы юл атамасы. *Баскан юлы* – Мамадыш районы Бүрсет-Сөкәче авылы янындагы юл атамасы. *Яман юл* – Лениногорск районы Шушма/Чишмә елгасы кушылдыгы. *Яна юлы басуы* – Кама Тамагы районы Кече Салтык авылы янындагы басу атамасы. *Янык юлы* – 1. Арча районы Сикертән, 2. Саба районы Түбән Симет авыллары яннарындагы юл атамалары. *Йантуган юлы* – Кама Тамагы

районы Келәнче авылы янындагы кыр атамасы. *Яңа авыл юлы* – Теләче районы Түбән Саурыш авылы янындагы юл атамасы. *Яңа Чаллы юлы* – Әлки районы Иске Чаллы авылы янындагы юл атамасы. *Чүпрәле юлы* – Чүпрәле районы Мунчәли авылы янындагы юл атамасы. *Иске кала юлы* – 1. Теләче районы Алан, 2. Питрәч районы Кибәче авылларында юллар атамасы. *Каз башы юлы* – Саба районы Олыяз авылы янындагы юл. *Югары йаз юлы* – Саба районы Тимершык авылы янындагы юл атамасы.

Нурулла Гарифның зур әһәмияткә ия сүзлегендә *юл* термины белән тарихи атама теркәлгән: «Арская дорога (Арча юлы – даругасы)».

*Юл* лексик берәмлеге әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында кулланыла. Габдулла Тукайның «Туган җиремә» исеме алган шигырендә *юл* термины еш очрый:

*Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,*
*Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың.*

***Юлавыч*** – бу тарихи сүзнең мәгънәсе «Миллият сүзлеге»ндә болай бирелгән: «Тизгер хәбәрче, курьер». «Апостол, пәйгамбәр, хәварийун» мәгънәсендәге *йәлавыч* сүзенә тәңгәл (Сәгыйть Хәлфиннең кульязма сүзлегенә теркәлгән. Кашгарида да очрый, «Рисаләи Газизә»дә – *ялавыч*). Э.Н. Нәҗип *юлавыч* сүзе «юлны яктыртыучы» мәгънәсендә булырга мөмкин дип фараз итә.

***Юламан*** – турында «Миллият сүзлеге»ндә «Сәфәрчеләргә юл – үткел күрсәтеп, аларны озатып баручы, кулавыз, рәһбәр, гид // *Яманнан яман кем яман? Ят явына юламан.* Мәкаль».

***Юллама*** – «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә теркәлгән сүз. Хәзерге вакытта аның гадәти мәгънәләренә («путевка»; «фатиха») яңа мәгънә («послание») өстәлде. // *Президент юлламасы. Еллык юллама* һ. б.

***Як***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә як лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе анык аңлатылган:

1. Нинди дә булса юнәлеш һәм шул юнәлештәге пространство, урын. *Урман ягы. Шәһәр ягы. Кояш иңгән якта болытлар аллы-кызыллы җемелди*. Ш. Камал. *Захаров, иптәшләрен калдырып, алга, ат һәм кеше тавышы ишетелгән якка таба үрмәләде*. А. Шамов; 2. Нинди дә булса бер өлкә, төбәк, ил. *Минзәлә ягы. Тау ягы. Туган як. Беләк сызганып, югары белем (вуз) диңгезенә кереп киткәч, тәмам тулы бер кеше булып чыкмый торып, ул якларга тиз генә әйләнергә туры килмәс*. М. Җәлил. *Зәңгәр төнле җылы яклардан күпме кошлар килеп киткәндер*. К. Нәҗми. *Бик кечкенә идем ул вакытта, Белми идем Херсон якларын*. З. Мансур; 3. Урталыктан читтә (уңда яки сулда) булган урын, пространство; шулай ук кемнән яки нәрсәдән дә булса уңдагы яки сулдагы урын. *Һаман сак бул, кара ул як, бу якны*. Г. Тукай. // Елга, урам, юл кебек буйга сузылган нәрсәләрнең ян-ягына, кырына урнашкан урын, пространство. *Урамның сул ягы. Күпер аркылы теге яктан бу якка сыерлар чыгалар*. И. Гази. *Днепрның уң як ярында, Көзге таңда томан сарыла*. Ф. Кәрим (ТТАС, III: 625).

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, «***Арйак җыены*** яисә ***ар җыйынын*** июнь ахырында Тукташ җыены үткәргәннән соң бер атна үткәч Вятканың уң кушылдыгы Өшия елгасы бассейнында урнашкан татар авыллары Татар Дөм-Дөме, Морт (Иске Юраш), Илмәт~Илбәт авыллары халкы бәйрәм иткән».

Җыйынның *Арйак* атамасы *арйак* лексик берәмлегеннән < *аргы + йак* «елга аръягы» сүзеннән алынган. Икенче атамасы *Ар* удмуртларны татарлар атый торган *ар* этнонимыннан ясалган.

Татар топонимнары арасында *як* лексик берәмлеге белән ясалган атамалар байтак. *Буләр ягы* – Алексеев районы Карга авылында урам атамасы. *Басу капкасы ягы* – Апас районы Иске Әнәле авылында. *Югары як* – Балтач районы Түбән Кенә авылындагы урам атамасы. *Югары як урман* – Яшел Үзән районындагы Олы Җәке авылы янындагы урман атамасы. *Әчелек ягы чишмәсе* – Балтач районы Смәел авылында. *Пожарный*

*ягы* – Чирмешән районы Иске Кади авылындагы урам атамасы. *Зират ягы* – Арча районы Кырлай авылындагы урам атамасы. *Зират ягы урамы* – 1. Әлки районы Иске Салман, 2. Арча районы Кырлай авылларындагы урам атамалары. *Зират як басу* – Балтач районы Кили авылы янындагы басу атамасы. *Зират як болын* – Саба районы Керәнне авылы янындагы болын атамасы. *Зират як елга* – Арча районы Урта Бирәзә авылы янында Бирәзә елгасына кушыла. *Янган як* – Яңа Чишмә районы Чаллы башы авылының бер өлеше (ул элек янган булган). *Биш мунча ягы басуы* – Баулы районы Бәйрәкә авылы янындагы басу атамасы. *Биш мунча ягы* – Бөгелмә районы Сугышлы авылындагы урам атамасы. *Биш мунча ягы очы* – Баулы районы Бәйрәкә авылындагы бер оч. *Каралык ягы* – Мамадыш районы Баскан авылындагы урам атамасы. *Шайтан ягы елгасы* – Саба районы Сатыш авылы яныннан ага торган Казкаш елгасы кушылдыгы. *Шөкә ягы* – Арча районы Шушмабаш авылыннан Шөкә авылына бара торган юл юнәлеше.

*Як* лексик берәмлеге әдипләребез иҗатында еш очрый. Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» романында *як, ягы* лексик берәмлекләре топонимнар ясауда байтак кулланылалар: *«...Мин ышанмый башладым инде. Алар телләре белән табигатьне шундый кайгыртып сөйлиләр, шундый ялкынлы мәкаләләр язып чыгалар, укыйсың да ышанасың: менә кая ул үз ягының патриоты, менә кемнәр саклап калачак туган яклар табигатен, дисең! Бактың исә!.. – Камил, шулай булуына хәйран калгандай, кашларын сикертте, кулларын җәеп җибәрде. – Бактың исә, күз буяу гына икән ул! Телләре белән тегермән тарттыра, куллары белән табигатьнең җелеген суыра икән алар!..*

Фатыйх ага Хөсни «Йөзек кашы» повестенда *як* лексик берәмлегеннән матур файдалана: *«Таллар, елганың уң як ярлары буйлап, һаман сузылалар. Без инде нәкъ авыл турында».*

Вахит Имамовның «Утлы дала» исеме алган тарихи романында *ян-як, як* лексик берәмлекләре шактый очрый: *«Шул миз-*

*гелдә хан сараеның ян-якларындагы тәрәзә пыялалары коелып төште һәм зал эченә дистәләгән сугышчы сикереп керде».*

***Яка*** апеллятивы татар гидронимиясендә елга ярының, диңгез ярының, су чыганакларының кырыйларын аңлата. Бу термин «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бирелмәгән.

*Яка* терминын Адлер Тимергалин болай сыйфатлый: «*Яка* – гомумтөрки сүз. Мәгънәсе – кием якасыннан тыш, *кырый, чит, як, яры, яр,* диалектта – *төбәк, чит җир*. //*Кабер якасы. Су якасы ~елга яры, су буе. Барып ул, су якасына утырып, Возу кыйлыр ирде, ул йирдә торып*. Хисам Кятиб. *Камугын Сыр якасында бөтедем. – Барын да Сыр-дәрья буенда яздым.* Харәзми».

*Яка* компоненты елга атамалары составында байтак очрый: *Елга якасы чишмәсе* – Биектау районында Казан елгасына кушыла. *Чишмә якасы* – Балтач районында Кугубор елгасы ярында. *Инеш якасынандагы чишмә* – Балтач районында Шушма елгасы ярында (чагыштыр: *Казансу якасына кала салдылар*: Насыйри, 1974: 62). *Тау якасы* – Кама Тамагы районында ага торган Коры Үләмә елгасы ярында. *Тау якасы кизләве* – Зәй елгасы бассейнында (Зәй районы). *Чирмешән якасы* – Әлки районындагы урын. *Тау якасы кизләве* – Зәй елгасы бассейны (Зәй районы).

Себер татарлары сөйләшендә *сай ягасы* – «елга-яры», «яр буе».

*Яка* термины төрки һәм төрки булмаган халыкларда да очрый. Халха-монгол телендә – *зах,* бурят телендә – *заха,* үзбәк – *яка,* уйгыр – *жага,* алтай – *jака*, кыргыз – *жака,* казак – *жага,* каракалпакларда – *жаға*, нугай телендә *дж̧ъа «*яр, кырый» төшенчәсендә кулланыла.

Бу сүз әдипләр иҗатында да кулланыла. Габдулла Тукайның «Дустларга бер сүз» дигән шигырендә мондый юллар бар:

*Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк,*
*Тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк;*
*Диңгез якасында торып, без сусамыйк, –*
*Хөрриятнең диңгезләре ташый имди.*

Айдар Хәлимнең «Кыйбла: хикәяләр һәм новеллалар» китабында *яка* лексик берәмлеге кергән мондый юллар бар: *«... гомереңне иблискә табындырып үткәрсеннәр дә, инде гүр якасына җиткәч кенә намазлык өстенә менү, кемнәрдер кебек, кичә коммунист булып, бүген ишанга әйләнү – моннан да зуррак иблислек бармы?»*

***Ялан***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *беренче мәгънәсе* исем дип бирелгән һәм «Урмансыз, куаксыз һәм корылмалар булмаган кыр, үлән яки иген генә үскән агачлык», – дип аңлатылган. *Авыл зур вә киң яланның уртасында булган бер үргә утырган*. Г. Ибраһимов. *Бакчага төшкән вакытта гына түгел, урамда, яланда очрашырга туры килсә, Ибрайны күрү белән еректан ук кача торган идек*. М. Әмир. *Алар уенга яланга баралар.* А. Таһиров.

Бу терминның *икенче мәгънәсе* «сыйфат» дип ныгытылган, аңлатмасы мондый: «Шәрә, бернәрсә белән дә капланмаган, ялангач». *Ялан тау башы. Кояш, кояш синең нурларыңнан кемнәр генә рәхәт тапмады, кемнәр сиңа ялан арка биреп, Кәефләнеп кызынып ятмады.* М. Җәлил (ТТАС, III: 630)

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә «Ялан – гомумтөрки тамырлы сүз – кыр; дала; болын. Борынгы төрки телдә *далаң* – киң бушлык, буш дала. Чуваш телендә *йалам* – болын дигән сүз. *Ялангач* сүзе дә шул тамырдан дип уйлыйлар. «Башкорт АССРның топонимнар сүзлеге»ндә *ялан* сүзе белән *елань* сүзе арасында тигезлек билгесе куела. // *Ялан кантоны* (Уфа губернасында).

Чаг.: *Алан»*.

*Япан* сүзен дә яланга нисбәтле итеп карыйбыз.

*Япан* «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә: «Киң дала яки урман-кырсыз, кешесез-авылсыз җир».

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә *япанның* аңлатмасы болай: «Ялан, кыр. Бу сүз рус телендәге «пустырь» мәгънәсен дә бирә ала шикелле. Г. Ишмөхәммәтованың «Төрки, фарсы, гарәп һәм казакча, татарча, русча сүзлекчә»сендә ябан –

япан; дача. // Япан кыр. *Яза япан* – кыр-далалар, ачык сахра. *Бийабан* – чүл («Древнетюркский словарь»). *Йапан кебек ызбада ничек курыкмый бер үзе генә тора*? «Диалектолок сүзлек», 1959.

Тагын кара: *Язи-ябан*.

*Язи-ябан, язи-япан* искергән сүз дип ныгытылган. – Кырлар, далалар, ачык сахра.

Тагын кара: *Япан»*.

*Ялан* лексик компоненты топонимнар барлыкка китерүдә катнаша: *Ялан* – Актаныш районы Иске Кормаш авылы янындагы ялан, буш җир атамасы. *Ялан аланы* – Аксубай районы Шәрбән авылы янындагы атама. *Олы ялан* – 1. Мөслим районы Тырыш, 2. Азнакай районы Әлкәй авыллары янындагы ялан атамалары.

Бу лексик берәмлек әдипләр һәм шагыйрьләр иҗатында еш очрый. Фатыйх ага Хөснинең «Без яшь идек» повестенда *ялан* лексик берәмлеге матур кулланыла: *«Шунда, ялан уртасында, язгы кояш астында күңелемнең кайсыдыр яшертен бер почмагы белән сиздем – ояла-ояла сиздем: буйга сузылган бу малайга мин җаным-тәнем белән гашыйк икәнмен»*.

Айдар Хәлимнең «Кыйбла: хикәяләр, новеллалар» дип аталган теле уйнаклап торган, нык гражданлык позиция-юнәлешләреннән торып язылган китабында *ялан* термины йөрәккә ятышлы итеп файдаланылган: *«Әкчин станцасының яшел хәтфәсендә, Тансыгының сөякләре яткан яланда, Тансыгына багышлап, шау чәчәктә утырган бакчалар аша меңләгән төп бәрәңге куакларына, җир-ихаталарга, урман-тауларга, барча кешелеккә иминлек теләп, Өммегөлсем карчык «Кәүсәр» сүрәсеннән «Мәгавен» сүрәсенә күчте»*.

Роза Хәбибуллинаның «Мулла килене» дигән романында *ялан* термины күңелне кузгатырлык итеп кулланылган: *«Хисапсыз миллионнар өчен бу сугыш заман ахыры, гомерләр кыелган мәхшәр булачак. Кояшлы яланнарда яңадан тиз генә сабантуйлар булмаячак... Мәйдан тоткан яшь, таза, асыл ирләрнең газиз башкайлары корбан булачак...»*

*Ялан* термины күп төрки телләрдә очрый. Алтай телендә ул – «кыр, үзән, тигезлек, ачык шәрә урын». О.Т. Молчанова алтай теленең көньяк диалекты вәкилләрендә терминның язылышын *айан* дип бирә һәм бу аланның биек тауларда яисә үлән чаба торган урманда урнашуын аңлата. Тывалыларда *ялан* «болынчык, алан, чирәмлек» *аян* дип йөртелә.

***Яныk***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *яныk* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай аңлатылган: 1. Нәрсә дә булса янганнан калган калдык. *Шәм яныгы* //Нәрсәнең дә булса янган урыны; 2. Урмандагы янган урын, участок //Урманны яндырып эшкәртелгән иген кыры; ышна. (ТТАС, III: 642).

*Яныk* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда шактый күп кулланыла: *Яныk* – Мамадыш районы Югары Ушмы авылындагы урам атамасы. *Йаныk басуы* – Арча районы Сикертән авылы янындагы басу атамасы. *Йаныk юлы* – 1. Арча районы Сикертән, 2. Саба районы Түбән Симет авыллары янындагы юл атамалары. *Яныk елгасы* – 1. Мамадыш районы Иске Чәбия, 2. Арча районы Сикертән, 3. Саба районы Симет, 4 Балтач районы Яңгул, Биектау районы Өлә авыллары яныннан агып үтә торган елгачыклар атамалары. *Яныk күле* – Әгерҗе районы Салагыш авылы янындагы күл. *Яныk сазлыгы* – Биектау районы Яңавыл янындагы сазлык. *Янган* лексик берәмлеген дә шушы ук рәткә кертеп карыйбыз.

*Янган аланнар* – Яшел Үзән районы Күгәй авылы янындагы алан атамасы. *Янган атау арасы* – Лаеш районы Имәнкискә авылындагы җир атамасы. *Янган җир* – Мөслим районы Симәк авылы янындагы җиләк җыярга йөри торган урын. *Янган як* – Яңа Чишмә районы Чаллы Башы авылының кайчандыр янган бер өлеше. *Янган тармак* – Әлки районы Иске Салман авылы янындагы Мәкәш чокыры кушылдыгы. *Янган теш* – Чирмешән районы Иске Кади авылы янындагы урын атамасы. *Янган чит* – Кама Тамагы районы Яңа Сала авылы янындагы урманның янган урыны. *Янган ындыр башы* – Балтач районы Иске Чепья

авылы янындагы урын атамасы. *Янган ышна* – Тәтеш районы Кече Тормы авылы янындагы басу атамасы. *Янган ял сазы* – Буа районы Зур Кырлангы авылы янындагы кизләү. *Янган ял сазы* – Буа районы Зур Кырлангы авылы янындагы сазлык, Тошы суы бассейнында. *Янган күл* – Әлки районы Түбән Әлки авылы яныннан ага торган Ата елгасы бассейнында. *Янган саз* – Буа районы Адав-Толымбай авылы янындагы саз һ. б.

***Япь***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *япь* лексик берәмлегенең географик терминга мөнәсәбәтле мәгънәсе күрсәтелмәгән. Шулай да *япь* лексик берәмлеге «исем» дип ныгытылган һәм мәгънәсе болай аңлатылган: 1. Агачның икегә яки берничәгә аерылган, ботакланган кәүсәсе яки ботагы. //Шул аерылып, ботакланып киткән урын, аерма. // Аермалы агач кәүсәсе яки ботагының аерылып торган бер сабагы, ботагы (ТТАС, III: 643). Бу сүзләрне, ягъни сүзлек шәрехләмәләрен географик берәмлекләргә (су, тау һ. б.) карата да әйтергә мөмкин булыр иде.

*Япь* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда байтак кулланыла. *Япь күле* – Буа районы Адав-Толымбай авылы яныннан агып үтә торган Зөя елгасы бассейнында. *Япьле елга* – Чүпрәле районы Зур Чынлы авылы янындагы Чынлы елгасы бассейнында. *Япьле күл* – 1. Апас районы Болын-Балыкчы, 2. Апас районы Колгына авыллары янындагы күлләр. Зөя елгасы бассейнында. *Аргы япьле күл* – Апас районы Болын-Балыкчы авылы янында. *Каенлы япь* – Балык Бистәсе районы Югары Тегермәнлек авылы янында сулы елгага тоташа.

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ут чәчәге» дип аталган повестенда *яплекә* сүзе кулланыла: *«Габделнур каршысына шуышып килгән фашист солдатының җиң эченнән чыккан яплекәсен күреп алды»*. Шул ук авторның «Ачы тәҗрибә» исеме белән дөнья күргән китабында мондый юллар бар: *«Бичара Овсеюк беседкага утырып кулларын каната-каната ярты көн буе якорь җәплекәсен кайрап утырды»*. Казан арты сөйләшләрендә *җ* һәм *йә* (я) авазлары чиратлаша. Шушы сөйләш вәкиле

буларак галим-әдип бер терминны ике төрле итеп кулланган булса кирәк.

***Яр.*** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *яр* лексик берәмлеге «исем» дип нығытылган һәм аның ономастикага мөнәсәбәтле мәгънәсе ачык итеп бирелгән: «Елга, диңгез, күл кебек сулыклар әйләнәсендә күтәрелеп торган коры җирнең чите». *Дулкыннар ярга йөгереп менәләр дә, вак ташларны өстерәп, шаулап, кире төшеп китәләр*. И. Гази. *Ватан өчен безнең йөрәкләрдә Диңгез ярындагы таш тауларын Җимереп аткан вулкан көче бар*. Ф. Кәрим. *Суның уң яр кырлары куе таллар белән күмелгән*. Ф. Хөсни (ТТАС, III: 643).

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, «Урта Казансу һәм аның кушылдыклары тирә-юнендә *Кызыл йар ~ Кызыл яр,* икенче атамасы *Җөлби җыены, Сасмак җыйыны* үткәрелгән. Аны Ашыт елгасы кушылдыклары Красна һәм Шәмәк елгалары (Казансуның уң кушылдыклары) ярына утырган Иске Җөлби, Яңа Җөлби, Комыргуҗа, Олыяз, Сасмак авыллары халкы бергә җыелып бәйрәм иткән.

Археологлар мәгълүматларына караганда, Җыен бәйрәме үткәрелә торган җирлектә болгар чоры табылдыклары, Казан ханлыгы чоры авыллары калдыклары, шул ук чорның кабер ташлары сакланып калган каберлекләр билгеләнгән».

*Яр* лексик берәмлеге географик атамалар ясауда шактый актив кулланыла. *Яр башы суы* – Апас районы Олы Болгаер авылы яныннан агып үтә торган Олы Шаһиян елгасы бассейнында. *Яр башы чыгышы* – Апас районы Олы Болгаер авылы янындагы Яр башы суы бассейнында. *Ярлар башы* – Әлмәт районы Ялхавай авылы янындагы урын атамасы. *Икенче яр* – Аккош күле кушылдыгы, Апас районының Коштаулы авылы янындагы елга. *Яшен суккан яр* – Мамадыш районы Югары Яке авылы янындагы елга ярының бер урыны. *Ярлы күл* – Чистай районы Нарат Елга авылы янындагы күл. *Яр асты чишмәсе* – 1. Арча районы Югары Сәрдә авылы янындагы Сәрдә суы ярында; 2. Биектау районы Өмбе

авылы яныннан агып үтә торган Шәмәк елгасы бассейнында. *Яр юган* – Тәтеш районы Олы Әтрәч авылы янындагы урын атамасы. *Яр суы* – Кама Тамагы районы Бәби авылы янындагы елгачык.

Нурулла Гариф сүзлегендә *яр* термины болай бирелгән: «Козыл Җияр (Кызыл Яр авылы), «тат». и «чюв.» служ. и яс. д. Ч. дор., смежна с пом. д. Ачи – № 217» (Гариф, 2011: 58).

*Яр* компоненты үзе генә дә һәм атамалар составында да шактый әйләнештә йөри. «Идегәй» дастанында ул болай ныгып калган:

*Иделнең ике ягы кызыл яр,*
*Ысбадан савыт салыр ул;*
*Иртеш башы Кара Тун,*
*Ике арасын куар ул;*
*Чиксез кузы сансыз куй,*
*Күп гаскәре туйсын дип,*
*Суеп казан асар ул.*
(Идегәй, 1988: 68)

Яр компоненты әдипләр, шагыйрьләр иҗатында да еш кулланыла. Габдулла Тукайның «Яз галәмәтләре» дип аталган шигырендә мондый юллар бар:

*Шул бакалар ярга чыгып бакылдаша,*
*Берсен берсе аңлашмыйча такылдаша;*
*Әллә нәрсә киңәшәләр акыллаша;*
*Ахры, мантыйк укыганнар бунлар имди.*

Гомәр ага Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» повестендагы гамь белән шыплап тутырылган матур җөмләләр һәм гүзәл сүзләр тезмәсеннән торган, күңелгә якын фикерләрдән тиз генә аерылып булмый: «*...Аҗги амбарын» бик тирән диләр. Ул биек кызыл яры белән болын юлына түгәрәкләнеп уелып кергән. Аның суы да үзалдына шомлы булып, кара-кучкылланып күренә. Яр буенда төнбоеклар үсеп утыра. Бер ярыннан икенче*

*ярына, уктай атылып, ак түшле көрәшчәләр (яр карлыгачы) уйнап йөри».*

Фоат Садриевның «Таң җиле» романында *кызыл яр* термины искә алынган: *«Ә Ык тын иде, аның ярга ышкылганы да сизелми, күктәге йолдызлар да, ай да елгага кереп тулганнар, алар беркая да акмый, ә менә бу кызыл яр авыл белән бергә акрын гына шуыша кебек иде».*

Э.М. Мурзаев мәгълүматлары күрсәтүенчә, *яр* термины төрле фонетик вариантлар белән барлык төрки телләрдә дә бар. Борынгы төрки телдә *jar* – «яр», «чокыр»ны аңлаткан. Азәрбайҗан телендәге – *ярган* «чокыр», «озын чокыр, сыза, коры үзән»; балкар, казак һәм кыргыз телләрендәге – *жар,* алтай – *jar,* үзбәк – *ёр,* хакаслардагы *чар* әйтеп үтелгән мәгънәләрдә кулланыла. Хакас телендә тагын «кыя» мәгънәсе дә бар.

*Яр* – биек текә яр. Бу термин ярдәмендә шактый географик атамалар ясалган: *Акъяр, Красноярское* авылы, *Красноярка, Белоярск, Красноярск.*

Кыргыз географик атамалары составында *яр* термины белән ясалган авыл атамалары очрый: *Ак-Жар* – Ош өлкәсенең Карасу районындагы Джоош, Кызылсу авыл җирлекләрендә, шул ук өлкәнең Узген районында урнашканнар. *Кызыл-Жар* елгасы – Ырдык елгасының сул кушылдыгы Ыссык күл өлкәсе, Джетиогюз районында. *Кылыяр* – Алтайда Кош-Агач һәм Турачак районнарындагы, *Кёкьяр* – Кёксу тамагы районындагы авыллар.

*Яр* термины славян телләрендә дә бар: украин телендә *яр* – «чокыр», «озын чокыр, сыза, коры үзән», «упкын, төпсез чокыр», «киң һәм озын чокыр»; белорус телендә шул ук мәгънә аңлата һәм еш кына *жар* дип тә кулланыла, поляк телендә *jar* – «чокыр», «ялпылык, уйсулык, уйсу җир (киң иңкү җир)», болгар телендә *яр* – «текә яр», словен телендә *jarek* – «озын чокыр, канау», «төпсез упкын». Шушы рәткә тагын ненец телендәге *яр* – «кырый», «як» (*кырый борын* – диңгезгә, күлгә

яки елгага очлаеп кергән коры җир), *Яр-Седаяха* – «кырыйдагы кечкенә тау елгасы»]; удмуртлардагы *яр, ярдур* – «текә яр»; «яр»; эвенк телендәге *еран* «сибелмә (тау токымнарының таркалуыннан барлыкка килгән өем)», эвен диалектындагы *jaru* «су белән юылган яр», «ишелеп төшкән өем (кар яки кыялар)» мәгънәләрендә кулланыла. Бу термин үз чиратында монгол *эрэг* – «яр», «текә яр» термины белән бәйләнгән.

Кара туфраклы үзәктә Калач шәһәре янында «зур озын чокыр, сыза, коры үзән» мәгънәсендәге *яр* термины белән ясалган *Коры яр* (Сухой яр) бар, ул 15 чакрымга сузылган. Урал елгасында *Тихий, Боевой, Разбойничий, Сторожевой, Караульный, Красный, Черный яр* исемнәре алган текә ярлар бар. Ростов-на-Дону янындарак *Почтовый Яр* бар. *Аксай Курмоярский* елгасы Донның сул кушылдыгы. Себердә *Красноярск* шәһәре, Төньяк Осетиядә *Черноярская* станицасы бар. Алтайда *Ярлу, Ярлукол* елгалары ага, *Яр-Бажи* һәм *Яр-Кобы* торак пунктлары бар; Уссури елгасында *Краснояровка;* төрле өлкәләрдә *Красный, Высокий, Черный Яр* атамалары очрый. Камчаткада *Березовый Яр* исеме алган текә яр бар. Дагстанда *Кизләр* атамасы *Кызыл Ярга* (Красный Яр) барып тоташа. *Кызыл-джар, Караяр, Акжар, Кокджар* һ. б. атамалар Россия төбәкләрендә бик күп (Мурзаев, 1984: 650–651).

М.Ф. Розен һәм А.М. Малолетко Обь елгасының сулъяк ярындагы Чижапка елгасы кушылдыклары *Куныджар, Тогулджар* һәм Суйга елгасы кушылдыклары *Каладжар*ны, Галыски (хәзер Галка) кушылдыгы *Кыльджар* елгаларын теркәгәннәр. Шулай ук бернинди дәлилләү китермичә генә алар, иран теленә мөнәсәбәтле булса кирәк дип, *Хылкандар* һәм *Пасмандар* атамасы алган елгаларны да күрсәтәләр.

***Яткылык***. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *яткылык* терминының географиягә караган мәгънәсе теркәлмәгән.

«Татар теленең диалектологик сүзлеге»ндә бу терминның ике мәгънәсе бирелгән. *Беренче мәгънәсе:* «Минзәлә сөйләшендә агым су җыелып тора торган җир (место, где нет течения, ти-

хая заводь)»; *Икенче мәгънәсе:* «Казан арты дөбьяз сөйләшендә туплавык, көтү ята торган урын (лежбище, где отдыхает табун скота)» (ТТДС, 1969: 168).

*Яткылык* лексик берәмлеге белән географик атамалар шактый ясалганнар: *Олы яткылык* – Мамадыш районы Усали авылы янындагы урын атамасы. *Эт яткылыгы* – Минзәлә районы Бикбау авылы янындагы Брустан елгасы бассейнында. *Яткылык* – Арча районы Орнаш авылы янындагы көтү туплана торган урын.

## ЙОМГАК

Кайбер җирле географик апеллятивларны карап анализланганнан соң, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин.

1. Терминнарның күпчелеге төрки телләр өчен уртак. Чөнки алар борынгы төрки чорларда, аерым төрки телләр әле баба төрки телдән аерылып чыкмаган дәверләрдә үк барлыкка килгәннәр.

2. Төрки географик терминнар бик киң җирлекләргә таралган. Бу күренеш төрки халыкларның күченеп йөрүләрен һәм дөньяның төрле кыйтгаларында үз эзләрен калдырулары турында сөйли. Аерым җирлекләрдә төрки кавем-кабиләләрнең күбесе аерым халык булып формалашканнар һәм үз дәүләтләрен дә торгызганнар.

А.В. Суперанская киң җирлекләрдә таралган топонимик параллельләрне мисал итеп китерә һәм шуның нигезендә түбәндәге нәтиҗәне ясый: «...аерым җирлектә тупланган топонимнарның төрдәшләре (вариантлар) башка урыннарда, якында яки еракта урнашкан дәүләтләр халкы телендә кулланылган географик берәмлек атамалары арасында очрый. Топонимнарның барлыкка килү юллары барлык халыкларда да бер төрле. Аерым регионнарның, яисә дәүләтләрнең топонимнар җыелмасының үзенә бертөрлелеге ул җирлектәге җәмгыятьнең тарихи һәм мәдәни үсеше этаплары һәм теленең региональ сыйфатлары белән бәйләнешле» (Суперанская, 1984: 10–11).

А.М. Малолетконың фикере мондый: «Топонимикадагы географик терминнар, телләре төрле булуга карамастан, бер халыктан икенчесенә бер-бер артлы бирелә баралар. Озак вакытлар дәверендә һәм күп тапкырлар алынма булып йөрүләре нәтиҗәсендә терминнар төрле тел төркемнәренә караган телләргә килеп керәләр, хәтта аларның кайсы телдән алынганын аеруы да кыен була башлый һәм аны элекке хәленә кайтару, ягъни реконструкцияләү дә мөмкин булмый. Ләкин алар тарихчылар, телчеләр һәм географлар өчен әһәмиятле мәгълүмат туплаган булалар». А.М. Малолетко фикерен болай дәвам итә: «...планетабызда шактый күп топонимнар, территориаль яктан ераклашуларына карамастан, яңгырашлары белән генә түгел, бәлки мәгънәләре ягыннан да тәңгәл киләләр. Бер очракта бу очраклы рәвештә туры килү булса, икенче юлы туганлык җепләренең озак гасырлар дәвамында онытылуы, ә өченче юлы – озак гасыр үзара аралашып яшәгән кавем-кабилә яисә халыкларның тел, лөгать алмашулары нәтиҗәсе буларак яшәве күзәтелә» (Малолетко, 1993: 152).

3. Татар тононимиясенең һәм шул исәптән гидронимиясенең дә терминнарга бай булуы – халкыбызның югары дәрәҗәдә үскән матди һәм рухи мәдәнияткә ия булуының чагылышы. Аларның күпчелеге элекке һәм хәзерге халыкларның физикгеографик берәмлекләр, табигать белән тыгыз бәйләнешен күрсәтәләр. Алар тарихыбызның, телебезнең борынгылыгын аңлата торган шөбһәсез дәлилләр.

4. Топонимия һәм гидронимия терминнары, топонимнар һәм гидронимнар ясау белән беррәттән, ойконимнар һәм микротопонимнарны атау өчен дә еш кулланылалар.

5. Татар топонимиясе һәм гидронимиясе терминнарынын шактый күбесе, гомумән, төрки халыклардагы шундый ук күмәклек исемнәре дә, кеше әгъзаларын белдерә торган сүзләргә нигезләнеп ясалганнар. Бу күренеш борынгы кешеләрнең табигатьтә, җирлектә дөрес юнәлеш алуны һәм табуны гәүдә әгъзаларына нигезләнеп башкаруларын күрсәтә.

Бу китабыма соңгы ноктаны куйганчы һәм куйгач та Аллаһы Тәгаләгә һәр көн саен шөкрана кылдым. Язмышыма фән белән шөгыльләнү бүләге биргән Бөек Затка бетмәс-төкәнмәс шөкрана!

Җирле гидрографик терминнарны тикшергәннән соң шушындый нәтиҗәгә килергә мөмкин:

1. Апеллятивларның күбесе төрки телләрнең күпчелеге өчен уртак. Алар, күрәсең, гомумтөрки заманаларда ук барлыкка килгәннәр.

2. Төрки-татар гидронимиясендә апеллятивларның күп булуы халкыбызның матди һәм рухи мәдәнияте нык үскән булуы белән бәйләнешле. Аларның күплеге элекке һәм хәзерге халыкларның физик-географик берәмлекләр, табигать белән тыгыз бәйләнешен күрсәтәләр.

3. Төрки-татар гидронимиясендә гидрографик терминнар гидронимик атамалар ясау белән беррәттән, ойконимнар һәм микротопонимнарны атау өчен дә еш кулланылалар.

4. Төрки-татар гидрографик апеллятивларның шактый күбесе, гомумән төрки халыклардагы шундый ук күмәклек исемнәре кебек үк, кеше әгъзаларын белдерә торган сүзләргә нигезләнеп ясалганнар. Бу күренеш борынгы кешеләрнең табигатьтә, шул җирлектә дөрес юнәлеш табулары үз гәүдәсе әгъзаларына нигезләнеп башкарылуын күрсәтә.

## ФАЙДАЛЫНГАН ӘДӘБИЯТ

*Абаев В.И.* Историко-этимологический словарь осетинского языка / В.И. Абаев. – Т. L – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1958. – 657 с; Т. II. – Л.: Изд-во АН СССР, 1973. – 449 с; Т. III. – Л.: Изд-во АН СССР, 1979. – 360 с; Т. IV. – Л.: Изд-во АН СССР, 1989. – 326 с.

*Абаев В. И.* Осетинский язык и фольклор / В.И. Абаев. – М.-Л.: АН СССР, 1949. – 603 с.

*Абаев В.И.* О собственных именах нартовского эпоса / В.И. Абаев // Язык и мышление. – Вып. 4. – М.-Л., 1935. – С. 76–78.

*Абдимуратов К.* Топонимия Каракалпакии: автореф. дис. ... канд. филол. наук / К. Абдимуратов. – Нукус, 1966. – 22 с.

*Абдрахманов М.А., Бонюхов А.А.* Топонимические названия Шории / М.А. Абдрахманов, А.А. Бонюхов // Языки и топонимия Сибири. – Вып. 1. – Томск, 1966. – С. 159–169.

*Абдрахманов М.А.* О тюркских топонимах Западной Сибири (топонимы эуштинцев и калмыков) / М.А. Абдрахманов // Уч. зап. Томского пединститута. – Т. 22. – Томск, 1965. – С. 92–94.

*Абдуллин И.А.* Армянско-кыпчакские рукописи и их отношение к диалектам татарского языка / И.А. Абдуллин // Материалы по татарской диалектологии. – Вып. 3. – Казань, 1974. – С. 166–185.

*Абдуллин И.А.* Некоторые вопросы русской передачи географических названий Татарской АССР / И.А. Абдуллин // Вопросы лексикологии и лексикографии татарского языка. – Казань, 1976. – С. 116–124.

*Абрамзон* С.*М.* Этнический состав киргизского населения северной Киргизии / С. М. Абрамзон // Труды Киргизской археолого-этнографической экспедиции. – Т. 4. – М., 1960. – С. 104–109.

*Абрамзон С.М.* Киргизы и их этногенетические и историко-культурные связи / С.М. Абрамзон. – Л.: Наука, 1971. – 404 с.

*Абрамова М.П.* К вопросу об аланской культуре Северного Кавказа / М.П. Абрамова // Советская археология. 1978. – № 1.

*Абуль-Гази.* Родословное древо тюрков / Абуль-Гази. – Казань, Tiполитография университета. – Т. XVI. – 1906.

*Авакян А.В., Салтанкин В.П., Шарапов В.А.* Водохранилища / А.Б. Авакян, В.П. Салтанкин, В.А. Шарапов. – М.: Мысль, 1987. – 325 с.

*Агаджанов* С.*Г.* Очерки истории огузов и туркмен Средней Азии IX–XIII вв. / С.Г. Агаджанов. – Ашхабад: Ылым, 1969. – 294 с.

*Агаев Х.* Вопросы этнической истории огузских племен / Х. Агаев. – Ашхабад, 1975.

*Агафий.* О царствовании Юстиниана / Агафий / Перевод М.В. Левченко. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1953. 219 с.

*Агбунов М.В.* Путешествие в загадочную Скифию / М.В. Агбунов. – М.: Наука, 1989. – 191 с.

*Агеева Р.А.* Гидронимия Москвы / Р.А. Агеева // Географические названия в Москве. – М., 1985.

*Агеева Р.А.* Гидронимия Псковских и Новгородских (Шелонская и Деревская пятины) земель в свете истории заселения края: дис. ... канд. филол. наук / Р.А. Агеева. – М., 1973.

*Агеева Р.А.* Проблема топонимического субстрата / Р.А. Агеева // Этническая топонимика. – М., 1987.

*Агеева Р.А.* Происхождение имен рек и озер / Р.А. Агеева. – М.: Наука, 1985. – 144 с.

*Агеева Р.А.* Страны и народы. Происхождение названий / Р.А. Агеева. М.: Наука, 1990. 256 с.

Аграрный вопрос и крестьянское движение 50 70-х годов XIX в. Материалы по истории народов СССР. Вып. 6. Татарская АССР. Материалы по истории Татарии второй половины XIX века. Часть первая. – М.-Л., 1936.

*Аджи Мурад.* Европа, тюрки, Великая степь / М. Аджи. – М.: Мысль, 1998. – 334 с.

*Аджи Мурад.* Полынь половецкого поля / М. Аджи. – М.: ТОО ПИК-Контекст, 1994. – 349 с.

Административная карта Казанского уезда. Масштаб 1:25 200. Казань, 1882. – 1 л., многокрас.

Административная карта Казанского уезда Казанской губернии. Масштаб 1:210 000. Казань, 1910. – 1 л., многокрас.

Административная карта Мамадышского уезда Казанской губернии. Масштаб 1:168 000. Казань, 1910. – 1 л, многокрас.

Админстративная карта Свияжского уезда Казанской губернии. Масштаб 1:210 000. Казань, 1882. – 1 л., однокрас.

*Азизов Э.И.* К истории цоканья в азербайджанских говорах / Э.И. Азизов // Проблемы диалектологии и лингвогеографии тюркских языков. – Уфа, 1986.

*Айдаров Г.* Язык орхонских памятников древнетюркской письменности VIII в. / Г. Айдаров. – Алма-Ата: Наука, 1971. – 380 с.

*Айтмуратов Д.* Тюркские этнонимы: каракалпак, черные клобуки, черкес, башкурт, кыргыз, уйгур, тюрк, печенег, сак, массагет, скиф / Д. Айтмуратов. – Нукус, 1986.

*Айуновский В.А.* Список инородческих населенных мест / В.А. Айуновский // Симбирский сборник. Т. 2. – Симбирск, 1870.

*Акбаев Ш. Х.* Сравнительно-исторический метод в тюркологии и генезис балкарского цоканья / Ш. Х. Акбаев // Сов. тюркология. – 1971. – № 2.

*Акишев А.К.* Новые художественные бронзовые изделия сакского времени / А.К. Акишев // Прошлое Казахстана по археологическим источникам. – Алма-Ата, 1976.

*Аксаков С.Т.* Литературные и театральные воспоминания / С.Т. Аксаков. – М., 1886.

Актуальные проблемы карачаево-балкарского и ногайского языков. – Ставрополь, 1981.

Актуальные проблемы советского уйгуроведения: Материалы I респ. уйгур. конф. 29–31 мая 1979 года. – Алма-Ата, 1979.

Акты исторические, собранные и изданные археографическою комиссиею. – СПб., 1841–1842. – Т. I–V (Акты И.)

Акты, относящиеся до юридического быта древней России, изданные археографическою комиссиею под ред. члена комиссии Н. Калачова. – СПб., 1857. – Т. I; СПб., 1864. – Т. 2; СПб., 1854. – Т. 3. (Акты Ю).

Акты членов ревизионной комиссии, образованной Казанским губернатором для рассмотрения деятельности Казанского Городского Общественного Управления за 1905 1908 гг. – Казань, 1911. – Т. I (Акты Р).

*Алабин П.* Несколько старинных документов, относящихся до истории Самары и Самарского края / П. Алабин. – Самара, 1890.

*Алексеева Т.А.* Словообразующие омоморфемы в персидском языке: Автореф. дис. ... канд. филол. наук / Т.А. Алексеева. – Баку, 1964.

*Алексеев В.П.* Очерк происхождения тюркских народов Восточной Европы в свете данных краниологии / В.П. Алексеев // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. – Казань, 1971.

*Алексеев В. П.* Происхождение народов Кавказа / В.П. Алексеев. – М., 1974.

*Алексеев В.П.* Ранние формы религии тюркоязычных народов Сибири / В.П. Алексеев. – Новосибирск, 1980.

*Алиев А.И.* Топонимия западных районов Азербайджана: Автореф. дис. ... канд. филол. наук / А.И. Алиев. – Баку, 1975.

*Алиев У.Б.* Диалектное членение языка карачаевцев и балкарцев // Вопросы диалектологии тюркских языков / У.Б. Алиев. – Баку, 1963.

*Алимов С.* Из ономастики Памира / С. Алимов // Ветер странствий. – М., 1971. – Вып. VI.

*Али Рахим.* Булгаро-татарские эпиграфические памятники в Вятском крае / Али-Рахим // Материалы по охране, ремонту и реставрации памятников ТАССР. – Казань, 1930. – Вып. 4.

*Алишев С.Х.* Историки. Татарский народ / С.Х. Алишев. – Казань: Форт-Диалог, 1998. – 63 с.

*Алишев С.Х.* Исторические судьбы народов Среднего Поволжья (XVI – начало XIX веков) / С.Х. Алишев. – М.: Наука, 1990. – 270 с.

*Алишев С.Х.* Источники и историография города Казани / С.Х. Алишев. – Казань: Диалог-Компьютерс, 2001. – 71 с.

*Алишев С.Х.* Казан тарихы сәхифәләреннән / С.Х. Алишев // Соц. Татарстан. – 1979. – 24 март.

*Алишев С.Х.* Казан ханлыгы чорындагы татарча чыганаклар / С.Х. Алишев. – Казань, 2002. – 71 б.

*Алишев С.Х.* Казань и Москва: Межгосударственные отношения в XV–XVI вв. / С.Х. Алишев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. – 159 с.

*Алишев С.Х.* По следам минувшего / С.Х. Алишев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 128 с.

*Алишев С.Х.* Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании / С.Х. Алишев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1973. – 213 с.

*Алпаров Г.* Сайланма хезмәтләр / Г. Алпаров. – Казань, 1945.

Алфавит волостей и селений Уфимской губернии. – Уфа, 1902.

Алфавитный список населенных пунктов Нижегородской губернии (в границах на 1 января 1925 г.) – Н.-Новгород, 1925.

*Альбиков Х.* Кирәкле үтенечкә җавап / Х. Альбиков // Шура. – 1911. – № 22.

*Аманжолов С.А.* Вопросы диалектологии и истории казахского языка / С.А. Аманжолов. – Алма-Ата, 1959.

*Амин аль-Холи.* Связи между Нилом и Волгой в XIII–XIV вв. Сокр. пер. с араб / Амин аль-Холи. – М., 1962.

*Амирханов Р.М.* Татарская социально-философская мысль средневековья (XIII – середина XVI веков.). В 2-х книгах / Р.М. Амирханов. – Книга первая. – Казань, 1993.

*Амирханов Р.М.* Татарская социально-философская мысль средневековья. В 2-х книгах / Р.М. Амирханов. – Книга вторая. – Казань, 1993.

*Амирхан Р.У.* Золотая Орда и ее правители / Р.У. Амирхан. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2003. – 72 с.

*Амирхан Р.У.* Мы татары / Р.У. Амирхан. – Казань: Магариф, 2002. – 32 с.

*Амирханов Р.У.* Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восход-Запад» (на примере развития русской культуры) / Р.У. Амирханов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. 240 с.

*Амирханов Р. У.* Татарский народ и Татарстан в начале XX века: Исторические зарисовки / Р.У. Амирханов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – 152 с.

*Аммиак Марцеллин.* История / Аммиан. – Киев, 1906–1908. – Вып. I–III.

*Аннинский С.А.* Рассуждение Тьеполо о Московии / С.А. Аннинский. – М.-Л., 1940.

Античная география / составитель проф. М.С. Бозпорский. – М., 1953.

Античные города Северного Причерноморья. – М.-Л., 1955. – Т. I.

*Антонов Н.К.* Материалы по исторической лексике якутского языка / Н.К. Антонов. – Якутск: Якуткнигоиздат, 1971. – 175 с.

*Антонов Ф.М.* Карта Казанского уезда / Ф.М. Антонов. – Казань, 1881. Масштаб в англ. дм. 6 верст, 1 л., двухкр.

Антропонимика: Сб. статей / ред.: В.А. Никонов, А.В. Суперанская. – М.: Наука, 1970. – 360 с.

*Анчабадзе З.В.* Кипчаки Северного Кавказа по данным грузинских летописей XI–XIV вв. / З.В. Анчабадзе // Материалы сессии по проблеме происхождения балкарского и карачаевского народов. – Нальчик, 1960.

Арабо-персидские источники о тюркских народах. – Фрунзе: Илим, 1973.

Арабский аноним XI века. Издание текста, перевод, введение в изучение памятника и комментарии П.А. Грязневича. – М., 1960.

*Аракел Даврижеци.* История. Перевод с армянского, предисловие и комментарии А.А. Ханларян / Аракел Даврижеци. – М., 1972.

*Ардашев П.Н.* Татарские земельные письма XV века и спорное дело XVIII в. о ясашных землях / П.Н. Ардашев. – М., 1908. – 20 с.

*Ардзинба В.Г.* Ритуалы и мифы древней Анатолии / В.Г. Ардзинба. – М.: Наука, 1982. – 253 с.

*Аристов Н.А.* Заметки об этническом составе тюркских племен и народностей и сведения об их численности / Н.А. Аристов // Живая старина. – СПб., 1896. – Вып. III–IV.

*Аристов Н.А.* Заметки об этническом составе тюркских племен и народностей и сведения об их численности / Н.А. Аристов // Живая старина. – СПб., 1897. – Вып. 3, 4 (отдельный оттиск).

*Арнольдов М.В.* Из путевых заметок по Буинскому уезду / М.В. Арнольд // Симбирские губернские ведомости. – 1966. № – 6.

*Арсланова Ф.Х., Чариков А.А.* Каменные изваяния Верхнего Прииртышья / Ф.Х. Арсланова, А.А. Чариков // Советская археология. – 1974. – № 3.

*Арсланов Л.Ш.* Из материалов диалектологической экспедиции 1968 года в Волгоградскую и Астраханскую области / Л.Ш. Арсланов // Материалы по татарской диалектологии. – Казань: Татар, кн. изд-во, 1974. – Вып. 3. – С. 136–144.

*Арсланов Л.Ш.* О влиянии языка юртовских татар (ногайцев) на язык татар Наримановского района Астраханской обл. / Л.Ш. Арсланов // Вопросы татарского языкознания. Уч. Зап. Казанского пед. ин-та. – Казань, 1978. – Вып. 186. – С. 107–119.

*Артамонов М.И.* История хазар / М.И. Артамонов. – Л.: Изд-во Эрмитажа, 1962. – 523 с.

*Артамонов М.И.* К вопросу о происхождении скифов / М.И. Артамонов // Советская археология. – 1950. – № 2.

*Артамонов М.И.* Киммерийцы и скифы (от появления на исторической арене до конца IV в.н.э.) / М.И. Артамонов. – Л.: Изд-во Ленин. универ., 1974. – 156 с.

*Артамонов М.И.* Очерки древнейшей истории хазар / М.И. Артамонов. – Л.: СОЦЭКГИЗ, 1936.

*Артамонов М.И.* Сокровища саков / М.И. Артамонов. – М.: Искусство, 1973. – 280 с.

*Артемьев А.* Древний булгарский город Жукотин / А. Артемьев. – СПб., 1851.

